Татарстан Фәннәр академиясе
А.Х. Халиков исемендәге археология институты

Фаяз Хуҗин

# БОЛГАР-ТАТАР ТАРИХЫННАН САЙЛАНМА ХЕЗМӘТЛӘР

Казан
2026

УДК 902
ББК 63.444/63.401
Х98

**Җаваплы редактор:**
тарих фәннәре докторы, академик А.Г. Ситдыйков

**Бәяләмә язучылар:**
тарих фәннәре докторы, профессор Г.М. Дәүләтшин,
тарих фәннәре кандидаты, доцент А.З. Нигамаев

**Х98 Хуҗин Ф.Ш.**

**Болгар-татар тарихыннан сайланма хезмәтләр = Избранные труды по болгаро-татарской истории** / Җаваплы редактор А.Г. Ситдыйков. – Казан: ТФА нашрияте, 2026. – 328 б.

**ISBN 978-5-9690-1516-6**

Тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Фаяз Шәрип улы Хуҗинның укучыларга тәкъдим ителә торган элеге китабы галимнең 75 яшьлек юбилее уңаеннан чыгарыла. Биредә авторның төрле елларда язылган фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләре урын алган. Алар киң фәнни диапазонга ия булган, татар дөньясында гына түгел, Россия һәм чит илләрдә дә танылган күренекле галимнең урта гасырлар чорында яшәгән бабаларыбыз турында үзенчәлекле карашларын шактый төгәл ачып бирәләр.

Китап татар телле укучыларга – беренче чиратта, югары уку йортлары укытучыларына һәм студентларына, музей һәм китапханә хезмәткәрләренә, ерак тарихыбыз белән кызыксынучы зыялыларыбызга тәгаенләнә.

ISBN 978-5-9690-1516-6

© ТФА, Археология институты, 2026
© Хуҗин Ф.Ш., 2026

## ЭЧТӘЛЕК


Автордан Сүз башы ....................5

Җаваплы редактордан Кереш: Казан археология мәктәбе традицияләрен лаеклы дәвам иттерүче олуг галимебез (Фаяз Шәриф улы Хуҗинның 75 еллык юбилее уңаеннан) ....................8

**Татарстан археологиясе тарихыннан**

Казан археология мәктәбенә нигез салган галим: Н.Ф. Калинин ....................19

Атаклы галим – гадилек һәм бөеклек үрнәге (Альфред Халиков шәхесенә тасвирлама) ....................27

Тел әдәбият һәм тарих институтында Татарстан археологиясе ....................32

**Болгар бабаларыбыз мирасы**

Хәзерге Татарстан җирләре һуннар һәм Төрки каганлыклары чорында: историографик күзәтү ....................46

Кубрат хан һәм аның «хәзинәсе». Хазар дәүләте идарәчеләре ....................58

Болгар шәһәре һәм Урта Иделдә Ислам цивилизациясе ....................66

Европа халыклары тарихында һәм мәдәниятендә болгарлар мирасы ....................172

Чынгызхан татарлар нәселеннәнме? ....................187

Алтай якларыннан – Дунай буйларына: борынгы бабаларыбыз эзеннән ....................191

**Идел болгарлары һәм аларның күршеләре**

Россия дәүләтчелегенең оешу тарихыннан ....................198

Идел Болгарлары, славяннар һәм Борынгы Русь: элгәреге урта гасырлар чорында мәдәни, икътисади һәм этносәяси багланышлар ....................204

Татарлар һәм башкортлар – кардәш халыклар ....................220

Чуашларның килеп чыгышы мәсьәләсенә карата ....................224

**Тәнкыйть мәкаләләре, бәяләмәләр**

Риваять-легендаларда болгар-татар тарихы ....................236

Тагын бер тапкыр «Иске Казан» турында ....................247

Коми-пермякларның борынгы бабаларында игенчелек һәм шул өлкәдә болгарлар мирасы (А.Н. Сарапуловның «Средневековое земледелие Пермского Предуралья по археологическим данным» дигән монографиясе турында ....................254

«Шайтан-каласы» – Ак мәчет ул (язучы Мөсәгыйть Хәбибуллинның яңа романы турында) ....................262

Вахит Имамов иҗатында татар тарихы ....................267

Язучының иң уңышлы әсәре
(Вахит Имамовның «Утлы дала» романы тарихчы күзлегеннән) ....................275
Хак тарихны кайтару юлында. Түгәрәк өстәл .............................................284
Идел болгарлары тарихы турында яңа китап: Георги Владимиров.
Великата България на Волга през средните векове ....................................289
Казан ханнарының мәшһүр хатыннары турында роман-трилогия
(Ольга Иванова. Повелительницы Казани: Нурсолтан. Гаухаршад.
Сююмбика) .....................................................................................................296
Борынгы бабаларыбыз нинди телдә сөйләшкән?
Профессор Марсель Бакировның «Тайны происхождения наших
предков (историко-лингвистическое исследование» дигән китабын
укып чыккач туган фикерләр .........................................................................305
**Йомгаклау урынына**
Средневековые предки татарского народа
на страницах вузовских учебников ...............................................................316
Кыскартмалар исемлеге .................................................................................327

# АВТОРДАН СҮЗ БАШЫ

Хөрмәтле укучылар,

2011 елда, 60 еллык юбилеема туры китереп, үземнең сайланма хезмәтләремне рус телендә бастырып чыгарган идем[1]. Аннан соң шәкертләрем, рәхмәт төшкерләре, биш ел саен кабатланып торган юбилейларыма багышлап, халыкара фәнни конференцияләр үткәрә башладылар. Ул конференцияләрдә укылган докладлар махсус җыентыкларда дөнья күрде[2]. Ә менә үзем, 2011 елгы тәҗрибәмне искә төшереп, зыялы укучылар өчен кызык булачак дип тәгаенләнгән кайбер фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләремне татарча җыентык итеп бастырып чыгарырга җөрьәт итәм. Шулайрак фикерләдем: ана телебез бетә бара, татарча укучылар һәм сөйләшүчеләр саны кими, әмма ул барыбер беркайчан да юкка чыкмаячак, яшәячәк. Ахырчиктә, бәлки ерак киләчәктәдер, әнә шундый ватанпәрвәр затлардан зыялы бер төркем барлыкка киләчәк. Менә шул төркемдәгеләр инде татарларның сөйләм телен генә түгел, фән телен дә, аерым алганда тарих, археология, нумизматика, эпиграфика, этнография, антропология кебек гуманитар фәннәр телен дә үстерү, камилләштерү турында уйлый башлаячак. Һичшиксез шулай булачак!

Әйе, татар теле һәм әдәбиятында фәнни терминология эшләнгән, фәнни хезмәтләр, фәнни-популяр китаплар чыга тора. Ә менә тарих буенча татар телендә язылган чын фәнни китаплар юк дәрәҗәсендә. Кулланыла торган фәнни терминнар башлыча йә урыс телендәгечә, йә гарәп-фарсычадан алынган.

Археологиянең исә үз теле, чит терминнар белән чүпләнгән авыр тел, күпләргә әле аның русчасы да аңлашылып җитми («открытый лист», «материковый слой», «камералка», «гребенчато-шнуровой, накольчатый, струйчатый орнаменты»). Мәрхүм Равиль Фәхретдиновка кадәр әле бит «селище» сүзенең дә татарчасы («авыллык») юк иде. Сезнең кулдагы китапка кертелгән һәм русчадан татарчага тәрҗемә итеп бирелгән кайбер мәкаләләрдә мин инде тарихи һәм археологик терминнарны татарча бирергә тырыштым, шулай да аларның эчтәлеген, уку өчен җиңелләштерү максаты белән, бераз «популярлаштырырга» кирәк дип таптым.

Татар теленең фәнни терминологиясе проблемалары галимнәрне күптән борчый, бу – мин күтәргән проблема икән дип аңлашылмасын. Татарстан

---

[1] Исследования по булгаро-татарской археологии. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2011. 468 с.

[2] Средневековая археология Волго-Уралья. Сб. науч. тр. к 65-летнему юбилею Фаяза Шариповича Хузина / отв. ред. А.Г. Ситдиков. Казань: Ин-т археологии им. А.Х. Халикова АН РТ, 2016. 164 с., 8 с. цв. вкл.; Археология евразийских степей / гл. ред. А.Г. Ситдиков. 2021. № 3. 323 с.

Дәүләт (Милли) архивының 1995 елдан бирле чыгып килә торган «Эхо веков. Гасырлар авазы» журналы да, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ТӘТИ) тарафыннан 2014 елдан башлап чыгарыла торган «Фәнни Татарстан» журналы да әлеге проблемаларга игътибарсыз калмады. Институт галимнәре арасында да фәнни терминология темасына караган диссертация язучылар, китаплар чыгаручылар булды. Әмма аларның хезмәтләре укучыларның киң даирәсенә барып җитми. Алай гына да түгел, татар тарихы, филологиясе һәм сәнгате белән шөгыльләнүче яшь галимнәр арасында ана телен мөкәммәл белүчеләр саны кими бара. Киләчәктә ничек булыр? – күз алдына китерү дә куркыныч.

Әнә шуларның бөтенесен дә уйлап әйтәм инде мин бу сүзләрне. Әйе, татарның борынгыдан башлап бүгенге көннәрне дә колачлаган фәнни тарихын ана телебездә дә яза башларга кирәк. Татарстан китап нәшрияты да әлеге мәсьәләгә җитди игътибарын юнәлтер дип ышанам. Дамир Исхаков, Илдус Заһидуллин, Искәндәр Гыйләҗев, Җәмил Мөхәммәтшин кебек бөтен төрки-татар дөньясында танылу алган мәшһүр тарихчыларыбызның фәнни китапларын – монографияләрен татар телендә дә күрәсе килә. Укылачак алар, соңгы елларда халык үз тарихы белән ныграк кызыксына башлады. Шатланырлык хәл: истәлекләр җыеп, булдыра алганча архив материалларын өйрәнеп, төбәк тарихларын язу һәм шәҗәрәләр төзү кебек эшләрне мөстәкыйль башкаручы һәвәскәр тарихчыларыбыз да күп хәзер.

Сез кулга алган китап татар телле укучыларга – беренче чиратта, югары уку йортлары укытучыларына һәм студентларына, музей һәм китапханә хезмәткәрләренә, урта белем бирү мәктәпләренең университет белеме булган тарих укытучыларына, кыскасы, ерак тарихыбыз белән кызыксынучы зыялыларыбызга тәкъдим ителә. Биредә күтәрелгән проблемалар сезне дә битараф калдырмас дип ышанам.



## ҖАВАПЛЫ РЕДАКТОРДАН КЕРЕШ: КАЗАН АРХЕОЛОГИЯ МӘКТӘБЕ ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ЛАЕКЛЫ ДӘВАМ ИТТЕРҮЧЕ ОЛУГ ГАЛИМЕБЕЗ

**(Фаяз Шәриф улы Хуҗинның 75 еллык юбилее уңаеннан)**

Республикабызның әйдәп баручы, күренекле галимнәре арасында остазыбыз Фаяз Хуҗинның да исеме бар. Хәер, ул күпсанлы фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләре аша бөтен Россиядә, хәтта чит илләрдә дә билгеле шәхес. Фән дөньясына беренче адымнарын ул әле 1969 елда ук, Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультеты студенты буларак Биләр археологик экспедициясендә башлап җибәрә. 1974 елдан – профессиональ археолог.

Сокланырлык дәрәҗәдә эш сөючән, талантлы һәм дөрес куелган максатына ирешүдә көчен кызганмый торган олуг галимебез әле һаман да – 50 елдан артыграк! – яраткан фәненә, Казан археология мәктәбенең данлы традицияләрен саклауга, бүгенге яңа шартларда ул традицияләрне тагын да баетуга хезмәт итә,

Фаяз Шәриф улы Хуҗин – тарих фәннәре докторы (2002), Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы (2004), А.Х. Халиков исемендәге Археология институты баш гыйльми хезмәткәре, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты (1994), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (2002).

Ул 1951 елның 1 августында Татарстанның Зәй районы Карман авылында туган. 1968 елда Бигеш урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетында укып, 1972 елда тарих белгечлеге буенча югары белем турында диплом ала. Ике ел Зәй районының Кадер сигезьеллык мәктәбендә укытып алганнан соң аны Казанга, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының археология һәм этнография секторына фәнни хезмәткәр итеп эшкә чакыралар. 1996 елдан ул – Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында әйдәп баручы гыйльми хезмәткәр, 2007 елдан – шул ук институтта баш гыйльми хезмәткәр, 2014 елдан – А.Х. Халиков исемендәге Археология институты баш гыйльми хезмәткәре,

В 1987 елда СССР Фәннәр академиясе Археология институтының Ленинград филиалында «Биләр шәһәрлеге: стратиграфиясе һәм хронологиясе» темасына кандидатлык (рәсми оппонентлары проф. И.В. Дубов, доц. Ф.Д. Гуревич), 2002 елда Удмуртия дәүләт университетында «X – XIII гасыр башында болгар шәһәрләре» темасына докторлык (рәсми оппонетлары академик В.В. Седов, профессорлар М.Г. Иванова, А.М. Белавин) диссертацияләре яклый.

1974–1988 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәи тарих институты (ТӘТИ) белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән Биләр археология экспедициясе җитәкчесе урынбасары, 1989–1994 елларда шул ук экспедиция җитәкчесе,1994–2005 елларда – ТӘТИ (1997 елга кадәр) һәм Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының «Казан кремле» археология экспедициясе җитәкчесе.

* * *

Фаяз Хуҗинның ярты гасыр буена алып барылган фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешләре – Идел Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы археологиясе. Аның шул өлкәләргә караган 40тан артык китап-монографияләре, урта мәктәп укучылары, югары уку йортлары студентлары өчен дәреслекләре, уку ярдәмлекләре (бер өлеше автордашлар белән), 700дән артык фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләре басылып чыккан. Чит илләрдә немец, инглиз, болгар, төрек, чех телләрендә дөнья күргән хезмәтләре дә байтак,

Фаяз Шәриф улы гыйлем дөньясындагы киләчәк язмышы шулай уңышлы килеп чыкканы өчен үзенең легендар остазы Альфред Хәсәнович Халиковка рәхмәтле. Нәкъ менә ул яшь кенә авыл егетен, тыйнак кына пединститут студентын, тапшырылган эшкә җаваплы каравы, аны сөеп, җиренә җиткереп башкаруы, фикерләүдәге мөстәкыйльлеге һәм коллектив белән тыныч кына, конфликтка кермичә генә эшли алу сәләтен, яраткан фәне белән җитди кызыксынуын, кыскасы, археолог профессиясе өчен иң кирәкле сыйфатларны күрептер инде, башкалардан аерып алып, аның янында ешрак булырга тырыша, ирексезләмичә генә археология серләренә төшендерә башлый. Практикант исә дүрт ел институтта уку дәверендә тәҗрибәле археологлар белән башка экспедицияләрдә эшләп алу мөмкинлеген таба, таш һәм бронза, элгәреге болгарлар чоры истәлекләрен казып тикшерүдә катнаша.

1969 елның июлендә икенче курска гына күчкән студент-практикант Хуҗин изге Биләр җиренә аяк басканда археологик казу эшләренең әле башлангыч чоры гына була. Шуңа карамастан, яңа табылдыклар, күзәтүләр, ачышлар Биләр тарихына бәйле элеккеге карашлар кысасына сыймый башлыйлар. Җавапларга караганда сораулар күбрәк була.

А.Х. Халиков Биләр археологиясендә эшли алырдай төре белгечләрдән (архитекторлар, палеоботаниклар, палеозоологлар, һәм дә фотографлар, сызымчылар, лаборантлар) торган

зур гына дус коллектив оештыра һәм аның белән җитәкчелек итү эшенә Ф.Ш. Хуҗинны да тарта. Бер үк вакытта ул яшь галимгә кандидатлык диссертациясе өчен кызык, әмма бик тә бәхәсле тема тәкъдим итә – Идел Болгары дәүләте тормышында әһәмиятле урын биләп торган, аның башкаласы ролендә танылган Биләрнең культура катламы стратиграфиясе һәм табылдыкларның хронологиясе нигезендә барлыкка килү һәм җимерелү вакытларын ачыкларга, үсешенең төп этапларын билгеләргә.

Күп көч сорый торган тема. Фаяз Шәрипович мавыгып эшли, материаллар туплау һәм аларны фәнни эшкәртү... унөч елга сузыла. «Мин ашык-пошык эшләп тиз генә яклауга омтылмадым да, – дип искә ала ул хәзер шул вакытларны. – Археологиягә кереп чуму, яңа материалларны анализлап, мәкаләләр язу процессын мин башта ниндидер бер күңел бәйрәме рәвешендәрәк кабул иттем һәм ул бәйрәмнең озаккарак сузылуын теләдем. Әмма көннәрдән бер көнне Альфред Хәсәнович мине үз янына чакырды да бүлек утырышында минем диссертацияне тикшерү кирәклеге турында сүз кузгатты. Мин язылып бетмәгән диссертациямне тәмамлау өчен ике атна вакыт сорадым һәм нигездә вакытында төгәлләдем дә. 1986 елның апрелендә Ленинградта Археология институтының славян-фин археологиясе бүлегедә тикшерелгәннән соң, аны яклауга тәкъдим иттеләр. Яклау 1987 елга билгеләнгән иде. Шөкер, көтелмәгәнчә җиңел үтте». Монда бернинди хикмәт тә юк, әлбәттә, – диссертация күпсанлы яңа чыганакларга, авторның басма хезмәтләре аша инде фәнни даирәдә шактый таныш мөстәкыйль тикшеренүләре нәтиҗәсенә нигезләнгән иде.

Остазы А.Х. Халиков белән берлектә монгол яуларына кадәр Идел Болгарының башкаласы булып торган Биләрдәге археологик тикшеренүләр Идел-Урал төбәгенең урта гасыр шәһәрләрен өйрүнүдә яңа этап ачып җибәрде. Ф.Ш. Хуҗинның фәнни хезмәтләрендә, шул исәптән, 1995 елда чыккан монографиясендә, Биләр шәһәрлегенең стратиграфиясе һәм хронологиясе мәсьәләләре ышандыргыч аргументлар китереп ачыкланган, аның Болгар иленә Багдад илчелеге килгән 922 елдан башлап дәүләт башкаласы ролен үтәгән булуы расланган. Ф.Ш. Хуҗин һәм, әлбәттә инде, А.Х Халиков хезмәтләре һәм дә аларның коллегалары тырышлыгы нәтиҗәсендә Биләр археологлар тарафыннан яхшы өйрәнелгән тарихи истәлекләр исемлегенә керде.

1980-нче еллар ахырында – 1990-нчы еллар башында Ф.Ш. Хуҗин тикшеренүләр диапазонын киңәйтә: моңа кадәр начар өйрәнелгән Сувар, Җүкәтау, Чаллы (Балык Бистәсе)ише шәһәрлекләргә экспедицияләр оештыра, фәнни консультант булarak, үзенең шәкерте А.З. Нигамаевка Кирмән һәм Алабуга («Шайтан каласы») шәһәрлекләрендә казу эшләре башлап җибәрүдә булыша, Яңа ачышларның нәтиҗәләре «Волжская Булгария в домонгольское время» (Казань, 1997, 183 с.), «Булгарский

город в X – начале XIII в.» (Казань, 2001. 480 с.), «Ранние булгары и Волжская Булгария. VIII – начало XIII в.» (Казань., 2006. 583 с.) кебек фундаменталь монографиярендә, күпсанлы мәкаләләрендә бәян ителә. Әлеге хезмәтләрендә Ф.Ш. Хузин күз алдына киң эрудицияле, археология и тарих (язма) чыганакларын тикшерү методикасын тирәнтен үзләштереп, уңышлы кулланучы галим буларак килеп баса.

Урта гасырлар чорындагы Казанның археологиясе һәм тарихы – галимнең соңгы еллардагы фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән. Билгеле булганча, башкалабызга нигез салыну вакыты турындагы мәсьәлә озак еллар буе бәхәсле булып кала бирде. Бәхәсләргә 1970-нче еллардагы А.Х. Халиков тикшеренүләре дә нокта куя алмады. Казанның яше турындагы мәсьәлә яңа бер көч белән егерме еллап вакыт үткәннән соң яңадан калкып чыкты – Кремльдә башланып киткән ремонт-төзү эшләре вакытында борынгы культура катламнарын җимертү, юкка чыгару куркынычы килеп туган иде. Каты авырудан соң яңа гына тернәкләнеп килгән Альфред Хәсәновичка 1994 елның яз башында казу эшләрен башлап җибәргә рөхсәт бирелде. Кызганыч, июль ахырында ул мәңгелеккә күчте, экспедиция белән җитәкчелек итү эше аның шәкерте Фаяз Шәриф улы Хуҗинга тапшырылды.

«Дөресен генә әйткәндә, баштарак мине шәһәребезнең яше проблемасы артык кызыксындырмады, – дип искә ала Фаяз Шәрипович. – заманында Халиков тәкъдим иткән датага (1177 ел) мин ышана идем әле. Безгә беренче чиратта Кремльнең культура катламын саклап калырга кирәк иде. Казу эшләре вакытында тупланган табылдыклар нигезендә аның яшен төгәлрәк итеп билгеләргә мөмкин булыр иде. Археология материаллары нигезендә расланган теләсә кайсы дата мине канәгатьләндерергә тиеш, дип уйладым ».

Тәҗрибәле археолог һәм талантлы оештыручы Ф.Ш. Хуҗин үзенең остазы кебек үк, эшне булдыклы, яшь, дус коллектив төзүдән башлап җибәрә. Киң күләмдә үткәрелгән казу эшләре Татарстан башкаласы тарихының элгәрерәк чорларына нисбәтле сокланырлык ачышлар белән тәмамлана. Моның өчен асылда ял көннәрсез һәм отпускларсыз үткәрелгән ун ел вакыт кирәк була. Киеренке хезмәт Россиянең һәм чит илләрнең гыйльми үзәкләренә кыска вакытлы командировкалар белән генә өзелеп тора. Ф.Ш. Хузинның, аның шәкертләренең һәм коллегаларының археологик чыганакларга таянып Казанның яшен билгеләүгә багышланган хезмәтләре Россия һәм чит ил белгечләре тарафыннан югары бәягә лаек була, халыкара танылу ала. Әлеге мәсьәлә буенча Фаяз Шәрипович төп докладчы сыйфатында төрле халыкара конференцияләрдә, симпозиумнарда, Татарстан Фәннәр академиясе президиумы утырышларында, Россия Фәннәр академиясенең гуманитар фәннәр бүлегендә чыгышлар ясый. Шунысы мөһим, Россия Фән-

нәр академиясе тарафыннан урта гасыр шәһәрләренең яшен ачыклау мәсьәләсендә Казан галимнәре тәкъдим иткән методика шәһәрләрнең елъязмаларда беренче тапкыр телгә алынган даталарына карап билгеләүгә нигезләнгән иске методикага караганда камилрәк дип табылды.

Фаяз Шәрипович Алабуганың 1000 еллык яшен раслауга да үзеннән саллы өлеш кертте. «Шайтан каласында» һәм шәһәрнең тарихи үзәгендә алып барылган казу эшләре белән аның шәкерте, педуниверситет доценты А.З. Нигамаев җитәкчелек итте һәм бу эшләрнең барысы да остазыбызның актив катнашында алып барылды.

Басым ясап әйтергә тиешбез: урта гасыр шәһәрләренең яшен аныклауга караган яңа методика Чабаксар, Ульяновск (Сембер), Саратов (Сарытау), Волгоград (Царицын, Сары-чин) Әстерхан (Хаҗитархан)ише шәһәрләрнең рәсмиләштерелгән тарихта кабул ителгән барлыкка килү вакытларына төгәллек кертергә дә мөмкинлек бирә. Санап үтелгән шәһәрләр, хәрби крепостьлар буларак, Иван Грозный хакимияте вакытында төзелгәннәр дип санала иде. Чынлыкта исә алар, рус крепостьлары, археологик материаллар күрсәткәнчә, Идел Болгары һәм Алтын Урда чорындагы болгар-татар шәһәрләре нигезендә калкып чыкканнар, дип саный Ф.Ш. Хуҗин.

Соңгы елларда галимебезне татар халкының борынгы бабалары археологиясенә һәм тарихына караган бәхәсле проблемалар кызыксындыра. Алар арасында элгәреге болгарларның ярымкүчмән тормыштан утрак тормышка күчү, аларның Борынгы Русь һәм рус кенәзлекләре белән хәрби-сәяси һәм икътисади-мәдәни бәйләнешлары, Идел-Урал төбәкләренең этномәдәни киңлекләрен формалаштыруда «постпетрогром» культурасының, ә чуашларның этнос буларак калыплашуында болгар-суарларның роле кебек элгәреге тимер гасырыннан башлап (б.э. га кадәр I меңьеллык), XVI гасырга кадәрге чорны үз эченә алган актуаль темалар бар.

Галимнең хезмәтләре фәнни яктан ышанычлы фактларга нигезләнүләре, хәл итәсе проблемаларны куюда һәм бәхәсле мәсьәләләрне чишүдәге кыюлыгы, нәтиҗәләр ясаганда беренче планда тарихи чыганакларга нигезләнүләре белән аерылып торалар.

Ф.Ш. Хуҗинның 130 дан артык фәнни җыентыкларның, коллектив хезмәтләрнең, «Поволжская археология», «Археология Евразийских степей», «Гасырлар авазы. Эхо веков», «Фәнни Татарстан» кебек журналларның җаваплы редакторы, редакция әгъзасы һәм төзүчесе буларак хезмәтләрен дә онытмаска кирәктер. Җаваплы редактор сыйфатында ул, мәсәлән, 7 томлык «История татар с древнейших времён» коллектив монографиясенең икенче (Волжская Булгария и Великая степь. Казань, 2006. 960 с.), шулай ук 7 томлык «Археология Волго-Уралья»ның V (Средние века. VIII– начало XIII вв.: Волжская Болгария. Финно-угорский мир. Кочевники Восточной

Европы. Казань, 2022. 888 с.) һәм VII (Позднее средневековье. Середина XV – XVII вв. Казань, 2022. 532 с.) томнарын бар яктан да яхшы сыйфатлы итеп чыгаруда катнашты.

Фаяз Хуҗин менә дигән библиограф та икән әле ул. Эшчәнлегенең бу ягына без моңарчы нишләптер игътибар итмичә килгәнбез. Баксаң, әле ул А.Х. Халиковның 1989 елда аның 60 яшьлек юбилеена багышлап чыгарылган китабында ук авторы турында белешмә һәм басылып чыккан хезмәтләре исемлеген бирә (Халиков А.Х. Татарский народ и его предки. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. С. 3–7, 198–221). 2002 елда Казанның урта гасырлар тарихына багышланган библиогафик күрсәткеч басылып чыга (Хузин Ф.Ш., Ситдиков А.Г. Средневековая Казань. Краткий библиографический указатель. Казань: «Школа», 2002. 152 с.). 2007 елгы басмада Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Археологик тикшеренүләр милли үзәге галимнәренең хезмәтләре урын алган (Национальный центр археологических исследований: Библиография трудов научных сотрудников (1987–2006 гг. / Сост. и отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань, 2007. 115 с.). Ф.Ш. Хуҗинның югарыда телгә алып үтелгән «Ранние булгары и Волжская Булгария» китабында әлеге темага багышланган библиография 286–579 битләрдә урнаштырылган. Ниһаять, әле күптән түгел генә без аның Татарстан археологиясенә багышланган фундаменталь библиографик хезмәтен күреп шатландык (Археология Татарстана. Библиографический указатель / под общей ред. А.Г. Ситдикова. Казань: Изд-во АН РТ, 2004. 604 с.).

Остазыбызның фәнни-педагогик эшчәнлегенә дә тукталып үтәсем килә. Әле мәктәптә уку елларында ук ул тарих укытучысы булырга хыяллана. Дөрес, институтны бетергәннән соң мәктәптә озак эшләргә туры килми, әмма коллегаларын-укытучыларын гына түгел, укучыларын да бүгенге көнгә кадәр онытмый, хәбәрләшеп, хәлләрен белешеп тора. Мәктәп укучыларының археологик экспедицияләрдә катнашуларын хуплый. Искә төшереп үтү урынлы булыр: Фаяз Хуҗинның иң элгәреге басма хезмәтләре арасында «Мәгариф» (ул вакытта әле «Совет мәктәбе») журналында чыккан һәм мәктәп балаларында ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләүдә, танып белү сәләтләрен үстерүдә Биләр археологик эспедициясендә тупланган тәҗрибә турында кызыклы гына мәкаләсе дә бар (Совет мәктәбе, 1977, № 5). «Мәгариф» журналы белән ул бүген дә хезмәттәшлек итә: биредә аның төрле елларда 40тан артык мәкаләсе басылып чыккан. Аның исемен журналның редакция әгъзалары арасында да күрәбез.

1990-нчы еллардан башлап ул бүгенге көннәрдә бик популяр булган «Сәләт» педагогик комплексы эшчәнлегендә актив катнаша, укучыларның ел саен Татарстан Фәннәр академиясе галимнәре катнашында үткәрелә торган «Эрудит» конкурсының жюри рәисе булып тора.

Ф.Ш Хуҗин урта гомумбелем бирү мәктәп укучылары өчен Татарстан һәм татар халкы тарихы буенча дәреслекләр, уку ярдәмлекләре язуда, хрестоматияләр төзүдә актив катнаша.

1993–1994 елларда урта мәктәпнең 5–6 сыйныфлары өчен яңа буын дәреслеге чыккан иде (Дәүләтшин Г.М., Хуҗин Ф.Ш., Измайлов И.Л. Татарстан тарихыннан хикәяләр. Урта мәктәпнең 5–6 сыйныфлары өчен дәреслек / С.Х. Алишев ред. Казан: Мәгариф, 1993. 271 б.; Рассказы по истории Татарстана. Учебник для 5–6 классов средней школы / Под ред. С.Х. Алишева. Казань: Магариф, 1994. 272 с.). Педагогик җәмәгатьчелек тарафыннан ул хуплап каршы алынды, югары бәягә лаек булды.

2001 елда профессор Б.Ф. Солтанбәков редакциясендә тагын бер дәреслек дөнья күрә (История Татарстана. Учебное пособие для основной школы / Под ред. Б.Ф. Султанбекова. Казань: ТаРИХ, 2001. 544 с.; Переизд. стереотип.: 2005). Әлеге дәреслекнең борынгы община строе, борынгы төркләр һәм Түрк каганатлары, Идел Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыклары тарихына багышланган өлешләре (5–103 бб.) Ф.Ш. Хуҗин тарафыннан язылган. 2003 елда шул дәреслеккә «Хрестоматия» дә килеп өстәлә (Хрестоматия по истории Татарстана. Учебное пособие для общеобразовательных учреждений / Сост. Ф.Ш. Хузин, И.А. Гилязов, В.И. Пискарёв. Казань: ТаРИХ, 2003. 480 с.).

2008 елда шушы дәреслек нигезендә Ф.Ш. Хуҗин, И.А. Гыйләҗев һәм В.И. Пискарёв катнашындагы авторлар коллективы 10 нчы сыйныф укучылары өчен махсус дәреслек язалар (Гилязов И.А., Пискарёв В.И., Хузин Ф.Ш. История Татарстана и татарского народа с древнейших времён до конца XIX в. Учебное пособие для 10 класса средней общеобразовательной школы / Руководитель проекта Б.Ф. Султанбеков. Казань: Хэтер, 2008. 271 с.; Гыйләҗев И.А., Пискарёв В.И., Хуҗин Ф.Ш. Татарстан һәм татар халкы тарихы: борынгы заманнардан алып XIX гасыр ахырына кадәр / Проект җитәкчесе Б.Ф. Солтанбәков. Казан: Хәтер, 2008. 271 б.).

Ф.Ш Хуҗинның профессор В.И. Пискарёв белән берлектә (ул методик аппарат авторы) гомумбелем бирү мәктәпләренең 6 сыйныф укучылары өчен язылган уку әсбабының язмышы катлаулырак булып чыга (Хузин Ф.Ш., Пискарёв В.И. История Татарстана с древнейших времён до середины XVI века. Учебное пособие для 6 класса общеобразовательной школы / Рук. проекта Б.Ф. Султанбеков. Казань: ТаРИХ, 2004. 95 с.; Хуҗин Ф.Ш, Пискарёв В.И. Татарстан тарихы: борынгы заманнардан алып XVI гасыр уртасына кадәр. Гомуми белем мәктәбенең 6 сыйныфы өчен уку ярдәмлеге / Проект җитәкчесе Б.Ф. Солтанбәков. Казан: Тарих, 2004. 103 б. Переизд. стереотип.: 2012).

2014 елда шушы ук дәреслекне, бераз редакцияләп, ягъни 1552 ел вакыйгаларын шактый дәрәҗәдә йомшартып, бары 1500 тираж белән Мәскәүдә нәшир итәләр: Хузин Ф.Ш., Пискарёв В.И. История России. Учебное пособие к учебнику Е.В. Пчелова «История России с древнейших времён до конца XVI века. 6 класс. Региональная составляющая». (М.: «Русское слово», 2014. 102 с.). 2016 елда дәреслекне инде, тагын бераз үзгәрешләр кертеп, 13000 тираж белән бастыралар (Хузин Ф.Ш., Пискарёв В.И. История России. Учебное пособие к учебнику Е.В. Пчелова, П.В. Лукина «История России с древнейших времён до начала XVI века. Региональный компонент (Республика Татарстан). М.: «Русское слово», 2016. 104 с.

Ф.Ш. Хуҗин белән В.И. Пискарёв дәреслеген нигез итеп алып, ләкин автоларыннан хәер-фатыйха алмыйча гына, 2016 елда Татар балалар нәшрияты чираттагы уку әсбабы әзерләп чыгара: «История Татарстана и татарского народа с древнейших времён до конца XVI века. 5–6 классы. Учебное пособие для общеобразовательных организаций». (Казань: Татарское детское изд-во, 2016. 128 с., тираж 38500 экз.; татарчасының тиражы 4500 экз.). Бу уку әсбабының фәнни редакторы Россия Фәннәр академиясенең Россия тарихы институты директоры Ю.А Петров, проект җитәкчесе А.М. Ганиев, авторлар төркеме җитәкчесе Р.Р. Фәхретдинов. Авторлар төркемендә Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре А.Р. Мөхәмәдиев, И.М. Миргалиев һәм М.М. Гибатдинов исемнәре бар. Алар китапка «Татар дәүләтләре – Алтын Урда варислары» дигән 14 битлек яңа параграф өстәгәннәр.

2010 елда чыккан «Татар халкы тарихы һәм мәдәнияты: Борынгы заман һәм урта гасырлар. 5 нче сыйныф өчен уку китабы» (Казан: «Мәгариф», 2010; русча варинты: Казань, 2011), Татар халкы һәм мәдәнияте. Урта гасырлар. 6 нчы сыйныф өчен уку әсбабы (Казан, 2012) кебек басмаларда да Ф.Ш. Хуҗинның саллы өлеше бар.

Югары уку йорты студентлары да игътибардан читтә калмаган. Ф.Ш. Хуҗин башлангычы белән Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты археологлары 2001 елда югары уку йортларының тарих факультеты студентлары һәм аспирантлары өчен «Очерки по археологии Татарстана», 2008 елда Яр Чаллы дәүләт педагогия институты исә галимебезнең «Волжская Булгария в домонгольское время (X – начало XIII в.)» исемле уку әсбабларын бастырып чыгардылар. Ф.Ш. Хуҗинның «Ранние булгары и Волжская Булгария» (Казан, 2006. 583 с.) китабы башлыча археология буенча диплом эше язарга әзерләнгән соңгы курс студентларына һәм кандидатлык диссертациясе өстендә эшлүче аспирантларга тәгаенләнгән, шуңа күрә аның күп өлешен язма чыганаклар һәм бай библиография алып тора да.

Студентлар Фаяз Шәриповичны «Археология» һәм «Татарстан тарихы» курслары буенча методик

кулланма авторы буларак та beləләр (Учебно-методический комплекс по курсу «Археология»: с применением модульной технологии обучения и балльно-рейтинговой системы оценки качества. Для студентов-бакалавров 3 курса исторического факультета ТГГПУ. Казань: Школа, 2008. 40 с.; Учебно-методический комплекс по курсу «История Татарстана»: с применением модульной технологии обучения и балльно-рейтинговой системы оценки качества. Для студентов 1 курса исторического факультета ТГГПУ, обучающихся по специальности «История». Казань: Школа, 2008. 52 с., и т.д.).

Фаяз Шәрипович студент халкын яхшы белә – Биләр экспедициясендә археологиядән практикага килгән студентлар белән егерме ел чамасы аралашып торды ул. Үзе дә югары белеме буенча педагог кеше. Барысын да исәпкә алсаң, аны 2008 елда Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының Татарстан тарихы кафедрасына мөдир итеп чакырылуы бер дә гаҗәп түгел. Әйе, Тарих институтында да эшен дәвам итте ул. Берьюлы югары уку йорты профессоры һәм академик институт хезмәткәре вазыйфаларын башкару, әлбәттә, җиңел булмагандыр – икеләтә тырышлык белән эшләргә туры килә аңа. Эшен яратып башкара, студентлар арасында да, кафедрадагы коллегалары арасында да абруе зур була – 2010 елда аңа университетның «Ел профессоры» дигән дәрәҗәле исем бирелә. Әйтергә кирәк, югары рейтингны аңа студентлар бәясе тәэмин итә.

Ф.Ш. Хуҗин «археология» белгечлеге буенча яшь галимнәр әзерләүгә дә җитди игътибар бирә. Аның җитәкчелегендә 10 аспирантның 6-сы диссертацияләрен яклаган инде һәм аларның барысы да, профессияләренә тугры калып, үз белгечлекләре буенча эшлиләр. Форсаттан файдаланып, мин үземнең остазыма профессия сайлауда, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклауда эчкерсез ярдәме өчен чиксез рәхмәтемне җиткерәм һәм бүгенге көндә әйдәп баручы археологлар Н.Г. Нәбиуллин, А.З. Нигамаев, З.Г. Шакиров, Р.Р. Вәлиев һәм дә арада иң нык танылган тарихчы, педагог, язучы Нурулла Гарифның да Фаяз Шәрипович шәкертләре икәнлеген исегезгә төшереп үтәм. Ул аспирантлар белән күп эшли. Йомшак күңелле һәм мәрхәмәтле, тыйнак (хәтта артык дәрәҗәдә), әмма таләпчән, принципиаль, эш кешеләрен ярата, эленке-салынкы йөрүчеләрне күрә алмый. Без үзебезне горурланып Фаяз Шәрипович шәкертләре, Н.Ф. Калинин һәм А.Х Халиков нигез салган данлыклы Казан археология мәктәбе вәкилләре дип йөртәбез.

Ф.Ш. Хуҗинның яшь галимнәр тәрбияләүдәге эшчәнлеге турында сөйләгәндә аның Татарстан Фәннәр академиясе каршындагы тарих фәннәре буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советы рәисе урынбасары, Казан Федераль университеты, Казан дәүләт

мәдәният институты каршындагы кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советлары әгъзасы булып торуын да әйтеп китү урынлы булыр.

Республикабызда аны танып белмәгән, ишетмәгән татар юктыр дигән идек. Минемчә бу аның коеп куйган фән кешесе генә түгел, бәлки шул фән казанышларын гади, татарча төзек, матур тел белән халыкка җиткерә белү сәләтендәдер. Тарихи мирас – халкыбызның борынгы бабалары мирасы! Шул мирасны ачарга, эзләп табарга, өйрәнергә кирәк. Без моны булдырабыз – Татарстанның 6 томлык Археологик картасы, казу эшләре вакытында тупланган тупланган байлыклар, аларны өйрәнеп язылган фәнни хезмәтләр шуны раслый. Әмма бу гына аз – ул байлык халыкка җиткерелергә, бүгенгегә хезмәт итәргә, татарларны милләт буларак берләштерү, саклап калу бурычын үтәүгә юнәлдерелергә тиеш, Фаяз Шәриповичның радио-телевидениедә, башкалабыз һәм район мәктәпләрендә үткәргән күпсанлы даими чыгышлары, лекцияләре нәкъ менә шул максаттан чыгып оештырыла. Шуңа күрә халык аны мөкаддәс мирасыбызны риясыз популярлаштыручы тынгысыз галим буларак та хөрмәт итә.

Бу җәһәттән аның 1992 елда эшли башлаган Биләр дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгын оештырудагы актив ролен дә билгеләп үтәргә кирәк. Казан кремлендә ачылган ханнар төрбәсен, Губернатор сарае каршында казып чыгарылган «Олы палата» һәм дә Спас-Преображение хәрабәләрен туристларга күрсәтү өчен консервацияләү (өлешчә реставрация ысулларын кулланып) археологлар әзерләгән проект документларына нигезләнеп башкарылды.

Күргәнегезчә, мөхтәрәм Фаяз Шәриф улы Хуҗинны олуг юбилее белән ихлас күңелдән котлап, аңа киләчәктә дә яраткан эшендә зур уңышлар һәм ныклы сәламәтлк теләп калырга тулы нигезебез бар.

*А.Г. Ситдыйков, академик, Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты директоры.*

## ТАТАРСТАН АРХЕОЛОГИЯСЕ ТАРИХЫННАН



# КАЗАН АРХЕОЛОГИЯ МӘКТӘБЕНӘ НИГЕЗ САЛГАН ГАЛИМ: Н.Ф. КАЛИНИН

*Татарстан археологиясе соңгы елларда Урта Идел һәм Кама төбәге халыкларының борынгы һәм урта гасыр тарихын өйрәнүдә зур уңышларга иреште. Моның ачык дәлиле – Казан Кремле, Болгар шәһәрлеге һәм Зөя каласының ЮНЕСКО тарафыннан дөньякүләм әһәмиятле тарихи-мәдәни һәйкәлләр исемлегенә кертелүе. 2014 елда Татарстан Фәннәр академиясе составында мөстәкыйль Археология институты барлыкка килде. Халыкара танылу алган Казан археология мәктәбенең нигез ташы күренекле галим, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, тарихчы һәм археолог Николай Филиппович Калинин тарафыннан салынган.*

Археология чагыштырмача яшь фәннәрдән санала. Аның мөстәкыйль өйрәнү объекты, терминнар системасы, үзенчәлекле тикшеренү ысуллары бары тик XIX йөз урталарында гына калыплашып җитә. Әмма бит археология истәлекләре – борынгы шәһәр хәрабәләре, иске зират урыннары, таш кыяларга уеп ясаган рәсемнәр, әледән-әле очрап торган сәер табылдыклар кешеләрнең игътибарын үзенә һәрдаим җәлеп итеп торган. Ярый, борынгы чүлмәк кисәкләренә исләре дә китмәсен ди, ә чакматаштан ясалган ук-сөнге очлары, балталар, бакыр пычаклар, таш плитәләргә төшерелгән рәсемле язулар – болары инде аңлашылып җит-

ми торган серле табылдыклар. Нәрсә булыр бу? Әлбәттә инде, үзләренчә аңларга һәм аңлатырга тырышканнар. Чынбарлыктан ерак торган төрле фаразлар, мифлар туган. Җир астыннан килеп чыккан мамонт сөякләрен дөнья яратылган чорларда ук яшәгән гигант кешеләрнеке дип уйлаганнар. Ук очларын Күк алласы җибәргән «яшен ташлары» дип атаганнар, таш балталарны исә, изге әйбер санап, императорларга бүләк итә торган булганнар, төрле авыруларны дәвалаганда файдаланганнар. Болгар-татар бабаларыбыз исә, борынгы курганнар Алып батыр чабата каккан урында барлыкка килгән, дип ышанганнар.

Менә шундый борынгы әйберләр турында сүз барганда безнең эрага кадәр IV гасырда яшәгән атаклы грек философы Платон беренче тапкыр фәнни әйләнешкә «археология» дигән төшенчәне кертеп җибәрә (*архайос* – борынгы, *логос* – сүз, белем мәгънәсендә). Әмма Платонга кадәр дә, кеше ышанмаслык мифлар белән генә канәгатьләнмичә, борынгы табылдыкларны ерак тарих белән бәйләп аңлатырга омтылучы акыл ияләре булган. Безгә, мәсәлән, Вавилон патшасы Набонидның әле б.э. га кадәр VI гасырда ук «археологик тикшеренүләр» алып барганлыгы мәгълүм. Әмма археологиянең фән буларак оешуы озак дәвам иткән һәм катлаулы юллар аша барган.

Россия археологиясенең барлыкка килүе һәм башлангыч чоры, Европа илләрендәге кебек үк, XVIII–XIX гасырларга карый. Император Петр Беренчене дәүләт эшлеклесе буларак күкләргә чөеп мактыйлар да, канәчкеч патша дип сүгеп тә ташлыйлар. Мондый бәяләмәләрнең икесе дә дөреслеккә туры килә. Безнең өчен шунысы әһәмиятле: нәкъ менә Петр I 1718 елның 13 февралендә, үз куллары белән язып, археологиянең киләчәк язмышын хәл итәчәк тарихи фәрман (указ) чыгара. Бу фәрманда шундый юллар бар (үзенчәлекле стилен саклау максатында оригиналдагыча китерәбез): *«Ежели кто найдет в земле или в воде какие старые вещи, а именно: каменья необыкновенные, кости человеческие или скотские, рыбьи или птичьи, не такие, какие у нас ныне есть, а такие да зело велики или малы перед обыкновенным; также какие старые надписи на каменьях, железе или меди, или какое старое и ныне необыкновенное ружие, посуду и прочее все, что зело старо – такожь бы приносили, за что будет довольная дача, смотря по вещи... Где найдутца такие, всему делать чертежи»*.

Археологиянең фән буларак оеша башлавында әлеге фәрманның файдасы күп була: яңа башкалага, Санкт-Петербургтагы Кунсткамерага, Россиянең төрле төбәкләреннән «куриоз», ягъни гадәти булмаган, сәер табылдыклар агыла башлый. Тиздән шул ук Петр I фәрманы белән 1725 елда оешкан Фәннәр академиясе Россиягә чагыштырмача күптән түгел генә кушылган җирләрнең табигый байлыкларын, халкының гореф-гадәтләрен, телен, традицион культурасын өйрәнү максаты белән

академик экспедицияләр оештыра башлый. Экспедиция әгъзалары алдына берочтан төбәкләр тарихының борынгы чорларына караган материаллар туплау бурычы да куела.

Россия Фәннәр академиясенең башлыча 1760–1770 елларда эшләгән Н.П. Рычков, И.И. Лепехин, И.Г. Георги, П.С. Паллас җитәкчелегендәге экспедицияләре Себер һәм Идел-Урал археологиясенең үсешенә зур өлеш кертәләр. Россия тарихының «атасы» саналган күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм галим В.Н. Татищев үзенең «Борынгы заманнардан башлап Россия тарихы» исемле мәшһүр хезмәтендә (беренче томы 1768 елда, үзе үлгәннән соң, дөнья күрә), борынгы елъязмаларга, башка ышанычлы чыганакларга таянып, Болгар – Бряхимов, Биләр – Олуг шәһәр, Җүкәтау – Жукотин, Ошель – Ашлы, Кашан кебек болгар шәһәрләре турында кызыклы мәгълүматлар урнаштыра. Югарыда телгә алынган экспедиция җитәкчеләре төбәкләрдәге җирле халыкларның тарихын өйрәнгәндә беренче чиратта, әлбәттә инде, В.Н. Татищев хезмәтләренә мөрәҗәгать иткәннәр, хәзерге Татарстан, Ульяновск, Самара төбәкләрендә урнашкан дистәдән артык болгар истәлекләре ачканнар.

XIX гасырның беренче яртысында болгар истәлекләрен, ягъни шәһәр-авыл урыннарын, шул тирәләрдә сакланып калган борынгы кабер ташларын эзләү дәвам итә. 1871 елда К.И. Невоструевның, 1874 елда Н. Вячеславның беренче «археологик карталары» дөнья күрә.

Татарстан археологиясе үсешенең яңа чорын хаклы рәвештә 1877 елда Казанда үткәрелгән IV Бөтенроссия археология съездыннан башлап җибәрәләр. Әлеге съезда катнашучылар Казан университеты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте оештыру турында мөһим карар кабул итәләр. 1931 елга кадәр актив эшчәнлек алып барган әлеге җәмгыятьтә әгъза булып торучылар арасында С.М. Шпилевский, А.Ф. Лихачёв, П.А. Пономарёв, И.А. Износков, В.А. Казаринов, Н.Ф. Высоцкий, А.А. Штукенберг, И.Н. Смирнов, М.Г. Худяков, В.Ф. Смолин кебек күренекле шәхесләрнең исемнәре бар. Туып килүче милли тарихыбызның беренче вәкилләре Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Бикмөхәммәт Зәетов, Гайнетдин Әхмәрев, Ризаэддин Фәхреддин һәм кайбер башка зыялыларыбыз да Археология, этнография һәм тарих җәмгыяте белән тыгыз бәйләнештә торганнар, әлеге җәмгыятьнең «Хәбәрләре»ндә гыйльми язмаларын бастырып чыгарганнар.

XIX йөз ахырларында Суар, Кашан, Ошель (Ашлы), Тубылгытау, Кирмәнчек кебек тарихи болгар калаларының төгәл урынын ачыклау буенча зур эшләр башкарыла. Ш. Мәрҗани 1885 елда дөнья күргән «Мөстәфәдел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле атаклы әсәрендә Суарның урынын, халык авыз иҗаты әсәрләренә һәм тарихи топонимия материалларына таянып, хәзерге Спас районының Кузнечиха авылы тирәсендәрәк күрсәтә. Бу фа-

разны 1890 еллар башында тарихчы Г. Әхмәрев археология материаллары белән исбатлап чыга. Шул ук елларда П.А. Пономарёв Ашлы, Җүкәтау, Кашан, Тубылгытау калаларының урынын билгели, Е.Т. Соловьёв исә XIV йөз чыганакларында телгә алынган Кирмәнчекнең эзләрен хәзерге Мамадыш районының Урта Кирмән авылы яныннан таба. Кызганычка каршы, финанс кытлыгы аркасында әлеге шәһәрлекләрдә казу эшләре үткәрелми, галимнәргә җир өстендә аунап яткан табылдыкларны җыеп өйрәнү белән генә чикләнергә туры килә. Шундый ук хәл таш, бронза, элгәреге тимер гасырларына караган борынгы чор археологиясендә дә күзәтелә. Борынгы әйберләр сирәк булса да очраштыргалый, Алабуга янында Ананьино каберлеге дә казып тикшерелә хәтта, тик торак урыннары гына табылмый.

1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң Россия халыкларының борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнүдә артык үзгәреш сизелми. Археология фәне дә «балалык чорынннан» чыга алмаган әле. Бер генә факт: мин югарыда телгә алып үткән галимнәрнең берсе дә төп белгечлеге, профессиясе буенча археолог түгел. Алар – мәгариф хезмәткәрләре, юристлар, геологлар, биологлар, филологлар – борынгы тарихыбыз белән кызыксынучы һәвәскәр археологлар гына. Дөрес, арада А.С. Башкиров, В.Ф. Смолин, М.Г. Худяков кебек тарихчы-археологлар да бар. Әмма алар Татарстанда озак эшләмәделәр һәм республикабызда археологиянең аерым фән тармагы буларак оешып китүенә катнаша алмадылар.

1930 нчы елларда башта Суар, аннан соң Болгар шәһәрлекләрендә киң масштаблы казу эшләрен башлап җибәреп, күп еллык хезмәтенә күрә атаклы болгарчы-галим исемен алган Мәскәү археологы профессор А.П. Смирнов та Казан археология мәктәбенә нигез салды дип әйтә алмыйбыз. Әйе, Болгарны дөньякүләм атаклы тарихи-археологик истәлек итеп танытуда аның роле бәя биреп бетергесез. Без моны, һичшиксез, танырга тиешбез, әмма Казанда җирле кадрлардан көчле археологик үзәк оештырып җибәрү аның планына кермәгән иде.

Бу эшне Николай Филиппович Калинин башкарып чыга.

Н.Ф. Калинин 1888 елның 24 маенда Саратов шәһәрендә ветеринар-врач гаиләсендә туган. 1902 елда Калининнар Казанга күчеп килә. Гаилә башлыгы Ветеринария институтында укыта башлый, Николай исә 1 нче гимназия укучысы булып китә. Гимназияне тәмамлаганнан соң ул 1910 елга кадәр Казан университетының тарих-филология факультетында белем ала. Дипломлы тарих укытучысы башта Царевококшайск (Йошкар-Ола), аннан соң Сембер (Ульяновск), Тәтеш, Мариуполь мәктәпләрендә балаларга белем бирә, 1921 елда Казанга кайтып, 3 нче һәм 15 нче санлы урта мәктәпләрдә тарих һәм география фәннәрен укыта. Зыялы гаиләдә тәрбияләнеп үскән егет (Николай Филиппович француз һәм немец телләрен яхшы белә, татарча аңлый һәм

ярыйсы гына сөйләшә, рояльдә уйный, өстәвенә әле менә дигән рәссам да була) университет белеме белән генә чикләнеп калмый, Казан һәм җирле халыклар тарихын тирәнрәк өйрәнергә омтыла. Шул максат белән ул үзе эшләгән мәктәптә төбәкне өйрәнү түгәрәге оештырып җибәрә, укучыларын тарихи урыннарга алып бара, шәһәрнең тирә-юненә, Казансу буйларына алып чыга, үзе исә китапханәләрдә, архивларда эшли. Тиздән Н.Ф. Калининның «А.С. Пушкин Казанда», «А.М. Горький һәм Казан» дигән китаплары, газета битләрендә исә күпсанлы мәкаләләре дөнья күрә.

1924 елда Н.Ф. Калинин Казан университеты каршында эшләп килгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең актив члены булып китә, Җәмгыятьнең гыйльми сәркәтибе итеп сайлана. Шул ук елда аны Татарстан Үзәк музеена (бүген республикабызның Милли музее) эшкә чакыралар. Биредә ул ике дистә елдан артык тарих һәм археология бүлеген җитәкли, экспозицияләрне яңарта, күргәзмәләр оештыра. Нәкъ менә музейда эшләгән чорда Николай Филиппович үзенең беренче археологик экспедицияләрен оештыра, баштарак чорда Казанның үзәк урамнарында системалы рәвештә археологик күзәтүләр, соңыннанрак исә үзе эшләгән мәктәп укучылары белән Кремль территориясендә казу эшләре дә алып бара. Әле 1920 нче елларда ук ул профессор А.С. Башкиров белән Биләр һәм Җукәтау калаларын тикшерүдә, И.Н. Бороздин белән Казан кремлендәге эпизодик характердагы археологик казу эшләрендә катнашкан була. 1928–1931 елларда аны хәтта Мәскәү университетының Кама буе районнарына оештырган антропологик экспедициясе эшләренә дә археолог сыйфатында җәлеп итәләр.

1938 елда Татарстанда А.П. Смирнов җитәкчелегендәге Болгар археологик экспедициясе эшли башлый. Николай Филиппович шундук экспедициягә чакырыла һәм киң эрудицияле, инде ярыйсы гына бай тәҗрибә туплап өлгергән археолог буларак, отряд җитәкчесе итеп билгеләнә. А.П. Смирнов аны рәссам сыйфатында да файдалана – Николай Филиппович үзе казып чыгарган борынгы архитектура объектларының реконструкцияләрен менә дигән итеп башкарып чыга. Болгарда эшләгән чорда Н.Ф. Калининның күп кенә хезмәтләре Мәскәүдә нәшер ителә торган фәнни журналларда һәм җыентыкларда басыла.

Гыйльми даирәләрдә дә, студентлар һәм мәктәп укучылары, шәһәр халкы арасында да Николай Филипповичның абруе үскәннән-үсә бара. Шәһәр халкы галимне музейларда, завод-фабрикаларда оештырылган лекцияләре, республика газеталарында басылып чыккан мәкаләләре аша яхшы белә, студентлар исә аны киң эрудициясе, йөзенә-кыяфәтенә чыккан зыялылыгы, үз фәненә чиксез бирелгәнлеге өчен хөрмәт итә. Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер: Н.Ф. Калинин мәктәп укучылары һәм студентлар белән һәрвакыт яхшы мөгаләмәдә булырга тырыша, алар белән араны бервакыт-

та да өзми. 1934–1940 елларда үзенең музейдагы төп эше белән бергә Казанның 2 нче мәктәбендә дәресләр алып бара, 1933–1935 елларда Көнчыгыш педагогия институтында, 1941–1957 елларда Казан дәүләт университетында доцент вазыйфаларын башкара, лекцияләр укый, диплом эшләре белән җитәкчелек итә. Казан университетының тарих факультетында Н.Ф. Калинин тарафыннан оештырылган археология түгәрәге бүгенге көндә дә бик актив эшләп килә. Казан археологларының барысы да (шул исәптән, мин фәкыйрегез дә) фәнгә тәүге адымнарын шушы түгәрәктән башлап киттеләр. Яшьләр белән дуслыкның тагын бер файдалы ягы була: алар археологик экспедицияләргә бик теләп катнашалар (романтика ич!), казу эшләрендә төп эшче көч булып торалар. Шуңа күрә, шәкертләре сөйләвенчә, ул заманнарда Николай Филипповичка экспедицияләр оештыру артык авырга туры килмәгән, аның белән юлга чыгарга атлыгып торганнар.

Татарстан Фәннәр академисенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарихында да Н.Ф. Калининның үз урыны бар – ул әлеге институтның беренче гыйльми хезмәткәрләреннән. Биредә Николай Филиппович 1942–1959 елларда эшли. Институттагы фәнни эшчәнлеген галим болгар-татар эпиграфикасы буенча комиссия төзүдән башлап җибәрә, моңа кадәр билгеле булмаган эпиграфик материаллар (кабер ташларындагы язмалар) туплау максаты белән Татарстан һәм Чуаш республикаларының төрле районнарына барып чыга, Болгар ташларын җентекләп өйрәнә. Яңа чыганаклар нигезендә язылган доклад белән ул 1946 елда Мәскәүдә уздырылган «Казан татарларының килеп чыгышы» дигән конференциядә катнаша.

Бөек Ватан сугышы елларында Н.Ф. Калинин борынгы община строе һәм урта гасырлар археологиясе буенча элегрәк тупланган материаллар нигезендә Урта Иделнең иң борынгы чорларыннан башлап (таш, бронза, элгәреге тимер гасыры) Идел Болгарстанына кадәр булган тарихын язу өстендә эшли. Әйтергә кирәк, әлеге тарихның Идел болгарларына караган өлешен ул СССР Фәннәр академиясе академигы, мәшһүр тарихчы Б.Д. Греков белән бергә яза. Хезмәтнең беренче кисәген Н.Ф. Калинин 1946 елда кандидатлык диссертациясе рәвешендә эшләп бетерә һәм аны уңышлы яклап чыга. Әлеге хезмәтләр 1951 һәм 1955 елларда дөнья күргән «Татарстан АССР тарихы»ның 1 нче томында басылып чыгалар.

Сугыштан соңгы елларда Н.Ф. Калинин төп игътибарын Татарстанның археологик картасын төзү эшенә юнәлтә. Моның өчен республикабыз районнары территориясен разведкалар юлы белән җентекләп тикшереп чыгарга кирәк була. Биш ел эчендә Татарстанның Кама аръягы районнарында 400 дән артык яңа археологик истәлекләр табыла, әмма тиз арада гына алга куелган максатка ирешеп булмаячагы аңлашыла – археологик объектлар фаразланганнан күбрәк булып чыга. Искәртеп үтим: Татар-

станда Н.Ф. Калинин башлаган Археологик карта төзү эшен без, Россиядә беренчеләрдән булып, нигездә 1980 еллар ахырында гына төгәлләдек. Алты томнан торган Картага 4300 чамасы объект теркәлгән иде.

1950 нче еллар башында археологлар алдына тагын бер проблема килеп баса – кыска гына вакыт эчендә Куйбышев гидроэлектростанциясенең сусаклагычы астында калып юкка чыгачак археологик һәйкәлләрнең бер өлешен генә булса да казып-тикшереп өлгерергә кирәк иде. Төп көчне моңа кадәр бик начар өйрәнелгән таш һәм бронза чорларына караган объектларны казуга юнәлтәләр. Ләкин алар арасында IV–VII гасырларга караган уникаль Имәнкискә шәһәрлеге дә бар иде. Н.Ф. Калинин аны үзенең талантлы шәкерте А.Х. Халиков белән берлектә өйрәнергә карар кыла. Казу эшләре уңышлы төгәлләнә, нәтиҗәдә бу шәһәрлек фәндә моңа кадәр билгеле булмаган кабиләләр тарафыннан төзелгән дигән нәтиҗәгә киләләр. Кемнәр алар имәнкискәлеләр – төркиләрме, фин-угырлармы, сарматлармы, славяннармы? Серле кабиләләр калдырган археологик истәлекләрнең саны да инде 600 дән артып китте, әмма бәхәсле сорауга археологларның бүгенгә кадәр җавап таба алганнары юк әле. Калинин үзе аларны төрки телдә сөйләшүче бортаслар дип санады.

Куйбышев сусаклагычына нисбәтле тагын бер гыйбрәтле факт: ясалма диңгез астында калып, безгә билгеле булган 700 ләп (!) археологик һәйкәл юкка чыкты. Шуларның бик аз өлеше генә көзгә табан, су кимегән чорда, күренеп ала һәм археологлар «диңгез»дулкыны белән сөзәк ярга юып чыгарылган табылдыкларны гына булса да җыеп калырга ашыгалар. Бу эш 1961 елда башланып китте һәм әле хәзер дә дәвам итә.

1950 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтының Н.Ф. Калинин җитәкчелегендәге экспедициясе Тәтеш районының Олы Тархан авылы янында VIII гасыр урталарында – IX гасырның беренче яртысында яшәгән элгәреге болгарларның зиратын таба. Соңыннарак биредә Николай Филипповичның шәкертләре А.Х. Халиков һәм В.Ф. Генинг тарафыннан 358 кабер казып тикшерелә. Моңа кадәр Урта Идел буйларында элгәреге болгарларның археологик эзләре ачылмаган иде әле. Шуңа күрә 1988 елда Н.Ф. Калининның 100 еллык юбилеен «Көнчыгыш Европада элгәреге болгарлар» дигән Бөтенсоюз конференциясен үткәреп билгеләп үтү һич тә очраклы түгел иде.

1950 нче елларны Н.Ф. Калининның фәнни эшчәнлегендә иң актив һәм уңышлы еллар дип әйтергә була. Ул Балык Бистәсе районында урнашкан Чаллы шәһәрлегендә казу эшләре үткәрә (без ул тапкан материалларны 2000 елда гына бастырып чыгара алдык), бераз «Иске Казан» исеме белән мәгълүм Камай шәһәрлегендә һәм Рус Урматы авыллыгында (Биектау районы) эшләп ала, биредә Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорына караган табылдыкларның ярыйсы гына бай коллекциясе туплана.

Борынгы Казан археологиясе Ка-

лининның иң яраткан темаларыннан иде. Казан кремле территориясендә ул 1925 (В.Ф. Смолин белән берлектә), 1928–1929, 1935, 1947, 1953–1954 елларда эшли, табылдыклары хәзер Татарстан Милли музее фондларында саклана. Алар арасында монголларга кадәрге болгарлар чорына караганнары да бар. XIV гасырда сугылган акча хәзинәләре исә Кремль җирлегендә XIX – XX йөз башларында табылган иде. Шулай булуга карамастан, Н.Ф. Калинин Казан шәһәренең барлыкка килүен бары тик ханлык чоры белән генә билгеләү ягында торды. Ул «Иске Казан»ны һәм Казан читендә, Кабан күле янында урнашкан борынгы каланы (Кабан шәһәрлеген) – биредә 1297 елда вафат булган Алтын Бөртек исемле кыз һәм XIV йөзнең икенче яртысында үлгән Мир-Мәхмүд угылы Хәсән-бәк каберләренә куелган каберташлар сакланып калган – хәзерге Казанның башлангычы, «яралгысы» дип саныды. Бу фикерне ялгыш дип әйтеп булмый – ул заманнарда иң күп табыла торган археологик материалларның, бигрәк тә керамиканың, төгәл датасын билгеләү ысуллары безнең фәндә әле начар өйрәнелгән иде.

Казан шәһәренең төрле чорларына багышлап Н.Ф. Калинин дистәләрчә фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр бастырды дидек. Аның күп еллык хезмәт җимеше буларак язылган күләмле «Казан. Тарихи очерк» китабы 1952, 1955, 1957 елларда рус һәм татар телләрендә дөнья күрде. 1950 еллар уртасында Николай Филиппович Казанның XVIII гасырга кадәрге тарихын эченә алган докторлык диссертациясен дә төгәлләгән иде. Археологлар һәм тарихчылар аны бер дә икеләнмичә фундаменталь хезмәт дип бәяләделәр. Ул үзенең тарихи әһәмиятен бүген дә югалтмаган әле. Кызганычка каршы, СССР Фәннәр академиясенең Археология институты югары профессиональ дәрәҗәдә эшләнгән диссертацияне яклауга кабул итмәде. Бу – Алтын Урда һәм Казан ханлыгы тарихын өйрәнүгә партия идеологлары тарафыннан рәсми рәвештә тыю салынган заман иде.

Әмма Николай Филиппович Калинин, Татарстанның беренче профессиональ археологы, язмыш тарафыннан тәгаенләгән төп бурычын җиренә җиткереп үтәде – ул тарих фәннәре докторы дәрәҗәсенә ирешкән А.Х. Халиков һәм В.Ф. Генинг, тарих фәннәре кандидаты Т.А. Хлебникова кебек талантлы шәкертләрен тәрбияләп, Казан археология мәктәбенә нигез салды. Алар һәм аларның шәкертләре Татарстан археологиясен остазлары хыяллана да алмаган югары халыкара дәрәҗәгә күтәрделәр.

*Мәйдан. 2018. № 7. 95–107 бб.*



## АТАКЛЫ ГАЛИМ – ГАДИЛЕК ҺӘМ БӨЕКЛЕК ҮРНӘГЕ
### (Альфред Халиков шәхесенә тасвирлама)

Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Фән һәм техника өлкәсендә республикабызның Дәүләт премиясе лауреаты, дөньякүләм танылган археолог Альфред Хәсән улы Халиков археологиягә беренче адымнарын күренекле тарихчы-археолог Николай Филиппович Калинин җитәкчелегендә башлый. Үзенең хөрмәтле остазы белән бергәләп университет студенты чагында ук ул археологик разведкаларда, казу эшләрендә катнаша, ныклап торып фән белән шөгыльләнергә кирәк дигән карарга килә. А. Халиковның студент елларында ук язылып, 1951 елда университетның «Гыйльми язмалар»ында басылып чыккан беренче фәнни хезмәте СССР Югары белем бирү министрлыгы тарафыннан I премиягә лаек дип табыла. Шул ук елны университетның соңгы курс студенты А. Халиков СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына лаборант буларак кабул ителә. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр галим шушы институтта эшли, гади лаборанттан башлап, археология бүлеге мөдире һәм баш фәнни хезмәткәр дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Биредә аның ургылып торган энергиясе, искиткеч оештыру сәләте моңа кадәр фәндә мәгълүм булмаган дистәләрчә, йөзләрчә археологик истәлекләр ачуга юнәлтелә, Татарстан районнарында һәм күрше өлкәләрдә алып барган нәтиҗәле казу эшләре күпләрне көн-

ләштерерлек фәнни ачышларга китерә.

Альфред Хәсән улын кайберәүләр Идел-Урал буе халыкларының борынгы ыруглык җәмгыяте чорына караган археологиясен бар яклап, төптән өйрәнгән галим буларак кына беләләр. Бу дөрестән да шулай. СССР Фәннәр академиясенең Археология институтында 1956 елда якланган кандидатлык диссертациясе дә, 1966 елда якланган докторлык диссертациясе дә җирле фин-угыр халыкларының таш һәм бронза гасырына караган иң борынгы тарихын өйрәнүгә багышланган иде. Әмма шушы хезмәтләрендә дә галим үзен гаҗәеп киң эрудицияле тарихчы итеп (археолог кына түгел!) күрсәтә алды. Фин-угыр халыкларының этногенезына кагылышлы бик тә катлаулы проблемаларны өйрәнүче галимнәр әле хәзер дә А.Х. Халиков хезмәтләренә, бигрәк тә «Урта Иделнең борынгы тарихы» (М., 1969), «Бадано культурасы истәлекләре» (М., 1976), «Идел-Кама элгәреге тимер гасыры чорында» (М., 1977), «Казан буе кабиләләре культурасы» (М., 1980) кебек фундаменталь монографияләрендә бәян ителгән фактларга таяналар, аның концепциясен тагын да үстерәләр. Бәхәсләшәләр дә, билгеле, кайбер фикерләрен кире дә кагалар. Әйе, фән бит ул: яңа материаллар табылып кына тора. Әмма Халиков концепциясенең нигезе нык, чөнки ул искиткеч бай тарихи-археологик чыганакларга таяна.

Профессор А.Х. Халиковның археологиядә якты эз калдырган тагын бер фәнни юнәлеше бар – төрки халыкларның, бигрәк тә болгар бабаларыбызның борынгы тарихы. Бу тарих белән ул утыз елдан артык шөгыльләнде. Элгәреге болгарларның Тәтеш районындагы Олы Тархан каберлеген казып тикшерү нәтиҗәләренә багышланган классик монографиясен (автордашы В.Ф. Генинг) Мәскәүнең «Наука» нәшрияты 1964 елда ук бастырып чыгарган иде. Хәзер дә безнең куллардан төшми ул китап, чөнки фактлары да, шул фактларга нигезләнгән фикерләре дә һаман искерми.

1970 елларда А.Х. Халиков бу юнәлештәге фәнни эшчәнлеген тагын да киңәйтә, тирәнәйтә төште. Идел буе төбәгенә төрки кабиләләрнең болгарларга кадәр берничә гасыр элек үтеп керүләрен исбатлап язган фәнни мәкаләләре галимнәрнең кискен тәнкыйть утына дучар булса да, бүгенге көндә Халиков концепциясе беркемдә дә шик уятмый инде. Киресенчә, төрки бабаларыбызны тагын да борынгырак чордан эзли башладылар, дөрес, әлегә фактлар гына җитәрлек түгел.

1967 елда Альфред Хәсән улы Идел Болгарстанының монгол яуларына кадәрге башкаласы булган Биләрдә киң масштаблы казу эшләрен башлап җибәрә. Шәһәрлекне һәм аның тирә-юнен, Көнчыгыш Европа археологиясендә беренчеләрдән булып, самолёттан фотога төшерәләр, Мәскәүдән белгечләр чакыртып, аэрофото материалларын җентекләп өйрәнәләр. Әлеге эшләрне, хаклы рәвештә, болгар калаларын өйрәнүдә

яңа этап дип бәяләделәр. Дөрестән дә, моңарчы әле бер генә шәһәрлекне дә шулкадәр зур мәйданда казып тикшергәннәре юк иде. Ун ел эчендә ике гектар чамасы җирдә культура катламы ачылган! Кәрван-сарай тирәсендә борынгы мунча хәрабәләре, шәһәр үзәгендә Җәмигъ мәчет, аның янында кирпечтән салынган бай феодал йорты, тимерчеләр һәм чүлмәк ясаучылар бистәсе, мөселман зиратлары, болгар археологиясендә беренче юрта эзләре һәм бу объектларны казыганда килеп чыккан меңләгән табылдыклар, уникаль әйберләр – ачышларның ниндие генә булмады?! Боларның барысы да бит, уйлап карасаң, Халиковның фидакарь хезмәт нәтиҗәсе, болгар археологиясенә керткән саллы өлеше.

Һәрвакыттагыча, Биләр археологиясендәге ачышлар да бәхәссез генә кабул ителмәде. Идел Болгарстанының монгололларга кадәрге башкаласы турындагы фәнни бәхәсләргә әле дә нокта куелмаган. Хафаланырга кирәк түгел – хакыйкать бәхәстә туа диләр ич. Ни генә булмасын, олы галимебез тарафыннан әйтелгән фикерләр, нигезле фаразлар әле дә яшиләр, актуальлеген югалтмагннар. Димәк, киләчәктә бу юнәлештә тикшеренүләр дәвам итәчәк әле.

Галим-голәмәгә киң җәмәгатьчелек арасында танылу, дан-шөһрәт казану җиңел түгел. Әмма Альфред Хәсән улын олы галим, археолог буларак белмәгән, ишетмәгән татар сирәктер ул. Халкыбызның килеп чыгышын җентекләп өйрәнгән, шул хакта газета-журнал битләрендә күпсанлы мәкаләләре белән чыгыш ясаган, китаплар язган кеше буларак беләләр аны. Галим «Татар халкының килеп чыгышы» дигән китабын 1974 елда татар телендә бастырып чыгара. 1977 һәм 1989 елларда аның киңәйтелгән басмалары рус телендә дөнья күрә. Билгеле инде, шунда ук таралып та бетәләр, чөнки халык үзенең дөрес тарихын белергә тели һәм ул аны Халиков хезмәтләреннән таба. «Кемнәр без – болгарлармы, татарлармы?» һәм «Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе» дигән хезмәтләрен ул гади халык укырлык итеп, фәнни-популяр китаплар рәвешендә язды. Үзләре юка гына булса да, эчтәлекләре бик саллы. Тарихчылар әле хәзер дә файдалана алардан, фәннән ерак торган милләттәшләребез дә йотлыгып укый.

А.Х. Халиковны, гадәттә, татар этногенезын өйрәнүче галимнәрнең «болгарчылар» төркеменә кертәләр. Хакыйкатькә туры килеп бетми торган караш бу. Ни өчен дигәндә, халкыбызның борынгы тарихын ул һуннар чорыннан ук башлый, Төрки каһанлыкларын, Кубрат ханның Бөек Болгарын, Хазар дәүләтен дә читләтеп узмый, аларны халкыбыз формалашуда аерым этаплар итеп карый. Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында барлыкка килгән этник үзгәрешләрне дә күрә, җирле фин-угыр һәм күрше славян-рус халыкларының татар этногезендагы ролен дә инкарь итми, калку итеп күрсәтә. «Татарларның халык булып формалашуында төрле этник компонентлар катнашкан, – дип нәтиҗә ясый А.Х. Хали-

ков, – әмма болгарларны Идел һәм Урал буе татарларының төп ата-бабалары дип санарга хаклыбыз». Фәндә яңа фикерме бу? Юк, әлбәттә. Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Г. Әхмәров, М.Г. Худяков, А.П. Смирнов кебек мәшһүр тарихчыларыбыз да шундый ук карашта торалар иде. А.Х. Халиков исә бу концепцияне яңа археологик материаллар белән баетты, тулыландырды һәм кайбер мәсьәләләргә төгәллек кертте.

Бүгенге көндә татар этногенезында хәлиткеч этап итеп Алтын Урда чоры карала. Бусы да аның яңа концепция түгел. Һ. Атласи, Г. Гобәйдуллин, М. Сәфәргалиев, Ш. Мөхәммәдьяров һәм башка күп кенә тарихчы галимнәр, болгарларның, кыпчакларның һәм башка төрки халыкларның, Алтын Урда составында татар исеме алып, бербөтен этнос булып оешып җитүен ышанычлы фактлар белән расладылар. Ахыр чиктә, әлеге концепция тарафдарлары да болгарларның татар этногенезында тоткан урынын танырга мәҗбүрләр. Соңгы елларда ясалган археологик ачышлар яктылыгында болгарларның Алтын Урда цивилизациясен тудыруда актив катнашканлыгы тагын да ачыграк күренә.

Күпләрнең хәтерендәдер: 1977 елда башкалабызның 800 еллык юбилеен үткәрергә йөргән идек. Дәлилләрегез аз дигән сылтау белән, Мәскәү аны бәйрәм итәргә рөхсәт бирмәде. Әлеге юбилейны фәнни яктан нигезләргә тырышкан галим А.Х. Халиков иде. Тик ул чакта аңа хәзерге кебек масштаблы казу эшләре алып барырга ирек куелмады. Әйтергә кирәк, фән дөрес юлда булды. Аек акыллы Мәскәү галимнәре дә моны таныды: Казанның монгол яуларына кадәр үк барлыкка килгән шәһәр булуын раслаган мәкаләләр хәтта Россия энциклопедияләрендә дә урын алды.

1993 елда А.Х. Халиков Казан Кремлендә яңадан казу эшләренә тотынган иде. Кызгныч, нәтиҗәсен генә күрергә өлгермәде. Остазыбыз башлаган эшне без, аның шәкертләре, дәвам иттек. Яңа ачышлар-табышлар Халиковның элеккеге фаразларын тулысынча раслады! Алай гынамы соң – башкалабызның 1000 еллык юбилеен ил күләмендә бәйрәм итә алдык. Татарстан археологиясенең олы казанышы иде бу, һәм әлеге уңышларда Альфред Хәсән улы Халиковның саллы өлешен танымау хата булыр иде.

Профессор А.Х. Халиков турында озаклап сөйләргә мөмкин, әлбәттә. Аның фәнни эшчәнлегендәге тагын бер өлкәне генә телгә алып үтәсем килә. 1950 еллардан башлап, гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул Татарстанның археологик истәлекләрен барлау, яңаларын эзләп табу һәм аларны тасвирлап, фәнни әйләнешкә кертү белән шөгыльләнде. Шәкертләре Е.П. Казаков, П.Н. Старостин, Р.Г. Фәхретдинов, Р.С. Габәшев һәм башка археологлар белән җәяүләп, туры килгәндә экспедиция машинасына утырып, кайвакытта кеше аягы басмаган җирләрдән ничәмә-ничә мең чакрым юллар үтелгән? Нәтиҗәдә 4500дән артык археологик истәлекне туплаган фундаменталь хезмәт – «Та-

тарстанның археологик картасы» төзелә. Алты томнан торган бу хезмәт 1994 елда республикабызның Дәүләт бүләгенә лаек дип табыла.

А.Х. Халиковның ике дистәдән артык шәкертләре булуын, җаваплы редактор сыйфатында кырыктан артык китап һәм фәнни җыентыклар әзерләп чыгаруын, союзкүләм һәм халыкара конференцияләрдә, конгрессларда докладлар һәм дә кандидатлык, докторлык диссертацияләре яклаганда рәсми оппонент буларак чыгышлар ясавын, Казан дәүләт университеты профессоры дәрәҗәсендә студентларга лекцияләр укуын, ниһаять, әллә никадәр җәмәгать эшләре алып баруын да искә алсаң, боларның барысына да ничек өлгергән икән ул дип шаккатырга гына кала.

*Фән һәм тел. 2007. № 1. Б. 36–42 (кыскартып бирелә).*




## ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНДА ТАТАРСТАН АРХЕОЛОГИЯСЕ

Татарстан археологиясенең, күренекле галимнәр Н.Ф. Калинин һәм А.Х. Халиков исемнәрен йөртүче Казан археология мәктәбенең оешуы, археология фәненең ярты гасырдан артык, 1996 нчы еллар уртасына кадәр дәвам иткән тотрыклы, алгарышлы үсеш чорлары, борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнү юлында ясалып, бөтен Рәсәйдә һәм чит илләрдә танылу алган олы ачышлары Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән бәйләнгән.

Дөрес, Татарстан археологиясенең башлангыч чорлары турында сүз барганда 1878 елда Казан университеты каршында оешып, 1930 нчы елларга кадәр эшләп килгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте эшчәнлеген дә онытырга ярамый. Татарстан җирлегендә беренче казу эшләрен нәкъ менә шушы җәмгыять әгъзалары – күбесе профессиональ археологиядән ерак торган кешеләр башлап җибәрәләр. С.М. Шпилевский, А.Ф. Лихачёв, А.А. Штукенберг, Н.Ф. Высоцкий, П.А. Пономарёв, Н.А. Толмачёв, В.К. Савельев, Г. Әхмәрев, В.Ф. Смолин, М.Г. Худяков кебек галимнәрнең Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте «Хәбәрләре»ндә басылган фәнни мәкаләләре, казу эшләре вакытында, ә башлыча исә очраклы рәвештә табылган борынгы әйберләр коллекцияләре Татарстан археологиясе үсешендә нигез ташлары ролен үтәделәр. Мәсәлән, А.А. Штукенберг һәм Н.Ф. Высоцкий таш, бронза, элгәреге тимер гасырында яшәгән кешеләрнең беренче торулыкларын табып тикшерделәр, В.Ф. Смолин Чувашиянең Абашево авылы янында урнашкан борынгы курганнарны казып, фәндә моңа кадәр билгеле булмаган яңа археологик культура ачты. Профессор С.М. Шпилевскийның «Казан

губернасында борынгы шәһәрләр һәм башка болгар-татар истәлекләре» дигән фундаменталь хезмәте (1877) әле бүген дә үзенең фәнни кыйммәтен югалтмады, 2012 елда аның репринт басмасы дөнья күрде.

1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң фәнне оештыру системасында яңа үзгәрешләр килеп чыга. ТАССР Мәгариф комиссариаты каршында төзелгән Гыйльми үзәк (1921–1930), Татарларны өйрәнү Гыйльми җәмгыяте (1923–1929), Татарстанны өйрәнү җәмгыяте (1928–1930) басмаларында сирәк кенә булса да археология һәйкәлләрен өйрәнү һәм аларны саклау мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр басыла. Шул ук вакытта А.С. Башкиров, И.Н. Бороздин, Н.Ф. Калинин кебек галимнәр тарафыннан Биләр, Җүкәтау, Казан кремле, Иске Казанише болгар-татар калаларында зур булмаган, рекогносцировка характерындагы казу эшләре үткәрелә.

1933 елда СССР Фәннәр академиясенең Матди культура тарихы Институты (Институт истории материальной культуры) оештырган археология экспедициясе Дәүләт тарих музее һәм Татарстан Үзәк музее белән бергәләп республикабызда казу эшләре башлап җибәрә. Тиздән атаклы болгарчы-галим булып танылачак А.П. Смирнов җитәкчелегендәге экспедиция биш ел буена Суар шәһәрлеген тикшерә, 1938 елда исә киң масштаблы һәм системалы казу эшләре Болгарда башланып китә. Бу эшләрдә Татарстан Үзәк музее хезмәткәрләре Н.Ф. Калинин, А.М. Ефимова, О.С. Хованская һәм З.А. Акчурина актив катнашалар.

1939 елда оешкан Тел, әдәбият һәм тарих институтында беренче археолог – Казан археология мәктәбенә нигез салучы олы галим Николай Филиппович Калинин 1942 елда эшли башлый, 1951 елда ул үзенең талантлы шәкерте А.Х. Халиковны лаборант сыйфатында эшкә урнаштыра, шулай итеп, институтның тарих секторында археология төркеме барлыкка килә.

***Тарих секторы составындагы археология төркеме*** тиздән Т.А. Хлебникова[1], Һ.В. Йосыпов[2], Ф.Ф. Генинг[3] кебек яшь археологлар белән тулыландырыла.

1945 елда Институт каршына СССР Фәннәр академиясе тарафыннан Советлар Союзы халыкларының тарих һәм мәдәнят һәйкәлләрен исәп-

[1] Проф. А.П. Смирновның шәкерте, Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң 1952–1955 елларда Дәүләт тарих музеенда (Мәскәү) аспирантура үтә һәм 1957 елдан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли башлый.

[2] Казан дәүләт университетын 1941 елда тәмамлый, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952 елда филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклаганнан соң СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтында эшли. 1958–1968 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән гыйльми хезмәткәр. Галимнең фәнни мирасын башлыча болгар-татар эпиграфикасына, этнография һәм археология өлкәсенә караган хезмәтләр тәшкил итә.

[3] Н.Ф. Калининның шәкерте, Пермь университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң 1955–1958 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада укый.

кә алу кысаларында Татарстанның Археологик картасын төзү бурычы куела. Берничә ел эчендә республикабызның төрле районнарына экспедицияләр оештырыла, музей һәм архив фондлары тикшерелә. Үткәрелгән тикшеренүләрнең беренче нәтиҗәсе буларак, 1954 елда Н.Ф. Калинның А.Х. Халиков белән язылган китабы дөнья күрә. Бу китапта Татарстанның 21 районында урнашкан 447 археология һәйкәле исәпкә алынган һәм болгар-татар шәһәрлекләренең типологиясе тәкъдим ителгән (Калинин, Халиков, 1954, с. 63–126).

Сугыштан соңгы елларда аз гына финанс мөмкинлекләре килеп чыгуга ук борынгы археология һәйкәлләрендә стационар казу эшләре үткәрелә башлый, аерым алганда, Минзәлә районының Дәвек авылы янында палеолит (б.э.к. X–VIII меңъеллыклар), Апас районының Кабык Күпер авылы янында мезолит (б.э.к. VI–V меңъеллыклар), Казаннан ерак түгел Обсерватория поселогы янында неолит (б.э.к. IV–III меңъеллыклар) чоры кешеләре калдырган торулыклар казып өйрәнелә. Урта Идел һәм Түбән Кама төбәкләрендә моңарчы билгеле булмаган таш гасыры чорына караган гаять кыйммәтле археологик материаллар А.Х. Халиков хезмәтләрендә беренче мәртәбә киң фәнни әйләнешкә кертелә (Халиков, 1958; 1960). Яшь галим, шулай ук беренче мәртәбә, бронза гасырында (б.э.к. II меңъеллык) яшәгән кабиләләрнең торулыкларын һәм каберлекләрен казып өйрәнә, шул материаллар нигезендә элгәреге тимер гасыры чорында ананьино культурасын формалаштыруга катнашкан Казан буе археологик культурасын ача (Калинин, Халиков, 1954 а; 1954 б; Халиков, 1962), баланово һәм абашево кабиләләренең курган каберлекләрен казый (Халиков, 1959; 1960). Киң колач белән үткәрелгән тикшеренүләр вакытында тупланган өр-яңа археологик материаллар нигезендә А.Х. Халиков башта кандидатлык (1955), аннан соң докторлык (1966) диссертацияләрен яклап, фән дөньясына таш һәм бронза дәверләрендә Төньяк-Көнчыгыш Европаның Урта Идел – Урал буе төбәкләрендә яшәгән күпсанлы борынгы кабиләләрнең катлаулы тарихын тәкъдим итә.

1953–1954 елларда Н.Ф. Калинин белән А.Х. Халиковның Лаеш районы Имән Кискә авылы янында урнашкан борынгы шәһәрлекне казыганда табылган материаллары фәндә моңа кадәр билгеле булмаган тагын бер археологик культура ачарга мөмкинлек бирде (Калинин, Халиков, 1960). Бу культураны IV–VII гасырларда яшәгән кабиләләр калдырган, аларны шартлы рәвештә имәнкискәлеләр дип атыйлар. Кызганычка каршы, имәнкискәлеләрнең этник тамырлары әле һаман да ачыкланмаган (төркиләр? славяннар? сарматлар?), болгарларның этник яктан формалашуында катнашу-катнашмау мәсьәләсе дә юньләп өйрәнелмәгән.

Тимер гасырына караган һәм бүгенге мари, удмурт халыкларының борынгы бабаларыннан саналган пьянобор (б.э.к. II – б.э.ның II гасырлары) һәм аларның дәвамчылары азе-

лино (III–V гасырлар) кабиләләренә нисбәтле археологик истәлекләрне өйрәнү В.Ф. Генинг өлешенә туры килде (Генинг, 1959). Ул шулай ук имәнкискә кабиләләренең Лаеш районы Рождествено авылы янында урнашкан борынгы каберлекләрен (Генинг и др., 1962), Менделеев районының Турай авылы янында һуннарның хәрбиләре җирләнгән уникаль курганнарны казып тикшерде (Генинг, 1962). Урта Идел һәм Түбән Кама төбәкләре халыкларының болгарларга кадәрге чордагы этник тарихына багышланган һәм фәнни кыйммәтен әле бүген дә югалтмаган беренче саллы хезмәтне дә В.Ф. Генинг язды (Генинг, 1959).

Азов, Кара диңгез далаларыннан безнең якларга VIII гасыр урталарында күчеп килгән болгарлар күмелгән Олы Тархан зираты (республикабызның Тәтеш районында) 1957, 1960 елларда В.Ф. Генинг һәм А.Х. Халиков тарафыннан җентекләп өйрәнелгән иде. Аның материаллары 1964 елда Мәскәүнең «Фән» нәшриятында дөнья күрде (Генинг, Халиков, 1964). Татар этногенезының болгар чорына караган этабын өйрәнү бүген дә Олы Тархан материалларыннан башлана.

Болгарда СССР Фәннәр академиясенең А.П. Смирнов җитәкчелегендәге Идел буе археологик экспедициясе сугыш вакытында өзелеп торган эшләрен дәвам итте. Шәһәрлекнең башлыча Куйбышев сусаклагычы астында калачак өлешләре казылды. 1957 елдан башлап экспедициядә Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре Т.А. Хлебникова эшләде.

Һ.В. Йосыповның 1960 елда басылып чыккан фундаменталь хезмәте болгар-татар эпиграфикасына багышланган иде. Биредә татар зиратларында башлыча XIV–XVI йөзләрдән сакланып калган 500 ләп каберташ язмалары тикшерелә (Юсупов, 1960). Еллар үткән саен әлеге хезмәтнең фәнни әһәмияте күтәрелә генә бара.

1950 нче елларда безнең Институт, күрше республикалар һәм өлкәләр белән фәнни хезмәттәшлек традицияләрен башлап, Марий АССРның Тел, әдәбият, тарих һәм экономика фәнни-тикшеренү институты белән берлектә А.Х. Халиков җитәкчелегендә Марий археологик экспедициясе оештыра. Әлеге экспедиция тарафыннан Марий республикасында һәм Горький (хәзерге Түбән Новгород) өлкәсендә борынгы фин-угыр кабиләләре калдырган дистәләгән археологик һәйкәлләр ачыла һәм казып тикшерелә (Никитин, 2007, с. 3–19).

***Археология һәм этнография секторы*** Тел, әдәбият һәм тарих институты составында 1962 елда оеша. 1965 елга кадәр проф. Н.И. Воробьев, аннан соң А.Х. Халиков җитәкләгән әлеге секторның археология төркемендә 4 археолог (сектор җитәкчесеннән башка Т.А. Хлебникова, Р.С. Габәшев, П.Н. Старостин) һәм эпиграфист-галим Һ.В. Йосыпов була. Соңгырак елларда секторга яшь археологлар Р.Г. Фәхретдинов (1966 елда), Е.П. Казаков (1967 елда) килеп өстәлә. 1970 елларда археологлар төркеменә М.Г. Косменко, Ф.Ш. Хуҗин, Р.Ф. Шәрифуллин, М.М. Кавеев, Г.И. Дроздова кабул

итеЛә. Институт коллективында археозоология (А.Г. Петренко, 1966 елда) һәм антропология (Р.М. Фаттахов, 1977 елда) буенча югары квалификацияле белгечләр эшли башлый.

Археологларның фәнни-тикшеренү планнарында өстенлекле юнәлеш булып һаман да Татарстанның Археологик картасын төзү темасы кала бирде. Бу эш бары тик 1970 нче еллар ахырында гына тәмамланды. 4500 дән артык археология һәйкәлләренең тасвирламасын үз эченә алган хезмәт 1981–1990 елларда алты томлык китап булып басылып чыкты[4] (Археологическая карта, 1981; 1984; Археологические памятники, 1988; 1989; 1990). Мәскәүнең «Фән» нәшрияты чыгара торган «Археологик чыганаклар тупланмасы» сериясендә тематик карталары белән Имәнкискә (Старостин, 1967), Баланово (Бадер, Халиков, 1976), Казан тирәсе (Халиков, 1980) археологик культураларына багышланган китаплар дөнья күрде. Р.Г. Фәхретдиновның болгар-татар археологик һәйкәлләре тупланмасы фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алынды (Фахрутдинов, 1975).

1961 елдан Куйбышев сусаклагычының Татарстан зонасында (Идел белән Кама кушылган җирдә) башланып киткән һәм дулкыннар белән яисә су астында калып юылып юкка чыга язган 700 ләп археологик һәйкәлләрне саклау-коткару максатын күз алдында тоткан тикшеренүләр Казан археологлары эшчәнлегенең күп елларга исәпләнгән тагын бер фәнни юнәлешенә әверелде. Разведка һәм казу эшләре башлыча иртәнге яз һәм көз көннәрендә, сусаклагычта су кимегән чорда башкарылды (Габяшев и др., 1976).

1968–1972 елларда П.Н. Старостин, Р.С. Габәшев, Е.П. Казаков һәм М.Г. Косменко төзелеп килүче Түбән Кама сусаклагычы астында калачак археология һәйкәлләрен казыдылар. Әлеге эшләрнең нәтиҗәләре күпсанлы мәкаләләрдә, фәнни җыентыкларда, китапларда чагылыш тапты (Древности, 1978; Казаков, 1978), тупланган материаллар М.Г. Косменконың Урта Идел мезолитына (Косменко, 1972), Р.С. Габәшевның Түбән Кама неолитына багышланган кандидатлык диссертацияләрендә төп чыганак буларак кулланылды (Габяшев, 1978).

Бронза һәм элгәреге тимер дәверләрен өйрәнү элеккечә А.Х. Халиков һәм аның коллегалары, шәкертләре тарафыннан дәвам итеЛде (1977а; 1980; Бадер, Халиков, 1976; Халиков, Патрушев, 1982). А.Х. Халиковның таш һәм бронза гасырларында Урта Идел бассейнында яшәгән халыкларның тарихын өйрәнүгә багышланган монографиясе (Халиков, 1969) Россия һәм чит ил галимнәре тарафыннан Татарстан археологларының чираттагы уңышы буларак югары бәяләнде. Әйтергә кирәк, А.Х. Халиков тарафыннан тәкъдим ителгән

[4] Әлеге хезмәтнең төп авторлары А.Х. Халиков, Р.С. Габәшев, Е.П. Казаков, П.Н. Старостин, Р.Г. Фәхретдинов, Ф.Ш. Хуҗин, Һ.В. Йосыпов 1994 елда Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясенә лаек булдылар.

фин-угыр халыкларының этногенезы концепциясе асылда бүген дә искермәде, яңа чыганаклар нигезендә ул һаман да камилләшә генә бара.

1960 нчы елларның икенче – 1980 нче елларның беренче яртысында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре болгарларга кадәрге һәм бигрәк тә Идел Болгары чорына караган археология һәйкәлләрен өйрәнүгә күбрәк игътибар бирә башладылар. П.Н. Старостин актив рәвештә Имәнкискә кабиләләренең әле хәзер дә серләр-табышмаклар белән тулы тарихын язу белән шөгыльләнде (Старостин, 1967; 1981).

1961 елдан башлап Е.П. Казаков һәм Татарстан дәүләт музее хезмәткәре Е.А. Халикова IX гасырның икенче яртысында яшәгән элгәреге болгарларның Танкеевка некрополен (биредә якынча 5–6 мең чамасы кабер бар дип исәпләнелә) казып тикшерә башладылар. Яңа чыганаклар Идел болгарларының этногенезында төркиләрдән кала фин һәм угыр компонентларының да зур урын алып торуын расладылар (Казаков, 1971; Khalikova, Kazakov, 1977).

1970 нче елларның икенче яртысында Казан археологлары болгар этногенезын өйрәнүгә кагылышлы тагын бер уникаль археология һәйкәленә тап булдылар: А.Х. Халиков һәм Е.А. Халикова тарафыннан республикабызның Алексеевский районы Олы Тигәнәле авылы янында элгәреге венгр-мажарларның IX гасырда көнчыгыштан көнбатышка (Паннониягә) күчеп утырышлары вакытында калдырылган каберлекләре тикшерелде. Әлеге ачыш, аңлашыла ки, археология дөньясында, бигрәк тә Венгриядә, зур кызыксыну уятты. Венгр коллегаларыбыз Олы Тигәнәле ачышларына багышлап халыкара конференция дә үткәрделәр, казылмаларның материалларын да тулысынча бастырып чыгардылар (Halikova, Halikov, 1981). Кызганыч, ни Танкеевка материалларын (бүгенге көндә биредә 1200 кабер өйрәнелгән), ни Олы Тигәнәленекен һаман да үзебездә, рус телендә бастырып чыгара алмыйбыз әле[5].

1970–1980 нче елларда болгар шәһәрләрен археологик өйрәнү өлкәсендә зур уңышларга ирешелде. Болгарда казу эшләре дәвам итте, һәм иң мөһиме, биредә Алтын Урда чорында төзелгән борынгы архитектура корылмаларына игътибар көчәйде (Город Болгар, 1987, с. 42 и сл.). Т.А. Хлебникова болгарларның Танкеевка, Алексеевское, Җүкәтау һ.б. шәһәрлекләрендә казу эшләре алып барды (Хлебникова, 1971; 1975). Р.Г. Фәхретдинов «Иске-Казан» – XII гасыр ахырына – XVI гасыр башларына караган Камаево һәм Рус Урматы комплексын казый башлады (Фахрутдинов, 1984, с. 125–153). Шул ук елларда А.Х. Ха-

[5] Олы Тигәнәле материаллары, ниһаять, 2018 елда дөнья күрде: Халикова Е.А., Халиков А.Х. Ранние венгры на Каме и Урале (Больше-Тиганский могильник) // Археология евразийских степей. Вып. 25 / Отв. ред. А.Г. Ситдиков. Казань: Изд-во «Фэн»; Ин-т археологии им. А.Х. Халикова АНЕ РТ, 2018. 144 с.

ликов һәм аның хезмәттәшләре Казан кремлендә башкалабызга нигез салыну вакытын ачыклау максатында кызыклы тикшеренүләр үткәрде. Куелган максатка ирешелмәсә дә, әлеге тикшеренүләр нәтиҗәсендә башкалабызның монголларга кадәрге чорда ук яшәгәнлеген исбатлаучы материаллар, шул исәптән, иң борынгы саклану корылмалары табылды. Казан ханнары күмелгән төрбәләрне ачу исә киң җәмәгатьчелек тарафыннан олы бер сенсация буларак кабул ителде (Халиков, 1976; 1997).

Рус елъязмаларында Олуг шәһәр исеме белән билгеле булган, әмма археологик яктан бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән Биләрдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән экспедициясе проф. А.Х. Халиков җитәкчелегендә 1967 елда киң масштаблы казу эшләре башлап җибәрде. Көнчыгыш Европаның урман-дала киңлекләрендә беренче мәртәбә буларак Биләрне һәм аның тирә-юнен махсус приборлар белән аэрофотога төшерү, Урта Идел төбәгендә X гасырда ук салынган уникаль Җәмигъ мәчет хәрабәләрен, кирпеч архитектура биналарын («кәрван-сарай» мунчасы, «бай феодал йорты», эчке шәһәрдәге җәмәгать мунчасы) казып чыгарып консервацияләү, гомуми озынлыгы 40 чакрымга җитә торган саклану диварларын, торак йорт һәм хуҗалык корылмаларын, болгар археологиясендә бүгенгәчә бердәнбер булып кала биргән юрта эзләрен, металл коючылар, тимерчеләр, чүлмәк ясаучылар яши торган һөнәрчелек бистәләрен, шәһәр зиратларын тикшерү, материалларын озакка сузмыйча фәнни әйләнешкә кертү (Исследования, 1976; Новое в археологии, 1979; Культура Биляра, 1985 һ.б.) – боларның барысы да Биләрне, территориясенең бары тик 0,25% гына казылган булуга карамастан, археологик яктан яхшы ук өйрәнелгән болгар шәһәрләре рәтенә куйдылар. Һәрхәлдә Биләрдә эшләүче археологлар кулында Болгар дәүләтенең беренче башкаласына кагылышлы бәхәсле проблемаларны яңадан күтәрү өчен бай мәгълүмат тупланган иде (Биляр – столица, 1991; Хузин, 1995).

1970 нче елларда археологиядәге яңа ачышлар Урта Идел регионында яшәүче фин-угыр һәм төрки халыкларның килеп чыгышы проблемаларын өйрәнүне актуальләштерде. Төрки халыкларның этногенезына багышланган мәкаләләр җыентыгын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты 1971 елда чыгарды (Вопросы этногенеза, 1971). Әлеге җыентыкка кертелгән мәкаләләрнең кайберсе галимнәр арасында бәхәсләр тудырса да, ахырчиктә ул әлеге өлкәдә алып барыла торган тикшеренүләрне җанландырып кына җибәрде (Кузеев, 1974; Болгары и чуваши, 1984). Бу юнәлештә А.Х. Халиков бик актив эшләде (Халиков, 1972; 1978; 1985; 1989). Кызганычка каршы, галимнең 1970 нче еллар уртасында ук тәмамланган монографиясе моннан берничә ел элек кенә дөнья күрә алды (Халиков, 2011).

Институтның сан ягыннан артык зур булмаган археологлар төркеме алып барган тикшеренүләрнең тематикасы җитәрлек дәрәҗәдә киң булып, әлеге «киңлек» авторлар коллективы әзерләп чыгарган фәнни җыентыкларда чагылыш таба иде (Об исторических памятниках, 1981; Средневековые памятники, 1983; Военно-оборонительное дело, 1985; Волжская Булгария и Русь, 1986 и др.). Әйтергә кирәк, шул тематика кысаларында планлаштырылган хезмәтләр, кагыйдә буларак, югары фәнни дәрәҗәдә башкарылдылар. 1980 нче елларның беренче яртысында гына да Мәскәүнең «Фән» нәшриятында 5 индивидуаль монография (Халиков, 1980; Мухамадиев, 1983; Фахрутдинов, 1984; Петренко, 1984; Хлебникова, 1984) һәм 2 коллектив хезмәт (Археологическая карта, 1981; Культура Биляра, 1985) басылып чыгуы – әлеге фикерне куәтләүче ачык факт.

Казан археология мәктәбенең өлгергәнлеген күрсәтүче фактлар исәбенә галимнәребезнең еш кына Болгариядә, Венгриядә, Чехославакиядә, Финляндиядә һәм кайбер башка илләрдә үтә торган халыкара конференцияләрдә катнашуларын да өстәргә мөмкин.

1986 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтында чираттагы структур үзгәрешләр булды, аерым алганда, археология һәм этнография секторы икегә бүленде.

**Археология бүлегендә** 9 фәнни хезмәткәр (шул исәптән 1 доктор, 5 фәннәр кандидаты) һәм 4 лаборант эшли иде. Бүлек белән 1989 елга кадәр А.Х. Халиков, 1989–1990 елларда Ф.Ш. Хуҗин, 1990 елның октябреннән башлап П.Н. Старостин җитәкчелек иттеләр.

Фәнни тикшеренүләрнең тематикасы үзгәрмәде диярлек. Ел саен язын-көзен Идел-Кама сусаклагычлары зонасында калган һәм җимерелеп юкка чыгу куркынычы янаган борынгы объектларны саклауга, казулар үткәрүгә, һич югы аунап яткан табылдыкларны җыеп алуга юнәлдерелгән эшләр алып барылды. Шундый эшләр нәтиҗәсендә тупланган материалларны өйрәнеп, Е.П. Казаков Каманың түбән агымында урнашкан болгар авыллары, халыкара сәүдә үзәкләре турында кызыклы монография язды (Казаков, 1991).

Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары зонасында башлыча борынгы таш, бронза һәм элгәреге тимер гасырына караган археология һәйкәлләре өйрәнелде (Памятники первобытной эпохи, 1988; Археологические памятники зоны водохранилищ, 1992 и др.). В.Н. Марков 1988 елда ананьино кабиләләренең этник компонентларын ачыклауга багышланган кандидатлык диссертациясен яклады (Марков, 1988). П.Н. Старостинны соңгырак чорда яшәгән Пьянобор, Азелино һәм Имәнкискә кабиләләренең тарихы кызыксындырды (Старостин, 1986; Старостин, Чижевский, 1993).

Элгәреге болгарлар археологиясен Н.Ф. Калининның 100-еллыгына багышлап үткәрелгән Бөтенроссия фәнни конференциясе җанландырып җибәрде (Ранние болгары, 1989;

1990). Е.П. Казаков үзенең күпьеллык һәм уңышлы тикшеренүләр нәтиҗәсен фәнни җәмәгатьчелеккә болгар археологисендә әһәмиятле вакыйга буларак кабул ителгән фундаменталь монография һәм докторлык диссертациясе рәвешендә тәкъдим итте (Казаков, 1992).

Болгар һәм Биләр шәһәрләрендә казу эшләре тукталып тормады. Г.А. Фёдоров-Давыдов һәм Т.А. Хлебникова редакциясендә «Шәһри Болгар» исемле коллектив монографиянең беренче томнары дөнья күрде (Город Болгар, 1987; 1988). Биләр археологиясенә караган хезмәтләрдән Идел Болгарстанының X–XI йөзләрдәге башкаласы проблемасын чишүгә юнәлдерелгән мәкаләләр җыентыгын атарга була (Биляр – столица, 1991). Әлеге җыентык 1972–1975 елларда «Советская археология» журналы оештырган фәнни дискуссиядә традицион караш тарафдарлары буларак чыгыш ясаган А.П. Смирнов, Р.Г. Фәхретдинов һәм Т.А. Хлебниковага җавап рәвешендәрәк әзерләнгән иде. Болгар дәүләтенең әүвәлге башкаласы белән бәйле проблемаларны Ф.Ш. Хуҗин Биләрнең культура катламы стратиграфиясенә һәм хронологиясенә багышланган монографиясендә дә читләтеп уза алмады (Хузин, 1995, с. 137 и сл.).

1990 еллар башында Ф.Ш. Хуҗин һәм аның коллегалары моңа кадәр археологларның игътибарыннан читтәрәк калып килгән Сувар, Җүкәтау, Чаллы ише болгар-татар калаларында да казу эшләре үткәрә алдылар[6] (Хузин, Набиуллин, 1997; Хузин, Нигамаев, 1997; Хузин, Шарифуллин, 1999).

Украина ССР Фәннәр академиясенең Археология институты белән СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты арасында 1988 елда төзелгән килешү кысаларында XII гасыр гарәп географы әл-Идриси язмаларында тасвирланган Болгар – Киев сәүдә юлын археологик яктан өйрәнү өчен А.Х. Халиков һәм А.П. Моця җитәкчелегендәге экспедиция өч сезон буена (1989–1991 еллар) әлеге кәрван юлының көнбатыш (Русь) һәм көнчыгыш (Болгар) өлешләрендә җентекле разведка, ә кайбер пунктларда казу эшләре үткәрде. Тикшеренүләр нәтиҗәсе Воронежда һәм Казанда үткәрелгән конференцияләрдә чыгыш ясаучыларның докладларында (Путь из Булгара, 1992) һәм махсус монографиядә бәян ителде (Моця, Халиков, 1997).

1994 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты «Казан кремле» музей тыюлыгы һәм Казан дәүләт университеты белән берлектә Кремль территориясендә казу эшләре башлап җибәрде. Берләштерелгән археологик экспедициянең җитәкчесе итеп Ф.Ш. Хуҗин билгеләнде.

[6] Ул вакыттагы авыр кризис шартларында әлеге экспедицияләрне оештыруда, аз булса да финанслауда Институт директоры М.З. Зәкиевнең роле зур булуын рәхмәт хисләре белән махсус билгеләп үтәсем килә. – *Авт.*

Татарстан республикасы Министралар кабинетының 1995 ел 16 октябрендә чыккан 746 нчы номерлы карары нигезендә Тел, әдәбият һәм тарих институтының археология бүлеге Археологик тикшеренүләр милли үзәге (Национальный центр археологических исследований – НЦАИ) итеп үзгәртелә. Бер елдан әлеге Үзәк Татарстан Фәннәр академиясе составында яңа оешкан Тарих институтына күчә.

Шулай итеп, Тел, әдәбият һәм тарих институты составында археология фәне зур уңышларга иреште, халыкара танылу алды. Биредә үзенең илкүләм танылган галимнәре булган Казан археология мәктәбе барлыкка килде. Институт галимнәренең борынгы таш, бронза, элгәреге тимер һәм урта гасырлар, бигрәк тә болгар, Алтын Урда археологиясе өлкәсендә ясаган ачышлары археология фәненең киләчәктәге үсеше өчен нигез булып торалар.

### Файдаланылган әдәбият


Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье / Отв. ред. А.Х. Халиков. М.: Наука, 1981. 212 с.

Археологическая карта Татарской АССР. Предволжье / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1984. 116 с.

Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье / Отв. ред. П.Н. Старостин. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1986. 110 с.

Археологические памятники Центрального Закамья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1988. 98 с.

Археологические памятники Восточного Закамья / Отв. ред. Е.П. Казаков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1989. 100 с.

Археологические памятники бассейна р. Черемшан / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1990. 112 с.

Археологические памятники зоны водохранилищ Волго-Камского каскада / Отв. ред. П.Н. Старостин. Казань: ИЯЛИ КНЦ РАН, 1992. 143 с.

Археологические памятники Нижнего Прикамья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1984. 125 с.

Археология Волжской Булгарии: проблемы, поиски, решения / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 1993. 138 с.

*Бадер О.Н., Халиков А.Х.* Памятники балановской культуры. САИ. Вып. В I–25. М.: Наука, 1976. 168 с.

Биляр – столица домонгольской Булгарии / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. – Казань: ИЯЛИ КНЦ АН СССР, 1991. 139 с.

Болгары и чуваши. Чебоксары, 1984. 158 с.

Военно-оборонительное дело домонгольской Булгарии / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1985. 126 с.

Волжская Булгария и монгольское нашествие / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1988. 126 с.

Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1971. 295 с.

*Габяшев Р.С.* Неолит Нижнего Прикамья. Автореф. дис. … канд. ист. наук. М.: Ин-т археологии АН СССР, 1978. 18 с.

*Габяшев Р.С., Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х., Хлебникова Т.А.* Археологические памятники Татарии в зоне Куйбышевского водохранилища // Из археологии Волго-Камья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань, 1976. С. 3– 34.

*Генинг В.Ф.* Очерк этнических культур Прикамья в эпоху железа // Тр. КФАН СССР, сер. гуманит. наук. Вып. 2. Казань, 1959. С. 157–219.

*Генинг В.Ф.* Тураевский курганный могильник в Нижнем Прикамье // Вопросы археологии Урала. Вып. 2. Свердловск, 1962. С. 72–80.

*Генинг В.Ф., Стоянов В.Е., Хлебникова Т.А., Вайнер И.С., Казаков Е.П., Валеев Р.К.* Археологические памятники у села Рождествено. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1962. 127 с.

*Генинг В.Ф., Халиков А.Х.* Ранние болгары на Волге: Больше-Тарханский могильник. М.: Наука, 1964. 196 с., 11 л. ил.

Город Болгар: Очерки истории и культуры / Отв. ред. Г.А. Федоров-Давыдов. М.: Наука, 1987. 232 с.

Город Болгар: Очерки ремесленной деятельности / Отв. ред. Г.А. Федоров-Давыдов. М.: Наука, 1988. 280 с.

Древности Икско-Бельского междуречья: (Отчёты Нижнекамской археологической экспедиции АН СССР. Вып. 2. Работы Татарского отряда) / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1978. 151 с.

Из археологии Волго-Камья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1976. 192 с.

Исследования Великого города / Отв. ред. В.В. Седов. М.: Наука, 1976. 262 с.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Поселения эпохи бронзы в Приказанском Поволжье по раскопкам 1951–1952 гг. // МИА. 1954а. № 42. С. 157–246.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Итоги археологических работ за 1945– 1952 гг. // Тр. КФАН СССР. Сер. истор. наук. Казань: Таткнигоиздат, 1954б. 126 с.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Именьковское городище // МИА. 1960. № 80. С. 226–250.

*Казаков Е.П.* Погребальный инвентарь Танкеевского могильника // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань, 1971. С. 94–155.

*Казаков Е.П.* Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М.: Наука, 1978. 130 с.

*Казаков Е.П.* Булгарское село X–XIII веков низовий реки Камы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 176 с.

*Казаков Е.П.* Культура ранней Волжской Болгарии / Отв. ред. А.Х. Халиков. М.: Наука, 1992. 335 с.

*Косменко М.Г.* Мезолит Среднего Поволжья. Автореф. дис. … канд. ист. наук. – М.: Ин-т археологии АН СССР, 1972. – 18 с.

*Кузеев Р.Г.* Происхождение башкирского народа. М.: Наука, 1974. 571 с.

Культура Биляра: Булгарские орудия труда и оружие X–XIII вв. / Отв. ред. А.Х. Халиков. М.: Наука, 1985. – 215 с.

*Марков В.Н.* Нижнее Прикамье в ананьинскую эпоху: Об этнокультурных компонентах ананьинской общности. Автореф. дис. … канд. ист. наук. М., 1988. 18 с.

*Мухамадиев А.Г.* Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М.: Наука, 1983. – 164 с., 21 табл.

*Никитин В.В.* Пятьдесят лет Марийской археологической экспедиции // Влияние природной среды на развитие древних сообществ: Материалы науч. конф., посвящ. 50-летию Марийской археол. экспедиции / Отв. ред. В.В. Никитин. Йошкар-Ола, 2007. С. 3–17.

Новое в археологии Поволжья: Археологическое изучение центра Билярского городища / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1979. 155 с.

Об исторических памятниках по долинам Камы и Белой / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1981. 143 с.

Памятники первобытной эпохи в Волго-Камье / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1988. 130 с.

*Петренко А.Г.* Древнее и средневековое животноводство Среднего Поволжья и Предуралья. М.: Наука, 1984. 184 с.

Путь из Булгара в Киев / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КНЦ РАН, 1992. 133 с.

Средневековые археологические памятники Татарии / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1983. 168 с.

*Старостин П.Н.* Памятники именьковской культуры. САИ. Вып. Д 1– 32. М.: Наука, 1967. 48 с.

*Старостин П.Н.* Памятники предболгарского времени в Нижнем Прикамье // Плиска – Преслав: прабългарската култура. Материали от българо-съветската среща, Шумен, 1976. София, 1981. С. 82–91.

*Старостин П.Н.* Именьковские могильники // Культуры Восточной Европы I тысячелетия / Отв. ред. Г.И. Матвеева. Куйбышев, 1986. С. 90–104.

*Старостин П.Н., Чижевский А.А.* Маклашеевский V могильник // Древние памятники приустьевого Закамья. Казань, 1993. С. 20–42.

*Фахрутдинов Р.Г.* Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. 219 с.

*Фахрутдинов Р.Г.* Очерки по истории Волжской Булгарии. М.: Наука, 1984. 215 с.

*Халиков А.Х.* История населения Казанского Поволжья в эпоху бронзы. Автореф. дис… канд. ист. наук. М.: ИА АН СССР, 1955. 18 с.

Халиков А.Х. Неолитические памятники в Казанском Поволжье // МИА. 1958. № 61. С. 11–44.

*Халиков А.Х.* Новые памятники абашевской культуры в Волго-Вятском междуречье // СА. 1959. № 2. – С. 148–168.

Халиков А.Х. Материалы к изучению истории населения Среднего Поволжья и Нижнего Прикамья в эпоху неолита и бронзы. Тр. МарАЭ. Т. 1. Йошкар-Ола, 1960. 187 с.

Халиков А.Х. Очерки истории населения Марийского края в эпоху железа // Тр. МарАЭ. Т. 2. Йошкар-Ола, 1962. С. 7–187.

*Халиков А.Х.* Древняя история Среднего Поволжья. М.: Наука, 1969. 395 с.

*Халиков А.Х.* К вопросу о начале тюркизации населения Поволжья и Приуралья // Советская этнография. 1972. № 1. С. 100–109.

Халиков А.Х. О времени, месте возникновения и названии города Казани // Из истории культуры и быта татарского народа и его предков // Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань, 1976. С. 3–19.

*Халиков А.Х.* Волго-Камье в начале эпохи раннего железа (VIII–VI вв. до н.э.). М.: Наука, 1977а. 264 с.

*Халиков А.Х.* Происхождение татар Поволжья и Приуралья. Казань: Татар. кн. изд-во, 1978. 160 с.

*Халиков А.Х.* Приказанская культура. САИ. Вып. В I–24. М.: Наука, 1980. 128 с.

*Халиков А.Х.* К вопросу этнической территории буртасов во второй половине VIII – начале X в. // СЭ. 1985. № 5. – С. 161–164.

*Халиков А.Х.* Татарский народ и его предки. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. 221 с.

*Халиков А.Х.* Остатки ханских мавзолеев в Казанском кремле (по материалам раскопок 1977 года) // Мавзолеи Казанского кремля / Отв. ред. Р.С. Хакимов. Казань, 1997. С. 22–49.

*Халиков А.Х.* Основы этногенеза народов Среднего Поволжья и Приуралья / Отв. ред. С.В. Кузьминых, Ф.Ш. Хузин. Казань: Ин-т истории АН РТ, 2011. 336 с.

*Халиков А.Х., Патрушев В.С.* Волжские ананьинцы: Старший Ахмыловский могильник. М.: Наука, 1982. – 277 с.

*Хлебникова Т.А.* Алексеевское городище: (К вопросу о своеобразии раннеболгарской культуры района Нижнего Прикамья) // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань, 1971. С. 156–174.

*Хлебникова Т.А.* К истории Жукотина (Джуке-тау) домонгольской поры (по работам 1970–1972 гг.) // СА. 1975. № 1. С. 234–251.

*Хлебникова Т.А.* Керамика памятников Волжской Болгарии: (К вопросу об этнокультурном составе населения). М.: Наука, 1984. – 240 с.

*Хузин Ф.Ш.* Великий город на Черемшане. Стратиграфия, хронология. Проблемы Биляра – Болгара. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1995. 223 с.

*Хузин Ф.Ш., Набиуллин Н.Г.* Булгарский город Джукетау на Каме (по материалам раскопа III 1991 и 1993 гг.) // Археологическое изучение булгарских городов / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань, 1999. С. 90–103.

*Хузин Ф.Ш., Нигамаев А.З.* Раскопки на территории пригородов Чаллынского городища // Археологическое изучение булгарских городов / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань, 1999. – С. 114–142.

*Хузин Ф.Ш., Шарифуллин Р.Ф.* Город Сувар: некоторые итоги и задачи археологического исследования // Проблемы древней и средневековой археологии Волго-Камья / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань, 1999. С. 85–100.

*Юсупов Г.В*. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 165 с., 77 табл.

*Khalikova E.A., Kazakov E.P*. Le cimetiere de Tankeevka // Les anciens hongrois et les ethnies voisines a l'Est. Budapest, 1977. P. 21–221.

*Halikova E.A., Halikov A.H*. Altungarn an der Kama und im Ural. (Das Gräberfeld von Bolschie Tigani) / Régészeti Füzetek, ser. II, No 21. Budapest: Maguar Nemzeti Múseum, 1981. 132 S.

*Фәнни Татарстан. 2014. № 4. Б. 109–120.*

# БОЛГАР БАБАЛАРЫБЫЗ МИРАСЫ



## ХӘЗЕРГЕ ТАТАРСТАН ҖИРЛӘРЕ ҺУННАР ҺӘМ ТӨРКИ КАГАНЛЫКЛАРЫ ЧОРЫНДА: ИСТОРИОГРАФИК КҮЗӘТҮ

Урта Идел төбәгенә төрки кабиләләр кайчан үтеп керә башлаган? дигән сорауга җавап әлегә кадәр табылмаган. Табигый ки, әлеге проблеманы чишү өстендә галимнәр күптәннән эшлиләр. Бүгенге көндә тарих фәнендә иң нык таралган җавапларны (концепцияләрне) өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1). Болгарларга кадәр безнең төбәкләрдә хәзерге мари, удмурт, мордва халыкларының борынгы бабалары – фин-угыр кабиләләре яшәгән, болгарлар исә Урта Идел буйларына көньяктан, Хазар дәүләте территориясеннән, VIII гасыр урталарында гына күчеп килгәннәр (Смирнов, 1951; 1962, с. 160–174; Каховский, 1965, с. 222 и сл.; Федоров-Давыдов, с. 72–83; Кузеев, 1992, с. 43–52; һ.б.);

2). Урта Иделнең төркиләшүе болгарлардан күпкә элегрәк, III–IV гасырларда һуннар чорында ук башланып, VI–VII гасырларда, ягъни Төрки каганлыклары чорында дәвам иткән, димәк, болгар бабаларыбыз чит-ят кавем җирләренә түгел, бәлки тугандаш кабиләләр арасына килеп төпләнгәннәр (Бартольд, 1968, с. 37–38; Худяков, 1927, с. 135–146, Халиков, 1971, с. 7–36; һ.б.);

3) төркиләрне Урта Идел буйларына каяндыр күчеп килгән килмешәкләр дип санау дөреслеккә туры килми, чөнки алар шушы җирләрдә

әле безнең эрага кадәр I меңьеллык башында ук формалашып, һуннарга кадәр үк тыныч кына яшәп ятканнар (Фирсов, 1919; Калинин, 1948; Малов, 1948; Зәкиев, 2008; 2012).

Соңгы концепция авторларының карашлары, күп кенә галимнәр тарафыннан кискен тәнкыйть утына дучар булса да, һичшиксез, игътибарга лаек, чөнки ул тел, тарих, археология һәм антропология материаллары белән берникадәр раслана. Мәсәлән, Казан археология мәктәбенә нигез салган күренекле галим Н.Ф. Калинин, 1940 нчы елларда ук инде, Идел-Кама төбәгендә элгәреге тимер гасырында формалашкан Ананьино культурасы кабиләләрен бөек грек тарихчысы Геродот тарафыннан телгә алынган һәм этник яктан Кара диңгез буйларында б.э.к. VII–III гасырларда яшәгән скифларга охшаш *фиссагет/ тюрагет*, *ирк/ тюрк (төрк)* кабиләләре белән тәңгәлләштерергә мөмкин, дип санаган иде (Калинин, 1948, с. 93–94: шулай ук карагыз: Малов, 1948, с. 116–119). Соңгы елларда элеге караш академик М.З. Зәкиев тарафыннан тагын да баетылып, өстәмә фактлар белән ныгытылып, аның күп кенә хезмәтләрендә чагылыш тапты (Зәкиев, 1998, б. 163–177; 2008, б. 203–219; 2012, б. 209–224 һ.б.). А.Х. Халиков исә үзенең бер хезмәтендә иң борынгы төркиләрнең Урта Идел төбәкләренә тагын да элегрәк, б.э.к. II меңьеллык урталарында ук үтеп керү ихтималы булганлыгын искәртеп үткән иде («среди носителей турбино-сейминского металла и валиковой керамики, проникших через Урал по Каме и Волге в Восточную Европу, могли быть и представители племен алтайской языковой общности – прототюрки или тюрко-монгольские племена» (Халиков, 2011, с. 29).

Кыскача гына әлеге фактларның кайберләренә тукталып үтик.

Ананьино культурасын өйрәнүче археологларның фикеренчә, әлеге кабиләләр яисә аларның зур гына бер төркеме Кама буйларына б.э.к. VII–VI гасырларда көнчыгыштан килеп урнашканнар. Аларның Көньяк Себер, аерым алганда, Алтай якларында формалашкан булуы мөмкин: Каманың түбән агымы тирәләрендә яшәгән Ананьино археологик культурасы вәкилләренең баш сөяге төзелешендә монголоид элементлары ярылып ята (Акимова, 1968, с. 19–20); бай каберлекләр өстенә, шул чорның Көньяк Себер кабиләләренә хас булганча, сугыш кораллары уеп ясалган таш стелалар урнаштырылган (Чижевский, 2008, с. 57–59, 81–82).

Әле б.э. к. V гасырда ук Геродотның игътибарын җәлеп иткән аргиппей кабиләләре – алар Көньяк Урал тирәләрендә һәм аннан төньяктарак урнашкан җирләрдә яшәгән булырга тиеш – «скифлар кебек үк киенеп йөрсәләр дә», телләре белән алардан аерылып торганнар, җиде тылмач ярдәме белән җиде тел аша гына аралаша алганнар. Аргиппейларның Геродот «Тарих»ында теркәлеп калган *асхи/асчи (әче/ачы)* сүзен галимнәр, бер дә шикләнмичә, төрки телләрдән чыгып аңлаталар (Геродот, 2004, с. 220, 530; Зәкиев, 2008, б. 209).

Борынгы тарихчы сүзләренә караганда, аргиппейлар башка кабиләләрдән үзләренең тышкы кыяфәтләре белән дә аерылып торганнар: алар «тумыштан пеләшләр» («лысые от рождения»), яссы борынлылар һәм киң ияклеләр». Ихтимал, биредә сүз барлык төрки халыкларның ир-атлары өчен хас булган гадәт – чәчләрен үстермичә, һәрдаим кырып йөрү гадәте турында барадыр. Игътибар итегез: «Болгар ханнары исемлеге» («Именник болгарских ханов») дип аталган борынгы документта Дунай болгарлары хакимнәре «чәчләре кыркылган кенәзләр» («князья/правители с остриженными головами») исеме белән телгә алынган. «Чәчләрен кыркып, толымнар йөртә торган хазарлар» («бреющие головы и носящие косы хазары») 627 елда Дербент ныгытмаларын штурмлаучы түрк (Төрки каганаты) гаскәрләре составында сугышалар (История…, 2006, с. 48). Шунысы кызык, Идел белән Иртеш елгалары арасында, ягъни төрки халыклар яши торган ареалда, бүген дә тамырында «тазлар» топонимын йөртә торган торак пунктлары бар (Гарипова, 1995, с. 35).

Кайбер галимнәрнең фаразлавынча, аргиппейлар иң борынгы төрки кабиләләрнең (огур-праболгарларның) көнбатыш төркемен тәшкил иткәннәр булса кирәк (Халиков, 2011, с. 141–142). Әмма бу кыю фикерне расларга әлегә ышанычлы фактлар җитенкерәми. Тик шунысы шик уятмый: скифлар дәверендә Хинган тауларыннан һәм Байкал аръягыннан башланып, Дунай-Карпат буйларына кадәр сузылган иксез-чиксез Евразия далаларында тереклек иткән халыкларның көнчыгыш төркемнәре, һичшиксез, борынгы төркиләрнең мөстәкыйль этнос булып оешуында хәлиткеч роль уйнаганнар. Борынгы скифлар культурасының нигезе, хәзерге заман галимнәренең раславынча, Үзәк Азия җирлегендә формалаша башлаган, биредә, Алтай үзәнлекләрендә һәм күрше-тирә өлкәләрдә, аларның дөньякүләм атаклы археологик истәлекләре – б.э.к. VIII–V гасырларга караган Аржан, Пазырык, Туэкты, Башадар, Укок курганнары казып тикшерелгән. Кара диңгез буйларына скифлар инде калыплашкан һәм әзер культура белән соңрак үтеп керәләр (Грязнов, 1980, с. 50–59). Менә шул курганнарны калдырган кабиләләр борынгы Кытай язма чыганакларында беренче тапкыр үз исемнәре белән б.э.к. IV–III гасырларда телгә алына башлаган һуннарның этносын, матди культурасын һәм рухи мәдәниятен формалаштыруда катнашалар. Һуннар дәүләте б.э.к. III гасыр ахырында оеша.

Төрки халыкларның иң борынгы бабаларыннан саналган һуннар тарихын начар өйрәнелгән дип булмый. Россия һәм чит ил историографиясендә әлеге проблеманың төрле аспектларына багышланган хезмәтләр санап бетергесез (иң соңгы мәгълүматлар һәм әдәбият: Боталов, 2009). Тик шунысы бар: тикшеренүләр методик һәм методологик яктан камилләшкән, киңрәк колач ала барган



саен хәл итәсе бәхәсле мәсьәләләр саны арта гына бара.

Мисал өчен һуннарның этносы (теле) проблемасын алып карыйк. Элегрәк тә бериш галимнәр аларны монгол телле, икенчеләре исә төрки телле халыклар төркеменә кертеп йөртәләр иде (Дёрфер, 1986). Шулай да күпчелек галимнәр һуннарны төрки телләләр дип санау ягында булды. Без дә шул фикердә, чөнки һуннарның түркләр этногенезындагы роле (ана бүре коткарып калган һун малае турындагы этногенетик легенданы гына исегезгә төшерегез), Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа төбәкләре белән бәйләнгән тарихлары, шул тарихка нисбәтле ономастика материаллары, матди һәм рухи мәдәният өлкәсендәге үзенчәлекләр, ниһаять, төрки телләрдән чыгып аңлатыла торган сүзләр, хәтта аерым фразалар – боларның барысы да аларның төрки телле булуларына шик калдырмыйлар. Дөрес, элгәреге һуннарның күп кенә археологик истәлекләре (мәсәлән, дөньякүләм атаклы Ноин-Ула каберлеге, соңгы елларда тикшерелгән башка объектлар) хәзерге Монголия территориясендә урнашкан. Ләкин бу факт кына аларны борынгы монголлар белән тәңгәлләштерергә нигез була алмый (Коновалов, 1985, с. 41–50; Тумэн, 1985, с. 87–96; Боталов, 2009, с. 42–114). Сүз дә юк, монгол этногенезында һуннарның ролен инкарь итү дә дөреслеккә туры килмәс иде, чөнки, ахыр чиктә, ике халыкның да борынгы бабалары уртак ич, соңыннанрак та, ягъни мөстәкыйль этнослар формалашкач, алар бер үк табигать шартларында, мәдәни, социаль-икътисади үсеше ягыннан караганда якынча бер үк дәрәҗәдә торган җәмгыятьтә яшәгәннәр.

Шуңа басым ясап үтәсем килә: төрки халыклар историографиясендә һуннарны хәзерге төрки халыкларның гомум бабалары дип кабул итү традициягә кергән (Gülensoy, 2011, s. 75–100). Урта гасырлар чорына, бигрәк тә Идел Болгары һәм Алтын Урда дәүләтләре яшәгән дәвергә караган төрки-татар цивилизациясенең чишмә башы, тарихи нигезләре дә һуннарның югары үскән дәүләти мәдәниятенә барып тоташа (Хузин, 2007, с. 26–37; 2013, с. 7–32). Һуннар тарихына җитди игътибар итүнең тагын бер сәбәбе шунда ки, Көнчыгыш Европаның, аерым алганда,

Урта Идел төбәкләренең төркиләшә башлавы, ниһаять, болгар бабаларыбызның Каспий, Азов, Кара диңгез буе далаларына күчеп утырулары да һуннар белән бәйләнгән. Кытайлар тарафыннан җиңелгәннән соң төньяк һуннар, юлларында очраган кабиләләрне буйсындырып һәм сугышка яраклы ир-атны үзләренә ияртеп, II–III гасырларда ук инде Арал-Каспий тирәләренә килеп чыгалар, IV гасырда исә Көнбатыш Европа җирләренә яу чаба башлыйлар.

Һуннар миграциясе Көнчыгыш Европаның этник картасына җитди үзгәрешләр кертә. Идел-Урал төбәкләрендә яшәгән фин-угыр халыкларының бер өлеше һуннар хәрәкәтенә кушылырга мәҗбүр була. Абориген кабиләләрнең мәдәни тормышындагы кайбер үзгәрешләр археологик материалларда чагылыш таба. Мәсәлән, Пермь, Киров, Ульян өлкәләрендә, Татарстанда табылган бронза казаннарны, һичшиксез, әлеге төбәкләргә үтеп кергән һун сугышчылары алып килгән. Самара өлкәсендә тикшерелгән каберлекләрдә һуннарның матди культурасына хас әйберләр: кылычлар, ук очлары, ат йөгәне бизәкләре, каеш прәшкәләре бар (Богачев, 2011, с. 186–202). Күчмәннәр йогынтысы астында җирле халыкларның күмү йоласында яңа элемент – үлгән кешеләрне курганнарда күмү йоласы барлыкка килә. Тел галимнәре фикеренчә, этник үзгәрешләр хәтта топонимикада да чагылыш тапкан (Гарипова, 1995, с. 243–247).

«Һуннар Идел-Кама буенда» проблемасын өйрәнүдә яңа этап узган гасыр урталарында башлана. Татарстанның хәзерге Менделеев районы Турай авылы янында урнашкан борынгы зиратта күренекле археолог В.Ф. Генинг тарафыннан IV гасыр ахыры – V гасырның беренче яртысында күмелгән ике дистәдән артык сугышчының бай каберләре казып тикшерелде (Генинг, 1976, с. 55–108). Тирәнлеге 2 метрдан алып 3,7 метрга җитә торган каберләргә төшереп урнаштырылган агач табутларда башларын көньяк-көнбатышка каратып куелган гаскәр башлыклары ята. Мәет белән янәшәдә саплары көмеш фольга белән бизәлгән кылычлар, сөңге һәм ук очлары, сугыш балталары, очлым, көбә күлмәк һәм башка кораллар куелган. Күмелгән сугышчыларның этносын ачыклауга В.Ф. Генинг бик сак килә: «Нәкъ менә шул вакытта (IV гасыр ахырында. – *Ф.Х.*) Көньяк Урал һәм Түбән Идел далаларыннан ташкындай булып һуннар урдасы узып китә һәм Турай төркеме, ихтимал, шул ташкынга ияреп көнбатышка хәрәкәт итүче сугышчылар булгандыр. Бу төркем, күрәсең, һуннарның Кара диңгез далаларына һөҗүме алдыннан (370 ел), ниндидер сәбәпләр аркасында төп гаскәрдән аерылып калып, төньякка, Түбән Кама тирәләренә күчеп киткәндер» (Генинг, 1976, с. 108). Галим Турай авылы янында күмелгән сугышчыларның төрки кабиләләрдән чыккан булуын дөреслеккә якын дип саный (Генинг, 1972, с. 288).

Аның бу фикере археологларның күпчелеге тарафыннан яклау тапты (Халиков, 1986, с. 73–90; Сунгатов, 2006, с. 153–155), әмма Турай каберлегенең башка этник төркемнәр тарафыннан калдырылган булуын исбатларга алынучылар да булды. Мәсәлән, Самара археологы Г.И. Матвеева, Турай сугышчылары каберлегендә табылган әйберләрнең аналогияләрен Себер һәм Урта Азия якларынннан түгел, бәлки көнбатыштан, славяннар белән турыдан-туры бәйләнеше булган Пшевор археологик культурасы материалларыннан эзләргә кирәк, дип язып чыкты (Матвеева, 2004, с. 73). Удмуртия дәүләт университеты археологы профессор Р.Д. Голдина исә турайлыларны һуннар һөҗүме вакытында тар-мар ителгән, Кара диңгез буйларыннан күчеп утырган герман телле готлар белән тиңләштерергә тырышып карады (Голдина, Бернц, 2010). Әлеге археологлар Турай каберлегендә табылган кайбер әйберләрнең (мәсәлән, сугыш балталарының) көнбатыш халыкларыныкына охшаш булуына басым ясыйлар. «Турай проблемасын» чишүдәге катлаулы ситуациядән чыгу юлын А.В. Богачев күрсәтте һәм аның фикере белән бүгенге көндә күпләр килешә. Турай сугышчыларын ул, Аттиланың үлеменнән соң (453 ел) Көнбатыш Европадан кире Кара диңгез буе далаларына әйләнеп кайткан һуннарның Урта Идел һәм Урал якларына күчеп киткән бер төркеме дип саный (Богачев, 2009, с. 207–220).

Заманында академик В.В. Бартольд һәм М.Г. Худяков чуашларның килеп чыгышын һуннар белән бәйләп карарга омтылыш ясаганнар иде (Бартольд, 1968, с. 37–38; Худяков, 1927, 135–146). Әлеге фикерне А.Х. Халиков узган гасырның икенче яртысында Сура һәм Зөя елгалары бассейнында казып тикшерелгән Писералы (Мари Эл) һәм Андреево (Мордовия) каберлекләренең бай материаллары белән ныгытырга тырышты (Халиков, 1987, с. 24; 2011, с. 29). Писералы-Андреево тибындагы каберлекләренең үзенчәлекләрен галим Көньяк Уралда һәм Казахстанның төньяк-көнбатыш территорияләрендә яшәгән төркиләрдә таба. Әлеге төркиләрнең бер төркеме, имеш, элегрәк Көнбатыш Себернең төрки-угыр телле кабиләләре белән катнашырга өлгергән һәм II гасыр урталарында ук Иделгә юнәлгән һуннар составында хәрәкәт итә, аннан соң, алардан аерылып, Сура-Зөя буйларына килеп чыга. Менә шул кечкенә генә төркем, А.Х. Халиков фикеренчә, хәзерге чуашларның этнос буларак оешу процессында катнаша.

Әйе, Писералы һәм Андреево каберлекләрендә күмелгән кешеләр, һичшиксез, чит кабиләләрдән чыккан күчмәннәр – галимнең бу тезисы беркемдә дә шик уятмый. Әмма чуаш этногенезында аларның катнашы бармы? Бусы – бәхәсле мәсьәлә. Әлеге проблема белән махсус шөгыльләнгән Самара археологы С.Э. Зубов Писералы һәм Андреево авыллары янындагы каберлекләрдә табылган сугышчыларның калдыкларын һуннар басымы астында Көнбатыш Себердән күчеп килгән

угырлар – саргат археологик культурасы белән бәйли (Зубов, 2011, с. 87). Бу – кайбер археологик материаллар белән расланган, шунлыктан ярыйсы гына ышандыру көченә ия булган чираттагы фараз гына.

Мәкаләнең ахырында инде ярты гасырдан артык актуальлелеген һич тә югалтмаган, вакыт үткән саен кискенләшә генә баручы бәхәсләр белән «баетылгын» Имәнкискә проблемасына кагылып үтү урынлы булыр. 1953–1954 елларда республикабызның Лаеш районы Имән Кискә авылы янында Н.Ф. Калинин һәм А.Х. Халиков тарафыннан IV–VII гасырларга караган шәһәрлек (Калинин, 1960, с. 226–250), 1956–1957 елларда шул ук районның Рождествено авылы янында В.Ф. Генинг тарафыннан зур гына каберлек казып тикшерелә (Генинг, 1960, с. 131–144). Яңа ачылган Имәнкискә археологик культурасына тулы характеристиканы П.Н. Старостинның 1967 елда Мәскәүдә басылып чыккан монографиясеннән табарга мөмкин (Старостин, 1967). Бүгенге көндә фәндә борынгы имәнкискәлеләр калдырган 600 дән артык археологик истәлек билгеле. Алар башлыча Самара һәм Ульян өлкәләрендә, Татарстан Республикасында – Сура елгасыннан алып Агиделгә кадәр, Каманың түбән агымыннан башлап Самар елгасына кадәр булган зур гына территориядә урнашканнар.

Имәнкискә кабиләләренең матди культурасы, күмү йолалары җирле халыкныкыннан кискен аерылып тора. Мәсәлән, мәетләрне алар башта яндырганнар (киемнәре белән), көл-күмер, янган сөяк калдыкларын, бөтенләй янып юкка чыкмаган металл әйберләрне, кечкенә генә чокыр казып, шуның төбенә таратып ташлаганнар, янәшәгә бер яисә берничә балчык чүлмәк куйганнар. Авыл урыннарын, ныгытылган торак пунктларын казыганда йорт һәм каралты-кура калдыклары, савыт-саба китекләре, эш һәм сугыш кораллары, балчыктан әвәләп ясалган хайван сурәтләре табыла. Имәнкискәлеләрдә игенчелек нык үсеш алган. Җирле кабиләләр арасында алар иң беренчеләрдән булып җирне ат җигелгән сука белән сөреп эшкәртә башлаганнар. Тимерчелек белән шөгыльләнгәннәр, башка төрле һөнәрләрне белгәннәр. Ерак төбәкләр, хәтта Шәрекъ илләре белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырганнар. Кыскасы, әлеге кабилә кешеләре ярыйсы гына югары үсешкә ирешкән җәмгыятьтә яшәгәннәр.

Кемнәр алар, имәнкискәлеләр? – дигән сорауга беренче җавапны Н.Ф. Калинин бирде. Аның фаразлавынча, имәнкискә археологик культурасын, кайберәүләр уйлаганча, җирле фин-угырлар түгел, бәлки төрки телдә сөйләшүче бортаслар калдырган (Калинин, Халиков, 1954, с. 57 и сл.). Бу фикергә соңрак В.Ф. Генинг та кушыла (Генинг, 1972, с. 289). Гомумән, имәнкискәлеләрнең Урта Идел буйларына һуннар, аннан соң Төрки каганатлар чорында килеп утырган халык булуына шикләнүчеләр юк диярлек. Ә аларның төгәл этносы турында сүз чыкканда карашлар төрлечә кала

бирә. П.Д. Степанов, мәсәлән, безнең яклар өчен чит-ят Имәнкискә кабиләләрен угыр-мадьярлар, ягъни борынгы венгрлар дип санады (Степанов, 1964, с. 136–148; 1967, с. 105). А.П. Смирнов исә, Рождествено каберлеге материалларын көнчыгыш славяннарныкы белән чагыштырып, анда күмелгән кешеләрнең борынгы славяннар кавемененнән чыгулары турындагы фикерне алга сөрде (Смирнов, 1960, с. 7). Бу фикерне 1980 елларда Г.И. Матвеева күтәреп алды, өстәмә аргументлар белән баетырга тырышты (Матвеева, 1981, с. 52–73; 2004) һәм ул, әлеге фикер, тарихи-археологик әдәбиятта киң яклау табып (Седов, 1994, с. 315; Приходнюк, 1998, с. 76; Голдина, 1999, с. 261, 266, 277; Богачев, 2007), 7 томлык «Татар тарихы»ның беренче томы авторлары тарафыннан да кабул ителде (Кляшторный, Старостин, 2002, с. 210–217).

Имәнкискәлеләрнең этник асылына үзгәрәк караш ташлаучылар да булды. А.Х. Халиков, мәсәлән, аларны борынгы балтлар («протолитовцы») дип атый башлады, Идел–Урал төбәкләрендә хәтта балт топонимнарын да табып алды (Халиков, 1988, с. 119–126; 2011, с. 81–83). Галимнәр арасында бу фикерне яклаучылар табылмады.

Е.П. Казаковның яңа һәм оригиналь фаразы Имәнкискә культурасының килеп чыгышын иран телле сарматлар дөньясы белән бәйли (Казаков, 1996, с. 40–57; 1996, с. 97–150; 2004, с. 280–284; 2006, с. 155–162; 2011, с. 8–39). Әлеге фаразның ныклы тарихи нигезе бар. Е.П. Казаков имәнкискә кабиләләренең яңа табылган каберлекләрен тикшереп, аларда мәетне яндыру (кремация) гына түгел, бәлки яндырмыйча күмү (ингумация) йоласы да булуын ачыклады. Соңгысы борынгы славяннар өчен һич тә хас йола түгел. Галим үзенең тикшеренүләрен комплекслы характерда алып бара, ягъни сарматларның күмү йолаларын да, матди культураларын да тирән анализлап, фәнни яктан кире кага алмаслык күзәтүләр, нәтиҗәләр ясый.

Мин Е.П. Казаковның сармат кабиләләрен тулысынча иран телендә сөйләшүчеләр рәтенә куюын гына кабул итә алмыйм. Археология материаллары күрсәткәнчә, II–IV гасырларда Көньяк Урал, Түбән Идел һәм Дон буе далаларында тереклек итеп ятучы сарматлар һуннарның көчле йогынтысына эләгәләр, аларның бер өлеше хәтта төркиләшә дә (Боталов, 2000). Исегезгә төшереп үтим: күренекле болгарчы-галим проф. А.П. Смирнов әле узган гасыр урталарында ук Идел болгарларының килеп чыгышында, аларга хас үзенчәлекле культураның формалашуында сарматларның роле искиткеч зур булуын билгеләп үткән иде (Смирнов, 1951, с. 19–20). Болгарлар белән бер рәттән төрки телле аланнар да – этник яктан алар, һичшиксез, сарматлар токымыннан – соңрак Хазар каганлыгының төп халкын тәшкил иткәннәр. Сарматларның һәм аларның дәвамчылары саналган аланнарның әүвәл һуннар, соңыннанрак Хазар каганаты составындагы болгарлар тарафыннан төркиләшкән кабиләләр булуы ту-

рындагы фикер киләчәктә яңа фәнни агументлар белән тагын да баетылыр, тулыландырылыр дип уйлыйм.

Имәнкискәлеләрнең славяннар булуын шик астына алырга мәҗбүр итә торган сәбәпләрнең тагын берсе шул: соңгы елларда үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәсендә аларның, протославяннарның, Одер-Висла бассейны тирәләрендә урнашкан борынгы җирләреннән, М.З. Зәкиев сүзләре белән әйткәндә, анаватаныннан (Седов, 2002, с. 69) Көнчыгыш Европаның урман-далалы өлкәләренә, хосусан, киләчәктә Киев Русе үсеп чыгачак җирләргә күчеп утырулары V гасырда гына булуы ачыкланды. Археология буенча югары уку йортлары өчен Мәскәү дәүләт университеты чыгарган соңгы дәреслеккә күз төшерик (биредә фактлар кат-кат үлчәнеп бирелгәндер дип уйлыйм): «Как мы знаем, ни одна из земледельческих археологических культур... первой половины I тыс. н.э., чьи памятники исследованы на обширных лесостепных пространствах, не являлась чисто славянской – население каждой из них было неоднородным и состояло из различных этнических компонентов, автохтонных и пришлых... *На территории от Эльбы до Днепра и от Поморья до Дуная в V в. складывается относительно единообразная археологическая культура, получившая название пражской. Пражская культура (корчакская на территории Украины. – Ф.Х.) является практически единственной культурой, чья принадлежность ранним славянам является общепризнанной»* (Археология..., 2006, с. 410). Прага-корчак культурасын калдырган славяннар мәйданы 1 гектардан артмаган авылларда көн күргәннәр, ныгытылган шәһәрлекләр бик сирәк очрый. Казылмалар табылдыкларга бай түгел: кулдан эшләнгән чүлмәк китекләре, орчык башлары, пычаклар, сирәк кенә каеш прәшкәләре, фибулалар, беләзекләр, аз санлы башка төрле әйберләр. М.Б. Щукин сүзләре белән әйтсәк, *«славянские культуры выглядят на удивление бедными»* (Щукин, 2005, с. 158): Менә шул славяннар, имеш, үзләре яши торган җирләргә генә сыеша алмыйча, III–IV гасырлардан башлап (?), искиткеч зур киңлекләрне үзләштергәннәр – аларның, имәнкискәлеләрнең, көнчыгыш төбәкләрдәге археологик истәлекләре хәтта Агыйдел буйларында, Уфа тирәсендә дә табылган.

Монда шикләнер нәрсәләр күп, әлбәттә. Халыкларның Бөек күченеш чорында славяннарның һуннар, башка төрки күчмәннәр тарафыннан урыннарыннан кузгатылып, тынычрак төньяк-көнчыгыш тарафларга юл тотуы, беренче карашка, бер дә гаҗәп түгел. Тик бик җиңел генә мондый реконструкцияләр тәкъдим иткәнче, имәнкискә кабиләләре калдырган археологик истәлекләрне максатчан һәм комплекслы рәвештә тикшерергә, нәтиҗәләрен гомумиләштереп, әлеге өлкәдә эшләүче белгечләргә җиткерергә кирәк. Шулай булмаганда, имәнкискә «славяннарын», академик В.В. Седов фикеренә кушылып (Седов, 2001, с. 5–15), Идел Болгары дәүләтен оештыручы һәм шул дәүләт

чикләрендә яшәүче төп халыклар рәтенә кертеп куярга әзер галимнәр дә табылачак.

Аңлашыла ки, Урта Идел буе халыкларының болгарларга кадәрге чорын өйрәнүдә, тарихи чыганакларның аз булуы сәбәпле, археология фәненә өстенлекле урын бирелә. Кызганыч, Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институтында бу өлкәдә эшләүче бер генә белгеч дә юк. Галимнәрне генә түгел, киң катлау җәмәгатьчелекне дә тирәнтен кызыксындыра торган этник тарихыбыз проблемалары киләчәктә киң планда, комплекслы рәвештә өйрәнелергә тиеш.

### Файдаланылган әдәбият


*Акимова М.С.* Антропология древнего нселения Приуралья. М.: Наука, 1968. 119 с.

Археология. Учебник для студентов вузов, обучающихся по специальности «История» / Под ред. акад В.Л. Янина. М.: Изд-во МГУ, 2006. 608 с.

*Бартольд В.В.* Двенадцать лекций по истории турецких народов Средней Азии // Бартольд В.В. Сочинения. М., 1968. Т. V. С. 19–192.

*Богачев А.В.* Хронология двукружковых поясных накладок и проблема миграций в Волго-Камье на рубеже IV–V веков // Археологические памятники Оренбужья. Вып. VII. Оренбург, 2007.

*Богачев А.В.* Славяне, германцы, гунны, болгары на Средней Волге в I тыс. н.э. Saarbrücken: LAP LAMBERT Academic Publishing, 2011. 340 с.

*Боталов С.Г.* Гунны и тюрки: историко-археологическая реконструкция. Челябинск: Рифей, 2009. 672 с.

*Боталов С.Г., Гуцалов С.Ю.* Гунно-сарматы Урало-Казахстанских степей. Челябинск: Рифей, 2000. 267 с.

*Гарипова Ф.Г.* История в названиях. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 287 с.

*Генинг В.Ф.* Селище и могильник с обрядом трупосожжения доболгарского времени у села Рождествено в Татарии // Материалы и исследования по археологии СССР. М. 1960. № 80. С. 131–144.

*Генинг В.Ф.* Тураевский могильник V в. н.э. (захоронения военачальников) // Из археологии Волго-Камья. Казань, 1976. С. 55–108.

*Генинг В.Ф.* Южное Приуаралье в III–VII вв. н.э. (проблема этноса и его происхождения) // Проблемы археологии и древней истории угров. М.: Наука, 1972. С. 221–295.

*Геродот.* История в девяти книгах / Пер. с греч. и коммент. Г.А. Стратановского. М.: Олма-Пресс Инвест, 2004. 640 с.

*Голдина Р.Д.* Древняя и средневековая история удмуртского народа. Ижевск: Изд-во Удм. гос. ун-та, 1999. 464 с.

*Голдина Р.Д., Бернц В.А.* Тураевский I могильник – уникальный памятник эпохи Великого переселения народов в Среднем Прикамье. Ижевск: Изд-во Удм. гос. ун-та, 2010. 499 с.

*Грязнов М.П.* Аржан. Л.: Наука, 1980. 62 с.

*Дёрфер Г.* О языке гуннов // Зарубежная тюркология. Вып. 1. Древние тюркские языки и литературы. М., 1986.

*Зәкиев М.З.* Төрки-татар этногенезы. М.: Инсан, 1998. 624 б.

*Зәкиев М.З.* Татар халкы тарихы: Этник тамырлары, оешуы һәм киләчәге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 544 б.

*Зәкиев М.З.* Хәзерге татар халкының тирән тамырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 359 б.

*Зубов С.Э.* Воинские миграции римского времени в Среднем Поволжье (I–III вв.). Saarbrücken: LAP LAMBERT Academic Publishing, 2011. 136 с., 67 илл.

История татар с древнейших времен в семи томах. Т. I. Народов степной Евразии в древности. Казань: Изд-во «Рухият», 2002. 551 с.

*Казаков Е.П.* К вопросу о турбаслинско-именьковских памятниках Закамья // Культуры Евразийских степей второй половины I тысячелетия н.э. Самара, 1996. С. 40–57.

*Казаков Е.П.* Коминтерновский II могильник в системе древностей эпохи Тюркских каганатов // Культуры Евразийских степей второй половины I тысячелетия н.э. (вопросы хронологии) Самара, 1996. – С. 97–150.

*Казаков Е.П.* Новые материалы к проблеме интерпретации именьковских древностей // Вопросы археологии Урала и Поволжья. Вып. 2. Самара, 2004. С. 280–284.

*Казаков Е.П.* К проблеме выявления древностей средневековых сармат // Историко-археологические исследования Поволжья и Урала. Казань, 2006. С. 155–162;

*Казаков Е.П.* Этнокультурная ситуация IV–VII вв. н.э. в Среднем Поволжье // Finno-Ugrica. 2011. № 12–13. С. 8–39.

*Калинин Н.Ф.* К вопросу о происхождении казанских татар // Происхождение казанских татар. Казань, 1948. С. 90–107.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Именьковское городище // Материалы и исследования по археологии СССР. М., 1960. № 80. С. 226–250.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Итоги археологических работ 1945–1952 гг. // Тр. КФАН СССР. Сер. гуманит. наук. Казань, 1954. 126 с.

*Каховский В.Ф.* Происхождение чувашского народа. Основные этапы этнической истории. Чебоксары: Чув. кн. изд-во, 1965. 483 с.

*Кляшторный С.Г., Старостин П.Н.* Праславянские племена в Поволжье // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности. Казань, 2002. С. 210–217.

*Коновалов П.Б.* Некоторые итоги и задачи изучения хунну // Древние культуры Монголии. Новосибирск, 1985. – С. 41–50.

*Кузеев Р.Г.* Народы Среднего Поволжья и Южного Урала: этногенетический взгляд на историю. М.: Наука, 1992. 347 с.

*Малов С.Е.* Выступление на сессии Отделения истории и философии АН СССР и ИЯЛИ КФАН СССР // Происхождение казанских татар. Казань, 1948. С. 116–119.

*Матвеева Г.И.* О происхождении именьковской культуры // Древние и средневековые культуры Поволжья. Куйбышев, 1981. С. 52–73;

*Матвеева Г.И.* Среднее Поволжье в IV–VII вв.: именьковская культура. Самара: Изд-во СГУ, 2004. 168 с.

*Приходнюк О.М.* Пеньковская культура. Культурно-хронологический аспект исследования. Воронеж: Изд-во Воронеж. гос. ун-та, 1998. 256 с.

*Седов В.В.* Славяне в древности. М.: Наука, 1994. 344 с.

*Седов В.В.* К этногенезу волжских болгар // Российская археология. 2001. № 2. С. 5–15.

*Седов В.В.* Славяне. Историко-археологическое исследование. М.: Языки славянской культуры, 2002. 624 с.

*Смирнов А.П.* Введение // Материалы и исследования по археологии СССР. М., 1960. № 80. С. 5–9.

*Смирнов А.П.* Волжские булгары. Тр. ГИМ. Вып. XIX. М., 1951. 275 с.

*Смирнов А.П.* Некоторые спорные вопросы истории волжских болгар // Историко-археологический сборник. М., 1962. С. 160–174.

*Старостин П.Н.* Памятники именьковской культуры. САИ. Вып. Д 1-32. М.: Наука, 1967. 97 с., 26 л. табл.

*Степанов П.Д.* Памятники угро-мадьярских (венгерских) племен в Среднем Поволжье // Археология и этнография Башкирии. Уфа, 1964. Т. II. С. 136–148.

*Степанов П.Д.* Ош Пандо. Саранск: Мордов. кн. изд-во, 1967. 211 с.

*Сунгатов Ф.А.* Гунны в Волго-Уральском регионе // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности. Казань, 2006. С. 153–155.

*Тумэн Д.* Антропологическая характеристика хунну Монголии // Древние культуры Монголии. Новосибирск, 1985. С. 87–96;

*Федоров-Давыдов Г.А.* Некоторые проблемы археологии Поволжья железного века // Материалы конференции «Археология и социальный прогресс». Вып. 2. М., 1991. С. 72–83.

*Фирсов Н.Н.* Чтения по истории Среднего и Нижнего Поволжья. Вып. II. Казань, 1919. 136 с.

*Халиков А.Х.* Истоки формирования тюркоязычных народов Поволжья и Приуралья // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971. С. 7–36.

*Халиков А.Х.* Об этнокультурной ситуации в Среднем Поволжье и Приуралье в I тысячелетии н.э. // Культуры Восточной Европы I тысячелетия. Куйбышев, 1986. С. 73–90.

*Халиков А.Х.* Памятники писеральско-андреевского типа в Волжском правобережье и их этнокультурная интерпретация // Археология и этнография Марийского края. Вып. 12. Древности Волго-Вятского междуречья. Йошкар-Ола, 1987. С. 8–24.

*Халиков А.Х.* К вопросу об этносе именьковских племен // Памятники первобытной эпохи в Волго-Камье. Казань, 1988. С. 119–126.

*Халиков А.Х.* Основы этногенеза народов Среднего Поволжья и Приуралья. Казань: Ин-т истории АН РТ, 2011. 336 с.

*Худяков М.Г.* К вопросу о происхождении чуваш // Изв. Об-ва обследования и изучения Азербайджана. 1927. № 4. С. 135–146;

*Хузин Ф.Ш.* Узловые проблемы изучения средневековой тюрко-татарской цивилизации // Средневековая археология Евразийских степей. Т. 1. Казань, 2007. С. 26–37.

*Хузин Ф.Ш.* У истоков тюрко-татарской цивилизации // Татарстан: из века в век. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. С. 7–32.

*Чижевский А.А.* Погребальные памятники населения Волго-Камья в финале бронзового – раннем железном веках (предананьинская и ананьинская культурно-исторические области). Казань: Ин-т истории АН РТ, 2008. 172 с., илл.

*Щукин М.Б.* Готский путь: готы, Рим и черняховская культура. СПб: Изд-во СПбГУ, 2005. 576 с.

*Gülensoy Tuncer*. Barbar türkler. Ankara, 2011. 494 s.

*Фәнни Татарстан. 2014. № 2. 65–75 бб.*



# КУБРАТ ХАН ҺӘМ АНЫҢ «ХӘЗИНӘСЕ». ХАЗАР ДӘҮЛӘТЕ ИДАРӘЧЕЛӘРЕ

*Азов-Кара диңгез буе далаларында 630 еллар тирәсендә барлыкка килгән Бөек Болгар дәүләтенең гомере бик кыска була, шушы дәүләтне оештыручы Кубрат хан вафатыннан соң, 960 нче елларда, ул таркала. Көнчыгыш Европа халыкларының язмышында VII гасыр урталарыннан башлап X гасыр ахырларына кадәр – 350 ел чамасы! – яшәгән Төрки каганаты зур роль уйный. Ни кызганыч, безнең татар тарихы белән турыдан-туры бәйләнгән шушы ике дәүләтнең дә тарихы бик начар өйрәнелгән. Язма чыганаклардагы мәгълүматлар тулы түгел. Аларның хакимнәрен дә юньләп белмибез хәтта. Без белгәннәр түбәндәгеләрдән гыйбәрәт.*

**Кубрат хан.** Әлеге шәхес тарихи чыганакларда, Болгар дәүләтенең хакиме буларак, беренче мәртәбә 630 еллар башында (төгәлрәк 632 ел дип әйтүче галимнәр бар) булып үткән вакыйгалар белән бәйле рәвештә телгә алына. Кубрат – болгарлар юлбашчысы, рәсми титулы билгеле түгел. Болгариядә аны «хан» дип атау гадәткә кергән. Бөек Болгар дәүләтен «каганат» дип йөртмәгәч, аның хакимен (идарәчесен) дә «каган» дип атау дөрес булмас иде, әлбәттә. Шуңа күрә, Кубратны гади халык арасында киң таралган «хан» дәрәҗәсенә күтәрү, минемчә, чынбарлыкка хилаф китермәс кебек.

Азов буе болгарлары һәм Түбән Идел, Каспий буе далаларында күчмә

тормыш алып барган башка халыклар 558 елда борынгы түркләрнең Истеми каган гаскәрләре тарафыннан җиңеләләр һәм нәтиҗәдә Төрки каганаты составына кушылалар. 630 нчы елларга кадәр Кубрат төркиләр буйсынуындагы бер төбәкнең (бәклекнең) идарәчесе булгандыр дип фаразларга нигез бар. Төрки каганаты зәгыйфьләнеп, таркалу чорына килеп кергәч, Кубрат үз сәясәтен үткәрә башлый, мөстәкыйльлеккә омтыла. Дала халыклары арасында гегемонлыкка дәгъва кылган аварларга каршы сугышлар алып бара.

Әмма Кубрат – төрки-огурларның атаклы Дуло ыруыннан чыккан Орхан/Органа исемле хакимнең бертуган агасының улы – әлеге вакыйгалардан күпкә элегрәк Византия сәясәтчеләре арасында билгеле шәхес була. Язма чыганакларда сакланган мәгълүматларга караганда, Орхан агасы аны әле яшүсмер чагында ук Византия императоры Ираклий сараена тәрбиягә бирә. Биредә ул рум телендә сөйләшергә һәм укырга-язарга өйрәнә, сәясәт, дипломатия серләренә төшенә. Соңрак ул Ираклий белән хәрби союзга керә, Византия чикләренә һәрдаим янап, яу чабып торучы аварларга каршы юнәлтелгән килешү төзи. Һәм бу килешү шартларын тормышка ашыруда сизелерлек нәтиҗәләргә дә ирешә. Һәрхәлдә, Кубратның император Ираклий кулыннан чит кавемнәргә сирәк бирелә торган патрикий титулы алуы һич тә очраклы хәл түгел, бәлки аның Византия алдындагы казанышларын күз алдында тотып эшләнгән гамәлдер.

Кубратның христиан динен кабул итүе – ә бу факт безнең тарихчылар арасында һичбер шик тудырмый һәм ул мәктәп дәреслекләренә дә кертелгән, – аның Византия императоры сараенда тәрбияләнү нәтиҗәсе буларак кабул ителә. Әйе, бер карасаң, мантыйкка да каршы килми бу. Болгарларда һәм башка төрки халыкларда дини толерантлык хөкем сөргән Тәңречелек киң таралган булса да, арада Будда һәм зараостризм тарафдарлары да, несториан-христианнар да очрап торган. Шулай булгач, Кубратның христиан динендә булуын гайре табигый хәл дип кабул итмәскә кирәк, минемчә. Ләкин...

Ләкин шикләнергә дә урын бар. Ни өчен дисәгез, Кубрат ханның христиан динен кабул итүе турындагы хәбәр VII гасыр ахыры – VIII гасыр башында Александриядә (Мисыр) яшәгән Иоанн Никиусский (Никиуслы) исемле чиркәү әһеле калдырган язмаларда гына телгә алына. Әлеге документ латинча түгел, ә борынгы эфиоп телендә язылган һәм, белгечләрнең әйтүенчә, анда авыр аңлашыла торган сүзләр күп. Безне кызыксындырган әлеге хәбәр – ә ул төрле имеш-мимешләргә таянып язылганга охшый, диләр галимнәр, – башка чыганаклар белән расланмый. Алай гына да түгел. Иоанн Никиусский язмаларында христиан динен кабул иткән «варварлар юлбашчысының» исеме «Кубрат/Кuврат» түгел, ә «Кетрадес» дип бирелгән. Кетрадесның Кубрат булу мөмкинлеге бары тик фаразлана гына. Бу фаразны яңа, өстәмә дәлилләр белән раслау яки

аны кире кагу өчен галимнәргә күп эшләргә кирәк әле.

Әлбәттә, Кубратның кайсы дингә өстенлек биргән булуы безнең өчен алай ук мөһим түгел. Иң мөһиме шул: Кубрат хан менә дигән сәясәтче һәм дипломат, дәүләт эшлеклесе, хәрби җитәкче булган. Болгарларның беренче тапкыр халыкара күләмдә танылуы Кубрат хан идарә иткән чорга туры килә. Кубратның вафатыннан соң аның уллары үзләренә буйсынган халык белән төрлесе төрле якка таралып бетә. Алар хәтта Көнбатыш Европага, хәзерге Венгрия, Германия, Италия җирләренә килеп урнашалар. Кубрат хан оештырган Бөек Болгар дәүләте хәзерге болгарлар (Дунай болгарлары) һәм татарлар тарихы белән тыгыз бәйләнгән.

**Кубрат хан хәзинәсе.** Полтава губергнасының Константиновград өязе Малая Перещепина авылы – бу исемне Россия һәм чит ил археологлары арасында белмәүчеләр юктыр, дип уйлыйм. Шушы авылның ике яшүсмер малае 1912 елның 29 маенда көтү көткәндә очраклы рәвештә бик зур хәзинәгә юлыгалар. Малайларның берсе, унике яшендәгесе, уҗымга кереп баручы сыер артыннан чабып барганда, аягы ниндидер бер чокырга төшеп, туктап кала. Кулындагы таягы белән чокырны казып карый – алтын савыт килеп чыга. Чакыруга иптәше йөгереп килеп җитә – тагын бер көмеш савыт табып алалар. Табылдыклар турында авыл старостасына хәбәр җиткерәләр. Чокыр урынын тиз арада авыл крестьяннары чолгап ала. Хәзина бай булып чыга: әллә никадәр савыт-саба металл акчалар, сугыш кораллары, ат дирбияләре, бизәнү әйберләре... Барысы да диярлек алтын-көмештән. Табыдыклар кулдан-кулга күчә һәм... кешеләр арасында таралып та бетә.

Әмма бу тарихның ахыры хәерле була. Хәзинә турында өязнең полиция идарәсенә, Полтава Гыйльми архив комиссиясенә һәм җирле археолог И.А. Зарецкийга хәбәр итәләр. Петербургта Император археология комиссиясе Малая Перещепинага тагын бер археологны – Н.Е. Макаренконы җибәрә. Берничә көн эчендә әлеге төркем авыл кешеләре кулыннан хәзинәдәге әйберләрнең барысын да диярлек җыеп ала һәм табылдык урынын җентекләп тикшерә. Әйберләрнең тулы исемлеген төзеп һәм авырлыгын төгәл үлчәп, аны башта Константиновградтагы полиция идарәснә, аннан Полтавага һлм июль ахырларында Петербургка, Дәүләт банкына озаталар. Әлеге банктан хәзинәне Император археология комиссиясенә галимнәр карамагына җибәрәләр. 1914 елда Малая Перещепина хәзинәсе Дәүләт Эрмитажы фондларына килеп керә. Эрмитаж хезмәткәрләренең тырышлыгы аркасында, хәзинәнең авыл кешеләре кулында калган яисә төрле юллар белән коллекционерларга эләккән өлеше дә дәүләт саклагычына кайтарыла.

Шулай итеп, хәзинә составында 800дән артык предмет, шул исәптән 69 Византия акчасы булуы ачыклана. Хәзинәнең гомуми авырлыгы 75 килограмм чамасы, аның 25 килогаммы – алтын, 50 килограммы

көмеш әйберләрдән гыйбарәт. Табылдыклар арасында тәлинкә, кубок, амфора, кувшин, кашык-чүмеч кебек савыт-саба, бил каешы очлыклары, хәнҗәр-кылычлар, колак алкалары, беләзекләр-йөзекләр, ат йөгәне, ияр, өзәңге, ыңгырчак бизәкләре, кадаклар һ.б. күптөрле әйберләр бар.

Хәзинә табылган урынны 1960–1980 елларда Украина һәм Болгария археологлары тикшереп карыйлар, әмма яңа әйберләр табылмый. 1912 елгы хәзинәгә юлыккан малайны – Карп Иванович Маджар исемле кешене дә эзләп табалар. Аның сөйләве буенча, хәзинә яткан чокырда черек агач калдыклары, берничәданә кеше һәм хайван сөякләре дә булган.

Хәзинә галимнәр арасында зур кызыксыну уята: кайчан һәм ни сәбәпле күмелгән, кайсы халыкка нисбәтле? Беренче сорауга җаваны тиз табалар – VII гасыр урталары яисә шул гасырның икенче яртысы. Икенче һәм



өченче сораулар бәхәслерәк булып чыга.

Озак еллар совет археологичсенең башында торган академик Борис Александрович Рыбаковның фаразы, көчле фактлар белән расланмаган булса да, аксиома рәвешендә бөтен дәреслекләргә үтеп керә. Г.Ф. Корзухина, М.И. Артамонов, А.К. Амброз һәм Б.И. Маршак кебек археологларның башкача фикерләре, көчле тәнкыйть утына дучар була. Академик Б.А. Рыбаков Малая Перещепина хәзинәсен, аңлашыла ки, тарих битләренә антлар исеме белән кереп калган борынгы славяннарныкы дип «исбатлады». Аның төп аргументы, гадиләштереп әйткәндә, болайрак яңгырый: шулкадәр дә бай хәзинә славяннарныкы булмыйча, кучмән төркиләрнеке булмас бит инде?! Аның оппонентлары СССР Фәннәр академиясенең Археология институты директоры белән артык бәхәсләшеп торырга теләмәсәләр дә, хезмәтләрендә нәкъ менә шундый фикерне үткәрә башлаганнар иде.

Хәзинә кемнеке, дигән сорауга көтелмәгән яктан һәм бернинди бәхәсләргә урын калдырмаслык итеп ачык җавап килде. Австрия галимнәре В. Зайбт һәм тарихчы Й. Вернер хәзинә составына керә торган монограммалы (язулы) ике алтын йөзеккә игътибар итәләр һәм шул монограммаларны, дөреслегенә бернинди шик калдырмыйча, укуга (дешифровкалауга) ирешәләр. Бу ачыш турында Йохим Вернер беренче тапкыр үзенең 1984 елда чыккан китабында хәбәр итә. Беренче йөзек кашына

ХОВРАТҮ («Куврат/Кубрат», икенчесенекенә ХОВРАТОҮ ПАТРІКІОҮ («Куврат/Кубрат – патрикий») дип язылган була. Беренчесе, күрәсең, Кубратка әле патрикий дәрәҗәсе бирелгәнче бүләк ителгән булгандыр.

Өченче йөзек кашындагы монограммага галимнәр ВАТ ОРХА(N) OҮ ПАТРІКІОІ (ват/кенәз Орхан – патрикий) дип дешифровка ясыйлар. Орган/Орһан, югарыда әйтеп үтелгәнчә, болгарларның әле Төрки каганатына буйсынып яшәгән чордагы юлбашчысы, Кубратның агасы, яшь вакытта аны Константинопольгә, император сараена тәрбиягә биреп калдырган регенты. Әмма хәзинәнең Орханга бәйләнеше юк, чөнки әйберләре соңгырак чорга карый. Шулай итеп, Перещепина хәзинәсе Бөек Болгар ханы Кубратныкы булып чыга. Хәзер аны «Кубрат хан хәзинәсе» дип кенә йөртәләр.

Ничек барлыкка килгән соң бу хәзинә? Хәзер галимнәрне шул сорау борчый. Болгавыр заманнарда киләчәктә тыныч көннәр килүгә яңадан казып алу максаты белән дошманнар күзеннән саклап калу өчен махсус күмелгән «чиста» хәзинәме бу? Бераз шикләндерә. Археологлар хәзинәне табучы кешенең, без казыган чокырда черек агач калдыклары, берничә данә кеше һәм хайван сөякләре дә бар иде, дигән сүзләрен искә төшерәләр. Әгәр дә «хәзинәбез» болгар патшасының кабере булса? Бик мөмкин ич! Бу хакта бер-берсенә каршы килә торган, әмма тарихи чынбарлыкны якынайтуга, хакыйкатьне ачыклауга юнәлдерелгән фаразлар күп әйтелә. Шуларның иң ышанычлысы, минемчә, Украина археологы А.Т. Смиленко тарафыннан әйтелгән. Кубрат хан хәзинәсе серләрен ачуга күп көч куйган бу ханым озак тикшеренүләрдән соң, болгарлар үз патшаларын яндырып күмгәннәр (мондый йола югары катлау төркиләр өчен традицион күренеш) һәм кремация урыныннан якын гына бер җирдә аңа үзе исән вакытында бүләк итеп бирелгән әйберләрен дә күмеп куйганнар, дигән нәтиҗәгә килә.

Шунысы кызык: соңгы елларда Кубрат хан «хәзинәсенә» охшаш бай хәзинәләр Албания территориясендә дә, Врап һәм Ерсике авыллары тирәсендә табылды. Биредә дә шундый ук алтын һәм көмеш савыт-саба, алар арасында Византия императоры Констанц II (641–651) тамгалары куелган ике көмеш савыт, билбау бизәкләре, сугыш кораллары, алтын акчалар. Галимнәр фаразлавынча, бу байлык башта авар каганы кулында булып, соңыннан Кубрат ханның улы Куберга күчкән һәм әлеге «хәзинәләргә» эләккән.

Кубрат хан «хәзинәсенең составына тагын бер тапкыр игътибар итик. Византия акчалары арасында күпчелекне Константинопольдә император Ираклий хакимлегенең соңгы елларында (637/638 – 41 данә) һәм Константин II хакимлегенең башлангыч чорында сугылганнары (641–646 – 19 данә) тәшкил итә. Каеш прәшкәләре арасында бары тик югары катлау кешеләре – патрикийлар өчен махсус эшләнгәне бар. Бу, һичшиксез, Кубратка Ираклий бүләк иткән билбау

бизәге. Кызыклы факт: ул саф алтыннан ясалган һәм аның авырлыгы 400 граммны тәшкил итә. Элегрәк чорга караган әйберләр арасында Патерн исемле епископның император Анастасий (491–518) келәймәсе куелган тәлинкәсе, Юстиниан I (527–565) вакытында эшләнгән амфора аерылып тора. Кайбер әйберләр тупасрак, әмма күчмәннәрнең зәвыген күз алдында тотып эшләнгән.

Кубрат хан хәзинәсе турында сөйләгәндә шунысын да онытырга ярамый: болгарлар (шулай ук аларга кадәрге һәм алардан соң яшәгән төрки кабиләләр) украин халкының этник яктан формалашуында азмы-күпме дәрәҗәдә катнашканнар. Шулай булмаса, хәзерге Украина җирендә, Полтава өлкәсендә, Кубрат хан хәзинәсе табылган Малая Перещепина авылы янында беренче болгар ханына атап һәйкәл торгызып куярлар иде микән?

Һәйкәл дигәннән. Ә нигә безнең үзебездә, башкалабызда Кубрат ханга һәйкәл куймаска!? Ул һәйкәлне мин «Кубрат хан васыяте» дип атар идем. Хәтерлисездер: уләр алдыннан Кубрат, улларын чакырып, аларга дус һәм бердәм булырга куша, үзара ызгыш-талашлар чыгармыйча, дошманнар алдында тез чүкмичә, дәүләтне сакларга, исән-имин килеш киләчәк буыннар кулына тапшырырга васыять итә. Бу васыятьне скульптурада гәүдәләндерү бик актуаль бүгенге көндә.

**Хазар каганлыгы идәрәчеләре** турында бик аз беләбез. Аларның исемнәре генә билгеле, гамәлләре түгел. «Шул чордагы Европа халыклары караңгылыкта яшәгәндә күк йөзендә балкып киткән якты йолдыз кебек» (акад. В.В. Григорьев) өч гасырдан артык яшәгән дәүләт ич ул, югыйсә.

Хазар каганлыгы – Төрки каганлыгының дәвамчысы. Хазарлар элеккеге традицияләрне нык саклаганнар, дәүләт төзелеше ягыннан да, хуҗалыгы, мәдәнияты, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре һәм гореф-гадәтләре ягыннан караганда да үзләренең элгәреләреннән аерылмаганнар. Хакимият башында каган/хакан торган. Аны элгәрерәк чорларда Тәңренең җирдәге илчесе рәвешендә кабул иткәннәр: барлык җирләр һәм шул җирдәге байлык – аныкы, халкы тулысынча аңа буйсынган, гаскәр – аның кулында, сугышны ул башлый, солыхны ул төзи. Уңышлы яулар нәтиҗәсендә кулга төшерелгән байлыкларны, мөмкин кадәр гадел булырга тырышып, каган бүлә. Кыскасы, ул чикләнмәгән хокукларга ия булган.

Әмма бу хәл озак дәвам итмәгән. IX гасыр чыганакларында инде каган реаль хокукларга ия хаким рәвешендә түгел, бәлки нindидер бер дәүләт символы, элеккеге хокукларыннан мәхрүм ителгән бер изге шәхес рәвешендәрәк кабул ителә. Элеккечә аны сайлап куялар (яисә ул «вазыйфа» нәселдән нәселгә күчә). Яңа сайланган каганны сарайга алып киләләр, муена бау бәйлиләр һәм аны буа башлап сорыйлар: «Ничә ел идарә итәргә чамалыйсың?». Теге уйлаган арада муенын һаман да тыгызрак итеп кыса баралар, инде җаны чыга башлаганда гына мескен каган җавап

бирә: «Фәлән ел утырырга телим тәхеттә». Ул әйткән ел дәвамында каган үлеп куя икән, бу – аның бәхете, үлмәгән икән, аны, бөтен йоласына туры китереп, көчләп үтерәләр һәм дәүләт күләмендә берничә көнлек траур ясап, күп кеше катнашында олылап күмеп куялар. Ибн-Фадлан язмаларында «изге корбан» итеп куелган каганның исәнлеген белдереп, өч-дүрт ай саен аны халыкка күрсәтеп торулары турында хәбәр бар.

Тәхеттә менә шундый символик каган утырган чорда дәүләт белән бәк идарә итә, каганның элеккеге вазыйфаларын тулысынча ул башкара.

***Булан каган һәм Обадия.*** Хазар дәүләтенең өч гасыр ярым дәвердә идарә иткән дистәләрчә хакимнәре арасыннан безгә билгелеләре түбәндәгеләр: Булан, аннан соң Обадия, аннан Езекия, Манассия, Ханукка (Обадиянең туганы), Исаак (Ханукканың улы), аннан соң Завулон, тагын бер Манассия, Нисси, Манахем, Вениамин, Аарон, Иосиф – барлыгы 13 каган. Игътибар итегез – аларның барысы да яһүдләр токымынан (Буланның гына исеме төрки – Болан).

Шул исемлектән өчесе безгә күбрәк билгеле. Кылган гамәлләре белән. Булан (Болан) һәм аның оныгы Обадия VIII гасыр ахырыннан башлап IX гасыр урталарына кадәр идарә иткәннәр (төгәл еллары билгеле түгел). Тарихка дәүләт күләмендә яһүд динен кабул итүче буларак кереп калганнар.

Билгеле булганча, Булан каганга кадәр дәүләт дине булып ислам дине хезмәт иткән. Бу дин 737 елда, озакка сузылган гарәп-хазар сугышында Хазар дәүләтенең Мәрван җитәкчелегендәге гарәп гаскәрләре тарафыннан җиңелүе нәтиҗәсендә кабул ителә. Рус галимнәре бу фактка артык зур әһәмият бирмиләр. Имештер, азсанлы югары катлау кешеләре генә бу динне тоткан, хазарлар үзләре, шул дәүләттә яшәүче башка халыклар, шул исәптән болгарлар да, элеккеге мәҗүсилекләреннән (тәңречелектән) аерылып җитмәгәннәр әле. Бу фикер белән тулысынча килешеп бетеп булмый. Чөнки, беренчедән, археология материаллары, икенчедән, язма чыганаклар башкача фикерләргә мәҗбүр итәләр. Хазар каганлыгы территориясендә 1970 нче еллардан башлап IX гасырга (бәлки элгәрерәк чорга да?) караган мөселман зиратлары казып өйрәнелгән. Ә инде Хазар дәүләтенең башкаласы Итилдә күпсанлы мөселман халкы, шул исәптән, болгарларның да яшәве, аларның дистәләгән үз мәчетләре булуы турында укып-ишетеп белмәгән кеше сирәктер, минемчә.

Тагын бер кызыклы факт: Обадия каган яһүд динен гади халык арасында бик актив рәвештә тарата башлагач, болгарлар баш күтәрә, ризасызлык белдерә һәм, аларның бер өлеше Урта Иделгә, анда элегрәк китеп төпләнгән ырудашлары-кабиләдәшләре янына күчеп китәләр. Бу факт язма чыганакларда сакланып калган.

Ә менә Хазар халкының яһүд диненә күпләп күчүләре турында бернинди мәгълүмат юк. Әйе, югары катлау кешеләре кабул иткәннәр бу динне. Ләкин массовый рәвештә

кабул итү булмаган. Бу хакта археология материаллары да ачык сөйли: бүгенгә кадәр яһүдиләр йоласы белән күмелгән бер генә кабер дә ачылмаган әле. Шулай да хәзер «Хазар каганты – яһүдләр дәүләте» дигән уйдырма тезис халыкара мәйданда бик актив таратыла.

***Иосиф/Йосыф каган***. Ул – соңгы хазар каганнарыннан. Бәлки әле иң соңгысыдыр. Кайбер тарихчылар ул рус кенәзе Святослав явы вакытында, 965 (972?) елда үлгәндер дип фаразлыйлар. Иосиф «патша» тарихка ничек кереп калган соң?

954–961 елларда Кордова (Испания) хәлифәсе Габдрахман II, дөресрәге, аның сарай чиновнигы еврей Хасдай ибн Шафрут белән Иосиф патша арасында хат алышу булып ала. Теге яһүдкә Хорасан сәүдәгәрләре аркылы ерак Идел-Каспий буйларында урнашкан «яһүдләр иле» турында хәбәрләр килеп ирешә. Нинди ил ул? Нинди халыклар яши анда? Зурмы ул, кечкенәме? Шәһәрләре бармы? – Иосифка җибәргән хатында Хасдай ибн Шафрут аннан шул сорауларга җавап бирүен үтенә. Иосифның Кордова хәлифәсенә җибәргән хаты ике нөсхәдә сакланып калган. Берсе, кыскача варианты, әле 1577 елда ук, икенчесе, киңәйтелгән варианты, 1877 елда табылган. Бу документлар тарихчылар өчен кыйммәтле чыганаклар булып тора. Биредә хазарларның төрки кабиләләрдән килеп чыгышы турында мәгълүмат бирелгән. Дәүләтнең чикләре дә күрсәтелә, әмма инде Иосиф биредә бераз алдаша, чикләрне киңәйтебрәк күрсәтә. Аңа буйсынган халыклар арасында славяннар (вятичлар, северяннар һ.б.лар), аланнар, бортаслар, болгарлар, суварлар, черемислар – барлыгы 13 халык, «аларның барысы да миңа буйсыналар һәм миңа салым түлиләр», дип санап кителгән.

Хазар дәүләтендә яшәгән халыклар арасында болгарлар белән аланнар күпчелекне тәшкил иткәннәр. Ни кызганыч, аларның безгә мәгълүм идарәчеләре арасында төрки кавемгә караганнары юк.

*Татарстан. 2017. № 3. Б. 70–73;*
*2018. № 3. Б. 48–51.*



## БОЛГАР ШӘҺӘРЕ
## ҺӘМ УРТА ИДЕЛДӘ ИСЛАМ ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ

Ислам, дөньядагы башка диннәр кебек үк, фәлсәфи, социаль һәм этик карашлар системасы, иҗтимагый тормышны, кеше мөнәсәбәтләрен җайга салу кодексы, милли үзаңның состав өлеше, халыкларның этник берләшүенең мөһим идеологик факторы.

922 елның 21 маенда (иске стиль буенча 16 майда) Россия Федерациясендә яшәүче хәзерге заман татарларының болгар бабалары ислам динен рәсми рәвештә Болгар шәһәрендә[1] кабул итеп, мөселман дөньясының бер өлешенә әверелде.

Шушы тарихи вакыйгага кадәр Идел буе болгарларына, әле ул чакта ярымкүчмә кабиләләргә, Азов-Кара диңгез төбәкләреннән күтәрелеп, безнең җирлектә утрак тормышка күчүләре, яңа табигый-географик һәм климат шартларына җайлашулары, Идел-Кама буйларында яшәп ятучы җирле халыклар арасында сәяси гегемон буларак формалашулары белән бәйле шактый катлаулы һәм озын юл үтәргә туры килә.

Төрки телле һәм җирле фин-угор кавемнәрен үз эченә алган Болгар җәмгыяте яңа идеологиягә мохтаҗ була, чөнки күп аллалыкка нигезләнгән мәҗүсилек эльтебер (илтабар) Алмыш һәм аның тирәсендәге югары катлау вәкилләренең төрле кабиләләрне берләштерү юлы белән куәтле дәүләт төзү планнарын тормышка ашыруга киртә булып тора. Бу максатка шул заманнарда таралган монотеистик, ягъни бер аллага таянучы диннәрнең берсе генә идеология коралы булып хезмәт итә ала. Мондый идеология сыйфатында, болгар хакиме Алмыш оешып килә торган дәүләтнең төрле кавемнәрен

[1] Ибн Фадлан язмаларында Болгар шәһәре бер тапкыр да телгә алынмый, күрәсең, ул вакытта әле Болгар шәһәр дәрәҗәсенә кадәр үсеп җитмәгән булгандыр, соңрак яуланган шанлы тарихының башлангыч чорында гына булгандыр.

бердәм халыкка тупларга сәләтле ислам динен сайлап ала.

Бу дин болгарларга күптән таныш булган. Аларның бер өлеше әле Хазар каганлыгында яшәгән чорда ук мәҗүсилектән, дөресрәге, тәңречелектән, мөселман диненә күчкән була. Биредә, Хазар дәүләтендә, Шәрыкнең иң зур Ислам мәдәнияте үзәге – Харәземнан килгән мөселманнар күп була. Болгарның Урта Азия белән сәүдә һәм мәдәни элемтәләре әле Иделдә дәүләт барлыкка килгәнче үк урнашкан була. Бу элемтәләр тугандаш төрки халыклар арасында рухи бердәмлекне ныгытуда сизелерлек роль уйнаган.

Шилки угылы Алмыш хан[2] Урта Азияда таралган хәнәфи мәзһәбенең сөнни исламын әле IX гасыр ахырында ук кабул иткәндер дип фаразлана. 902–908 елларда сугылган болгар тәңкәләрендә аның мөселманча исеме Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ дип күрсәтелгән. 922 елның 21 маенда исә Идел Болгары ерак Багдадтан чакырылган дәрәҗәле кунаклар тарафыннан рәсми рәвештә мөселман дәүләте дип таныла һәм аның ислам цивилизациясе дәүләтләре составына керүе уңаеннан тантаналар уздырыла.

Әлеге истәлекле тарихи вакыйгадан соң 1100 елдан артыграк вакыт узып киткән.

Татарларның болгар бабалары белән бәйләнгән бар нәрсәгә карата дулкынландыргыч мөнәсәбәтен аңлау кыен түгел. 2010 елның октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Болгарда Ислам динен рәсми кабул итү көнен истәлекле дата дип игълан итте, һәм ел саен мөселманнар бу көнне зур бәйрәм буларак билгеләп үтәләр. Хәтта республикадан читтә яшәүче татарлар да Болгарның изге урыннарына сәяхәт кылуны үзләренең изге бурычлары дип саныйлар, борынгы легендаларны, риваятьләрне хәтерләрендә саклыйлар. Дистәләрчә күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре XIX гасырга кадәр «Болгари» тәхәллүсен үз исемнәренә һәм фамилияләренә кушып, зур горурлык хисләре кичергәннәр. Соңгы елларда исә Казанда һәм Ульянда болгар шагыйре Кол Галигә, Алабугада – Ибраһим ханга скульптура һәйкәлләре ачылды…

Әлеге язмабыз Иделдә болгар-татар цивилизациясен формалаштыруда төп роль уйнаган мәшһүр шәһәр үзәкләренең берсенә, ә соңрак, Казан ханлыгы таркалганнан соң, Россия мөселманнарының бердәмлек символына әверелгән урта гасыр Болгарына багышлана. Бу рольне ул бүген дә, ЮНЕСКО тарафыннан Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирас һәйкәлләре исемлегенә кертелгәннән соң да лаеклы рәвештә башкарып килә.

Хөрмәтле укучыбыз алда күрер әле: Алтын Урда дәүләтчелеге чорында чәчәк атып яшәгән Болгар шәһәре, хәтта җимерелеп юкка чыкканнан соң да кызыксынучан сәяхәтчеләрне үзенә җәлеп итеп торудан туктамаган. Аның хәрабәләрен зират кылырга югары дәрәҗәле дәүләт җитәк-

[2] Гади халык арасында Болгар хакимнәрен илтабар, әмир дип түгел, хан дип атау киң таралган. Бу социаль термин борынгы төркиләрнең *каһан* сүзеннән барлыкка килгән.

челәре, императорлар Петр I һәм Екатерина II, атаклы дин әһелләре, дөньякүләм танылган зур галимнәр килеп киткәннәр.

Бүгенге Болгар – арттырып әйтүебез түгел! – чын-чынлап «Яңарыш чоры» кичерә. Республикабызның беренче президенты М.Ш. Шәймиев башлангычы белән оешкан «Татарстан республикасы тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу фонды»ның актив эшчәнлеге һәм хөкүмәтебез тарафыннан кабул ителгән «Татарстан Республикасы мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчеге» комплекслы программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә шәһәрлекнең масштаблы археологик тикшеренүләре, яңа ачык архитектура корылмаларын консервацияләү һәм реставрацияләү, шәһәрлек территориясен төзекләндерү эшләре алып барылды. Яңа музейлар ачылды. Алар арасында уникаль Болгар цивилизациясе музее да бар. Ак мәчет һәм янәшә урнашкан Ислам академиясе ачылу Болгарны яңадан Ислам цивилизациясе үзәгенә әйләндерде.

Болгарга бүген дә халык ташкыны агыла. Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән туристлар Идел буе болгарларының, аларның турыдан-туры варислары булган татар халкының борынгы һәм заманча мәдәнияте белән танышудан чын ләззәт алып китәләр.

* * *

Исламның туган җире – VII гасырда борынгы ыруглык җәмгыятенең таркалуы һәм яңа феодаль тәртипләр барлыкка килү процессын кичергән Согуд Гарәбстаны. Төрле социаль катламнар, сәяси фиркаләр һәм аларның өйрәтмәләре – идеологияләре арасында кискен конфликтлар белән үрелеп барган күчү чоры халыкны үзләре артыннан алга алып барырга сәләтле күренекле лидерларын тудыра. Гарәп җәмгыятенең иске, инде шактый какшаган нигезләре җимерелә башлаган бер чорда Абдаллаһ Абд Әл-Моталлиб улы Мөхәммәд (570–632) шундый лидер булып танылa.

Язмыш кушуы буенча вакыйгалар үзәгендә торып калган Мөхәммәд мәҗүсилек белән бәйләнгән иске идеологиягә каршы көрәш башлап җибәрү өчен нигезендә дөньяга бөтенләй башкача караш яткан яңа доктрина, яңа идеология эшләргә кирәклеген аңлый. Күңелендә әлегә инстинктив рәвештә генә урнашкан бу фикер Мөхәммәдкә һич тынгы бирми. Яңа идеология, аның уйлавынча, Гарәбстан җирендә яшәп ятучы күпсанлы, еш кына бер-берсе белән сугышып ятучы күчмә һәм ярымкүчмә кабиләләрне берләштерү көченә ия булырга тиеш. Бердәнбер Аллаһы Тәгаләнең бөеклеген игълан итүче ислам тиздән әнә шундый идеологиягә әвереләчәк. Мөхәммәднең актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә Гарәбстанның барлык халкы диярлек исламга күчеп бетәчәк.

Мөхәммәд исән вакытта уңышлы гына башланып киткән яңа дин тарату кампаниясе аның вафатыннан соң Гарәбстан ярымутравыннан читкә чыга. Йөз ел дәвамында, дөрес, бераз

«тәнәфесләр» белән, көнбатышта Испания, Марокко һәм Мавританиядән башлап, көнчыгышта Пакыстан, Һиндстан һәм Бангладешка кадәр сузылган, төньякта исә Урта, Кара, Каспий һәм Арал диңгезләре, көньякта Африка Сахарасы һәм Һинд океаны диңгезләре белән чикләнгән зур территорияләр һәм шул җирләрдә яши торган халыклар тиздән Багдад хәлифәте хакимияте астына эләгәләр.

VII гасыр урталарында ук исламның Көнчыгыш Европага, хәзерге Россия җирләренә үтеп керүе башлана. Хәзерге Дагыстан территориясендә Халифәтнең төп көндәше – Хазар каганаты. Гарәп-Хазар сугышлары йөз елга якын дәвам итә. 737 елда полководец һәм булачак хәлифә Мәрван ибн-Мөхәммәдкә Хазар дәүләте белән солых килешүе төзергә туры килә. Шартнамә буенча Хазар каганы, аның яраннары һәм кул астындагы халыклар, шул исәптән болгарларның да бер өлеше, җиңүчеләр динен кабул итәргә мәҗбүр ителәләр.

**Болгар тарихында 922 ел.** 1956 елда Бөек Новгородның Нерев дип аталган бер бистәсендә археологик казу эшләре алып барганда Шәрык илләреннән китерелгән көмеш тәңкәләр хәзинәсе табыла. Хәзинәдәге тәңкәләр арасыннан бер ягына Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ исеме язылган дирһәм галимнәрнең игътибарын яулап ала. Ул елларда Көнчыгыш нумизматикасы белән актив шөгыльләнүче Мәскәүнең Дәүләт тарих музее хезмәткәре Светлана Алексеевна Янина Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ – Идел буе Болгары хакиме Алмыш ханның мөселманча исеме, ә тәңкә исә дирһәмнең кире ягында күрсәтелгән Аббас хәлифәсе әл-Муктафи (902–908) идарә иткән чорда сугылган булуын кире какмаслык дәлилләр белән исбатлый алды.

Тагын бер кызыклы факт. Ул 903–912 елларда танылган гарәп географы һәм тарихчысы Ибн Рөстә тарафыннан язылган «Әл-алак ән-Нәфисә» («Кадерле кыйммәтләр») дигән зур энциклопедик хезмәтнең җиденче томында теркәлгән. Ул болай дип хәбәр итә: "Болгарларның күпчелеге ислам динен тота, авылларында мәчетләре һәм имамнары-мөәзиннәре белән башлангыч мәктәпләр бар <...> Аларның киемнәре мөселманнарныкына охшаган, зиратлары да мөселманнарныкы кебек». Болгар мөселманнары турында мәгълүмат Ибн Рөстәнең китап язу чорында гына барлыкка килмәгәндер дип уйларга кирәк; бу мәгълүматлар, безнең уйлавыбызча, IX гасыр азагы чынбарлыгын чагылдыра.

Шунысы гаҗәп, хәтта шушы фактлар да фәндә ныклап урнашкан һәм Идел буена килеп төпләнгән болгар халкы ислам динен 922 елда гына, дин эшләре буенча һәм кайбер башка мәсьәләләрне хәл итү өчен махсус чакырылган Багдад илчелеге Болгар шәһәрендә булган көннәрендә генә Җәгъфәр ибн Абдаллах тарафыннан кабул ителгән дигән фикерне юкка чыгара алмады. Исламның болгарларга бик иртә үтеп керү фактларына игътибар итмәделәр.

Шул ук вакытта, XIX гасырның 80-нче елларында ук танылган дин

галиме һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани болгарларны Алмыш хан (Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ) заманында түгел, ә Габбаси хәлифәләре әл-Мә’мүн (813–833) һәм әл-Васыйк (842–847) идарәсе чорында, ягъни IX гасырның беренче яртысында ук исламлаштыра башлыйлар, дип язып чыккан иде. Шушы ук фикерне соңыннан, әле Советлар хакимияте чорында ук, күренекле археолог һәм тарихчы профессор Альфред Халиков әйтте. Ул үзенең хезмәтләрендә хәлифә Мә’мүн заманында Хазар каганлыгы белән инде VIII гасырда ук мөселманлашкан Урта Азия арасында тыгыз хәрби-сәяси һәм сәүдә-икътисади элемтәләр урнашкан булуына басым ясады. Хазар дәүләтендә яшәгән болгарларга ислам дине нәкъ менә Урта Азиядән, төгәлрәге Харәзем өлкәсеннән үтеп кергән булырга тиеш, дип фаразлады әлеге галим.

Каганлык халкының шактый өлеше чыннан да ислам динен тоткан дигән фикерне Дон елгасы бассейнында ачылган IX гасыр мөселман зиратларын казып тикшергән археологлар да раслый. Хәзерге вакытта Хазар каганлыгы территориясендә, нигездә Азов буйларында, ягъни, соңрак Урта Иделгә күчеп утырган болгарлар тупланган урыннарда, дистәгә якын мөселман каберлекләре турында мәгълүматлар бар. Хазар илендә мөселман сәүдәгәрләре, һөнәрчеләр, Урта Азиянең төрле өлкәләреннән килгән башка төркем вәкилләре күп була. Аларның археологик эзләре Урта Азия шәһәрләрендә сугылган тәңкәләр, тандыр тибындагы мичләре булган торак урыннар, керамик эшләнмәләр, башка әйберләр рәвешендә сакланып калган. Шундый ук әйберләр X гасырның беренче яртысында Идел болгарлары яшәгән шәһәр-авыл урыннарын казыганда да табылып тора.

X гасырда яшәгән гарәп географы Ибн Хәүкәл сүзләренчә, Хазар иленең башкаласы Итилдә утызга якын мәхәллә мәчете эшләп торган, мәчет каршында балаларны Коръән укырга өйрәтү өчен мәктәпләр ачылган. Шәһәрнең үзәк мәйданында биек манаралы Җәмигъ мәчете урнашкан була.

Археологлар тарафыннан расланган тагын бер фактны исәпкә алырга кирәк: Идел буе Болгарына хәлифә Мөкътәдир илчелеге килгәнче үк Урта Азия сәүдәгәрләре Болгар базарларында сәүдә иткән, алар белән һөнәрчеләр дә, ислам дине вәгазьчеләре дә килгән. Нәтиҗәдә, Болгар дәүләте мәдәни яктан, академик Ю.В. Готье язганча (әлбәттә, бераз арттырып, әмма асылда дөрес) «Шәрыкнең чын колониясенә» әверелә башлый. Бу исә болгарларның ислам диненә күчү процессын җиңеләйтә генә.

...Болгарлар арасында ислам диненең таралу юллары һәм вакыты турында сөйләгәндә, бер кызыклы фаразны да читләтеп үтү мөмкин түгел. Бу фаразны алга сөрүчеләр, Россия җирлегендә ислам дине Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре чорында ук, ягъни VII гасыр урталарында ук тарала башлый, дип тәкърарлыйлар. Әлеге караш яклылар XVI–XVII гасырларда яшәгән

төрек язучысы Чокрыкчызадәнең бер китабына таяналар. Аның китабында Азов буе болгарларының Фарух ибн-Гамру Хизами исемле ниндидер бер хакиме тарафыннан чын дингә, ягъни исламга табынуы турында хикәя бар. Аның яңа динне кабул итүе 629 елга карый, имеш. Йомшак кына әйткәндә, бераз шикләндерә әлеге фараз.

Идел буе Болгарында Ислам динен кабул итүне пәйгамбәребез сәхабәләре белән бәйләүче сюжет татарларның фольклор иҗатында да очрый. Риваятьләрнең берсендә, легендар Айдар хан идарәсе вакытында Болгар җиренә Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләре – Зөбәир ибн-Талкә, Зөбәир ибн-Җаһда һәм Габдрахман килеп киткәннәр, дип бәян ителә. Ерак якларга китәр алдыннан пәйгамбәр аларга, башыннан салып, үзенең чалмасын, таягын һәм кара савытын тапшыра, имеш. Бу сәхабәләр Айдар ханның ислам динен кабул итүендә хәлиткеч роль уйнаганнар булып чыга.

Ул вакытта Айдар ханның Туйбикә исемле егерме яшьлек кызы озак вакытлар инде беркем дә дәвалый алмый торган начар авырудан интеккән, имеш. Сәхабәләр ханга ярдәм итәргә теләп, кызны авыруыннан ничек коткарырга кирәклеген беләбез, дип мөрәҗәгать итәләр. Ханның ризалыгын алгач, алар Мөхәммәд бүләк иткән таякларын җиргә кадап куялар. Габдрахман дога кылганнан соң бу урында су пәйда була, ә аннары күз алдында ук каен агачы үсеп чыга. Каен ботакларыннан себерке җыялар, һәм бу себерке белән авыру кызны мунчага алып барып чабалар. Тиздән Туйбикә тулысынча терелеп бетә. Могҗиза өчен рәхмәт йөзеннән Айдар хан үз кызын пәйгамбәребезнең бер сәхабәсенә – Коръәнне яттан белүче Зөбәир ибн-Талкәгә кияүгә бирә. Алар егерме биш ел бергә яшиләр. Вафатыннан соң Зөбәер ибн-Талкә Болгар шәһәрендәге Кече манара янында барлыкка килгән Изгеләр зиратына җирләнә, имеш.

Күргәнебезчә, Болгар илендә Ислам дине таралу Пәйгамбәребез Мөхәммәд заманында ук башлана дигән фикер риваять-легендаларга гына таяна һәм объектив чыганаклар белән расланмый. 630–660 нчы еллар тирәсендә, ягъни Кубрат хан идарә иткән чорда, Бөек Болгар дәүләтенең халкы ислам дине тотмаган. Алардан соң калган зиратларда бары тик мәҗүси йолалар буенча күмелгән кеше сөякләре генә табыла. VII гасырның 60 нчы елларында Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң Урта Иделгә күчеп килүчеләрнең беренче дулкыны булып саналган болгарлар да үлгән кешеләрне мәҗүсиләр йоласы буенча күмгәннәр. Ләкин әле бу, болгар халкы Ислам дине белән бөтенләй дә таныш булмаган, дигән сүз түгел. 922 елгы тарихи вакыйгаларыннан соң Болгардагы Ислам тарихын Мөхәммәд пәйгамбәр белән бәйләргә омтылу барлыкка килә. Бу омтылыш-теләк болгарларның Ислам дине белән Урта Иделгә күчкәнче үк таныш булуларына ишарә, күрәсең.

* * *

Болгарларның Ислам динен кабул

итү тарихында төп вакыйгаларның берсе, һичшиксез, бүген гади халык арасында Алмыш исеме белән танылган, чынлыкта исә 922 елга кадәр кимендә ике дистә ел элек үзенә Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ исеме алган Болгар ханы белән бәйле. Заманында аның титулы борынгы төркиләрдәгечә эльтебер/илтабар/йылтывар (ил башлыгы, юлбашчы мәгънәсендә) дип йөртелгән, ә соңрак, ислам динен кабул иткәч, әмир дип атый башлаганнар.

...921 елның язында Багдадка Абдаллаһ ибн-Башту җитәкчелегендәге илчелек килә. Ул ерак Болгардан Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ тарафыннан җибәрелгән була. Илче тарафыннан Габбасилар хәлифәсе әл-Моктәдиргә тапшырылган хатында Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ аннан «дингә өйрәтүче, Ислам диненең кануннарын аңлатучы, аның өчен мәчет төзеп бирүче, аның (хәлифәнең) Ислам диненә өндәвен үзенең шәһәрендә һәм үзенең бөтен дәүләтендә халыкка җиткерү өчен аңа, Болгар патшасына, мөнбәр торгызучы кешеләр җибәрүен сораган һәм ул, Болгар патшасы, дошман патшалардан анда торып саклансын өчен хәлифәдән кальга (крепость) салуын үтенгән... Хат килгәч, аңа, Болгар патшасына, аннан, хәлифәдән, нәрсә сораган булса, шуңа ризалык бирелде» (Ибн Фадлан язмаларыннан).

921 елның 21 июнендә Багдадтан Болгар иленә Сусан әр-Расси һәм аның сәркәтибе Әхмәд ибн-Фадлан җитәкчелегендә зур кәрван-илчелек китә. Юл Хамадан, Рей, Нишапур, Мәрв һәм Бохара аша Харәземга кадәр дәвам итә. Аннан соң кәрван зур кыенлык белән ярымчүлле Устюрт калкулыгы буйлап бара һәм Җаек (Урал) елгасына чыга. Ерак араларны үтеп, күчмә төрки халыклар биләп торган җирләр аша юлчылар Иделгә якынлаша. Сүзне Ибн Фадланга бирәбез:

«Без болгарлар патшасыннан, ә ул – без бара торган кеше, бер көн һәм бер төн ара ераклыгында булганда, безне каршылау өчен үзенә буйсынган дүрт патшаны, ир туганнарын һәм улларын җибәргән иде. Алар безне каршыладылар, аларның ипиләре, итләре һәм тарылары бар иде, һәм алар безнең белән бергә кузгалып киттеләр. Һәм без болгарлар патшасыннан ике фәрсах ара ераклыгында булганда, ул безне үзе каршылады. Безне күргәч, атыннан төште, бөек һәм кодрәтле Аллаһыга табынып, рәхмәтләрен белдереп, йөзтүбән егылды. Аның җиң эчендә дирһәмнәр бар иде, һәм ул аларны безгә сипте. Ул безнең өчен чатырлар кордырды һәм безне аларда урнаштырды. Безнең аның янына килеп җитүебез – өч йөз унынчы ел мөхәррәм аеның уникенче төне үткәч, якшәмбе көнне булды» (хәзерге календарь буенча 922 елның 17 маена туры килә).

Багдад илчелеге маршрутын һәм Ибн Фадлан язмаларын җентекләп өйрәнү 922 елның 21 маенда узган тантаналарның кайда узуын ачык күрсәтә. Ул Итилдән бер фәрсах (6 чакрым) ераклыгында урнашкан Болгар дәүләте хакиме ставкасында, соңрак шәһәр һәм башкала статусын алган артык зур булмаган бер җирлектә уза.

Багдадтан килгән илчеләр якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрендә үзләренең чатырларында калалар, илнең башка төбәкләреннән бәкләр, олы бәйрәмгә чакырулы затлар китеп җиткәнче ял итәләр. Пәнҗешәмбе көнне барысы да Багдад хәлифәсенең хатын уку һәм бүләкләр тапшыру тантанасына җыелалар. Тантаналар турында бездән яхшырак итеп илчелек сәркәтибе Әхмәд ибн-Фадлан сөйләячәк:

*«Пәнҗешәмбе килеп җиткәч һәм халык җыелгач, без үзебез белән алган ике чигелгән байракны җәеп җибәрдек, Болгар патшасына җибәрелгәнияр белән атны иярләдек, Болгар патшасын кара киемнәргә киендердек һәм башына чалма кидердек. Мин хәлифәнең хатын чыгардым һәм аңа: «Хат укыганда утырып тору рөхсәт ителми», – дидем. Һәм ул аякларына торып басты, үз дәүләтенең шунда булган күренекле кешеләре дә торып бастылар. Мин укый башладым һәм хатның башын укыдым, һәм «Сиңа тынычлык булсын! Һәм чыннан да, мин сиңа мөрәҗәгать итеп, Аллаһыны данлыйм, Аннан башка бүтән бөек көч юк», дигән сүзләргә җиткәч, мин: «Мөселманнарның хөкемдарына тынычлык теләп җавап бир!» – дидем. Һәм ул җавап бирде, һәм шунда булган кешеләр дә барысы бергәләп җавап бирделәр.*

*Безнең укыганны хәрефен хәрефкә тәрҗемә итүдә тәрҗемәче дә ялгышмады. Һәм без хатны укып бетергәч, алар «Аллаһу әкбәр!» сүзен әйттеләр. Җир яңгырап торды.*

*Аннан соң мин вәзир Хәмид ибн әл-Габбасның хатын укыдым, һәм Болгар патшасы бу вакытта басып торды. Аннан соң мин аңа утырырга куштым, һәм ул Нәзир әл-Хәраминең хатын укыганда утырып торды. Һәм мин хат укуны тәмамлагач, Болгар патшасының ирченнәре аңа бик күп дирһәмнәр чәчтеләр. Аннан соң мин хуш исле нәрсәләрдән, аның өчен һәм аның хатыны өчен булган киемнәрдән, энҗеләрдән торган бүләкләрне чыгардым... Аннан соң мин аның хатынын кешеләр барында бүләкләдем, ә ул аның (Болгар патшасы) белән янәшә утыра иде. Һәм бу – аларның йоласы. Һәм мин аны бүләкләгәндә хатын-кызлар аңа дирһәмнәр чәчтеләр».*

Кич белән Багдадтан килгән мәртәбәле кунаклар хөрмәтенә тантаналы мәҗлес үткәрелә.

Шулай итеп, Багдад хәлифәсе илчелеге программасының мөһим өлеше – Болгар дәүләтендә рәсми дин буларак Исламны канунлаштыру тәмамлана. Болгар иле урта гасыр ислам цивилизациясенең иң төньякта урнашкан өлкәсе булып танылды.

Күпмедер вакыт делегация әгъзаларын ил һәм аның табигате белән таныштыруга, болгарларның яшәү рәвешен, аларның шөгыльләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен, салым салу системасын, мирас кагыйдәләрен өйрәнүгә китә. Ибн Фадланда бай рус-скандинав сәүдәгәрен җирләү процессын күзәтү бик зур тәэсир калдыра.

Шунысы игътибарга лаек: Багдадка әйләнеп кайткач язылган

«Рисале»сендә Ибн Фадлан үзенең бары тик бер гаиләне генә исламга күндерүе турында хәбәр итә. Биш мең кешедән торган бәрәнҗәрләр кабиләсенә караган кешеләрнең барысы да күптән инде мөселманлыкка күчеп беткән булалар. Аларның агач бүрәнәләрдән салынган мәчетен гарәп илчесе үз күзләре белән күрә.

Илчелек сәркәтибе һәм аның иярченнәре мөәзиннәргә һәм имамнарга исламның кайбер нигезләмәләре, Коръән укуда һәм җәй көне намазда килеп чыккан бәхәсле мизгелләргә аңлатма табарга да вакыт таба.

Ибн Фадлан үзенең китабында Болгар ханы белән үзенең арасында килеп чыккан бер сөйләшү турында яза. Эш шунда ки, мөәдзин мәчет манарасыннан намазга чакырып әйтелә торган сүзләрне, икамәтне (камәтне), Багдад шәфиитләре кебек бер мәртәбә генә түгел, Урта Азиядә кабул ителгән хәнәфиләр мәзһәбе таләпләренә туры китереп, ике мәртәбә әйтә. Бәхәсләр булып ала, әмма сорау җавапсыз кала. Дөресрәге, болгарлар икамәтне үзләренчә әйтүдән баш тартмыйлар.

Җәйге сезонда намазларның саны турындагы мәсьәлә дә хәл ителмәгән килеш кала, бу исә, Болгар мөселманнары фикеренчә, соңгы төнге һәм иртәнге намазларны берләштерергә мөмкинлек бирә. Шунысы кызык, болгарлар һәм аларның нәселләре, Идел буе татарлары, озак вакытлар намазны көнгә дүрт тапкыр гына укыганнар. Биш тапкыр намазларның мәҗбүрилеге XVIII гасырда гына торгызыла.

* * *

Багдад илчелегенең Болгар иленә килүләренә бер ай чамасы вакыт үтеп тә киткән. Җәгъфәр ибн-Абдаллаһның Багдад хәлифәсенә язылган һәм хәлифә тарафыннан ярдәм итәргә вәгъдә бирелгән тагын бер бик мөһим мәсьәләне хәл итәсе кала. Ул да булса, Болгар илен яһүдиләрдән, ягъни Хазар патшасыннан саклау өчен хәрби ныгытма – крепость һәм мәчет төзү белән бәйле эшләр. Билгеле булганча, бу вакытта болгарлар Хазар каганлыгының вассаллары булып торганнар. Җәгъфәр ибн-Абдаллаһның улы Итилдә тоткынлыкта газап чигә, әле сөекле кызын да, җария итеп, хәрәмдәге хатыннар янына алып китмәкчеләр. Шуңа күрә, Болгар патшасының хазарладан бәйсезлеккә омтылуын аңларга була.

Кальга (крепость) төзү мәсьәләсен Багдад илчеләре белән очрашуда Болгар ханы үзе күтәрә. Эш шунда ки, Багдад хәлифәсе үзенең хатында Болгар илендә ныгытылган кала төзү өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан мөмкин дип саналган чыганаклардан алып, дүрт мең динар акча вәгъдә иткән була. Ибн Фадланга кагылмаган төрле сәбәпләр аркасында бу акча Болгарга килеп җитми. Җәгъфәр хан Ибн Фадланның аклануларын тыңларга да теләми: табыгыз акчаны – бетте-китте. Ахыр чиктә Багдад илчесе сорый Болгар патшасыннан:

«Синең дәүләтең бик зур, акчаларың күп, керемең күпсанлы, ә син ни өчен хәлифәдән киләчәк аз гына акчага ныгытма төзеп бирсен дип

үтендең?» Җәгъфәр ибн-Абдаллаһың җавабы бик төпле:

«Ул акчалар дини кануннар тарафыннан рөхсәт ителгән чыганаклардан алыналар дип санадым. Һәм чыннан да, әгәр дә мин үземнең акчаларга, көмешләргә яки алтыннарга ныгытма төзәргә теләгән булсам, минем өчен моңарда бернинди авырлык булмас иде».

Һәм Болгар ханы Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ Җаушир[3] дип аталган елга янына кузгалып китә. Бирелә ул ике ай чамасы була. Җауширгә киткәнче хан барлык кабилә башлыкларына хәбәр җибәрә. Алар үзләренә буйсынган халыкның бер өлешен (ир затларын) алып, килеп тә җитәләр. Арада суар (суаз) дип аталучы кабилә юлбашчысы гына күренми. Алар, ихтимал, Җауширгә барудан баш тартканнар. Болгар патшасы аларга тагын бер чакыру җибәрә һәм кисәтә: «Кодрәтле һәм бөек Аллаһ миңа Ислам динен һәм мөселманнар хөкемдарының хакимлеге дәрәҗәсен бүләк итте. Һәм мин – аның колы, бу эшне ул (Аллаһ) миңа үзе йөкләде... Һәм кем дә кем миңа каршылык күрсәтә, мин аны кылыч белән каршы алачакмын». Бу кисәтүдән соң суар халкы тиз арада Болгар ханына кушыла.

922 елның җәендә Җаушир елгасы янында нинди вакыйга булган соң? Бу турыда Ибн Фадлан язмаларында бер сүз дә әйтелмәгән (хәер, ул язмалар безгә тулысы белән килеп тә җитмәгән ич). Галимнәргә тагын фаразларга гына кала.

Аларның фикеренчә, Җаушир елгасы буенда Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ белән килгән болгар төзүчеләре һәм Багдад илчелеге составына кергән шәһәр төзү осталары, бүген кулланыла торган сүз белән әйткәндә, архитекторлар, Биләр каласына нигез салалар. Эшне хәрби ныгытмалар һәм булачак шәһәр үзәгендә мәчет төзүдән башлыйлар. Ягъни мәсәлән, Болгар ханының Багдад хәлифәсенә язган үтенечен тормышка ашыра башлыйлар.

Исегезгә төшерәбез, Багдад илчелеге составында башта берничә мең кеше була. Алар арасында ислам дине белгечләре һәм хәрби ныгытмалар, шәһәр-крепостьлар төзү буенча тәҗрибәле осталар булгандыр дип уйларга кирәк. Илчелекнең бер өлеше, бәлки әле күпчелегедер дә, юл авырлыкларыннан куркып, кире кайтып китә. Ә Болгарга килеп җиткәннәре арасында, һичшиксез, шәһәр ныгытмалары һәм мәчетләр төзү осталары булгандыр. Бу турыда Ш. Мәрҗани да шулай яза, күренекле тарихчыларыбыз да каршы фикер әйтмиләр.

Биләрнең планына күз салыгыз. Ул бер-берсенә кереп утырган ике өлештән – бер үк вакыт аралыгында барлыкка килгән эчке һәм тышкы шәһәрләрдән тора. Урыны-урыны белән икешәр рәтле калын диварлар – туфрак өеп ясалган биек үрләр, шул үрләргә куелган агач буралар һәм

[3] Хәзер бу елганы Кече Чирмешән дип йөртәләр.

башнялар белән ныгытылган эчке шәһәрнең мәйданы 130 гектар чамасы. Өч рәт диварлар белән уратып алынган тышкы шәһәр исә 490 гектар җирне биләп тора. Крепость диварларының гомуми озынлыгы 40 километр чамасы. Шунысы кызык, Биләр үзенең планировкасы белән урта гасырлар Багдадына охшаган. Багдад та бит хәлифә резиденциясе урнашкан эчке һәм сәүдә-һөнәрчелек бистәләрен берләштергән тышкы шәһәрдән гыйбәрәт булган. Күрәсең, Биләргә нигез салуда катнашкан Багдад белгечләре, интуитив рәвештә булса да, үзләренең шәһәр образын күз алдында тотканнар.

Биләрнең эчке шәһәрендә, аның үзәгендә диярлек, XVIII–XIX йөз сәяхәтчеләре һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләре борынгы мәчет урынын табып алалар. 1970 елларда Казан археологлары шул мәчет хәрабәләрен казып чыгардылар. Бик ачык күренеп тора: X гасырның беренче яртысында ул ике өлештән торган. Борынгысы, 1400 квадрат метр мәйданда агач бүрәнәләрдән салынган өлеше, профессор А. Халиков фаразлавынча, IX гасырда ук корылмаган микән? 922 елда аның ак таштан салынган өлешен торгызганнар булса кирәк. Ул 1076 квадрат метр мәйданны били. Таш мәчетнең эчендә алты рәт колонналар тезелгән (һәр рәттә дүртәр колонна). Көньяк-көнчыгыш дивары ярымколонналар – пилястрлар белән ныгытылган.

Бу – Идел Болгары дәүләтендә археологлар тарафыннан өйрәнелгән иң борынгы мәчет һәм ул, турыдан туры булмаса да, Биләрнең беркайчан да гади шәһәрләр рәтендә йөрмәвенә ишарәли. Белгечләрнең раславынча, ул заманнарда Җәмигъ мәчете – вәгазь сөйләү һәм ил хакиме (хан/әмир) исемен кушып хөтбә уку өчен имам-хатибка дип махсус ясалган мөнбәре белән – бары тик дәүләтнең административ үзәгендә генә булган.

Шушы мәчет янында ук 1971–1972 елларда кирпечтән салынган зур гына бина хәрабәләре тикшерелде. Биредә үзенең гаиләсе белән югары дәрәҗәле берәр дин әһеле яшәгәндер дип уйланыла иде. Бүген исә аның функциясен мунча яисә тәһарәтханә белән бәйләп аңлаталар. Бу фикер идән астында урнашкан җылыту системасы каналлары, сүүткәргеч торба ватыклары кебек табылдыклар белән раслана. Архитекторлар исә Биләр биналары төзелешендә Якын Көнчыгыш һәм Урта Азия архитектурасы элементларын табалар.

Тагын бер кызыклы факт: мәчет тирәсендә гади кешеләр яши торган агач йортлар, хуҗалык корылмалары, ашлык саклау амбарлары урнашкан. Арада безнең якларга бөтенләй дә хас булмаган торак йортлар да бар. Аларның стенасы, талчыбыктан үрелеп, ике яктан калын итеп кызыл балчык белән сыланган. Өй эчендә, ишегалдында тандыр тибындагы мичләр тора. Баш ватып та торасы юк: биредә, һичшиксез, Урта Азия якларыннан, Шәрык илләреннән килгән кешеләр яшәгән. Ирексездән, «Багдад илчелеге белән килгән төзүчеләр түгел микән?» дигән уйлар туа.

Тарих фәнендә урын алган төрле фикерләргә карамастан, Багдад илчелеге алдында торган бурычлар тулысы белән диярлек тормышка ашырыла дип әйтәсе килә. Һәм Әхмәд ибн Фадлан, кире Багдадка әйләнеп кайткач, бу турыда хәлифәнең үзенә хисап тота. Аның кыйммәтле язмалары бүгенге көндә Мәшхәд шәһәренең (Иран) бер архивында саклана.

**Ислам дөньясында иң төньяк ил.** Шулай итеп, Урта гасыр мөселман цивилизациясе дәүләтләре чылбырындагы буыннарның берсе сыйфатында Хәлифәт тарафыннан рәсми рәвештә танылган Идел Болгарын атый башлыйлар. Хәер, аның икенче исеме дә бар – «Караңгылык диңгезе янындагы ил» («страна у Моря Мрака»). Әйе, Болгар иле Евразия кыйтгасының көньяк поясын биләп торган мөселман дөньясындагы башка илләрдән бик еракта урнашкан. Бу исем шуңа ишарәли.

Идел Болгары зур дәүләт булган һәм хәзерге вакытта аларның нәсел дәвамчылары – Идел-Урал татарлары яши торган җирләрне биләп торган. Болгарларның археология истәлекләре (һәйкәлләре) нигездә Татарстан территориясендә, күрше Чуашстанның көньяк-көнчыгыш районнарында, Ульян, Самара, Пенза өлкәләрендә табылган. Аерым һәйкәлләр, шул исәптән, шактый зур шәһәрлекләр, Әстерхан өлкәсендә, Мордва һәм Башкортостан республикаларында, Пермь краенда билгеле.

Х гасырда бу җирләрдә «әс-сәкалибә» – «төньяк халыклары», ягъни болгарлар, барсиллар (берсула), эсегеллар, суарлар (савирлар), биләрлар һәм бәрәнҗәлар яшәгән, дип яза Ибн Фадлан. Гарәп тарихчылары исә: «Бу кабиләләр еш кына үзара сугышып торганнар, ә инде читтән берәр дошман килеп чыкса, берләшеп каршы торганнар», – дигән хәбәрләр калдырган. Х йөз ахырында бердәм болгар халкы оеша, элеккеге кабилә исемнәре онытыла. Әйе, яңа дин, этносәяси процессларда үзенең берләштерүче ролен күрсәтеп, хакимият тирәсенә болгарлар исеме белән атала башлаган төрле кавемнәрне туплый.

Болгар халкы, башлыча авылларда яшәп, игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән. Гарәп географы Ибн Рөстә: *«Болгарлар – нигездә игенчелек белән көн күрүче халык, бодай, арпа, тары һ.б. төрле ашлык иккәннәр»*, – дип язган. Халык икмәккә кытлык кичермәгән, моннан тыш, ашлык экспортның иң мөһим маддәләренең берсе булган.

Шәһәрләрдә һөнәрчелек үсә. Әйдәп баручы тармаклар – кара металлургия һәм металл эшкәртү – теләсә кайсы җәмгыятьнең икътисади көче, нигезе. Тимерчелек эшендә билгеле бер хезмәт бүленеше булган, ягъни мәсәлән, бер остаханәдә авыл хуҗалыгы кораллары җитештергәннәр, икенчеләрендә коралчылар эшләгән, өченчеләре көндәлек тормышта кирәкле көнкүреш әйберләре ясау белән мәшгуль булган. Төсле металл эшкәртү буенча һөнәрчеләр продукциясе халык арасында аеруча зур ихтыяҗга ия була. Зәркәнчелек югары дәрәҗәгә ирешә. Зәркәнчеләр

кыйммәтле металл эшкәртүнең катлаулы алымнарын белгәннәр. Алар, мәсәлән, хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре ясаганда бик нечкә алтын-көмеш җепләрдән үреп ясау (филигрань, скань) һәм бөртекләү (зернь) техникасын еш кулланганнар. Зәркәнчелек һөнәренең искиткеч үрнәге булып алтын боҗра эченә үрдәк сыны урнаштырылган һәм шул боҗрага нечкә чылбыр белән имән чикләвеге рәвешендәге өч төймә ялганган чигә алкалары санала.

Болгар чүлмәкчеләренең уңышларын шәһәр һәм авыл җирлекләрендә археологлар тарафыннан ачылган югары җитештерүчәнле савыт-саба яндыру мичләре генә түгел, ә Көнчыгыш Европаның барлык төбәкләрендә бу савыт-сабаларның киң таралу факты да күрсәтә. Рус кенәзлекләрендәге шәһәрләрнең барысында да диярлек археологик казылмалардан яхшы сыйфатлы болгар керамикасы килеп чыга.

Болгар шәһәрләрендә пыяла әйберләр җитештерү XI гасырда башлана. Биләрдә уникаль һөнәрчелек комплексы – пыяла савытлар ясау остаханәсе ачылды. Әлеге һөнәрчелекнең элитар, бары тик эре шәһәрләрдәге җитештерү үзәкләрендә генә барлыкка килү мөмкинлеген ассызыклап үтәргә кирәк. Бу төр җитештерүне үзләштерү факты, тулаем алганда, ил икътисады үсешенең гомуми югары дәрәҗәсен дә ачык күрсәтеп тора.

Болгар шәһәрләрендә шулай ук күнчелек һөнәре дә үсеш ала. Көнчыгыш һәм Көнбатышның күп кенә илләрендә «болгари» дип аталган югары сортлы тире эшләнмәләре бик югары бәяләнгән.

Урта гасыр сәяхәтчеләре Идел Болгарстанын «шәһәрләр иле» дип атаганнар. Шул ук вакытта Болгар дәүләтенең «сәүдәгәрләр иле» дигән даны да булган.

Сүз дә юк, Болгар икътисадының нигезен авыл хуҗалыгы (игенчелеек, терлекчелек) һәм һөнәрчелек тәшкил иткән. Әммә хуҗалыкның әлеге тармакларында җитештерелгән продукция беренче чиратта халыкның үз ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә киткән, ягъни товар эчке базарга чыгарылган. Бер яктан, шәһәр белән авыл, икенче яктан, илнең төрле төбәкләре арасында җанлы сәүдә барган. Ә дәүләт казнасы эчке сәүдә түгел, башлыча тышкы сәүдә хисабына баеган.

Моның чыннан да шулай икәнен раслау өчен язма чыганакларга мөрәҗәгать итик. Игътибарыгызны бер нәрсәгә юнәлтәсе килә: безнең көннәргә кадәр килеп җиткән язма чыганакларның барысы да чит ил укымышлылары тарафыннан язылган. Чит ил кешеләре ни өчен Болгар белән кызыксынганнар икән, дисезме? Болгар – сәүдә иле булганга. Элек тә, хәзер дә шулай – һәр дәүләт үзендә җитештерелгән товарларның бер өлешен чит илгә чыгарып, кыйммәтрәк бәягә сатарга тырышкан. Дөнья базарына чыгу өчен конкуренция шул заманнарда ук булган. Идел Болгары (Идел Болгарстаны) исемле яңа дәүләт барлыкка килгәч, бирегә дөньяның төрле почмакларыннан, бигрәк тә Шәрык илләреннән, сәүдә-

гәрләр агыла башлый. Географларның энциклопедик язмаларында Болгар һәм аның халкы турында белешмәләр бирелә. Алай гына да түгел, Болгарны дөнья карталарында күрсәтәләр. Бу җәһәттән гарәп географы әл-Идрисинең Болгар – Киев сүдә юлының картасы урнаштырылган 1154 елгы «Сәяхәткә сусаганнарга күңел ачу» исемле хезмәтен искә төшереп үтәргә була.

Идел Болгары геополитик яктан искиткеч уңай урында – Бөек Ефәк юлының төньяк тармагы булган Балтыйк – Идел юлы белән Чулман мех юлы кисешкән төбәктә калкып чыга. Болгар ханнары аның шушы геополитик өстенлегеннән бик оста файдаланалар: Идел буйлап кыйммәтле товарлар төяп килгән Шәрык сүдәгәрләрен Болгарда туктаталар, тагын да төньяккарак җибәрмиләр; төньяктан, ягъни Новгород, Ладога якларыннан һәм Балтыйк, Скандинавия илләреннән килгән сәүдә корабларына исә Болгардан түбәнгә йөзәргә рөхсәт итмиләр. Шулай итеп, чит ил сәүдәгәрләре бер-берсе белән Болгар җирендә очрашырга мәҗбүр ителәләр. Ризасызлык күрсәтүче булмагандыр, чөнки тыныч һәм ике як өчен дә файдалы сәүдә өчен бередә бөтен шартлар тудырылган була.

Багдад илчелеге сәркәтибе Әхмәд ибн-Фадлан язмаларына караганда, сәүдә корабларын болгар ханы шәхсән үзе каршы ала торган була. Һәр товарның уннан бер өлешен ул, сәүдә практикасында кабул ителгән таможня кагыйдәләре буенча, дәүләт казнасына озатып барган. Аңлашыла ки, чит ил сәүдәгәрләреннән тотып калына торган әлеге таможняналогының гомуми күләме сәүдәгәрләр саныннан һәм төяп килгән товарлар күләменнән бәйле булган. Шул заман кешеләре, дәүләт казнасында тупланган байлыкның төп өлешен сәүдәдән кергән дисәтинә тәшкил итә, дип язганнар икән, димәк, Идел Болгарының Биләр, Суар, Җүкәтау ише эре шәһәрләрендә җәен-көзен үткәрелә торган ярминкәләрнең ил тормышындагы роле зур булгандыр, дип уйларга кирәк.

Болгар ярминкәләре дигәннән. Күренекле археолог һәм тарихчы академик Валентин Янин, нумизматика материалларына таянып: «Болгар VIII–IX гасырлардан ук Рус дәүләтенең сәүдә дөньясындагы көнчыгыш капкасы ролен үти башлый», – дип язган иде. Ягъни мәсәлән, русларга Шәрык илләреннән килгән товарлар Болгар аша үтеп кергән булып чыга. Бу фикер белән килешмичә булмый, әлбәттә, чөнки ул археология материаллары белән дә раслана.

Шул заман язучылары Ибн Рөстә, әл-Балхи, әл-Истахри, әл-Мәсгуди, әл-Мөкаддәси Болгардан Харәземгә һәм башка Шәрык илләренә чыгарыла торган товарларны санап китәләр. Бу исемлектә кыйммәтле җәнлек (кеш, тиен, сусар, ас, кызыл һәм кара төлке) һәм йорт хайваннары (кәҗә, сарык) тиреләре, яхшы сыйфатлы күн («болгари»), күннән һәм мехтан тегелгән әйберләр (бүрек, тун, кафтан, аяк киемнәре), бал, балавыз, урман чикләвеге, эре елга балыгы, каен агачы, ук очлары, кылыч, көбә

күлмәк (кольчуга), сарык, эре мөгезле хайваннар, славян коллары ише товарлар бар.

Шул ук вакытта болгар шәһәрләрендә башлыча Русьтан һәм Шәрык илләреннән, Кавказдан килгән әйберләр очрый. Урта Азия якларыннан Болгарга ефәк тукыма, фарфор, фаянс, пыяла савыт-саба, ювелир сәнгатендә кулланыла торган асылташлар, кипкән җимеш, тәмләткечләр ише төрле экзотик товарлар гына түгел, кәгазь, дини һәм дөньяви эчтәлекле китаплар да килгән. Кыскасы, сәүдә гөрләп торган.

Болгарда гына түгел, барлык Европа һәм Азия шәһәрләрендә дә иң эре базарлар гадәттә шәһәр үзәгендә, мөселман илләрендә – мәчет, христиан илләрендә чиркәү тирәсендәге мәйданда, ягъни халык күп йөри торган җирдә урнашкан була.

Хәзер Болгарда алып барыла торган археологик казу эшләренә күчик. Болгарның атаклы Җәмигъ мәчетен барыбыз да беләбез. Әнә шул мәчеттән 100–150 метр чамасы төньяк-көнбатыш тарафка китеп, элегрәк вакытларда (1970 нче елларга кадәр) XIV гасырга караган бакыр, көмеш акчалар юлдан барганда да күпләп табыла торган бер урында, 2011 елда археологлар эшли башлады (биредә инде элегрәк тә бераз казып караганнар иде). Ул эшләр әле һаман дәвам итә, җәй көне Болгарга килсәгез, безнең табышлар белән үзегез дә таныша, табылдыкларны кулга тотып карый аласыз.

Бу урында иңе-буе 32–34 метрлар чамасы, ягъни мәйданы Җәмигъ мәчетнеке кадәр булган монументаль кирпеч бина хәрабәләре ачылды. Аның таш нигезе өчен тирәнлеге 1 метрга, киңлеге 1,2 метрга җитә торган чокыр – траншея казылган. Таш нигезгә калынлыгы дүрт кирпечтән торган стена өелгән. Стена эчендәге мәйдан яндырылмаган кирпеч, ә кайбер урыннарда агач (бүрәнә) стена белән аерым бүлмәләргә бүленгән. Тәрәзәләре тимер рәшәткәләр белән ныгытылган. Бүлмәләр арасында киңлеге 4 метр чамасы булган коридор. Бүлмәләрнең һәм коридорның идәннәре тактадан. Бинага төп керү урыны төньяк-көнчыгыш яктан булгандыр, күрәсең. Киңлеге 12 метрга җитә торган һәм ике яктан биек булмаган кирпеч койма белән чикләнгән киң урам туп-туры әлеге бина ишегенә алып килә – коридор урамның дәвамы булып тора. Ишек янында йозак һәм тимер эшермә – аркылы бик табылды.

Болгар шәһәрләрендә мондый уникаль архитектура корылмалары әлегә кадәр тикшерелмәгән иде әле. Шулай да бинаның нинди максатларда төзелүен, хезмәт итүен аңлау әлләни авыр булмады. Бу бинада, һичшиксез, шәһәр базары урнашкан булган һәм анда чагыштырмача кыйммәтле әйберләр – Кытай һәм Һиндстаннан китерелгән ефәк тукымалар, аш тәмләткечләр, савыт-сабалар, хатын-кыз бизәнү әйберләре сатылган.

Табылдыклар арасында үлчәү детальләре, биш дистәдән артык тимер, бронза һәм бакыр фольгага төрелгән кургаш герләр бар. Иң кызыклы табылдыклар – Германия, Бельгия, Гол-

ландия, Фландрия кебек Көнбатыш Европа илләреннән китерелгән үлчәү герләре һәм кургаш пломбалар. Әлеге пломбаларны чит ил сәүдәгәрләре кыйммәтле тукыма төргәкләренә беркетеп кую өчен кулланганнар. Инде күптән котелгән табылдыклардан X гасырда сугылган болгар акчаларын атап китәргә кирәктер, моңарчы әле аларның археологик казылмаларда табылган юк иде.

Болгар үзенең топографиясе, планировкасы, бигрәк тә архитектурасы ягыннан караганда, – чын Шәрык шәһәре. Шуңа күрә аның төп базары да мөселман илләрендә таралган базарларга охшаш. Мондый базарлар Стамбулда, Сәмәркандта, Бохарада хәзер дә гасырлар буена сыналган борынгы традиция нигезендә төзеләләр.

Димәк, тиздән Болгар дәүләт тарих һәм архитектура музей-тыюлыгында туристларга күрсәтү өчен тагын бер уникаль объект пәйда булачак.

* * *

Идел Болгары әле Җәгъфәр хан вакытында ук үзенең күршеләре – Идел-Урал һәм төньяктарак урнашкан өлкә халыклары белән тыгыз икътисади-мәдәни бәйләнешләр урнаштыра. Шул ук вакытта Киев Русе һәм борынгы Русь кенәзлекләре, Хазар каганаты, Урта Азия һәм башка Шәрык илләре дә болгар ханнарының тышкы сәясәтендә мөһим урын алып торалар.

Идел Болгарының Шәрык илләре белән бәйләнешләре турында сөйләгәндә XII гасырда яшәгән фарсы тарихчысы Әбү-л Хәсән Бәйхакиның бер оригиналь хәбәрен искә төшереп үтәргә кирәктер. Ул болгар әмире Әбү Исхак Ибраһим ибн-Мөхәммәднең Хөрәсән патшасына Сәбзевар һәм Хөсрәүҗард шәһәрләрендә мәчет төзү өчен акча һәм бүләкләр җибәрүе турында яза.

Әлбәттә, язма чыганакларның ярлылыгы Идел Болгары белән Шәрык илләре арасындагы мөнәсәбәтләр эпизодик характерда гына булган икән, дип уйларга нигез бирми. Болгар бабаларыбызның мәдәни һәм матди тормышында югары үскән Шәрык мәдәниятенең тәэсире нык сизелә.

* * *

Шәһәр һәм шәһәр мәдәнияте – мөселман цивилизациясенең мөһим өлеше. VII–VIII гасырларда кәрван, елга һәм диңгез сәүдәсенең чәчәк атуы үзенчәлекле архитектурасы, базар мәйданнары, кәрван-сарайлары, мунчалары һәм башка иҗтимагый корылмалары булган шәһәрләрнең нәкъ менә эре сәүдә юлларында барлыкка килүе белән үрелеп барган. Якын Көнчыгыш һәм Урта Азия илләре (аерым алганда, Харәзем) башка өлкәләрдән һәрвакыт югары үскән шәһәр архитектурасы, төзелеш мәдәнияте белән аерылып торган. Чакырылган төзүчеләр һәм архитекторлар эшчәнлеге аша бу культура Идел Болгарына да үтеп керә. Моңа Биләр, Суар, Алабуга, Муром (Мөрән?) һәм эреле-ваклы башка болгар шәһәрләрендә ачылган мәчет һәм җәмәгать мунчалары калдыклары дәлил.

*Болгар шәһәре* дәүләт тормышында аерым урын алып торган. Берен-

че чиратта, әлбәттә, шул заманның иң алдынгы илләре белән халыкара сәүдәдә уйнаган роле аркасында. Алай гына түгел. Багдад илчелеге шәһри Болгарны Ислам дөньясының иң ерактагы Төньяк иле дип рәсми рәвештә игълан иткәннән соң, ул халыкара танылу ала һәм Идел-Урал мөселманнарының рухи үзәге статусына ия була.

Болгар – Россиянең Идел-Урал төбәгендәге иң борынгы шәһәрләреннән санала. Аның урнашу урыны – Кама тамагыннан 30 км көньякта һәм Иделдән 6 километр ераклыкта – борынгы таш гасыры кешеләре тарафыннан, ягъни моннан 8–10 мең еллар чамасы элек үзләштерелә башлый. Шәһәр территориясендә антик чорга караган тәңкәләр дә бар, ләкин беренче ныгытылган торулыкларның барлыкка килүе Имәнкискә археологик культурасы яшәгән чорга карый (IV–VII гасырлар). Серле имәнкискәлеләр Урта Иделгә көньяктан болгарлар, көнчыгыштан протовенгрлар төркеме килеп чыккач, бу җирләрне ташлап киткән. Болгарлар ул вакытта әле – күчмәннәр, ләкин утрак тормышка күчү стадиясендә булганнар.

Болгарларның IX гасыр ахыры дирһәмнәре табылган иң борынгы торулыклары – ул хәзерге Кече Иерусалим чокыры тирәсендә барлыкка килгән – артык зур мәйданны биләп тормаган. Ибн Фадлан, югарыда искәртеп үтелгәнчә,үзенең язмаларында Болгар дип аталган шәһәрне бер тапкыр да искә алмый. Күрәсең, дөньядагы иң зур шәһәрләренең берсе – Багдадтан чыккан кешегә яңа гына барлыкка килә башлаган шәһәр нык тәэсир итмәгәндер. Әмма соңгы елларда үткәрелгән археологик казу эшләре Болгарның инде X гасыр урталарыннан ук чын шәһәр булуын раслый. Яңа материаллар шәһәр халкының башлыча һөнәрчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнүләре турында сөйли: казылмалардан кара металлургия һәм тимерчелек эше, чүлмәк һәм күн җитештерү белән бәйле табылдыклар, гарәп дирһәмнәре килеп чыкты.

X гасыр башында тупланган культура катламында сакланып калган көмеш тәңкәләр һәм шул тәңкәләрне сукканда кулланыла торган инструментлар Болгарның ил сәүдәсендә тоткан әһәмиятен тагын бер кат күрсәтә. Бу уңайдан академик В.Л. Янинның ярты гасыр элек әйткән, һәм бүген дә гадел, дөрес яңгыраган сүзләре искә төшә: «VIII гасыр азагыннан алып XI гасыр башына кадәр Идел Болгары Русь белән Көнчыгыш сәүдәсендә бердәнбер капка ролен башкарып килгән».

Ярминкәләр сезонында Көнчыгышның төрле илләреннән күпсанлы мөселман сәүдәгәрләре җыелган шәһәрдә, әлбәттә, аның үз мәчете дә булгандыр. Бу хакта, аерым алганда, Ибн Фадланның без югарыда телгә алган азан алдыннан әйтелә торган икамәтне ике тапкыр кабатларга ярамавы турында кисәтүе дә сөйли. Кызганычка каршы, әлеге мәчетнең эзләре табылмаган, хәер, ул эзләрне саклаган борынгы катламнар соңгы еллардагы төзелеш эшләре вакытын-

да юкка чыккандыр. Борынгы мәчетнең Алтын Урда чорындагы Җәмигъ мәчете урынында торуы да ихтимал.

*Биләр* – Идел Болгарының иң зур шәһәре. Аның рус елъязмаларында теркәлеп калган атамасы – Олуг шәһәр (Великий город). Олуг шәһәргә нисбәтле хәбәрләр шул рус елъязмаларында сакланып калган.

Соңгы мәртәбә Олуг шәһәр урыс елъязмаларында 1236 елгы канлы вакыйгалар уңаеннан телгә алына.

Биләр археологик экспедициясе тарафыннан шәһәрлектә архитектура истәлекләре ачылды, әллә никадәр йорт һәм хуҗалык корылмалары, яхшы гына сакланган коелар, төрле һөнәр ияләренең остаханәләре, саклану ныгытмалары казып тикшерелде.

Эчке шәһәрдә тикшерелгән гади генә агач йортлар арасында иң кызыклысы – XII гасыр ахырларына караган һөнәрче остаханәсе. Биредә патша һәм бай түрәләр заказы белән кыйммәтле бизәнү әйберләре ясаучы бер оста яшәгән. Бу йорт урынын казыган вакытта гәрәбә кисәкләре, алтын-көмештән, сөяктән һәм гәрәбәдән ясалган бизәнү әйберләре, пыяла савыт ватыклары, үлчәү тәлинкәләре һәм герләре табылды. Табылдыкларга караганда, биредә яшәгән һөнәрче килеп чыгышы буенча болгар түгел, ә урыс кешесе булган.

Тышкы шәһәрдә башлыча уртакул һәм ярлы һөнәрчеләр, вак сәүдәгәрләр, әле җирдән-авылдан аерылып җитмәгән кичәге игенчеләр, терлекчеләр көн күргән. Чүлмәкчелернең остаханәләре, савыт-саба яндыру мичләре урнашкан бистә 3 гектарга якын җирне биләп торган! Казу эшләре вакытында табып тикшерелгән ике катлы чүлмәк яндыру мичләре үзләренең камильлеге белән аерылып торалар.

Тышкы шәһәрдән эчке шәһәргә үтә торган Көнчыгыш капкасы тирәсендә шартлы рәвештә «кәрван-сарай» дип аталган зур гына кирпеч бина калдыклары сакланган. Гомуми мәйданы 240 квадрат метр чамасы (16×15 м). Бүлмәләре идән астындагы каналлар буйлап килүче кайнар һава белән җылытылган. Бина X гасыр ахырында төзелгән. Әле күптән түгел генә, биредә чит иллләрдән сату-алу эшләре белән килгән сәүдәгәрләр өчен кунакханә урнашкан, дип фаразлана иде. Чынлыкта исә бу бина кәрван-сарай комплексына караган мунча булган.

Биләрдә, 1973 елгы аэрофото материалларына таянып, 30 дан артык кирпеч бина урыны ачыкланган. Аларның әле өчесе генә тикшерелгән. Казу эшләре дәвам итә.

*Сувар (Суар)* Болгар иленең иң атаклы тарихи һәйкәлләре исемлегендә урын алган, шуңа күрә аны еш кына шәһри Болгар белән янәшә куеп телгә алалар. Ул хәзерге Спас районының Кузнечиха авылыннан дүрт чакрым ераклыкта урнашкан. Хәрабәләре 4,5 чакрым озынлыктагы балчык үрләрдән һәм тирән чокырлардан торган ныгытмалар белән уратып алынган турыпочмаклы шәһәрлектән гыйбәрәт. Борынгы кала 90 гектар мәйданны биләгән. Баштан ук ул суар-савир исемле эре кабилә берләшмәсенең – Суар билегенең

(әмирлегенең) үзәге, башкаласы сыйфатында төзелә. Шуңа күрә дә биредә Шәрык илләреннән килгән сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр еш булганнар. Суарны алар үзләренең язмаларында телгә алар. Мәсәлән, гарәп географы әл-Балхи хезмәтендә (аның хәбәрләре X гасыр географы әл-Истахри язмаларына сакланып калган), Суар – зур шәһәр, аның үзәк мәйданында Җәмигъ мәчет урнашкан, халык саны 10 меңгә җитә, дигән хәбәр бар. Моңа охшаш юлларны әл-Җәйхани язмаларыннан да табарга мөмкин.

Шунысы гаҗәп: Болгар иленә 1135 елда ерак Андалузиядән (Испаниядән) килеп, озак кына торып киткән Әбү Хәмид әл-Гарнати үзенең китабында нишләптер Суарны телгә дә алмый. Урыс елъязмаларында да аның турында бер кәлимә сүз юк.

Суар билегенең X йөздәге сәяси тормышын өйрәнүдә нумизматика материаллары да мөһим роль уйный. Галимнәр болгар акчалары арасыннан Суар әмирләре Талиб ибн-Әхмәд һәм Мөэмин ибн-Әхмәд тарафыннан 948–976 елларда сугылган көмеш тәңкәләрне аерып алдылар. Нумизматика материаллары күрсәткәнчә, Суар X йөз ахырына кадәр мөстәкыйль, ягъни Болгарга буйсынмыйча яшәүче суверен билек (әмирлек) булган.

Суарда иң беренче һәм иң күләмле казу эшләрен Мәскәү археологы атаклы болгарчы-галим Алексей Петрович Смирнов 1933–1937 елларда үткәрә. Башта ул шәһәр ныгытмаларын казый. Ул ныгытмалар биек үрләр өстендә 4×5 метр үлчәмдәге бураларны бер-берсенә ялгап төзелгән стеналар рәвешендә булган икән. Араларын 100–120 метр калдырып, биек башнялар корылган. Бу ныгытмаларның буеннан буена, тышкы яктан, тирәнлеге 5 метрга җитә торган чокыр казылып, төбенә очлы казыклар кагып куелган.

А.П. Смирнов тикшергән корылмаларның иң кызыклысы – X гасыр ахырында ук салынган кирпеч бина калдыклары. Гомуми мәйданы 96 квадрат метр. Үзәкләштерелгән ягу системасы – идән астыннан үтә торган төтен юллары сакланып калган. Галим бинаның борынгы «кыяфәтен» күз алдына китереп, аның якынча реконструкциясен дә ясап куя: артык зур булмаган тәрәзәләр, як-яктан ярымколонналар куелган арка тибындагы киң һәм биек ишек. Ишегалды кирпеч белән түшәлгән. Галим әлеге бинада Суар әмире торгандыр, дип фаразлый.

Суар шәһәрлегенә археологлар 1970 һәм 1990 нчы елларда да бераз эшләп алалар. Әмма болгарларның бу шәһәре әлегә кадәр үзенең серләрен ачарга җыенмый әле.

*Ошель (Ашлы)* – Иделнең уң як ярында урнашкан Болгар шәһәре. Хәзерге вакытта аның археологик калдыклары Татарстанның Тәтеш районы Богдашкино авылыннан төньякта урнашкан 77 га мәйданлы шәһәрлек урынында дип фаразлана. Ошель рус елъязмаларында, Владимир-Суздаль кенәзенең Идел болгарларына 1220 елда чапкан яуларына бәйле рәвештә дип беренче һәм соңгы тапкыр телгә

алына. Бу яу вакытында Ашлыны бик каты талыйлар, яндыралар һәи җимерәләр. Шәһәр яңадан торгызылмый.

Аның калдыклары археологик яктан өйрәнелмәгән диярлек. Ул үзенең тикшерүчеләрен көтә.

*Мөрән шәһәрлеге* – Биләрдән соң болгар тарихының монголларга кадәрге чорына караган иң зур археология һәйкәле. Ул Самара өлкәседә, Болгар дәүләтнең көньяк чигендә урнашкан. Шәһәрнең мәйданы 400 гектардан артыграк. Тарихи исеме билгеле түгел. Фәндә кабул ителгән исеме – Муромский городок. Асыл исеме Мөрән булмадымы икән? дип уйлаучылар бар (А.Х. Халиков), әмма тәгаенләп әйтүе кыен. Археологик казу эшләре вакытында дүрт кирпеч бинаның хәрабәләре, гади шәһәр кешеләренең торак йортлары, җитештерү корылмалары (һөнәрчелек остаханәләре), шул исәптән, берничә бакыр эретү һәм чүлмәк яндыру мичләре, тимерче алачыклары тикшерелде. Муром шәһәрлеге – бай шәһәр, болгарларның хәзерге Самара төбәгендә яшәгән зур гына бер төркеме өчен административ үзәк булып хезмәт иткән. Монгол-татарлар явы вакытында яндырыла һәм яңадан торгызылмый.

Идел Болгарының шактый зур шәһәрләре исемлегенә шулай ук X–XI гасыр чигендә, дәүләтнең төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләрендәге форпостлар, Кашан, Кирмән, Алабуга, һәм тарихи исемнәре язма чыганакларда телгә алынмаган башка шәһәрләр керә.

Болгар дәүләте чикләреннән тышта, Иделнең түбән агымы төбәгендә, кыпчаклар яши торган өлкәдә, урта гасыр сәяхәтчеләре *Саксин* дигән шәһәрне еш телгә алалар. Әбү Хәмид әл-Гарнати, мәсәлән, шул Саксинда күп төрле халыклар, алар арасында сәүдәгәрләр, дәрәҗәле мөселман укымышлылары яшәүләрен сөйли. «Шәһәрнең нәкъ уртасында, – ди ул, – болгар кешеләренең әмире тора, аларның үз Җәмигъ мәчете бар, анда җомга намазы укыйлар, аның тирәседә болгарлар яши. Ул халыклардан һәркайсының үз казыйлары, фәкыйһләре, хатиблары бар».

Хәзерге Пермь краенда Идел болгарларының *Афкула* исемле шәһәре билгеле. Аның хәрабәләре (Рождественск шәһәрлеге) соңгы елларда археологлар тарафыннан яхшы өйрәнелде. Шәһәр янында мөселман зираты урнашкан. Афкул борынгы коми-пермяклар җирендә болгарларның сәүдә факториясе ролен үтәгән. Биредә, әлбәттә, һөнәрчеләр дә яшәгән. Шәһәрнең бер почмагында болгарларның чүлмәк яндыру мичләре казып тикшерелде.

«Болгарлар – шәһәр төзелешендә дан яулаган халык», дип язуы белән «рус тарихының атасы» Василий Татищев, һичшиксез, хаклы була.

* * *

Ислам дине кабул ителү белән Идел Болгарында, беренче чиратта, аның мәдәният дөньясында, идеологиясендә кискен үзгәрешләр барлыкка килә. Моңарчы булмаган-күрелмәгән бөтенләй яңа мөселман мәдәнияте барлыкка килә. Архитектура

һәм мәгариф системасы, әдәбият һәм фән, метрология һәм санау системасы, календарь, гореф-гадәтләр һәм йолалар, киемнәр, халыкның рухи һәм матди культурасы – барысы да тирән үзгәреш кичерә һәм бу үзгәрешләр мөселман кануннарының, тәртип һәм кагыйдәләренең яшәешнең бөтен өлкәләренә тирән үтеп керүе турында сөйли.

Ислам – югары үскән язмачылык традицияләре, тирән фәлсәфә белән сугарылган бай әдәбияты булган дин. Яңа дин кабул ителгәннән соң болгарларга бик тиз арада гарәп язуы үтеп керә һәм ул, гарәп графикасы, борынгы руниканы кысып чыгарып, болгар-татар мәдәниятенә 1927 елга кадәр – мең елдан артыграк дәвер буена! – хезмәт итә.

Болгарларда укый яза белү югары катлау кешеләре, байлар арасында гына таралган нәрсә түгел. Гади халык та, бигрәк тә шәһәр халкы, грамоталы булган. Болгарларның дәвамчылары булган татарларның хәтта Россия империясе составында да, XIX гасыр ахырында, башка милләт вәкилләренә караганда күпкә мәгърифәтле булуы бер дә гаҗәп түгел.

Ислам һәм аның тәгълимәте, өйрәтмәләре уку-язуны яхшы белгән кешеләргә исәпләнгән, Коръәнне һәм мөселман хокукын яхшы үзләштергән затларга мохтаҗ булган. Шуңа күрә, яңа дингә күчү белән шәһәр-авылларда мәчетләр ачыла, ә мәчетләр үзләренең мәктәп-мәдрәсәләрен булдыру ягын карыйлар. Ул мәдрәсәләрдә, беренче чиратта, әлбәттә, дин әһелләре әзерлиләр, әмма дини предметлардан башка көндәлек тормышта кирәк булган математика, тыйб (медицина), тарих, география, астрономия кебек дөньяви фәннәрне дә укыталар. Сәләтле яшьләрне гадәттә белем эстәргә Шәрыкнең Бохара, Сәмарканд, Багдад, Каһирәише эре фән һәм мәдәният үзәкләренә җибәрә торган булалар.

Урта гасыр язма чыганакларында фәннең төрле тармакларында эшли торган, мөселман дөньясында дан-шөһрәт казанган болгар галимнәренең исемнәре сакланып калган. Мәсәлән, күптән түгел безгә фармакология өлкәсендә атаклы белгеч Таҗетдин ибн Юныс әл-Болгариның «Олы тирйак» («Агулануга каршы дару») исемле кулъязмасы билгеле булды. 1220–1221 елларда язылган бу хезмәт Таһранда, Иранның Сенат китапханәсендә саклана.

Моңа кадәр инде без Шәрык илләрендә заманында бик популяр булган Хуҗа Әхмәд Болгари исемле бер легендар табипны белә идек. Ул – атаклы солтан Мәхмүт Газнәвинең (967–1030) остазы. Әхмәд Болгари «Әл-җәмигъ», «Әт-тарика», «Әл-фәваид» исемле әсәрләре белән бөтен Көнчыгыш илләрендә танылган олы галим булган. Шунысы гаҗәп, Әхмәд Болгариның исеме әле бүген дә онытылмаган: безгә билгеле мәгълүматларга караганда, 1971 елда Әфганстанда аның кабере өстенә ак мәрмәрдән мавзолей – төрбә салып куйганнар.

XI–XII гасырларда яшәгән Йакуб ибн Ногман исеме безгә Андалусиядән (Көньяк Испания) Болгарга кил-

гән сәүдәгәр һәм сәяхәтче Әбү Хәмид әл-Гарнатиның 1155 елда язылган бер әсәре аша билгеле. Ул 1135 һәм 1153 елларда Болгарда булып китә. Йакуб ибн Ногманның «Болгар тарихы» әсәрен ул үзе укыган.

Идел Болгарында иң популяр һәм, аңлашыла ки, иң күп укыла торган әсәрләр – дини трактатлар. Шәрык илләрендә болгар галимнәре Борһанетдин әл-Болгари һәм Әбү-Хәмид ибн-Идрис әл-Болгариның дини-дидактик характердагы фәлсәфи әсәрләрен яхшы белгәннәр.

Сөләйман ибн-Дауд ас-Саксини ас-Сувари атлы болгар галименең һәм ул язган кайбер әсәрләрнең исеме әле Шиһабетдин Мәрҗанигә үк билгеле булган. Күптән түгел Стамбулның Сөләймания китапханәсендә аның суфичылык фәлсәфәсенә багышланган сигез кулъязмасы табылды. Алар арасында эшләнеше ягыннан иң камиле һәм кызыклысы – «Зүһрәт әр-рийад вә нөзһәт әл-колүб әл-мирад» («Авыру күңелләрне сөендерүче бакча чәчәге» исемле әсәр.

Кол Гали (1183–1236?) хаклы рәвештә болгар-татар язма әдәбиятына нигез салучы булып санала. Ул «Кыйсса-и Йосыф» поэмасын язганда Фирдәүсинең «Йосыф вә Зөләйха» исемле әсәрен, шул заманның башка шагыйрьләре әсәрләрен иҗади кулланган. Кол Галинең әлеге поэмасы монголларга кадәрге чордагы болгар әдәбиятының йөзек кашы булып тора.

Поэманың нигезендә Якын Көнчыгыш халыкларының мифологиясендә тирән тамыр җәйгән гүзәл Йосыф (Иосиф) турында «Тәүрат» риваяте ята. Җәмгыятьнең түбән катлавыннан чыккан һәм башыннан үткән сынаулардан соң Мисыр җиренең хакименә әверелгән егет турында бәян итеп, Кол Гали идеаль дәүләт һәм идеаль идарәче образын сурәтли. Шагыйрь илнең һәм халыкның иминлеген хакимнең әхлакый камиллегендә, тирән акылында, гаделлегендә, тигезлектә күрә. Моның белән шагыйрь гади халыкның гасырлардан килгән хыялын чагылдыра. Кол Гали кешеләрне сугыш-талашсыз, үзара тату яшәргә, изгелек кылырга, шәфкатьле булырга өнди. Шагыйрь уенча, гаилә мөнәсәбәтләре мәхәббәткә, тугрылыкка гына нигезләнергә мөмкин. Зөләйха нәкъ менә шундый хатын-кыз булып гәүдәләнә.

Поэманың бай эчтәлеге, гуманлы юнәлеше, тирән хисләр белән сугарылганлыгы һәм йөгерек теле аны урта гасырлар шигъриятенең иң популяр әсәрләре рәтенә кертә. Аның образлары бик күп буын татар шагыйрьләре өчен илһам чыганагына әверелә.

**Ислам һәм Алтын Урда цивилизациясе.** XIII гасыр башы Евразия халыклары тарихында аларның киләчәк язмышларын билгели торган эпохаль характердагы вакыйгалары белән аерылып тора. 1207 елда Чыңгыз хан тарафыннан дөньяда «иминлек һәм бай тормыш» империясе булдыру максатыннан башланган монгол-татар яуларын континентның Европа өлешендә аның оныгы Батый хан дәвам итә. Ул бу яуларны 1242 елда тәмамлый, бик күп җирләрне

басып алып, аларны үз биләмәләре составына – рәсми рәвештә Җучи Олысы дип аталган яңа дәүләт составына кертә. Әлеге дәүләтне гадәттә Алтын Урда дип йөртәләр.

Җучи Олысы үзенең чәчәк ату чорында Азия һәм Европа территориясенең яртысын диярлек биләп торган. Аның төньяк биләмәләре Идел Болгарының элеккеге җирләрен һәм болгарларның күршеләре булган мордва, чуаш, мари, удмурт, башкорт җирләрен үз эченә ала. Гомумән алганда исә, Җучи Олысында, югарыда санап үтелгәннәрдән башка, төрле телләрдә сөйләшүче кыпчаклар, саксиннар, бортаслар, руслар, шулай ук Кавказ, Себер һәм Урта Азиянең күпсанлы халыклары яшәгән. Аларның кайберләре – ислам, икенчеләре – христиан дине тоткан, араларында мәҗүсиләр дә, шаманнар да күп була.

Яңа дәүләт яшәешенең башлангыч чорында, XIV гасыр урталарына кадәр, чыңгызыйлар-җүчиләр диндә толерантлык сәясәте алып баралар, чөнки бу «Яса» күрсәтмәләренә – Чыңгыз хан законнарына туры килә. Бату хан үзе, фарсы тарихчысы Җүәйни сүзләренә караганда, «бер генә дин дә тотмаган һәм Аллаһы Тәгаләне белүгә омтылмаган да».

Батудан соң хакимияткә килгән Бәркә хан Алтын Урданың ислам динен кабул иткән беренче хакиме була. Бу адымга баруның мөһим сәбәпләре була. Бәркә ханның Монгол империясеннән тулысынча аерылып, Каракорымда хакимлек кылучы Бөек ханга буйсынудан качарга омтылышы көчле була. Бәркәнең Бохарадагы суфичыл җәмгыятьләрдә торган мөселман галимнәре белән ихлас күңелдән үткән ышанычлы әңгәмәләре дә аны исламга этәргәндер, дип уйларга нигез бирә. Әмма Бәркә хан вакытында аның якыннары һәм буйсынган халыклары арасында ислам дине нык тарала алмый. Дәүләт идарәсендә элеккечә борынгы төрки-монгол гореф-гадәтләрен саклыйлар (Мәңгелек Күккә мөрәҗәгать итү, хан ярлыкларында һәм дипломатик документларда уйгур язуы һ.б.). Аннан соңгы ханнар – Мәңге-Тимер (1266–1281), Туда-Мәңге (1281–1287), Тула-Буга (1287–1291), Токта (1291–1312) вакытында да шулай дәвам итә. Ни генә булмасын, бу вакытта инде Ислам диненең абруе хөкүмәт даирәседә дә, гади халык, хәтта күчмән кыпчаклар арасында да сизелерлек дәрәҗәдә арта.

Хөкүмәт даирәсендә эшчәнлек алып барган мөселманнар ярдәме белән Җучи дәүләтендә Токта хан тәхетенә, ул үзе үлгәннән соң, Мөхәммәд Үзбәк (1312–1342) утыра. Илдәге сәяси хәлне һәм җәмгыять алдында торган бурычларны дөрес бәяләп, ул дәүләт идеологиясе дәрәҗәсенә күтәрелгән һәм рәсми дин булган Исламны икеләнмичә кабул итә. Аны нигездә үз ихтыярлары белән Алтын Урда җәмгыятенең барча катламнары, хәтта дала күчмәннәре – кыпчаклар да кабул итәләр (мәҗүси кыпчакларның күмү йоласына хас таш балбалларның юкка чыгуы һәм аларда мөселман зиратлары барлыкка килү бу процесска бик яхшы иллюстрация).

Гади халык арасында яңа динне ныгытуга Үзбәк ханның кече улы Җанибәкнең (1342–1357) мөселман

руханиларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән сәясәте дә ярдәм итә. Фарсы тарихчысы Мөхәммәд әд-Дин Натанзи Җанибәк турында болай яза: «Үзбәк ханның бөтен олысы Ислам динен кабул итте, ул мәҗүсиләрнең барлык гыйбәтәтханәләрен, изге урыннарын җимертте, бик күп мәчетләр һәм мәдрәсәләр ачты. Ул барлык игътибарын Ислам кешеләренең иминлегенә юнәлтте < ... > Ислам илләренең барлык гореф-гадәтләрен ул үзенең дәүләтенә кертте».

Алтын Урдада Ислам диненең тиз һәм уңышлы таралуында Болгардан килгән миссионерлар да зур роль уйнаган, чөнки аларның инде кәферләргә каршы «изге сугышлар» үткәрүдә дә, фин-угыр күршеләре арасында тыныч пропаганда эшчәнлегендә дә бай тәҗрибәсе була. XIV гасырда болгарлар «башка кавемнәргә караганда Мөхәммәд кануннарын нык тоткан иң явыз сарациннар[4]» (В. Рубрук) буларак билгеле була.

* * *

Замандашлар монгол-татар яуларын «моңа кадәр күрелмәгән, очкыннары бөтен якларга җәелеп, явызлыгы бөтен җирләргә таралган коточкыч бәхетсезлек» дип тасвирлый (Ибн әл-Асир). Әмма монголларның бу канлы вакыйгалар артыннан башланып киткән «изге эшләре» турында да онытырга ярамый. Замандашлар алар турында да сокланып язалар.

Язма документларда теркәлеп калган хәбәрләргә нигезләнеп, шуны раслый алабыз: Алтын Урда ханнары үзләренең кул астындагы җирләргә һәм халыкларга талау объекты буларак кына карамаганнар, ә гади игенчеләрнең, терлекчеләрнең һәм һөнәрчеләрнең хуҗалык тормышын җайга салып, аларны үзләренең байлык чыганагы итәргә омтылганнар. Шул максат белән 1257–1259 елларда Җучи олысы территориясендә халык санын алу үткәрелә, акыл белән уйлап, һәр хуҗалыктан тиешле күләмнәрдә (еллык keremнең 10 процентыннан артык түгел) салым алуның бердәм системасы кертелә, башка йөкләмәләр исемлеге билгеләнә. Бу сәясәтнең нәтиҗәсе халыкны хәерчелеккә төшерү түгел, бәлки Җүчилар дәүләтен һәм аның составындагы җирләрне тернәкләндерү, куәтен ныгыту, халыкның тормыш дәрәҗәсен үстерү була.

Алтын Урданы, соңгы елларга кадәр тарихчылар раслаганча, буйсындырылган халыклардан җыелган салымнар хисабына яшәүче паразит дәүләт дип санау дөрес булмас. Әлбәттә, яулап алынган җирләрнең гаять зур мәдәни һәм икътисади потенциалы җимерелгән хуҗалыкны торгызу чорында нык җәлеп ителә. Әмма Алтын Урда цивилизациясе, башлыча, үз икътисадын – авыл хуҗалыгын, һөнәрчелекне, эчке һәм тышкы сәүдәне рациональ оештыру һәм алардан килгән табышны дөрес куллану нигезендә барлыкка килә.

Һөнәрчелек җитештерүе һәм тышкы сәүдә күбесенчә административ-сәяси генә түгел, беренче

[4] Биредә сарациннарны мәҗүсиләр, христиан булмаган халык рәвешендә аңларга кирәк.

чиратта, һөнәрчелек һәм мәдәни үзәкләр булган шәһәрләрдә урнашкан була. Алтын Урда цивилизациясе баштан ук урбанистик характер ала – безгә билгеле шәһәрләр саны гына да 100 дән артып китә. Аларның иң эреләре Идел сәүдә юлында калкып чыгалар.

Алтын Урда тарихының төрле чорлардагы башкаласы турындагы мәсьәлә бүгенге көнгә кадәр кайнар бәхәсләр китереп чыгара. Оешып кына килә торган Алтын Урданың Бату хан сайлаган беренче башкаласы Болгарда булган. Бу хакта язма чыганаклар хәбәр итә, шуңа күрә, әлеге мәсьәлә галимнәрдә бәхәс уятмый. Бу шәһәрдә, ягъни Болгарда, иң элгәреге Җүчи акчаларын суктыра башлау факты үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Алтын Урданың икенче башкаласы булып озак вакытлар хәзерге Әстерхан төбәгендәге Селитренное шәһәрлеге саналып килде. Биредә чыннан да бик зур шәһәр хәрабәләре урнашкан, әмма анда хәзергә кадәр XIII гасыр тәңкәләре табылмаган.

Ә менә Әстерханнан түбәнрәк, Ахтуба елгасында урнашкн Кызыл Яр (Красноярск) шәһәрлегендә XIII гасыр акчалары бар. Галимнәрнең раславынча, Бату хан аңа 1240 елларда дәүләтнең рәсми башкаласы буларак нигез сала. Ул *Сарай әл-Мәхрүсә* исемен йөртә (мәгънәсе: «Аллаһ тарафыннан саклана торган Сарай»).

Урта гасыр шәһәрләре, бигрәк тә Көнбатыш Европаныкылар арасында Сарай үзенең югары дәрәҗәдәге төзеклеге, уңайлыклары белән аерылып торган. Монда керамик торбалардан суүткәргечләр һәм канализация системасы булган. Шәһәр кешеләре эчәр өчен суны арыклар белән тоташтырылган фонтаннардан алганнар. Матур сарайлар һәм җәмәгать биналары яндырылган кирпечтән, ә гади кеше йортлары чи кирпечтән (сырец) һәм агачтан салынган. Биналар таштан яисә балчыктан сырлап ясалган бизәкләр, ялтыравык йөгерелгән полихром бизәкле плитәләр белән тышланган. Бай йортларда бүлмәләр эссе һава белән җылытылган. Ул, мичтән чыгып, идән астында урнашкан төтен юллары аша йөргән. Диварларга терәтеп җылы суфа – ятаклар куелган. Еш кына ишегалдында яисә биналар эчендә агымсулы бассейннар ясалган.

Сарай, дәүләтнең административ үзәге булудан тыш, эре һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак та танылган.

Сарайда 75 мең чамасы кеше яшәгән. Соңгы елларда үткәрелгән археологик тикшеренүләр Сарайны Багдад, Каһирә, Рим һәм Константинополь кебек урта гасыр чорындагы Евразиянең гигант шәһәрләре рәтенә куярга нигез бирә.

XIV гасырның икенче яртысында Җучи олысы башкаласы итеп *Яңа Сарай – Сарай әл-Җәдид* билгеләнә. Ул Үзбәк хан идарә иткән чорда (1312–1342) төзелгән һәм улы Җанибәк (1342–1357) хакимлеге вакытында, биредә «Гөлстан» исемле акча суктыру үзәге барлыкка килгәч, чәчәк атып яшәгән.

Бу шәһәр турында замандашларның кызыклы мәгълүматлары са-

кланган. Гарәп сәяхәтчесе Ибн Баттута (1333 ел) болай дип язып калдырган: «Ул Сарай Бәркә исеме белән билгеле. Бу – Үзбәк солтан башкаласы. Сарай шәһәре гаять зур, иң матур шәһәрләрнең берсе, тигез җирдә урнашкан, халкы тулып торган, матур-матур базарлары һәм киң урамнары булган гүзәл шәһәр. Бервакыт без, андагы аксакалларның берсе белән, шәһәрнең ни зурлыкта булуын белергә теләп, атка атланып, аны әйләнеп кайтырга дип киттек. Без шәһәрнең бер башында яши идек, аннан иртән чыгып киттек һәм шәһәрнең икенче очына бары тик төштән соң гына барып җиттек, анда өйлә намазын укыдык, ашап-эчтек, үзебез кайтасы урынга кояш баеганда гына барып җиттек. Бервакыт без аны киңлеккә үттек һәм ярты көннән соң гына әйләнеп кайттык. Бу шәһәр урамнары тоташ йортлардан гына тора, анда буш урыннар да, бакчалар да юк. Шәһәрдә җомга гыйбәдәте өчен 13 мәчет бар < ... > Аннан кала, тагын бик күп мәчетләр санадык. Анда төрле халыклар яши: монголлар – болар чын мәгънәсендә илнең үз халкы, хуҗалары, аларның бер өлеше мөселманнар; аслар – мөселманнар; кыпчаклар; черкесләр; руслар һәм византиялеләр – болары христианнар. Һәр халык үз мәхәлләсендә аерым яши, базарлары да шунда. Гыйрактан, Мисырдан, Сүриядән һәм башка урыннардан килгән сәүдәгәрләр күп. Солтан сарае Алтынташ дип атала».

Шәһәр ике квадрат километр чамасы зур мәйдан биләп торган. Археологлар биредә элеккеге монгол шәһәре төзелеше традицияләрен саклап калган шәһәр эзләрен ачтылар: үзәктәге хан сараеның һәм гомумән шәһәрнең саклану ныгытмалары юк; хәтта югары катлау кешеләренең бай утарлары да ничектер тәртипсез, «ирекле» рәвештә урнашкан, кирпеч йортлар янында гына күчмәннәрнең чатырлары тезелеп китә.

Яңа Сарай дистәләрчә мәчетләре, шау-шулы базарлары белән дан тоткан. Ул базарлар урынында әле бүген дә җир өстендә сибелеп яткан әллә никадәр көмеш һәм бакыр акчалар җыеп алырга була. Шәһәр үзәгендә матур бизәлешле биналар калкып торган, читтәрәк һөнәрчеләрнең остаханәләре урнашкан булган.

Яңа Сарай 1395 елда Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан җимертелә.

Иделнең уң як ярында, Волгоградтан 40 км ераклыкта урнашкан *Бәлҗемән* Алтын Урданың зур булмаган шәһәрләре исәбенә керә. Шәһәр халкының матди культурасын өйрәнүче галимнәр анда бер үк дәрәҗәдә диярлек рус һәм болгар традицияләренең берләшкән булуын билгеләп үтәләр. Бу аңлашыла да: археологлар фикеренчә, биредә руслар күпләп яшәгән, аларның хәтта аерым колонияләре дә булган. Бәлҗемәндә шулай ук кирпечтән салынган торак йортлар, мәчет, җылыту системасы булган җәмәгать мунчалары, чүлмәк яндыру мичләре казып тикшерелгән. Шәһәр читендә ерактан ук гөмбәз түбәле, диварлары мозаик плитәләр белән бизәлгән кирпеч төрбәләр (мавзолейлар) күренеп торган.

*Укәк* – Саратов шәһәре читендә, Иделнеә уң ягында урнашкан Алтын Урда шәһәре. Территориясенең җимерелүләрдән сакланып калган өлеше 205 гектардан артык (*«урта зурлыктагы шәһәр, әмма бик матур төзелгән»* – Ибн Баттута искәрмәсе, XIV гасыр). Үкәкнең иң югары икътисади күтәрелеш чоры 1270–1360 елларга карый. Ул чорда бу шәһәр Алтын Урданың икътисади һәм сәяси тормышында зур роль уйнаган. Үкәктә сугылган акчалар да шуны раслый. Шәһәрлектә кирпеч төрбә хәрабәләре, майолик плитәләр яндыруга көйләнгән мичләр ачылган. Шәһәр тирәсендә игенчелек белән көн күрүче һәм әле күчмә тормыштан аерылып җитмәгән кешеләрнең торулыклары урнашкан. Кара диңгез, Якын һәм Урта Көнчыгыш, Көнбатыш Европа шәһәрләреннән килгән күпсанлы тәңкәләр һәм чит ил эшләнмәләре Үкәкне халыкара сәүдә үзәге буларак та күрсәтә.

*Мухшы* хәзерге Мордовия территориясендә урнашкан. Бу шәһәргә монголларга кадәр үк нигез салынган дип фаразлыйлар. Аның мәйданы 250 гектар тирәсе. Алтын Урдаынң күренекле шәһәрләреннән. Биредә көмеш һәм бакыр акчалар да сугылган. Кирпечтән һәм таштан торак йортлар, мәчетләр, кәрван-сарай, төрбәләр төзелгән. Суүткәргеч балчык торбалардан гыйбәрәт канализация калдыклары сакланган. Җитештерү комплекслары – чүлмәк ясау һәм тимерчелек остаханәләре, төзелеш кирпечен яндыру өчен мичләр эшләп торган. Археологик материаллар Мохшаның Сура һәм Мокша бассейны төбәкләрендә эре икътисади һәм сәяси үзәгенә әйләнеп китүен, Алтын Урданың күп кенә төбәкләре, шулай ук рус кенәзлекләре белән дә мәдәни һәм сәүдә элемтәләре урнаштырган булуын раслыйлар. Мохша шәһәре 1395 елга кадәр яшәгән, ул Аксак-Тимер яулары вакытында җимертелә.

Алтын Урда ханнары хакимияте астында булган, әмма билгеле бер автономиядән файдаланган Кырым ярымутравы шәһәрләре арасында иң зурысы – *Кырым* (аны генуялылар Солхат дип атаганнар, хәзерге Иске Кырым). Шулай ук хәзерге Бахчасарай районында Кырк-Ер/Чуфут-Кала, Кафа (хәзерге Феодосия), Солдайя/Судак, Мангуп тавындагы Феодоро һ.б. һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләре буларак танылганнар. Кырым нигез салынганнан алып XV гасыр ахырына кадәр ярымутрауның иң мөһим икътисади, сәяси, административ һәм мәдәни үзәге, «башкаласы» булып саналган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, шәһәрнең югары статусын гәүдәләндерүче монументаль архитектура корылмаларының күбесе (мәчетләр, мәдрәсә, төрбәләр, кәрван-сарай, крепость стеналары һ.б.), бүгенге көнгә кадәр шактый яхшы хәлдә сакланып калган. Үзбәк хан мәдрәсәсе – Кырымның (Солхатның) иң матур биналарыннан саналган. Аның янәшәсендә фонтан атып торган, аңа су керамик торбалар буйлап якындагы тау сыртында урнашкан чишмәдән агып килгән.

Алтын Урданың көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш биләмәләрендә,

нигездә хәзерге Казахстан һәм Төркмәнстан җирләрен үз эченә алган төбәкләрдә (Аму-Дарьяның аскы өлешендә) Сарайчык, Өргәнч, Сыгнак, Сауран, Яссы, Отрар, Җәнд һ.б. кебек шәһәрләр урнашкан була. Аларның бер өлеше монгол яулауларына кадәр үк барлыкка килеп, Җүчиләр дәүләте таркалганнан соң да яшәүләрен дәвам иткән.

Көнбатыш Себернең иң танылган Алтын Урда шәһәрләре – шул олысның административ-сәяси үзәге булган Төмән һәм хәзерге Тубыл (Тобольск) янында урнашкан Искер. Себер ханлыгы чорында башкала Төмәннән шул Искергә күчерелә. Бу шәһәрләрнең төрки телле халкы ислам белән таныш булган, ләкин күпчелеге иске диннәрендә калганнар, Тәңрегә табынганнар.

Хәтта иң танылган Алтын Урда шәһәрләрен өстән-өстән генә күзәтү дә, монгол ханнары җимерүчеләр түгел, ә төзүчеләр булган, дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Шәһәрләр яшәү шартларының уңайлылыгы, архитектура корылмаларының матурлыгы, урамнар һәм мәйданнарның чисталыгы белән аерылып торган. Хакимнәр шәһәр халкы өчен булдыра алган дәрәҗәдә уңай шартлар тудырырга тырышканнар. Һәр шәһәрдә диярлек археологлар күп бүлмәле кирпеч йортлар, мәчетләр, мунча, кәрван-сарай һәм башка иҗтимагый биналарның хәрабәләрен казып чыгарганнар. Аларның стеналары полихром плитәләр, фрескалар белән бизәлгән.

Алтын Урданың шәһәр мәдәнияте монголлар басып алган төрле илләрнең оста-һөнәрчеләре традицияләре кушылмасы була. Анда Кытай һәм Урта Азия сәнгате сыйфатлары, Үзәк Азия, Кавказ һәм Русьтан алынган йорт төзелеше элементлары, Кырым, Хәрәзем һәм Идел Болгары һөнәрчелеге элементлары чагыла. Кытай цивилизациясенең кайбер казанышлары Урда шәһәрләренә Бөек ефәк юлыннан җиңел үтеп керә. Казу эшләре вакытында археологлар кытай көзгеләре, фарфор һәм селадон савыт-саба, кош һәм аждаһа сурәтләре төшерелгән сөяк әйберләр, чуен казаннар, кытай ефәге табалар. Алтын Урданың эре шәһәрләрендә XIII–XIV гасырлар арасында бай художество традицияләренә ия булган мөселман сәнгате тарала.

Шәһәрләрне салу һәм тиешле дәрәҗәдә тоту өчен чыгымнарның шактый зур өлешен рус кенәзлекләреннән алынган салым түгел, ә тышкы сәүдә биргән. Биредә сәүдәнең, гомумән, икътисадның тиз адымнар белән үсешенә Алтын Урда ханнары тарафыннан үткәрелә торган эчке сәясәтнең уңай нәтиҗәләрен искә төшерергә кирәктер. 1310 нчы елгы акча реформасы (ул дәүләтнең барлык җирләрендә бер үлчәүдәге Сарай дирһәмен канунлаштыра), сәүдә юлларының иминлеген, куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча файдалы чаралар, моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә түбән (товар бәясенең 3–5 проценты кадәр) таможня җыемнары һ.б. – боларның барысы да чит ил сәүдәгәрләрен Алтын Урда базарла-

рына тартып торган. Өстәвенә әле ул сәүдәгәрләр өчен махсус юлкүрсәткечләр, карталар, «Codex Cumanicus» тибындагы ике телле сүзлекләр төзеп таратылган.

* * *

Алтын Урда урта гасырлар цивилизациясенең моңарчы күрелмәгән дәрәҗәсенә ирешкән. Аның чәчәк атуы XIV гасырның беренче яртысына туры килә, ул вакытта үзәкләшкән дәүләт шартларында ике арадагы ызгышлар туктатыла, сәяси хәл тотрыклана, тышкы дөнья белән киң сәүдә элемтәләре урнаштырыла. Алтын Урда хакимнәре сарайга атаклы галимнәрне, дин әһелләрен, шагыйрьләрне, ерак илләрдән белемле кешеләрне җәлеп итәргә омтылып, аларга һәрдаим ярдәм итеп тора. Шул эшләре белән Бәркә, Үзбәк, Җанибәк ханнар мәдәният дөньясында олы хөрмәт һәм дан казаналар. Бәркә хан үз халкы арасында Ислам дине тарата башлавы белән таныла: «аның карамагында булган барлык җирләрдә мәчетләр һәм мәктәпләр төзи башлый, галимнәрне, хокук белгечләрен үзенә чакыра, алар белән дуслаша» (Ибн Халдун). Берке хан сараенда «фән һәм шәригатькә карата диспутлар даими үткәрелеп тора» (Җүзҗани). Үзбәк хан Сарайда «галимнәр өчен мәдрәсә төзеде, чөнки ул фәнгә һәм кешеләргә бик тугъры иде» (әл-Гомәри). Җәнибәк «белемнәре, аскетик эшләре һәм диндарлыгы белән аерылып торган галимнәргә һәм барлык кешеләргә зур хөрмәт күрсәтте» (Әбү-л-Гази Баһадур).

Мәдәният үзәге – Алтын Урда башкаласы. XIV гасыр гарәп язучысы Ибн Гарәбшаһ билгеләп үткәнчә, Сарай әл-Мәхрүсә Бәркә заманында ук «фән һәм иркенлек чыганагына әверелә; кыска гына вакыт эчендә бирегә галимнәр, атаклы затлар, танылган шагыйрьләр һәм сәнгатьчеләр, кыскасы, бик күп лаеклы кешеләр туплана, шул кадәр мәшһүр затлар хәтта халкы күп Мисырның күп өлешендә дә җыела алмас иде».

Алтын Урда шәһәрләрендә мәдәният үсеше Ислам динен дәүләт дине буларак кабул итү нәтиҗәсе булып тора. Ислам белән бергә гарәп графикасы һәм әдәбияты нигезендә язмачылык та килгән. Җәмәгать биналарының иң күренекле урыннары, мәсәлән, гөмбәз, биек порталлар һәм ишекләр гарәпләрнең бормалы язуы, Коръән сүрәләре, Шәрык шагыйрьләренең шигырьләреннән өзекләр белән бизәлгән. Кәгазьгә металл каләм белән язганнар. Балчык һәм металл савытларда, бизәнү һәм көнкүреш әйберләрендә гади халык арасында грамоталылыкның киң таралуына ишарәләүче төрле язулар сакланып калган.

Бай йортларның китап киштәләрендә Фирдәүси һәм Рудаки (X гасыр), Гомәр Хәйәм (XII гасыр), Низами (XII гасыр), Руми һәм Сәгъди (XIV гасыр) иҗат иткән әсәрләрне күрергә мөмкин була. Алар Алтын Урда шагыйрьләренә үрнәк булып торганнар, яңа әсәрләр язарга рухландырганнар.

Сарайда һәм илнең башка шәһәрләрендә төрле уку йортларының киң челтәре булдырылган. Биредә күре-

некле дин белгечләре, галимнәр һәм шагыйрьләр, шул исәптән, мөселман илләреннән чыккан кешеләр укыткан. Мәсәлән, Болгарда озак вакытлар Ганҗәдән чыккан Хәсән ибн-Гомәр әл-Болгари (Әзербәйҗан), Иран качагы Әбу Мохтар ибн-Мәхмүд әл-Казвини, Фирганәдән Ибн Мәлик әл-Маргиани кебек укымышлылар яшәгән. Мәдрәсә каршында бай китапханәләр, каллиграфлар мәктәбе һәм китап күчереп язучылар булган.

Күп кенә галимнәр һәм шагыйрьләр берничә телне белгән, алар үз әсәрләрен Идел буе төркисендә, гарәп һәм фарсы телләрендә язганнар. Ләкин язма мәдәният, нигездә, хәзерге татар теленә бик якын булган кыпчак телендә үсеш алган. Ул телдә рәсми хан ярлыклары, XIV гасырның Алтын Урда әдәбияты шедеврлары – Котбнең «Хөсрәү вә Ширин», Мәхмүд әс-Сараи әл-Болгариның «Нәһҗ әл-фәрадис», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә-Солтан», Сәиф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» китаплары язылган.

Алтын Урда шәһәрләре арасында Болгар аерым урын алып тора. Рус елъязмачылары аны Бөек Болгар дип атаган. Нәкъ менә шушы шәһәрдә – яңа гына барлыкка килгән татар дәүләтенең беренче башкаласында күпмедер вакыт дәвамында, якынча 1240–1250 нче елларда, Бату һәм Бәркә ханнарның резиденцияләре урнашкан була. Биредә ханнар гадәттә җәй айларында, ярминкәләр сезонында, Ага-Базар читтән килгән сәүдәгәрләр белән тулган чорда яшиләр. Монда ук ханнарга рус князьләрен, шулай ук ярлык артыннан князьлеккә килгән башка җирләрнең хакимнәрен кабул итү, халыктан салымнар җыю өчен уңай шартлар тудырылган була.

Ханнар кышны Түбән Иделдә, йомшаграк климатлы, ат һәм сарык көтүләре – күчмә халыкларның төп байлыгы! – дала киңлекләрендә азыкны җиңел таба торган урыннарда үткәргәннәр. Шунда ук Җучи Олысының яңа башкаласына – Сарай әл-Мәхрүсәгә нигез салына.

1230 нчы еллар азагы – 1240 нчы еллар башында Болгарда Алтын Урданың беренче тәңкәләре сугыла башлый. Дөрес, әлегә Бөек Монгол ханы исеменнән генә, әмма барыбер инде бу факт өстәмә рәвештә Болгарның башкала статусы алганлыгын күрсәтә. 1260 нчы елларда тәңкәләр Алтын Урда ханнары исеме белән чыккан, бу исә Җучи Олысының тулы суверенитетын һәм аның Каракорумдагы империя үзәгеннән бәйсезлеген аңлаткан.

1236 елгы фаҗигадән соң Болгар тиз арада торгызыла: янгын эзләре (көл-күмер катламы) һәм җимерелгән корылмаларның хәрабәләре ком белән күмелә, элеккеге шәһәр ныгытмаларын сүтеп ташлыйлар, яңаларын төзергә тотыналар. Гомумән, шәһәрдә зур төзелеш башлана, яңа торак йортлар һәм иҗтимагый биналар салалар. Шәһәрнең үзәк өлешендә ак таштан биек манаралы Җәмигъ мәчете калкып чыга. Шәһәр читендәрәк яңа һөнәрчелек районнары – металлурглар һәм тимерчеләр, чүлмәкчеләр һәм күнчеләр бистәсе барлыкка

килә. Чуен җитештерү җайга салына, пыяла ясау һәм зәркән (ювелирлык) эше яңадан торгызыла. Шулай итеп, Болгар һөнәрчеләр шәһәренә әверелә, бер үк вакытта, Бөек Идел юлында эре халыкара сәүдә үзәге буларак, элеккеге данын саклап кала.

Югарыда әйтелгәнчә, үзәк базар шәһәрнең үзәгендә, Җәмигъ мәчете янында диярлек урнашкан. Соңгы еллардагы археологик мәгълүматларга караганда, ул шактый зур бина булып күз алдына килеп баса. Кызганычка каршы, базар кыска гомерле булып чыга – 1361 елда Булат Тимер шәһәргә басып кергән мәлдә, зур янгын вакытында юк ителә.

Икътисадның яңарышы һәм төбәкнең сәяси тормышы сизелерлек җанлану тирә-юньдәге халыкның эшче көчләргә бик тә мохтаҗ шәһәргә күпләп килеп төпләнүенә сәбәп була. Моның нәтиҗәсе – шәһәр территориясенең монголларга кадәрге чор белән чагыштырганда ун тапкырга диярлек киңәюе. Аның чәчәк атып яшәгән чордагы мәйданы якынча 400 гектарга җитә. Шәһәр яны бистәләрендә чит ил сәүдәгәрләре, һөнәрчеләр һәм төзүчеләр яшәгән. Мәсәлән, әрмәннәрнең үз чиркәүләре булган («Греческая палата»). Ул бина һәм дә руслар яшәгән бистә археологлар тарафыннан да тикшерелгән иде. Күрәсез ки, болгарлар читтән килгәннәргә алар өчен ят мөселман мохитендә уңайсызлыклар тудырмаска тырышканнар.

Болгар Евразиянең төрле төбәкләре: Түбән Идел һәм Кырым шәһәрләре, Балтыйк буе илләре, Иран һәм Урта Азия, Русь һәм Византия, Һиндстан һәм Кытай белән сәүдә итә. Шәһәрнең культура катламы чит ил әйберләренә бай: Кытайдан, Ираннан һәм Харәземнән фарфор һәм селадон савыт-саба, Венеция, Сүрия һәм Мисыр һөнәрчелек остаханәләрендә җитештерелгән пыяласы эшләнмәләр, Балтыйк диңгезе ярларыннан гәрәбә, Һинд океаны утрауларыннан килгән экзотик кабырчыклар (каури) – барысы да бар. Язгы-җәйге ярминкәләргә килгән чит ил сәүдәгәрләре кәрван-сарайда яшәгәннәр. Шуларның берсе, «Кече шәһәр» дип аталганы, Болгарның көньяк капкасы янында урнашкан була, ул соңгы елларда археологлар тарафыннан җентекләп өйрәнелде.

Сәүдә, әлбәттә, табыш алу өчен алып барыла. Шул ук вакытта аның башка төрле функцияләре дә булган: сәүдәгәрләр бер-берләре белән теге яки бу илдә барган сәяси вакыйгалар, фән һәм мәдәният өлкәсендәге мөһим казанышлар турында фикер алышканнар, һөнәрчелек өлкәсендә килеп чыккан яңа технологияләр дә игътибардан читтә калмаган. Кыскасы, һәр сәүдәгәр үзенә күрә бер информация чыганагы булган. Шунысын да онытмыйк: алар үзләре белән бик кыйммәтле товар – китаплар да алып килгәннәр. Махсус заказ буенча, яисә ачык сатуга куяр өчен. Болгарлар, билгеле булганча, элек-электән Сәмәркандтан китерелгән кәгазьгә язганнар.

Халыкара сәүдә ярдәмендә урта гасырлар дөньясы киңлек (пространство) һәм мәгълүмати бердәмлек

тәшкил иткән. Әлеге Евразия бердәмлеген булдыруда байлык тупларга гына түгел, үзләрен рухи яктан да баетырга теләгән чит ил вәкилләрен очраштырган кунакчыл Болгар да мөһим роль уйнаган.

**Шәһри Болгар Алтын Урда чорында.** Әйтеп узганыбызча, XIV гасыр урталарында Болгар Алтын Урданың иң зур шәһәрләре генә түгел, ә иң төзек һәм матур шәһәрләре рәтендә йөргән. Аның архитектурасында болгар төзүчеләре Якын Көнчыгыш, Урта Азия мөселман традицияләренә таянганнар, ләкин бер үк вакытта төбәкнең табигый-климат үзенчәлекләренә бәйле күп кенә оригиналь яңалыклар да тәкъдим иткәннәр.

Болгар шәһәре территориясендә XVIII йөз сәяхәтчеләре 70 кә якын бина хәрабәләре санаганнар. Хәзерге вакытта ике дистәдән артык монументаль корылма тикшерелгән. Алар арасында биек манаралы Җәмигъ мәчете, Хан сарае хәрабәләре, «Кара пулат» һәм Хан төрбәсе янында урнашкан Кече манара аерылып тора. Архитектура корылмаларының иң зур төркемен таш мавзолейлар һәм җәмәгать мунчалары тәшкил итә.

*Хан сарае* – Бату хан резиденциясе, Идел үзәненең биек террасасында, хәзерге шәһәрлекнең төньягында урнашкан. Эчке периметр буенча 27×29 метрлы әлеге зур кирпеч-таш корылма хәрабәләре Болгар археология экспедициясе тарафыннан 1996–2011 нче елларда тикшерелгән. Бина начар сакланган. Сакланып калган стеналарның биеклеге көньяк өлешендә 2 метрдан артмый. Бинаның 1,5 метр калынлыктагы нигезе ак таштан салынган, стеналары яхшы яндырылган квадрат кирпечләрдән өелгән, ә фасад ягы җентекләп шомартылган известь блоклар белән капланган. Бинаның көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш почмакларында махсус эшкәртелгән блоклардан түгәрәк пилон-башняларның нигезләре саклап калган. Йортның байлыгын казулар вакытында табылган күп сандагы көмеш акчалар күрсәтеп тора. Аларның шактый өлеше 1240–1259 нчы елларда сугылган. Табылдыкдар арасында, Кытайдан һәм Якын Көнчыгыш шәһәрләреннән китерелгән кыйммәтле савыт-саба ватыклары (пыяладан эшләнгәннәре дә күп), бизәнү әйберләре, сугыш кораллары бар.

Бинаның сакланып калган өлешләрен консервацияләү (өлешчә реставрацияләү юлы белән) 2012–2013 нче елларда башкарылды: фундаменты ныгытылды, стенаның бер өлеше һәм почмак башнялары, шулай ук монголларга кадәр салынган агач йорт торгызылды. ЮНЕСКО тәкъдиме буенча әлеге уникаль архитектура һәйкәлен саклау өчен заманча технологияләр кулланылган. Корылманың реставрацияләнгән фундаменты өстенә поликарбонаттан саклагыч гөмбәз куелган, ул металл колонналарга урнаштырылган. Нәтиҗәдә ул туристларның яратып карый торган объектына әверелде.

*Җәмигъ мәчете* – төзелгән вакыты буенча Болгарның монументаль таш корылмалары арасында икенче урын-

да. Шәһәрнең Үзәк мәйданында, административ биналар һәм сәүдә үзәге урнашкан җирдә калкып чыккан биек манаралы бу мәчет әле хәзер дә болгар архитектурасының чын бизәге булып тора.

Әлеге бинаның хәрабәләре галимнәр игътибарын күптән җәлеп итеп торган. Аларның иң әүвәлге һәм шактый җентекле тасвирламасы Россия Фәннәр академиясе әгъзасы, XVIII гасырның танылган сәяхәтчесе П.С. Паллас кулы белән язылган: «Сие здание состоит из неровных худо отёсанных, но весьма плотно складенных известковых диких и гипсовых камней, которые уповательно браны в гористом береге Волги <...> Знатнейшая из оных башня [Большой минарет] сделана из отёсанных камней несколько выше 12 сажень [26 м]. На оную всходят по круглой лестнице о 72 ступенях <…> Двери в башню сделаны на полуденной [южной] стороне, и видны в стене большие железные крючья, на которых дверь висела. В стенах башни оставлены небольшие скважины, в которые свет проходит, и потому видно ходить по лестнице».

П.С. Паллас фикеренчә, «кайчандыр бу хәрабәләр урынында, бәлки, зур мәчет булгандыр». Соңрак әлеге бинаны «калын таш стеналар белән ныгытылган замок – солтан яки хан торагы», яисә «манаралы Хан сарае» булмады микән дип фараз кылучылар да табыла. 1892 нче елда "Дүртпочмак» хәрабәләрен казу белән шөгыльләнгән археология комиссиясе әгъзалары бәяләмәсе буенча, "тикшерелгән бина барыннан да бигрәк мәдрәсә калдыкларына охшаган» .

1964–1970 нче елларда А.П. Смирнов җитәкчелегендә үткәрелгән археологик тикшеренүләр бу мәсьәләгә нокта куйды. Бинаның башта түбәне күтәреп торучы биш рәт булып урнашкан колонналы залдан гыйбәрәт турыпочмаклы (32×34 м) таш корылма булуы ачыкланды. Нигез чокыры 2 метр тирәнлектә. Стеналар ак таштан өелгән. Төньяк фасадка керү порталы тоташкан һәм шул якта ук 24 метр биеклектәге манара урнаштырылган. Манараның алты кечкенә тәрәзәсе булган, югарыга әйләнгеч (винтовой) баскычтан күтәрелгәннәр. Намаз залының көньяк стенасында михраб уемы урнашкан, аның стеналары уеп ясалган орнаменталь бизәк эзләрен саклаган. Ишек һәм тәрәзә уемнары, капительләр һәм колонналарның декоратив бизәлешендә шулай ук ташны уеп ясалган орнаментлар кулланылган. Зал аркалар биеклегендә урнашкан тәрәзәләр белән яктыртылган.

XIII гасыр ахырында Җәмигъ мәчете реконструкцияләнә: кайбер урыннарда стеналарын алыштыралар, яңа идән салына, көнбатыш һәм төньяк стеналар буйлап антресоль галереясен күтәреп торырга ярдәм итүгә исәпләнгән өстәмә сигез кырлы колонналар куела, иске колонналарның барысын да бераз нечкәртеп, сигез кырлы итеп үзгәртәләр. Көнбатыш һәм Көнчыгыш фасадлар буенча декоратив нишалар – уемнар ясала.

Мәчетнең икенчел реконструкциясе XIV гасыр башында үткәрелә: би-

наның дүрт почмагына да диварларның ныклыгын арттыру өчен контрфорс ролен башкаручы унике кырлы крепость башнялары утыртып куялар. Моннан тыш, эчке терәкләрне дә ныгыталар: алты рәтнең һәрберсендә алты колонна барлыкка килә, өч ишек янына эчке тамбурлар ясала. Стеналарны тагын бер мәртәбә штукатурлыйлар, кайбер урыннарга майолик һәм изразец плитәләр ябыштырып куялар.

Шул кыяфәттә Җәмигъ мәчете халыкка 1431 нче елга кадәр, Болгарга Фёдор Пёстрый исемле рус воеводасы җимергеч яу белән килгәнче хезмәт итә. Бу яу нәтиҗәсендә шәһәр үзенең элеккеге данын-кодрәтен югалта һәм түбәнгә тәгәри башлый. Әмма мәчет әле нигезенә кадәр җимерелеп бетмәгән, мөселман халкы, болгарлар, ярымҗимерек шәһәрдә яшәвен дәвам иткән һәм үз мәчетен саклап кала алган.

1964–1967 нче елларда Җәмигъ мәчете хәрабәләрен археологик казулардан соң нинди хәлдә була, шул килеш консервацияләп куялар (бераз гына реставрациягә дә дучар ителә). Бу эшләр барышында ак таштан идән түшәлә, кар-яңгыр суын агызып тору өчен ялгаш тибындагы су үткәргечләр ясала. Өч башняны элеккеге хәленә кайтарып, аларны юка таш плитәләр белән тышлыйлар. Бик начар сакланган Төньяк-көнбатыш башняга консервация кагылмый, аны җил-яңгырдан саклау өчен металл торбаларга козырёк беркетеп куялар. Казу эшләре вакытында табылган колонналарның эре кисәкләреннән җыелган капительле бер колонна барлыкка килә.

XVIII–XIX гасырлардан калган иконографик документларга караганда, Җәмигъ мәчетенең Олы манарасы бүгенге көннәргә кадәр яхшы сакланган Кече манарага бик охшаш, әмма соңгысыннан ике тапкыр биегрәк һәм фасадына уеп эшләнгән гарәп язулары белән генә аерылып торган. 1841 нче елда Олы манара җимерелә, ташларын җирле халык тиз арада хуҗалыкта куллану өчен ташып бетерә. Казан университеты профессоры, танылган рус шәрыкчесе И.И. Березин: «хәзер Олы манара юк инде, аның калдыклары шул җимерелгән урынында ята. 1846 нчы елда мин Болгар җиреннән үтеп барышлый әл-Коръәннән алынган язулы берничә таш күрдем», – дип язып калдырган.

Н.И. Савинков һәм И. Крапивин (1732), В.Н. Татищев (1730), Г.Р. Державин (1761), А.М. Свечин (1762), П.С. Паллас (1768), И.И. Лепёхин (1767), Н. И. Кафтанников (1819), П.П. Свиньин (1823), Ф.Х. Эрдман (1825), Э. Турнерелли (1837), Г.Г. һәм Н.Г. Чернецовлар (1838), А. Дюранд (1839), И.И. Второв (1840) кебек галимнәр калдырган рәсемнәр, тарихи-әдәби һәм иконографик материаллар, архитектор А. Шмитның «1827 елда натурадан төшерелгән «Борынгы Болгарның архитектура сызымнары» альбомы Җәмигъ мәчетенең Олы манарасын торгызу проекты нигезен тәшкил иттеләр. Ул проект 2000 елда тормышка ашырылды.

Манараны торгызу Тарихи һәйкәлләрне һәм истәлекле урыннары

саклау һәм реставрацияләү буенча Халыкара Хартия («Венеция хартиясе») нигезендә башкарылды. Манараны торгызганда Сөйки (Сюкеево) ятмасыннан алынган (Болгар каршында Иделнең уң як ярында урнашкан Сөйки авылы янында урнашкан) бурташ – известняк файдаланылды. Комплексның барлык архитектура һәйкәлләре шул таштан төзелгән.

Олы манараны торгызу әлеге комплексның гомуми күренешен, аны карарга килүчеләргә тәэсир көчен шактый яхшыртты, Җәмигъ мәчете, Төньяк һәм Көнчыгыш төрбәләр белән төс, тон, структура, форма буенча бәйләнешен һәм бердәмлеген тәэмин итте.

Хәзерге вакытта комплексның үзәк өлеше XVII–XIX гасырларның иконографик документларыдагы күренешенә тәңгәл килә.

Зур манараны торгызу дини мәнфәгатьләре, ихтыяҗлары белән дә аклана: мөселманнарның изге урыннарга «кече хаҗ кылуы», ел саен Ислам динен кабул итү көнен бәйрәм итү шушы тирәдә уздырыла.

Чагыштыру нәтиҗәләре буенча, Җәмигъ мәчетенең төзелеш материалы, техник һәм декоратив алымнары Кавказ аръягы, Кырым, Кече Азия, Төньяк Месопотамиянең таш корылмаларына якын булуы ачыкланды. Шул ук вакытта бу мәчетнең архитектурасында, бигрәк тә аның соңгы «кыяфәтендә», Алтын Урда чорындагы Урта Азия корылмаларына хас күләмле-композицион сыйфатлар, Биләрдәге Җәмигъ мәчетен һәм Алабуга шәһәрендәге мәчетне төзегәндә кулланылган җирле традицион алымнар чагылыш тапкан. Гомумән алганда, Болгардагы һәйкәл архитектурасы Шәрык архитектурасының үзенчәлекле стилистик тармагын тәшкил итә.

Җәмигъ мәчете комплексына Болгарның мемориаль корылмалары – шәһәрнең аристократик катлау вәкилләре күмелгән ак ташлы төрбәләр (мавзолейлар) керә. Алар арасында шәһәрнең үзәк өлешендә урнашкан Көнчыгыш төрбә (Изге Николай чиркәве) һәм Төньяк төрбә (Монастырь базы) иң атаклыларыннан санала.

*Көнчыгыш төрбә* Җәмигъ мәчетенең көнчыгыш фасады каршында урнашкан. 1330 нчы елларда төзелгән әлеге бина XVIII гасыр башында Изге Николай чиркәвенә әверелә, аның төп фасадын көньяктан көнбатышка таба күчерелә, очына тимер хач утыртып куелган сөзәк түбәсе сигез кырлы итеп корыла. Чиркәү янында православие зираты барлыкка килә, анда 1965–1966 еллардагы казу эшләре вакытында өч дистәдән артык XVIII–XIX гасырларга караган каберлек ачыла.

Бу төрбәнең элгәреге күренешен, беренчел йөзен реконструкцияләү галимнәргә аны фасад стенасыннан чыгып торган порталлы чатыр рәвешендә эшләнгән Шәрык төрбәләре төркеменә кертеп карарга нигез бирде. Чиркәүгә әверелдергәнче порталлы төп ишек көньякка юнәлтелгән була. Эчке өлеше, ягъни дога уку залының түшәме, ярымсфера рәвешендәге гөмбәз итеп эшләнгән. Өч яктан стенада тәрәзә уемнары бар. XVIII гасыр сәяхәтчеләре хәбәр итүенчә,

төрбә эчендә «гарәпчә язулы кабер плитәләре табылган».

Архитектура тарихы белгече профессор С.С. Айдаров фикеренчә, Көнчыгыш төрбә Урта Азия, Кырым һәм Кавказ мавзолейларына якын, Башкортстандагы «Кәшәнә» төрбәсе белән охшашлыгы бар.

1964–1966 нчы елларда төрбәнең тышкы стеналары янында, ә 1990 нчы еллар башында аның эчендә археологик казу эшләре алып барыла. Алар фикеренчә, Көнчыгыш төрбә шәһәрнең монгол яуларына кадәр үк үзләштерелгән борынгы өлешендә урнашкан. Бу тирәдә һөнәрчеләр яшәгән. Алар Алтын Урда чорында да яшәүләрен дәвам итәләр. Эшләре тимер кою белән бәйле булгандыр, ихтимал, бу урында тимер кою мичләре – горннар казып тикшерелә.

Төрбә Җәмигъ мәчете янындагы мөселман зираты читендә барлыкка килә. Төрбәдә тышкы яктан 2,5–3,2×1,1–1,3 метр (эчке яктан 2×0,8 м га якын) һәм биеклеге 0,9 метр булган җиде таш кабер ачылган. Мәрхүмнәр мөселманнарда кабул ителгән йолага туры китереп күмелгән. Кабертäшлар күрсәткәнчә, биредә болгар нәселеннән булган Бураш-бәкләрнең гаилә төрбәсе булган.

1960 нчы еллар ахырында Көнчыгыш мавзоле реставрацияләнә. Шул вакытта көньяк фасад ишеге яңадан торгызыла, сигезкырлы пирамидаль түбә яңартыла. Хәзерге вакытта һәйкәл тарихи культура корылмасы интерьерында археологик культура объектларын күрсәтү өчен кулланыла.

*Төньяк төрбә* 1330 нчы елларда төзелгән. Озак вакытлар Успение монастыре монахлары аны нәүрәп – кар базы сыйфатында файдаланган. Моннан әлеге төрбәнең икенче исеме килеп чыга – Монастырь базы.

Ул Җәмигъ мәчетенең төп фасады каршында урнашкан, шуңа күрә, Көнчыгыш төрбәгә караганда зуррак һәм матуррак булган. Тик ул бик начар сакланган: безнең көннәргә кадәр нигезе, стена калдыклары, ишек һәм тәрәзә уемнары, планда квадрат рәвешле эчке залның стеналары сигез кырлыга күчә барган өлеше һәм түгәрәк гөмбәз нигезе килеп җиткән. Шуңа да карамастан, төрбәнең элеккеге күренешен яңадан торгызу алай ук кыен түгел, чөнки белгечләр раславынча, планлаштыру структурасы һәм интерьерның сакланган детальләре охшашлыгы буенча бу һәйкәл Көнчыгыш төрбәгә охшаган.

XVIII гасыр сәяхәтчеләре мәгълүматлары буенча, биредә, Көнчыгыш төрбәдәге кебек үк, кабер ташлары яткан, ә җир эшләре вакытында мөселман йоласы буенча күмелгән каберләр ачылган.

Һәйкәл 1968–1969 нчы елларда консервацияләнә һәм реконструкцияләнә. Хәзерге вакытта монда лапидарий ачылган, экспозициядә – XIII гасыр ахыры – XV гасыр башындагы Болгарның кабер ташлары. Аны җыю һәм өйрәнү эшенә 1722 нче елда Азов походына барганда шәһәрлеккә кереп чыккан Россия императоры Петр I нигез салган.

*Кара пулат («Чёрная палата»)* – үзенең элеккеге кыяфәтен тулысынча

диярлек саклап (әлбәттә, бөтенләй юкка чыккан өлешләре дә күп), безнең көннәргә кадәр килеп җиткән гүзәл архитектура һәйкәле. Ул Җәмигъ мәчете комплексыннан көньякка 400 метр ераклыкта һәм Кече манара комплексыннан көнчыгышка таба шундый ук ераклыкта урнашкан. XIV гасыр уртасында ак бурташтан (известняктан ) салынган.

Ни өчен бу пулатны «кара» ди атаганнар? «Янмый торган кыз» исемле татар риваяте аны болай аңлата: «Шөһрәтле Болгар шәһәрен Аксак Тимер (Тамерлан) басып ала һәм кешеләрен кылычтан үткәрә... Болгарда ул вакытта патшалык иткән Габдулла хан, үзенең шәһәрне саклап кала алмавын аңлагач, гаиләсе һәм кайбер якыннары белән шәһәрнең иң нык таш пулатларыннан исәпләнгән Хөкем палатасына кереп бикләнә. Дошман сугышчылары бу бинаны бүрәнәләр, корыган агачлар белән әйләндереп алалар да, ут төртеп җибәрәләр. Габдулла хан һәм аның белән бергә бинага бикләнгән якыннары, хан кызыннан һәм аның Галимбәк белән Алтынбәк исемле ике улыннан кала, барысы да һәлак булалар». Ак таштан салынган Хөкем сарае шушы янгыннан соң каралып калган, имеш». Чынлыкта, аңлатма күпкә җиңелрәк – XVIII гасыр монахлары биредә Иделдән тотылган балыкны ыслау белән шөгыльләнгәннәр, пулат диварларын кара корымга батырганнар.

Башта Кара пулат ике катлы бинадан гыйбәрәт булып, аның икенче катында өч яруслы гөмбәзле залы (7×7 м) булган. Ул төрле функцияләр үтәүгә исәпләнгән зур булмаган биналар белән әйләндереп алынган. Төньяк һәм көнбатыш яктан алар мәһабәт портал һәм таш баскычлы ябык галерея хезмәтен үтәгәннәр, калган ике яктан исә ябык биналар һәм 9,5 метр биеклектәге гөмбәзле залга керү юлы каршындагы ачык портал нишасы рәвешендә булганнар. Һәр ярусның барлык дүрт стенасында да тәрәзәләр урнаштырылган. Дүртенче ярус ярымсферик гөмбәз белән тәмамлана торган сигезпочмак рәвешендә төзелгән. Бина ягыннан беренче кат тигезлегендә зур булмаган бүлмәләр урнашкан.

Икенче ярусның гөмбәзле бинасында бина штукатурланган һәм йолдызлы розеткалардан, капительле кечкенә колонналардан, тромп йөзлегендәге сталактитлардан торган алебастрдан әвәләп ясалган орнаментлар белән бизәлгән. Дүртпочмаклы өлешенең үлчәмнәре – 10×10 метр, галереяне дә кертеп, – 15×16 метр.

«Кара пулат» стеналарын, бурташ (известь) измәсе белән сылап-беркетеп, бурташ туфыннан салганнар. Гөмбәз исә бик сыйфатлы бурташ измәсе белән беркетелгән туф блоклардан эшләнгән.

Татар халык риваятьләрендә, болгар ханы Кара пулатта гаеплеләрне гадел хөкемгә тарткан, диелә. Хөкем карарын ул абруйлы картлардан сайлап куелган өч хөкемдар белән бергәләп чыгарган. Хөкем йортының беренче катындагы түбән бүлмәләрендә хөкем ителгәннәрне тотканнар, имеш.

Болгар археологиясенең абруйлы белгече, профессор А.П. Смирнов фикеренчә, «Кара пулат» халыкка мәчет сыйфатында хезмәт иткән. Бу бинада дәүләт архивы һәм китапханәсе урнашкан булырга мөмкин, дип фаразлый кайберәүләр. Кара пулатны ханәкә – сәяхәтче дәрвишләр, суфилар өчен сыену урыны буларак күз алдына китерүчеләр дә бар. Мәскәү археологы Э.Д. Зиливинская тарафыннан күптән түгел әйтелгән тагын бер фараз материаллар белән ярыйсы гына нигезләнгән: Кара пулат – Алтын Урданың Болгар олысы хакимнәреннән берсе күмелгән төрбә. Кыскасы, фаразлар күп һәм әлегә аларның барысы да яшәргә хаклы.

Белгечләрнең фикеренчә, Кара пулатның борынгы тышкы күренеше куб рәвешендәге үзәк бинаны әйләндереп алган галереяләре, портал тибындагы ишеге һәм сигез бүлемле гөмбәзе белән Бакуда (Азәрбайҗан) XV гасырда, ягъни бераз соңрак төзелгән «Диван-ханә» бинасына охшаш. Дөрес, ул тагын да зиннәтлерәк күренә, әмма, кайбер галимнәр фикеренчә, ул да ханның хөкем итү урыны булып хезмәт иткән. Киңрәк алып караганда, Кара пулат, гомүмән, урта гасырлар чорында Шәрык илләрендә таралган архитектура корылмаларын хәтерләтә. XIV гасырның урталарында һәм икенче яртысында Урта Азия корылмалары, аерым алганда, Күнә-Үргәнечтәге Түрәбәк-ханым, Шах-и-Зинда ансамблендәге Ширин-бикә-әкә төрбәләрендә дә Кара пулат архитектурасына охшаш элементлар табарга була. Кара пулатның Урта Азия корылмалары белән бердәмлеге төзелеш техникасы үзенчәлекләрендә дә ачык чагыла: эчке һәм өлешчә тышкы капламнарда кулланылган туф блокларының формасы һәм үлчәмнәре шуңа ишарәли.

Кара пулатта археологик тикшеренүләр 1957 һәм 1966 нчы елларда, реставрация эшләре – 1897, 1911, 1956–1957, 1977–1984 һәм 1999 нчы елларда үткәрелде.

*Кече манара һәм Хан төрбәсе* Кара пулаттан көнчыгыштарак урнашкан, биредә XIV гасырда кабер-ташлар куелган мөселман зираты һәм ак таштан салынган төрбәләр урнашкан булган.

Шул ук районда чатырлы очыннан башка 12 метр биеклектәге Кече манара урнашкан. Ул – Болгарның элеккеге хәлендә сакланып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән берданбер архитектура һәйкәле. Кече манара тулысынча диярлек Җәмигъ мәчетенең Олы манара үрнәге буенча төзелгән. Аның куб сыман аскы өлешенә (4,8×4,8 м), сигезкырлык утыртылган, ә кубның түбәләре өчпочмаклы кыеклар рәвешендә. Сигезкырлыкка цилиндрик кәүсә утыртылган, ул өскә таба нечкәреп килгән һәм тагын да нечкәрәк цилиндрга тоташтырылган. Аңа уелган кечкенә ишектән чыгып, тар гына түгәрәк мәйданчыкка әлегергә була.

Манараның төньягында җирдән бер метр чамасы биклектә як-ягы үрмә гөлләргә охшаш бизәкләр уелган ишек аша эчкә үтәргә мөмкин. Яшьрәк туристлар гадәттә, 45 әйләнгеч баскычтан югарыга күтәрелеп,

түгәрәк мәйданчыктан тирә-юньне күзәтергә ярата.

Манараның тышкы ягында туристлар игътибарыннан читтә калмый торган тагын бер нәрсә бар: астагы нигез кубның көнбатыш стенасында көймә сыман куыш күренеп тора. Анда нәфис итеп уелган бизәкле кайма эзләре сакланган, ә өстәрәк геометрик һәм үсемлек бизәкләре төшерелгән. Биредә кайчандыр язулы таш булгандыр, дип уйлый эпиграфист галимнәр.

Әйбәт сакланган дип әйтсәк тә, XIV гасыр урталарында яхшы итеп шомартылган сыйфатлы ташлардан төзелгән бу корылма, әлбәттә, элеккеге матур күренешен бераз җуйган, кайбер өлешләре юкка чыккан. Шуңа күрә, реставраторлар 1968 нче елда ук әле өске түгәрәк катның беренчел тышкы капламын, өстәге түгәрәк мәйданчыкның рәшәткәсе, 1969 нчы елда цилиндр сыман катларның кәрнизләрен, манарага керү ишеген, тыштагы бурташ блокларның кайберләрен, куыш белән ишек янындагы бизәкләрне өлешчә торгыздылар, яңарттылар. 1990 нчы елларда да биредә реставраторлар эшләде. 1995 елда мөселман халкы соравы буенча, манарада ярымай урнаштырылды.

Тышкы күренеше һәм бизәлеш элементлары ягыннан караганда бу манара күзәтү башнясы буларак, ягъни, хәрби максатларда кулланылмады микән? дип сорау бирә кайбер галимнәр. Әйе, Азәрбайҗандагы безнең манараларга охшаш корылмалар чыннан да күзәтү максатларында да хезмәт иткәннәр. Болгарның Кече манарасы исә «Хан зираты»нда урнашкан. Ул безнең көннәргә кадәр сакланмаган мәчеткә караган булса кирәк. Җәмигъ мәчетенең биек манарасыннан да тирә-юнь бик яхшы күзәтелә. Һичшиксез, хәрби максатларга да хезмәт иткән булырга тиеш ул.

Кече манарадан төньякка урнашкан төрбә хәрабәләрен хәзер шулай, Ханнар зираты дип йөртәләр, чөнки, археологлар һәм эпиграфист галимнәр раславынча, бу мөселман зиратына югары катлау кешеләрен генә күмгәннәр. Мәрхүмнәрнең күпчелеген табутларга салып җир куенына тапшырганнар, кайбер каберләр өстендә таш төрбә эзләре бар. Әлбәттә, матур каллиграфик язулы каберташлар да куелган.

Бу төрбәләрнең берсе, «Хан төрбәсе» дип йөртелгәне – ул бүген дә тулысынча диярлек төньяк һәм көнбатыш диварларын саклап калган – планда квадрат рәвешендәге, үлчәмнәре 9,5×9,5 метрлы бина. Тышкы яктан куе һәм ачык зәңгәр, сары һәм ак төстәге ялтыравыклы геометрик бизәкләр төшерелгән, куфи язулы гипс плитәләр белән капланган була. Эчкә кереп карасаң, бинаның аскы каты почмак кыеклары ярдәмендә сигезкырлыкка күчүен шәйләргә мөмкин. Сигезкырлык өстендәге түгәрәк нигезгә гөмбәз рәвешендәге түбә утыртылган. Бина эчендә мөселман йоласы буенча күмелгән җиде каберлек ачылды. Биредә олы яшьтәге кешеләр дә, балалар да күмелгән. Димәк, төрбә ниндидер бер танылган

гаиләгә мөнәсәбәтле, дип уйларга нигез бар. Бинаның көньяк диварына 1309 нчы елгы кабер плитәсен кертеп урнаштырганнар.

Хан төрбәсенең көнбатыш ягында тагын бер кечерәк кенә төрбә булган, көнчыгыш ягында исә соңрак янәдән бер бина төзеп куялар. Анысының төньякка карап торган порталы да бар. Төньяк-көнбатыш тарафта Хан төрбәсенә охшатыбрак тагын бер төрбә салып куялар. Хәер, 1968 нче елда үткәрелгән казу эшләре вакытында әлеге «төрбәнең» кеше күмү өчен билгеләнмәве ачыкланды – биредә мич калдыклары һәм идән астыннан җылыту өчен төтен юллары ачылды. Белгечләрнең раславынча, элегрәк бу бина зират мәчете буларак яисә биредә күмелгән атаклы затларны зиярәт кылучы мөселманнар, дәрвишләр өчен махсус салынган ханәкә сыйфатында кулланылгандыр. Соңрак исә аны төрбәгә әйләндерүләре дә мөмкин.

Болгарда ачылган ***мемориаль объектлар*** арасыннан тагын берничәсенә тукталып китик.

*1 нче төрбә.* Ул XIV гасыр ахырында төзелгән. Кече манарадан көньяк-көнчыгышка таба 150 метр ераклыкта урнашкан. 1970–1971 нче елларда археологик яктан өйрәнелә. Бинадан тасмалы фундамент чокыры (котлован), кайбер участокларда стена хәрабәләре һәм төзелеш чүп-чары сакланган. Турыпочмаклы корылманың пландагы үлчәме – 6,6×7 метр, диварларның калынлыгы 1 метрга җитә. Көньяк диварга портал (2,5×2 м) тоташкан, аннан пилон эзләре сакланган. Төрбәнең идәне – җир. Биредә мөселман йоласы буенча күмелгән бердәнбер каберлек ачылды.

Консервация-реставрация эшләре барышында һәйкәлне туристларга ачык һавада күрсәтү ысулы сайланган.

*2 нче төрбә.* 1976–1977 елларда өйрәнелгән бу төрбә Кече манарадан көньяк-көнчыгышка 350 метр һәм югарда тасвирланган 1 нче төрбәдән 110 метр ераклыкта урнашкан. Төзелеш вакыты – XIV гасыр ахыры (1390 нчы еллар). Корылмадан 1 метр киңлектәге тасмалы нигез чокыры, фундаменты һәм стеналарның аерым участоклары, идәне, шулай ук уелган ганч плитәләре һәм штукатурка кисәкләре сакланган. Корылма квадрат планда (9,6×9,6 м). Төньяк диварга ике пилон – а́ркалы портал (2×3 м) нигезләре тоташкан. Бина эчендә идән агач такталардан ясалган. Төрбә тирәсендән участокларга бурташ (известь) измәсе белән ныгытылган вак таш түшәлгән. Эчке стеналар штукатурланган.

*3 нче төрбә.* XIV гасырның икенче яртысында төзелгән, Кече манарадан 250 метр ераклыкта көнчыгыш тарафта урнашкан. Археологик яктан 1981 елда өйрәнелә. Әлеге корылмадан тасмалы фундамент чокыры, фундамент һәм кайбер участокларда пилон нигезләре, төзелеш эизмәсе кисәкләре һәм бурташ кисәкләре сакланган. Мавзолей турыпочмаклы планда (5,5×5,3 м), төньяк диварга портал (2×1,7 м) тоташа. Корылманың идәне – җир. Төрбәдә

мөселман йоласы буенча дүрт кеше күмелгән.

*4 нче төрбә* шулай ук 1981 елда казып чыгарылган. Ул Кече манарадан көньяк-көнчыгышка таба 600 метр һәм 1 нче төрбәдән 230 метр ераклыкта урнашкан. Төзелү вакыты XIV гасырның икенче яртысына – XV гасыр башына карый. Корылмадан тасмалы нигез чокыры сакланып калган. Үлчәмнәе 8,6×8,6 квадрат метр, стеналарының киңлеге 0,7–0,9 метр. Бу төрбәдә унбер кабер ачылган. Шуларның өчесендә балалар күмелгән. Дүрт каберлек соңрак күмелгән кешеләрне күмгән вакытта җимертелгән.

*5 нче төрбә* XIV гасырның икенче яртысында төзелгән. Шәһәрнең көньяк читендә, көньяк капкадан 300 метр ераклыкта урнашкан. 1983–1985 елларда үткәрелгән казу эшләре вакытында үлчәмнәре 14×8 м зурлыгында һәм стеналарының киңлеге 1,2–1,3 метр булган турыпочмаклы корылманың тасмалы фундамент чокыры ачылды. Ишеге көньяктан булган, анда а́рка пилоны һәм порталның нигезе (2×2,5 м) сакланып калган. Төрбә эче үлчәмнәре 6×6 һәм 5×5 метрлы ике бүлмәдән гыйбәрәт. Беренчесендә сигез, икенчесендә – дүрт кеше күмелгән. Әлеге төрбәдә, казу эшләре вакытында табылган иске ташларны кулланып, консервация үткәрелде.

*6 нчы төрбә* XIV гасыр уртасында төзелгән, шәһәрнең үзәк өлешендә урнашкан. Ул бик начар сакланган. Төрбәнең ишеге көньяк өлешендә булгандыр кебек, чөнки биредә а́ркалы порталның пилон эзләре (1,2×1,5 м) сакланган. Корылманың нигезе квадрат рәвешендә (8,6×8,6 м), стеналарының киңлеге 0,7–0,9 метр чамасы, бурташтан һәм туфтан өелгән. Алебастр кисәкләре төрбә диварларының штукатурланган булуына ишарәли. Археологик казу эшләре вакытында кеше сөякләре табылган, әмма каберлекләр сакланмаган.

*Көньяк төрбә* 2012 елда казып тикшерелгән. Ул Болгар шәһәрлегенең көньяк өлешендә, Көньяк капкадан ерак түгел бер җирдә урнашкан. Биредә, өстендә таш-кирпеч кисәкләре аунап яткан артык биек булмаган бер калкулыкта, археологлар XIV гасыр уртасында төзелгән төрбә хәрабәләрен тикшерәләр. Аның нигезе турыпочмаклы (10,2×9,7 м), керү төньяктан, *а*ркалы ишеге 2,7 метр киңлектә урнаштырылган пилоннар белән чикләнгән. Төрбәнең фундаменты берсе өстенә берсен авыштырып куйган тупас эшкәртелгән ташлардан өелгән. Ташлар коры килеш, измә кулланмыйча гына куелган. Төрбәнең эче сигез почмаклы итеп ясалган.

Биредә, төрбәнең көньяк өлешендә, мөселман йоласына туры китереп күмелгән 9 кешенең кабере урнашкан. Аларның барысы да калын һәм киң такталардан ясалган әрҗә тибындагы табутларда ята. Төрбә янында гына мөселман зираты барлыкка килгән. Биредә археологлар 90 нан артык каберлек казып тикшерәләр. Зиратның төньяк-көнбатыш почмагында рельефлы гарәп язуы язылган каберташ табылган.

***Җәмәгать мунчалары*** – Шәрык шәһәрләрен төзекләндерүнең, шәһәр халкына яшәү өчен уңайлыклар тудыруның мөһим өлешен булып тора. Җәмәгать мунчалары Идел Болгарында монголларга кадәр дә, Алтын Урда чорында да күп була. Болгар мунчалары санитар-гигиеник максатларда гына файдаланылмаган. Алар бер үк вакытта аралашу һәм ял итү урыны булып та хезмәт иткән. Биредә бай шәһәр халкы әңгәмәләр алып барган, агымдагы сәясәткә үз карашларын белдереп бәхәсләшкәннәр, бәхәсләшеп туйганнан соң шахмат һәм шашка уйнаганнар, тәмле ризыклар һәм эчемлекләр белән сыйланганнар.

Хәзерге вакытта Болгарда археологик яктан алты җәмәгать мунчасы казып тикшерелгән, алар барысы да Шәрык архитектура мәктәбенең иң яхшы традицияләренә нигезләнеп төзелгән. Күп кенә уртак конструктив элементлары да карамастан, алар үзләренең күләме-үлчәмнәре, планировка үзенчәлекләре, төзелеш материаллары һәм төзелә вакытлары белән бер-берсеннән аерылып торалар.

Алты мунчаның дүртесе Болгарның тауасты өлешендә, Мелёнка елгасы ярында урнашкан булган. Алар арасында әле 1939–1940 нчы елларда ук казып чыгарылган һәм үзәк залга урнаштырылган фонтаны белән күпләргә таныш «Кызыл пулат» дип аталган мунча да бар. Шәһәрнең югары өлешендә ике мунча өйрәнелгән, аларның хәрабәләре өлешчә реставрацияләнгән.

*«Кызыл пулат»* – Болгардагы атаклы мунчаның шартлы исеме. Бу мунчаның эчке таш стеналары кызыл төстәге измә белән штукатурланган була һәм шул төс аның исемендә чагылыш тапкан. Кызыл пулат Мелёнка елгасының сул як ярында, тау итәгендә, Җәмигъ мәчетеннән бераз төньяккарак китеп урнашкан. Бина XIV гасыр уртасында эшли башлый, җимерелү вакыты Федор Пёстрыйның 1431 нче елгы явы белән бәйле.

Кызыл пулат – Болгар шәһәренең иң эре мунчаларыннан санала, нигезенең үлчәмнәре: 32×16–24 метр. Казу эшләре бинаның 1,5–2 метр биеклектә (көньяк-көнчыгыш почмагында 3 метрга кадәр) сакланып калган фундаментын һәм стеналарын ачты. Бер метрга якын киңлектәге фундамент һәм стеналарның аскы өлеше таштан, ә өске өлеше, җылыту миче, бина өстендәге ярымсферик гөмбәз – квадрат кирпечтән (25×25×4 см) салынган. Эчке төзелеше, планировкасы ягыннан караганда ул – гадәти шәрык мунчасы. Үлчәмнәре 14×16 метрлы үзәк залның дүрт почмагына 4×4 метрлы юыну-парлану камералары урнаштырылган. Төп залының үзәгендә 12 аерчалы розетка рәвешендәге фонтан, ә стеналар уртасында суы краннардан агып чыга торган таш юынгычлар урнашкан. Зал өстән олы гөмбәз һәм кечерәк үлчәмле дүрт тартма гөмбәз белән ябылган була. Үзәк залны яктырту өчен гөмбәз өстендә пыялалы тәрәзәләр һәм түбәндәрәк кечерәк тәрәзәләр хезмәт иткән. Бик күп пыяла кыйпылчыклары казу эшләре вакытында табылган.

Бу залга капма-каршы бер яктан мунча алды – үлчәмнәре 7,6×4,2 метрлы чишенү бүлмәсе, икенче яктан – салкын һәм кайнар су өчен таш цистерна һәм зур бакыр казан урнаштырылган ярдәмче эш бүлмәсе, шулай ук су һәм бүлмәләрне җылыту өчен ике мич килеп кушылган. Стенада, идәннән 45 см биеклектә, җылытылган төтен газлары, кайнар һәм салкын су йөри торган керамик торбалар өчен горизонталь уемнар эшләнгән. 20–25 см диаметрлы төтен торбалары идән астында урнашкан җылыту каналлары белән тоташтырылган. Мунча ишеге 4 метр киңлектәге *а*ркалы портал белән бизәлгән. Ишек каршында уртасында бассейны яисә су бөркеп торган фонтаны булган мәйдан барлыкка килгән. Фонтан версиясе вертикаль торба урнаштыру өчен блок-бүлгеч куелган керамик суүткәргеч ватыклары белән раслана.

Тикшеренүчеләр фикеренчә, мунча халыкның урта хәлле катламнарына хезмәт күрсәткән – табылдыклар арасында акчалар, чит илләдән кайтарылган кыйммәтле әйберләр күп түгел. Югары катлау кешеләре башка мунчаларга йөргәннәрдер, шәт.

*1 нче мунча* XIV гасыр башында төзелгән һәм ул башта гади шәһәр кешеләре өчен тәгаенләнгәнн: күләме белән артык зур түгел (14×9 м), эчке планировкасы һәм интерьеры гадиләштерелгән, ә табылдыклар арасында байлыкның беренче билгесе буган ялтыравыклы савыт-саба ватыклары бөтенләй юк.

Әлеге мунча хәрабәләре Кызыл палатадан көнчыгыш якта, аннан 150 метр чамасы ераклыкта урнашкан. Археологлар тарафыннан 1950 елда тикшерелгән. Ул аркылы ике стена белән өч өлешкә бүленгән турыпочмаклы (14×9 м) бина булган. Төньяк-көнчыгыш өлеше (3×5,5 м) киенү-чишенү һәм ял бүлмәсе булып хезмәт иткән, аның суфа тибындагы җылытыла торган ятагы да булган. Юына торган үзәк зал (6×6,5 м) мичтән идән астында урнашкан торбалар буенча килә торган кайнар һава белән җылытылган. Әлеге мич үзе юыну залына көньяк-көнбатыш яктан килеп тоташкан ярдәмче бүлмәдә (7×3 м) торган. Ул мичне тышкы яктан якканнар – аның тамагы ишегалды ягына көньяк-көнбатыш стенада ясалган уем аша чыккан. Суны мунчаның көньяк-көнчыгыш ягыннан бер-ике метр ераклыкта гына казылган сай коедан алганнар. Коедан су агач улактан турыдан-туры ярдәмче бүлмәдә урнаштырылган цистерналарга аккан. Казу эшләре вакытында мунча хәрабәләреннән күп санда керамик торба ватыклары килеп чыга.

*2 нче мунча* баштан ук хакимият идарәсендә югары урыннар биләп торган хәлле кешеләр һәм бай сәүдәгәрләр өчен билгеләнгән. Җиһазлары, ярыйсы гына катлаулы планировкасы белән шәрык мунча-хаммамнары өчен хас булган бүлмәләре; җентекләп сайланган төзелеш детальләре; яхшы итеп шомартылган таш блоклар; интерьерны бизәү байлыгы (мәсәлән, үзәк зал стеналарындагы полихром орнамент эзләре); мунча алдында фонтаннар

белән җиһазландырылган һәм таш плитәләр җәелгән киң мәйдан; чит илләрдән кайтарылган әйберләр һәм күпсанлы көмеш акча табылдыклары – боларның барысы да шул фикергә дәлил булып торалар.

Бу мунча Кызыл палатадан көнбатышка таба Мелёнка елгасының сул як ярында урнашкан. Археологлар тарафыннан 1951 нче елда тикшерелгән.

Турыпочмаклы корылманың пландагы үлчәмнәре – 20×11 метр. Бина күпчелек болгар мунчалары өчен хас өч өлештән тора: киенү-чишенү һәм ял итү өчен мунча алды (6,2×3 м), юыну өчен үзәк зал (10×9 м) һәм җылыту миче, салкын һәм кайнар су өчен цистерналар куелган ярдәмче бүлмә (2,6×9 м). Бер метр чамасы калынлыктагы стеналары тупас эшкәртелгән бут ташыннан салынган, ишек уемнары яхшылап шомартылган ак таш блоклар белән тышланган.

Керү ишеге мунчаның төньяк-көнчыгыш стенасында урнашкан. Сулда, мунча алды почмагында, озынлыгы 2, киңлеге 0,4 метрлы җылытыла торган суфа – таштан ясалган ятак урнашкан. Үзәк залының һәр почмагында 2,6×2,2–2,6 метр үлчәмендәге парлану-юыну бүлмәләре.

Мунчаның өченче бүлмәсе үз чиратында таш стена белән тагын ике өлешкә бүленгән. Мәйданы 2,6×2,6 метрлы көньяк-көнбатыш бүлмәнең идәне үзәк зал идәненнән 55 сантиметрга югарырак – үзәкләштерелгән су үткәрү системасында кирәкле басымга ирешү максатыннан шулай ясалгандыр. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, әлеге бүлмәнең идәне дә, 60 см биеклеккә кадәр стеналары да 20 см калынлыктагы су үткәрми торган измә («цемент») катламы белән сыланган. Биредә, күрәсең, салкын су тотыла торган цистерна торгандыр. 4,5×2,2 метр үлчәмле икенче бүлмәнең идәне тегесенекенә караганда да биегрәк иде. Ул цистернада кайнар су җылыту һәм саклау өчен яраклаштырылган. Шул цистерна янәшәсендә генә диаметры 1,5 метрлы ярымшар рәвешендәге мич торган. Аның тамагы бинадан тышка үтәли тишек аша чыгарылган. Мичтән бинаны җылыту һәм су белән тәэмин итү каналларының тармакланган системасы башланып киткән.

Цистерналарга су күлдән яисә мунчадан 40 метр биеклектәге тау башына урнашкан ясалма сулыктан сuүткәргеч торбалар буенча килгән. Казу эшләре барышында керамик торба ватыклары һәм өч тармаклы субүлгечләр табылган.

*3 нче мунча* Мелёнка елгасының уң як ярында, елга аръягының көнбатыш өлешендә урнашкан. Тикшеренүчеләр фикеренчә, XIV гасыр уртасында, шәһәр үзәгеннән ерактарак торган гади халыкка хезмәт күрсәтү максатыннан төзелгән. Бина үзе шактый зур – мәйданы 12×15 метр һәм ул барлык төр мунчаларга хас функциональ өлешләргә ия: киенү-чишенү бүлмәсе; почмакларында парлану-юыну бүлмәләре булган үзәк зал; мич, салкын һәм кайнар су өчен цистерналы ярдәмче бүлмә (аның мәйдан 28 кв. м чамасы). Мунчаны

су белән тәэмин итү, канализация һәм гадәти җылыту системасы булганлыгын күп санлы керамик торба ватыклары, идән астында төтен йөри торган каналлар күрсәтеп тора. Бина интерьерының декоратив бизәлешенә ишарә ясый торган фактлар юк. Табылдыклар гадәти, арада, берән-сәрән очрый торган акчалардан башка, мунчага йөрүчеләрнең байлыгын күрсәтә торган әйберләр юк.

*Ак пулат* Кара пулаттан көньяк-көнбатышка таба 100 метр чамасы ераклыкта урнашкан. Бу тирәдә кайчандыр шәһәрнең югары катлау кешеләре яшәгән. Бина XIX гасыр уртасына кадәр чагыштырмача яхшы хәлдә сакланган. Түбәләре ишелеп төшкәнчегә кадәр аның тышкы күренешен Андре Дюранд гравюралары һәм бертуган Н.Г. һәм Г.Г. Чернецовлар төшергән рәсемнәр буенча (алар бүген Петербургта Рус музеенда һәм Третьяков галереясында саклана) шактый ачык итеп күз алдына китереп була. Археологлар бу корылманы ике тапкыр – 1887 нче һәм 1979–1983 нче елларда тикшерәләр. Нумизматика мәгълүматларына караганда, мунча 1330–1340 нчы елларда төзелгән һәм 20–30 елдан да артык эшләмәгән. Архитектурасы һәм төзелеш үзенчәлекләре ягыннан караганда ул без югарыда сөйләп үткән Кызыл пулатка охшаш.

Ак пулат – төньяктан көньякка 30 метрга сузылган турыпочмаклы бина. Киңлеге төньякта 10 метр, урта һәм көньяк өлешләрендә 13,5 һәм 17 метр. 1,4 метр калынлыктагы фундамент һәм 1 метр калынлыктагы стеналар бурташ-алебастр измәсе белән беркетелгән эре ташлардан панцир салу техникасында салынган. Үзәк залның эчке диварлары һәм гөмбәз түбәсе штукатурлы профильле архивольтлар, кессоннар белән бизәлгән. А́ркалы төп ишек көнчыгыш якта урнашан һәм шул ишектән стена буйлап таш эскәмияләр куелган чишенү бүлмәсенә кергәннәр. Бу бүлмә (7×7,6 м) һәм аның белән чиктәш тамбур янкорылмасы (7,6×2,7 м) җылытылмаган.

Чишенү бүлмәсеннән ишек аша 12×12 метр мәйданны биләп торган һәм гөмбәз түшәменең биеклеге 6 метрга җитә торган үзәк залга үткәннәр. Зал уртасында фонтанның таш касәсе һәм һәр почмагында планда 3×3 метр үлчәмле юыну-парлану бүлмәләре урнашкан. Аларның һәрберсендә суы стенага беркетелгән краннан ага торган таш юынгычлар булган. Төп залга көньяктан ярдәмче янкорма килеп кушыла, анда ике зур түгәрәк мич һәм цистерналар – кайнар һәм салкын су өчен чаннар куелган. Мичләрнең диаметры 2 метрга җитә, сакланып калган биеклеге 1,7 метр чамасы. Шул мичләрдән үзәк залга таш идәннәрне җылыту өчен идән асты каналлары буенча кайнар һава килеп торган. Керамик суүткәргеч торбалар, канализация торбалары стеналардагы уемнарга салынгын. Яктылык гөмбәздәге һәм стеналардагы тәрәзәләрдән төшкән.

Ак палатаның архитектурасында археологлар Урта Азия, Кырым һәм Кавказ архитектура мәктәпләренең үзебезнең җирле климат шартлары-

на яраклаштырылган традицияләрен күзәтәләр.

*Көнчыгыш пулат* археологлар тарафыннан 1984–1994 нчы елларда тикшерелде. Көнчыгыш пулат Зур Иерусалим чокырының көнчыгыш ягында урнашкан. Ул Болгарның иң эре архитектура һәйкәле булып тора – аның гомуми мәйданы 700 квадрат метрдан артып китә (39×19 м). Корылма, башка мунчалар кебек үк, планда турыпочмаклы, ә үлчәмнәре буенча төрле өч өлештән тора.

Урамнан керүче кеше иң әүвәл чишенү бүлмәсенә эләгә. Аның стеналарына терәтеп, җылытыла торган суфа – кирпеч ятак куелган. Кечкенә генә арадаш коридор аша киенү бүлмәсеннән җылытыла торган икенче мунча алды бүлмәсенә (биредә кайнар мунчага керер аолыннан җылынып утырганнар булса кирәк), аннан соң гына мунчаның үзәк өлешенә үткәннәр. Соңгысы дүрт почмагында да юыну-парлану камералары булган иркен залдан гыйбарәт. Үзәк зал дивары янына, көнчыгыш яктан, кайнар һәм салкын су тутырылган чаннар һәм җылыту миче урнаштырылган ярдәмче бина килеп тоташа. Бу бинадан керамик торбалар аша үзәк залга су килгән, идән астындагы канаулардан кайнар һава бирелгән.

Казу эшләре вакытында табылган нумизматика материаллары күрсәткәнчә, Көнчыгыш җәмәгать мунчасы 1290 нчы еллар башында ук төзелгән һәм 1330–1340 нчы елларга кадәр эшләп торган.

Мунчаның сакланышы төрле участокларында төрлечә. Аның көнчыгыш өлешендә сакланып калган стеналарның биеклеге 1,4 метрга җитә, көнбатыш өлешендә исә фундамент нигезенең эзләре генә сизелеп тора. Кайбер урыннарда идән һәм идән астыннан килә торган җылыту канаулары канәгатьләнерлек сакланган. Шуларның барысын да исәпкә алып, һәм инде яхшырак тикшерелгән мунчалардан алынган информациягә таянып, әлеге бина хәрабәләрен туристларга күрсәтү өчен, өлешчә реставрация алымнарын кертеп, консервацияләп куйдылар.

Күргәнебезчә, Болгарның барлык мунчалары да диярек үзләренең архитектурасы, төзелеш үзенчәлекләре ягыннан мөселман илләрендә таралган мунчаларга – хаммамнарга бик охшаш. Аларга иң якын тиңдәшләрне Түбән Иделдә, Әзербайҗанда һәм Урта Азия шәһәрләрендә табарга мөмкин.

Шәһәр чигендә, Җәмигъ мәчете комплексыннан 2 километр чамасы ераклыкта, көньяк капка тирәсендә, борынгы ныгытмаларга терәлеп диярлек урнашкан ***Кече шәһәр*** («Малый городок») 1712 елда Успение монастырена җир биләмәсе сайлап алу өчен Болгарга килгән Казан губернасы канцеляриясе дьягы Михайлов тасвирламасында беренче тапкыр телгә алына.

Кече шәһәр – исеме үк әйтеп тора – зур түгел, төньяктан көньякка сузылган трапеция рәвешендә. Ике рәт артык биек булмаган балчык үр һәм чокыр белән әйләндереп алынган. Көнбатыш ягыннан тышкы ныгытмаларның озынлыгы – 330 метр,

көнчыгыш ягыннан – 290 метр, төньяктан – 300 метр, көньяктан – 150 м; ныгытмалар эчендәге мәйданның үлчәме – 105×90–106 метр. Шәһәрчекнең төньяк һәм көньяк якларында нindидер таш корылмалар урнашкан. Тагын бер корылма харәбәләре шәһәрчекнең төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан. Биредә беренче казу эшләре, шул исәптәнн, таш бина калдыкларын казый башлау 1893 нче елда башкарылган, әмма бу казылмалардан бернинди документ та сакланмаган. Озак вакытлар Кече шәһәрне Болгарның көньяк тарафтан начаррак ныгытылган өлешен саклау өчен төзелгән үзенчәлекле форт калдыклары дип санап килделәр.

Кече шәһәрне максатчан тикшерү 1981–1984 нче елларда Мәскәү археологы Л.А. Беляев тарафыннан башкарылды һәм 2000 нче еллар башында дәвам итте. Тикшерелә торган объектының юка гына культура катламында керамика ватыклары һәм төзелеш чүп-чарыише табылдыкларның аз булуы ачыкланды. Шәһәрчекнең төзелү вакытын XIV гасырның уртасы – икенче яртысы итеп билгеләделәр. Төзелеш эшләре 1361–1367 нче елларда Булат-Тимер идарә иткән чорда башланган булырга мөмкин. Әмма комплексның беренчел архитектура идеясе тормышка ашырылып бетмәгән, ягъни, проектлана торган биналар нинди дә булса сәбәпләр аркасында туктатылган һәм алга таба яңадан дәва ителмәгән.

Ансамбльнең композицион үзәге булып шәһәрнең төньягында 4 метр киңлегендәге, ике ягынннан башнялар күтәрелгән капка тора. Ул башняларның нигезе 8×9 метрлы турыпочмак рәвешендә. Көнбатыш башня эчендә борылма баскычның астагы басмалары сакланган. Көнчыгыш башнясы бер залдан торган гөмбәз түбәле бинадан гыйбарәт. Башняларга эчтән менеп, капка өстеннән йөрергә мөмкин булган дип фаразлыйлар.

Кече шәһәрчекнең икенче монументаль корылмасы шәһәрчекнең көньягында урнашкан. Аның да нигезе турыпочмак рәвешендә (19×13 м). Бина эчендә ике бүлмә булган.

Өченче корылма – көнчыгыш ягыннан 2,7 метр киңлегендәге ишекле, нигезе 5,2×5,3 метр үлчәмле кечерәк кенә бина. Ян стеналар буенда таш эскәмия калдыклары, ә ишек каршында михраб эзләре сакланган. Аның каршында юыну өчен бүлеп бирелгән каналлы кечкенә сулык була. Шул тирәдә үк тәһарәт алу өчен тәгаенләнгән кечкенә генә ясалма сулык.

Әлегә кадәр галимнәр арасында бердәм фикер юк: нәрсә бу – шәһәр сакчылары өчен махсус урынмы, дәрвишләр өчен ханәкәме, әллә кәрван-сараймы? Шунысы ачык: корылмаларның берсе дә ахырынача төзелеп бетмәгән. Алар 1361 нче елда Булат-Тимер заманында төзелә башланмаган, киресенчә, җимертелгәннәр һәм төзелешкә яңадан әйләнеп кайтмаганнар дип уйлаучылар да бар.

Комплексның барлык биналары да туристларга күрсәтү өчен консервацияләп куелды.

Яңа ачышлар яктылыгында Кече шәһәрчек ансамбленең Көнчыгыш

сәүдәгәрләре өчен кәраван-сарай сыйфатында салына башлавы турындагы фикер дөреслеккә күбрәк туры килә кебек. Әмма объектның оборона функциясе үтәргә тиешлеге турындагы фараздан да тулысынча баш тартырга кирәкми. Төзелеш тәмамланган очракта ул ике функцияне дә үти алачак иде.

* * *

Шәһәр халкына яшәү өчен уңайлы шартлар тудыруның мөһим бер өлкәсе төзекләндерү, шәһәр территориясен тәртиптә, чисталыкта тоту кебек эшләр белән бәйләнгән.. Әгәр дә без бу мәсьәләгә кыскача гына тукталмасак, Алтын Урда чорындагы Болгар турындагы күзаллауларыбыз тулы булмас иде.

Билгеле булганча, аның төп территориясе чагыштырмача тигез, урыны-урыны белән чокырлар белән кискәләнгән урынны – Иделнең сул як ярындагы яссы калкулыкны биләп тора. Мелёнка елгасының ике ярында урнашкан тауасты өлешендә дә халык шактый тыгыз утырган була. Әмма биредә зур биналар, кайчак хәтта гади генә йортлар төзү өчен дә грунт суларын корыту һәм Идел үзәнен чикләп торган терраса итәген – тау киртләчен ныгыту буенча инженерлык корылмалары булдыру таләп ителә. Мәсьәлә су җыю бассейннары, кое һәм каналларны үз эченә алган шактый катлаулы конструкциягә ия булган гидротехник корылмалар төзү юлы белән хәл ителә. Калкулык итәгеннән, сазлыклы урыннардан бәреп чыккан су махсус сузылган торбалар буенча барып, суҗыйгыч коеларга агып төшкән. 60 метрга якын озынлыктагы шундый корылмаларның калдыклары археологлар тарафыннан 1950 нче елларда, әлеге район Куйбышев сусаклагычы сулары астында калганчы тикшерелә. Шул ук елларда 40 метрга сузылган 8×2,5 м үлчәмендәге агач буралар чылбырын тәшкил иткән, эче исә балчык һәм вак ташлар белән тутырылган ряж калдыклары өйрәнелә. Дренаж-ряж системасы шәһәрнең тауасты өлешендә урнашкан монументаль кирпеч-таш корылмаларның куркынычсызлыгын тәэмин иткән, язын кар эрү һәм җәйге чорда көчле яңгырлар вакытында территорияне су басу куркынычын киметкән.

Шәһәрнең урам челтәрен һәм мәйданнарны, һөнәр бистәләрен һәм шәһәр киңлегенең башка элементларын ачыклауга юнәлдерелгән эчке планлаштыруны җентекләп өйрәнү – киң мәйданнарда казу эшләре таләп ителә торган эш. Әмма 1938 нче елда башланган системалы тикшеренүләр нәтиҗәсендә безне кызыксындырган мәсьәләләр буенча күп кенә мәгълүмат тупланды. Шәһәрнең үзәк өлешендә башланып киткән казу эшләренең беренче елында ук таш плитәләр җәелгән борынгы юл, ә якында гына ясалма сулык һәм аның белән тоташкан суүткәргеч керамик торбалар чылбыры ачыла. Зур бина фасады каршындагы мәйдан менә шулай төзекләндерелгән булган икән.

Эре җәмәгать биналары тирәсендә фонтан атып торган яки ясалма сулыклары булган, таш түшәлгән мәйданнар барлыкка килгән. Шундый мәй-

даннарның иң гүзәле Җәмигъ мәчете каршында булган, анда җомга намазларына шәһәр кешеләре генә түгел, җәй айларында – ярминкәләр сезонында чит илләрдән, ерак өлкәләрдән килгән мөселманнар да җыела торган булган.

Урамнарның һәм мәйданнанынр чисталыгына нык игътибар биргәннәр – бу барлык көнчыгыш шәһәрләренә хас. Моны археологик казулар вакытында табылган чүп һәм бәдрәф чокырларының күп булуы да раслый.

***Болгарның эпиграфик һәйкәлләре.*** Хәзерге вакытта Идел буе болгарлары яшәгән җирләрдә мөселман күмү йоласының мөһим элементы булган 400ләп эпиграфик һәйкәл – үлгән кешеләрнең кабере өстенә куела торган ташлар ачыкланган. Аларның яртысы, 200гә якын кабер ташы, Болгар шәһәрлегендә табылган. Әлегрәк алар, әлбәттә, күбрәк булган. Казан университеты профессоры С.М. Шпилевскийның «Спас өязендәге бер алпавытның ишегалдына язулы ташлардан тулы бер тротуар салуы турында» сүзләрен искә төшерик: "Икенче бер Спас алпавыты – ул Успенскоедан, ягъни Болгар шәһәрлегендә урнашкан авылдан була инде, – шул авылдан үзенең имениесенә язулы бер зур таш алып кайтырга боерган була. Кызганыч, ди ул, юлда бу ташны йөкчеләр ватып бетергән». Инде югарыда әйтеп үтелгәнчә, кабертাшларның бер өлеше Җәмигъ мәчете янында Успение чиркәвен төзегәндә һәм дә XIX гасырда архитектура ядкярләрен ремонтлаганда кулланылган. Беркемгә дә сер түгел: күп кенә кабер ташлары тирә-юньдәге авылларда төзелгән шәхси йортларның нигезе астына кулган.

Хәзерге вакытта йөздән артык һәйкәл Болгар тыюлыгы фондларында саклана, шуларның утыз икесе генә тулысынча сакланган, күбесе безгә бик нык җимерелгән хәлдә килеп җиткән. Өч дистәгә якын каберташ Успение чиркәве нигезендә ята.

Атаклы Болгар каберләренә куелган Болгар эпиграфик һәйкәлләре, нигездә, Җәмигъ мәчете янындагы некрополь һәм шәһәрнең көньяк капкасы янындагы зират белән бәйләнгән. Таш каберләрнең күпчелеге (98,5%) чагыштырмача аз вакыт – XIV гасырның сиксәненче – XV гасыр уртасына карый. Бу – Алтын Урданың чәчәк ату, илнең чагыштырмача тыныч шартларда үсеп, халыкның яшәү шартлары күзгә күренеп яхшыра барган чоры.

Каберташлар җирле материалдан – известьташның безнең якларда киң таралган төрләреннән ясалган. Алар үзләренең эшләнеше һәм тышкы бизәлеше, текст төзелеше һәм теле ягыннан берничә төркемгә бүленәләр. Әмма асылда каберташларның барысы да озынча турыпочмак формасында, өске өлеше ярымтүгәрәк рәвешендә ясалган һәм анда алты яисә сигез таҗлы яфрак рәвешендәге розетка уеп төшерелгән. Каберташның бизәкле бордюр белән каймалап алынган төп өслеген гарәп хәрефләре белән язылган текст биләп тора. Текст «Ул мәңге тере, һичкайчан үлмәс, һәр җан иясе үләчәк»;

«Һәр җан иясе үлем ачысын татыячак, ахырда барыгыз да миңа кайтачаксыз»; «Гомер бик кыска мизгел, аны изге гамәлләр кылу өчен куллан» кебек Коръән аятләреннән алынган сүзләр белән башалана. Төп текстта мәрхүмнең һәм ата-бабасының исеме (кайберләрендә җиде буынга кадәр шәҗәрәсе) күрсәтелә, аннан соң «Я раббем, үзеңнең киң рәхмәтең белән ярлыка», «Аллаһның юмартлыгы, киң рәхмәте яусын», «Аллаһ тәгалә бу мәрхүмнең каберен җәннәт бакчасы итсә иде, барча гөнаһларын ярлыкаса иде, урынын мәңге җәннәттә насыйп әйләсә иде» кебек мәрхүмгә яхшы теләкләр формуласы языла.

Белгечләр күзәтүенә караганда, Болгар һәм аның тирә-юнендә табылган каберташлар сыйфатлырак, нәфисрәк, башка төбәкләрнеке белән чагыштырганда яхшырак эшкәртелгәннәр. Күбесенең ян-якларында да бизәкләре бар. Кайберләрендә Алтын Урданың әдәби телендә – Идел буе төркисендә язылган җөмләләр дә очрый. Эпиграфик һәйкәлләр өчен таш Иделнең уң ягында чыгарылган дип уйлыйлар, чөнки Болгардагы барлык архитектура корылмаларының шул таштан төзелгән булу бәхәссез.

Күпчелек каберташларга хас бертөрле бизәлеш, текстларның структурасы һәм анда формулалар охшашлыгы, аерым фразаларның шаблонлылыгы каберташлар ясау буенча Болгар мәктәбе барлыкка килүен раслый.

Эпиграфик һәйкәлләр текстларын өйрәнү болгар-татар җәмгыятенең идеологик тормышында ислам һәм гарәп теленең гаять зур ролен күрсәтә.

* * *

Болгардан кала рус елъязаларында, гарәп-фарсы язучыларының әсәрләрендә, татар риваятьләрендә һәм легендаларында Биләр, Җукетау, Казан, Алабуга һәм Кирмәнчүк кебек шәһәрләр дә телгә алына.

Алтын Урданың Болгар олысы шәһәрләре арасында ***Биләр*** дә бар. Бу шәһәр тулысынча 1236 нче елда юк ителгән һәм үзенең элекке урынында яңадан торгызылмаган. Алтын Урда чоры Биләре Кече Чирмешән елгасының сул ягында, элеккеге урыныннан 3 чакрым ераклыкта урнашкан һәм 70 гектардан артык мәйданны биләп торган. Шәһәр акча сугу үзәкләренең берсе буларак та билгеле. Ул акчаларның күбесе Мәңге-Тимер ханы идарә итү чорына карый һәм XIII гасырның 80–90 нчы елларында күмелгән хәзинәләрдә табылган.

Алтын Урда Биләре территориясендә узган гасыр ахырында үткәрелгән казу эшләре аны югары үсеш алган һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак күрсәттеләр. Казылмаларда Түбән Идел шәһәрләреннән, Урта Азиянең, Иранның һөнәрчелек үзәкләреннән һәм хәтта ерак Кытайдан китерелгән кыйммәтле савыт-саба табылдыклары чыга.

1236 нче елдан соң яшәүдән туктамаган болгар шәһәрләренең берсе – ***Җукәтау.*** Монгол-татар яуларыннан соң шәһәрнең ныгытылган өлеше яңадан торгызылмый, аның каравы, һөнәрчелек бистәсе 150 гектарга кадәр киңәйгән. Биредә савыт-са-

ба җитештерү, кара һәм төсле металл эшкәртү кебек һөнәрләр чәчәк аткан. Казу эшләре вакытында тиме кою һәм чүлмәк яндыру мичләре, тимерче алачыгы кебек һөнәрчелек корылмалары ачылган. Җүкәтауда табылган хәзинәләрнең берсендә Һиндстан солтаннарының 1340 нчы елда сугылган алтын динарлары һәм алтын-көмеш бизәнү әйберләре бар. Алар шәһәрнең халыкара сәүдәдәге роле турында сөйли. *Җүкәтау* исеме бертуган Пициганилар төзегән дөнья картасында һәм XIV гасырның Каталон атласына очраклы рәвештә генә төшерелмәгәндер инде.

XIV гасырның икенче яртысында, Җучи Олысында хакимият кризисы башланып, Сарайдан аерылып чыгу тенденцияләре тәгаенләнгәч, Җүкәтау шул ук исемдәге билек (кенәзлек) үзәгенә әверелә.

Алтын Урда чоры – ***Казан*** тарихында да мөһим этап. Болгарның үзәк җирләреннән читтә урнашкан шәһәр монгол-татарлар тарафыннан җимертелми. Әмма биредә сизелерлек үсеш тә күзәтелми. Урта Идел һәм Урал төбәкләренең Алтын Урда составында булуы сәбәпле Казанның чик буе ныгытмасы буларак тоткан роле югала. Әмма ул үзенең тирә-юнендәге төбәкләрнең административ һәм мәдәни үзәге буларак әһәмиятен саклап кала. Казан төбәгенең көчәеп китүендә монгол-татарлар тарафыннан таланган Кама аръягы җирләреннән килеп урнашкан халыкның күбәеп китүе дә җитди роль уйнаган, әлбәттә. Хакимият тирәсендәге кешеләрнең низаглары нәтиҗәсендә сәяси көрәшләрдә җиңелгән бәкләрнең шау-шулы Болгардан тыныч Казанга күчеп килүе тиздән бу каланы феодал билекнең үзәгенә әверелдерә. Шушы низагларда катнашкан «бөек һәм данлыклы хаким, хакимнәр ярдләмчесе, хөрмәтле һәм җиңелмәс әмир» Мир-Мәхмүд улы Хәсәнбәкнең Кабан шәһәрлегендәге каберенә XIV гасырның икенче яртысында куелган таш бу хакта ачык сөйли.

Алтын Урда чоры ахырына Казан әкренләп төзекләндерелә, калын агач такталар, вак ташлар белән түшәлгән урамнар барлыкка килә, таштан һәм кирпечтән салынган биналар калкып чыга (казылмаларда еш кына шундый бай йорт диварларына ябыштырыла торган полихром плитәләр табыла). Шәһәр территориясенең һөнәрчелек бистәләрендә кара һәм төсле металлургия эзләре ачыкланды. Гомумән алганда, бу чорның сәяси торышы шәһәр үсешендә уңай чагылыш таба.

Алтын Урданың таркала башлавы шартларында Булат-Тимернең (1361) һәм рус воеводасы Фёдор Пёстрыйның (1431) җимерүле яуларыннан соң Болгар олысының сәяси тормышында Казанның роле көчәя. Ул әле XIV–XV гасырлар чигендә үк акча сугу үзәгенә әверелә: Гийас ад-Дин исеме язылган тәңкәләрне нумизматлар Казанда сугылган дип раслыйлар. Мәшһүр тарихчыбыз Шиһабетдин Мәрҗани язганча, «Болгар өстенә килгән күпләгән фетнәләр һәм бәла-казалар аркасында аның элеккеге муллыгы, иминлеге бетүгә йөз тота, әкренләп боларның барысы

да Казанга күчә һәм Казан элеккеге бөеклекнең варисына әверелә».

**Болгар әл-Җәдид – Казан ханлыгы башкаласы.** Гийас ад-Дин акчаларында Болгар ал-Җәдид / Яңа Болгар дип Казан – элеккеге Идел Болгары һәм Алтын Урданың Болгар олысы җирләрендә төзелгән ханлык башкаласы аталган. Казан ханлыгы бу дәүләтләрнең турыдан-туры варисы була һәм үз элгәрләреннән дәүләт төзелеше, җәмгыятьнең икътисадый һәм мәдәни-идеологик тормышын оештыру системасын кабул итеп ала.

Казан ханлыгының барлыкка килүе XIV гасыр ахырында – XV гасыр башында Алтын Урдадагы сәяси вәзгыятьнең үзгәрүенә бәйле.

Алтын Урдадан бәйсез, үзенең мөстәкыйль тормышы белән тыныч кына яшәп ятучы Казан билеге (кенәзлеге) тарихында борылыш чоры 1437 нче елда башлана. Шул елда Алтын Урда тәхетеннән куылган Олуг Мөхәммәд хан Кырымдагы биләмәләрен ташлап, Мәскәү Русенең көньяк-көнбатыш чигендәге Ока елгасы янына урнашкан Белёв шәһәрен ала һәм Урта Иделдә Казан кенәзлеге нигезендә яңа дәүләт төзергә омтыла. Тик ул үз планын тормышка ашырырга өлгерми, 1445 нче елда Курмыш шәһәрендә вафат була. Рус елъязмачылары хәбәр иткәнчә, шул ук елның көзендә «Олуг Мөхәммәд улы Мамотек (Мәхмүтәк, Мәхмүт) Казанны яулап ала, аның вотчичы (кенәзе) Либәйны (Алибәй, Галимбәк) үтерә, үзе патшалык итә башлый». Рус елъязмачысына ышансаң, Казан җире халыклары – нигездә ул элеккеге болгарлар һәм аларның нәсел-нәсәпләре, Идел-Урал буе финнары, ягъни хәзерге мари һәм удмуртларның ата-бабалары, чувашлар, башкортлар һәм дә Алтын Урданың төрле төбәкләреннән күчеп утырган кешеләр – барысы да Казанда Мәхмүт ханның хакимлек итә башлавын «сөенеп каршы алганнар». Казан ханлыгы чорында элеккеге болгарларны Бату хан гаскәрләре составында монголлар белән бергә Көнчыгыш Европа далаларына килеп утырган татарлар исеме белән атау гадәткә керә.

***XVI гасыр Казаны.*** Халыкара сәүдә үзәге буларак, Шәрык һәм Көнбатыш Европа илләрендә дә билгеле булган ханлык башкаласы Казан, бүгенге күзлектән чыгып караганда, артык зур шәһәр булмаган. Аның тау башында урнашкан һәм көчле ныгытмалар белән уратып алынган өлеше (кала – кремль) якынча 10 гектар мәйданны биләп торган. Шул заман кешеләре: «Казан крепосте бик нык – таш тау кебек», – дип язып калдырганнар (А. Курбский). Елъязмачы сүзләренә караганда, хәтта рус патшасы Иван IV Васильевич та, 1552 нче елның август ахырында шәһәргә килеп, «барын да күздән кичергәч, крепость стеналарының гадәттән тыш матурлыгына һәм ныклыгына соклана». Казансу һәм Болак ягыннан әлеге стеналарның калынлыгы 5–6 метрга җиткән. «Ул урыннар һичкем дә яулап ала алмаслык» саналган. Кирмән стеналарында башнялар һәм капкалар да булган: Зур капка – Хан капкасы (хәзерге Спас башнясыннан төньяктарак), Түбән капкасы (хәзер-

ге Преображение башнясы тирәсендә), Нурали (хәзерге Тайницкая башнясы тирәсендә), Елгабуе (Елбугина, хәзерге Воскресение башнясы урынында) һәм башка капкалар.

Кирмәннең төньяк өлешендә ак таштан салынган һәм тәбәнәк кенә стена белән ныгытылган хөкүмәт резиденциясе урнашкан була. Биредәге Хан сарае башкан биналардан үзенең матурлыгы һәм архитектурасының камиллеге ягыннан аерылып торган. Хан сарае каршында, 1565–1568 нче елларда төзелгән «Теркәү китабы»нда («Писцовая книга») күрсәтелгәнчә, «Большая палата» исемле соңгы елларда археологлар тарафыннан тикшерелгән ак ташлы бина (18×24 м) урнашкан. Хан сараеннан ерак түгел, көньяк-көнбатыш якта, хәзерге Сөембикә манарасы янында Хан һәм, тагын да eрактарак, Нур-Али мәчетләре калкып торган. Хан мәчете янында гына ханнар зираты барлыкка килгән. Археологлар казып тикшергән таш төрбәдә Мәхмүт (1464 нче елда вафат) һәм Мөхәммәт-Эмин (1518 нче елда вафат) исемле ханнарның каберләре табылды.

Хан резиденциясе каршында, әмма аннан читтәрәк урнашкан мәйданда шәһәрнең мөселман руханилары башлыгы, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм шагыйрь Кол Шәриф исеме белән аталган сигез манаралы Җәмигъ мәчете һәм ул заманнарда югары мәктәп вазыйфасын үтәгән мәдрәсә эшләп торган. Археологлар аның хәрабәләрен Благовещение соборы каршындагы бакчада таптылар. Мәчет нигезе астына 1552 елның фаҗигале көзендә зур гына ике акча хәзинәсе күмеп куйганнар. Ул хәзинәләрнең берсендә бөек князьләр Иван III (146–1505) һәм аның улы Василий III (1505–1533) идарә иткән чорда Мәскәү, Псков, Тверь, Рязань, Можайск һәм кайбер башка рус шәһәрләрендә сугылган 1449 көмеш тәңкә, икенчесендә күн янчыкка төрелгән 556 тәңкә ята яшерелгән иде.

Кирмәннең соңрак «Туп ишегалды» («Пушечный двор») дип аталган төньяк-көнбатыш өлешендә хәрби гарнизон, корал остаханәләре һәм сугыш кирәк-яраклары арсеналы урнашкан була. Казан кирмәненең калган территориясен дәүләт идарәсенә якын торган аксөякләрнең, замандашлары язганча, «бик матур һәм гаҗәпләнүгә лаек» бай утарлары биләп торган, сарай хезмәткәрләре яши торган гади генә йортлар, ашлык саклау амбарлары тезелеп киткән. Шәһәр каласында, Кремльдә, Нурали исемен йөртүче тагын бер мәчет эшләп торган. Аның кайда урнашкан булуы әлегә билгеле түгел, Нурали (хәзерге Тайницкая) башнясы яныңдарак түгел микән дигән фараз гына бар.

Шәһәрнең төп өлеше, әлбәттә, сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр бистәсеннән гыйбәрәт булган. Ул көнбатыштан Болак елгасы, көнчыгыштан Кара, Ак, Мунча, Шакшы (Поганое) күлләре, көньякта исә хәзерге Лобачевский һәм Астрономия урамнары белән чикләнгән 60 гектар чамасы мәйданны биләп торган.

Ханлык чорында шәһәр бистәсе дә кереп-чыгып йөрү өчен 9–10 башнясы булган имән диварлар белән әйләндереп алына. Ныгытмалар 3–4 метр биеклектәге җир үрләр өстенә бер-берсенә терәтеп утыртылган агач буралардан гыйбәрәт булган. Буралар эченә туфрак һәм эреле-ваклы таш тутырганнар. Бистә ныгытмалары кирмәннең Нурали башнясыннан (Төмән башнясыннан да булырга мөмкин) Болакка кадәр төшкән, андагы Аталык капкасыннан елганың уңъяк яры буйлап барып, Кырым һәм Көрәеш капкаларына тикле сузылган, аннары, көнчыгыш тарафка борылып, Арча кыры ягына күтәрелгән. Арча кыры капкасыннан стена күлләр яныннан төньякка таба дәвам иткән һәм кирмәннең төньяк-көнчыгын ягындагы Елгабуе капкасына барып тоташкан.

Бистәнең Казансуга якын өлешендә кара һәм төсле металл кою мичләре, тимерчеләрнең, чүлмәкчеләррнең, тире-күн эшкәртүчеләрнең күпсанлы остаханәләре, ә Болак тирәсендә, Нурали башнясыннан ерак түгел җирдә, Таһир мунчасы («Даирова баня») урнашкан була. Хәзерге Үзәк стадионга каршы якта, элеккеге Ташаяк урамы тирәсендә, даими эшләп торучы зур гына базар булган.

Башка урыннарны гади агач йортларда яшәүче шәһәр кешеләре, сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең утарлары алып торган. Алар арасында мөлкәтле кешеләрнең, бай сәүдәгәрләрнең агач бүрәнәләрдән, сирәк булса да кирпечтән салынган, шул заман кешеләре язганча, икешәр катлы «гаҗәпләндерерлек матур» йортлары аерылып торган. Кызганыч, язма чыганакларда Казан бистәләрендәге мәчетләр һәм башка җәмәгать биналары турында хәбәрләр сакланмаган. Алар да булган, әлбәттә. Мөселман шәһәрен диварлары төсле чынаяк плитәләр белән капланган мәчетләр һәм аларның югарыга омтылган манараларыннан башка күз алдына да китереп булмый. Шул мәчетләре бит инде шәһәргә үзенә бер төрле матурлык биреп торган һәм чит ил кешеләре аны «искиткеч шәһәр», «Шәрыкнең башкаласы» дип атаганнар.

Тормыш шәһәр яңы бистәләрендә дә кайнап торган. Болак аръягында, хәзерге Мәскәү урамы буйлап, XV йөз урталарында ук Көрәеш бистәсе үсеп чыга. Бистәнең сокланырлык матур Өтәч мәчете (Отучева мечеть) хәтта рус елъязмаларында теркәлеп калган. Көрәешнең археологик эзләре, шул исәптән, борынгы зират урыны, хәзерге Колхоз базары тирәсендә ачылды. Көрәеш бистәсеннән арырак, Иделгә таба, Хан болыны башланып киткән, анда җәен зур бәйрәмнәр оештырылган, ат чабышлары уздырылган.

Казансуның Иделгә кушылган урынында балта осталары һәм кораб төзүчеләр бистәсе – Бишбалта барлыкка килә. Шунда ук, Идел култыгында, сәүдә һәм хәрби суднолар тукталышы өчен уңайлы урын да табыла.

Шәһәрнең икенче ягында, Арча кыры белән Кабан күле арасында, Әрмән бистәсе урнашкан була. Өлкән яшьтәге кешеләр әйтүенчә, әле узган гасыр урталарында да Калинин

урамы башланган җирдә борынгы зират урынын күрсәтеп торучы әрмән язмалары белән чуарланган кабер ташлары калкып торган.

Гомуми мәйданы чама белән 100 гектарга җитә тоган шәһәрдә һәм аның тирә-юнендәге бистәләрендә, безнең якынча исәпләүләр буенча, 7–8 мең чамасы кеше (һәрхәлдә 10 меңнән артык түгел) – башлыча һөнәрчеләр һәм вак сәүдәгәрләр яшәгән. Кызганыч, археологик казулар вакытында һөнәрче остаханәләре бик сирәк очрый, әмма алар кулланган инструментлар һәм шул остаханәләрдә җитештерелгән әзер продукция – тимерчеләр ясаган хезмәт һәм сугыш кораллары, күптөрле көнкүреш кирәк-яраклары, бакырчылар ясаган комганнар һәм кувшиннар, ювелир осталары җитештергән алтын-көмеш бизәнү әйберләре, күнчеләр теккән аяк киемнәре, ук савытлары – археологик табылдыклар арасында сирәк түгел. Чүлмәкчеләр аеруча оста һөнәр ияләре саналган. Алар эшләгән югары сыйфатлы балчык савыт-саба һәм дә кош-хайван сурәтендәге уенчыклар матур формалары, үзенчәлекле бизәкләре белән аерылып торган. Хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре ясаганда ювелирлар бакырга, алтын-көмешкә чокып рәсем төшерү, кыйммәтле ташлар кую, металл үрү кебек катлаулы ысуллар кулланганнар. Алтын-көмеш әйберләр хан сараена аруча күп кирәк булган. Замандашлары язганча, һәр яңа хан үзенә «кыйммәтле таҗ, алтын-көмештән савыт-саба эшләткән, кыйммәтле кием-салым тектергән». Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында сакланган уникаль «Казан бүреге» кешеләрдә бүген дә зур соклану уята. Аны XVI гасырның беренче яртысындагы татар ювелир сәнгатенең гүзәл үрнәге дип атарга мөмкин.

Һөнәрчеләр арасында төзелеш белән мәшгуль кешеләр аерым бер төркем тәшкил иткән. Алар «патша пулатлары һәм биек манаралы мәчетләр салучы осталар» гына түгел, ә төрле төстәге кирпечләр, матур бизәкле гипс плитәләр эшләүче осталар да булганнар. Таш кисүче осталарның байлар заказы буенча искиткеч матур итеп эшләнгән, матур каллиграфия белән гарәпчә текстлар язылган каберташлары безне әле дә хәйран калдыра.

Казан ханлыгы икътисадында сәүдә, бигрәк тә тышкы сәүдә зур роль уйнаган. Татар сәүдәгәрләре Мәскәү Русе, Кавказ һәм Урта Азия, хәтта Көнбатыш Европа илләре белән тыгыз элемтәдә торганнар. Иделнең Казанга якын Кунаклар (Гостиный) утравында ел саен даны еракларга таралган Казан ярминкәсе уздырылган. Шул заманның бер кешесе: «Казанга бөтен Рус иленнән бай сәүдәгәрләр һәм ерактан бик күп чит ил кешеләре җыелып килә һәм кыйммәтле товарлар белән күпләп сату итә», – дип язып калдырган. –Сәүдәгәрләр Бохарадан, Шәмәхәдән, һәм дә төрекләр, әрмәннәр иленнән, һәм дә башка илләрдән» килеп йөргән. Чит ил сәяхәтчеләре дә рус елъязмачыларының сүзен раслый. «Казан – сәүдә шәһәре, – дип язып калдырган XV гасырда яшәгән Венеция сүәдәгәре Иосафато

Барбаро. – Аннан ифрат күп санда мех чыгарыла, алар Мәскәүгә, Польшага, Пруссиягә һәм Фландриягә китә». XVI гасыр башында яшәгән Австрия дипломаты Сигизмунд Герберштейн Казанга «Әстерхан, шулай ук Персия/Фарсы һәм Әрмәнстан базарларыннан сәүдәгәрләр» килүе турында хәбәр итә. Югарыда китерелгән тарихи чыганаклар яктылыганда Казан ханлыгы Европа белән Азия халыклары арасындагы сәүдәдә әһәмиятле урын тоткан дип әйтә алабыз.

Ханлык чоры Казаны элгәреге Алтын Урда һәм Идел Болгары шәһәрләреннән зурлыгы ягыннан да, байлыгы ягыннан да күпкә калыша. Биредә Биләр, Болгардагы кебек монументаль архитектура корылмалары юк дияргә була (хуш, аларның бер өлеше соңгы төзелешләр вакытында юкка чыккан дип уйларга да нигез бар). Икътисад үсешен югары бәяләгән очракта да, әлеге күренеш Казан өчен генә хас дип уйларга нигез бар, чөнки Арча, Лаеш, Тәтеш һәм башка шәһәрләр бик кечкенә, шунлыктан алар һөнәрчелектә сизелерлек роль уйнамаганнар.

Казанда тормыш дәрәҗәсе шактый югары булган. Бу аңа бай һәм мул тормышлы дигән дан китергән. Тау өстендәге мәһабәт крепосеь, хан сараеның зиннәтле биналары, алъяк (фасад) стеналары төсле чынаяк плитәләр белән бизәлгән мәчетләрнең биек манаралары, байларының матур йортлары белән Казан атаклы Шәрык шәһәрләренә охшап торган. Чит ил кешеләре аны юкка гына «гаҗәеп шәһәр» («дивный город»), «Шәрык башкаласы» («столица Востока») дип атамаганнардыр инде.

***Шәһри Болгар ханлык чорында.*** Ханлык чорында безнең шәһри Болгар ни хәлдәрәк була соң? Рус кенәзе Фёдор Пёстрыйның 1431 нче елгы җимергеч явыннан соң ул шәһәр булarak яшәүдән туктый. Әмма аны тулысынча ташлап китмәгәннәр. Болгарның ханлык чорында тупланган юка гына культура катламыннан табылган әйберләрр шул хакта сөйли. Ташландык шәһәрдәге мәчетләрне, төрбәләрне, кабер ташлары куелган зиратларны җимерелүдән саклап калуны изге бурыч дип санаучы шәһәр кешеләре була алар. Сүз уңаеннан, борынгы актлар тупланган Россия дәүләт архивында Биляр белән Балынхуҗа тавындагы «изге урыннар»ны саклау кебек изге эш белән мәшгуль кечкенә татар авылы кешеләре турында мәгълүмат теркәлеп калган. Ул документ XVII гасырга карый. Мөселманнарның изге урыннарын саклап-чистартып тору гамәле татарларда шул заманнарда формалашкан, күрәсең.

Казанның кайбер «ханнарын», чынбарлыкта исә югары катлау руханиларын һәм зыялыларын мөселманнар аеруча хөрмәт иткән изге урыннарда – Болгарда һәм Биләр янындагы Балынгуз тавында күмүләре турында тарихи мәгълүматлар сакланган. Моның белән без шәһри Болгар да, Биләр дә, җимерелеп яшәдән туктауга карамастан, халык игътибарыннан читтә калмаган дип әйтергә телибез.

***Казан ханлыгында мәдәният.*** Алтын Урда казанышларының лае-

клы варисы булып торган Казан ханлыгы аның мәдәниятен дә үстерүне дәвам итә. Ул әле Болгар чорыннан ук халык аңында ныгып, ислам диненең күп гасырлык традицияләренә нигезләнә.

Дәүләт тормышында исламның ролен Ибраһим һәм Сәхип-Гәрәй ханнар исеменнән 1470 һәм 1523 нче елларда язылган, Аллаһ исеме белән башланып киткән һәм «әмирләргә, бөек сәетләргә һәм кадияләргә» мөрәҗәгать иткән хан ярлыклары ачык гәүдәләндерә. Сәетләр, Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән буларак, бөтен ил масштабында дин башлыклары функцияләрен үтәгәннәр һәм халык арасында зур абруй казанганнар. 1517 нче һәм 1526 нчы елларда Мәскәү дәүләтенә килеп, озак кына яшәп киткән Австрия илчесе Сигизмунд Герберштейн, Казан сәете турында дәүләтнең иң югары рухани заты буларак сөйләгәндә, шаккатып, болай дип яза: «Ул аларда шундый хөрмәт һәм ихтирам казанган ки, аңа якынайганда хәтта патшалары (ханнары) да аңа, атка атланып баручы сәеткә, атларыннан төшеп каршы чыгалар, аягүрә басып куларын сузалар, башларын иеп, кул биреп исәнләшәләр; болай итеп исәнләшү патшаларга гына рөхсәт ителә; аларның кенәзләре (бәкләре) сәетнең кулына түгел, тезләренә генә кагылалар, башка аксөяк затлар аның аягына, ә гади халык исә киеменә яисә атына гына кагыла». Сәетләрнең абруен ханнар еш кына дипломатик максатларда кулланганнар. Ш. Мәрҗани мәгълүматларына караганда, «рус кенәзләре Казан ханнарына үз илчеләре аша хатлар җибәргәндә, сәет Шәрифколга (Кол Шәрифкә) аерым хат һәм бүләкләр җибәрә торган булалар».

Казан ханлыгында традицион рәвештә Ислам тәгълиматлары таләп ителә торган грамоталылык гади халык арасында да югары дәрәҗәгә ирешкән. Дини белемгә генә түгел, дөньяви мәгарифкә дә омтылышны дин әһелләре Аллага яраклы эш дип санаганнар. Хәтерегездә булса, без әле, монгол яуларына кадәр яшәгән болгарлар да балаларына мәктәп-мәдрәсәләрдә дөньяви предметлардан башлангыч белем биргәннәр, дигән идек. Бу традиция ханлык чорында да дәвам иткән. Югарыда телгә алынган австрияле дипломат Сигизмунд Герберштейн сүзләренә караганда, «татарлар [Идел буенда яшәүче] башка халыкларга караганда белемлерәк». Һөнәрчеләр арасында грамоталыкның таралган булуын Мөхәммәд Әмин ханның гаскәр башлыгы Күбәк баһадирга аталып ясалган җиз комганга гарәп хәрефләре белән уеп язылган шигырь юллары да раслый. Аның тоткасына шул комганны ясаган останың исеме дә язылган: «(Мөхәммәд) Әмин хан бакырчысы Насыйр».

Казан ханлыгы чорыннан дистәләрчә кабер ташлары сакланып калган. Аларның чокып язылган матур, җыйнак һәм тирән мәгънәле җөмләләрендә ник бер хата булсын! Димәк, байларның каберләренә куела торган ташлар ясау белән шөгыльләнүче осталар, һич-

шиксез, укый-яза белгәннәр. Коръән сүрәләреннән башка, алар шул заман шигъриятен да яхшы үзләштергәннәр кебек: каберташларның ян-якларында еш кына уеп язылган шигырь юлларын очратырга мөмкин.

Атаклы дин әһеле һәм шагыйрь Кол Шәрифнең мәчет имамы гына түгел, ә шул мәчет каршындагы югары уку йортының – мәдрәсәнең мөдәррисе, сәләтле шәкертләрнең яраткан остазы булуын күпләр беләдер инде. Бу шәкертләр бит, мәдрәсәдә укуларын тәмамлагач, мәчет муллалары гына булып китмәгән. Нәкъ менә шулар арасыннан хан канцеляриясендә эшлүче белгечләр, дипломатлар, илчеләр сайлап алынган. Шәкертләрнең бер өлеше язучылар, шагыйрьләр, галимнәр булып өлгергән.

Дини мәктәпләрдә бай кулъязма әдәбият туплаган китапханәләр булган, шунда ук китап күчерүчеләр һәм каллиграфлар эшләгән. Хан сараенда канцелярия эшләрен башкару чиновниклардан югары стиль белән халар яза белү осталыгын, тарих, тел, каллиграфия сәнгатен тирәнтен белүне таләп иткән. Аларны моңа Урта Азия, Кырым, Якын Көнчыгыш шәһәрләреннән махсус чакыртылган профессионаллар өйрәткән. Дини һәм дөньяви фәннәргә караган китапларны сәүдә кәрваннары белән хәтта ерак Шәрык илләреннән кайтартканнар. 1552 нче елда Казан алынганнан соң Явыз Иван тарафыннан Мәскәүгә озатылган Хан китапханәсендә генә дә меңнәрчә том китаплар булган, сирәк кулъязмалар сакланган.

Казанда татар әдәбияты, бигрәк тә поэзия үсә. Ханлык чорында иҗат ителгән әдәби әсәрләрдән Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» «Егетләр бүләге» һәм «Нуры содур» («Күңел нурлары») исемле поэмалары, Өмми Кәмал, Кол Шәриф, Мөхәммәт-Әмин, Гарифбәкнең аерым шигырьләре сакланып калган. Казанда болардан кала да искиткеч фикер ияләре, шагыйрьләр һәм язучылар яшәгән һәм иҗат иткән. Кызганыч, алар калдырган мирас безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән, югалган.

Казан ханлыгында Алтын Урда шагыйрьләре мирасының иң якты дәвамы булып 1552 нче елда Явыз Иван гаскәрләре Казанны камаган вакытта һәлак булган бөек шагыйрь Мөхәммәдьяр иҗаты тора. Үз ватанының тугрылыклы улы буларак, ул ил өстенә ябырылып килгән һәлакәтне авыр кичергән. Аның шигърияте тирән әхлакый нормалар, гаделлек һәм патриотизм рухы белән сугарылган. Гуманист буларак, Мөхәммәдьяр гади кешеләрнең хәлен, авыр язмышын күреп-сизеп торган, матди байлыгына карамастан, һәркемнең тигезлеген икърар иткән. Ул, җәмгыять гаделлеккә нигезләнергә тиеш, чөнки гаделлек «барлык догалардан да кыйммәтрәк» дип санаган. «Нуры содур» поэмасында шәфкатьлелек, юмартлык, тыйнаклык, оят, намуслылык, сүзгә тугрылык, киң күңеллелек кебе игелекләр турында да әйтелә. Бу игелекләр мәңгелек рухи кыйммәтләр булып саналалар.

Халкыбыз күңелендә Кол Шәриф үзенең илһамлы шигърияте, рухи би-

еклеккә өндәүче әсәрләре белән урын алган. Аның бүгенгә кадәр сакланып калган әсәрләре аз: безгә аның бары дүрт-биш шигыре, шул исәптән «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» исемле зур күләмдәге поэмасы һәм дә «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» («Казан иленең җиңүе») дигән чәчмә әсәре генә билгеле.

Кол Шәрифне әдәбият белегечләре суфи шагыйрьләре рәтенә кертәләр. Кол Шәриф үзенең остазлары итеп XII гасырда Урта Азия якларында яшәп иҗат иткән бөек шәхес Әхмәт Ясәвине һәм аның шәкерте Сөләйман Бакырганине саный. Аларның әсәрләре Казан ханлыгы чорында безнең якларда да киң таралган була.

Шигырьләрендә Кол Шәриф Аллаһы Тәгаләгә дан җырлый, аны олыларга өнди, фани дөньяда намус белән, нәфескә бирелмичә яшәп, Аллаһ каршына гөнаһсыз булып барырга чакыра.

Халык арасында Алтын Урданың катлаулы һәм каршылыклы таркалу чоры турында сөйләүче «Идегәй» дастаны тарала башлый. Зыялылар арасында күп кенә төрек, азәрбайҗан, үзбәк, төрекмән шагыйрьләренең әсәрләре уңыш казана. Җәмгыятьнең мәгърифәтле вәкилләре гарәп һәм фарсы телендәге фәлсәфә һәм табигать фәннәре буенча язылган хезмәтләргә еш мөрәҗәгать итә.

Халык риваятьләр, хикәят, дастаннар уйлап чыгарган һәм аларны буыннан-буынга тапшыра торган. Халык авыз иҗатының «Алпамша», «Чура батыр», «Әхмәт турында хикәят», «Җик Мәргән» кебек әсәрләре беркемне дә битараф калдырмаган. Гасырлар үткәч, «Җик Мәргән» дастанының сюжеты күренекле татар композиторы Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил либреттосына язылган «Алтынчәч» операсы нигезенә ятты.

**Россия дәүләте составындагы татарларда ислам.** Казан ханлыгы һәм Мәскәү Русе арасында озак еллар буена барган көрәш 1552 нче елның 2 октябрендә Казан егылу һәм хан биләмәләрен Рус дәүләте составына кертү белән тәмамланды. Казанның егылуы 1556 нчы елда бәйсезлеген югалткан Алтын Урда дәүләте – Әстерхан ханлыгының да язмышын хәл итә. Нәтиҗәдә, рус җирләренең чикләре көньяк юнәлештә шактый киңәя һәм Каспий диңгезенә кадәр килеп җитә. Россия күпмилләтле һәм күпдинле илгә әверелә.

Иван Грозныйның җиңүе татарларның киләчәк язмышы өчен чын афәт була. Алар һуннар һәм борынгы төркләр чорында ук барлыкка килгән дәүләтчелеген югалта. Бер көн эчендә диярлек ханлык башкаласы Казан рус шәһәренә әйләнә. Шәһәрдә яшәп яткан татарларның күп өлеше һәлак була, үтерелә, бер өлеше рус җирләренә әсирлеккә куыла. Калганнары, бик аз өлеше, шәһәрдән куылып, Кабан күленең сазлыклы ярына күчерелә. Биредә берничә дистә гаилә утырган Татар бистәсе барлыкка килә.

Татарлар шулай ук шәһәр катламын, ә аның белән бергә илнең рухи байлыгын булдырырга сәләтле алдынгы өлешен, зыялыларын да югалттылар. Репрессив чаралар ил

белән идарә иткән, ислам кануннарына нигезләнгән халык хокукларының гаранты булган феодаль сыйныфның юкка чыгуга китерә. Яңа хакимиятнең дошманнары булган күпчелек физик яктан юк ителә, ә Мәскәүгә хезмәт итәргә әзер лояль өлеше халык мәнфәгатьләренә җитәрлек дәрәҗәдә игътибар итмәгән һәм православие динен кабул итеп, үз милли тамырларын югалткан.

Казан ханлыгы җимерелүенең иң куркыныч нәтиҗәләренең берсе – татар җәмәгатенең бөтен тормышын, яшәешен тотып торган, аның нигез ташы булып торган ислам идеологиясенең чынбарлыкта законсыз булып чыгуы. Ул кайчандыр рәсми, яшәешнең барлык өлкәләрендә өстенлек иткән дүләт диненнән юкка чыгарылырга тиешле, төрле мәсхәрәләргә дучар булган дингә әверелде. Бу – борынгы төрки заманнардан ук барлык диннәргә толерантлы мөнәсәбәт булган, дини мотивлар буенча җәберләүләр булмаган җәмгыятьтә яшәргә күнеккән халыкның иң зур фаҗигасе иде.

Казан алынганнан соң ук биредә торгызу һәм төзелеш эшләре башлана. Яңа ныгытма – ак ташлы кремль барлыкка килә. Хан заманындагы шәһәрләр һәм җирлекләр урынында – Арчада, Лаешта, Тәтештә һәм башка урыннарда Мәскәү дәүләтенең төрле өлкәләреннән күчеп утырган руслар яшәячәк яңа ныгытма-крепостьлар барлыкка килә. Казан ханлыгы җирләрен үзләштерү башлана. Дәүләтнең сәясәте, беренче чиратта, басып алынган җирләрдә хәрби көчләр урнаштыру, аннан соң шул хәрбиләрнең югары катлавына һәм православие дине әһелләренә җир бүлеп бирүдән гыйбәрәт булган.

1555 нче елда Мәскәүдә уздырылган дини собор Казан өлкәсендә яңа епархия ачарга һәм анда беренче архимандрит итеп сайланган Гурийны җибәрергә карар чыгара. Гурий Казанга бик күп яраннары белән килә. Аларны тантаналы төстә кабул итәләр. «Бу вакыйганың әһәмияте, – дип язып калдырган атаклы рус тарихчысы С.М. Соловьёв, – хәрби яудан ким түгел, чөнки ул православие тәресен беренче тапкыр мөселман иленә баш итеп кую эшен башкарды».

***Бу вакытта Болгар.*** Әйе, ул җимерек хәлдә ята. Тик аны тулысынча ташландык дип санау дөрес булмас иде. Анда мәчетләрнең ярым җимерек биналары һәм хан төрбәләре, кабер ташлары куелган зиратлар... Аларга тирә-юньдә яшәүче мөселман халкы аерым хөрмәт белән караган, үткән буыннар хәтерен саклаучы корылмаларны төзәтеп, тәртипкә китереп торырга тырышканнар, дини бәйрәмнәрдә генә түгел, елның теләсә кайсы фасылында, бигрәк тә җәй көннәрендә, ярымҗимерек Болгар мәчетенә килеп, изге урыннарны йөреп чыгып, намаз кылып, догалар укып киткәннәр.

Мөселман дине православие христианнары ягыннан төрлечә эзәрлекләүләргә дучар булган елларда, мәчетләр аяусыз рәвештә җимертелеп юкка чыккан һәм Исламның биш баганасы булган кагыйдәләрен

«яшерен» мәчетләрдә үтәргә мәҗбүр булган гадәттән тыш авыр шартларда, татарлар Болгарга, ата-бабалар шәһәренә, асылда инде рус авылына әйләнгән, әмма һәр мөселманның күңел түрендә урын алган борынгы һәйкәлләргә омтылалар. Нәкъ менә шул вакытта Идел буе мөселманнары күз алдында Болгар ирексездән үзенчәлекле хаҗ кылу үзәгенә әверелә башлады, ә борынгы һәйкәлләр «изге урыннар» төсен алды.

Җәмигъ мәчете җимерелгән урыннарга һәм изге Хан төрбәсе каберләренә хәтта ерак Азиядән дә килгәннәр, анда хәнәфиләр исламы мәзһәбенең суфия тәрикаты, Урта Идел болгарларында кебек үк, бик популяр булган. 1670 нче елларда Болгар тирәсендә урнашкан һәм бередә дини-агарту эшчәнлеге белән актив шөгыльләнгән шагыйрь һәм дин эшлеклесе Мәүлә Колый язганча, "бу урында төрле яклардан килгән мөселманнар – Казан татарлары, башкортлар, бохаралылар, хивалы һ.б., изге урыннарны зират итеп, намаз укып китәләр».

Исегезгә төшерәбез: югарыда без, Кара пулатның нинди максатларда хезмәт иткәнлеге турындагы фаразлар турында сөйләгәндә, улерактан килгән дәрвишләр өчен сыену урыны булмадымы икән? дигән сорау куйган идек. Бу версия чынбарлыктан ерак түгел кебек: заманында хөкем палатасы сыйфатында файдаланылганнан соң, әлеге корылмада җәен хаҗиларга да яшәргә мөмкинлек булгандыр. Әлбәттә, хаҗилар Болгарда Мөхәммәд пәйгамбәребезнең легендар сәхәбәләре күмелгән каберләр турында да белгән булырга тиешләр. Бу исә аларның күңелләрендә Болгар изгеләренә зират кылырга өстәмә теләк-омтылыш тудырган.

Болгарга «кече хаҗ» кылырга килүчеләрнең һәрдаим артып-өстәлеп торуына пошаманга калган Казан һәм Зөя митрополиты Тихон 1712 нче елда Апраксин фамилияле Казан губернаторына «беркемгә дә кирәк булмаган борынгы таш бина хәрабәләреннән кала буш торган Болгар мөселман шәһәрчеге урынында» монастырь төзү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә. Шундый юл белән, митрополит «кире-беткән мөселман мәҗүсиләренең» Болгардагы «изге урыннар»га сәяхәт кылуларын туктатырга тели.

Губернатор әлеге планны хуплый һәм Андрей Михайлов исемле дьякка булачак монастырь биләмәләренә керергә тиешле урыннар исемлеген төзергә боера. Михайловның хисабында 70 борынгы бина һәм корылма санап кителгән, шул исәптән: «дүрт түгәрәк палата», «хәзерге вакытта унбер сажин биеклектәге манара», «киләчәктә Никольская чиркәве булачак урында теге дүрт түгәрәк палата янында бишенчесе», «татарча язулы зират ташлары сакланган дүртпочмаклы палата», «җиде сажин биеклектәге татар баганасы [манарасы] янында дүртпочмаклы ике мәчет», «тагын бер дүртпочмаклы палата, элегрәк анда чиркәү булган, чөнки ул тирәдә зират ташлары бар, ә ул ташлардагы язулар әрмән язуларына охшаш».

1722 нче елда Болгарга, Идел буйлап Азов походына бару юлында

бераз вакыт табып, император Петр I кереп чыга. Борынгы Болгар манарасының җимерек нигезен күреп һәм аны ремонтларга кирәклеген аңлап, Казан губернаторына бирегә «үзләренең кораллары белән унике яки унбиш кеше һәм берничә мичкә известь җибәрергә <...> һәм әлеге корылманы төзәтергә боера». Император шулай ук җирдә аунап яткан кабер ташларын җыярга һәм андагы «арап язулы» текстларны тәрҗемә итеп, Санкт-Петербургтагы Кунсткамерага тапшырыга әмер биреп китә.

Боерыклар үтәлә: каберташларны Төньяк төрбәгә урнаштыралар, Җәмигъ мәчете янындагы Олы манараның өске өлеше тимер кыршаулар белән нығытыла, түбәсе калай белән каплана. Әмма озак та үтми, 1732–1734 нче елларда Җәмигъ мәчете хәрабәләре янында гына Успенская чиркәве һәм аның чаң башнясы – колокольня төзеп куялар. Әлеге биналарның нигезен салуда Болгар биналарының җимерелгән урыннарыннан җыелган таш блоклар һәм мөселман зиратындагы каберләр өстеннән умырып алынган «арап язулы» ташлар кулланылган.

Борынгы шәһәр территориясендә монастырь салу һәм аның тирәсендә рус авылы барлыкка килү борынгы һәйкәлләрне җимерү процессын көчәйтә. Успенский авылында яшәүчеләр борынгы биналарны сүтеп алынган ташларны хуҗалык ихтыяҗлары өчен файдаланалар, хәзинәләр эзләү белән шөгыльләнә башлыйлар. 1760 елларга шәһәр территориясендә XVIII гасыр башында теркәлгән 70 корылманың 44е генә сакланып калган. Аннан соңгы елларда Болгарга сәяхәт кылучы галимнәр әле күптән түгел генә борынгы биналар торган урыннарда хәзер кызганыч таш-кирпеч өемнәре генә калганын билгеләп үткәннәр.

Төбәкнең мөселман халкында әлеге "яңалыклар» зур ачу хисе тудыра. Шушы шартларда, җимертелгән архитектура һәйкәлләре, зиратлардагы каберташлар рәвешендә булса да борынгы мөселман цивилизациясе, югары үскән болгар мәдәнияте элементларын саклап кала алган Болгар шәһәре Ислам дине кабул ителгән, гыйбадәт һәм «кече хаҗ» кылу өчен Аллаһ үзе күрсәткән изге урын буларак кабул ителә башлый. «Кече хаҗ» Болгарны үзенә ниндидер бер тылсымлы көч белән җәлеп итеп торучы сакраль үзәккә, ата-бабаларыбызның элеккеге даны символына әйләндереп куя.

Бу фактны 1767 елда Болгар харәбәләренә сәяхәт кылган патшабикә Екатерина II үзенең язмаларында билгеләп үтә: "...татарлар бу хәрабәләргә олы хөрмәт күрсәтәләр һәм бирегә Аллаһыга гыйбадәт кылу өчен киләләр. Казан архиерее Лука моңа көнләшеп караган, күп нәрсәләрне җимерткән, ә кайберләреннән, Петр I нең борынгы биналарны җимермәскә дигән указы булуга карамастан, чиркәү һәм азык-төлек саклау базлары ясаткан, монастырь төзеткән». Ун ел узгач, бу сәфәре турында Екатерина II француз философы Вольтерга да хат язган: "Идел буйлап сәяхәт иткән вакытта мин, үземнең баркамны кал-

дырдып, борынгы Болгар шәһәрен карарга киттем ... Мин монда җиде яки сигез таш бина һәм шул кадәр үк манаралар күрдем. Мин янында кырыклап татар басып торган хәрабәләрнең берсенә килдем. Губерна башлыгы бу урынның татарлар өчен изге булып саналуын әйтте: алар монда бик күп киләләр».

***Россия дәүләтенең дини сәясәтендә борылыш*** императрица Екатерина II идарә иткән чорда (1762–1796) башлана. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: 1742 нче елда «Казан губернасында мәчетләр төзүгә юл куймау, губернаторларга һәм воеводаларга яңа чукындырылган кешеләрнең мөселман диненә кире кайтуын тикшерү турында»гы фәрманга кул куйган император Елизавета Петровна, барыбызга да мәгълүм Батырша восстаниесеннән соң, 1756 нче елда чыккан фәрманы белән татарларга мәчет төзергә рөхсәт иткән. Екатерина II вакытында исә, 1773 нче елда, Синод барлык диннәргә тигез караш турында фәрман кабул итә. 1789 нчы елда Уфада мөселман кануннары Диния нәзарәте (мөфтияте) ачылу Россия мөселманнары тормышында зур вакыйга була. Хөкүмәт, бигрәк тә Пугачёв восстаниесе белән бәйле вакыйгалардан соң, Россия халыкларының «мәхәббәт, тынычлык һәм татулыкта» яшәве турында кайгыртырга мәҗбүр булган.

Чынбарлыкта исә мөселман халыкларын христианлаштыру сәясәте 1917 нче елның октябрь вакыйгаларына кадәр дәвам итә. Совет власте исә илебездәге бөтен халыкларны – мөселманнарны да, христианнарны да, яһүдиләрне дә барлык хокукларында, шул исәптән дини хокукларында да, бик үзенчәлекле рәвештә тигезли: бердәнбер коммунистик идеология һәм аның состав өлеше булган сугышчан атеизм хөкем сөргән шартларда барлык дини учреждениеләр – православие храмнары, мәчетләр һәм синагоглар барысы да ябыла.

Әмма татар хаалкы Болгарын онытмый. Аңлашыла ки, Гражданнар сугышы, аннан соңгы коллективлаштыру һәм Бөек Ватан сугышы елларында «хаҗилар» агымы сизелерлек дәрәҗәдә кими. Тик әлеге катаклизмнар халыкта Аллаһы Тәгаләгә булган ышанычны юкка чыгара алмый. Авыр вакытларда, болганчык заманнарда халык күңел тынычлыгы эзли һәм аны Коръән сүрәләрендә һәм аятьләрендә таба. Мәчет-мәдрәсәләрдән мәхрүм ителгән халык яңадан ата-бабаларына, беренче чиратта, әлбәттә, аның мокаддәс һәйкәлләре сакланган Болгарга, Изге чишмә янында тыныч кына гыйбадәт кылырга мөмкин булган Биләр шәһәренә, Казан кремлендәге Сөембикә манарасына тартыла.

Сугышчан атеизмның дин һәм аның «калдыклары» белән көрәш еллары эзсез узмады. 1980 нче елларга кадәр Болгарның изге урыннарына табынырга килүчеләрнең саны сизелерлек кими. Биләрдәге Хуҗалар тавына һәм Изге чишмәгә бару традициясе дә юкка чыгу дәрәҗәсендә иде. Җирле халык еракτан килгән кешеләрне Изгеләр чишмәсенә якын җибәрмәскә кушылган милиция

нарядын да хәтерли әле. Чишмәне бульдозер һәм экскаватор чакыртып күмеп куярга да тырышалар хәтта, тик ул барыбер җир астыннан бәреп чыга. Әйе, шундый заманнар да булган. Әмма дини рухны кешенең күңеленнән көчләп тартып алу, сүндерү ысулларын гына уйлап таба алмаганнар атеист галимнәр.

**Яңарыш: Болгар шәһәре һәм хәзерге дөньяда ислам.** Болгарның тарихи-мәдәни потенциалы – борынгы архитектура һәйкәлләре, 6 чакрымга сузылган ныгытмаларның сакланып калган өлеше; археологик казулар вакытында табылган торак, хуҗалык һәм җитештерү корылмалары калдыклары, күпсанлы матди мәдәният предметлары һәм дә әлегә ачылмаган катламнарда яткан байлыклар – Татарстан республикасының иктисадый һәм мәдәни үсешендә мөһим ресурс булып торалар. Һәм ул ресурс белем бирү һәм агарту, толерантлык, яшь буынга үткән чорлардан калган мирасыбызга сак караш тәрбияләү максатларында актив кулланыла.

Хәтер... Хәтер бурычы... Бу изге бурыч карашыбызны тарихи һәйкәлләребезгә юнәлтергә мәҗбүр итте. Без элек тә әлеге һәйкәлләрне ачыклау, өйрәнү һәм бераз күләмдә булса да саклап калу эшләре белән шөгыльләнә идек. Хәзер исә, ерак бабаларыбызның рухлары тыныч булсын өчен, яхшырак сакланган һәйкәлләрнең элеккеге күренешен, алар яшәгән чордагы әйләнә-тирә мохитен фәнни нигездә реконструкцияләп, үзебезне моннан берничә гасыр элек яшәгән бабаларыбыз җәмгыятендә тоярлык итеп тырышырга кирәк. Бу өлкәдә дә галимнәрнең уңышы күзгә күренерлек.

1989 нчы ел Болгар өчен дә, бөтен мөселман дөньясы өчен дә гадәти булмаган, юбилей елы булды – Россия мөселманнары Идел Болгарында Ислам динен кабул итүнең һиҗри календаре буенча 1100 еллыгын билгеләп үттеләр. Искәртеп узабыз, 1922 нче елда Татарстанда, әлбәттә, тыйнаграк масштабта, Ислам кабул ителүнең 1000 еллыгын бәйрәм итү үткәрелде. Бу вакыйгага Казанда «Ислам кабул итүнең меңъеллыгы» мәчете һәм мәдрәсәсе ачылу белән истәлекле булды, алар бүген дә уңышлы гына эшләп килә.

1989 елда беренче тапкыр ***«Изге Болгар җыены»*** яки «зиярәт әс-салихин» («чишмә башына, асылыбызга кайту») бәйрәме үткәрелде. Бу чараның максаты – тарихыбызны барлау, милли мәдәниятебезгә игътибарны көчәйтү, аны саклап калу һәм торгызу, рухи байлыгыбызны өйрәнү, ислам кыйммәтләренә нигезләнгән халыкның мәдәни-тарихи традицияләрен арттыру, бабаларыбызның дин чисталыгын саклап калу иде.

Бәйрәмнең инициаторы – СССР-ның һәм Себернең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин. Анда Россиянең барлык республикалары һәм өлкәләре мөфтиләре, күпсанлы чит ил кунаклары, журналистлар катнашты. Программгаа борынгы Җәмигъ мәчете янында бәйрәм догасы, Коръән уку бәйгесе, мөфтинең Кече манара янында бәйрәм вәгазе, мөнәҗәтләр

уку, дини бәйрәм рухына туры килерлек репертуар белән татар эстрадасы осталары концерты кертелгән иде.

Бу башлангыч Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Татарстан мөфтие тарафыннан хупланды. 1989 нчы елдан башлап "Изге Болгар җыены» бәйрәме ел саен үткәрелә. 2010 нчы елдан бәйрәмне оештыруга Татарстан Республикасы тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу Республика фонды («Яңарыш» фонды) кушылды. Бәйрәм ачылышында кунакларны һәм Җыенда катнашучыларны гадәттәгечә Татарстан Республикасы Президенты сәламли.

Әйе, хәзер бөтенләй башка эш – Болгар җанланды. Изге Болгар җыенына хәтта Болгария, Румыния, Венгрия, Финляндия, Төркия, АКШ, Германия, Австралия, Кытай һәм БДБ илләреннән татарлар да килә. Язмыш кушуы буенча алар Россиядән читкә чыгып киткәннәр, бүген исә ата-бабалары Ватанына барып кайту мөмкинлеге бар.

Изге Болгар җыенын уздыруда яшьләрнең аерым ролен билгеләп үтәргә кирәк. 1990 нчы еллардан башлап ел саен балалар Сабантуе, төрле конкурслар, ислам динен кабул итүгә багышланган театральләштерелгән тамашалар, Изге Болгар форумнары, ә 1999 нчы елдан – Татар яшьләре фестивале ткәрелә.

Безнең көннәрдә Болгар – уникаль шәһәр-музей, Россия һәм чит илләр мөселманнары өчен сакраль, изге урын. Бу җирдә яшәгән һәм эшләгән, шәһәр төзегән, илен тышкы дошманнардан саклаган бабаларыбыз белән рухи бәйләнешне тоярга ярдәм итәргә сәләтле аурага ия булган урын. Бабаларыбыз монда матур итеп төзелгән таш биналар гына торгызмаганнар, ә татар халкы – болгар бабаларыбызның бөек мирасын саклаучы киләсе буынны да калдырып үлеп киткәннәр. Шуңа күрә, меңләгән мөселманнар Изге Болгар җыенына болгар бабаларына изге гамәлләре өчен рәхмәт әйтергә, искиткеч һәйкәлләрдә гәүдәләндерелгән иҗат эшләре алдында баш иярргә дип киләләр.

***«Болгар» фонды*** – 1989 нчы елда Болгар шәһәренең тарихи истәлекләрен саклау һәм торгызу максатларында төзелгән җитештерү-коммерция оешмасы – озак яшәмәде, әмма үзеннән соң якты эз калдырды: шәһәрлек янында Идел фарватеры тирәнәйтелде. Нәтиҗәдә, «Метеорлар» һәм «Ракеталар» гына түгел, ә дүрт палубалы теплоходлар да Болгар пристанендә тукталу мөмкинлеге алды. Моннан тыш, фонд ярдәмендә шәһәрнең архитектура һәйкәлләре асфальт юл белән тоташтырылды, кафе һәм кибетләр ачылды, сувенир продукциясе, буклетлар һәм юл күрсәткечләр чыгару җайга салынды. Болгар шәһәре яңадан бөтен мөселман дөньясында танылды.

***«Яңарыш» фонды»*** – Татарстан Республикасының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне яңадан торгызу Республика фонды («Яңарыш» фонды) Татарстанның Беренче Президенты М.Ш. Шәймиев инициативасы буенча Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгын, «Свияжск утра-

у-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музеен, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан башка тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен, Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының тарихи, мәдәни һәм рухи традицияләрен, татарларның милли-мәдәни үзенчәлеген һәм традицияләрен саклау һәм үстерүгә ярдәм итү, шулай ук моның өчен кирәкле финанс ресурсларын җәлеп итү максатыннан барлыкка килде. Бу карарны кабул иткәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр дә искә алынды.

Арттырмыйча әйтергә мөмкин: бу Фонд Болгар тарих-архитектура комплексы тарихында яңа этап башлап җибәрде. Соңгы ун ел эчендә тарихи һәйкәлләрне, архитектура ансамбльләрен торгызып кына калмадылар, яңа әһәмиятле корылмалар төзеп, заманча инфраструктура булдырдылар, җирлек территорияләрен төзекләндерделәр, ә иң мөһиме – ата-бабаларыбызның рухи образларын, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен торгызу буенча күп эш эшләделәр.

2014 нче елда Болгар тарих-археология комплексын, ә 2017 нче елда – Успение соборын һәм Зөя утрау-шәһәрчеген ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү Фонд тарафыннан башкарылган эш нәтиҗәләрен халыкара тану булды. Фонд җитәкчесе Татарстан Республикасының Беренче Президенты М.Ш. Шәймиев билгеләп үткәнчә, мөселман һәм православие изге урыннарын бер үк вакытта торгызуның алымы вакыт белән сыналган. Әле 2005 нче елда ук Казан Кремле территориясендә Кол Шәриф мәчете һәм Благовещение соборы яңадан торгызылды. Ә соңгы проектлар арасында – Болгар ислам академиясен төзү һәм Казан Мәрьям Ана иконасы соборын торгызу каралган иде.

Болгар территориясендә мөселман тәңгәллеген күрсәтүче яңа объектлар арасында Ислам дине кабул итүнең истәлек билгесен, Ак мәчетне, Габдрахман коесын һәм, әлбәттә инде, Болгар ислам академиясен билгеләп үтәргә мөмкин.

*Истәлек билгесе (Коръән музее)* 922 нче елда Идел буе болгарлары тарафыннан Ислам динен кабул итү хөрмәтенә куелган. Ул әлеге урынның Идел болгарлары тарафыннан Ислам кабул ителүен, вакыйганың чынлыгын, рухын һәм хисен саклап калучы бердәнбер аутентик чыганак булуын раслый.

Болгар күп гасырлар дәвамында, хәтта Россия тарихының татарларны көчләп чукындыру белән бәйле иң катлаулы чорында һәм Совет хакимияте тарафыннан атеистик идеология көчләп тагылган елларда да табыну һәм хаҗ кылу объекты булып тора. Бу фактор мөселман җәмәгатьчелегенең хаҗилар хәрәкәте үзәкләре вәкилләренең Болгарның Ислам белән бәйле изге урыннарын олылау мәсьәләсенә игътибар белән һәм җитди карауларын китереп чыгарды. XX–XXI гасыр чикләрендә

массакүләм аңда уникаль күренеш – исламның Төньяк төбәгендә мөселман мәдәнияте барлыкка килүне мәңгеләштерү турында таләп формалаша. Бу объектны төзүгә ихтыяҗ шулай ук дини җәмгыятьләрнең һәм оешмаларның, шәхси затларның әлеге символик билгене төзүгә акча җыюны оештыру буенча күпсанлы мөрәҗәгатьләрен тормышка ашыру зарурлыгына да бәйле иде.

Истәлек билгесе – борынгы Болгар архитектурасы рәвешенә туры китереп стильләштерелгән, титаниттан ясалган түгәрәк гөмбәзле, сигез кырлы бина. Түбәсендә – мөселман ярымае.

Үзәк залда, махсус пьедесталда Италия осталары ясаган Коръән урнаштырылган (шуңа күрә бу бинаны Коръән музее дип атыйлар). Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы тарафыннан бу уникаль китап югары сәнгати дәрәҗәдә башкарылуы өчен мәдәни кыйммәт дип танылды. Ул рекордлы үлчәмнәргә ия: озынлыгы 2 метр, киңлеге 1,5 метр, авырлыгы 800 килограмм. Залда доломит, мрамор һәм металлдан эшләнгән Багдад хәлифәсе әл-Моктәдир илчелеге маршрутының күләмле картасы урнаштырылган.

Иң биек катта Татарстан рәссамнарының йөздән артык эшләреннән торган картиналар галереясы, күргәзмәләр һәм конференцияләр үткәрү өчен каралган музей-күргәзмә комплексы урнашкан. Комплекс экспозициясендә археологик табылдыклар, язма чыганакларның төп нөсхәләре һәм күчермәләре, нумизматика һәм зәркәнчелек әйберләре, шулай ук сынлы сәнгать үрнәкләре, шул исәптән Идел буе болгарларының дәүләт дине буларак ислам динен кабул итү көне һәм Алмуш ханның Багдад хәлифе делегациясе белән очрашуы турында сөйли торган мозаика панносы тәкъдим ителә.

Панноның эскиз авторы – рәссам Фәрит Вәлиуллин. Төп һәм иң мөһим тарихи чыганак булып, Әхмәд ибн-Фадланның Иделгә сәяхәте турында «Язмалары» булды. Эскизны төзегәндә бөек татар рәссамы Бакый Урманче мирасы кулланылды, аның тарафыннан татар тарихының Болгар чоры тирән өйрәнелгән. Паннода танылган панорама – елганың матур яры һәм шул тирәдә болгар ханы Җәгъфәр ибн-Абдаллаһның (Алмышның) Хәлифә илчеләре белән Болгар җирендә яшәүче төрле халык вәкилләре катнашында очрашуы сурәтләнгән. Үзәктә – хәлифә әл-Мөктадирның хатын укучы Ибн Фадлан һәм хатыны белән Болгар ханы.

Рәссамнар, тарихчылар, археологлар, этнографлар, дин эшлеклеләрнең зур уртак эше нәтиҗәсендә паннода чагылыш тапкан өс һәм аяк киемнәре, көнкүреш әйберләре, әләмнәр – максималь дәрәҗәдә дөрес итеп сурәтләнгән.

Бу вакыйганың төп һәм иң мөһим тарихи дәлиле – Әхмәд ибн-Фадланның Иделгә сәяхәте турында язган көндәлеге – «Рисалә» («Язмалар»). Ибн Фадлан сәяхәт турында җентекле хисап калдырган, анда тарихи һәм этнографик характердагы уникаль мәгълүматлар китерелгән. «Язмалар»

текстының гарәп, татар, рус, алман телләрендәге басмалары шулай ук Истәлек билгесе экспозицияләрендә тәкъдим ителә.

Истәлек билгесе – Россиянең күпчелек мөселманнары һәм чит илләрнең татар диаспорасы өчен Болгарның дини әһәмияте аның археологик әһәмиятеннән өстенрәк булуын ассызыклаучы үзенчәлекле символ.

*Габдрахман коесы.* Габдархман – болгарлар арасында яңа дин тарату өчен килгән пәйгамбәр сәхәбәләренең берсе. Аның исемендәге кое шәһәрнең төньяк-көнчыгыш читендә, Иерусалим чокырының тамагында урнашкан. Ул элек-электән Болгарга килгән мөселманнар тарафыннан Ислам диненең ата-бабалары җиренә үтеп керүенең беренче адымнарының «тере шаһиты» буларак хөрмәтләнә. Коеның су изге, шифалы дип санала. Коеның урнашу урыны 1998–2002 нче елларда төзекләндерелгән.

*Туйбикә коесы* – изге сулы икенче кое, Болгар шәһәрлегеннән көнбатышка таба 1,5 км ераклыкта урнашкан. Мөхәммәд пәйгамбәр сәхәбәләре тылсымы белән дәвалау тапкан болгар ханы кызы хөрмәтенә аталган. Әлеге коены мөселманнар да, православие динендәгеләр дә изге дип атыйлар, бертигез хөрмәтлиләр. Бу урында, янәсе, 1229 нчы елда Аврамий дигән бер христианны үтергәннәр, ә ул соңыннан чиркәү тарафыннан изгеләштерелгән. Чынбарлыкта исә Аврамий Бөек шәһәрдә – Биләрдә үтерелә. Бу турыда рус елъязмачылары хәбәр итә.

Кое 2004–2007 нче елларда реконструкцияләнгән.

*Ак мәчет* – хәзерге Болгарның горурлыгы һәм Татарстанның архитектура энҗесе – шәһәр читендә, аның көньяк капкасы тирәсендә урнашкан һәм әйләнә-тирә ландшафтка бик тә туры килеп тора. Ул ак Италия мәрмәреннән салынган, төсе тынычлык һәм чисталыкны гәүдәләндерә. «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәре» республика программасы нигезендә һәм «Яңарыш»фонды финанс ярдәме белән төрле илләрнең һәм чорларның ислам архитектурасы үзенчәлекләрен өйрәнеп кайткан Сергей Шәкүров проекты буенча төзелгән. Мәчет 2012 нче елның 10 июнендә, Идел болгарлары тарафыннан Ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгән көннәрдә ачылды. Тантаналы церемониядә Россия Федерациясенең 62 төбәгендәге мөселман җәмгыятьләренең 900дән артык вәкилләре катнашты.

Комплекс бөтендөнья ислам архитектурасының иң яхшы әсәрләре үрнәге булып тора. Комплекс мәчеттән тыш, мәдрәсә (шәкертләре өчен тулай торагы белән) һәм мөфти резиденциясе (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Ислам үзәге) биналарын үз эченә ала. 300 кешегә исәпләнгән гыйбадәт залы булган төп бина симметрик композициянең үзәге булып тора. Мәчет үзе сигезъяклы, күпкатлы гөмбәз белән капланган һәм 10 метр биеклектә (эчтән) яктылык гөмбәзе белән тәмамланган. Гөмбәз нигезен-

дәге тәрәзәләргә витражлар куелган. Гыйбадәт залында хатын-кызлар өчен антресоль бар.

Мәчеткә керү өсте очлаеп торган биек портал рәвешендә. Залның шул ук рәвештә ясалган тәрәзәләре витраж пыялалар белән бизәлгән. Төп бинаның ян-ягында 46,5 метр биеклектәге ике дүртъяруслы манара. Алар Гарәбстанның Мәдинә шәһәрендә мөселманнар хаҗ кыла торган Пәйгамбәр мәчете манаралары стилендә эшләнгән. Мәчет диварлары традицион декоратив элементлар – лалә чәчәкләре, арабесклар, мукарнаслар һәм бина эчендә кабатланмас атмосфера тудыра торган геометрик бизәкләр белән бизәлгән.

Мөфти резиденциясенең ике катлы корпуслары һәм шәкертләр өчен тулай торак бинасы беренче катта а́ркалы галерея белән әйләндереп алынган. Ян биналарның үзәк һәм почмак ризалитлары 88 колонналы *а*ркада рәвешендәге портиклар белән берләштерелгән. Керү урыннары мәчетнең төп порталына охшаш порталлар белән бизәлгән. П-образлы комплекс бәйрәм намазлары өчен билгеләнгән мәйданны колачлый.

Ак мәчет Болгар җирендә дини Ренессанс символын гәүдәләндерә. Ул, кайчандыр борынгы Җәмигъ мәчете кебек, дин тотучыларны үзенә тартып торучы үзәк булып әверелде.

*Болгар ислам академиясе.* 2016 нчы елның 21 нче маенда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми кабул итү көнендә «Изге Болгар җыены» кысаларында Болгар ислам академиясе нигезенә капсула салу тантанасы узды. Капсулада дүрт телдә – татар, рус, инглиз һәм гарәп телләрендә киләчәк буыннарга юллама язылган. Академиянең урнашу урыны ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы үзәге белән килештерелгән. Болгар ислам академиясен булдыру инициативасы белән илнең иң зур үзәкләштерелгән мөселман дини оешмалары: Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте, Россия Федерациясе Мөселманнарының Диния нәзарәте, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте чыкты. Әлеге инициатива Россия Федерациясе Президенты тарафыннан да хупланды.

Болгар, ислам дөньясының төньяк форпосты буларак, һәрвакыт танылган галимнәрне җәлеп итү урыны һәм классик хәнәфи дини мәктәбенең танылган үзәге, шулай ук Каһирә, Истамбул, Багдад һәм Сәмәрканд белән беррәттән, үз чорының танылган интеллектуаль үзәкләреннән берсе булды. Болгар ислам академиясе мөселман өммәтенең бердәмлеген, илдә тынычлыкны һәм татулыкны саклап калырга, ата-бабаларыбызның бай дини мирасын һәм рухи традицияләрен торгызырга тиеш.

Болгар ислам академиясе – белем бирү һәм торак биналар комплексы. Уку барышында «Ак мәчет» һәм Болгар музей-тыюлыгының башка биналары да кулланыла. Ул илебезнең мөселман өммәте интеллектуаль элитасын – ислам дине магистрларын һәм докторларын әзерләүне гамәлгә ашыра. Өстәмә һөнәри белем алу өчен мөмкинлекләр тудырылган. Академиядә бер үк вакытта көндез-

ге һәм читтән торып берничә меңгә кадәр кеше укый ала. Фәнни-педагогик процесста әйдәп баручы белгечләр һәм дин белгечләре катнаша. Танылган чит ил мөселман мәгариф үзәкләре белән тыгыз хезмәттәшлек оештырылган, чит илләрдә югары һөнәри белем бирү системасы эшчәнлеге тәҗрибәсе актив өйрәнелә, ике диплом бирү һәм Иордания, Мисыр, Марокко һәм Сүриянең югары уку йортлары белән уртак белем бирү программалары булдыру мөмкинлеге карала. Татар дини мирасы традицияләрен дәвам итеп, Болгар ислам академиясе әйдәп баручы мөселман фәнни-белем бирү һәм рухи-агарту үзәге булырга тиеш.

**Шәһри Болгар сәнгать әсәрләрендә.** Болгар – бөтен дөньяга танылган шәһәр-музей. Анда ерак бабаларыбыздан калган таш биналарда, гади торак йортларда, хуҗалык-җитештерү корылмаларында һәм казу вакытында табылган әйберләрдә гәүдәләнгән белемнәр һәм казанышларның уникаль җыелмасы тупланган.

Мәчет, төрбә, мунча кебек архитектура корылмаларының калдыклары (аеруча әһәмиятлеләре югарырак тасвирланган иде), консервациядән һәм зур булмаган реконструкциядән соң ачык һавада саклана. Казу эшләре вакытында чыккан табылдыкларның күп өлеше әле күптән түгел генә илебезнең төрле музей фондларында (Дәүләт тарих музее, Мәскәү; Дәүләт Эрмитажы, Санкт-Петербург һ.б.) саклана иде. Табылдыкларның бер өлеше генә Татарстан Республикасы Милли музее экспозицияләрендә күрергә мөмкин иде. Дөрес, Болгарның үзендә дә археология музее булдырырга берничә омтылыш булган. Күпләр әле музей экспозицияләрен Успение чиркәвендә дә хәтерли, ләкин ул да Болгар коллекцияләренең барлык байлыгын күрсәтә алмады.

Һәм менә «Яңарыш» фонды эшчәнлегенең беренче елында ук, ягъни 2010 елда, ***Болгар цивилизациясе музеен*** булдыру турында карар кабул ителде.

Музей өчен Болгар шәһәрлегенең Иделнең югары террасы сөзәклегендә алты катлы яңа монументаль бина төзелгән. Аның архитектурасы урта гасыр Болгар корылмаларының архитектурасы белән аваздаш. Бинаның төп өч күләмен (төп корпус һәм ике башня-ротонда) Болгар, Сувар, Биләр шәһәрләрен символлаштыра.

2013 нче елның маенда Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы структурасына керүче Болгар цивилизациясе музее ачылды. Музейның төп экспозицияләре 2 мең квадрат метр мәйданда өченче һәм дүртенче катларда урнашкан һәм өч төп өлештән тора: «Борынгы Болгарны ачу» «Болгар цивилизациясе тарихы» һәм «Борынгы Болгар: шәһәр тормышы». Экспозицияләрдә Болгар дәүләт тыюлыгы, Татарстан Республикасы археология музее фондларыннан 1600дән артык чын әйбер, шулай ук Иске Казан һәм Биләр дәүләт музей-тыюлыклары, Дәүләт Эрмитажы, Дәүләт тарих музее, Мәскәү Кремле музейлары, Чуваш дәүләт педагогика университетының

археология-этнография музее һәм, Нью-Йоркның (АКШ) Метрополитен музее коллекцияләреннән алынган предметларның күчермәләре тәкъдим ителә. Болгар цивилизациясе музеенда Болгар архитектура һәйкәлләренең макетларын, Болгар халкының антропологлар тарафыннан реконструкцияләнгән скульптур портретларын күрергә мөмкин.

Борынгы Болгар һәм башка Болгар шәһәрләренең казылма әйберләрен күрсәтеп кенә калмыйча, хунн/гуннар, Түрк каһанлыклары, Бөек Болгар һәм Хазар каһанлыгы чорыннан башлап төрки-татар цивилизациясе тарихы турында сөйләүче бүлекләр дә килүчеләр арасында зур кызыксыну уята. Чын хәзинәләр Җучи олысының шәһәр мәдәниятенә һәм урта гасыр чорындагы татар дәүләтләренә багышланган бүлекләрдә тәкъдим ителә. Болгар цивилизациясе музееның берничә бүлеге Исламның болгар мәдәниятендә тоткан ролен чагылдыра.

Биредә «Болгар цивилизациясе. Мәңгелеккә озын юл» дип исемләнгән күргәзмәнең Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булганын да әйтеп китәргә кирәктер.

Болгарның рухи мирасы, Идел Болгары һәм Алтын Урда башкаласының якты һәм бай тарихы татар сынлы, театр һәм музыка сәнгате, сәнгать әдәбияты һәм шигърият, гомумән, милли мәдәният үсешенә көчле этәргеч ясады. 1990 еллар башында, милли яңарыш барышында татарларның иҗтимагый аңында идеологик стереотиплардан арынып, тарихка, мәдәни мираска, халыкның гореф-гадәтләренә һәм рухи кыйммәтләренә ихтыяҗ зур булган чорда, татар тарихчыларының, прозаикларның, шагыйрьләрнең һәм рәссамнарының күп санлы әсәрләре иҗат ителде. Болгарның күпгасырлык тарихындагы фаҗигале вакыйгалар халык иҗаты әсәрләрендә – риваятьләрдә, легендаларда, тарихи җырларда һәм дастаннарда чагылыш тапкан. Алар заманча милли мәдәниятнең яңа әдәби һәм музыкаль әсәрләрен булдыру өчен нигез булып торалар.

Иң кызыклы үрнәкләр, яңа иҗади уңышлар арасында премьерасы Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры сәхнәсендә 2013 нче елда тамашачы хөкеменә тәкъдим ителгән, бөек цивилизациянең һәлак булу темасына багышланган «Алтын Урда» исемле балетны күрсәтергә кирәк. Спектакльгә либреттоны Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, музыканы талантлы композитор Резедә Ахиярова язган. Балетның нигезенә көчле мәхәббәт кичерешләре, бәхетле һәм бер үк вакытта фаҗигале мәхәббәттә кискен борылышлар, хакимлеккә ашкыну, мәкерле хыянәт, җиңү тантанасы һәм җиңелү ачысы һәм шул ук вакытта безнең көн өчен мөһим тарихи үткәннең гыйбрәтле дәресләре.

Тамашачылар һәм музыка тәнкыйтьчеләре арасында зур кызыксыну уяткан 2013 нче елның тагын бер истәлекле вакыйгасы – балетмейстер

Григорий Ковтунның яшь композитор Эльмир Низамов музыкасына «Кара пулат» операсын сәхнәләштерүе. Болгар тарихының легендар сюжетларына куелган спектакльгә либретто Ренат Харис тарафыннан язылган иде. Опера урта гасырдагы сарайларны һәм мәчетләрне декорацияләрдә куллану максаты белән Болгар шәһәре территориясендә кую өчен махсус әзерләнгән иде.

Ренат Харисның тарихи үткәне белән кызыксынуы күп санлы шигъри әсәрләрдә, аерым алганда, «Ант касәсе» поэмасында чагылды. 2005 нче елда шагыйрьнең зур күләмле эшләренең берсе – «Кыйссаи Йосыф» балеты либреттосы әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Россия Федерациясенең Дәүләт бүләгенә лаек булды. Либреттоның нигезе итеп Гүзәл Йосыф – танылган болгар шагыйре Кол Гали поэмасының төп герое турындагы легенда алынган. Спектакль кеше яшәешенең матурлыгы һәм мәгънәсе турында. Ул – Муса Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрының иң уңышлы проектларыннан берсе.

Болгар образы хәзерге татар шагыйрьләренең дистәләрчә әсәрендә, Кара пулат һәм Кече манара фонында үз клипларын төшерергә яратучы эстрада артистларының җыр репертуарында, Казан кремле һәм Кол Шәриф мәчете диварларында сурәтләнгән. Россия Федерациясенең атказанган артисты Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор ансамбле, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбле репертуарларында Болгар тематикасы лаеклы урын алды.

Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Флүс Латыйфи, Вахит Имамов, Марат Әмирханов һәм башка татар язучыларының урта гасыр болгар-татар тарихының, шәхесләренең сәнгати реконструкцияләрендә уңышлы чагылыш тапкан тарихи романнары халык тарафыннан киң танылды.

Рәссамнарның иҗатын аерым ассызыклап үтәсе килә. XIX гасырның беренче яртысыннан ук борынгы болгар-татар һәйкәлләре Россия һәм чит ил рәссәамнәренең игътибарын җәлеп иткән. Без беренче чиратта 1837 нче елда инглиз Эдуард Турнереллиның натурадан төшерелгән Болгар архитектурасы һәйкәлләрен, француз Андре Дюранның 1849 нчы елда Парижда нәшер ителгән «Россиянең рәсем сәнгате һәм археология буенча сәяхәт альбомы»на кергән литографияләрен күз алдында тотабыз.

Рәсем сәнгатендә әлеге юнәлеш рус пейзажчылары – бертуган Григорий һәм Николай Чернецовлар (1802–1865; 1805–1879) язган картиналарда дәвам итә. Ул картиналарда без Олы һәм Кече манара, Көнчыгыш мавзолей, Ак Һәм Кара пулатлар кебек архитектура һәйкәлләрен күрәбез. Атаклы якташыбыз Иван Шишкин (1832–1898) «Борынгы Болгар архитектурасы һәйкәлләре» дигән рәсемнәр сериясен язган.

Советлар хакимияте чорында бары тик 1970 нче еллардан башлап кына ерак тарихыбызга, шул исәптән

болгар борынгылыкларына карата кызыксыну уяна. Бөек Болгар Рәшит Госманов, Бакый Урманче акварельләрендә, бераз соңрак Канәфи Нәфыйков, Рифкать Вахитов акварельләрендә гәүдәләнә. Алар арасында Бакый Урманченың «Ибн Фадланның Болгарга килүе» картинасы (1973) аерылып тора.

Алга таба рәссамнар иҗатында Болгар тематикасы киңәя бара, моңа К. Нәфыйковның «Болгар урамы» (1975), «Ага-Базар» (1976), «Чүлмәкче остаханәсендә» (1979), «Болгарда чуен коючылар» (1980) һ. б. картиналары дәлил. 1990 нчы елларда Рифкат Вахитов иҗатында Казан чоры башлана. Ул ерак бабаларыбызның тарихын үзенчә күрә һәм аңлый белә. Мисалы – «Болгар иле турында легенда» картинасы.

Күренекле татар рәссамы Фиринат Халиков иҗаты бүгенге Татарстанның сәнгать дөньясында үзенә бер аерым урын алып тора. Аның профессионал тарихчылар белән хезмәттәшлек нәтиҗәсе булган күпсанлы картиналарын карап, тарихыбызның Идел Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларын яхшы өйрәнергә була.

Болгар-татар тарихының таныш сюжетларын һәм образларын без рәссамнар Равил Заһидуллин, Рушан Шәмсетдинов, Илгизәр Самакаев, Фәрит Якупов, Фәрит Вәлиуллин, Булат Гыйльванов, Рөстәм Хуҗин, Мөдәррис Минһаҗев һ. б. күренекле рәссамнар әсәрләрендә табабыз.

Кол Галинең скульптура һәйкәлләре Болгарда, Казанда һәм Ульяндა, XI гасырда идарә иткән Болгар әмире Ибраһим һәйкәле Алабугада куелган.

Татарларның урта гасыр дәүләтчелеге, Болгар шәһәре һәм ислам – бу триада безнең сәнгаткярләребезне киләчәгебез хакына яңа әсәрләр иҗат итүгә рухландырачак әле.

* * *

Уникаль архитектура һәйкәлләре булган Болгар тарих-археология комплексы – X–XV гасырларда Урта Идел һәм Урал буе территориясендә югары үсеш алган цивилизациянең барлыкка килүен дәлилли. Бу цивилизацияне барлыкка китерүче һәм үстерүче – Бөек Идел юлында эре сәүдә үзәге һәм шәһәрләр иле буларак танылган Болгар дәүләте. Шул дәүләт исемен йөрткән шәһәргә – Болгарга 922 нче елның маенда Багдад илчелеге килә һәм берничә көннән соң биредә, күпсанлы болгар халкы һәм аларның Җәгъфәр атлы әмирләре катнашында Ислам динен рәсми рәвештә кабул итү тантанасы була.

Болгар дәүләтенең, Алтын Урданың, Казан ханлыгының болгар-татар халкы тормышында, соңыннан Россия дәүләте составында исламның ролен бәяләп бетергесез. Ислам Идел-Урал төбәгенең һәм Себернең төрки телле халыкларының этник берләшүенә ярдәм итте. Авыр һәм катлаулы шартларда ул безгә бербөтен халык буларак сакланып калырга, үзенчәлекле мәдәниятебезнең байлыгын арттырырга, менталитет формалаштырырга һәм милли характер булдырырга ярдәм итте. Ислам диненң гасырлар барышында сыналган рухи-әхлакый кыйммәт-

ләре Россия татарларының үзаңына һәм милли психологиясенә әверелде. Ислам цивилизациясенең бер өлеше буларак, илнең мөселман халыклары һәм аларның мәдәнияте Россия цивилизациясенең мөһим компонентына әверелде, аның социомәдәни үзенчәлеген формалаштыруга сизелерлек йогынты ясады.

Болгарда XIII–XIV гасырларга караган уникаль архитектура һәйкәлләре саклanган, алар бүгенге көнгә кадәр урта гасырлар чорының мөселман сәнгатен өйрәнүчеләренең игътибарын җәлеп итеп торалар. Бу һәйкәлләр Көнчыгыш Европаның инде күптән юкка чыккан ике дәүләтенә – Идел Болгары белән Алтвн Урдага мөнәсәбәтле. Хәзерге заман шәһәр архитектурасы үз милли үзенчәлекләрен тулысынча диярлек югалткан шартларда белгечләрнең Болгар архитектура шедеврларына мөрәҗәгать итәргә өндәүләре бик актуаль һәм таләпчәнрәк яңгырый башлады.

Болгарда барлыкка килгән мәгариф системасы традиция буенча Казан ханлыгында дәвам итә һәм, берникадәр тәнәфестән соң, XVIII–XIX гасырларда Казан, Оренбург, Уфа һәм Россиянең башка шәһәрләрендәге югары дини уку йортларында яңадан торгызыла. Мөселман реформаторлыгы – җәдидчелек – XIX гасыр ахырында Казанда формалаша һәм Евразиянең бөтен территориясендә ислам динен тотучы халыклар арасында тарала. Эпиграфик һәйкәлләрдә, төрбәләрдә дини эчтәлектәге язулар, мәчет диварлары янында аерым каберлекләр – суфичылык белән бәйле барлык гореф-гадәтләр Алтын Урда, Казан ханлыгы чорында барлыкка киләләр һәм Россия дәүләте кысаларында да югалып калмыйлар.

Болгарда рус халкының яшәеше белән бәйле археологик артефактларның шактые, әрмән телендә язылган кабер плитәләре куелган зират, «Грек палатасы» дип аталган христиан чиркәвенең археология калдыклары, башка күренекле матди объектлар мөселман һәм христиан диннәренең үзара бәйләнеше турында сөйли, Болгар илендә төрле дин йолаларын һәм ритуалларын үтәү ирeгeн күрсәтә.

Ислам динен тотучы татар халкы һәрвакыт башка дин вәкилләренә зур хөрмәт белән карады. Мондый менталитет, үзенә хас дини толерантлык белән, VI–VIII гасырларда ук борынгы төрки мохиттә формалаша башлый һәм Идел буе Болгарында һәм Алтын Урдада тулысынча калыплаша. Алты миллионлы татар халкы бүген дә башка халыклар белән дус һәм тату яшәргә омтыла, үз мәдәниятен һәм гомумән дөнья мәдәниятен баета торган мәдәниятара, төбәкара һәм этникара бәйләнешлар процессында үзара кыйммәтләр алмашуның мөһимлеген аңлый.

## Файдаланылган әдәбият

*Белавин А.М., Иванов В.А.* Восход золотого полумесяца над Восточной Европой (Начальные этапы утверждения ислама в Урало-Поволжье). Уфа: Изд-во Башкир. гос. пед. ун-та, 2011. 135 с.

Великий Болгар / Науч. ред. А.Г. Ситдиков. М.; Казань: Феория, 2013. 404 с.

Город Болгар. Монументальное строительство, архитектура, благоустройство / Отв. ред. Г.А. Фёдоров-Давыдов. М.: Наука, 2001. 365 с.

*Давлетшин Г.М.* Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 431 с.

*Измайлов И., Хамидуллин Б.* Ислам в Золотой Орде. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. 63 с.

Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье: история и современность. Очерки / Отв. ред. Р.М. Мухаметшин. Казань: Мастер Лайн, 2001. 452 с.

Ислам. Энциклопедический словарь / Ред. Г.В. Милославский, Ю.А. Петросян, М.Б. Пиотровский. М.: Наука, 1991. 315 с.

*Махмутов М.И.* Мир ислама: прошлое и настоящее. Казань: Центр инновационных технологий, 2006. 616 с.

Музей болгарской цивилизации. Т. I. Древний Болгар: жизнь города / Авт.В.С. Баранов, Д.Г. Бугров, А.Г. Ситдиков. Казань: Главдизайн, 2016. 267 с.

Музей болгарской цивилизации. Т. II. История тюрко-болгарской цивилизации / Авт. В.С. Баранов, Д.Г. Бугров, А.Г. Ситдиков. Казань: Главдизайн, 2016. 254 с.

Музей болгарской цивилизации. Т. III. Открытие древнего Болгара / Авт.Х.М. Абдуллин. В.С. Баранов, Д.Г. Бугров, А.Г. Ситдиков. Казань: Главдизайн, 2016. 254 с.

*Мухаметшин Д.Г.* Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Казань: Ин-т истории АН РТ, 2008. 132 с., ил.

Очерки истории исламской цивилизации. Т. 1 / Под общей ред. Ю.М. Кобищанова. М.: РОССПЭН, 2008. 936 с.

Очерки по истории татарской культуры (в контексте «Запад – Восток»). Казань: «Фикер», 2001. 624 с.

*Хузин Ф.Ш.* Исследования по булгаро-татарской археологии. Казань: Фолиант, 2011. 468 с.

(Бу хезмәт А.Г. Ситдыйков белән берлектә язылды).




*Рәс. 1. Идел Болгарстаны биләп торган җирләр*




*Рәс. 2. Алмыш хан / Җафар ибн-Абдаллаһ. М. Горелик рәсеме*



*Рәс. 3. Болгар хакиме Җафар ибн-Абддаллаһ хакимлеге вакытында чыгарылган көмеш дирһәмнәр В. Кулешов буенча*



*Рәс. 4. Багдад илчелеген Болгар иленә җибәргән хәлифә әл-Мөкътәдир чорында сугылган гарәп дирһәмнәре*



*Рәс. 5. Җафар ибн-Абдаллаһның Ибн Фадлан белән очрашуы. Р. Шәмсетдинов рәсеме*



*Рәс. 6. Болгарда Ислам динен рәсмиләштерү тантанасы*



*Рәс. 7. 922 елның 16 мае. Багдад илчелеге сәркатибе Әхмәд ибне Фадлан болгар ханы Җафар ибн-Абддаллаһ алдында әл-Мөкътәдир хәлифәнең хатын укый. В. Лаптев рәсеме*



*Рәс. 8. Җафар ибн-Абдаллаһ, Багдад илчелеге башлыгы Сусан әл-Расси һәм Ибн Фадлан мәҗлестә. Р. Шәмсетдинов рәсеме*



*Рәс. 9. 1869 елда Спас өязендә табылган догалык – Коръән сүрәләрен саклау өчен кулланыла торга көмеш футляр. Дәүләт Эрмитажында саклана*



*Рәс. 10. Биләр шәһәрлеге. 1973 елгы аэрофото*



*Рәс. 11. Биләрнең Җәмигъ мәчете һәм аның янындагы тәһарәтнәмә хәрабәләре. 1975 елгы аэрофото*



*Рәс. 12. Биләр. Җәмигъ мәчетенең агачтан салынган бинасы.*
*IX гасыр ахыры – X гасыр башы. Н.Х. Халитов реконструкциясе*



*Рәс. 13. Биләр. Җәмигъ мәчетенең 922 елда таштан салынган бинасы.*
*Н.Х. Халитов реконструкциясе*

*Рәс. 14. Биләр. Тәһарәтхана хәрабәләре консервациядән соң.*





*Рәс. 15. Тәһарәтхана бинасы. Э.Д. Зиливинская реконструкциясе*



*Рәс. 16. Биләр төзелә. Ф. Халиков рәсеме*



*Рәс. 17. Коръән сүрәләре язмаларын саклау өчен ясалган китап тышлыгы. Биләрдә табылган. Казан сәүдәгәре В.И. Заусайлов коллекцияләреннән. Хельсинкидагы Финляндия Милли музеенда саклана*



*Рәс. 18. Биләр. Өчаяк (трипод) тоткасындагы рун язуы. XII гасыр. Ф.Ш. Хуҗин казылмаларыннан*



*Рәс. 19. Биләр. Гарәпчә язулы йозак. 1146/47 ел. Әбүбәкер бине Әүхмәд оста эше. Татарстан Милли музеенда саклана*



*Рәс. 20. Язу-сызу әсбаплары: каләмнәр, кара савытлары. Биләр археология музее коллекцияләреннән*



*Рәс. 21. Биләрдә табылган Иран касәсе. XI гасыр. А.Х. Халиков казылмаларын-нан*



*Рәс. 22. Биләрдә рус осталары яшәгән утарда табылган гәрәбә. Ф.Ш. Хуҗин казылмаларыннан*




*Рәс. 23. Биләрдә табылган пыяла савытлар. С.И. Вәлиулина казылмаларыннан*



*Рәс. 24. Биләр. Алтыннан эшләнгән чигә алкалары. Татарстан Милли музеенда саклана*



*Рәс. 25. Суварның саклану стеналары. А.П. Смирнов реконструкциясе*



*Рәс. 26. Сувар сарае. Ф.Х. Вәлиев реконструкциясе*



*Рәс. 27. Суварда сугылган көмеш дирһәм*



*Рәс. 28. Борынгы Алабуга-
ның агач ныгытмалары.
Реконструкция*



*Рәс. 29. Алабуга.
Болгар чорыннан
калган саклану
башнясы һәм
Ак мәчет хәрабәләре*



*Рәс. 30. Биләр казу эшләреннән табылган Всеволод Зур Ояның асылмалы мөһере*



*Рәс. 31. Болгар әмире Ибраһимга һәйкәл. Алабуга*




*Рәс. 32. Кол Галигә куелган һәйкәл*



*Рәс. 33. Болгарда Үзәк мәйдан*



*Рәс. 34. Болгарның үзәк өлеше консервация һәм реставрациядән соң: Җәмигъ мәчете, аның янында Успение чиркәве, сул якта – Төньяк төрбә (мавзолей), уң якта – көнчыгыш мавзолей, ерактарак – Бату хан резиденциясе, алдагы планда – Алтын Урда чорына караган торак йорт урыннары*



*Рәс. 35. Төньяк төрбә. Бирелә эпиграфика истәлекләре – каберташлар саклана*



*Рәс. 36. Көнчыгыш төрбә*



*Рәс. 37. Кече манара янында Хан төрбәсе*



*Рәс. 38. Кара пулат (хөкем сарае? Хан төрбәсе?)*




*Рәс. 39. Ак пулат – XIV насыр мунчасы. 1990 елларда консервацияләнгән*



*Рәс. 40. Бөек Ефәк юлында сәүдә кәрваны. Р. Җанибәков рәсеме*



*Рәс. 41. Насир лид-Дин акчалары*



*Рәс. 42. «Бату» тамгалы Мөнкә хан акчалары*



*Рәс. 43. Җанибәк хан акчалары*



*Рәс. 44. Җүкәтауда табылган XIV гасыр акчалары*

*Рәс. 45. Туктамыш хан чорында күмелгән Каратун акча хәзинәсе*





*Рәс. 46. Алтын-көмеш кубок. XIV гасыр*



*Рәс. 47. Алтын-көмеш савыт. XIV гасыр*



*Рәс. 48. Байлар өстәленә куела торган савыт-саба фрагментлары*




*Рәс. 49. Чистай шәһәренең татар зиратында XIV йөздә куелган каберташлар*




*Рәс. 50. Казан ханлыгының төп җирләре*




*Рәс. 51. Казан кремле анспмбле*



*Рәс. 52. Казан кремле. Президент резиденциясе территориясендә казу эшләре*




*Рәс. 53. Президент резиденциясе территориясендә казып тикшерелгән таш бина хәрабәләре. XVI гасырның беренче яртысы*



*Рәс. 54. Казан кремленең төньяк-көнчыгын өлешендәге тау итәгендә урнашкан торак йортларның берсе тире эшкәртү остаханәсе булып та хезмәт иткән; урам түшәмәсе урталай ярылган бүрәнәләрдән ясалган*



*Рәс. 55. Казан кремле территориясендә, хәзерге Кол Шәриф мәчете тирәсендә казып чыгарылган мунча бурасы. XVI гасыр уртасы*




*Рәс. 56. Сөембикә манарасы белән Ввведение чиркәве арасында Хан мәчете хәрабәләре*



*Рәс. 57. Ханнар төрбәсендә казу эшләре. 2005 ел*



*Рәс. 58. Ханнар төрбәсе хәрабәләре*



*Рәс. 59. Ханнар төрбәсе консервациядән соң (1977 елгы казылмалар)*



*Рәс. 60. Ханнар төрбәсенең бүгенге күренеше.*
*Пыяла колпак астында төрбәнең 2005 елда ачылган өлеше.*



*Рәс. 61. Мәхмүд хан. Антрополог Т. Балуева реконструкциясе*



*Рәс. 62. Мөхәммәд-Әмин хан. Антрополог Т. Балуева реконструкциясе*



*Рәс. 63. Шагыйрь Мөхәммәдьяр.*
*Р. Шәмсетдинов рәсеме*



*Рәс. 64. Мөхәммәд-Әмин хан заманында сарай остасы Насыйр ясаган язулы кувшин. XVI гасыр башы*










## ЕВРОПА ХАЛЫКЛАРЫ ТАРИХЫНДА ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕНДӘ БОЛГАРЛАР МИРАСЫ

Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа халыклары тарихында, бигрәк тә аларның килеп чыгышында, матди һәм рухи культуралары формалашу процессында урта гасырлар чоры болгарларының ролен аныклау мәсьләләсе галимнәрнең игътибарын элегрәк тә җәлеп итеп торды. Әле кайчан гына тарих фәнендә болгарларны хәзерге Идел-Урал татарларының бердәнбер борынгы бабалары итеп карау өстенлек итеп килә иде. Дөрес, башка компонентлар да кире кагылмады, әмма Алтын Урда чорында барлыкка килгән тирән этник үзгәрешләр исәпкә алынмады. 1980 нче еллар ахырында башланып киткән фәнни бәхәсләр барышында исә Идел болгарларының татар этногенезындагы роле бик нык киметелеп күрсәтелде, хәтта ки бөтенләй диярлек инкарь ителде. Кайбер мөхтәрәм галимнәребез Медисон (АКШ) университеты профессоры Юлай Шамилоглу хезмәтләрендә әйтелгән сәер фикергә (Shamiloglu, 1991, p. 157–163) җиңел генә ияреп, болгарларның күп өлеше монгол-татар яуларыында үлеп беткән, калганнары XIV йөз урталарында бөтен Европага таралган чума пандемиясендә юкка чыккан, дип яздылар (Әхмәтҗанов, 1997). Тик нишләп соң ул чумада югары цивилизацияле, ислам дине таләп иткән чисталыкны-пөхтәлекне яшәү рәвешенә әверелдергән болгарлар гына үлеп беткән, ә аларның мәҗүси күршеләре, бигрәк тә чума котырынган Сарай халкына якынрак торган кыпчаклар, мордвалар һәм башка халыклар исән калган?

Болгар бабаларыбызны монгол яулары нәтиҗәсендә күчеп утырган, сан ягыннан күпчелекне тәшкил иткән татарлар арасында «эреп» беткән, ягъни ассимиляцияләнгән

бер халык итеп караудан «болгарчы» галимнәрнең кире кага алмаслык дәлилләре генә саклап калды.

Соңгы елларда тарихчылар, татар халкының бердәм этник тамыры юк, аның озак гасырларга сузылган этнос буларак оешу процессында һуннар, болгарлар, кыпчаклар һәм нугайлар кебек күчмә дала халыклары да, күрше фин-угырлар һәм славян-руслар кебек утрак тормышта яшәүче урман һәм урман-дала халыклары да катнашкан, дигән уртак фикергә килделәр (История татар ..., 2002, с. 5–6). Бу нигездә дөрес фикер, әмма югарыда санап кителгән этник компонентлар татарларның төрле этнографик төркемнәрен барлыкка китерүдә бер дәрәҗәдә катнашмаганнар (кыпчак компоненты, мәсәлән, мишәрләрдә, болгар компоненты Урта Идел татарларында, җирле фин компоненты керәшеннәрдә ачыграк сизелә).

Болгар мирасы турында сүз барганда, әлбәттә, тугандаш чуаш халкының килеп чыгышына караган мәсьәләләрне дә читләтеп үтәргә ярамый. Бүгенге көндә Чуашстан галимнәре арасында әле XX йөз башларында ук Н.И. Ашмарин тарафыннан тәкъдим ителгән болгар-чуаш тәңгәллеге теориясе өстенлек итә (Ашмарин, 1902; Димитриев, 2004). Татарлар – безнең якларга 1236 елда килеп төпләнгән монгол-татар калдыклары, имеш; димәк, аларның болгар мирасына дәгъва кылырга хаклары юк булып чыга. Соңгы елларда көндәлек матбугат битләрендә генә түгел, хәтта фәнни хезмәтләрдә дә, чуашларның исемен «сувар-болгар»га алыштырырга кирәк, дигән катгый таләпләр яңгырый башлады. Имештер, «чуаш» дигән «аһәңсез социаль этноним XVI гасырдан башлап системалы рәвештә геноцид кичергән сувар-болгар халкына карата патша чиновниклары тарафыннан аңлы рәвештә кимсетелеп кулланылган» (Ювенальев, 2012, с. 293).

Башкорт тарих фәнендә, бигрәк тә археологиядә, болгар мирасына бәйле проблемалар чагыштырмача күптән түгел, әмма шактый кискен формада калкып чыкты. Башкорт галимнәре раславынча, республиканың татарлар – «башкортларның төньяк-көнбатыш этнографик төркеме» – яши торган төбәкләр Идел Болгарының аерылмас бер өлешен тәшкил иткән. Урта гасыр чорына караган «башкорт шәһәрләре» исемлегенә алар Чаллы һәм Алабуганы гына түгел, хәтта борынгы рус елъязмаларында «Олуг шәһәр» исеме белән аталган Биләрне дә кертәләр. XII гасыр ахырында – XIII гасырның беренче яртысында иҗат иткән мәшһүр шагыйрь һәм фикер иясе, «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының авторы Кол Гали, «Болгар тарихы»н язган хокук белгече (кади) Йакуб ибн Ногман башкорт кавеменнән чыккан шәхесләр дип игълан ителә (Мажитов, Султанова, 2010, с. 327–328; Мажитов, 2013, с. 100–102).

Археология язма чыганакларга, антропология, этнография, лингвистика кебек гуманитар фәннәр тарафыннан тупланган материалларга нигезләнеп, урта гасыр болгарларының хәзерге халыклар тарихына һәм мәдәниятенә керткән өлеше турын-

дагы бәхәсле проблемаларга шактый дәрәҗәдә ачыклык кертә ала.

Сүзне болгарларның Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европада таралып утырган, тереклек кылган җирләрен билгеләүдән башлыйк. Ышанычлы чыганаклардагы болгар кабиләләре турында иң борынгы хәбәрләр V гасырга карый (Сиротенко, 1961, с. 47). Заманында көнчыгыш тарафтан һуннар урдасы белән күченеп килгән болгарлар Азов һәм Кара диңгез буйларында, Төньяк Кавказ далаларында төпләнеп калганнар, башлыча күчмә тормыш алып барганнар. Тиздән алар Көнбатыш Европадагы хәрби-сәяси вакыйгаларда актив катнаша башлыйлар – Византия императоры аларны союздашлары һәм хәрби ялчылары сыйфатында үзенең дошманнарына каршы көрәштә файдалана. Әле 475 елда ук болгарлар, Византия чикләренә китеп барышлый, Дунай буйларына килеп чыгалар (Сиротенко, 1972, с. 202).

Азов һәм Төньяк Кара диңгез далаларында көн күргән төрки кабиләләр VII гасырда Кубрат хан идарәсендәге Бөек Болгар дәүләте составына керәләр. Кубрат болгарлары калдырган археология һәйкәлләре башлыча аерым каберлекләрдән һәм әйбер хәзинәләреннән гыйбарәт. Дәүләтнең башкаласы антик чордан калган Фанагория булган, дип фаразлана (Рашев, 2004; Комар, 2006; Комар, Кубышев, Орлов, 2006). 660 нчы елларда хазарлар тарафыннан җиңелеп, Бөек Болгар дәүләте таркалганнан соң халыкның бер өлеше Дунай якларына, ә икенче өлеше Урта Иделгә күчеп китәләр (биредә алар үзләренең мөстәкыйль дәүләтләрен төзиләр). Калганнары исә, «җирле» болгарлар, Хазар каганаты составында яшәүләрен дәвам итәләр, әкренләп күрше төбәкләргә дә үтеп керәләр – алар калдырган археология һәйкәлләре Кырымда һәм Төньяк Кавказда күп таралган. VIII–IX гасырларда яшәгән болгарларның археологик эзләре (керамика, сугыш кораллары, ат дирбияләре, бизәнү әйберләре) хәзерге Украина, Молдавия, Румыния һәм Венгрия территориясендә дә күпләп табыла (Die Keramik ..., 1990). Бу җирләргә алар Хазар каганатыннан һәм Дунай Болгариясеннән таралып утырганнар.

Идел Болгарстанының монголларга кадәрге чикләре аның бүгенге көннәргә кадәр сакланган 2 меңгә якын археология һәйкәлләрен картага төшерү (картографияләү) нигезендә ярыйсы гына төгәл ачыкланган (Фахрутдинов, 1975). Ул һәйкәлләрнең күбесе, шул исәптән, тарихи исемнәре билгеле булган шәһәрләр (Болгар, Биләр, Сувар, Җүкәтау, Кашан, Ошель/Ашлы, Чаллы, Кирмән, Алабуга, Казан), Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан. Дистәләгән-йөзләгән болгар шәһәрләре һәм авыллары, дөресрәге, аларның археологик калдыклары, күрше Ульян, Самара һәм Пенза өлкәләрендә табылган. Югары Кама (ул заманнарда аны, Агыйдел кушылган җирдән югарыдагы өлешен, Чулман дип атаганнар) һәм шул төбәктә яшәп яткан борынгы коми-пермяклар җирендә дә берничә болгар шәһәре

– һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләре булган. Рождественск (язма чыганакларда сакланган тарихи исеме – Афкула) һәм Кыласово шәһәрлекләренең оборона корылмаларына кадәр болгарлар тарафыннан төзелгән. Казылмалардан чыккан табылдыкларның 80 проценты диярлек болгарларныкы. Шәһәр ныгытмаларына якын гына җирдә мөселман зираты урнашкан. Шул тирәдә үк болгар чүлмәкчеләренең остаханәләре, ике яруслы чүлмәк яндыру мичләре казып өйрәнелгән (Белавин, Крыласова, 2008).

Соңгы елларда Түбән Иделдә яшәгән болгарлар турында да яңа мәгълүматлар тупланды. Табигый ки, Хазар каганаты таркалганнан соң да (X гасыр ахыры) аның төп халкы булган болгарларның күбесе шул ук җирләрдә яшәп кала. Әмма XI гасырның икенче яртысыннан башлап Түбән Идел, Каспий, Азов һәм Кара диңгез буе далаларына көнчыгыштан кыпчаклар күченеп киләләр һәм биредә элегрәк яшәгән бәҗәнәкләрне, гузларны, аланнарның һәм болгарларның бер өлешен «йоталар», ассимиляциялиләр. Озак еллар төрки күчмәннәр археологиясе белән шөгыльләнгән күренекле совет галиме профессор С.А. Плетнёва, соңгы тикшеренү нәтиҗәләренә таянып: «Кыпчакларның болгарлар белән кушылуы аларның антропологик кыяфәтенә дә үзгәрешләр кертә, күмү йолаларында да кабергә акбур порошогы һәм агач күмере сибү кебек болгарлардан алынган яңа элементлар килеп чыга», – дип язган иде (Плетнёва, 1997, с. 38).

Иделнең түбән агымына караган төбәкләрдә болгарларның монгол яуларына кадәр күпләп яшәгән шәһәрләре турында XII гасыр сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Гарнати кызыклы язмалар калдырган. Саксин шәһәренең үзәгендә, дип яза ул, «Болгардан килгән кешеләрнең әмире яши, аларның җомга намазы укыла торган зур Җәмигъ мәчетләре бар, аның тирәсендә болгарлар бистәсе. Аларның (болгарларның) тагын бер Җәмигъ мәчетләре бар, бирегә «Сувар кешеләре» дип атала торган халык намазга йөри. Алар шулай ук күпсанлы» (Путешествие ..., 1971, с. 27).

Идел елгасы тамагында урнашкан һәм VIII–X гасырларда Хазар каганатының башкаласы булып торган Итиль шәһәре турында да язма чыганакларда шуңа охшаш хәбәрләр сакланган.

2000 елдан башлап Әстерхан шәһәреннән 40 чакрым чамасы көньяктарак урнашкн Самосдельское шәһәрлегендә Мәскәү археологлары киң күләмдә казу эшләре алып баралар. Бу эшләрдә Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты галимнәре дә катнаша. Шәһәрлекнең гомуми мәйданы 200 га һәм ул, җир өстендә аунап яткан табылдыкларга карап, Алтын Урда чорында яшәгән булырга тиеш, дип фаразлана иде. Әмма биредә һич көтелмәгәндә монголларга кадәр тупланган шактый калын культура катламы да ачылды. Һәм бу катламда төрле типтагы торак йорт калдыклары, шул исәптән, юрта эзләре, хуҗалык корылмалары, кое-

лар казып тикшерелде. Катлам әйбер табылдыкларына да бай һәм аларның күпчелеге, бигрәк тә керамик савыт-саба, казу эшләренең җитәкчесе профессор Э.Д. Зиливинская сүзләре белән әйткәндә, «X–XII гасырларда яшәгән Идел болгарларыныкына абсолют охшаш» (Зиливинская, 2011, с. 27). Димәк, бу шәһәрдә яшәүчеләрнең күпчелеген болгарлар тәшкил иткән, дип раслый алабыз. Сүз уңаеннан: әлеге шәһәрлекне археологлар инде күптәннән эзли һәм кайбер тарихчылар тарафыннан, Каспий диңгезе күтәрелгән чорда су астында калып юкка чыккан, дип фаразлана торган Итиль белән тәңгәлләштерәләр. Дөрес, Саксин каласыдыр, дип уйлаучылар да бар.

Түбән Иделдә монголлар чорына кадәрге болгарлар калдырган археологик һәйкәлләр берән-сәрән генә түгел. Казан археологларының тикшеренүләре нәтиҗәсендә ел саен диярлек яңа авыл-шәһәр урыннары табылып тора. Казу эшләре вакытында тупланган материаллар биредә яшәгән кыпчак һәм болгарларның матди культурасын, аның башка төбәкләргә хас булмаган үзенчәлекләрен өйрәнүдә мөһим роль уйныйлар. Табылдыкларның иң күп өлешен тәшкил иткән керамик эшләнмәләрне җентекләп анализлап, археологлар хазарлар белән болгарларның һөнәрчелек культурасында буыннан-буынга күчеп килә торган охшашлык билгеләрен таптылар. Баксаң, чүлмәкчелекнең Алтын Урда чорында калыплашкан традицияләре дә нигездә әнә шул болгар һөнәрчелегенә барып тоташа икән. Алай гына да түгел. Идел буе далаларында әле монголларга кадәр үк калкып чыккан һәм кайчандыр тулы канлы тормыш белән яшәп яткан шәһәрләрне өйрәнү, Г.А. Федоров-Давыдовның, Алтын Урда шәһәрләре халкы утрак тормышны белмәгән, шәһәр кору традицияләре булмаган буш урында үсеп чыгалар, дигән ялгыш концепциясенә каршы килә. Түбән Иделдә һәм Җучиләр дәүләтенең башка өлкәләрендә барлыкка килгән торак пунктлар, шәһәрләр бу җирләрдә инде күптән оешып җиткән авыл-шәһәр структурасына нигезләгән, дип икеләнмичә әйтә алабыз.

Югарыда китерелгән фактлар тагын шуны күрсәтә: болгарлар инде монголларга кадәрге чорда ук Урта Идел (Казан), көнбатыш (мишәрләр), Урал буе (Пермь), Әстерхан татарларының бүген дә яши торган җирләрен билән торганнар. Себердә болгарлардан калган археология истәлекләре юк Себер татарларының күп өлеше соңгырак чорларда Урта Иделдән күчеп утырган халык, дип исәпләнелә иде. Археологларның яңа материаллары күрсәткәнчә, татарларның әлеге территориаль төркемнәре Болгар һәм Алтын Урда чорларында ук оешып, соңыннан сизелерлек этник үзгәрешләр кичермичә, безнең көннәргә кадәр килеп җиткәндер.

Башкортостан территориясендә болгарларга кагылышлы археология һәйкәлләре юк (Археологическая карта ..., 1976). Димәк, алар бу җирләрдә яшәмәгән. Бу, әлбәттә, бик бәхәсле мәсьәлә һәм болгарларның

башкортлар тарихындагы роле проблемасын бик җиңел хәл итү өчен уйлап чыгарылган кебек. Татарларны башкортлар белән якынлаштыручы этник компонентлар кыпчаклар белән бәйле – бусы бәхәссез факт. Ә аларның телләре болгар теленә бик якын булган («с болгары язык и род един»), – диелә рус елъязмаларында. Шунысы да бар, башкорт археологлары моңа кадәр бары тик урта гасырлар чорына караган мәҗүси каберлекләрне генә казып өйрәнделәр, авыллыкларга игътибар булмады. Ә бит болгарлар утрак тормышка күчкән халык, мөселманнар. Аларның эзләрен башкорт коллегаларыбыз табар әле дигән өметтә калабыз.

Чуашларга килгәндә исә, бу халыкның этник нигезләре формалашуда болгар компонентын инкяр итү ярамас, дип уйлыйм. Шул ук вакытта чуваш галимнәренең катгый рәвештә, чувашлар үзләрендә болгар культурасының бөтен үзенчәлекләрен саклап калган бердәнбер халык, ә татарларның килеп чыгышы тулысынча Көнчыгыш Европаны басып алган монгол-татарлар белән бәйле, дигән концепцияләре дөреслектән бик ерак тора, дип саныйм. Чөнки нәкъ менә югары үскән болгар мәдәниятенең асылын тәшкил иткән, бары тик аңа гына хас төп компонентлар: гасырлардан килгән дәүләтчелек традицияләре, рун һәм гарәп язмачылыгы, ислам (мөселман) дине, дөньяви фәннәр (медицина, шул исәптән, фармакология, астрономия, химия/алхимия, тарих һ..б.), поэзия (Кол Гали), шәһәрләр кору һәм монументаль архитектура сәнгате – урта гасырлар чуаш мәдәниятендә бөтенләй булмаган күренеш. Соңгырак чорларда боларның барысы да татар мәдәниятендә күчемле үсеш алалар. Нәкъ менә татарларның милли үзаңында чыңгызыйлар түгел, болгар бабалар өстенлекле, ныклы урын алып торалар. Чуашлар һәм башкортлар түгел, бары тик татарлар болгарлар белән бәйле ерак үткәнебезгә һаман да эчке бер дулкынлану, соклану һәм горурлык хисләре аша карыйлар, бүгенгә кадәр сакланып калган таш-кирпеч бина хәрабәләренә килеп, бабаларыбыз рухына дога кылып китәләр.

Әйе, тел гыйлемендә, борынгы болгар теле үзенең үсешендә артык үзгәрешләр кичермәгән хәлдә хәзерге чуаш телендә сакланып калган, дигән сәер теория яшәп килә. Бу теория беренче чиратта XIV гасыр мөселман каберташларындагы язмаларга нигезләнгән. Чыннан да чуаш һәм якут телләре бүгенге төрки телләрдән бик нык аерылып торалар һәм алар арасында иң борынгыларыннан саналалар. Әмма чуаш-болгар тәңгәллеген раслау өчен болар гына җитә микән? Чынлап торып караганда без бит болгар телен белмибез, ә белгән кадәресе яманаты чыккан шул теорияне җитди тәнкыйть утына алырга мөмкинлек бирә (Закиев, Кузьмин-Юманади, 1993). Бу проблема безнең телче галимнәребез тарафыннан аерым игътибар сорый.

Болгарларга нисбәтле археология һәйкәлләре башлыча Чувашстанның Татарстанга чиктәш көньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнарында,

Зөя елгасы бассейнында урнашкан (Фахрутдинов, 1971). Аларның тик берсе – Тигәш шәһәрлеге генә яхшы өйрәнелгән. Археолог Г.А. Фёдоров-Давыдов фикеренчә, ул башта мәҗүсиләрнең гыйбәдәтханәсе булган, соңыннан бай феодал утарына әверелгән (Фёдоров-Давыдов, 1962; бу турыда башка фикерләр дә бар: Хузин, Хамидуллин, 2013, с. 216–217). Бүгенге фән карамагындагы объектив мәгълүматлар чуашларның этнос буларак оешу процессында болгарлар да өлешчә (!) катнашкан дигән фикергә каршы килми, шулай да археология, этнография һәм антропология материаллары чуаш этногенезында өстенлекне җирле фин кабиләләренә бирә (Краснов, 1974; Хузин, 2012).

Фәнни әдәбиятта болгарларның Төньяк Кавказда яшәүче төрки халыклар тарихындагы роле бик аз яктыртылган. Без беренче чиратта карачай һәм балкар халыкларын күз алдында тотабыз. Алар яшәгән җирләргә төрки кабиләләр һуннар заманында ук үтеп керә. Язма чыганакларда ул кабиләләр арасында савирлар/суварлар телгә алына. Шунысы кызык, сваннар үзләренең ут күршеләре булган карачайлар белән балкарларны бүген дә суарлар/савирлар дип атап йөртә (Кубанов, 1987, с. 48). Болгарлар бирегә Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң, ягъни VII гасыр ахырларында күчеп утырганнар булса кирәк. Соңрак аларга аланнар да килеп кушыла. Үзенең көчле ныгытмалары һәм рун язмалары белән атаклы Хумара крепостенда болгар-алан хәрби гарнизоны торган. Карачай-Черкесиядә һәм Кабардин-Балкариядә башка болгар һәйкәлләре дә, шул исәптән, күмү йолалары һәм кабергә куелган әйберләре белән Азов-Дон болгарларыныкына охшаш зиратлар да бар (Степи Евразии ..., с. 83 и сл, 224 и сл.).

IX–X гасырларда Урта Идел болгарлары арасында яшәп яткан бәләнҗәр/баранҗарларның һәм берсула/барсилларның да Төньяк Кавказ, хәзерге Дагъстан җирләреннән чыккан кавемнәр икәнлеген искә төшереп үтәсе килә. Шул ук вакытта археологлар тарафыннан Кырымда да күпсанлы болгар-хазар һәйкәлләрен казып өйрәнүләрен әйтеп узарга кирәктер (Баранов, 1990). Аларның кырым-татар этногенезына катнашулары юк дәрәҗәдә дип саныйлар, әмма бу фикер әлеге истәлекләрнең җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәвеннән генә килергә дә мөмкин.

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, Үзәк һәм Көнбатыш Европага болгарлар V гасырның икенче яртысында килеп чыгалар. Иоанн Антиохийский язмаларына караганда, остготлар һәм аларның юлбашчылары «ромейларны куркуга салдылар, Фракия шәһәрләрен туздырып ташладылар һәм император Зенонны болгарлар белән союздашлык килешүенә күндерделәр» (Сиротенко, 1972, с. 200). Остготлар белән 488 елгы сугышта болгарлар җиңелә, әмма алар хәтта дошманнары тарафыннан сокландыргыч сыйфатламага лаек булалар: менә дигән җәйдаклар, яшен тизлегендә һәм максатчан хәрәкәт итәргә һәм табигый

киртәләрне бик җиңел үтәргә сәләтлеләр, искиткеч түземлеләр».

Остготлар Италиягә киткәннән соң болгарлар, Византия гаскәрләре составында сугышып, Дакия, Фракия, Мёзия җирләрен яулап алалар, 515 елда күтәрелгән Виталиан восстаниесендә җирле халык ягында Анастасий хөкүмәтенә каршы көрәшәләр һәм әкренләп Балкан ярымутравында төпләнә башлыйлар. Павел Диаконның (720–797) «Лангобардлар тарихы»нда лангобардларның һәм алар артыннан ук болгарларның да аварлар басымы астында 568 елда Паннониядән Италиягә китүләре турында хәбәр ителә. Әлеге тарихчы Италиянең төньягында, Лангобард корольлегендә, Болгар (Bolgare) исемле крепость-шәһәрчек булуы турында яза. Сүз уңаеннан бу шәһәрнең бүгенге көндә дә шул ук исемне йөртүен әйтеп үтәргә кирәктер (Сиротенко, 1972, с. 207).

Аңлашыла ки, бу вакыйгаларның барысы да VI–VII гасырларда болгарларның Түбән һәм Урта Дунай җирләренә күпләп күчеп утыруларына китерә. Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң Аспарух болгарлары бу якларга чагыштырмача тиз һәм җиңел килеп урнаша. 681 елда аларның тарихка Беренче Болгар патшалыгы исеме астында кереп калган дәүләте барлыкка килә.

Болгарларның Кубер исемле юлбашчылары (Кубрат ханның дүртенче улы) җитәкләгән тагын бер төркеме VII гасыр ахырында, ягъни әле бу якларга мадьяр-венгрларның күчеп утырышына кадәр, җирле халык белән килешү төзеп, Паннониягә, хәзерге Венгрия җирләренә килеп төпләнә (Сиротенко, 1972, с. 216). Әмма чыганакларда Паннониягә тагын да элегрәк килеп эләккән болгарлар турында дә хәбәрләр бар. Фредегар «Хроникасы»ндагы хәбәрләргә караганда, 631–632 елларда ук аварлар һәм алар кул астындагы Паннония болгарлары арасында сугышлар булып торган. Бу сугышларда болгарлар җиңелә һәм аларның 9 меңгә якын гаиләсе юлбашчылары Альцек җитәкчелегендә Бавариягә китеп урнашырга мәҗбүр була (Сиротенко, 1972, с. 209). Франк короле Дагоберт болгарларга кышны үзе күрсәткән җирдә үткәрергә рөхсәт итә, әмма тиздән үзе үк аларның барысын да кылычтан үткәрергә әмер бирә. Шулай да хатыннары һәм бала-чагалары белән 700 болгар ире үлемнән качып котыла һәм үзләренә Венет (Венеция) маркасында вакытлыча сыеныр урын таба. Павел Диакон хәбәрләренә караганда, лангобард короле аларга Сепин, Бовиана һәм Изерния җирлегендә даими яшәү өчен урын бүлеп бирә. «Һәм алар бу җирләрдә бүгенге көнгә кадәр яшәп яталар, – дип яза Павел Диакон. – Латинча бик әйбәт сөйләшсәләр дә, үзләренең телләрен дә онытып бетермәгәннәр, шул телдә аралашалар» (Сиротенко, 1972, с. 209).

Галимнәр раславынча, Төньяк Италиядә әлеге болгарларның археологик эзләре сакланып калган. Җирле халык күмелгән борынгы зиратларда сирәк булса да башларында ясалма деформация, йөзләрендә монголоид

сыйфатлары сизелеп торган кеше сөякләре очраштыргалый. Үлгән кеше янында аның яраткан аты ята. Янәшәдә ат дирбияләре (йөгән детальләре, өзәңге) һәм сугыш кораллары (ук-җәя, кылыч-хәнҗәр) куелган. Бу каберләргә болгар сугышчылары күмелгән (Мингазов, 2012, с. 203–204). Тел белгечләре Италиядә еш очрый торган *Булгаро*, *Булгарелли*, *Булгарени* фамилияләрен дә әнә шул VI–VII гасырларда яшәгән болгарлардан килә, дип саныйлар. Төньяк Италиядә килеп чыгышлары белән болгарларга нисбәтле топонимнар да очрый (Мингазов, 2012, с. 204). Сүз уңаеннан әле үземә дә шушы араларда гына килеп ирешкән бер кызыклы факт: 2016 елда Болгария эшмәкәрләренең матди ярдәме белән Италиянең Челе де Булгария шәһәре үзәгендә Кубрат ханның төпчек улы Альцекка һәйкәл ачылган икән. Күптән түгел Италиянең Мәскәүдәге илчелеге Татарстанның Мәскәүдәге вәкиллегенә Челе де Булгария белән республикабызның берәр шәһәре арасында туганлык җепләре урнаштырырга теләкләре барлыгын белдереп мөрәҗәгать иткән. Челе де Булгариягә, минемчә, безнең шәһри Болгар тугандаш була ала. Әлбәттә, биредә Кубрат хан белән аның улларына матур гына бер һәйкәл куелса, тагын да яхшырак булыр иде.

Болгарларның (гомумән төркиләрнең) Венгриядәге эзләре археологиядә дә, телдә дә бик ачык чагыла (Fodor, 1982a, p. 45–81). Шулай булырга тиеш тә. Этник тамырлары белән Көньяк Себердәге дала кабиләләренә барып тоташкан мадьярларның борынгы бабалары әле VI гасырның икенче яртысында ук Төрк каганатыннан бәйлелеккә эләгәләр. Бераздан алар, күчмәннәр, көнбатышка табан хәрәкәт итеп, венгрлар тарихына Magna Hungaria (Бөек Венгрия) исеме белән кереп калган Идел – Урал арасындагы җирләргә килеп чыгалар һәм биредә бәҗәнәкләр, болгарлар, угырлар чолганышында калалар (Halikova, 1976, p. 53–78). IX гасырның беренче яртысында Урта Иделдән көнбатышка таба күчешләрен дәвам итәләр, башта Дон һәм Азов диңгезе буйларында урнашкан легендар «Леведия» илендә, ә Паннониягә күчеп китәр алдыннан Хазар каганаты кул астындагы «Әтелкузу»да, Днепр-Днестр елгаара өлкәсендә яшәп алалар. Леведиядә венгрларның Алмуц/Алмош исемле юлбашчылары була. Әнә шул Алмошның улы Арпад вакытында, 895 елда, алар Урта Дунай буйларына килеп төпләнәләр һәм биредә Венгрия корольлеге барлыкка килә (Fodor, 1982б; Фодор, 2015).

Бу урында шуны искәртеп үтәргә кирәк: борынгы венгрларның барысы да Урта Идел һәм Урал буйларыннан көнбатышка күчеп китмәгән, бер өлеше әлеге җирләрдә бөтенләйгә утырып калган. Төп төркемнән аерылап калган әнә шул венгрларның зур гына бер зираты 1970 нче елларда республикабызның Алексеевский районы Олы Тигәнәле авылы янында Казан археологлары тарафыннан казып өйрәнелгән иде (Chalikova,

Chalikov, 1981; Халиков, Халикова, 2018).

Венгрларның болгарлар белән тыгыз багланышлары турында сөйләүче чыганакларның беренчесе – тел өлкәсенә караган материаллар:

*Алмош/Алмыш* – Идел Болгарстанының безгә билгеле иң беренче хакиме (эмире) һәм шул ук исемдәге кеше – Венгрия дәүләтенә нигез салган, аның идарәчеләре династиясенең башында торган король.

*Арпад* – Алмошның этисе; исеме *арпа* сүзеннән килеп чыккан дип фаразлана; *д* – венгрларда кечерәйтү суффиксы (Шушарин, 1997, с. 152).

*Золта* исемле корольнең, аның улы *Такшон*ның һәм дә кайбер мадьяр кабиләләренең (*тарьян, ене, кер, кеси*) исемнәре дә төрки телләрдән алынган (Шушарин, 1997, с. 191).

Бер төркем болгарларның Венгриядә яшәгәнлеген раслаучы фактлар арасында бүгенге көнгә кадәр сакланып калган өч дистә чамасы топонимнарны да күрсәтергә мөмкин: *Болгар*, *Богард*, *Полгар*, *Полгарди*, *Боляр*, *Берсел* һ.б. (Шушарин, 1997, с. 185). Форсаттан файдаланып, безнең топонимист галимнәргә дә Көнбатыш Европада таралган төрки-татар топонинарын (аларны бигрәк тә Болгариядә киң таралган төрек топонимнары белән бутамыйча) җитди рәвештә өйрәнә башларга тәкъдим итәр идем.

Мадьярларның килеп чыгышы турында XIII гасырда ук язып алынган риваять-легендалар бик кызыклы: «Эвилат илендә яшәүче гигант – алыптай гәүдәле Менрот Энет исемле хатыны белән Һунора һәм Мадьяра (Могора) исемле ике угыл тудыралар. Шулардан инде һуннар белән мадьярлар килеп чыккан. Берзаман, Меотида [Азов] сазлыкларына китеп баралар, биредә алар Белар исемле кешенең тол халган хатыннарын һәм ятим балаларын очраталар. Бу ике мадьяр аларны бөтен байлыклары белән үзләренә ияртеп алып китәләр...» (Шушарин, 1997, с. 198–203). Бу риваятьтә безнең игътибарны Һунор һәм Мадьярның әниләре *Энетның* (төрк. *эни/әни*) һәм *Беларның* (*булар/бүләр/биләр*) исемнәре җәлеп итә. Бүләр/биләр кабиләләре белән мадьярлар VIII–IX гасырларда күршеләр булып яшәгәннәр һәм 1235 елда венгр монахы Юлиан Болгар илендә утырып калган мәҗүси кардәшләрен үзе табынган католик диненә күндерү өчен нәкъ менә Биләргә – Олуг шәһәргә килә (Хузин, 2006, с. 283).

Әле узган гасыр башларында ук тюрколог-галим Золтан Гомбоц тарафыннан тикшерелгән венгр телендәге төрк (башлыча болгар) алынмаларының күпчелеге игенчелек һәм терлекчелек, аучылык һәм балыкчылык, мәдәният һәк көндәлек тормыш өлкәләренә карый. Алынмаларның шактый өлеше хәзерге татар теленә охшаш: *arpa* – тат. арпа, *alma* – алма, *boršo* – борчак, *torma* – торма, *kapu* – капка, *balta* – балта, *sakal* – сакал, *sirt* – сырт, *kender* – киндер, *oršo* – орчык, *šator* – чатыр, *bator* – батыр, *temen* – төмән (ун мең), *tilmacs* – тылмач, *oroslan* – арыслан, *korom* – корым, *kek* – күк, *beka* – бака һ.б. (Gombocz, 1912, S. 203–210; Шушарин, 1997, с.

206–210; Закиев, Кузьмин-Юманади, 1993, с. 62 и сл.).

Идел буе болгарларының венгрлар белән X гасырдагы бәйләнешләре турында XIII гасырда язылган «Венгр Анонимы»нда кызыклы мәгълүматлар бар. Россиядә бу чыганакны XIX гасырның икенче яртысында күренекле семитолог Д.А. Хвольсон фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә. Текстның эчтәлеге (Хвольсон комментарийлары белән) түбәндәгечә:

«Bilers, ягъни Биләрдән яки Болгар иленнән чыккан кешеләр, – мөселманнар. Мадьяр герцогы (идарәчесе) Таксонь идарә иткән заманда, 970 нче еллар тирәсендә, Венгриягә Билла һәм Боксу исемле ике бертуган җитәкчелегендә Идел буе болгарлары төркеме килә; бераздан Хәсән җитәкчелегендә тагын бер төркем килә. Аларны дусларча каршы алалар һәм яшәү өчен Дунай елгасының сул ягындагы авылларны бирәләр. Шул урында алар Пешт шәһәренә нигез салалар. Болгарларның бу якларга күченеп килүе, шөбһәсез, 968 елда болгарларга һәм хазарларга каршы князь Святослав вакытында булган коточкыч рус явы нәтиҗәседер... Венгриядә Болгардан күчеп килгән әлеге мөселманнарны *биләрләр (Bilers)*, ягъни болгарлар һәм *исмаилитлар (Ismahelitae)* дип атадылар. Шуннан соң алар Венгриядә, төрлечә кысуларга һәм эзәрлекләүләргә карамастан, откупщиклар һәм финанс белән идарә итүчеләр (управляющийлар) буларак, бик мөһим роль уйнадылар» (Хвольсон, 1869, с. 108–109). Шул болгарлар нәселеннән чыккан затлар, Д.А. Хвольсон күрсәтеп үткәнчә, әле XIV гасырда да венгрлар җәмгыятендә күренекле урын биләп торганнар.

Венгриядә болгарның торак урыннар рәвешендәге археологик эзләре билгеле түгел. Хуш, үзләренең элгәрege, X гасырга караган авыл урыннары да әле күптән түгел генә табылды бит. Әмма археологлар болгар әйберләрен авар һәм венгр каберлекләрендә еш очраталар. Матесалкта (Собольч өлкәсе) табылган кылычлар, ат дирбияләре, болгарларга хас бизәкләр төшерелгән савыт-саба, алтыннан ясалган бил каеше прәшкәләре, Тисабур (Сольнюк өлкәсе) авылы янындагы каберлектән чыккан каеш гарнитуры, атаклы Надьсентмиклош хәзинәсендәге (хәзер ул авыл Сынниколаул дип йөртелә, Румыния территориясенә керә) рун язмалы көмеш савытлар – шундыйлардан.

Албаниядә Врап һәм Ерсеке авыллары янында табылган һәм килеп чыгышлары белән болгарларга нисбәтле ике хәзинә билгеле. Аларның беренчесендә 4 потир, 3 чүмеч, өч дистәгә якын каеш детальләре (барысы да алтыннан), төбенә монограммалар уелган көмеш кувшин һәм казан, икенчесендә – 120 дән артык алтын-көмеш каеш детальләре, төбенә Констанца II мөһерләре сугылган (641–651, 659–661) ике көмеш тәлинкә (Friedler, 1996, S. 248–264; Werner, 1986, S. 7–104) бар. Бу әйберләрнең төгәл аналогияләре Болгариядә казып тикшерелгән һәм VII–VIII гасырларга караган Велино, Кабиюк, Дивдядово, Злагари, Гледачево каберлекләрендә

табылган. Алтын-көмештән ясалган затлы әйберләрнең хуҗасы, һичшиксез, Плиска аксөякләре, болгар ханнары. Галимнәрнең фикеренчә, Албаниядә табылган Врап һәм Ерсеке хәзинәрендәге әйберләр авар ханы һөнәрчеләре тарафыннан эшләнеп, ниндидер юллар белән Кубрат ханның Кубер исемле улына килеп эләккән булырга мөмкин. Әмма затлы әйберләр ясауга махсуслашкан һөнәрче остаханәсе Куберның үзенеке үк булмады микән – ул бу вакытта авар ханы кушуы буенча Византия чикләрендә торган әсир румлыларның управляющие вазыйфасын башкарган, ләкин бик тиз аның буйсынуыннан чыгып, мөстәкыйль идарәчегә әверелгән (Тотев, Пелевина, 2011, с. 202–218).

Хазар каганаты чорына караган һәм болгар һөнәрчелегенә хас савыт-сабалар, сирәгрәк булса да сугыш кораллары табыла торган йөздән артык авыл урыннары археологлар тарафыннан Молдавиядә һәм Румыниядә тикшерелгән (Die Keramik …, 1990, S. 171; Козлов, 2015). Биләр коллекцияләрендә аналогияләре булган вертикаль тоткачлы керамик казаннар Сербиядә Вршац шәһәре тирәсендәге борынгы торак пунктын казыганда килеп чыккан (Fodor, 1979, p. 315–325). Моравиядә (Чехия), Саксониядә һәм Бавариядә (Германия), Австриядә очрый торган Bolghri, Bulgheria, Pulgram, Pulgarn, Bulhary, Polgren кебек этнотопонимнарның килеп чыгышын тел белгечләр кайчандыр шул төбәкләрдә яшәп көн күргән болгарлар белән бәйләп аңлаталар (Мингазов, 2013, с. 24).

Югарыда телгә алынган фактларның барысы да элгәреге урта гасыр болгарларының Урта Иделдән башлап Дунай-Карпатка кадәр сузылган географик киңлекләрдә таралып утырган булуларын, бүгенге көндә төрки, славян, фин-угыр, иран һәм роман телләрендә сөйләшә торган Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа халыклары тарихында, хәтта аларның этник яктан, милләт буларак формалашуында сизелерлек роль уйнаганнарын ачык күрсәтеп тора. Кызганыч, бу мәкаләдә күтәрелгән проблемалар әлегә бик аз өйрәнелгән. Болгар мирасына кагылышлы мәсьәләләр әле һаман да үзләренең актуальлелеген югалтмый. Киләчәктә алар яңа чыганаклар нигезендә тагын да киңрәк планда өйрәнелсен иде дигән теләктә калабыз.

## Файдаланылган әдәбият

Археологическая карта Башкирии / Отв. ред. О.Н. Бадер. М.: Наука, 1976. 263 с.

*Ашмарин Н.И.* Булгары и чуваши // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1902. Т. XVIII, вып. 1–3. 132 с.

*Әхмәтҗанов М.И.* Болгар теленең язмышы (эпиграфика материаллары буенча) // Татарская археология. 1998. № 1 (2). Б. 99–120.

*Баранов И.А.* Таврика в эпоху раннего средневековья. Киев: Наукова думка, 1990. 168 с.

*Белавин А.М., Крыласова Н.Б.* Древняя Афкула: археологический комплекс у с. Рождественск. Пермь: Изд-во Перм. гос. пед. ун-та, 2008. 603 с.

*Димитриев В.Д.* Вопросы этногенеза, этнографии и истории культуры чувашского народа. Чебоксары: Изд-во Чуваш. гос. ун-та, 2004. 312 с.

*Закиев М.З., Кузьмин-Юманади Я.Ф.* Волжские булгары и их потомки. Казань: АН РТ, 1993. 160 с.

*Зиливинская Э.Д.* Раскоп № 1 // Самосдельское городище: вопросы изучения и интерпретации / Отв. ред. В.Д. Васильев. Астрахань, 2011. С. 13–35.

История татар с древнейших времен в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности / Отв. ред. С.Г. Кляшторный. Казань: Изд-во «Рухият», 2002. 552 с.

*Козлов В.И.* Население степного междуречья Дуная и Днестра конца VIII – начала XI веков: балкано-дунайская культура. Казань; СПб.; Кишинев, 2015. 323 с.

*Комар А.В.* Перещепинский комплекс в контексте основных проблем истории и культуры кочевников Восточной Европы VII – начала VIII в. // Степи Европы в эпоху средневековья. Т. 5. Хазарское время / Гл. ред. А.В. Евглевский. Донецк, 2006. С. 7–244.

*Комар А.В., Кубышев А.И., Орлов Р.С.* Погребения кочевников VI–VII вв. из Северо-Западного Приазовья // Степи Европы в эпоху средневековья. Т. 5. Хазарское время / Гл. ред. А.В. Евглевский. Донецк, 2006. С. 245–374.

*Краснов Ю.А.* Проблема происхождения чувашского народа в свете археологических данных // СА. 1974. № 3. С. 112–124.

*Лимонов Ю.А.* Владимиро-Суздальская Русь. Очкерки социально-политической истории / Отв. ред. Б.А. Рыбаков. Л.: Наука, 1987. 214 с.

*Кубанов А.Х.* К вопросу об этническом составе населения западной Алании // Вопросы археологии и традиционной этнографии Карачаево-Черкесии / Отв. ред. А.И. Першиц. Черкесск, 1987. С. 45–59.

*Мажитов Н.А., Султанова А.Н.* История Башкортостана. Древность. Средневековье. Уфа: Китап, 2010. 496 с.

*Мажитов Н.А.* Вопросы древней и средневековой истории башкирского народа. Уфа: Гилем, 2013. 300 с.

*Мингазов Ш.Р.* Наследники Великой Болгарии в Западной Европе // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. № 1 (2). С. 203–204.

*Мингазов Ш.Р.* Великая Болгария и роль тюркоязычных болгарских племен в истории Европы. Автореф. дис. … канд. ист. наук. Казань, 2013. 24 с.

*Плетнёва С.А.* Древние болгары в восточноевропейских степях // Татарская археология. 1997. № 1. С. 31–60.

Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.) / Публикация О.Г. Большакова, А.Л. Монгайта. М.: Вост. лит-ра, 1971. 136 с.

*Рашев Р.* Прабългарите през V–VII век. София: Фабер, 2004. 348 с.

*Сиротенко В.Т.* Византия и булгары в V–VI вв. // Уч. зап. Перм. гос. ун-та. 1961. Т. XX, вып. 4. С. 43–70.

*Сиротенко В.Т.* Письменные свидетельства о булгарах IV–VII вв. в свете современных им исторических событий // Славяно-балканские исследования. Историография и источниковедение / Отв. ред. С.А. Никитин. М.: Наука, 1972. С. 195–218.

Степи Евразии в эпоху средневековья. Археология СССР / Отв. ред. С.А. Плетнёва. М.: Наука, 1981. 303 с.

*Тотев Б., Пелевина О.* Сокровище из Врапа (Албания) и аристократические погребения болгар Нижнего Дуная // Археология евразийских степей. Т. 12. Материалы I Междунар. Болгарского форума / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань, 2011. С. 202–218.

*Фахрутдинов Р.Г.* О степени заселённости булгарами территории современной Чувашской АССР // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1971. С. 175–201.

*Фахрутдинов Р.Г.* Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. 219 с.

*Фёдоров-Давыдов Г.А.* Тигашевское городище. (Археологические раскопки 1956, 1958 и 1959 гг.) // МИА. 1962. № 111. С. 49–89.

*Фодор И.* Венгры: древняя история и обретение родины. Пермь: ООО «Типография «ЗЁБРА», 2015. 132 с.

*Халикова Е.А., Халиков А.Х.* Ранние венгры на Каме и Урале. (Больше-Тиганский могильник) // Археология евразийских степей. Вып. 25. Казань: Изд-во «Фэн», 2018. 144 с.

*Хвольсон Д.А.* Известия о хозарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда бен Омар Ибн-Даста, неизвестного доселе арабского писателя начала X века, по рукописи Британского музея. СПб., 1869. 199 с.

*Хузин Ф.Ш.* Ранние булгары и Волжская Булгария (VIII – начало XIII в.). Казань: Ин-т истории АН РТ, 2006. 583 с.

*Хузин Ф.Ш.* О некоторых проблемах булгарской археологии в аспекте этногенеза чувашского народа // Волжская Болгария (Булгария): этнокультурная ситуация и общественное развитие. Материалы научного семинара / Отв. ред. Г.А. Николаев. Чебоксары: Чув. гос. ин-т гуманит. наук, 2012. С. 37–45.

*Хузин Ф.Ш., Хамидуллин Б.Л.* Ещё раз о соотношении язычества и ислама в домонгольской культуре Волжской Булгарии // Филология и культура. Philology and Culture. 2013. № 1 (31). С. 214–221.

*Шушарин В.П.* Ранний этап этнической истории венгров: проблемы этнического самосознания. М.: Российская полит. энциклопедия, 1997. 512 с.

*Ювенальев Ю.Ю.* Этническая религия суваро-булгар // Государственность восточных булгар IX–XIII вв. Материалы междунар. науч. конф. Чебоксары: Изд-во «Таус», 2012. С. 293.

*Chalikova E.A., Chalikov A.H.* Altungarn an der Kama und im Ural: Das Gräberfeld von Bolschie Tigani / Régészeti Füzetek, ser. II, No 21. Budapest: Maguar Nemzeti Múseum, 1981. 132 S.

Die Keramik der Saltovo-Majaki Kultur und ihrer Varianten / Hrsg. von Csánad Bálint. Budapest, 1990. 342 S.

*Fiedler U.* Die Spätawarenzeitlichen Gürtelbestandteile von Vrap-Erseke aus Velino // Germania. 1996. Bd. 74. S. 248–264.

*Fodor I.* Archaeological traces of the Volga Bulgares in Hungary of the Arpad period // Acta Orientalia Acad. Scient. Hung. 1979. T. XXXIII, 3. P. 315–325.

*Fodor I.* On Magyar-Bulgar-Turkish contacts // Chuvash Studies. Ed. A. Róna-Tas. Budapest, 1982. P. 45–81.

*Fodor I.* Die Grosse Wanderung der Ungarn vom Ural nach Pannonien. Budapest, 1982. 373 S.

*Gombocz Z.* Die bulgarisch-turkischen Lehnwörter in der ungarischen Sprache. Memoires de la Societe Finno-Ougrienne. T. XVIII. Helsinki, 1912. 252 S.

*Halikova J. A*. Ősmagyar temető a Káma mentén. (Magna Hungaria kérdéséhez). Ancient Hungarian Cemetery along the River Kama. (Contribution on the Issue of Magna Hungaria) // Archaeologica Értesitó. 1976. T. 103. P. 53–78.

*Shamiloglu U.* The End Volga Bulgarian // Varia Eurasiatica. Festschrift für professor Andras Rona-Tas. Szeged, 1991. P. 157–163.

*Werner J.* Der Schatzfund von Vrap in Albanien // Studien zur Archäologie der Awaren. T. II. Wien, 1986. S. 7–104.

*Фәнни Татарстан. 2019. № 1. 82–95 бб.*



## ЧЫНГЫЗХАН ТАТАРЛАР НӘСЕЛЕННӘНМЕ?

Бүгенге халыкларның килеп чыгышын өйрәнү тарих фәнендә, мөгаен, иң кызыклы һәм катлаулы мәсьәләләрдән саналадыр. Кемнәр алар Идел буе татарлары? – дигән сорауны безгә еш бирәләр. Аңа иң әүвәл XVI йөздә язылган «Казан тарихы» дигән китапның билгесез авторы, аннан соң XVIII йөз галимнәре җавап табарга тырышканнар. Урыс тарихчылары татарларның килеп чыгышын башлыча монгол яулары белән Көнчыгыш далаларыннан килеп утырган татар кабиләләре белән бәйләп аңлатсалар, XIX йөзнең беренче яртысында яшәп иҗат иткән татар әдипләре Габдерәхим Утыз-Имәни (1754–1834) һәм Таҗетдин Ялчыгол (1768–1838) халкыбызның борынгы тарихын болгар чорларыннан ук башлап җибәрәләр. Менә шул заманнардан ук оеша башлаган «татар» һзм «болгар» теорияләре озак яшәүчән булып чыктылар. 1980 нче еллар ахырында, бигрәк тә 1990 нчы елларда галимнәребез арасында бу хакта кискен бәхәсләр дә булып алды. Тарихыбызга битараф булмаган мөхтәрәм язучыларабыз, журналистлар һәм дә моңарчы болгар бабаларыбыз турында популяр язмалардан гына укып-ишетеп белгән әллә кемнәр, үзләренең фикерләрен тизрәк укучыларга җиткерергә ашыгып, вакытлы матбугатта чыгышлар ясадылар, кайвакытта шаккатмалы «ачышлар» да ясап куйдылар.

Татарларның Болгар һәм Алтын Урда дәүләтләре белән бәйләнешле ерак тарихын өйрәнү юлында соңгы елларда сизелерлек уңышларга ирешелде. Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәе Тарих институты галимнәре 7 томлык фундаменталь «Татар тарихы»н язу эшенә керешкәнче халкыбызның

этногенезы проблемаларын да җентекләп өйрәнделәр. Бердәм фикер туды: татар тарихын борынгы төркиләр, хәтта скифлар һәм һуннар чорыннан, ягъни безнең эрага кадәр II–I меңъеллыклар чигеннән башлап җибәрергә кирәк, чөнки соңыннан татар халкын оештыруга катнашкан борынгы кабиләләрнең – шул исәптән, татарларның һәм болгарларның да – этник тамырлары шул ерак заманнарга барып тоташа. Болгарлар (күрәсең, һуннарга ияреп) Көнчыгыш Европа далаларына күчеп утыруы III–IV гасырларга карый, әмма ышанычлы язма чыганакларда аларның исемнәре V гасырда гына пәйда була. Биредә алар соңыннанрак үзләренең дәүләтләрен төзиләр (Кубрат ханның Бөек Болгары, VII гасыр). Ул дәүләт таркалганнан соң, VII гасыр ахырларында, болгарларның бер өлеше Урта Идел буйларына килеп төпләнә, күчеп утырулар VIII–IX гасырларда да дәвам итә. Ниһаять, биредә X гасыр башында яңа дәүләт – Идел Болгары калкып чыга. Бу чордан меңләгән археологик истәлекләр сакланып калган, алар арасыннан Болгар, Биләр, Суар, Җүкәтау, Кашан, Ашлы калалары бөтен дөньяга мәгълүм.

Борынгы татар кабиләләре исә әүвәл VIII гасырга караган орхон язмаларында, төгәлрәк әйткәндә, Күлтәгин истәлегенә куелган каберташта, Көнчыгыш Төрки каганлыгына буйсындырылган халыклар исемлегендә телгә алыналар («отуз-татарлар» һәм «токуз-татарлар»). Күренекле Шәрык белгече профессор С.Г. Кляшторный, ышанычлы язма чыганакларга таянып, заманында татарларның берничә дәүләт тотканлыклары турында яза. XI йөз тарихчысы әл-Гардизи хезмәтендә китерелгән бер риваятьтә, аларныж Кимак дәүләтен төзүдә катнашулары бәян ителә. Чыңгыз хан төзегән дәүләттә дә татарлар сан ягыннан шактый булып, сәяси тормышта мөһим роль уйнаганнар.

Татарларның төркиме-монголмы булулары турында фәндә төгәл фикер юк. Мәхмүд Кашгариның атаклы «Диване лөгат-ит-төрк» әсәрендә бер-берсенә каршы килә торган мәгълүматлар бар: берничә тапкыр ул татарларның төрки кабиләләр булуын искәртеп, ахырда «алар үз телләрендә сөйләшәләр, әммә төрк телен дә яхшы беләләр», – дип өстәп куя. Күрәсең, алар төрки телле булганнардыр (тугандаш этнонимнарга игътибар итегез: тат-*ар*, болг-*ар*, су-*ар*, маж-*ар*, бәрәнж-*әр*, хаз-*ар*), әмма алар төзегән дәүләтләрдә монгол кабиләләренең да яшәве бәхәссез.

Безнең якларга татарлар кайчан килеп чыгалар? Бәхәсле мәсьәлә. Монгол яуларына кадәр үк кыпчак кабиләләре составында килгәннәрдер, диюче галимнәр бар. Мөмкин, әмма бу фикер чыганаклар белән нигезләнмәгән. Шуңа күрә, татарлар Көнчыгыш Европага 1236–1240 елларда Чыңгыз ханның оныгы Бату хан гаскәрләре составында киләләр, дигән традицион фикер белән килешергә туры килә. XIII гасырның икенче яртысында монгол-татарлар басып алган җирләрдә Җучи олысы –икътисадый яктан көчле, югары

үскән мәдәнияткә ия, дөньяда тиңдәше булмаган Алтын Урда дәүләте төзелә. Идел Болгары да, мөстәкыйльлеген югалтып, яңа дәүләт составына кушыла. Нәкъ менә шул чорларда болгарларны, башка буйсындырылган халыклар белән беррәттән, татарлар дип йөртә башлыйлар. Һәм бу атама болгарларга тагылып кала, гәрчә алар озак гасырлар буена үзләренең асыл исемнәрен онытмасалар да.

Алтын Урда чорында, болгарлар монгол ханнары тарафыннан төзелгән бердәм дәүләт составында яшәгән дәверләрдә, этник үзгәрешләр күзәтеләме? Әлбәттә, иҗтиманый-сәяси тормышта да, идеология һәм мәдәният өлкәләрендә дә, телдә дә сизелерлек үзгәрешләр булган, әмма этник үзгәрешләрне, кайбер галимнәр кебек, чамадан тыш арттырып күрсәтү дөрес түгел: монгол-татар сугышчыларының күбесе кире туган якларына кайтып китә, җирле халык исә элеккечә туган төбәкләрендә яшәүләрен дәвам итә. Антропологларның фикеренчә, болгарлар арасында монголларга хас физик сыйфатлар элеккеге дәрәҗәдә калган. Югары катлау кешеләре арасында исә хәтта үзләренең гаилә чылбырларын да Чыңгыз нәселенә китереп тоташтыручылар күп була. Бу хәл Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән Казан ханлыгы чорында да дәвам итә. Ул чакларда инде элеккеге болгарларны башлыча (бигрәк тә күршеләре, мәсәлән, урыслар) татарлар дип йөрткәннәр.

Димәк ки, халкыбызның милләт буларак формалашу тарихында башлангыч өч төп чорны – борынгы төркиләр, Идел буе болгарлары һәм Алтын Урда чорларын аерып күрсәтергә мөмкин. Югарыда бәян ителгән концепцияне икенче төрле төрки-татар теориясе дип йөртәләр. Бу теория тарафдарлары, Шиһабетдин Мәрҗанидән, Газиз Гобәйдуллиннардан башлап, татар этногенезында хәлиткеч чор дип Алтын Урда чорын саныйлар, әмма һич тә болгар бабаларыбызны этногенетик процесслардан төшереп калдырмыйлар. Реаль тормыш күпкә катлаулырак була, әлбәттә. Этнология фәнендә «халык» (народность) дип йөртелә торган этник берәмлек барлыкка килү процессында, мәсәлән, күрше фин-угыр халыклары да, хәтта славян-руслар да мәгълүм роль уйнаган.

Кызганычка каршы, соңгы елларда бары тик килмешәк монгол-татарларга гына мәдхия укуга корылган мәкаләләр, хәтта калын-калын китаплар күренә башлады. Аларның авторлары – һәвәскәр тарихчылар, дилетантлар. Мәсәлән, Камил Аблязовның ике томнан торган «Татарларның тарихи язмышы» исемле китабында[1] Идел буе болгарлары турында бер кәлимә сүз әйтелмәгән. Ибн Фадлан чорында болгарларның рәсми рәвештә ислам динен кабул итүләре дә, күптән түгел генә 1000 еллыгын бәйрәм иткән Казан, Алабуга һәм башка шәһәрләр тарихы да, Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыфы да,

[1] Аблязов К.А. Историческая судьба татар. Саратов: Научная книга, 2012.

бүгенге көндә Болгарда алып барыла торган реставрация-төзекләндерү эшләре дә авторның игътибарыннан бөтенләй читтә калган.

Кайберәүләр Чыңгызханның татар нәселеннән чыкканлыгын исбатларга омтылалар. Икенчеләре исә, аңа татар җирендә, Казанда, һәйкәл куярга тәкъдим ясыйлар. Алтын Урданы, ягъни Җучи олысын монголлар түгел, бәлки татарлар төзегән дәүләт дип атыйлар. Имеш, дәүләт кадәр дәүләт торгызу «кыргый» монголлар кулыннан килерлек гамәл түгел. Чыңгызханның «милләтен» ачыклау өчен тарихи чыганаклар юк дәрәҗәсендә, шуңа күрә, галимнәр әлеге сорауга төгәл генә җавап бирә алмыйлар. Тарих фәнендә, Чынгызхан килеп чыгышы белән монгол, дигән караш өстенлек итә. Шулай булып калсын әйдә.

Монгол яугирләре составындагы татарларның тарихыбыздагы ролен ясалма рәвештә күпертеп, без – Чынгызхан токымнары дип, болгар чорын бөтенләй инкарь итү нигә кирәк? Аңлашылмый. Әйе, Алтын Урда – заманында дөньяны дер селкетеп торган, искиткеч югары казанышларга ирешкән дәүләт. Ә бит ул дәүләт ирешкән казанышларда, аның халыклары калдырган мираста болгарларның да роле зур[2]. Һәм ул мирастан берәү дә баш тартырга җыенмый. Киресенчә, бүген Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты галимнәре болгар тематикасына игътибарны көчәйтә генә баралар. Чөнки болгарларның археологик эзләрен илебезнең Урал тауларыннан, хәтта Себердән башлап Көнбатыш Европа чикләренә, Печора, Вычегда бассейннарыннан башлап Кырым, Төньяк Кавказ тауларына кадәр җәелгән төрле киңлекләрендә очратырга мөмкин. Шул төбәкләрдәге коллегаларыбыз белән күмәкләшеп тикшерергә генә кирәк аларны.

Кыскасы, тамырларыбыз тирән – Алтын Урда составындагы һәм тагын да элегрәк яшәгән болгар-кыпчакларга, төрки-һуннарга, аларның ерак бабаларына барып тоташа. Һәр чор тарихыбызда тирән эз калдырган.

---

[2] Бу турыда тулырак карагыз: Bulgarica. Время и пространство Болгарской цивилизации. М.; Казань, 2012.



# АЛТАЙ ЯКЛАРЫННАН – ДУНАЙ БУЙЛАРЫНА: БОРЫНГЫ БАБАЛАРЫБЫЗ ЭЗЕННӘН

Россия тарихы елы дип игълан ителгән 2012 ел тарихи вакыйгаларга бай булды. Рус дәүләтенең оештырылуына 1150 ел, XVII йөз башында рус дәүләтчелегенең яшәешенә куркыныч салган һәм тарихка «болгавыр заман» исеме белән кереп калган вакыйгаларның тәмамлануына 400 ел, Наполеон гаскәрләрен тар-мар итү белән истәлекле 1812 елгы Ватан сугышына 200 ел тулуга багышланган чараларда Татарстан җәмәгатьчелеге дә, бигрәк тә галимнәр, актив катнаштылар. Бу шулай булырга тиеш иде дә, чөнки татар тарихы гасырлар буена Россия тарихы белән тыгыз бәйләнештә үскән һәм уртак ватаныбызда барган олы вакыйгалар безне дә читләтеп үтмәгән.

Россия тарихы елын без, Татарстан археологлары, үзебезчә билгеләп үттек. Тантаналар булмады, әмма күңелебездә тирән эз калдырырлык истәлекле һәм, иң мөһиме, фәнебезнең киләчәктәге үсеш перспективаларын ачыкларга ярдәм иткән файдалы чаралар оештыра алдык. Бу мәкаләмдә мин шуларның икесенә, болгар тарихы һәм археологиясенә кагылышлы халыкара форумнарга гына тукталып үтмәкче булам. Укучыларыбыз өчен дә кызык булыр дип уйлыйм.

Болгар археологиясе үсештә һәм бу фактны берәү дә инкарь итә алмас дип уйлыйм. Соңгы елларда республикабызның беренче президенты М.Ш. Шәймиев башлангычы белән оештырылган «Яңарыш» фондының турыдан-туры катнашында Болгар шәһәрлегендә алып барыла торган казу эшләре төгәлләнеп килә. Әлбәттә, тикшеренүләр киләчәктә дә дәвам итәчәк, әмма туристик комплекслар төзү белән бәйле казулар җитәрлек дәрәҗәдә башкарылды һәм киләсе елда ачылачак Болгар цивилизациясе музее экспозицияләре өчен

бай материал тупланды. Болгар истәлекләрен өйрәнү республикабызның башка районнарында да һәм дә күрше өлкәләрдә, Россиянең төрле төбәкләрендә, чит илләрдә дә тукталып тормады. Яңа материалларны фәнни күзлектән үткәреп, җентекләп тикшерү, гомумиләштерү һәм галимнәр алдына килеп баскан проблемаларны чишү юлларын билгеләү өчен борынгы төркиләр, болгарлар, Алтын Урда, Казан ханлыгы археологиясе белән шөгыльләнүче белгечләрнең очрашып фикер алышулары кирәк иде. Шул ук «Яңарыш» фонды ярдәме белән мондый очрашулар сентябрь аенда Барнаулда һәм Таулы Алтай республикасында, октябрь аенда Болгариянең Варна шәһәрендә булып үтте.

5 сентябрь көнне Алтай крае башкаласы Барнаул шәһәрендә, Алтай дәүләт университетының Гыйльми советы утырышлары залында, берьюлы өч зур фәнни җыен: Евразия далалары археологиясенең II Халыкара конгрессы, III Болгар форумы һәм II Идел-Алтай форумы ачылды. Аларны оештыручылар Алтай дәүләт университеты, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Казан (Идел буе) федераль университеты иде. Уртак проблемалар белән шөгыльләнүче галимнәр арасында Монголия, Кытай, Япония, Франция, Болгария, Венгрия, Румыния, Польша, Украина, Беларусь – барлыгы 11 илдән килгән белгечләр бар иде. Фәнни җыеннарны ачканда Алтай крае губернаторы урынбасары Ю.Н. Денисов, Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе М.Ш. Шәймиев, Алтай дәүләт университеты ректоры С.В. Землюков, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Р.С. Хәкимов галимнәргә котлау сүзләре җиткерделәр. Пленар утырышта Россия Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы Н.Н. Крадин «Үзәк Азиянең борынгы һәм урта гасырлар чорындагы күчмә империяләре» һәм Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы Ф.Ш. Хуҗин «Борынгы болгар культурасының оешу тарихыннан» дигән докладлар белән чыгыш ясадылар.

Тәнәфестә университетның «Universum» галереясында яңа археологик табышлардан торган «Урта гасырлар Алтае» дип аталган күргәзмә ачылды. Галимнәр археология музее һәм борынгы төркиләрнең әле быел гына казылган каберлекләреннән чыккан искиткеч бай материаллар белән дә таныштылар.

Пленар утырыш тәмамлангannan соң форум өч көн буена Таулы Алтай республикасында урнашкан «Стик-Тревел» туристик комплексының конференц-залында дәвам итте.

Борынгы төрки бабаларыбызның Алтай чорына караган археологик истәлекләре белән танышу, аларда болгар культурасына хас үзенчәлекләрне табу һәм башка уртак проблемалар турында Россия һәм чит ил галимнәре белән эшлекле сөйләшү безнең күптәнге хыялыбыз иде. Аралар ерак булса да, Идел белән Алтай төбәкләрендә яшәп яткан халыклар арасында тарихи бәйләнешләр өзелеп тормаган.

Әле моннан өч мең еллар элек, бронза гасыры ахырында ук, аннан соң элгәреге тимер гасыры чорында Идел-Кама төбәгендә көнчыгыштан, Себер якларыннан күчеп килгән кабиләләр төркеме күренә башлый. Бу җәһәттән безнең эрага кадәр VII–V гасырларда яшәгән ананьино кабиләләре калдырган истәлекләр кызыклы. Ананьино кабиләләрен кайбер галимнәр грек тарихчысы Геродот тарафыннан скиф кабиләләре составында искә алынган аргиппейлар яисә тиссагетлар белән тиңләштерәләр. Скифлар, ди Геродот, аргиппейлар белән җиде тылмач ярдәмендә генә сөйләшә алалар, имеш, аларның телләре бөтенләй башкача. Телче галимнәр исә бертавыштан аргипейларның «асхи» исемле эчемлекләренең мәгънәсен «әче», «ачы» дип төрки сүзе аша аңлаталар. Шунысы да кызык, Татарстан җирләрендә, төгәлрәге, Кама буйларында яшәп яткан ананьино кешеләренең антропологиясендә монголоид билгеләре ачык күренә. Алай гына да түгел, ананьинолылар кабер өстенә сугышчы, йә булмаса сугыш кораллары чокып ясалган таш плитәләр куя торган булганнар. Менә боларның барысы да безнең яклардагы ананьино кабиләләре арасында ерак Себердән күчеп килгән төркемнәр булуына ишарәли. Тагын бер кызыклы факт: Геродот язмаларына караганда, аргиппейлар яссы борынлы, пеләш башлы, гомумән, кыяфәтләре белән скифлардан аерылып торалар. Ә бит соңгырак чорга караган чыганаклар да борынгы төркиләрне, болгарларны һәм хәзәрләрне пеләш башлы кешеләр дип тасвирлыйлар («бритоголовые тюрки», «болгарские князья с остриженными головами», «бреющие головы и носящие косы хазары»). Борынгы төркиләр яшәгән төбәкләрдә «Тазлар» исемле топонимнар булуы да очраклы хәл түгелдер, шәт.

Идел-Урал төбәкләрендә әле безнең эрага кадәр ук төрки телдә сөйләшүче кабиләләрнең булуы күпләр тарафыннан гайре табигый хәл дип кабул ителә, әлбәттә. Әмма иксез-чиксез Евразия далаларында әле бронза гасырында ук тереклек итеп килгән күчмә кабиләләрнең яшәү рәвешен, күмү йолаларын, матди культураларының үзенчәлекләрен җентекләп өйрәнсәң, мондый шикле уйларга нигез калмый кебек. Алтайның дөньякүләм атаклы Пазырык курганнарын калдырган кабиләләр, Казахстан далаларында яшәгән саклар һәм уйсуннар, мөгаен, төрки телләрдә сөйләшкәннәрдер, дигән фикер фәндә һаман саен ныклап урнаша бара. Һәрхәлдә бу кабиләләр, кайсы телдә сөйләшкән булуларына карамастан, төрки халыкларның формалашуында мөһим роль уйнаганнар. Ахыр чиктә, безнең эрага кадәр IV–III гасырларда ук тарихи чыганакларда телгә алына башлаган төрки телле һуннарның да элгәреләре булгандыр ич инде.

Һуннар дигәннән. Аларны борынгы төрки кабиләләр исемлегенә кертү-кертмәү мәсьәләсе фәндә әле һаман да бәхәсле булып кала. Эш шунда ки, һуннарның иң атаклы һәм иң борынгы археологик истәлекләре Монголия территориясендә урнаш-

кан, Россия һәм Монголия галимнәре тарафыннан соңгы елларда бик актив рәвештә казып тикшерелә. Аңлашыла ки, һуннарны төркиләр дип түгел, монголлар дип саныйлар анда. Бу бик табигый хәл. Әмма болай да катлаулы тарихны тагын да катлауландыралар гына. Югыйсә бит борынгы болгарлар культурасына хас элементлар (турыпочмаклы чокыр рәвешендәге каберләрдә мәетнең башын төньяк тарафка каратып күмү, мәет янына бер-ике чүлмәк яисә кувшин, ат, сыер, сарык, сирәк булса да эт ише йорт хайваннары суеп кую, кабер төбенә күмер кисәкләре яисә көл сибү һ.б.) һуннарда да, аннан соңгы төркиләрдә дә ачык күзәтелә. Антропологик тикшеренүләр дә борынгы төркиләр белән һуннар һәм хәтта аларга кадәрге кабиләләр белән болгарлар арасындагы уртаклыкны раслыйлар.

Шулай булуга карамастан, безгә таныш болгарларның археологик эзләрен V–VI гасырларга караган материаллардан гына аерып алырга мөмкин. Бу дәвердә болгарлар Азов һәм Кара диңгез буйларында яшәгәннәр, Византия императорларны аларны яллы сугышчылар рәвешендә кулланган. Фәнгә билгеле чыганакларга таянып, болгарлар Көнчыгыш Европага һуннар белән бергә килгән булырга тиешләр дип фаразлыйлар. Аларның элегрәк яшәгән урыннары Төньяк-Көнбатыш Казахстан җирләрендә, Арал диңгезе буйларында түгелме икән? Нәкъ шул төбәкләрдә археологлар Җетеасар культурасын өйрәнәләр. Җетеасар кабиләләре калдырган истәлекләрдә без Идел буе болгарлары культурасының аерым элементларын гына түгел, ә тулы бер комплексын табабыз.

Идел-Алтай форумында тыңланган докладларның күбесе борынгы төркиләр тарихының әле һаман да аз өйрәнелгән, бәхәсле проблемаларына багышланган иде. Казан галимнәрендә яңа археологик материалларны фәнни әйләнешкә кертү максаты куелган бай эчтәлекле чыгышлар арасыннан П. Георгиевның «Дунай Болгариясе культурасында борынгы төркиләр мирасы», Мацумото Тэцуның «Себердә Чжанго чорына караган Кытай көзгеләре (б.э.к. IV–V гасырлар)», С.Г. Боталовның «Көнбатыш Төрки каганаты халыклары арасында культурогенез», Н.Н. Крадин һәм Л. Эрдэнэболдның «Монголиядә Хэрмэн-денж шәһәрлеген тикшерү нәтиҗәләре», Ч. Мунхбояр, Ч. Энхтур һәм Ц. Мунхбатның «Монголиянең Манхан сомонында борынгы төрки сынташлары» һәм М.В. Гореликның «XII–XIV гасырлардагы монгол костюмының декоры турында» дигән докладлары зур кызыксыну уятты.

Соңгы пленар утырышта чыгыш ясап, Алтай университеты профессоры А.А. Тишкин киләчәккә планнар турында сөйләде, борынгы төрки археологиясе өлкәседә җитди уңышларга ирешү бары тик халыкара хезмәттәшлек нәтиҗәсендә генә булырга мөмкинлеген искәртте.

Әлбәттә, программада каралган чараларның иң кызыклысы һәм файдалысы Таулы Алтай республикасында урнашкан археологик истәлекләргә экскурсия ясау иде. Пазырык культу-

расына, һуннар һәм Төрки каганаты чорларына караган курганнарны, таш балбалларны, борынгы шәһәрлекләрнең саклану корылмалаын күреп исләребез китте, Казанга рухланып, ерак бабаларыбыз мирасын тагын да тирәнрәк өйрәнү кирәклеген аңлап кайттык.

«Болгар цивилизациясенең формалашуы, тарихи үсеше һәм мәдәни мирасы» дип аталган IV халыкара Болгар форумы 22–25 октябрьдә Болгариянең Варна шәһәрендә үтте. Оештыручылары Болгария Фәннәр академиясенең Археология институты, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Татарстан Республикасының «Яңарыш» фонды һәм Татарстан мәдәният министрлыгы иде. Форум эшендә безнең яктан Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе М.Ш. Шәймиев, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә.М. Мазһаров, Татарстан мәдәният министры А. Сибагатуллин, Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры Р.С. Хакимов, болгарлар ягыннан Болгария Фәннәр академиясе президенты Е. Николов, Мәдәният министры В. Рашидов, Болгария Фәннәр академиясенең Археология институты директоры Л.Л. Вагалински, Варна шәһәре башлыгы К. Йорданов катнаштылар.

Форум эше Болгария Республикасы президенты Росен Плевнелиевның Котлау хатын укыганнан соң М.Ш. Шәймиев чыгышы белән башланып китте. Сүз уңаеннан әйтеп үтим, аңа Болгария Мәдәният министрлыгын иң югары бүләге – «Златен век» медале тапшырылды, ә Р.С. Хакимов БФА Археология институтының шәрәфле әгъзасы итеп сайланды.

Пленар утырыш башланыр алдыннан башлыча Татарстан һәм Болгария археологлары тарафыннан әзерләнеп, Мәскүнең «Феория» нәшрияты бастырып чыгарган «Bolgarica. Болгар цивилизациясе» дигән атласны тәкъдим итү булды. Аның текст өлешен язуда Россия, Казахстан, Украина, Венгрия галимнәре дә катнашты. Басманың эчтәлеге дә, полиграфик яктан эшләнеше дә галимнәрдә соклану тудырды.

Пленар докладлар белән Ф.Ш. Хузин (Казан), Г. Владимиров (София), П. Георгиев (Шумен), А.А. Тишкин (Барнаул), В. Йотов (Варна), Г. Атанасов (Силистра) һәм Ю.М. Могаричев (Симферополь) чыгыш ясадылар. Сессия утырышларында яңгыраган чыгышлар болгар цивилизациясенең асылын ачыклауга, аның барлыкка килүенә һәм үсешенә ярдәм иткән тарихи факторларны өйрәнүгә, төрле чорларда болгарлар белән бәйләнештә торган халыкларның әлеге цивилизациягә керткән өлешен билгеләүгә багышланган иде.

Докладларда бәян ителгән фактлардан күренгәнчә, «болгар цивилизациясе» – бик шартлы төшенчә икән. Идел болгарлары цивилизациясен Дунай болгарларыныкы белән тәңгәлләштерергә ярамый. Ике тугандаш халык Европаның бер-берсеннән ярыйсы ук ерак торган төрле төбәкләрендә үзләренең




мөстәкыйль дәүләтләрен булдырып, югары мәдәнияткә ия булалар. Кубрат хан заманнарында формалаша башлаган уртак мәдәният болгарлар Урта Иделгә күчеп утыргач зур үзгәрешләр кичерә. Биредә алар фин-угыр халыклары белән аралашалар һәм аларның мәдәни казанышларын үзләштерәләр. Соңыннан, ислам дине кабул ителгәннән соң, болгар цивилизациясе Шәрык мәдәнияты сыйфатларын кабул итә (гарәп графикасы, архитектура һ.б.). Идел болгарларының югары үскән мәдәнияты Алтын Урда цивилизациясенең нигез ташын тәшкил итә.

Аспарух болгарлары исә, Дунай якларына китеп, славяннар белән аралашып бетәләр, хәтта үз телләрен онытып, славян теленә күчәләр. Шул ук вакытта Дунай болгарлары тудырган цивилизациядә биредә элек-электән үк яшәп килгән Фракия һәм Мёзия халыкларының роле зур. Тагын бер факторны искә алып үтмичә булмый. Бусы – антик чор Рим империясенең турыдан туры варисы булган феодаль Византиянең искиткеч югарылыкта торган мәдәнияте. Византиядән православие дине кабул ителгәч, әйтергә кирәк, Болгариянең үзенчәлекле төрки цивилизациясе бөтенләй яңа рәвешкә керә.

Әмма уртак мирас эзсез югалмаган, ул әле бүген дә төрки (татар, чуваш, балкар, карачай), славян (болгар, рус), угыр (венгр), роман (молдова, румын) халыклары мәдәниятында чагылыш таба. Хәтта Көнбатыш Европа илләрендә дә (Австрия, Германия, Италия) бүгенге көнгә кадәр «болгар» тамырыннан ясалган этнотопонимнар сакланган. Бу мәдәни мирас, кызганычка каршы, әле начар өйрәнелгән.

Болгариядә безгә әнә шул, нигезендә борынгы төркиләр мирасы яткан цивилизация шедеврлары белән танышу да насыйп булды. Дунай болгарларының беренче башкаласы Плиска, икенче башкаласы Преслав хәрабәләренә сәяхәт кылдык, таш кыяга уеп ясалган атаклы Мадара җәйдагын карап хозурландык. Варна

шәһәренең Археология музеенда сакланучы уникаль табылдыкларны җентекләп карап чыктык.

Урта гасырларның төрки-татар цивилизациясен шулай төрле яклап, киң планда өйрәнә башладык. Биләр, Сувар, Җүкәтау калалары археологларны күтеп ята. Кырымда, Төньяк Кавказда, Түбән Идел төбәкләрендә урнашкан истәлекләрне казып тикшерү өчен планлы һәм максатчан эшләр алып барырга кирәк. Кыскасы, алдыбызда зур бурычлар тора әле. Варна форумында болар турында да эшлекле сөйләшү булды. Нәтиҗәсе озак көттермәс дип ышанырга кирәк.

*«Мәгариф», 2012. № 12. Б. 65–67.*

# ИДЕЛ БОЛГАРЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ КҮРШЕЛӘРЕ




## РОССИЯ ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕНЕҢ ОЕШУ ТАРИХЫННАН

2012 елда илебездәге иң әһәмиятле иҗтимагый-сәяси вакыйгаларның берсе буларак, Россия дәүләте оешуга 1150 ел тулу датасы билгеләп үтелде. Әлеге дата игътибарыбызны борынгы рус елъязмаларында теркәлеп калган 862 ел вакыйгаларына, хәтта тагын да элгәрерәк чорларга юнәлтә.

Борынгы славян кабиләләре, Одер һәм Висла елгалары бассейнында, хәзерге Польша, Чехия, Словакия җирләрендә, мөстәкыйль этнос буларак оешып, V гасыр ахырында гына Көнчыгыш Европага – Днепр буйларына, төньякта исә Ладога, Онега күлләре тирәсенә, ягъни балт, фин-угыр һәм төрки кабиләләре яши торган җирләргә күчеп утыралар. Нәкъ шушы төбәкләрдә славяннарның полян, древлян, северян, радимич, вятич, кривич, дрегович, словен һәм башка исемнәр белән соңыннанрак рус елъязмаларында телгә алынган кабилә берләшмәләре (союзлары) барлыкка килә. Болар арасында социаль-икътисади үсешләре ягыннан алгарак киткән поляннар һәм словеннар аерылып торган. Инде VIII гасыр урталарында ук поляннар җирендә Киев, словеннар җирендә Ладога кебек кабилә үзәкләре оеша.

Шуны да искәртеп үтик: VIII гасыр ахыры – XI гасыр башы Европа тарихында «викинглар дәвере» буларак билгеле. Викинглар дип Скандинавиядән чыккан төньяк юлбасарларын атаганнар. Аларны бер үк вакытта норманнар (төньяк кешеләре), варяглар, руслар (фин телендә Ruotsi – ишкәкчеләр) дип

тә йөрткәннәр. Сугышчан викинглар – башлыча хәзерге Норвегия җиреннән чыкканнары – корабларга төялеп килеп, Британиягә, континенталь Европа илләренә һөҗүм итеп торганнар, шәһәрләрен, чиркәү хәзинәләре тупланган монастырьларын талаганнар. Һәм аларның бер өлеше әкренләп үзләре талаган җирләрдә төпләнеп тә калган (мәсәлән, Франциянең Нормандия провинциясе әле дә викинглар-норманнар исемен йөртә).

Хәзерге Швеция җирләреннән чыккан викинглар (варяглар, руслар) талау һәм бер үк вакытта сәүдә эшләре белән башлыча Көнчыгыш Европага, славяннар арасына йөргәннәр. Әйе, варяглар – славян авылларына көтелмәгән һөҗүмнәр оештыручы кыю сугышчылар гына түгел, сәүдәгәрләр дә. Идел елгасының сәүдә юлы буларак халыкара күләмдә танылуы нәкъ менә «викинглар чоры»на карый. Күрәсең, талап кына баеп булмаслыгын варяглар бик иртә аңлаганнар; Балтыйк диңгезен кичеп, алар корабларын Иделгә чыгарганнар һәм кайвакыт, Каспий диңгезе аша үтеп, аннан ары коры җир буйлап Багдадка кадәр килеп җитә торган булганнар.

Төньяк славяннар (словеннар) варяглар-руслар белән шул вакытлардан ук аралаша башлыйлар. Һәрхәлдә, археологлар фикеренчә, IX гасырда борынгы Ладога шәһәрен сәүдә үзәге буларак торгызуда варяг килмешәкләренең дә роле зур булган.

IX гасыр көнчыгыш славяннар тарихына хәлиткеч борылышлар, кискен үзгәрешләр чоры буларак кереп калган. Нәкъ менә шушы чорда славян җәмгыятендә борынгы община строе тәмам таркалып, аның урынына яңа феодаль тәртипләр, дәүләтчелек нигезләре ныгып урнаша башлый. Әмма славяннар, кабилә юлбашчылары һәм кенәзләре арасында даими рәвештә барган сугышлар-чуалышлар аркасында мөстәкыйль дәүләтчелек төзү процессын үзләре төгәлли алмыйлар, викинглар-варяглар токымыннан булган русларга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булалар. Ипатьево елъязмачысының 862 ел вакыйгаларына нисбәтле рәвештә теркәп куйган түбәндәге сүзләре зыялы укучыларыбызга таныштыр дип уйлыйм:

*«Тако же и ти словене пришедше и седоша по Днепру и нарекоша поляне, а друзии древляне, зане (потому что. – Ф.Х.) седоша в лесех; а друзии седоша межю Припетью и Двиною и нарекоша дреговичи; инии седоша на Двине и нарекошася полочане, речки ради, иже втечёт в Двину, именем Полота, от сея прозвашася полочане. Словени же седоша около езера Илмеря и прозвашася своим имянем, и сделаша град и нарекоша Новъгородъ. А друзии седоша по Десне, и по Семи и по Суле и нарекоша север...*

*И по сих пор братии (после смерти Кия, Щека и Хорива – легендарных основателей Киева. – Ф.Х.) держати почаша род их княженье в поляхъ, а в деревлях (у древлян. – Ф.Х.) своё, а древговичи своё, а словнени своё в Новъгороде, а другое на Полоте, иже полочане. От нихъ же кривичи,*

*иже седять на верхъ Волги, и на верхъ Двины и на верхъ Днепра, их же град есть Смоленскь; туде бо (именно там. – Ф.Х.) седять кривичи. Таже северъ от нихъ...*

*Се бо токмо славенескъ языкъ в Руси: поляне, деревляне, ноугородьци полочане, дреговичи, северъ, бужане, зане седоша по Бугу, послеже же велыняне...*

*Поляномъ же живущимь особе, якоже рекохомъ (как уже говорили. – Ф.Х.), сущимъ от рода словеньска и нарекоша поляне, а деревляне от словенъ же, и нарекошася древляне; радимичи бо и вятичи от ляховъ. Бяста бо 2 брата в лясехъ, Радим, а другий Вятко, и пришедъша съдоста Радимъ на Съжю, и прозвашася радимичи, а Вятъко седе с родом своим по Оце, от него же прозвашася вятичи. И живяху в мире поляне, и древляне, и северъ, и радимичи, вятичи и хвате. Дулеби живяху по Бугу, где ныне велыняне, а улучи и тиверьци седяху по Днестру, приседяху къ Дунаеви. Бе множьство ихъ; седяху бо по Днестру оли до моря, и суть гради их и до сего дне, да то ся зваху от грекъ Великая Скуфь...* (Повесть временных лет. СПб., с. 8–10, 144, 146.

*«И всташа словене, и кривици, и меря, и чюдь на врягы, и изгнаша я за море; и нача владети сами собе и городы ставити. И въсташа сами на ся воевать, и бымть межи ими рать велика и усобица, и въсташа града на град, и не беше в них правды. И реша к себе: «князя поищемь, иже бы владелъ нами и рядилъ ны по праву» Идоша за море к варягом и ркоша: «земля наша велика и обильна, а наряда (порядка) у нас ней нету; Да поидите к нам княжить и володеть нами. И избраша трие брата с роды своими и придоша к словенам первее, и срубиша город Ладогу. И седе старейший в Ладоге Рюрик, а другий Синеус на Белоозере, а третей Трувор в Изборске».* (Новгородская первая летопись.., 1950, с. 106).

Шул ук елъязмачы күрсәткәнчә, ике елдан соң Синеус белән Трувор ниндидер сәбәпләр аркасында үлеп китәләр. Рюрик үзенең резиденциясен хәзерге Новгород тирәсенә күчерә. Әлеге резиденция археологлар тарафыннан яхшы тикшерелгән, ул фәндә Рюрик шәһәрлеге (Рюриково городище) дип йөртелә. Бер гасырдан артык вакыт үткәч кенә Новгород Төньяк Русенең башкаласына әверелеп китә (Х гасыр ахырына кадәрге культура катламы Новгородта әлегәчә табылмаган). Елъязманың 864 ел белән тамгаланган өлешендә мондый сүзләр бар:

*«... и прия (принял) Рюрик власть один, и пришед к Ильмерю (Ильменскому озеру), и сруби(л) город над Волховом. И седе тут княжа, и раздая мужам своим волости и городы: овому Полтеск (Полоцк), овому Ростов, другому Белоозеро. И по тем городам суть находнице варяги; первие наследници в Новегорде словени, и в Полотьске кривичи, Ростове меряне, Белеозере весь, Муроме мурома. И тем всем обладаше Рюрик».*

Елъязмачының югарыда китерелгән сүзләрен анализлап караганнан

соң шундый нәтиҗәләргә килергә мөмкин: 1) Рус дәүләтенең беренче кенәзе Рюрик (Рёрик) словеннар чакыруы буенча 862 елда Ладога шәһәренә килеп утыра, димәк, дәүләтнең әүвәлге башкаласы да (кенәз резиденциясе) шунда урнашкан була; 2) ике елдан соң башкала Рюрикның махсус салынган шәһәрчегенә күчерелә; 3) елъязмада Төньяк Русеның якынча чикләре, биләмәләре дә күрсәтелгән – Новгород, Полоцк, Белоозеро, Ростов һәм Ока елгасы буенда урнашкан Муром җирләре. Шул җирләрдә утырган славян һәм фин-угыр халыклары (чудь) Рюрик оештырган дәүләткә салым түләп торган.

879 елда Рюрик вафат була. Аның дәвамчысы булып әле бик яшь улы Игорь (Ингвар) түгел, бәлки якын туганы Олег (Һельг) кала. 882 елда Олег Днепр буенда төпләнеп утырган көньяк славяннарның баш шәһәре Киевка уңышлы яу чаба, анда хакимлек итүче рус кенәзләре Аскольдны һәм Дирны үтереп, Төньяк Русе белән Көньяк Русен берләштерә. Шулай итеп, башкаласы Киев булган Борынгы Русь дәүләте барлыкка килә.

Күргәнегезчә, көнчыгыш славяннарда дәүләтчелек барлыкка килү тарихы Балтыйк аръягыннан килгән варяглар (руслар) белән турыдан-туры бәйләнгән икән. Рус кенәзе Рюриктан башланып киткән династия XVI гасыр ахырына кадәр – җиде гасырдан артык хакимлек итә. Руслар (варяглар) үзләре төзегән дәүләткә дә, шул дәүләт чикләрендә яшәүче славяннарга да үз исемнәрен тагалар.

Бүген тарих фәнендә рәсми танылган әлеге теория (советлар чорында рус дәүләтчелегенең «норман теориясен» гел тәнкыйтьләп килделәр) язма һәм археология чыганаклары белән тулысынча исбатлана. Киев Русе белән Византия арасында 911, 944 елларда Олег һәм Игорь Рюрикович исемле кенәзләр вакытында төзелгән солых килешүенә игътибар итик. Анда әлеге килешүне төзегәндә катнашкан рус илчеләре һәм сәүдәгәрләренең исемнәре санала: *Ивор, Вуефаст, Һельга, Слуды, Улеб, Каницар, Шихберн, Сфандр, Прастен, Турд, Либиар, Фост, Грим, Сфирк, Студек, Егри, Ерлиск, Войк, Аминд, Берн, Гунар, Клек, Стегги, Етон, Алвад, Фруди, Тулб, Мутур, Адунь, Адулб, Фрутан, Турберн, Руалд* һ.б. – барлыгы 50 гә якын исем, шулар арасында бары тик өчесенеке генә славяннар теленнән алынган (Святослав, Владислав, Предслава). Димәк, дәүләт төзелеп бер гасыр чамасы вакыт үткәч тә хакимияттә башлыча рус (варяг) вәкилләре утырган булып чыга (Памятники, 1952, с. 6,19; 30, 36).

Руслар (варяглар) күмелгән каберлекләр археологлар тарафыннан Смоленск янындагы Гнёздово, Ярославль өлкәсендәге Тимерёво авыллары янында, Чернигов, Новгород, Ладога тирәләрендә һәм башка урыннарда казып тикшерелде (Ярославское Поволжье, 1963; Славяне и скандинавы, 1986; Русь в IX–X веках, 2012). Русларның археологик эзләре Татарстан һәм күрше Ульян өлкәсе җирләрендә дә сакланган (Кирпичников, Измай-

лов, 2000; Измайлов, 1999; 2000; 2003; Семыкин, 2002; Стальсберг, 2000).

Рус дәүләте төзелү славяннарның социаль-икътисади һәм сәяси яктан зәгыйфьлеген түгел, киресенчә, дәүләтчелекләрен булдыра алу дәрәҗәсенә җиткән югары үсешен күрсәтә.

### Файдаланылган әдәбият


*Горский А.А.* Русское средневековье. Традиционные представления и данные источников. М.: Изд-во АСТ, 2023. 283 с.

*Измайлов И.Л.* «Русы» в Среднем Поволжье (этапы булгаро-скандинавских этно-социальных контактов и их влияние на становление городов и государств // Международные связи, торговые пути и города Среднего Поволжья IX–XII веков. Материалы международного симпозиума / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: «Мастер-Лайн», 1999. С. 94–100.

*Измайлов И.Л.* Балымерский курганный могильник и его историко-культурное значание // Средневековая Казань: возникновение и развитие. Материалы междунар. науч. конф. (Казань, 1–3 июня 1999 г.) / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань:»Мастер-Лайн», 2000. С. 190–206.

*Измайлов И.Л.* Балымерский курганный могильник в свете контактов Северной Европы и Волжской Булгарии: проблемы и дискуссии // Ладога и истоки русской государственности и культуры / Отв. ред. А.Н. Кирпичников.. СПб.: ИПК «Вести», 2003. С. 127–141.

История России в 2 тт. Т. 1. С древнейших времён до конца XVIII в. / Под ред. А.Н. Сахарова. М.: Изд-во АСТ; ЗАО НПП «Ермак»; Изд-во «Астрел», 2003. 943 с.

*Кирпичников А.Н., Измайлов И.Л.* Каролигские мечи из Булгарии (из фондов Государственного Объединённого музея Республики Татарстан // Средневековая Казань: возникновение и развитие. Материалы междунар. науч. конф. (Казань, 1–3 июня 1999 г.) / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань:»Мастер-Лайн», 2000. С. 207–218.

Новгородская первая летопись старшего и младшего изводов / Отв. ред. М.Н. Тихомиров; под ред. и с предисл. А.Н. Насонова. . М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1950. 565 с.

Памятники русского права. Выпуск первый. Памятники права Киевского государства X–XII вв. / Под ред. прооф. С.В. Юшкова; сост. А.А. Зимин. М.: Гос. изд-во юридич. лит-ры, 1952. 287 с.

Повесть временных лет. Изд-е 2-е, испр. доп. / Подговка текста, перевод статьи и коммент Д.С. Лихачёва; под ред. В.П. Адриановой-Перетц. СПб,: Наука, 1996. 667 с.

Русь в IX–X веках: археологическая панорама / Отв. ред. Н.А. Макаров. М.; Вологда: Изд-во «Древности Севера», 2012. 496 с.

*Семыкин Ю.А.* Находка кольцевой скандинавской фибулы из Ульяновского Поволжья // Великий Волжский путь: история формирования и развития. Материалы Круглого стола «Великий Волжский путь и Волжская Булгария» и Междунар.науч.-практич. конф. «Великий Волжский путь». Казань – Астрахань – Казань, 6–16 августа 2001 г. Часть II / Отв. ред. Р.Р. Хайрутдинов. Казань, 2002. С. 246–252.

Славяне и скандинавы. Перевод с немец. / Общая ред. Е.А. Мельниковой. М.: Прогресс, 1986. 416 с.

*Стальсберг Анне.* Находки скандинавского происхождения IX–XI вв. в Волжской-Камской Булгарии // Средневековая Казань: возникновение и развитие. Материалы междунар. науч. конф. (Казань, 1–3 июня 1999 г.) / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань:»Мастер-Лайн», 2000. С. 235–238.

Ярославское Поволжье X–XI вв. По материалам Тимерёвского, Михайловского и Петровского могильников / Под ред. А.П. Смирнова. М.: Изд-во «Северная Россия», 1963. 144 с., 19 л. табл.




# ИДЕЛ БОЛГАРЛАРЫ, СЛАВЯННАР ҺӘМ БОРЫНГЫ РУСЬ: ЭЛГӘРЕГЕ УРТА ГАСЫРЛАР ЧОРЫНДА МӘДӘНИ-ИКЪТИСАДИ ҺӘМ ЭТНОСӘЯСИ БАГЛАНЫШЛАР

IX–X гасырлар чигендә барлыкка килеп, 1236 елга кадәр чәчәк атып яшәгән Идел Болгарстаны – борынгы бабаларыбызның VII гасырда ук Кубрат хан тарафыннан оештырылган кыска гомерле Бөек Болгар дәүләте җимерелеп, ике гасыр чамасы Хазар каганлыгында яшәп алганнан соң төзелгән яңа мөстәкыйль дәүләте – күрше фин-угыр һәм төрки халыклары белән генә түгел, Киев Русе, ул таркалганнан соң эреле-ваклы Рус кенәзлекләре, Европа һәм Шәрык илләре белән дә тыгыз икътисади, сәяси һәм мәдәни бәйләнештә торган. Бу тарихи бәйләнешләр рус елъязмаларында чагылыш тапкан. Болгар археологисе материаллары исә язма чыганакларда сакланып калган мәгълүматларны тагын да тулыландыра, ачыклый төшә.

Якынча бер үк табигый-географик шартларда барлыкка килү сәбәпле социаль-икътисади һәм мәдәни үсеш дәрәҗәләре ягыннан да охшаш булган күршедәш Рус дәүләте һәм Идел Болгарының үзара бәйләнешләрен бер сүз белән генә йә һәрдаим дустанә, йә сугышчан характерда булган дип әйтә алмыйбыз. Алар арасында тыныч хезмәттәшлек күршеләре белән тышкы сәүдә мөнәсәбәтләре, кайвакыт хәтта идеология өлкәсендә килеп чыккан каршылыклар аркасында еш кына бозылып торган, ә бу исә эреле-ваклы хәрби бәрелешләргә китергән.

Совет чоры тарихи әдәбиятында, шул исәптән, югары уку йортлары студентларына, урта мәктәп укучыларына адресланган дәреслекләрдә болгарларның сугышчан характерда булуына аеруча басым ясап, күпертеп язалар иде, Имештер, алар рус шәһәрләренә һәм авылларына үзләренең бертуктаусыз булып торган яулары

нәтиҗәсендә зур зыян салганнар, тыныч хезмәт кешеләрен үтергәннәр, яндырганнар, әсирлеккә алып китеп, коллар сыйфатында Шәрык базарларына озатканнар. Имештер, Идел ярларында барлыкка килгән Городец, Түбән Новгород кебек элгәреге рус калалары да болгар яуларына каршы хәрби крепостьлар рәвешендә төзелгәннәр. Имештер, Рус кенәзлекләре белән аларның фин-угыр күршеләре арасында сәяси һәм икътисади бердәмлек оешкан һәм бу бердәмлек аларга, фин-угыр халыкларына, сугышчан болгар яуларыннан яклауны гарантияләгән (Жиганов, 1976, с. 73; Балыкина, 1997, с. 21, 22).

Татарстан галимнәре, үзләренең коллегалары алдында акланган рәвештәрәк, чынбарлыкта исә рус һәм болгарларның үзара бәйләнешләр тарихында тыныч сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләр өстенлек иткәнен раслап килделәр, илнең икътисади тормышына артык зыян китерми торган эреле-ваклы сугышлар урта гасырлар тарихы өчен гадәти нәрсә икәнлегенә басым ясадылар. Рус-болгар сәяси багланышларын шушы күзлектән чыгып аңлатуны XVIII гасыр тарихчысы һәм дәүләт эшлеклесе В.Н. Татищев хезмәтләреннән таба алабыз: *«...Болгары, хотя иногда с русскими воевались, однако ж видно, что немного о том прилежали и не искали чужаго преобрести, но своё паче защищать старались... В плодах земных они преизобиловали, что неоднократно Руссию во времена недородов житами довольствовали и более о ремёслах и купечестве прилежали (Татищев, 1962, с. 269)*.

Монгол яуларына кадәрге рус-болгар хәрби-сәяси бәйләнешләренең динамикасын өйрәнгәндә тарихчыларның борынгы рус елъязмаларында теркәлеп калган кыйммәтле хәбәрләргә таяну мөмкинлеге бар. Елъязмачылар, иң борынгы «Повесть временных лет»тан башлап, илдәге вакыйгалар агышы белән тирәнтен кызыксынып торганнар һәм үзләренең хроникаларына җентекләп теркәп барганнар.

Бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган елъязма хәбәрләренә караганда, болгарлар белән руслар арасындагы иң әүвәлге хәрби бәрелеш **964** (965) елда булган;. Ул кенәз Святославның Хазар каганатын җимерүгә юнәлтелгән һәм шактый кан коюлы яу буларак тасвирлана. Россия Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Россия тарихы институты директоры А.Н. Сахаров болай дип яза: «Ока-Идел төбәкләрендәге урманнарны, вятичлар яши торган җирләрне кичеп, Святослав башта Хазариянең союздашы Идел Болгарын җимереп ташлый, аның башкаласын һәм башка шәһәрләрен яулап ала, халкын пыран-заран китерә. Берочтан ул Руська дошман булып торган бортасларны да җиңә, аларның шәһәрләрен басып ала, яндыра, ә халкын тирә-юньгә таратып бетерә» (История России, 2003, с. 65; шулай ук карагыз: Сахаров, 1982, с. 96–99).

Елъязмаларда сакланып калган кыска гына икенче хәбәр **977** елга карый:

*«В лето... Иде Володимир на Радимици и Болгаре и победи их»* (ПСРЛ, т. XVI, 1889, с. 38).

Күренекле болгарчы галим, профессор А.П. Смирнов фикеренчә, Киев кенәзе Владимир Святославич оештырган әлеге яу очраклы бер хәрби авантюра рәвешендә генә булып, алдына бернинди аерым сәяси максат куймаган һәм болгар күршеләренә ниндидер дошманлык хисе белән сугарылмаган (Смирнов, 1951, с. 43). Моның шулай булмаганлыгын соңгырак чорга караган вакыйгалар күрсәтеп тора.

Әдәбиятта Владимирның **985** елда Болгар иленә чапкан икенче явы күбрәк билгеле (чөнки югары уку йортлары, урта мәктәп дәресләкләренә дә кертелгән) һәм ул элегрәк ясалган 977 елгы яу очраклы гына булган дигән версиянең дөреслеген шик астына куя. «Повесть временных лет» болай яза:

*«Иде Володимир на Болгары с Добрыною с воем своим в лодиях, а Торки берегом приведе на коних и победи Болгары. Рече Добрына Володимеру: съглядах колодникъ (осмотрел пленных. – Ф.Х.), иже суть вси в сапозех, сим дани нам не давати. Поидем искать лапотников. И сътвори мир Володимер с Болгары и роте заходиша (дали клятву. – Ф.Х.) межю собе и реша Болгаре: толи не будет межю нами мира, елико камень начнёт плавати, а хмель почнёт тонути. И приде Володимер Киеву»* (ПСРЛ, 1962, т. I, стб. 65).

Кайвакыт бу яу тарихи әдәбиятта болгарларның руслар тарафыннан вятичлар җиренә ясаган яуларын яклап түгел, киресенчә, гаепләп чыкканы өчен җавап рәвешендә ясалган дип карала. 985 нче елгы яуның «күркәм» максатын Владимирның һәм аның абыйсы Добрыняның «руслар эшенә болгарларның килеп тыкшынуын» тыярга тырышу теләге рәвешендә кабул итәргә чакыралар (Членов, 1981, б. 76). 985 елгы вакыйгаларның асылын болай аңлату ялгыш һәм бернинди документаль чыганаклар белән расланмаган. Руслар белән болгарлар арасында төзелгән солых килешүенең әһәмиятен күпертеп күрсәтү дә («йөз елдан артыкка сузылган тынычлык») реаль фактларга каршы килә. Безгә билгеле булмаган ниндидер сәбәпләр аркасында Владимир Святославич даны чыккан шул килешү шартларын ике мәртәбә боза:

*«В лето 6502 **(994)**. Ходи Володимир на Болгары и много ратовав их победи и възвратися с радостию в Киев».* (ПСРЛ, т. IX, с. 65).

*«В лето 6505 **(997)**. Ходи Володимир на Болгары воложскиа и камские и одолев плени их»* (ПСРЛ, 1965, т. IX, с. 66).

Күргәнебезчә, X гасыр дәвамында, төгәлрәге, йөзеллыкның икенче яртысында, Киев Русе Болгар иленә каршы 5 хәрби яу оештыра. Тарихи чыганакларда болгарларның җавап рәвешендәге яулары турында хәбәрләр юк.

Елъязмаларның түбәндә китерелгән кыска гына хәбәрләре кызык. Шул ук вакытта уйланырга да мәҗбүр итә:

*«В лето 6596 (**1088**). В се же лето взяша болгаре Муром»* (ПСРЛ, 1962, т. I, с. 207).

Үзенең «Россия тарихы»н язганда безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән елъязма материалларын киң кулланып эш иткән XVIII гасыр тарихчысы В.Н. Татищев үзенең хезмәтендә югарыда китерелгән хәбәрнең тулырак вариантын тәкъдим итә:

*«... В та же времена были на Волге и Оке разбои и многих болгар, торгующих пограбили и побили. Болгары же присылали ко князю Ольгу и брату его Ярославу просить на разбойников, но не получа управы и взятого, пришед с войски. Муром взяли и пограбили, а сёла пожгли»* (Татищев, 1963, с. 144).

Аңлашылганча, әлеге яуда руслар үзләре гаепле булып чыга. Кем белә, бәлки, болгарларның башка яулары да тиктомалдан гына түгел, күршеләренең агрессиясенә җавап рәвешендәрәк булгандыр?

Болгарлар ягыннан тагын бер яу, сәбәбе билгеле түгел:

*«В лето 6615 (**1107**)... В се же лето чюдо сътвори Бог и Святая Богородица в Суждалстеи земле. Приидоша Болгаре ратью на Суждаль и обьступиша град и много зла сътвориша, воююща села и погосты и убивающе многых от крестьян. Сущии же людие в граде, не могуще противу их стати, не сущю князю у них, на молитву к Богу обратишяся и к пречистеи его Матери покаанием и слезами и затворишяся в граде. И всемилостивый Бог услышав молитву их и покаание... сих избави от бед, ослепиша бо вся ратныа Болгаре, и та из града изшедше, всех избиша»* (ПСРЛ, 1921, т. XXIV, с. 72–73).

Билгеле булганча, 1117 елда кыпчакларның руслар белән союзлык мөнәсәбәтләрендә торган ханы Аепа болгарларга яу белән килә, әмма ул уңышлы булып чыкмый. Ханның үзен агулап үтерәләр. Шуннан соң кенәз Георгий (Юрий Долгорукий) көндәшләренә каршы үзе сугыш белән барырга карар кыла:

*«В лето 6628 (**1120**). Ярослав ходи на Половци за Дон и не обрет их воротися опять и Георги, брат его, ходи на Болгары и взя полон мног и полк их победи…»* (ПСРЛ, 1962,т. I, с. 292; 1962, т. II, с. 285–286).

Болгарлар белән руслар арасында килешү төзелә һәм ул озак еллар буена бозылмыйча саклана. Килешүне нинди дер сәбәпләр аркасында болгарлар боза:

*«В лето 6660 (**1152**)... Того же лета приидоша Болгаре по Волзе к Ярославлю без вести и оступиша градок в лодиях, бе бо мал градок, и изнемогаху людие в граде гладом и жажею, и не бе льзе никому же изити из града и дати весть ростовцем. Един же уноша от людей ярославских нощию изшед из града, перебред реку, вборзе доеха до Ростова и сказа им. Ростовци же пришедша, победиша Болгаре»* (ПСРЛ, 1921, т. XXIV, с. 77).

Болгарлар җиңелә, әмма алар руслар алдында үзләренең шактый көчле, җитди уңышларга ирешә алырдаай гаскәр икәнлеген дә күрсәтеп

алалар. Нәкъ менә шушы яудан соң руслар Иделдә, Ока тамагыннан ерак түгел бер җирдә, Городец крепостен төзергә керешә. Имештер, болгарлар агрессиясенә каршы, чынбарлыкта исә Урта Идел төбәкләрендә ныгып калу, Бөек Идел сәүдә юлында өстенлек итү өчен.

Рус дәүләтенең тышкы сәясәтендә кискен үзгәрешләр Юрий Долгорукийның улы Андрей Боголюбский хакимияте вакытында башлана.

*«В лето 6672 (**1164** )… В то же лето иде князь Андреи (Боголюбский. – Ф.Х.) на Болгары с сыном своим Изяславом и с братом своим Ярославом и с Муромьскым князем Гюргем, и поможе им Бог и святая Богородица, самех исекоша множьство, а стягы их поимаша и одва в мале дружине утече князь Болгарьскыи до Великого города на Черемисане (Биляра. – Ф.Х.). Князь же Ондреи воротися с победою, видев поганыя Болгары избиты… и шедше взяша град их славный Бряхимов*[1]*, а переди городы их пожгоша…»* (ПСРЛ, 1962, т. I, с. 352–353).

Сүз уңаенда әйтеп үтик: әлеге язмада без беренче мәртәбә Биләрне Олуг шәһәр дигән яңа исеме белән күрәбез – «Великий город на Черемисане». Элегрәк аны Болгар дип тә йөрткәннәр (карагыз: Биляр – столица, 1991).

1164 елгы уңышлы яу белән рухланган руслар Болгар иленә тагын бәреп керергә батырчылык итәләр. Андрей Боголюбскийның уллары үзләренең Рязаньдагы һәм Муромдагы союздашлары белән Болгарга 1172 елның кышында яңа яу оештыралар, авыл-шәһәрләрен талыйлар, әмма бу вакытта болгар бабаларыбыз да исләренә киләләр, дошманнарны Ока аръягына куып чыгаралар.:

*«В лето 6680 (**1172**)… Тое же зимы посла князь Андреи (Боголюбский. – Ф.Х.) сына своего Мстислава на Болгары и Муромскыи князь сына своего и Рязаньскыи князь сына своего. Бысть не люб путь всем людем сим зане непогодье се зиме воевати Болгар и падуче не идяху бывшю же князю Мстиславу на Городьци совкупльшюся (со) братома своима с Муромьскым и с Рязаньскым на устье Окы и ждаша дружины две недели и не дождавше ехаша с переднею дружиною Борису Жидиславичю воевода бе в то время и наряд весь держаще и въехаша в поганыя без вести, взяша сел шесть, а семои город, мужи исекоша, а жены и дети поима. Слышавше же Болгаре в мале дружине князя пришедша (и) идуша опять с полоном доспеша борзе и поехаша по них в шесть тысяч за малым не постигоша их за двадцать верст князю Мстиславу на устьи с малою дружиною всю дружину пустившю от собе и взврати от него Бог поганыи Болгары христьяны покрыв рукою своею слышавше бо наши се прославиша Бога заступи бо очивесть от поганых святая Богородица и христианьска молитв…»* (ПСРЛ, 1962, т. I, с. 346, 363).

[1] Ул Болгар шәһәре, яисә Нижний Новгород дип фаразлыйлар. Соңгысы булырга бик мөмкин.

Яңа бәрелешләрдән болгарларны көтелмәгән бер хәл генә коткарып кала – Андрей Боголюбскийны үтереп ташлыйлар. Үтерүчеләр арасында аның хатыны да була. Тверь елъязмачысы хәбәрләренә караганда, кенәз Андрей: *«убиен бысть от своих бояр, от Кучковичев, по научению своеа ему княгини. Бе бо болгарка родом и дрежаще злую мысль, не про едино зло, нои просто, иже князь великий много воева с ним Болгарскую землю, и сына посыла, и много зла учини болгарам»* (ПСРЛ, 1965, т. XV, с. 250, 251).

Андрей Боголюбскийның агрессив планнарын Всеволод Зур Оя дәвам итә. Ул болгарларга каршы 1183, 1185, 1205 елларда сугыша. Иң көчле яу 1183 елда дәүләтне башкаласы Бөек шәһәргә оештырыла һәм ул елъязмаларда шактый тулы чагылыш тапкан:

*«В лето 6691 (**1183**)*[2]*. Иде князь Всеволод (на Болгары) со Изяславом Глебовичем сыновцем своим и с Володимером Святославичем и с Мстиславом Давидовичем и с Глебовичи Рязаньскаго с Романом и со Игорем и со Всеволодом и с Володимером и с Муромьскым Володимером (и) приде в землю Болгарьскую и высед на берег поиде к Великому городу и ста у Тухчина городка*[3] *и перестояв ту два дни, поиде на третии день к Великому городу. Сторожем наперед ездящем оттоле же Белозерскыи полк отряди к лодьям, а воеводьство да Воме Лазковичю пошедшю же князю в поле узреша наши стороже-ве полк в поли и мняху Болгарьскыи полк и приехаша пять муж ис полку того и удариша челом перед князем Всеволодом и сказаша ему речь: кляняются, княже, Половци Емяковы, пришли есмы со князем Болгарьскым воевать Болгар. Князь же Всеволод здумав с братьею своею и с дружиною води их в роту в Половьцьскую поима их поиде к Великому городу и приде князь к городу и перешед Черемисан в первый день наряди полкы, а сам поча думати с дружиною. Изяслав же Глебович, внук Юргев, доспев с дружиною возма копье потече к плоту, где бяху пеши, вышли из города твердь учинивше плотом. Он же въгнав за плот к воротом городным изломи копье и ту удариша его стрелою сквозе броне под сердце и принесоша и ле жива в товары. Болгаре же из города и в Собекуля и из Челмата поидоша в лодья, а ис Торцьскаго на коних на лодье наши и приехавше им на лодье. Наши же Божьею помощью укрепляеми поидоша против им. Они же видевше побегоша, а наши погнаша секуще поганыя Бохмиты и прибегше к Волзе (въскакаша) в учаны и тако истопаша боле тысячи их. Божьим гневом гоними и святою Богородицею и Всеволода князя молитвою князь же Всеволод стояв около города десять дней. Видев брата изнемогающа и Болгаре выслалися бяху к нему с миром, поиде опять к*

[2] Әлеге яуның датасы төрле елъязмаларда төрлечә күрсәтелгән. Без Н.Г. Бережков китабында фәнни расланган датаны кабул итеп алабыз (Бережков, 1963, бб. 82, 201).

[3] Урнашкан урыны бүгенге көнгә кадәр тәгаенләнмәгән болгар шәһәрчеге.

*исадом и ту на исаде Бог поя Изяслава и вложиша и в лодью, князь же Всеволод възвратился в Володимер. А коне пусти на Мордву…»* (ПСРЛ, 1962, т. I, с. 390).

*«В лето 6694 (**1186**)… Того же лета посла великыи князь Всеволод Гюргевич на Болгары воеводы свое с городьчаны и взяша (села) многы и възвратишася с полоном (многым)…»*

*«В лето 6713 (**1205**)… Того же лета посыла князь велики Всеволод Юрьевич рать судовую на Болгары Воложскиа и Камскиа и ходиша по Волзе до Хомол*[4] *и много полона взяша, а других изсекоша. Учан много разбиша. И това много взяша. И тако възвратишася во своаси…» (ПСРЛ, 1965, т. X. с. 50).*

*«В лето 6726 (**1218**)… Приидоша Болгаре на Устюг и взяша и лестию и потом идоша ко Унжи и унжане отбишася от них …»* (ПСРЛ, т. VIII, 1859, с. 126).

*«В лето 6728 (**1220**) Георгии великыи князь сын Всеволожь посла брата своего Святослава с полкы и воеводами на безбожныя Болгары и яко приде Святослав под град их ошель и изидоша из лодьи вси полци пеши, видевше же еи безбожнии Болгаре скоро доспевше ови на коних, а друзии пеши устремишася на бои и изидоша из града противу. Наши же силою креста честнаго укрепляеми поидоша противу им стреляюще. Они же забегше за плот бьяхутся крепко, наши же расекше плот, вбиша в град и отяша у них врата и зажгоша град их и взяша и на щит и поможе Бог Святославу…»* (ПСРЛ, 1949, т. XXV, с. 116–117).

Шулай итеп, елъязмаларда чагылыш тапкан 16 хәрби яуның 12-се руслар тарафыннан болгарларга каршы ясалган. Алар арасыннан бишесе X гасырның икенче яртысына (965, 977, 985, 994, 997 еллар), бишесе XII гасырга (1120, 1164, 1172, 1183, 1186 еллар), икесе XIII гасырның беренче чирегенә карый (1205, 1220 еллар).

Болгарлар русларга каршы барлыгы 4: XI гасырда – 1 (1088 елда Муромга), XII гасырда – 2 (1107 елда, Суздальга, 1152 елда Ярославльга), XIII гасырда тагын бер яу оештыралар (1218 елда Устюгка).

Бер уйласаң, югарыда китерелгән саннарга артык ышанырга кирәкми, чөнки үзебезнең елъязмалар сакланмаган, ә урыс елъязмачылары «вактөяк» талау сугышларын телгә дә алып тормаган булырга мөмкин. Алар мәнфәгатендә түгел ич ул, киләчәк буыннарга калдырырга теләмәгәннәрдер.

1220 елларда Көнчыгыш Европада халыкара хәл Урта Азия һәм Кавказ якларында башланып киткән монгол-татар яулары белән бәйле рәвештә кискен үзгәрә. Шул шартларда, монголларның Болгар иленә сугыш белән килү мөмкинлекләренә тәмам ышанган болгар ханнары *(«хотят болгаров более покорить»)* әле 1221 елда ук, ягъни «кичәге» Ошель су-

[4] Урнашкан урыны бүгенге көнгә кадәр тәгаенләнмәгән болгар шәһәре.

гышыннан соң, Владимир-Суздаль кенәзләренә мөрәҗәгать итәләр: *«болгары, уведав о том, прислали послов с прозбою о мире»* (Татищев, 1963, т. 3, с. 209). Әмма бөек кенәз Юрий (Георгий) Всеволодович ризалашмый, алай гына да түгел, үзе болгарларга каршы яуга әзерләнә башлый: *«послал в Ростов известие Василько Константиновичю, повеле итти ему к Городцу. Сам же пошел к Омуте»*, чөнки биредә аны инде болгар илчеләре көтеп торган була: *«с мольбою и челобитием, просяще мира»* (ПСРЛ. 1965, т. XV, с. 117). Менә шундый кыен вакытта Юрий Всеволодович үз сугышчылары белән Городецка килеп җитә, Ростовтан килеп өлгергән дружинниклар белән кушыла. Биредә аны болгарларның инде өченче делегациясе көтеп тора: *«и послали к нему на Городец третьи посли с мольбою великою и с дары многими и с челом биемь»* (ПСРЛ. 1965, т. XV, с. 117). Ниһаять, бөек кенәз, бәлки, монгол баһадурлары Җебе белән Субәдәй гаскәрләренең рус кеәзлекләренә дә янаган куркынычын сиземләптер, болгарларның солых килешүе турындагы катгый тәкъдимнәрен кабул итәргә карар кыла: *«управившася по прежнему миру, яко же было при при отци его Всеволоде и при деде его Георгии Володимеричи, и посла с ними мужи свои водити роту князи их и земли их по их закону»* (ПСРЛ. 1965, т. XV, с. 117).

1229 елда болгар хакимнәренең гозерләп тәкъдим ителгән башлангычы буенча 1221 нче елгы килешү яңартыла: *«Того же лета Болгаре поклонишася великому князю Юрью, прося мира на шесть лет, и сътвори с ними миръ, и уверися с ними во всем талме и людми»* (Сборник материалов, 1941, т. II, с. 155–156).

Миңа калса, күрше дәүләтләр арасында еш булып торган хәрби бәрелешләр күп очракта һәр ике якның да Идел сәүдә юлында үзләренең позицияләрен ныгыту максатында оештырылган. Бөек Идел юлы Көнбатыш – Көнчыгыш, Төньяк – Көньяк регионнары арасында оешкан халыкара сәүдә мөнәсәбәтләре системасында әһәмиятле урын тоткан. Гомумән алганда, халыкара сәүдә, безнең очракта Бөек Идел Юлы, бер үк вакытта Болгар иле белән Рус дәүләте арасындагы дуслык мөнәсәбәтләренең дә, дошманлык мөнәсәбәтләренең дә сәбәпчесе булып торган.

Бу фикерне елъязмаларда тышкы сәясәт һәм идеология өлкәсенә караган хәбәрләр дә куәтли. Моңа мисаллар күп. Мәсәлән: Болгар ханы үзенең Киевтагы шымчылары аша кенәз Владимир Святославичның мәҗүсилеккә каршы көрәшен, рәсми дин сыйфатында инде күрше дәүләтләрдә күптән яшәп килгән христиан, яһүд йә ислам диннәренең берсен кабул итәргә әзер торуын белеп ала. Һәм озак та уйлап тормыйча, Киевка, Владимир кенәзгә, махсус илчелек җибәрә:

*«В лето 6494 (986 г.). Придоша Болгаре веры Бохьмиче, глаголюще: «Яко ты, князь, еси мудр и смыслен, не веси закона, но веруи в закон наш и поклонися Бохмиту (Мухаммаду.*

*– Ф.Х.)». И рече Володимер: «како есть вера ваша. Они же реша: веруем Богу, а Бохмит ны учит, глаголя: обрезати оуды таиные и свинины не ести, вина не пити, а по смерти же, рече, со жёнами похоть творити блудную. Даст Бохмит комуждо по семидесяти жён красных, исберёт едину красну и всех красоту възложит на едину, та будет ему жена... Володимир же слушаше их бе бо сам любя жёны и блуженье многое, послушаше сладко, но се ему бе нелюбо обрезанье оудов и о неяденьи мяс свиных, и о питьи отнудь рька: на Руси есть веселье питье, не можем бес того быти».* (ПСРЛ, 1962, т. I, с. 84).

Шулай да Владимир кискен карар кабул итеп ашыкмаска карар кыла, 987 елда Болгар иленә ислам йолалары белән тулырак танышу өчен бер төркем кешеләрен җибәрә. Лаврентий елъязмасы хәбәр итә:

*«В лето 6495 (987 г.). Созва Володимир боляры своя и старци градские и рече им: се приходише ко мне болгаре, рекуще, прими наш закон. Посемь же приходиша Немци – и те хваля закон свои... и реша им: идите первое в Болгары*[5] *и испытаите первое веру их. Они же идоша и пришедше видеша скверньая дела и кланянье в ропати (мечети. – Ф.Х.) и придоша в землю свою... И созва князь боляры своя и старци. Рече Володмимр: се придоша послании нами мужи, да слышим о них бывшее и рече: скажите пред дружиною. Они же реша: яко ходихом в Болгары, смотрихом, како ся покланяют в храме, рекше ропати, стояще бес пояса, поклонився сядет и глядит семо и онамо, яко бешен, и нет веселья в них, но печаль и смрад велик, не добро закон их»* (ПСРЛ, 1962, т. I, с. 85).

Кыскасы, исламнан баш тартып, 988 елда Византиядән кергән православие динен кабул итәләр. Алай гына түгел, мөселманнар арасында православие динен пропагандалау максаты белән Владимир 990 елда Марк Македонянин исемле христиан рухание җитәкчелегендә миссионерлар төркемен Болгарга җибәрә:

*«Посла Володимир философа, нарицаемого Марка Македонянина в Болгары... глаголя: яко приходиша ко мне прежде, егда ещё не просвещён беху верою православною, хваляще свою веру скверную... Ты же иди к ним и проповежь им слово Божие яко да веруют в Господа Бога и Спаса нашего Исуса Христа и да крестятся божественным его крещением и с нами единоверни и единосветни будут... Философ же иде в Болгары и много глаголав им слово Божие; они же безумием своим обьеродеша. Он же възвратися к Володимеру в Киев и много чествован бысть от него и от всех похвален. Того же лета придоша из Болгар к Володимеру в Киев четыре князи и просветишася божественным крещением»* (ПСРЛ, 1965, т. IX, с. 58–59).

Бер караганда дүрт болгар кешесенең православие диненә күчүе артык зур вакыйга түгел. Андый очраклар

[5] Биредә «Болгары» шәһәр түгел, Болгар иле мәгънәсендә кулланылган.

да булгандыр, әлбәттә, шулай да бу вакыйганың православие идеологиясе белән бәйләп җибәреп тарихка кертеп калдыру үзенә күрә кызыклы факт.

Хронология тәртибен бозып булса да, болгарлар белән руслар арасындагы ислам һәм православие мөнәсәбәтләренә караган тагын бер гыйбрәтле вакыйганы искә төшереп үтик. 1229 елда Биләрдә (Олуг шәһәрдә) Авраамий исемле бер христиан кешесен үтереп ташлыйлар. Сәбәбе төгәл билгеле түгел. Бериш галимнәр Авраамийны болгарларның хәрби куәте турында яшерен мәгълүматлар җыеп, урысларга тапшырып баручы шымчы сыйфатында күрәләр, икенчеләре исә, халыкны ачыктан-ачык православие диненә күчәргә котыртып йөргән ялкынлы пропагандист-миссионер булгандыр ул, дигән караштa торалар. Соңгысы, минемчә, дөреслеккә күбрәк туры килә. Башта аны Биләрнең христиан зиратына күмәләр (*«идеже вси христьяне лежат»*), бер ел үткәч, җәсәден Владимир шәһәренә күчерәләр. Соңрак Аврамийны православие дине өчен кан коеп шәһид киткән «новый мученик» сыйфатында изгеләр исемлегенә кертеп куялар (ПСРЛ, 1962, т. I, с. 452).

Яңадан элгәрерәк чорга әйләнеп кайтыйк.

Рус-болгар багланышлары тарихында XI гасырны, документаль чыганакларның азлыгын күз алдында тотып булса кирәк, «караңгылык чоры» дип атыйлар: елъязмалардагы бары тик өч кыска гына хәбәр әлеге багланышлар динамикасын тулысынча күзалларга мөмкинлек бирми. Шулай булуга карамастан, әлеге хәбәрләр ярыйсы гына күрсәтмәле һәм ике күрше дәүләт арасында өстенлек иткән реаль бәйләнешләрне чагылдыралар. 1006 елгы килешү (В.Н. Татищев язмасында) Болгар иле белән Киев Русе арасында яхшы оештырылган һәм төгәл регламентлаштырылган сәүдә мөнәсәбәтләре урнашкан булуын раслап тора:

*«Прислали болгары (волские) послов с дары многими, дабы Владимир позволили им в городах по Волге и Оке торговать без опасения, на что Владимир охотно соизволил. И дал им во все грады печати, дабы они везде и всем вольно торговали, и русские купцы с печатьми от наместников в Болгары с торгом ездили без опасения; а болгарам все их товары продавать во градах купцам, и от них купить, что потребно; а по сёлам тиунам, вирникам, огневщине и смердине не продавать и от них не купить»* (Татищев, 1963, с. 69).

Лаврентий елъязмасында Суздаль җирендә башланып киткән 1024 елгы ачлык вакытында болгарларның русларга ашлык белән ярдәм итүләре хакында кыска гына язма сакланып калган:

*«... бе мятеж велик и голод по всеи той стране, идоша по Волзе все людье в Болгары и привезоша жито и тако ожиша...»* (ПСРЛ, 1962, т. I, с. 148).

Рус елъязмачылары, аңлашыла ки, сирәк һәм гадәти булмаган вакыйгаларны гына теркәп барганнар.

Шунлыктан ике ил арасында даими рәвештә барган сәүдәнең торышы турында тарихи мәгълүматлар язма документларда түгел, бәлки археологик чыганакларда күбрәк сакланып калган.

Соңгы елларга кадәр X–XI гасырлардагы рус-болгар сәүдә бәйләнешләре турындагы мәгълүматларыбыз югарыда китерелгән елъязма хәбәрләре белән генә чикләнә иде. Аннан кала, Рус дәүләтеннән Болгар иленә чыгарыла торган тауарлар исемлеген тулыландыру өчен шул заманнарда яшәгән Ибн Рөстә, әл-Балхи, әл-Гардизи, әл-Мөкаддәси кебек Шәрык авторлары әсәрләреннән файдаландык (Халидов, 2001; Хузин, 2006, с. 104–105). Археологиядә эзләрен калдырмый торган тауарлар исемлегендә әлеге авторлар еш кына колларны күрсәтеп үтәләр:

*«Алар (руслар) славяннарга һөҗүм итеп торалар, көймәләргә утырып, алар яшәгән җирләргә юнәләләр, аларны әсирлеккә төшерәләр, Хазаран һәм Болгарга алып киләләр, саталар»* (Заходер, 1967, с. 81). Руслар да, болгарлар да чолыкчылык – кыргый умартачылык продуктлары белән сату иткәннәр; балык, җәнлек тиреләре кебек тауарлар экспорты халыкара сәүдәнең мөһим тармагы саналган. Болгардан чыгарыла торган югары сыйфатлы тирене Шәрекъ илләрендә «болгари» дип, русларда «юфть» дип йөрткәннәр.

Болгарларның тышкы сәүдә өлкәсенә караган белемнәребезне археология чыганаклары нык тулыландыра. Болгар экспорты тауарлары (кайвакыт хәтта болгар сәүдәгәрләренең даими яшәү эзләре) Киев, Чернигов, Иске Рязань, Муром, Городец, Суздаль, Владимир, Углич, Ростов, Новгород һәм башка Борынгы Русь шәһәрләрен казыганда килеп чыга. Ул тауарлар башлыча керамик һәм бакыр савыт-саба, сфероконус, хайван сурәтләре (күбесенчә мөгезле барс) рәвешендә бронзадан ясалган сандык һәм кечкенә тартма йозаклары, хатын-кыз бизәнү әйберләреннән гыйбәрәт (Полубояринова, 1993, с. 98 и сл.). Аерым табылдыклар, шул исәптән Болгарда сугылган X йөз көмеш тәңкәләре Псков һәм Новгород өлкәләрендә, Белоруссиядә, Украинада һәм Молдовада, Балтыйк буе һәм Скандинавия илләрендә, Венгриядә билгеле (Кропоткин, 1986). Биредә 902–908 еллар аралыгында сугылган иң борынгы болгар акчасының да Новгород казылмаларында (1956 ел, икенче Нерев хәзинәсе) табылуын искә төшереп үтү урынлы булыр (Янина, 1962, с. 179).

Заманында академик В.Л. Янин: «VIII гасыр ахырларыннан башлап XI гасыр башларына кадәр Болгар чынбарлыкта Шәрык илләре белән алып барылган сәүдә капкасы ролен үтәгән», – дип язган иде (Янин, 1956, с. 105). Болгар Урта Азия һәм гарәп илләре белән турыдан-туры бәйләнештә торган, ул илләрдән исә тәңкәләр һәм бизәнү әйберләре рәвешендә искиткеч күп көмеш китерелгән. Болгардан гарәп дирһәмнәре Ока елгасы буйлап вятичлар җиренә, Киевка килеп җиткән; көмеш «агымы» Югары Идел төбәкләренә, Новгород-

ка, Ладога, Балтыйк буе һәм Скандинавия илләренә кадәр таралган.

Киев Русеннан, соңыннанрак, феодаль таркаулык чорында, Болгарга төрле кенәзлекләрдән китерелгән товарлар археологик казулар вакытында бик еш табыла.

Биләр болгарларның атаклы халыкара сәүдә үзәкләреннән саналган. Чит ил товарларының күбесе Киев Русеннан һәм рус кенәзлекләреннән китерелгән. Киевтан ерак түгел генә урнашкан Овруч каласы тирәсендә шифер – шәмәхә, сирень чәчәге төсендәге йомшак таш ятмалары бар. Шифер ташларын эшкәртеп, X гасырда ук тормыш-көнкүрештә бик тә кирәкле орчык башлары ясау һөнәрчелеге барлыкка килә. Киев сәүдәгәрләре шул товар белән бөтен Европа базарларын тутыралар. Гади халык аны бик теләп сатып алган. Биләрдәге казылмалардан 160 ка якын шифер орчык башлары табылды (музей коллекцияләрендә элегрәк тупланган очраклы табылдыкларны да исәпкә алсаң, аларның саны 300 дән артып китә). Киевта пыяла савыт-саба ясау һөнәрчелеге дә алга киткән була. Ул заманнарда киң кулланышка әле керә генә башлаган, шунлыктан базар бәясе шактый кыйммәт торган пыяла флаконнар, банкалар, рюмкалар, дөресрәге, аларның кыйпылчыклары, Биләр казылмаларында еш очрый (Полубояринова, 1993, с. 33 и сл.; Макаров, 2001, с. 7 и сл.; Хузин, 2006, с. 107). Балтыйк буенда чыгарыла торган гәрәбәне дә болгарларга рус сәүдәгәрләре алып килгән дип фаразлана.

XII гасырда Биләр күбесенчә Владимир-Суздаль кенәзлеге һәм Бөек Новгород белән сәүдә итә. Бу җәһәттән игътибарыгызны рус һөнәрчеләренең Биләрдә казып тикшерелгән остаханәләренә юнәлтәсем килә. Алар эчке шәһәр үзәгендә урнашкан.

Казылмалардан күтелмәгәндә Болгар шәһәрләрендә моңа кадәр беркайчан табылмаган дуңгыз сөякләре килеп чыкты. Каян килеп кергән бу харәм ризык мөселманнар арасына? Сорауга җавапны тиз таптык: йорт тирәсендәге бер хуҗалык чокырында Юри Долгорукийның улы кенәз Всеволод Зур Ояның кургаштан коелган мөһере ята иде. Аның бер ягына изге Дмитрий Солунскийның сугыш киемендәге сурәте, икенче ягына изге Георгийның атка атланган сурәте төшерелгән (Янин, Гайдуков, 1998, с. 142, № 212-2, табл. 95; Седова, 1985, с. 357–359). Мондый мөһерләр белән гадәттә әһәмиятле документларны, кенәзләр, күрше илләр белән төзелгән язма килешүләрне беркетеп куйганнар. Тагын бер табылдык – христианнарның пасха бәйрәме көннәрендә кулланыла торган бизәкле йомырка (ул балчыктан әвәләп эшләнгән) – биредә, һичшиксез, рус гаиләсе яшәгәнлегенә шик калдырмады.

Бу торак йорт бер үк вакытта остаханә ролен дә үтәгән. Аны тикшергәндә археологлар 6 килограммга якын эшкәртелмәгән гәрәбә кисәкләре җыеп алдылар. Күрәсең, болгарлар тарафыннан махсус чакыртылган рус остасы биредә Балтыйк буеннан кайтарылган гәрәбәдән байлар заказы буенча бизәнү әйберләре ясап көн

күргәндер. Шундый ук һөнәрче-ювелир күрше йортта да яшәгән (Хузин, 1979, с. 78–79).

Биләр табылган рус әйберләрен тикшергәндә башка бер фикер килә: биредә рус кешеләре – сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр – аерым бер бистә булып урнашмаганнар микән? Бик мөмкин. Кыска гына вакытка, сезонлы эшкә килгән кешеләргә охшамаган алар. Югарыда әйтелгәнчә, аларның бит Биләрдә үзләре өчен генә тәгаенләнгән аерым зиратлары да булган.

Русьтан кергән товарлар арасында тимер йозак, сөяк тараклар, пыяла беләзекләр, сердолик, тау хрустале ише асылташлардан эшләнгән бизәнү әйберләре дә бар. Руслар үзләре белән балчык чүлмәкләр дә алып килгәннәр. Сату өчен түгел – алар түбән сыйфатлы. Килә-килүгә ул чүлмәкләрне хуҗалыкта, башлыча, аш пешерү өчен кулланганнар, аннан соң әкренләп болгар осталары җитештергән сыйфатлы савыт-сабага күчкәннәр.

Шунысы аерым игътибарга лаек: тарихчы галимнәр рус кенәзлекләренең икътисади тормышында Идел Болгарстаны тоткан урынны кайвакыт шулкадәр арттырып күрсәтәләр ки, хәтта болгарларга каршы хәрби яуларын да шул традицион сәүдә мөнәсәббәтләрен җайга салу зарурлыгы белән аңлаталар. Профессор Ю.А. Лимонов язганча, «болгарлар тарафыннан даими рәвештә сәүдә килешүләренең бозылуы Владимир-Суздаль җирләрендә генә түгел, Киев, Галич, Новгород, Смоленск төбәкләрендә дә җитди финанс кризисы китереп чыгарган һәм дәүләт казнасына искиткеч зур зыян китергән» (Лимонов, 1987, с. 140). Бозмаганнар алар сәүдә килешүләрен! Ике як өчен дә файдалы нәрсә бит сәүдә. Болгарлар да үзләрендә җитештергән товарларны рус базарларында сату өчен ашкынып торганнар. Владимир, Суздаль, Галич, Городец кебек шәһәрләрдә болгар һөнәрчеләре даими торып эшләгән. Шуңа күрә сәүдәгәрләре дә ике яклы килешү нигезендә тыныч сәүдә итү ягында булганнардыр дип уйларга кирәк. Рус тарихчылары шул яклап дөрес әйтәләр: Русия дәүләтчелегенең икътисади нигезен ныгытуда Идел Болгарстаны белән алып барылган җанлы сәүдә зур роль уйнаган. Моны инкарь итеп булмый.

Тарихи әдәбиятта озак вакытлар, XI гасыр ахырларына кадәр Киев белән Урта Идел төбәкләрен тоташтыра торган туры юл булмаган, дигән фикер өстенлек итеп килде. Сәүдә юлы Смоленск аша Югары Иделгә чыккан, ягъни мәсәлән, болгарларның тышкы сәүдәсе башта Новгородка һәм Новгород җирләренә, соңыннанрак Владимир-Суздаль кенәзлегенә юнәлтелгән була, дип уйлыйлар иде (Кузьмин, 2003, с. 162). Украина һәм Татарстан археологларының А.П. Моця һәм А.Х. Халиков җитәкчелегендәге берләштерелгән экспедициясе нәтиҗәләреннән күренгәнчә, гарәп географы әл-Идриси тарафыннан 1154 елда төшерелгән Киев – Болгар сәүдә юлы (Рыбаков, 1969) әле IX гасырда ук оешкан икән (Путь, 1992; Моця, Халиков, 1997).

Профессор А.П. Смирнов узган гасырның алтмышынчы елларында ук бик дөрес язган иде: «Болгарларның Русь белән күбесенчә тыныч яшәү проблемасы бары тик археология материаллары нигезендә генә хәл ителде. Бу мәсьәләгә елъязмачылар артык игътибар бирмәгәннәр, башлыча тышкы сәясәт турында, хәрби яулар, бәрелешләр турында язганнар... Русь белән Идел Болгары арасында 400 ел буена системалы рәвештә барган эреле ваклы сугышлар рус һәм болгарларның тыныч мәдәни багланышларын күләгәдә калдырып килгән» (Смирнов, 1968, с. 167). Бу сүзләр бедән килешергә була.

**Файдаланылган әдәбият:**

*Балыкина Л.Е.* Население средневекового Городца-на-Волге // Древности Нижегородского Поволжья. Вып. I. Н. Новгород, 1997. С. 17–30.

*Бережков Н.Г.* Хронология русского летописания. М.: Изд-во АН СССР, 1963. 376 с.

*Валиулина С.И.* Международная торговля Биляра по археологическим данным // Международные связи, торговые пути и города Среднего Поволжья IX–XII вв. Материалы Международ. симпозиума / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: Мастер-Лайн, 1999. С. 140–154.

*Валиулина С.И.* Стекло Волжской Булгарии. (По материалам Билярского городища). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2005. 280 с.

*Жиганов М.Ф.* Память веков. Изучение археологических памятников мордовского народа за годы советской власти. Саранск, 1976.

*Заходер Б.Н.* Каспийский свод сведений о Восточной Европе. Т. II. Булгары, мадьяры, народы Севера, печенеги, русы, славяне. М.: Наука, 1967. 212 с.

*Кочкина А.Ф.* Находки древнерусской керамики на Билярском городище // Волжская Булгария и Русь / К 1000-летию русско-булгарского договора / Отв. ред. А.Х. Халиков.. Казань, 1986. С. 117–122.

*Кропоткин В.В.* Булгарские монеты X в. на территории Древней Руси и Прибалтики // Волжская Булгария и Русь. (К 1000-летию русско-булгарского договора / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань, 1986. С. 38–62.

*Кузьмин А.Г.* История России с древнейших времен до 1618 г. Учебник для студентов вузов. Кн. 1. М., 2003.

*Лимонов Ю.А.* Владимиро-Суздальская Русь. Очеркеи социально-политической истории / Отв. ред. Б.А. Рыбаков. Л.: Наука, 1987. 214 с.

*Макаров Л.Д.* Древнерусское население Прикамья в X–XV вв. (Материалы и исследования Камско-Вятской археологической экспедиции. Т. 1). Ижевск: Изд. дом «Удмуртский университет», 2001. 140 с.

*Моця А.П., Халиков А.Х.* Булгар – Киев: Пути. Связи. Судьбы. Киев: Наукова думка, 1997. 192 с.

*Полубояринова М.Д.* Русь и Волжская Болгария в X–XV вв. М.: Наука, 1993. 123 с.

ПСРЛ. Т. I. Лаврентьевская летопись и Суздальская летопись по Академическому списку. М.: Изд-во вост. лит-ры, 1962 (1846). 580 с.

ПСРЛ. Т. II. Ипатьевская летопись. М.: Изд-во вост. лит-ры, 1962 (1908). 938 с.

ПСРЛ. Т. IX–X. Патриаршая или Никоновская летопись. М.: Наука, 1965 (1862). 244 с.; 266 с.

ПСРЛ. Т. XV. Летописный сборник, именуемый Тверской летописью. Рогожский летописец. М.: Наука, 1965. VIII, 186 с.: VII, 504 с.

ПСРЛ. Т. XXIV. Типографская летопись. М., 1921. 272 с.

ПСРЛ. Т. XXV. Московский летописный свод конца XV века. М.; Л., Изд-во АН СССР, 1949. 464 с.

Путь из Булгара в Киев / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань, 1992. 133 с.

*Рыбаков Б.А.* Путь из Булгара в Киев // Древности Восточной Европы / Отв. ред. Л.А. Евтюхова. М.: Наука, 1969. (МИА. № 169). С. 189–196.

*Сахаров А.Н.* Дипломатия Святослава. М.: Междурародные отношения, 1982. 240 с.

*Седова М.В.* Актовая княжеская печать из Суздаля // «Слово о полку Игореве» и его время. М.: Наука, 1985. С. 357–362.

*Седова М.В*. К вопросу об атрибутации одной группы княжеских актовых печатей // Биляр и Волжская Булгария: изучение и охрана археологических памятников. Тез. науч. конф. / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань, 1997. С. 77–78.

*Смирнов А.П.* Волжские булгары. (Тр. ГИМ. Вып. XIX). М., 1951. 275 с.

*Смирнов А.П.* Древняя Русь и Волжская Булгария // Славяне и Русь / Отв. ред. Б.А. Рыбаков. М.: Наука, 1968. С. 167–172.

*Татищев В.Н.* История Российская. Т. I. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1962. 500 с.

*Татищев В.Н.* История Российская. Т. II. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1963. 352 с..

*Халидов А.Б.* Перечни товаров Волжского пути в арабских источниках IX – начала XIII в. // Великий Волжский путь. Материалы Круглого стола и Междунар. науч. семинара / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: Мастер-Лайн, 2001. С. 189–193.

*Хузин Ф.Ш.* Рядовые жилища, хозяйственные постройки и ямы цитадели // Новое в археологии Поволжья. (Археологическое изучение центра Билярского городища) / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1979. С. 62–99.

*Хузин Ф.Ш*. Великий город на Черемшане / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 1995. 223 с.

*Хузин Ф.Ш*. Булгарский город в X – начале XIII вв. Казань, 2001. 480 с.

*Хузин Ф.Ш.* Ранние булгары и Волжская Булгария. (VIII – начало XIII в.). – Казань, 2006. 583 с.

*Хузин Ф.Ш., Валиуллина С.И.* Славяно-русские материалы в Биляре // Волжская Булгария и Русь / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань, 1986. С. 97–116.

*Членов А.М.* Из истории ранних русско-булгарских политических связей // Из истории ранних булгар / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань, 1981. С. 69–82.

*Янин В.Л.* Денежно-весовые системы русского средневековья. Домонгольский период. М.,.: Изд-во МГУ, 1956. 207 с.

*Янин В.Л., Гайдуков П.Г.* Актовые печати в Древней Руси X–XV вв. Т. III. Печати, зарегистрированные в 1970–1996 гг. М.: Интрада, 1998. 502 с.

*Янина С.А.* Новые данные о монетном чекане Волжской Болгарии X в. // МИА. 1962. № 111. (Тр. Куйбышев. археол. эксп. Т. IV). С. 153–178.

*«Волжские булгары, славяне и Древняя Русь: культурно-экономические и этнополитические связи в раннем средневековье»*
*из кн.: Тр. Гос. Эрмитажа. Вып. XLIX:*
*Сложение русской государственности в контексте*
*раннесредневековой истории Старого Света.*
*Материалы Междунар. конф., состоявшейся 14–18 мая 2007 года*
*в Государственном Эрмитаже. СПб.: Изд-во ГЭ, 2009. С. 227–234.*
*(Мәкалә авторының ирекле тәрҗемәсендә бирелә)*




## ТАТАРЛАР ҺӘМ БАШКОРТЛАР – КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР

«Кардәш» сүзе «карындаш» сүзеннән кыскартылып ясалган, аны бер ана (ата-ана) балалары, якын туганнар мәгънәсендә аңларга кирәк. Татарлар белән башкортларны кардәш халыклар дибез икән, димәк, бу аларның борынгы бабалары бер, шулай булгач, телләре, яшәү рәвешләре, матди һәм рухи мәдәниятләре дә белән бер-берсенә бик якын дигән сүз.

Этногенез, ягъни халыкларның этнос буларак формалашу процессы, этнография, антропология, археология, тарих, тел белеме фәннәрендә комплекслы рәвештә өйрәнелә торган проблемаларның иң катлаулыларыннан санала. Башкортлар белән татарларны чагыштырып карыйк: антропологик яктан алар бере-берсеннән шактый аерылып торалар – башкортларда монголоид элементлары күбрәк. Хуҗалык итүдә, яшәү рәвешендә дә соңгы вакытларга кадәр аермалыклар бар иде: чын башкортлар, дала халыкларына хас булганча, башлыча, һәрхәлдә, XVIII–XIX йөзләргә кадәр, күчмә тормыш алып барганнар һәм терлекчелек белән шөгыльләнгәннәр, безнең бабаларыбыз исә, Урта Идел табигате шартларында инде X–XI гасырларда ук утрак тормышка күчеп, шәһәр-калалар корып яши башлыйлар. Әмма ике халык арасында охшаш яклар күбрәк, минемчә. Телләрне әйтеп тә тормыйм инде – безләргә тылмач кирәкми! Динебез – бер, борынгыдан килгән һәм соңыннанрак ислам диненә яраклаштырылган гореф-гадәтләребез дә берүк диярлек. Шул сәбәпледер инде, вакыт-вакыт кайбер җавапсыз сәясәтчеләребез авызыннан, без – бер халык, башкорт теле татар теленең көнчыгыш диалекты гына ул, ике халыктан җиңел генә бер халык ясап була дигәнрәк мәгънәсез сүзләр дә чыгып куя.

Татар-башкорт тарихына якынрак килик. Һуннар дәүләте, Төрки (Түрк) каганлыклары белән бәйле чорлар – хәзерге көндәге барлык төрки халыкларның уртак тарихы. Ә менә татарларның VII–VIII гасырлардан башланып киткән тарихы, башка тугандаш халыкларныкыннан үзгә буларак, болгарлар белән тыгыз бәйләнгән. Болгарлар калдырган археологик мирасның күпчелеге Татарстан җирендә. Башкортостанда монгол яуларына кадәрге болгар истәлекләре булса да, әлегә берән-сәрән генә.

Алай икән, кайдан килә соң ул күзгә чалынып торган башкорт-татар бердәмлеге? – диярсез. Җавап: ике халык өчен дә бер төрле һәм тагын да борынгырак җирле компонентлар бар һәм ул мари, удмуртларның борынгы бабалары булган фин-угыр кабиләләре белән бәйле. Алып карагыз тагын элгәреге болгарлар чорына караган Танкеевка каберлеген (Татарстан, Спас р-оны). Биредә ачылган 1200 кабернең яртысыннан артыгында борынгы угырлар (шул исәптән мадьярлар) йоласы буенча күмелгән кешеләр ята. Шундый ук каберлекләр Башкротостан җирендә дә күп. Алар да бит хәзерге татар һәи башкортларның этногенезында катнашкан кабиләләр исәбендә.

XI гасыр ахырларыннан башлап Идел белән Урал арасындагы җирләргә кыпчаклар үтеп керә башлый. Монгол яуларыннан соң, Алтын Урда чорында, кыпчаклар миграциясе тагын да активлаша. Нәтиҗәдә болгарлар үзләренең телләренә бик якын булган кыпчак телендә сөйләшә башлыйлар. Шундый ук процесс башкорт кабиләләре арасында да күзәтелә. Ике халык арасындагы телләр бердәмлеге шуның белән аңлатыла. Лингвистика фәнендә татарлар белән башкортларны төрки телләрнең болгар-кыпчак төркеменә кертеп карыйлар. Шуны да онытмаска кирәк: Алтын Урда чорында ике күршедәш халык яулап алучылар оештырган көчле бер дәүләт кысаларында яши башлый. Бу хәл башкортлар белән татарларның тагын да ныграк берләшүенә китерә. Башкорт җирләрендә дә, Болгардагы кебек үк, аксөякләр нәселеннән булган затларны таш төрбәләрдә күмә башлыйлар, баерак кешеләрнең каберләре өстенә эпиграфик ташлар куялар. Ике күршедәш халыкны ислам дине һәм аның йолалары да берләштерә.

Монгол яуларына кадәрге чордагы болгарларга әйләнеп кайтыйк әле.

Урта гасырларда дәүләт һәм аерым кабилә-халыклар яши торган территория чикләрен, елга-тау ише табигый чикләр булмаган очракта шартлы рәвештә генә күрсәтеп килгәннәр. Кайбер язма чыганакларга караганда, хәзерге Башкортостанның төньяк-көнбатыш төбәкләре башта Болгар дәүләте, соңыннанрак, Алтын Урда таркалганнан соң, Казан ханлыгы биләмәләре составына кергән. (Исегезгә төшерәм: 1229 елда болгарларның сугышчан отряды монгол-татарларны тагын да ерактарак – Җаек елгасы тирәсендә, хәзерге Оренбург якларында каршы алалар). Археология материаллары ачык күрсәткәнчә, болгарлар бит хәзерге Ульян, Самара,

Пенза өлкәләрендә, хәтта ерак Пермь якларында да күпләп яшәгәннәр. Шул ук вакытта коми-пермякларның, удмурт, мари, мордваларның борынгы бабалары Болгар иленә килеп-китеп йөргәннәр, бер өлеше биредә үзләренең икенче ватанын тапкан. Менә шундый шартларда нишләп әле башкортлар аралашып яшәмәсеннәр ди болгар күршеләре белән?! Дөрес, халык чагыштырмача аз утырган чиктәш җирләрдә аларны күбесенчә болгарларның мул үләнле көтүлекләре генә кызыктырган, шул җирләрдә алар болгар чабаннары белән дә аралашканнар, көтү сезоны беткәч, кире кайтып китә торган булганнар. Әмма башкортлар таралып утырган җирләрне монгол яуларына кадәр үк Кече Чирмешән елгасы буенда урнашкан Биләр каласына кадәр киңәйтеп күрсәтү – бернинди фактлар белән расланмаган турыдан-туры ялганга бару нигә кирәк башкорт галимнәренә? Болгар бабаларыбыз калдырган археологик эзләр, югарыда әйтелгәнчә, ерак күршеләребезгә кадәр таралган. Нишләп әле ут күршеләре – башкорт җирләрен генә үзләштерә алмаганнар икән алар? Ягъни, яшәмәгәннәр микән безнең болгарлар башкортларның тагын да көнчыгыштарак яткан эчке төбәкләрендә дә? Әйе, археологик материаллар нигезендә элегә бу сорауга уңай җавап бирү мөмкин түгел. Болгар материаллары башкорт археологларын кызыксындырмаган, максатчан тикшеренүләр үткәрелмәгән. Безнең карашка, шуңа күрә генә әз алар.

Әмма дә ләкин башкортларның үзләренә кирәк булганда табалар алар болгар эзләрен. Бу җәһәттән Башкортостан башкаласы Уфада соңгы елларда күренекле археолог, Башкортостан Фәннәр академиясе академигы, башкортларның Бөтендөнья корылтае Башкарма комитеты рәисе, Башкортостан халыкларының Ассамблея советы рәисе Н.А. Мәҗитов җитәкчелегендә үткәрелгән экспедиция материаллары кызыклы. Әлеге экспедиция Уфаның нәкъ үзәгендә сакланып калган борынгы шәһәрлек урынын казып тикшерде. Уфа-II дип атала ул археологик истәлек һәм башкорт археологлары тарафыннан хәзерге Уфаның башлангычы, элгәрегесе дип игълан ителде. Ул V гасырдан башлап 1574 елга кадәр, ягъни хәзерге Уфа җирлегендә Казаннан җибәрелгән укчылар (стрелецлар) тарафыннан Уфа крепосте төзелгәнчегә кадәр яшәгән шәһәрлек, имештер. Менә шул шәһәрлек материаллары арасыннан Н.А. Мәҗитов элгәреге болгарларның VIII–IX гасырларга караган чүлмәк китекләрен аерып ала[1]. Бик хуп! Шулай икән, соңгырак чорлардагы, монгол яуларына кадәр яшәгән болгарлар башкорт күршеләре белән аралашып тормаганнар дип кем әйтә ала? Болгарлар, соңрак исә татарлар да, төрле сәбәпләр, бигрәк тә 1236 һәм 1552 елгы афәтләр аркасында

[1] Мажитов Н.А., Сунгатов Ф.А., Иванов В.А., Саттаров Т.Р., Султанова А.Н., Иванова Е.В. Городище Уфа-II. Т. I. Материалы раскопок 2006 года. Уфа, 2007. С. 35. Безнең фикеребезчә, әлеге шәһәрлек инде VIII гасыр ахырларында ук яшәүдән туктаган.

Кама аръягыннан Татарстанның төньяк-көнчыгыш һәм Башкортостанның төньяк-көнбатыш төбәкләренә күпләп күчеп утырганнар, даими яшәү өчен уңайлы урын тапканнар, дип фаразларга нигез бар (мәсәлән, башкорт шәҗәрәләрендә телгә алынган бүләр/биләр кабиләләре). Бу фаразны аксиома дәрәҗәсенә җиткерү өчен, әлбәттә, башкорт коллегаларыбыз белән бергәләп безне кызыксындырган төбәкләрдә максатчан тикшеренүләр үткәрү таләп ителә.

Бүгенге көннәргә кайтыйк. Билгеле булганча, автономияле республикаларның чикләрен нигездә 1920 елларда рәсми рәвештә билгеләп куялар. Беркемгә дә сер түгел: дәүләтчелегенең меңъеллап тарихы булган татарларга элек-электән урыс патшалары да, аннан соңгы җитәкчеләр дә үзләренең көндәшләренә караган кебек сагаебрак карадылар, җае чыккан саен аларны көчсезләндерергә омтылдылар. Халык саны буенча урыслардан һәм татарлардан кала өченче урында торган башкортларның автономияле республикасы 1919 елда ук территориясе ягыннан Татарстанныкына караганда ике мәртәбәдән артыкка зуррак итеп төзелде (халык саны бер чама) һәм аның төньяк-көнбатыш районнарында бүген дә татарлар гына яши. (Сүз уңаенда әйтеп үтик: хәзерге Мари Эл, Чувашия республикаларындагы, Ульян һәм Самара өлкәләрендәге Татарстан белән чиктәш районнарның да төп халкын татарлар тәшкил итә). Татарларда борын-борыннан толерантлык көчле: күршеләре белән һәрвакыт дустанә яшәгәннәр. Хәзер дә шулай. Башкортлар белән дуслыкны әйтеп тә торасы түгел: бер үк җырларны җырлыйбыз, бер үк шагыйрьләрнең шигырьләрен укыйбыз-тыңлыйбыз, яраткан артистларыбыз ике республиканың да атказанган һәм халык артисты исемнәрен йөртә.

Әлбәттә, башкортларның санын арттырабыз дип төрле юллар белән татарларның милләтен үзгәртү сәясәте белән һич тә килешеп булмый. Бу сәясәткә башкортлар үзләре дә каршы. Җитәкчеләр дә аңлар әле дип ышанырга кирәк. Гасырлар буена, буыннан-буынга сузылган туганлык җепләрен өзәргә маташу акылга сыймый торган нәрсә.

*Мәгариф. 2023. № 11. Б. 47–50;*
*Гаилә һәм мәктәп. 2023. № 11. Б. 12–14.*










## ЧУАШЛАРНЫҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

Борынгы һәм урта гасырлар чорында яшәгән халыкларның килеп чыгышын тикшергәндә гадәттә иң әүвәл археология чыганакларына мөрәҗәгать итәләр. Бу аңлашыла да, чөнки, беренчедән, борынгы чорлардан тарихи документлар (язма чыганаклар) күп очракта сакланып калмаган, яисә бик аз сакланган (аннан соң әле ул вакытларда күпчелек халыкларда язмачылык та булмаган бит әле); икенчедән, археология материаллары ел саен күбәя, тулылана бара һәм ул материалларны (артефактларны) тикшерү-анализлау ысуллары да камилләшә. Хәтта безнең институт кысаларында да пыялага, төсле металлга спектраль анализ ясау, агачтан, күннән, төрле тукымалардан ясалган әйберләрне консервацияләү һәм реставрацияләү лабораторияләре эшләп килә. Нәтиҗәдә казылмалардан чыккан табылдыклардан күбрәк информация алу мөмкинлеге туа. Әлеге информация нигезендә борынгы җәмгыятьләрнең икътисадын, мәдәниятен, тормышның социаль, рухи, көнкүреш һәм башка сфераларына караган якларын шактый тулы, тирән, кыскасы, дөрес итеп реконструкцияләү процессы җиңелләшә. Әмма ләкин археология чыганакларының информацион мөмкинлеклрен арттырып күрсәтергә дә ярамый. Аларны башка фәннәрдән алына торган мәгълүматләр белән бер комплекс итеп куллныргa кирәк. Ул комплекста беренче чиратта лингвистика (тел), этнография, антропология, фольклористика кебек фәннәр туплаган мәгълүматләр булырга тиеш. Ул фәннәрнең үзләренә генә хас тикшеренү ысуллары, димәк, мөстәкыйль нәтиҗәләре, фикерләре бар. Ә ул нәтиҗәләр башка фәннәрдән алына торганнары белән килешеп-ярашып бетмәскә дә мөмкин. Еш кына алар бер-берсенә каршы киләләр хәтта. Ул очракта инде каршылыкларның сәбәбен эзләргә кирәк, үзеңнең

нәтиҗәләргә төзәтмәләр кертү зарурлыгы да килеп чыгарга мөмкин.

Чуаш этногенезын археология чыганакларына таянып өйрәнгәндә, беренче чиратта, безнең карашка, Урта Иделнең уң ягында, Зөя белән Сура елгалары арасынд урнашкан торак урыннарының, борынгы зиратларның мөмкин кадәр төгәлрәк даталарын һәм анда яшәгән халыкларның этносын ачыклау мөһим мәсьәлә булып тора.

Россия һәм чит ил галимнәренең күпчелеге Идел болгарларының хәзерге чуаш һәм татар этногенезында катнашканлыкларын кире какмый. Бары тик аларның, болгарларның, шул процессларда катнашу дәрәҗәсе турындагы мәсьәлә генә бәхәсле булып кала бирә. Соңгы елларга кадәр чуаш галимнәре арасында бик тә популяр булган, чуашлар алар – Идел болгарларының бердәнбер варислары дигән һәм бары тик лингвистика материалларына гына нигезләнгән концепция, татарлар – Алтын Урда чорындагы монгол-татарлар токымыннан дигән концепция кебек үк, күпчелек галимнәр фикеренчә, дөреслектән ерак булып чыкты. Ә шулай да төрк филологиясендә болгар теленең чуаш теленә якынлыгы мәсьәләсе уңай чишелгән санала (Баскаков, 2010, с. 113; Мудрак, 2005, с. 83–96).

Чуаш Республикасы территориясендә урнашкан болгар археологиясе истәлекләре XIX гасырның икенче яртысыннан башлап өйрәнелә (Невоструев, 1871; Шпилевский, 1877; Савельев, 1892). Шул чакта ук инде Идел Болгарының көнбатыш чикләрен билгеләүдә ике караш урнаша: К.И. Невоструев белән С.М. Шпилевский ул чикне Зөя бассейны белән бәйләп куйса, А.И. Савельев аны Сура елгасына кадәр җиткерә. Беренче фикергә соңыннанрак 1926–1927 елларда Чуаш республикасында археологик эзләнүләр үткәргән П.Н. Третьяков та кушыла.

1950-нче еллардан башлап Чуаш республикасы территориясендә урнашкан болгар истәлекләрен В.Ф. Каховский өйрәнә. Ул чактагы Чуаш Фәнни-тикшеренү институтының (ЧувНИИ) В.Ф. Каховский җитәкчелегендәге экспедициясе республика территориясендәге, шул исәптән, аның төньяк районнарындагы һәм Сура елгасының уңъяк төбәкләрендәге болгар истәлекләренең санын бермә-бер арттыра (Каховский 1965, с. 329). Әлеге төбәкләрдә урнашкан болгар авыллыклары соңгырак елларда да табылып тора (Каховский, Смирнов, 1972, с. 115, 116; Каховский, 1978, с. 235–241; Каховский Б.В., Каховский В.Ф., 1993, с. 32–46).

Әмма ләкин ул авыллыкларның болгарларныкы булу-булмау мәсьәләсе бәхәсләр китереп чыгарды, кайбер болгарчы-археологларны ышандырмады. Р.Г. Фәхретдиновның А.П. Смирнов тарафыннан, безнең карашка, гаделсез тәнкыйтькә дучар ителгән кызыклы мәкаләсендә Чуаш республикасының әнә шул югарыда күрсәтеп үтелгән төбәкләрендәге кайбер болгар истәлекләрендә табылган материаллар анализлана, нәтиҗәдә ул, П.Н. Третьяков фикеренә кушылып, чуашларның ике зур

этник төркеме – вирьялларның һәм анатриларның формалашу процессы төрле юллар белән барганлыгын раслый. Болгар компоненты, дип яза ул, анатрилар этногенезында гына күзәтелә, ә вирьяллар, һичшиксез, җирле фин кабиләләре токымыннан (Фәхретдинов, 1971, с. 171–201).

Беренче чиратта бернинди аргументлар белән дә кире кага алмаслык шул фактны танырга кирәк: Чуаш республикасы территориясендә VIII–IX гасырларга, хәтта X гасыр башына караган болгар истәлекләре юк. Татарстан территориясендә Олы Тархан һәм Танкеевка (Тәнкәй) кебек классик каберлекләр калдырган элгәреге болгарлар X гасырга кадәр үзләренең тормыш-көнкүрешләрендә сизелерлек күчмәнлек калдыкларын саклаганнар, халыкның бер өлеше әле юрталарда яшәгән. Чөнки алар гомер-гомердән дала һәм урман-дала киңлекләрендә тормыш алып барган, урманлы төньякка үтеп кермәгәннәр. Болгарлар чорында бүгенге Чуаш Республикасы территориясе тулысынча урманнар белән капланып алынган булган. XVIII гасыр ахырлары – XIX гасыр башларында урман массивлары чуашлар яши торган территориянең яртысын диярлек биләп торган. (Археологическая карта, 2013, с. 11). Бары тик көньяк-көнчыгышта гына Гөбенә белән Карлы елгалары арасына кара туфраклы борынгы урман-дала участогы ярып керә һәм ул Зөянең урта агымындагы («Буа даласы») шундый ук участокның дәвамы булып тора» (Чуваши, 1956, с. 67).

Чуаш тарихчыларының, мәҗүси суазлар/суарларның төп өлеше 920-нче елларда Иделнең уң ягына чыгып төпләнә, дип тәкърарлавы археология чыганакларында чагылыш тапмый. Һәм болай дип раслау Әхмәд ибн-Фадлан язмаларындагы сүзләре белән дә ярашмый, Аның «Рисалә»сендә мондый юллар бар: 922 елның 21 май тантаналарыннан соң болгар ханы Алмыш / Җафар ибн-Абдаллаһ[1] *«переехал от водоёма, называемого Халладжа, к реке, называемой Джаушыр, на которой он остановился на два месяца. Потом он [вновь] захотел переехать и послал [посланника] к народу, называемому сувар, приказав им выступить вместе с ним. Они отказались [подчиниться] и разделились на две группы.*

*Одну из [этих групп] возглавил его зять, которого звали Вайрыг, он был их правителем. Царь [булгар] послал им [сообщение], говоря: «Поистине Аллах великий и могучий ниспослал мне благодать Ислама и верховенство повелителя верующих. Я его раб. Эти люди признали мою власть, и если кто-то будет перечить мне, я встречу его мечом! Другую группу возглавлял царёк племени, которого называли царь [народа] эскель. Он признавал верховенство [царя булгар], но [к этому моменту ещё] не*

---

[1] Ибн Фадлан язмаларының гарәпчәдән Вяч. С. Кулешов тарафыннан башкарылган яңа тәрҗемәсен тәкъдим итәм. Карагыз: Вяч. С. Кулешов, 2016, с. 40. Төгәл татарча тәрҗемәсе булмаганлыктан, текстны русча бирү хәерлерәк дип исәплэдем.

*принял ислам. Когда царь послал им это [последнее послание], они испугались [того, что он] вознамерился [сделать], и все поехали с ним к реке Джаушыр».*

Әйе, Җаушир – Кече Чирмешән ягына китәләр, хәзерге Чуашия җирләренә түгел. Әлеге язмалардан аңлашылганча, чуашлар үзләренең бабалары итеп күрергә теләгән суаз-суарлар 922 елдан соң һич тә мәҗүсиләр булып калмаганнар, ислам кабул иткәннәр. Бу турыда бит 930 елларда гарәп географы әл-Балхи язып калдырган: «Болгардан ерак түгел тагын бер шәһәр – Сувар урнашкан, анда да зур мәчет бар» (карагыз: Хузин, 2006, с. 241). Алай гына да түгел, 970-нче елларга кадәр Суар кенәзе Болгар әмире белән беррәттән өслекләренә Болгар илендә ислам кабул ителгәннән соң таралган гарәп графикасында язылган көмеш акчалар суктыра.

Чуаш республикасының көньяк-көнчыгыш төбәкләрендәге монголларга кадәрге болгар (суаз-суар түгел!) археологик истәлекләре арасында түбәндәгеләрне санап үтәргә була: Тигашево (Тигәш) I–II шәһәрлеге һәм аның тирә-юнендәге шул ук исемдәге I–IV авыллыклары, Олы Тайба һәм Иске Янаш шәһәрлекләре, Яльчик, Олы Яльчик, Байтирәк, Яңа Байбатыр, Арабузи, Криуши, Именево, Яңа Ахпердино, I–II Яншихово, I–II Яблоново, Яңа Чурино, Сюрбеево авыллыклары һәм берничә табылдыклар урыны (Фахрутдинов, 1971, с. 193–194; Археологическая карта, 2013, с. 32 и сл.).

Алар арасында археологик яктан яхшы тикшерелгәне – Тигәш шәһәрлеге. Аның элгәреге катламнарында Мәскәү археологы Г.А. Фёдоров-Давыдов 1950-нче елларда мәҗүсиләрнең изге урынын – гыйбадәтханә калдыкларын табып тикшергән (Фёдоров-Давыдов, 1958, с. 202–226; 1962, с. 82–95; Смирнов, 1961, с. 140–167). Моңа охшаган «гыйбәдәтханәләр» сирәк булса да Идел Болгарының үзәк районнарында да очраштыргалый, дип саный кайберәүләр (Руденко, 2004, с. 36–66). Теория ягыннан караганда бу бер дә гаҗәп түгел, чөнки болгарларда ислам дине таралу әле XI гасырда да, соңгырак чорларда да дәвам итә – Идел Болгары составында чит төбәкләрдән күчеп утырган җирле фин халыклары вәкилләре дә аз булмый, һәм алар үзләренең борынгы дини карашларыннан тиз генә аерыла алмаганнар. Әгәр дә, Фёдоров-Давыдов һәм чуваш археологлары кебек, ат яисә сыер башы табылган һәр чүп базын корбан чалу урыны дип фаразлап, көл-күмер калдыкларын үлгәннәрне искә алу йоласы белән бәйли башласаң, андый «гыйбәдәтханәләр» күп табылыр әле ул. Ә нишләп соң бер бай феодал («милләте» буенча суаз мәҗүсие дип уйларга кирәк), Тигашеводагы гыйбәдәтханә өстенә – изге урынга! – озак та уйлап тормыйча, үзенә за́мок салдыртып куя? Акылга сыймый торган урыннар моның белән генә бетми әле, һәм бу мәсьәләгә безнең махсус мәкалә багышланган (Хузин, Хамидуллин, 2013). Сүз уңаеннан: Тигәштә ачылган материалларны дөрес аңламау

шәһәрлекнең саклану (оборона) ныгытмаларын анализлау нәтиҗәләренә дә карый (Коваль, 2023, с. 293–310).

Чувашия территориясенең башлыча вирьяллар яши торган төньяк яртысында тикшерелгән болгар-сувар истәлекләренә тукталып үтик. Безне беренче чиратта шулар кызыксындыра, чөнки югарыда санап үтелгән болгар археологик истәлекләре Чуаш республикасы территориясендәге Зөя бассейнында – Идел Болгары чикләрендә урнашкан.

Олы Янгилде авыллыгы В.Ф. Каховский һәм А.П. Смирнов тарафыннан 1958–1961 елларда казып тикшерелгән һәм датасы IX–XII гасырлар дип билгеләнгән иде. Казылмалардан чыккан материаллар ярыйсы гына анализланып, фәнни әйләнешкә кертелгән дип йөри идек (Смирнов, Каховский, 1964, с. 223–263; Каховский, 1965, с. 333–337; Каховский В.Ф., 1966, с. 249–258). Нәтиҗәләргә караганда, авыллык чыннан да болгарларныкы. Әмма Республика музеена тапшырылган коллекцияләрне (соңыннан алар юкка чыга) Т.А. Хлебникова һәм Р.Г. Фәхретдинов карап чыгарга өлгерәләр. Нәтиҗә: авыллыкта җирле чуашлар XIII–XIV гасырларда яшәгән (Фахрутдинов, 1971, с. 181–185). «Музей коллекцияләрен өйрәнү шуны күрсәтте, – дип яза Т.А. Хлебникова, – 1958–1961 елларда казып өйрәнелгән Олы Янгилде авыллыгының керамика комплексында болгар савыт-сабасы 5,2% тәшкил итә. Әле бу кайбер шикле фрагментларны исәпкә алып; әгәр дә аларны санап тормасаң, болгар керамикасының проценты 4,52 чамасы булачак» (Хлебникова, 1967, с. 90).

Димәк, без В.Ф. Каховскийның, әлеге авыллыкта болгарларның IX–X гасырларда яшәгән юрта калдыклары табылды, дигән сүзләренә дә ышана алмыйбыз. Баксаң, А.П. Смирнов белән В.Ф. Каховский үзләре казып тикшергән авыллыкны болгарларныкы итеп күрсәтү өчен турыдан-туры фальсификациягә барганнар икән – басылып чыккан хезмәтләренә иллюстрация рәвешендә азсанлы болгар табылдыкларын гына биргәннәр, ә табылдыкларның 95 проценттан артыграгын тәшкил итә торган җирле фин халкына нисбәтлеләрен «онытып» калдырганнар.

Хронологиясе һәм этномәдәни асылы ягыннан караганда Олы Янгилде материалларына якын авыллыклар исемлегенә I–II Яндашево, Немичкасы, Янмурза (чув. Палаху), Таутово һәм башка истәлекләрне кертергә була.

В.Ф. Каховский һәм Н.В. Трубникова тарафыннан тикшерелгән Янмурзино авыллыгы һәм якында гына урнашкан каберлек болгар кабиләләренең IX–X гасырларда Чуашиянең төньяк төбәкләренә хәрәкәтен күрсәтү өчен кирәк иде (Каховский, 1965, с. 332). Авыллыкның датасын башта IX-X – XII гасырлар белән (Трубникова, 1958, с. 248), аннан соң X–XIII гасырлар белән (Каховский, Смирнов, 1972, с. 134) һәм, ниһаять, XII–XV гасырлар белән билгеләделәр (Каховский, 1975, с. 174). Музей коллекцияләрендәге табылдыкларны өйрәнгәннән соң Р.Г.

Фәхретдинов шундый фикергә килә: бирεдә чыннан да болгар керамикасы Чуашиянең төньяк төбәкләрендәге башка авыллыкларныкына караганда күбрәк – 13%, ләкин ул Алтын Урда чорына карый (Фахрутдинов, 1971, с. 188; шулай ук карагыз: Хлебникова, 1967, с. 90). Әйтергә кирәк, Палаху тирәсендәге каберлекне Н.В. Трубникова да Алтын Урда чорында калдырылган дип санады, чөнки кайдадыр якында гына өслегенә гарәп хәрефләре белән язылган каберташ табылган булган (Трубникова, 1958, с. 248).

Янмурзадан (Палаху) 3 чакрым ераклыкта гына урнашкан Челкасы авыллыгы материалларында болгар керамикасы 10–35% тәшкил итә, имеш (Каховский, Смирнов, 1972, с. 142). Әмма иллюстрацияләреннән үк күренеп тора: аларның барысы да болгар чүлмәкчеләренеке түгел (Каховский, Смирнов, 1972, Рәс. 41). Болгар осталары чүлмәк өчен әзерләнгән балчыкка, аны майсызландыру максатыннан чыгып, шамот[2], вак таш, төелгән бака кабырчыклары ише кушылмалар түгел, елга комы кушканнар. Ә тегеләре элек-электән җирле фин кабиләләренең славян чүлмәкләренә охшатып ясалган савыт-сабалары өчен характерлы. Димәк ки, өйрәнелгән авыллыкта табылган керамик эшләнмәләр арасында болгарларныкы дигәне күпкә азрак булып чыга.

В.Ф. Каховский һәм Б.В. Каховскийлар тарафыннан 1989–1982 елларда тикшерелгән Убеево авыллыгы материалларына күз төшерик. Өч җәйге сезон эчендә бирεдә 1266 кв. м мәйданда казу эшләре үткәрелгән. Җәмгысе 1720 фрагмент керамика табылган, шуларның 1190-ы (69,2%) кулдан әвәләп ясалган, 530-ы (30,8%) чүлмәк ясау түгәрәге кулланып эшләнгән. Соңгысында кара һәм караңгы-көрән төстәге чүлмәкләр бар (10%), болгар керамикасына һич тә хас булмаган шамот һәм вак таш катнашмалы савыт-саба фрагментлары еш очрый. Казылма авторлары фикеренчә, әлегге авыл монгол яуларына кадәрге чорда барлыкка килгән, әле Алтын Урда чорында да яшәгән һәм XV гасырда гына юкка чыккан. Шулкадәр озын вакыт аралыгында тупланган табылдыкларның сан ягыннан караганда бик аз булуы гаҗәпләндерә.

Югарыда исемнәре телгә алынган авылларда нигездә болгарлар (дөресрәге, суаз-суарлар) яшәгән дип ышандырырга тырышучыларның дәлилләү системасында безне тагын бер факт сагайта: аларның һәрберсендә табылган остеологик материаллар арасында дуңгыз сөякләре бар. Дуңгыз ите болгарларда элек-электән, әле алар мәҗүсилектә яшәгән чорларда ук, бөтенләй кулланылмаган. Дуңгыз сөякләрен хәзер безне кызыксындырган авылларда яшәгән халыкларның этносын («милләтен») ачыклауда мөһим бер индикатор ролендә карарга мөмкин: хәрам ризык ашаганнар икән, димәк алар болгарлар түгел.

[2] Иске чүлмәк ватыкларын төеп ясалган кушылма.

Шулай итеп, безнең чыганаклар арсеналында тупланган объектив материалларга таянып, болгарларның әкренләп хәзерге Чуашиянең үзәк һәм төньяк районнарына үтеп керү процессы бары тик XIII гасыр тирәләрендә генә, ягъни башлыча Алтын Урда чорында гына башланган дип әйтә алабыз. «Тагын да борынгырак дата бәхәсле, – дип яза чуаш археологиясен яхшы белүче танылган Мәскәү галиме Ю.А. Краснов (1974, с. 120). Һәм без бу фикергә кушылабыз.

Мин чуаш коллегаларыбыз тикшергән «болгар» истәлекләренең барысына да анализ ясарга теләмим. Укучыларымның игътибарын бары тик Олы Янгилде тибындагы археология истәлекләрен киң планда өйрәнгән В.Ф. Каховский һәм А.П. Смирнов ясаган нәтиҗәләргә генә юнәлтәсем килә: «Памятники эпохи Волжской Булгарии, расположенные в бассейнах рек Большой и Малый Цивиль, имеет ряд специфических особенностей, связанных с этническим смешением местного населения, носителя позднегородецкой культуры, с пришлыми булгарскими и суварскими племенами. В памятниках прицивильской группы элементы позднегородецкой культуры прослеживаются в значительно большем объёме, нежели в центральных (закамских. – *Ф.Ш.*) районах Волжской Булгарии. *Вследствие этого удельный вес материальных остатков булгарской культуры не является в них преобладающим*» (Каховский, Смирнов, 1972, с. 159; курсив минеке. – *Ф.Х.*). Миңа калса, бу – чынбарлыкка якынрак торган бик кызыклы нәтиҗә. Тик аңлашылып җитми, ул чакта ни өчен аз гына болгар табылдыклары бирә торган «соңгы городец» (позднегородецкие) торак урыннары болгарларныкы яисә суарларныкы дип белдерелә? Мин Ю.А. Красновның археология материалларын, беренче чиратта, үзендә искиткеч бай информация туплаган керамика табылдыкларын тирәнтен анализлап язылган «Чуаш халкының килеп чыгышы проблемасы» дигән мәкаләсенең төп положениеләре белән тулысынча килешәм: «Күренеп тора, безнең алда фин-угыр һәм болгар халыкларының бергә кушылып китүен, шул процессның башлангыч этапларын характерлаучы керамика комплексы; бу этапны чуаш этносының калыплаша башлавы белән бәйләргә мөмкин. Һәм бу комплексны болгарныкы дип түгел, чөнки болгар элементлары биредә күпчелекне тәшкил итми, ә борынгы чуаш комплексы дип атау дөресрәк булыр» (Краснов, 1974, с. 119). Кызганычка каршы, абруйлы галимнең әлеге фикеренә чуаш тикшеренүчеләре ягыннан бернинди җавап табышы ишетелмәде. Югыйсә, Ю.А. Краснов концепциясендә принципиаль яктан мөһим, фәннең башка тармакларында да, бигрәк тә антропологиядә[3] һәм

[3] «Шулай итеп, хәтта өстән-өстән генә ясалган морфологик тасвирламалардан да күренеп тора – чуашлар краниологик яктан үзләренең фин телле күршеләренә охшаш, димәк, аларның антрополик типлары Идел буе төбәкләрендә яшәүче халыкларга хас билгеләр ком-

этнографиядә[4] аваздаш фикерләр бар һәм аларны исәпкә алмыйча, әлеге регионнарның урта гасырлар чорына караган этник проблемаларын чишү мөмкин дә түгел.

Югарыда әйтелгәннәргә өстәп, укучыларыбызга тагын шуны белдерәсем килә: соңгы елларда Пермь краенда һәм Мордовия республикасында коми-пермякларның һәм мордваларның урта гасырлар чорына караган торак урыннары – авыллыклар һәм шәһәрлекләр казып өйрәнелде. Аларның керамика комплексында болгар савыт-сабалары 5–20%, ә кайберләренә 50% чамасы тәшкил итә, әмма ләкин ул истәлекләрне берәү дә болгарларныкы дип атамый, шул авыл-шәһәрләрдә мордва һәм коми-пермяклар белән бергә болгарлар да яшәгән, һөнәрчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнгәннәр, дип язалар (Белавин, 2000; Белавин, Крыласова, 2008; Беговаткин, 2006, с. 270; Загайнова, Зеленеев, Зеленцова, 2006, с. 161–166).

Әлбәттә, Чуашиянең үзәк һәм төньяк районнарына болгарларның монгол яуларына кадәр үк үтеп керә башлау ихтималлыгын кире кагарга ярамый, тик хәзергә археологик материллар гына җитенкерәми. Бу җәһәттән Чабаксар шәһәренең тарихи үзәгендә үткәрелгән археологик казу эшләренең кызык кына нәтиҗәләрен искә алып китәсем килә. Әлеге казулар белән җитәкчелек иткән Ю.А. Краснов һәм В.Ф. Каховский сүзләренә караганда, «инде XIV, бәлки әле XIII гасырның икенче яртысындауктыр, һәрхәлдә, Чабаксарның рус елъязмаларында беренче мәртәбә телгә алынган елдан (1555 ел. – *Ф.Х.*) бер-берьярым гасыр элегрәк, шәһәр инде яшәгән» (Краснов, Каховский, 1978, с. 156). Минемчә, әлеге археологик датаны да чынбарлыкка тулысынча туры килә дип кабул итәргә ярамый. Шәһәрнең түбән, инде су астында калган өлешендә, культура катламының аскы, иң борынгы ярусларында табылган керамиканың 9% чамасы болгарларныкы (Краснов, Каховский, 1978, с. 161). Белгечләрнең әйтүенчә, әлеге керамиканың – чүлмәк, кувшиннарның бизәлешендә (дулкын, каннелюр), өслегән ялтыратып куюда (лощение) – чүлмәкчелектә болгарларның монгол яуларына кадәр киң кулланган алымнары чагыла (Краснов, Каховский, 1978, с. 84). Н.А. Кокорина, 1997 елгы казылмалардан чыккан материалларны өйрәнеп, аларның бер өлеше, һичшиксез, монгол яуларына кадәрге чорның икенче яртысында, бәлки XIII гасыр башларында ук җитештерелгәндер, дигән нәтиҗәгә килә (Кокорина, 2009, с. 203–204). Болгарларның монгол яуларына кадәрге керамикасы 2003–2006 елларда Ю.А. Зеленеев һәм Е.П. Михайлов җитәкчелегендә

плексының интенсив рәвештә катнашуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән, һәм ул тип субурал исеме белән атала». Карагыз: Алексеев, 1971, с. 248.

[4] «Шулай итеп, чуашларның ике зур төркеме дә этнос буларак хәзерге Чуашиянең төньяк районнарында яшәүче абориген халыкларның көньяктан килеп утырган азсанлы килмешәкләр (болгарлар. – *Ф.Х.*)) белән якынлашуы нәтиҗәсендә XIV гасырдан башлап, XV гасыр дәвамында формалаша». Карагыз: Чуваши, 1956, с. 35.

үткәрелгән казылмалардан да табылган (Кокорина, 2009, с. 206–207).

Кызганычка каршы, шәһәрнең бүгенгәчә сакланып калган иң борынгы участокларындагы казу эшләре туктатылган. Ә бит аның нәкъ шушы өлешендә шәһәрнең барлыкка килү вакытына нисбәтле материаллар табу ихтималлыгы бар иде.

Болгарларның эчке һәм тышкы сәүдәдә җәһәтлеге һәркемгә билгеле. Бөек Идел юлының һәм аның Кама (Чулман), Ока ише эре тармакларының уңайлы урыннарында алар Болгар, Сембер, Әҗмер, Лаеш, Казан, Җүкәтау, ише сәүдә пунктлары, факторияләр ачканнар. В.Н. Татищев хәбәрләренә караганда, Түбән Новгород та 1221 елда, элегрәк болгарлар яшәгән, сәүдә иткән урында (Ибраһим /Бряхимов?) барлыкка килгән, шәһәр статусы алган (Татищев, 1964, с. 212). Дөрес, әлеге факт хәзергә археология материаллары белән ныгытылмаган, әмма Түбән Новгород кремлендә үткәрелгән археологик казылмаларда XIII–XIV гасырларга караган болгар керамикасы бар (Шакиров, 2010, с. 64). Казу эшләрен дәвам иткән очракта тагын да борынгыраклы табылырга мөмкин. Чабаксар шәһәре урынында да монголларга кадәр яшәгән болгарларның сәүдә итү урыны булгандыр, дип фаразлау бик табигый.

Монголларга кадәр яшәгән болгарларның археологик эзләрен Сура бассейны төбәкләрендә дә эзләүне дәвам итәргә кирәк. Моңа кадәр табылган болгар истәлекләренең элгәреге даталары бераз шикләндерә әле. Б.В. Каховский тарафыннан тикшерелгән Устинов авыллыгы, мәсәлән, табылдыкларына караганда (йозак, үзенчәлекле бизәкләре белән керамика), Алтын Урда чорына карый, элгәрерәк чорга түгел (Каховский Б.В, 1980, Рәс. 3, 4). Ә менә В.Ф. Каховский казыган Стемасы I авыллыгы катламнарында XII – XIII гасыр башы һәм тагын да соңгырак чор табылдыклары бар (Каховский В.Ф., 1978, с. 236–237). Монголларга кадәрге болгар истәлекләре Сура елгасының Түбән Новгород өлкәсендәге өлешендә дә ачылган (Хузин, 2009, с. 21–22). Археолог М.И. Федулов хәбәрләренә караганда, Тёша елгасы буенда урнашкан Архангельское I авыллыгында болгарларның бары тик X–XIII гасырларда гына ясалган савыт-саба фрагментлары табылган (Федулов, 2009, с. 109).

Югарыда язылганнардан аңлашылганча, Чуаш республикасында болгар истәлекләре әлегә кадәр җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, казу эшләре үткәрелгән истәлекләрнең датасы күп очракта бәхәсле булып кала. Безнең карашка, киләчәктә Олы Янгилде тибындагы авыллыкларны казып тикшерү чуашларның этногенезы мәсьәләсен хәл итүдә, Зөя бассейнындагыларын тикшерүгә караганда файдалырак булачак. Соңгылары, Олы Таяба тибындагылары, әйтеп үтелгәнчә, болай да Болгар дәүләте составында булган, ә төньяк, төньяк-көнчыгыш төбәкләрдәге халыкның матди культурасы үзенчәлекләре һаман да өйрәнелмәгән килеш кала бирә.

## Файдаланылган әдәбият

*Алексеев В.П.* Очерк происхождения тюркских народов Восточной Европы в свете данных краниологии // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1971. С. 232–271.

*Беговаткин А.А.* Характеристика основных этапов развития отношений между мордвой и Волжской Булгарией в домонгольское время // Историко-археологические исследования Поволжья и Урала. Материалы III Халиковских чтений / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: РИЦ «Школа», 2006. С. 262–282.

*Белавин А.М.* Камский торговый путь. Средневековое Приуралье в его экономических и этнокультурных связях. Пермь, 2000. 200 с.

*Белавин А.М. Крыласова Н.Б.* Древняя Афкула: археологический комплекс у с. Рождественск. Пермь, 2008. 603 с.

*Загайнова Л.П., Зеленеев Ю.А., Зеленцова О.В.* Новые данные о проникновении культуры волжских болгар в мордовские земли (поселения X–XIV вв. в лесостепном Посурье по работам 2005 г.) // Материалы и исследования по археологии Поволжья. Вып. 3. Средневековая археология евразийских степей. М.; Йошкар-Ола, 2006. С. 161–166.

*Каховский Б.В.* Археологические исследования 1978 года в Чувашской АССР // Труды ЧувНИИ. Вып. 105. Вопросы древней и средневековой истории Чувашии. Чебоксары, 1980. С. 51–69.

*Каховский Б.В., Каховский В.Ф.* Изучение булгарских памятников на территории Чувашии // Археология Волжской Булгарии: проблемы, поиски, решения / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 1993. С. 32–46.

*Каховский В.Ф.* Происхождение чувашского народа: основные этапы этнической истории. Чебоксары: Чув. кн. изд-во, 1965. 484 с.

*Каховский В.Ф.* Булгарское селище близ деревни Большое Янгильдино в Чувашской АССР // СА. 1966. № 2. С. 249–258.

*Каховский В.Ф.* Исследование средневекового селища и могильника Палаху // Труды ЧувНИИ. Вып. 60. История, археология и этнография Чувашской АССР. Чебоксары, 1975. С. 163–203.

*Каховский В.Ф.* Новые памятники болгарской культуры Чувашского Поволжья // Вопросы древней и средневековой археологии Восточной Европы / Отв. ред. В.И. Козенкова, Ю.А. Краснов, И.Г. Розерфельдт. М.: Наука, 1978. С. 235–241.

*Каховский В.Ф.* Итоги археологических работ 1979–1980-х гг. в Чувашской АССР // Актуальные проблемы археологии и этнографии Чувашской АССР. Чебоксары, 1982. С. 48–51.

*Каховский В.Ф.* Исследования археологических памятников Чувашии в 1981 и 1982 годах // Новые исследования по археологии и этнографии Чувашии. Чебоксары, 1983. С. 8–18.

*Каховский В.Ф., Смирнов А.П.* Памятники средневековья Чувашского Поволжья // Городище Хулаш и памятники средневековья Чувашского Поволжья. Чебоксары, 1972. С. 115–166.

*Коваль В.Ю.* Валы и рвы Тигашевского городища // Поволжская археология. 2023. № 3. С. 293–310.

*Кокорина Н.А.* О керамике средневековых Чебоксар // Научно-педагогическое наследие В.Ф. Каховского и проблемы истории и археологии: материалы научно-практической конференции. Кн. 2 / Ред.-сост. Е.П. Михайлов. Чебоксары, 2009. С. 203–222.

*Краснов Ю.А.* Проблема происхождения чувашского народа в свете археологических данных // СА. 1974. № 3. С. 112–124.

*Краснов Ю.А., Каховский В.Ф.* Средневековые Чебоксары: материалы Чебоксарной экспедиции 1969–1973 гг. М.: Наука, 1978. 190 с.

*Кулешов Вяч. С.* Книга Ахмада ибн Фадлана. Пер. с араб. и прим. Вяч. С. Кулешова // Путешествие ибн Фадлана: Волжский путь от Багдада до Булгара. Каталог выставки. М.: Изд. дом Марджани, 2016. С. 18–47.

*Мудрак О.А.* Заметки о языке и культуре дунайских болгар // Orientalia et Classica. Вып. 6. Аспекты компаративистики. М., 2005. Ч. 1. С. 83–106.

*Невоструев К.И.* О городищах древнего Волжско-Булгарского и Казанского царств в нынешних губерниях Казанской, Симбирской, Самарской, Вятской // Труды I Археологического съезда. М., 1871. Т. 2. С. 521–594.

*Руденко К.А.* Булгарские святилища XI–XIV вв. (по археологическим материалам) // Культовые памятники Камско-Вятского региона. Ижевск, 2004. С. 36–66.

*Савельев А.И.* Городища древнего Болгарского царства. СПб., 1892. 67 с.

*Смирнов А.П.* Древняя история чувашского народа (до монгольского завоевания). Чебоксары, 1948. 81 с.

*Смирнов А.П.* Железный век Чувашского Поволжья // МИА. 1961. № 95. 170 с.

*Смирнов А.П.* Рец. на: Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971 // История и культура Чувашской АССР. Вып. 1. Чебоксары, 1971. С. 481–506.

*Смирнов А.П., Каховский В.Ф.* Булгарское селище близ деревни Большое Янгильдино в Чувашской АССР // Археологически работы в Чувашской АССР в 1958–1961 гг. (Уч. зап. ЧувНИИ. Вып. XXV). Чебоксары, 1965. С. 223–263.

*Татищев В.Н.* История Российская. Т. III. М.; Л.: Наука, 1964. 338 с.

*Третьяков П.Н.* Средневековые феодальные городища ЧАССР // Сообщения ГАИМК. 1932. № 5–6. С. 62–66.

*Третьяков П.Н.* Памятники древнейшей истории Чувашского Поволжья. Чебоксары, 1948. 75 с.

*Трубникова Н.В.* О работах 2-го отряда Чувашской археологической экспедиции 1956 года // Уч. зап. ЧувНИИ. Вып. XVI. Чебоксары, 1958. С. 227–262.

*Фахрутдинов Р.Г.* О степени заселённости булгарами территории современной Чувашской АССР // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1971. С. 175–201.

*Фёдоров-Давыдов Г.А.* Булгарский феодальный замок X–XII вв. // Уч. зап. ЧувНИИ. Вып. XVI. Чебоксары, 1958. С. 202–226.

*Фёдоров-Давыдов Г.А.* Тигашевское городище. (Археологические раскопки 1956, 1958 и 1959 гг.) // МИА. 1962. № 111. (Тр. Куйбышев. археол. эксп., вып. IV). С. 49–89.

*Федулов М.И.* Средневековые памятники Чувашского Присурья // Научно-педагогическое наследие В.Ф. Каховского и проблемы истории и археологии: материалы научно-практической конференции. Кн. 2 / Ред.-сост. Е.П. Михайлов. Чебоксары, 2009. С. 104–114.

*Хлебникова Т.А.* Археологические памятники XIII–XIV вв. в Горномарийском районе Марийской АССР // Происхождение марийского народа. Йошкар-Ола, 1967. С. 148–169.

*Хузин Ф.Ш.* Ранние булгары и Волжская Булгария (VIII – начало XIII в.). Учебное пособие для студентов вузов и аспирантов. Казань: Ин-т истории АН РТ, 2006. 583 с.

*Хузин Ф.Ш.* К вопросу о происхождении татар-мишарей: булгарские памятники и памятники со следами присутствия булгар в Волго-Окском регионе // Проблемы археологии и истории Татарстана. Вып. 1. Казань: РИЦ «Школа», 2009. С. 13–32.

*Хузин Ф.Ш., Хамидуллин Б.Л.* Ещё раз о соотношении язычества и ислама в домонгольской культуре Волжской Булгарии // Филология и культура. Pfilology and Culture. 2013. № 1 (31). С. 214–221.

Чуваши. Этнографическое исследование. Ч. 1. Материальная культура / Под ред. Н.И. Воробьёва. Чебоксары, 1956.

*Шакиров З.Г.* Археологические исследования в здании арсенала Нижегородского кремля в 2007–2008 годах (предварительное сообщение) // Проблемы археологии и истории Татарстана. Вып. 1 / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: РИЦ «Школа», 2009. С. 59–65.

*Шпилевский С.М.* Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань, 1877. 585 с.

*Волжская Болгария (Булгария): этнокультурная ситуация и общественное развитие. Материалы научного семинара (Чебоксары, 13 апреля 2011 г.) / Сост. и науч. ред. Г.А. Николаев. Чебоксары: ЧГИГН, 2012. С. 37–45.*

# ТӘНКЫЙТЬ МӘКАЛӘЛӘРЕ, БӘЯЛӘМӘЛӘР




## РИВАЯТЬ-ЛЕГЕНДАЛАРДА БОЛГАР-ТАТАР ТАРИХЫ

Соңгы елларда тарихыбызны өйрәнүгә игътибар нык артты. Үткән тарихыбызны белмичә, бүгенге халәтебезне аңлап һәм киләчәгебезне күз алдына китереп булмый, дип дөрес әйтә галимнәр. Һәм бу өлкәдә күп эшлиләр дә. Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан 7 томлык "Татар тарихы" бастырылып чыгарылу гуманитар фәннәр дөньясында үзе бер вакыйга булды. Мәктәп укучылары өчен татар тарихы буенча яңа дәреслекләр язылды. Китап киштәләрендә, сирәк булса да, фәнни-популяр китаплар да күренә башлады.

Әмма, үзегез күреп торасыз, югары даирәләрдә илебездәге рус булмаган милләтләрнең киләчәгенә караш төрлечә. Тискәре караш тарафдарлары җанланып китте. Урта мәктәп программаларыннан милли-төбәк компонентын алып ташладылар. Нәтиҗәдә татар тарихы укытылмый башлады, ана теленә бирелгән сәгатьләр саны киметелде.

Барыбыз да аңлыйбыз: телсез һәм тарихсыз милләтнең киләчәге юк. Димәк, безгә телебезне һәм тарихыбызны саклап калу өчен көрәшергә кирәк. Моның төрле кануни юллары бар. Тарихчы буларак, мин бүгенге татар язучыларының, рәссамнәренең, композиторларының халкыбыз тарихының төрле чорларын яктырткан иҗат җимешләрен – роман-бәяннәрен, картиналарын, опера-балет-

ларын, драма әсәрләрен укып, карап, тыңлап сөенәм. Авыр тел белән язылган калын-калын фәнни китапларны халык укымый, ә менә шул китапларны кулланып язылган сәнгать әсәрләрен бик җиңел кабул итә. Шәһәр урамнарын, бакча-паркларны тарихи шәхесләребезнең һәйкәлләре белән бизәү дә халкыбызның милли үзаңын саклап калырга ярдәм итәр иде. Гаҗәп, бер уйласаң: урыс кенәзләренең, патша-императорларының исемнәрен, Рюриктан башлап соңгыларына кадәр, барысын да беләбез, ә үзебезнекеләрнекен – юк. Без дә бит дәүләтле халык, югыйсә!

Менә шул күзлектән карап, хәзер сез укып ләззәтләнәчәк китапның кыйммәтен мин бик югары бәялим. Чөнки китапка сайлап алынган легендаларның һәм риваятьләрнең нигезендә тарих ята. Халкыбыз иҗаты – гаять бай. Жанрлары да төрле: әкиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, мәзәкләр, җырлар, бәетләр, дастаннар... Шунысы кызык һәм игътибарга лаек – аларның барысында да теге яки бу дәрәҗәдә халкыбыз тарихы чагылган. Хәтта әкиятләрдә дә. Легенда һәм риваятьләрне әйтәсе дә юк инде. Дөрес, ул тарих бик үзенчәлекле, аны чынбарлыкның гади чагылышы дип карарга ярамый, чөнки вакыйгалар һәм аларга бәйләнешле тарихи шәхесләр хронологик яктан буталып бирелергә, ә реаль тормыш, фантазияләр белән баетылып, мифик, әкияти төс алырга мөмкин. Мондый әсәрләрне укуы кызык (шуңа күрә дә алар борынгы чорлардан бүгенгә кадәр килеп җиткәннәр дә инде), ә алардагы тарих эзләрен галимнәр күп очракты җиңел һәм ышанычлы итеп аңлатып та бирә алалар. "Тарих эзләре" дигәннән...

Менә китапка кертелгән риваятьләрнең беренчесе, Болгар каласының корылуы турындагысы. Нух пәйгамбәрнең бер утлы Яфәс атлы икән. Аның Газый, Төрек һәм Алып исемле өч улы булган. Газый белән Төрек ни сәбәпледер (араларына шайтан кергән, имеш) ачуланышалар да, Төрек үзенең туганнары, якыннары белән башка җиргә күчеп китәргә мәҗбүр була. Алып та Төрек туганы артыннан китә. Алар ерак салкын якка килеп чыгалар, олы елга янына килеп төпләнәләр. Берзаман Алып ауга чыгып китә, ерак урманда адаша һәм, йөри торгач, шул ук телдә сөйләшә торган башка кавем кешеләре белән очраша. Алып алар арасында яшәргә кала, бер кызга өйләнә. Аларның Болгар һәм Буртас исемле уллары туа.

Менә шундый риваять. Риваять кенә микән әле – чын тарихның үзе ич бу! Карагыз: Яфәс һәм аның өч улы көньякта (үзебездән өстибез – Азов-Дон буйларында, Кара диңгез буе далаларында) яшәгән. Төрек белән Алып салкын якка, олы елга буена (димәк, Урта Иделгә) күчеп китәләр. Алыпның ике улы була: Болгар һәм Бортас исемле. Бераздан Бортас башка урынга күчеп утыра. Болгар, аңлашыла ки, безнең якларда кала – Болгар каласына нигез сала. Ә Бортас? Галимнәр фаразлавынча, ул – хәзерге Пенза һәм Мордовия якларында яшәүче татарларның, ягъни

мишәрләрнең бабасы булгандыр, мөгаен. Нәкъ менә шул төбәкләрдә "бортас" топонимы киң таралган икән (шул исемдәге авыллар хәзер дә бар) һәм хәтта XVI–XVII йөз документларында да еш кына "борталар" телгә алына. Пенза археологы профессор Геннадий Белорыбкин Бортас каласын XI–XIII гасырларга караган Юлово шәһәрлеге белән тәңгәлләштерә.

"Белемле кеше" дигән риваятькә тукталып үтик. "Болгар" сүзенең мәгънәсе "белер", ягъни "белемле кеше", диелә анда. Бу риваяьне 1135–1136 һәм 1150 елларда Болгар илендә булып киткән гарәп сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Гарнати, болгар казые Йакуб ибн-Ногманның "Болгар тарихы" дигән китабыннан күчереп алдым, дигән искәртмә белән, үзенең "Төрле илләрдәге гаҗәп хәлләр" дигән китабында китерә. Соңгы елларда "Белер/Билер" – "Болгар" тәңгәллегенә күренекле Польша галиме, тарихчы һәм филолог М. Адамович игътибар итте. Ул да, нәкъ менә риваятьтә әйтелгәнчә, "Беләр" сүзен гарәп теле аһәңенә яраклаштырып, "Болгар" дип йөртә башлаганнар, дигән фикерне фонетик материалларга таянып раслады. Шунысы кызык, Биләр – Болгар тәңгәллеге татарларның башка риваятьләре белән дә раслана. Мәсәлән, "Рабига күле" дигән риваятьтән бу күлнең Болгарда түгел, ә Биләр тирәсендәге Хуҗалар тавыннан ерак түгел бер җирдә урнашкан булуы аңлашыла. "Туйбикә мәдрәсәсе" дигән риваятьтә исә иртәнге намаз сөннәтен Биләр шәһәрендә, ә фарызын Болгарга барып сабак укучы кызлар турында сөйләнелә. "Мәрҗан каласы һәм унике кыз хикәяте"ндә Рабига абыстайның көн саен алтмыш алты шәкертен белән шәһри Болгардан Биләр мәдрәсәсенә җир асты юлы буйлап укытырга йөрүе тасвирлана. "Биләр-Болгар диясез, / Болгарданмы киләсез" – дип башланган борынгы җырда да шул исемнәр тәңгәллеге яңгырый кебек. Тарихчылар арасында Идел Болгарстанының әүвәлге башкаласы турындагы озак елларга сузылган бәхәсне чишүгә, минемчә, халык иҗаты әсәрләрен дә җәлеп итәргә мөмкин икән.

Риваятьләрдәге Алып турында бер-ике сүз. "Алыптай зур гәүдәле", "Алып чабатасын каккан җир" (кечкенә калкулыклар турында) – бу гыйбәрәләрне ишетмәгән кеше юктыр. Ә чынлыкта булганмы соң ул андый баһадир? Әйе, дип җавап бирәсе килә әлеге сорауга. 922 елда Болгар иленә килгән Багдад илчелеге сәркәтибе Әхмәт ибн-Фадлан үзенең "Рисалә"сендә, Алмыш/Җәгъфәр ибн-Габдулла хан сүзләренә таянып, озынлыгы 12 терсәккә (6 метр чамасы) җитә торган бер баһадир турында сөйли. Шуңа охшаган кешене без югарыда телгә алып үткән сәяхәтче Әбү Хәмид әл-Гарнати Болгарда үзе күрә, аның озынлыгын ул 7 терсәк чамасы (3,5 метр) гына ди. Әл-Гарнати китабына комментарийлар язган күренекле тарихчылар О. Большаков һәм А. Монгайт гарәп сәяхәтчеләре сөйләгән баһадир чыннан да Болгар илендә яшәгән булырга тиеш, дигән

фикергә киләләр. "Дөрес, аның буе 2,2–2,3 метрдан артмагандыр", – дип яза алар. Күрәсең, әл-Гарнати үзенең укучыларын, Ибн Фадлан исә хәлифәне шаккаттырыр өчен әлеге баһадирны тасвирлаганда чама хисен бераз онытып җибәргәннәрдер.

Монгол яуларына кадәр идарә иткән болгар ханнары турында халык авыз иҗаты әсәрләрендә мәгълүматлар бик аз сакланган һәм аларның күбесе тарихи чынбарлыктан ерак тора. Ышанычлы тарихи чыганаклар, шул исәптән, нумизматика материаллары нигезендә Болгар дәүләтенең беренче ханы *Шәлки улы Алмыш (Алмас)* булган, дип әйтә алабыз. Ислам дине кабул иткәннән соң, 902–908 еллар тирәсендә сугылган акчаларда, аның исеме *Җәгъфәр ибн-Габдулла* дип күрсәтелгән. Ибн-Фадлан язмаларында, Җәгъфәр ханның берничә улы бар иде, диелә. Гарәп тарихчысы әл-Мәсгуди, аларның берсе (*Мәмәктай? Әхмәд?*) әле Моктәдир хәлифә заманында ук (908–932) Мәккәгә хаҗ кылган иде, дип хәбәр итә. Фаразлаулар буенча, ул Болгар иле белән бик аз вакыт идарә итеп калган булырга тиеш. Җәгъфәр ханның икенче улы *Микаил ибн-Җәгъфәр* тәхеттә озаграк утыра һәм үз исеме сугылган акчалар чыгара. Аның улы *Габдулла ибн-Микаил* Болгар хакиме булып 940 нчы елларда тора. Бу хан исеменнән суктырылган акчаларда 946 елга кадәр хәлифә булып торган әл-Мостакфи исеме бар. *Мөэмин ибн-Хәсән* патша тәхетен 976–985 еллар тирәсендә биләп торган. Аның акчаларына 974–992 елларда хәлифә булып торган әт-Таи исеме сугылган. Нумизматика материалларына караганда, *Мөэмин ибн-Әхмәд* исемле хан 980 нче елларның икенче яртысында идарә иткән булырга тиеш.

Суар шәһәрендә әмир *Талиб ибн-Әхмәд* тарафыннан 948–958 елларда, *Мөэмин ибн-Әхмәд* тарафыннан 976–977 елларда сугылган акчалар билгеле. Шул мәгълүматларга нигезләнеп, тарихчылар Суарның X гасыр ахырына кадәр мөстәкыйль әмирлек булып яшәвен таныйлар, Мөэмин ибн-Әхмәднең 980 нче еллар тирәсендә Болгар ханы булып китүен фаразлыйлар.

XII гасырда яшәгән фарсы тарихчысы Әбү-л-Хәсән Бәйхаки үзенең бер әсәрендә 1024–1025 еллар тирәсендә Болгар дәүләте белән *Әбү Исхак Ибраһим* исемле әмирнең идарә итүе турында яза. Бу ханның тәхеткә X гасыр ахырларында ук утырган булуы мөмкин. Урыс елъязмаларында телгә алынган Бряхимов шәһәре аның исеме белән бәйледер, дип фаразлана. Ибраһим хан хакимлек иткән чорда болгарларның Казан һәм Алабуга кебек калаларына нигез салына.

Шуның белән шул: тарихи документларда XII һәм XIII гасыр башларында яшәгән болгар хакимнәре турында бер сүз дә юк. Кайбер риваятьләрдә һәм безгә билгеле булмаган нининдидер шикле чыганакларга таянып язылган хезмәтләрдә югарыда саналып киткән болгар ханнары исемлегенә тагын дистәгә якын исем өстәлә: 980 еллар ахырында хакимлек иткән Мөэмин ибн-Хәсәннең улы

Хәйдәр (Х гасыр ахыры); Хәйдәр ханның Мөхәммәд һәм Сәед исемле уллары; Сәедтән соң Бораҗ; аннан соң Ибраһим исемле тагын бер хан (Ш. Мәрҗани, ниндидер мәгълүматларга таянып, ул хан әле 1164 елда исән иде, дип яза); аннаң соң Солтан-Мурад һәм Сәлим ханнар; Сәлимнең улы Илһам. Гайрәтле һәм курку белмәс Илһам хан болгарларны 1223–1236 елгы монгол-татар яуларына каршы көрәшкә күтәрүче буларак танылган, имеш.

"Айдар хан һәм аның сәхабәләре", "Сөләйман Хуҗа", "Габдешшәмс" турындагы риваятьләр асылда бер-берләренә охшаш. Аларның беренчесендә болгарларның Айдар хан вакытында Мөхәммәд галәйһиссәлам җибәргән сәхабәләр "кулыннан" ислам дине кабул итү тарихы тасвирлана. Мөхәммәд пәйгамбәребез, мәгълүм булганча, 632 елда дөнья куя. Бу Кубрат хан вакытында Азов-Дон буйларында Бөек Болгар дәүләте оешкан чор. Болгарлар әле Идел буена күчеп китмәгән, шәһри Болгар да әле өч гасыр чамасы вакыт үткәч кенә барлыкка киләчәк. Минемчә, без санап киткән риваятьләр өчен боларның берсе дә әһәмиятле түгел, аларда бары тик болгарларның ислам динен үз теләкләре белән кабул итүләренә генә басым ясала ("Болгар җире бик бәрәкәтле җир, ул җиргә ислам кылыч көче белән таралмаган"). Тарихи күзлектән чыгып караганда монда бернинди дә арттыру, чынбарлыктан читкә тайпылу юк.

Китапка кертелгән риваять-легендаларның бер өлеше болгарларның монгол-татар явына һәм Сәмәркәнд җиһангиры, атаклы яугир Аксак Тимергә (Тамерланга) каршы азатлык көрәше тарихының кайбер сәхифәләрен чагылдыра. Әлеге циклны "Билярне яндыру" исемле риваять ачып җибәрә.

1236 елның көзе болгар бабаларыбызга үлем, коллык һәм әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәтләр алып килгән канлы вакыйгалар белән тарихка кереп калган. Болгар иленең башкаласы Биләр – Олуг шәһәр дә монгол-татарлар тарафыннан җир йөзеннән мәңгегә юкка чыгарылган дистләрчә һәм йөзләрчә шәһәр-авыллар язмышына дучар ителә. "Биләрне яндыру" риваяте – замандашларның документ рәвешендә теркәлеп калган мәгълүматларына аваздаш. "Шәрыкъ илләреннән килгән татарлар болгарларның данлыклы Олуг шәһәрен яулап алдылар, – дип хәбәр итә урыс елъязмачысы. – Чал чәчле карт-корылардан башлап, имчәк балаларына кадәр бача халкын кырып бетерделәр, бик күп байлык кулга төшерделәр, шәһәрләрен яндырдылар, илләрен буйсындырдылар". Шул елларның икенче бер шаһите, фарсы тарихчысы әл-Җүвәйни болай дип язып калдырган: "Болгар җирендә угланнар (монгол ханының угыллары. – *Ф.Х.*) бергә кушылдылар. Гаскәрләрнең күплегеннән җир өсте гүләп, ыңгырашып торды, шау-шудан кыргый җәнлекләр һәм ерткыч җанварлар кая качарга белмәделәр. Башта алар, монголлар, көч кулланып, штурмлап Олуг шәһәрне алдылар. Халкының күплеге, үтеп булмастай урынга ны-

клап урнашуы белән бу шәһәр бөтен җиһанда мәгълүм иде. Башкаларга сабак булсын өчен шәһәр халкының бер өлешен үтерделәр, бер өлешен әсир иттеләр".

Биләр хәрабәләрен казыганда археологлар еш кына монгол-татар яуларының шушы көннәргә кадәр сакланып калган эзләренә тап булалар. Шәһәрлекнең теләсә кайсы урынында, казыйм дип җиргә көрәк тыгарга өлгермисең, көл-күмер катламына, таралып яткан кеше сөякләренә, ук-җәя, сөңге, балта ише сугыш кораллары калдыкларына килеп төртеләсең. Әллә ничә урында инде "туганнар каберлеге" казып тикшерелде. Артык тирән булмаган чокырларда мөселман йоласына туры китереп тормыйча гына ашык-пошык күмелгән 16–18 яшьлек ир-егет мәетләреннән калган сөякләр ята. Бер чокырда 26 мәет, икенчесендә – 5 бала һәм 7 хатын-кыз мәетләре... Кайберләренең баш сөягендә тимер ук очлары...

1236 елгы афәт, дәүләтләрен югалткан болгарлар язмышында кискен борылыш чорын башлап җибәргән вакыйгалар, табигый ки, халык авыз иҗатында, чагылыш табарга тиеш иде. "Биләрне яндыру" риваяте" язма чыганакларда китерелгән мәгълүматларны тагын бер катраслый һәм тулыландыра гына.

"Мәрҗән каласы һәм унике кыз хикәяте", "Кырык кыз" риваяте дә шул чор вакыйгаларының язма чыганакларда теркәлеп калган һәм археология материаллары белән раслана торган кайбер фактларын тулыландырып торалар. Бу риваятьләрнең беренчесендә хәзерге Аксубай районы Яңа Үзи авылы янындагы урман эчендә урнашкан Мәрҗән исемле болгар шәһәре халкының Биләргә яу белән килгән дошманга каршы аяусыз көрәшләре сурәтләнә. Иштирәк батыр һәм аның кыю егетләре, Тырышмал Хуҗаның унике кызы Биләрдән ерак түгел җирдә урнашкан Хуҗалар тауы тирәсендә сугышалар һәм тигезсез яуда һәлак булалар.

Тарихи чыганакларга һәм археология материалларына күз салыйк. 1236 елгы олы сугыштан соң монгол-татарлар, болгар җирләрен бераз тынычлыкта калдырып, урыс кенәзлекләрен яуларга китеп баралар. Биләр халкының тирә-юнь урманнарына качып котыла алган бер өлеше башкаланы яңадан тергезү теләге белән яна. Янып-җимерелеп хәрабәләргә әйләнгән шәһәр урынында яңасын төзү авырга туры киләчәген аңлап, аксакаллар яңа башкаланы өч чакырым чамасы читтәрәк, хәзерге Балынгуз тавында торгызырга киңәш итәләр. Кызу эш башлана. Ике-өч ел эчендә шәһәр ныгытмаларын корып бетерәләр диярлек (400 га чамасы җирне биләп алган Балынгуз ныгытмалары бүгенге көнгә кадәр сакланып калган).

Ни кызганыч, Биләр халкының элеккеге башкаланы торгызу планы тормышка ашмый кала. XIV гасыр фарсы тарихчысы Рәшидетдин язганча, 1240 нчы еллар башында болгарларның яңа кала төзеп ятуларын ишетеп алган монголлар бу якларга яңадан яу белән килеп чыгалар. Баян һәм Җикү бәкләр җитәкчеле-

гендәге болгарлар дошманга каршы күтәреләләр һәм шул сугышта һәлак булалар. Риваятьтә әйтелгәнчә, "аларны тау башында җирләгәннәр" (археологлар Балынгыз тавының иң биек ноктасында, шәһәр ныгытмаларының көньяк читендә, ул каберлек урынын казып тикшерделәр).

Күргәнегезчә, Җикү батыр – чит ил елъязмларына да кереп калган реаль шәхес. Җикү исемен ишетүгә күз алдына кылт итеп "бер бите ай, икенчесе кояш кеби бик сылу кыз" – Алтынчәч килеп баса. Китапка "Хан кызы Алтынчәч" дигән риваять тә урнаштырылган. Аның кыскача эчтәлеге болай: Алтынчәч яшәгән кала өстенә берзаман бик зур яу килә. Яу башлыгы кызны үзенә хатынлыкка сорый. Алтынчәч аның теләген кабул итми һәм әтисе бу хәбәрне яубасарга җиткерә. Дошман ханга каршы сугыш башлый. Хан гаскәрләре җиңелә. Әтисенең җиңелгәнен күреп, Алтынчәч тә яуга каршы чыга, яралана һәм ахыр чиктә, дошман кулына төшмәс өчен, хан хәзинәсе яшерелгән мәгарәгә кереп кача.

Беләсез инде, легендар Җикү, Алтынчәч образларын һәм алар белән бәйле төп вакыйгаларны нигез итеп алып, Муса Җәлил мәшһүр "Алтынчәч" операсының либреттосын яза. Мәрҗән каласыннан чыккан Иштирәк батыр белән аның сөйгән кызы Нәркәс һәм дә Җикү батыр белән Алтынчәч образларының бер-берләренә охшавы очраклы микән, дигән сорау гына хәзергә җавапсыз кала.

Атаклы яугир һәм Сәмәркандһең бөек әмире Аксак Тимер белән бәйле риваятьләргә тукталып үтик. Фәндә, Аксак Тимер яу белән Болгар җирләренә 1395 елда килеп чыга, дигән бәхәсле фикер яшәп килә. Бу фикер яклы галимнәр XVII гасыр ахырында билгесез автор тарафыннан төзелгән "Дәфтәр-и Чыңгыз-намә" исемле дастаннар җыентыгына таяна. Ышанычлы тарихи чыганакларда Аксак Тимернең Болгарны җимерүе турында хәбәрләр юк. Шуңа күрә кайбер тарихчылар, риваятьләрдә 1236 елгы Батый хан яулары Аксак Тимернең 1395 елда Кавказда, Терек елгасы буенда башланып киткән яулары белән буташтырып бирелмәгән микән, дип тә уйлыйлар (контаминация күренеше фольклор әсәрләрендә еш очрый). Бу җимергеч сугыш киң территорияләргә җәелгән, Идел буйларына кадәр килеп җиткән, шунлыктан Аксак Тимер гаскәренең кайбер отрядлары Болгар якларына да килеп чыгуы бик мөмкин.

Элегрәк без, Аксак Тимер Болгарны җимергәннән соң Биләргә килеп җитә алмаган, чөнки бу шәһәр Батый хан чорында ук тулысынча җимертелгән булган инде, дип уйлый идек. Баксаң, Биләр халкы, монгол-татарларның яңадан бер һөҗүме нәтиҗәсендә югарыда телгә алынган Балынгуз каласын төзеп бетерә алмагач, аннан ерак түгел икенче бер җиргә, Кече Чирмешән елгасының сул ягына, элеккеге болгар авылы урынына күчеп утыра. Ул авыл тора-бара шәһәр дәрәҗәсенә кадәр үсеп җитә (аның мәйданы 80 гектар чамасы). Ныгытмалары булмаган бу шәһәр, археология материаллары күрсәткәнчә,

XIV гасыр ахырларына, ягъни Аксак Тимер яуларына кадәр яши.

Риваятьләрдә урын алган тагын бер фактка игътибар итмичә булмый. "Янмый торган кыз", "Рабига күле", "Иске Казан каласының корылуы" риваятьләрендә, төрле вариантларда, соңгы Болгар ханы Габдулла, аның кызы, Алтынбәк һәм Галимбәк исемле ике улы турында сөйләнә. Аксак Тимер Болгарны яулап алганнан соң Габдулла хан үтерелә. Аның ике улын, берсенә 7, икенчесенә 9 яшь кенә тулган шаһзадәләрне, яшерен рәвештә башта Биләр шәһәренә озаталар, аннан соң Кама аръягына алып китәләр. Биредә, Казансу буенда, Алтынбәк белән Галимбәк кала корып яши башлыйлар. Болар корган каланы Иске Казан дип атаганнар. Иске Казанның беренче ханы Алтынбәк була, ул анда илле елдан артык ханлык итә. Аннан соң ханлык аның энесенә, Галимбәккә күчә. Ул хан тәхетендә утыз елдан артык утыра. Риваятьләрдә әйтелгәнчә, Габдулла ханның балалары Иске Казанда 104 ел хакимлек итәләр, аннаң соң кала Казансу тамагына, хәзерге Казан урынына күчерелә. "Яңа" Казан урыслар кулына калганчы 158 ел яшәп кала.

Хәзер риваятьләрдә бәян ителгән вакыйгаларга һәм фактларга бүгенге фән күзлегеннән карыйк. Миңа калса, Габдулла ханны да, аның ике улын да тарихи шәхесләр дип танырга мөмкин, һәрхәлдә, бу фикер мантыйкка каршы килми. Ә менә 1395 елда, яки бераз соңрак нигез салынган Иске Казанның 1499 елга кадәр (1395+104=1499) яшәгән булуы һәм шул ук елда салынган "Яңа" Казанның Явыз Иван кулына 1657 елда эләгүе (1499+158=1657) чынбарлыктан ерак тора. Кайбер тарихчылар тәкъдим иткәнчә, Аксак Тимерне Батый хан белән алыштырып карасак та (1236+104 =1340 – "Яңа" Казанга нигез салыну елы; 1340+158=1498 – Явыз Иван Казанны буйсындырган ел), очы очка ялганмый торган нәрсәләр килеп чыга. Археологик материаллар күрсәткәнчә, "Иске Казан", ә борынгы архив документларында күбесенчә "Ички", ягъни "Эчке Казан" дип йөртелә торган Рус Урматы авыллыгы ("шәһәр бистәсе"?) XII гасыр ахырында – XIII гасыр башларында барлыкка килеп, XIV гасыр ахырына кадәр яшәгән, ә аннан ике-өч чакрым ераклыкта урнашкан Камай шәһәрлеге ("шәһәрнең кремле"?) XIV гасыр ахырында гына барлыкка килгән, яшәүдән туктаган вакыты XVI гасыр урталарына карый. Ягъни мәсәлән, шәһәрнең бистәсе белән кремле икесе ике чорда, бер-берсеннән аерым яшәгән булып чыга. Баксаң, "Яңа" Казан да "Искесенә" караганда күпкә борынгырак икән. Археологлар аңа X гасыр ахырында – XI гасыр башында ук нигез салынган булуын исбатладылар.

Югарыда әйтелгәннәрдән ачык күренгәнчә, риваятьләрдә китерелгән конкрет шәхесләр, теге яки бу вакыйгаларның төгәл даталары кайчакта артык ышанучан укучыларны (хәтта галимнәрне дә) адаштырырга сәләтле икән.

Шул ук вакытта әлеге фактларны ышанычлы тарихи чыганаклар белән

чагыштырып карау кызыклы гына нәтиҗәләргә дә китерергә мөмкин. Галимбәк шаһзадә исеме белән бәйләнгән бер мисал. "Яңа Казанны салганда аның беренче ханы – Алтынбәк, икенчесе – Галимбәк, өченчесе – Мөхәммәд, дүртенчесе Мәхмүтәк була", – диелә риваятьләрнең берсендә. Игътибар итегез: Мөхәммәд, дөресрәге Олуг Мөхәммәд, биредә өченче хан рәвешендә күрсәтелә, ягъни ул ханлыкны оештыручы түгел (аның хәтта Казанда булуы да бернинди документлар белән дә расланмаган). Менә ышанычлы чыганак – урыс елъязмалары. Воскресение елъязмасында болай диелгән: "Олуг Мөхәммәд углы Мамотек (Мәхмүтәк, Мәхмүд. – *Ф.Х.*) Казанны алды, Алибей (Алимбәк, Галимбәк. – *Ф.Х.*) кенәзне үтерде һәм Казанда үзе патшалык итә башлады". Бу вакыйга 1445 елда була. Риваятьләр шуны күрсәтә: Алтын Урданың соңгы ханнарыннан булган Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүд Казанны сугышып ала һәм аның ханы булып торган Галимбәкне үтереп, тәхеткә үзе менеп утыра. Икенче төрле итеп әйткәндә, моңарчы Казан тәхетен биләп торган болгар династиясе урынына Җүчиләр (Алтын Урда) династиясенә караган ханнар килеп утыра. Менә шушы вакыйгадан шартлы рәвештә 1552 елга кадәр яшәгән Казан ханлыгы тарихын башлап җибәрәләр.

Риваятьләрдә бер гасырдан әз генә күбрәк яшәгән Казан ханлыгы идарәчеләренең исемнәре санап кителә: "Әүвәл Габдулла хан углы Алтынбик хан, Галимбик хан, аннан соң Мәхмүт хан, аннан соң Мәмнәк хан, аннан соң Хәлил хан, аннан соң Ибраһим хан, аннан соң Илһам хан, аннан соң Габделлатыйф хан, аннан соң Сәхиб Гәрәй хан, аннан соң Сафа Гәрәй хан, аннан соң Гали (Җангали. – *Ф.Х.*) хан, аннан соң Үтәш (Үтәмеш. – *Ф.Х.*) хан, аннан соң Ядгәр хан, әмма Ядгәр заманында тарих тугыз йөз илледә көн (кояш. – *Ф.Х.*) тотылды. Аннан соң Шәгали хан, аннан соң кяфер урыс алды". Шушы исемлекне ышанычлы тарихи чыганаклар нигезендә төзелгәне белән чагыштырып карагыз: Мәхмүд (1445–1465?), Хәлил (1465?–1467?), Ибраһим (1467?–1478), Илһам (1478–1487), Мөхәммәд-Әмин (1487–1496; 1502–1518/1519), Мамук (1496), Габдел-Латыйф (1496–1502), Шаһ-Гали (1519–1521; 1546: 1551–1552), Сәхиб-Гәрәй (1521–1524), Сафа-Гәрәй (1524–1531; 1535–1546; 1546–1549), Җан-Гали (1532–1535), Үтәмеш-Гәрәй (1549–1551), Ядгәр (1552). Риваятьләрдәге исемлектә Мәхмүд ханнан соң безгә тарихи чыганаклардан билгеле булмаган Мәмнәк хан килә, шул ук вакытта Мамук хан һәм Мөхәммәд-Әмин хан исемнәре бөтенләй төшеп калган. Мамук ханны аңлап була әле – ул тәхеттә берничә ай гына утырып кала, ә менә Казан дәүләтенең иң күренекле һәм ил белән озак идарә иткән ханның "онытылып" калуы бераз гаҗәпләндерә.

Шунысы игътибарга лаек: риваятьләрдә ханнарыбызның барысы да диярлек (Шаһ-Галидән калганнары) уңай яктан гына телгә алына, мактала, хәтта идеаллаштырыла: "Мөсел-

ман ханнары кулында Казан шәһәре бик төзек торды. Голәмалары вә мөдәррисләре вә һәм көтепханәләре күп иде вә талибләре күп иде. Ханнарның дошманнары юк иде. Казан ханлыгы мөддәтенә һичбер дошман килеп Казанга кул сузмады" ("Казанның алынуы"). Ә менә "Шәгали дигән адәм"гә, "ул хан булганнан соң Казанда күп тынычсызлык вә фетнә була башлады, мөселманнарга күп хыянәт кылды, урыс ханнары белән дуслашып, алардан күп мал алып, мәмләкәтне карауга күп илтифат кылмады", – дип тискәре мөнәсәбәт белдерелә.

Татар халык авыз иҗатында ханлык чоры идарәчеләреннән бары тик Сөембикә образына гына киң урын бирелгән. Шушы китапка кертелгән "Сөембикә" кыйссасында барыбызга да таныш бер фаҗигале вакыйга тасвирлана: Мәскәү патшасына кияүгә чыгарга теләмәгән ханбикә, башка чарасы калмагач, "ире (Сафа-Гәрәй. – *Ф.Х.*) күмелгән мәчетнең манарасына менә дә аска ташлана. Менә шуннан соң инде хан мәчетен "Сөембикә манарасы" дип атый башлыйлар". Чыннан да, Сөембикә манарасын татарлар инде күптән, ихтимал, Явыз Иван заманнарында ук җимертелгән хан мәчетенең манарасы дип кабул итәләр, бирегә килеп, бабаларыбыз рухына дога кылып китәләр. Археологлар исә Сөембикә манарасының бары тик XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башларында гына төзелгән булуын исбатладылар. Әмма шул тирәдә казу эшләре алып барган вакытта алар ханлык чорында салынган мәчет хәрабәләре ачтылар. Күрәсең, халык хәтерендә кайчандыр хәзерге Сөембикә манарасы урынында торган әнә шул Хан мәчете саклanaдыр. Моның белән, Сөембикә шул борынгы мәчет манарасыннан сикереп һәлак булгандыр, дип әйтүебез түгел. Ул әле 1551 елда ук биш яшьлек улы Үтәмеш хан белән Мәскәүгә әсирлеккә озатылып, аннан көчләп Касыйм ханы Шаһ-Галигә кияүгә бирелеп, 1554–1557 еллар тирәсендә гүр иясе була. Хан мәчетен Шәрык архитектурасы стилендә төзелгән "Сөембикә манарасы" белән тәңгәлләштерү бер дә гаҗәп түгел, димәкче булабыз.

Ниһаять, 1552 елның 2 октябрь фаҗигасы. Халык хәтерендә ул бүген дә саклана һәм мәңге сакланачак. Риваятьләрдә Казанның алынуы "һәр ике тарафның (Явыз Иван гаскәрләренең һәм казанлыларның. – *Ф.Х.*) туплары атылып, җир йөзендә адәм каны елга кебек аккан" көн буларак тасвирлана. Урыс гаскәрләре "ханзадәләрнең һәм әкябирләрнең кайсын үтереп, кайсын әсир кылып һәлак итте. Голләмаларын үтертте. Мәдрәсәләрен яндырды... Казанда мөселманнар бик аз калды, һәммә йортларга урыс халкы килеп урнашты". Бу сүзләргә бернинди аңлатма кирәкми, чөнки алар елъязмаларда һәм археологик материалларда чагылыш тапкан чынбарлык белән аваздаш.

Югарыда язылганнарга кыскача гына йомгак ясап, шуны әйтергә телим: риваятьләрдә һәм легендаларда халкыбыз тарихындагы иң мөһим, аның киләчәк язмышында кискен борылыш ясардай хәлиткеч вакый-

галар чагылыш тапкан. Халык ул вакыйгаларга үзенең бәясен биргән, мөнәсәбен белдергән. Татар халык авыз иҗатының кечкенә генә бер өлешен тәшкил иткән риваятьләр һәм легендаларны укып та искиткеч бай, катлаулы, батырлыкларына сокланырлык шәхесләр, аларның эшләре һәм фаҗигале язмышлар белән тулган тарихыбызны ярыйсы гына тулы һәм нигездә дөрес итеп күз алдына китереп була икән.

*Ханнар заманында. В ханские времена / Төз.: С. Гыйләҗетдинов, А. Гыйләҗетдинова. Казан, 2019. Б. 5–19.*







## ТАГЫН БЕР ТАПКЫР «ИСКЕ КАЗАН» ТУРЫНДА

Урта гасырлар чорына караган ике археологик объект – Камай шәһәрлеге һәм Рус Урматы авыллыгы – Идел Болгары һәм Казан ханлыгы тарихын өйрәнүдә әһәмиятле урын алып торалар. Археолог-галимнәрнең кайберләре әле һаман да «Яңа», ягъни бүгенге Казан үзенең килеп чыгышы, нигезләнүе белән «Иске Казанга» бурычлы дип ышаналар. Әлеге фикер тарафдарлары белән килешмичә, заманында үзенең Алтын Урда археологиясенә караган хезмәтләре белән танылган Мәскәү галиме В.Л. Егоров, «Иске Казан» мөстәкыйль шәһәр булып яшәгән һәм ул Казанның барлыкка килү тарихы белән берничек тә бәйләнмәгән, дип язып чыккан иде (Егоров, 1975, с. 80). Бу мәсьәләгә киңрәк тукталып үтәсе килә.

Касансу елгасының уңъяк ярыннан ерак түгел җирдә, биек тау башында урнашкан Камай каласы беренче мәртәбә әле XVIII гасырда ук Н.П. Рычков (1772, с. 1–5) һәм И.Г. Георги (Georgi, 1775, S. 811–813) тарафыннан тикшерелә. Һәм алар, җирле халык арасында таралган төрле риваять-легендаларга таянып, биредә озак кына гомерләр Иске Казан каласы яшәп килгән һәм ул төрле сәбәпләр аркасында соңыннанрак хәзерге, «Яңа» Казан җирлегенә күчерелә, дигән фикер әйтәләр. «Заволжский муравей» журналы редакторы М.С. Рыбушкин (1833, с. 1183–1189) һәм П. Малов (1853, с. 120) С.-Петербургта чыга торган «Археология җәмгыяте язмалары» журналында басылган мәкаләләрендә, «Иске Казан» составына Казансу елгасының сул ягында урнашкан Рус Урматы авыллыгын да кертеп куялар. Легендар «Иске Казан» калдыкларын Камай каласы

белән тәңгәлләштерү фикерен XIX – XX йөз башы тарихчылары һәм төбәкчеләре П.Е. Заринский (1880, с. 7–12, М.Н. Пинегин (1890, с. 21–24), Н.П. Загоскин (1895, с. 10–20), В.Л. Борисов (1901), И.Н. Смирнов (1901), П.А. Пономарёв (1904) яклап чыгалар.

Мәсьәләнең шулай куелышы белән килешмәгән бердәнбер автор М.М. Хомяков (1911) үзенең фикерен Камай шәһәрлегендә культура катламының бик юка һәм анда борынгыдан калган торак, хуҗалык корылмаларының булмавы белән нигезли. Камай каласы, дип яза ул, 1552 ел вакыйгаларында үзен Явыз Иван гаскәрләренә ярдәм күрсәтеп ятучы сатлыкҗан кенәз Камайның резиденциясе, яхшы ныгытылган крепосте булгандыр. Археолог И.Н. Бороздин (1929, с. 194, 199–200) М.М. Хомяков концепциясенең Камай каласы – хәрби крепость калдыклары, дигән өлеше белән килешсә дә, «Иске Казанны» бары тик Рус Урматы авыллыгы белән генә тиңләштерә (биредә ул бераз казу эшләре дә үткәреп ала). Н.Ф. Калинин (1954, с. 103–104) И.Н. Бороздинның әлеге фикере белән тулысынча килешә. Совет чоры болгарчы- археологларның башлыгы А.П. Смирнов (1962), бернинди казу эшләре үткәрмичә генә, бер көнлек күзәтүләре нигезендә, Камай шәһәрлеге хәрби крепость кына түгел, биредә «Иске Казан» исеме белән тарихка кереп калган зур шәһәр урнашкан булган, дип язып калдыра.

Игътибар итегез, югарыда санап кителгән авторларның барысы да диярлек (М. Рыбушкин белән П. Мalo-втан кала) Камай шәһәрлеген һәм Рус Урматы авыллыгын бербөтен археологик комплекс итеп карамый, «Иске Казанны» аларның йә берсе, йә икенчесе дип таныйлар.

1972 елдан башлап 1988 елга кадәр безне кызыксындырган археология истәлекләрендә Р.Г. Фәхретдинов киң казу эшләре алып барды (1970-нче еллар уртасында, бер-ике сезон дәвамында, экспедиция составында нумизмат һәм археолог А.Г. Мөхәмәдиев һәм Н.А. Кокорина да эшләп ала) (Мухамадиев, Фахрутдинов, 1977, с. 165–166; Кокорина, 1999, с. 72–102; Кокорина, Фахрутдинов, 1999, с. 103–134). Тикшеренүләр нәтиҗәсе аның күпсанлы фәнни-популяр хезмәтләрендә (Фәхретдинов, 1978, б. 175–180; 1992, б. 96–108) һәм 1984 елда Мәскәүнең «Фән» нәшриятында чыккан «Очерки по истории Волжской Булгарии» исемле монографиясендә чагылыш тапты. Галимнең концепциясе бу китапта бик ачык бәян ителгән: XIII гасырның икенче яртысында калкып чыккан һәм 6 гектардан артыграк мәйданны биләп торган Камай каласы, дип ышандырырга азаплана ул укучыны, һичшиксез, – *«кремль, политический центр города, где, кроме князя и его дружины, находились административный аппарат и высшее духовенство. Одновременно имелись некоторые производственные комплексы, построенные в целях удовлетворения потребности верхушки и гарнизона в вооружении и средствах первой необходимости»* (Фахрутдинов, 1984,

с. 146). Һәм шунда ук дәвам итә: *«Основная часть Иски Казани, занятая ремесленно-торговым людом, располагалась… на месте Русско-Урматского селища»*. Бу авыл исә XV гасыр башларында, чәчәк атып яшәгән вакытында, 120 гектар җирне биләп торган дип исәпләнә. Р.Г. Фәхретдинов фикеренчә, нәкъ менә шушы комплекс, Камай шәһәрлеге белән Рус Урматы авыллыгы, Болгар әл-Җәдид дип аталган да инде. Соңыннан бу исем XIV гасыр ахырларында барлыкка килгән «Яңа Казанга» күчә, имеш. Кызганыч, Идел Болгары тарихына багышланган китапта («»Очерки по истории...») әлеге концепция археологик материаллар белән расланмаган, булган материал фәнни-популяр характерда гына «анализланган». Автор үзеннән башка галимнәрне ышандырырлык тарихи чыганаклар да кулланмаган, чөнки алар юк.

1990-нчы елларда һәр ике объектта А.А. Борханов җитәкчелегендәге археологик экспедиция эшләде (Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты археологлары И.Л. Измайлов һәм А.М. Гобәйдуллин катнашында) (Бурханов, Губайдуллин, 1995, с. 14–17; Бурханов, Измайлов, 1999, с. 135–138). Үзенең бер өлеше хезмәттәшләре белән язылган башлыча кыска гына информация характерендагы хезмәтләрендә (Бурханов, 1995; 2011; Бурханов, Губайдуллин, 1995; Бурханов, Измайлов, 1999; Бурханов, Касимов, 1995) ул нигездә Р.Г. Фәхретдинов концепциясенә таяна, шул ук вакытта элгәрегеләрнекенә бераз яңалык та кертеп җибәрә. Мәсәлән, Р.Г. Фәхретдиновтан аермалы буларак, Рус Урматы авыллыгын шәһәрлек дип атый (дөрес, бернинди археологик аргументлар китермичә генә, чөнки алар юк). Аннан башка, ул бу юлларның авторы тарафыннан исбатланган (Хузин, 1995, с. 42–43) Камай шәһәрлеге белән Рус Урматы авыллыгының яшәү вакытлары бер-берсеннән аерылып тора, тәңгәл килми дигән тезисны яклап чыга (Бурханов, Измайлов, 1999, с. 137). Рус Урматы авыллыгы биләп торган мәйданның күләмен, тагын 80 гектар чамасы өстәп, 200 гектарга җиткерә, әмма археологик аргументларын китерергә генә онытa.

Кызганычка каршы, «Иске Казан» коллекцияләре бик начар сакланган, чөнки алар, казылмалардан чыккан табылдыклар, тулы мәгълүмат алырлык итеп тасвирланмаган, табылдыкларның кайсы урыннан, нинди тирәнлектә табылганлыклары турында информация язылган этикеткалары югалган, фән өчен яраксыз хәлгә килгән. Моны мин башлыча разведкаларга йөреп күнеккән, археологик казу эшләрендә катнаша алмаган (1968 елда Биләрдә эшләп алуын исәпкә алмаганда) экспедиция җитәкчесенең тәҗрибәсезлегеннән күрәм. 1970-нче елларда «Иске Казан» экспедициясендә бер-ике ел эшләп киткән нумизмат Ә.Г. Мөхәммәдиевнең дә (Мухамадиев, Фахрутдинов, 1977), 1990-нчы елларда казу эшләре үткәргән А.Ә. Борханов, И.Л. Измайлов, А.М. Гобәйдуллин да болгар шәһәр-авылларын казып тәҗрибә туплаган археологлар түгел иде. Шуңа

күрә, алар, табылдыкларны тирән өйрәнмичә, кыска гына информация бирү белән чикләнделәр (Бурханов, 1999; Бурханов, Губайдуллин, 1995; Бурханов, Измайлов, 1999).

Экспедиция составына Татарстан дәүләт музее хезмәткәре, тәҗрибәле археолог Н.А. Кокорина чакырылгач кына эшләр бераз җайга салынды, яңа казылмалардан чыккан материаллар, мөмкин булганда элегрәк тупланганнарын да исәпкә алып, фәнни әйләнешкә кереп киттеләр (Кокорина, 1999; 2002; Кокорина, Фахрутдинов, 1999).

Билгеле булганча, «Иске Казан» тарихы буенча язма чыганаклар юк дәрәҗәсендә. Аның каравы, борынгы бабаларыбыздан бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән халык иҗаты әсәрләре – легенда һәм риваятьләр сакланып калган. Алар әле XVIII гасырда ук язып алынган. Казан университеты профессоры С.М. Шпилевский үзенең 1877 елда чыккан китабында билгеләп үткәнчә, «Аксак Тимернең Болгарга хәрби явы, болгар шәһәрләрен талавы һәм Казанга нигез салыну вакыйгасы татар кульъязмаларының һәм риваятьләренең мөһим бер эчтәлеге, үзенчәлеге булып тора. Әлеге вакыйгалар бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән – [Иске] Казан Болгар ханының Тимердән качып котылган уллары тарафыннан салынган» (Шпилевский, 1877, с. 68). «Иске» Казанның Аксак Тимер тарафыннан 1391 елда ясалган хәрби яу нәтиҗәсе буларак барлыкка килүе турындагы сюжет тарих һәм археология материаллары белән берничек тә бәйләнмәгән булганлыктан, Р.Г. Фәхретдинов, бу риваятьләрдә Аксак Тимер вакытындагы вакыйгалар түгел, ә Батый хан заманнарындагы вакыйгалар чагылыш тапкан, дип фаразлый. Халык хәтеренә тулысынча ышанып, ул «Яңа Казанның барлыкка килүеннән 1552 ел вакыйгаларына кадәр 158 ел үткән, ә «Иске Казан «Яңа Казанга» күчерелгәнгә кадәр 104 ел яшәгән дигән фикергә килә. Менә шундый бик җиңел юл белән, ягъни мөселман хронологиясендәге датаны христиан хронологиясенә әйләндереп, ул «Иске» Казанның нигезләнү датасын 1298, «Яңа» Казанныкын 1399 ел белән билгеләп куя. Ә бит барыбер безгә билгеле археология материаллары белән ярашу килеп чыкмый: Рус Урматы авыллыгы – Р.Г. Фәхретдинов карашы буенча, шәһәр бистәсе – монголларга кадәрге чорда, һәрхәлдә инде XII гасырда ук, тыныч кына яшәп яткан.

Истәлекләрнең хронологиясе турында сүз чыккач, Р.Г. Фәхретдиновның югарыда күрсәтелгән 1984 елгы монографиясендә телгә алынган матералларга таянып, Рус Урматы авыллыгының (шәһәр бистәсенең) һәм Камай каласының (кремльнең) хронологиясе турында да бер-ике сүз әйтеп үтмәкче булам. Ул истәлекләр, һичшиксез, беркавым синхрон рәвештә, бер үк вакытта яшәгәннәр, әмма яшәү вакытлары бер-берсенә тулысынча тәңгәл килә дип әйтеп булмый. Авыллык XII гасырда барлыкка килә, XIV гасырга кадәр (бәлки, XV гасыр башларына кадәрдер) биредә тормыш кайный. Шәһәрлек соңрак барлыкка

килә, яшәү вакытын XV гасырдан башлап, XVI гасырның беренче яртысы, яки шул ук гасырның урталарына кадәр дәвам иткәндер, дип уйлыйбыз. Күренеп тора ич: Фәхретдинов монографиясендә Камай шәһәрлегенә нисбәтле рәвештә телгә алынган 77 Җүчи акчаларының 69-ы XV гасырда, бары тик икесе генә XIV гасырда сугылган, калганнарының датасы ачыкланмаган (Фахрутдинов, 1984, с. 142, 144). Соңгы елларда, безгә билгеле булгача, яңа нумизматика табылдыклары килеп чыккан, әмма алары да югарыда китерелгән нисбәтне бозмый. Монеталар арасында шулай ук XV гасыр башында, рус кенәзе Василий II вакытында сугылганнары бар. XVI гасырга караган бакыр тәреләр табыла. «Кремльнең» һәм һөнәрчелек бистәсенең без аныклаган хронологияләре Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европаның урта гасыр шәһәрләренә хас закончалыкны бозалар: гадәттә башта шәһәрнең ныгытылган өлеше – кремле барлыкка килә, бераз соңыннан аның тирәсенә һөнәрчеләр килеп утыра, шәһәр бистәсе үсеп чыга. Димәк, бу өлкәдә Р.Г. Фәхретдинов бераз ялгыша (Фахрутдинов, 1984, с. 163).

Хәзер шәһәрнең топографиясенә, ягъни Рус Урматы авыллыгы белән Камай шәһәрлегенең урнашу үзенчәлегенә күз төшереп алыйк. Алар бер-берсеннән 2 километрдан да ераграк аралыкта урнашканнар. Урта гасыр чорына караган борынгы рус һәм Европа шәһәрләрендә аларның административ үзәге (кремле) һөнәрчелек бистәсеннән шулкадәр ераклыкта урнашканнары билгеле түгел.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, без әлеге ике археология истәлеген бер комплекска берләштереп, аны «Иске Казан» дип атауга каршы чыгабыз. 1994–2005 елларда Казан кремлендә алып барылган казу эшләре вакытында табылган күпсанлы материаллар башкалабызның X–XI гасырлар чигендә барлыкка килүендә шик калдырмый. Бер үк вакытта әлеге материаллар Фәхретдиновның «Иске Казан» концепциясен челпәрәмә китерәләр: Рус Урматы авыллыгы Камай каласыннан күпкә борынгырак.

Шул ук вакытта әлеге археология истәлекләре арасында без әле аңлап җиткермәгән бәйләнешләр дә барлыгын кире кагып булмый. Мәсәлән, Алтын Урда чорында Рус Урматы авыллыгы «Иске» түгел, «Эчке» Казан дип аталган. Бу турыда, архив материалларына таянып, тарихчы Р.Ф. Галләмов язып чыкты (Галлямов, 2000, б.186–190). Күрәсең, монголларның теләсә кайчан мөмкин булган яу чабуларыннан куркып, «чын» Казанның кайбер функцияләре, беренче чиратта, һөнәрчелек белән бәйле булганнары, «Эчке» Казанга күчерелеп торгандыр.

## Файдаланылган әдәбият

*Бурханов А.А.* А.П. Смирнов и некоторые проблемы историко-археологического изучения Заказанья // Научное наследие А.П. Смирнова и современные проблемы

археологии Волго-Камья. Тезисы докладов научной конференции, посвящённой 100-летию со дня рожддения А.П. Смирнова / Отв. ред. И.В. Белоцерковская. М., 1999. С. 130–135.

*Бурханов А.А.* Историко-археологическое изучение памятников Золотой Орды и Казанского ханства в Татарстане: история, некоторые итоги и перспектвы. (Материалы и исследования по археологии и истории Золотой Орды и Казанского ханства. Вып. 6). Препринт доклада Международного научного симпозиума «История Идел-Урала, г. Анкара. Казань, 2011. 64 с.

*Бурханов А.А., Губайдуллин А.М.* Археологические работы в охранной зоне ИКГМЗ в 1995 году (предварительное сообщение) // Заказанье: проблемы истории и культуры. Материалы научно-практической конференции / Отв. ред. А.А. Бурханов. Казань: Изд-во «Заман», 1995. С. 14–17.

*Бурханов А.А., Измайлов И.Л.* Новые данные по фортификации Казанского ханства (по итогам раскопок памятников Заказанья) // Научное наследие А.П. Смирнова и современные проблемы археологии Волго-Камья. Тезисы докладов научной конференции, посвящённой 100-летию со дня рожддения А.П. Смирнова / Отв. ред. И.В. Белоцерковская. М., 1999. С. 135–138.

*Бурханов А.А., Касимов Х.М.* Памятники Иске-Казанского государственного музея-заповедника // Заказанье: проблемы истории и культуры. Материалы конференции / Отв. ред. А.А. Бурханов. Казань: Изд-во «Заман», 1995. С. 44–49.

*Галлямов Р.Ф.* Иски Казань – Ички Казань // Средневековая Казань: возникновение и развитие. Материалы Международной научной конференции / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: Мастер-Лайн, 2000. С. 186–189.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Итоги археологических работ за 1945–1952 гг. // Труды КФАН СССР, серия исторических наук. Казань: Татар. кн. изд-во, 1954. 126 с.

*Кокорина Н.А.* Керамика усадьбы гончара из Иски Казани // Татарская археология. 1999. № 1–2 (4–5). С. 72–102.

*Кокорина Н.А.* Керамика Волжской Булгарии второй половины XI – начала XV в.. (К проблеме преемственности булгарской и булгаро-татарской культур). Казань: Ин-т истории АН РТ, 2002. 383 с.

*Кокорина Н.А. Фахрутдинов Р.Г.* Гончарный комплекс золотоордынского периода из Иски Казани // Татарская археология. 1999. № 1–2 (4–5). С. 103–134.

*Мухамадиев А.Г., Фахрутдинов Р.Г.* Раскопки в Иске-Казани // Археологические открытия 1976 года. М.: Наука, 1977. С. 165–166.

*Смирнов А.П.* Работы Поволжской экспедиции 1960 г. // Краткие сообщения Института археологии АН СССР. 1962. Вып. 90. С. 25–32.

*Фахрутдинов Р.Г.* Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. 219 с.

*Фахрутдинов Р.Г.* Очерки по истории Волжской Булгарии. М.: Наука, 1984. 216 с.

*Фәхретдинов Р.* Ташлар моңы. Археолог язмалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 190 б.

*Фәхретдинов Р.* Мондадыр безнең бабайлар. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992. 176 б.

*Хузин Ф.Ш.* К вопросу о «Старой» и «Новой» Казани // Заказанье: проблемы истории и культуры. Материалы научно-практической конференции / Отв. ред. А.А. Бурханов. Казань: Изд-во «Заман», 1995. С. 41–43.

*Шпилевский С.М.* Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань: Изд-е Импер. Казан. ун-та , 1877. X+585+XVI с.

*Ещё раз об «Иски» Казани //*
*Средневековая Казань: возникновение и развитие*
*/ Отв. ред. и сост. Ф.Ш. Хузин. Казань: 2000. С. 181–185.*
*(мәкалә авторының иркле тәрҗемәсе, кайбер өстәмәләр белән).*




## КОМИ-ПЕРМЯКЛАРНЫҢ БОРЫНГЫ БАБАЛАРЫНДА ИГЕНЧЕЛЕК ҺӘМ ШУЛ ӨЛКӘДӘ БОЛГАРЛАР МИРАСЫ

А.Н. Сарапуловның «Средневековое земледелие Пермского Предуралья по археологическим данным (Пермь, 2015. 170 с.)» дигән монографиясе турында

Иң борынгы чорлардан башлап бүгенге көннәргә кадәр яшәгән һәр җәмгыятьнең тарихын өйрәнүне, кагыйдә буларак, аның икътисад үсеше дәрәҗәсен, хуҗалык үзенчәлекләрен ачыклаудан башлап җибәрәләр. Урта гасырларда. Көнчыгыш Европаның урта гасырлар чорына караган дәүләтләрендә, хәтта дәүләтчелек дәрәҗәсенә ирешмәгән кайбер җәмгыятьләрдә дә игенчелек һәм терлекчелек икътисадның мөһим тармакларыннан саналган. Шулай булуга карамастан, археологик тикшеренүләрдә игенчелек тарихына караган проблемаларга тиешенчә игътибар бирелми. Сәбәпләре бар, әлбәттә. Беренче чиратта культура катламнарының туплану вакыты яхшы билгеләнгән авыллыкларда табылган артефактларның аз булуы; игенчелек коралларының күбесе очраклы табылдыклар, шул сәбәпле аларның даталары киң диапазонлы, берничә гасыр эчендә үсеш-үзгәреш динамикасын өйрәнерлек түгел. Сыйфатлы археологик материалларның һәм дә тарихи чыганакларның җитәрлек булмавы игенчелектә кулланыла торган туфрак эшкәртү, уңыш җыю, аны кулланучыларга җиткерү өчен эшкәртү коралларын һәм, гомумән, игенчелек системасын реконструкцияләүне кыенлаштыра.

Шулай булуга карамастан, Россия историографиясендә В.П. Левашова (1956), Н.А. Кирьянов (1958), Ю.А. Краснов (1975; 1978; 1979; 1982), В.В. Туганаев (1972; 1975; 1976; 2006), Е.Ю. Лебедева (2005;

2014) һ.б. кебек археологларның һәм палеоботаникларның безне кызыксындыра торган проблема буенча методик-методологик аспектларына багышланган эшкәртмәләре һәм Көнчыгыш Европаның аерым төбәкләрендәге игенчелек тарихына багышланган кыйммәтле хезмәтләре төрле елларда дөнья күрде.

Әле күптән түгел генә тарих фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ия булган яшь галим Алексей Николаевич Сарапуловның 2015 елда басылып чыккан монографиясе моңа кадәр өйрәнелмәгән, әмма бик актуаль темага – урта гасырлар чорында бүгенге Пермь крае җирлегендә яшәгән коми-пермяк халкының игенчелек тарихына багышланган.

Билгеле булганча, тарихчылар, шул исәптән, археологлар да үзләренең тикшеренүләрендә документаль чыганакларга таяналар; шул чыганакларны фәндә кабул ителгән дөрес ысуллар белән җентекләп анализлау объектив нәтиҗәләрнең, тарихи реконструкцияләрнең ышанычлы нигезе булып тора.

А.Н. Сарапуловның без рецензияли торган хезмәте төрле характердагы, күләмле генә чыганакларга таянып язылган, һәм ул чыганаклар урта гасырлар чорында яшәгән коми-пермяк игенчеләренең ашлык чәчү өчен урман кисеп җир кишәрлекләре әзерләүдән башлап, уңышны җыеп алу һәм эшкәртүгә кадәр булган этапларында кулланыла торган эш коралларын, шулай ук археологик казулар вакытында табылган палеоботаник материалларны (бөртекле культуралар һәм чүп үлән орлыклары) үз эченә ала. Галимнең игътибарыннан этнография, фольклор һәм агрономия фәннәре бирә торган мәгълүматлар да читтә калмаган.

Әлбәттә, безнең өчен казу эшләре вакытында табылган материаллар кыйммәтрәк. Андый материаллар, очраклы рәвештә табылганнарына караганда азрак булса да, авыллык һәм шәһәрлек, 5 каберлек (борынгын зират) урыннарын казыганда килеп чыккан. Шунысын да әйтеп үтик: шул 30 объектның 12сен археологик яктан өйрәнгәндә монография авторы да актив катнашкан, табылдыклары да аның тарафыннан әтрафлы һәм, әйтергә кирәк, максатчан анализланган.

Кулланылган чыганаклар автор тарафыннан китапның Кереш өлешендә куелган проблемаларны объектив рәвештә чишү өчен җитәрлектер дип уйлыйм. Дөрес, биредә чыганакларны анализлау ысуллары турында бер сүз дә юк, әмма бу җитешсезлек хезмәтнең аерым бүлекләрендә бирелгән аңлатмалар белән берникадәр киметелә, ләкин тулысынча түгел.

Китапның беренче бүлегендә Пермь Урал алды төбәгенең (Пермское Предуралье) урта гасырлар чорындагы игенчелекне өйрәнү тарихы бәян ителә; төбәкнең урман табигый зонасына караган үсемлекләр дөньясы, климат һәм туфрак үзенчәлекләрен тасвирлауга басым ясала.

Беренче бүлекнең историографиягә багышланган өлешендә (§ 1) автор үзенең элгәреләренә – Ф.А. Теплоухов, М.В. Талицкий А.П. Смирнов,

В.А. Оборин, Р.Д. Голдина, А.М. Белавин, Н.Б. Крыласова, М.Г. Иванова, И.Ю. Пастушенко кебек археологлар, В.В. Туганаев, А.В. Туганаев, Т.П. Ефимова кебек палеботаникларның новаторлык рухында башкарылган хезмәтләренә объектив бәя бирә. Кулланылган чыганаклар турында белешмә (§ 2), тулы түгел, чөнки ул археологик артефактларны (казылмалардан табылганнарын, музей коллекцияләрендә саклана торганнарын, очраклы табылдыкларны) кыскача тасвирлау белән генә чикләнә, монографиядә киң кулланылган палеоботаника, этнография һәм фольклор материалларының тикшерелә торган теманы өйрәнүдәге потенциаль мөмкинлекләре бөтенләй ачылмаган. Кушымтада ломоватово-роданово чорына (VIII–XIV гасырлар) караган 79 археология һәйкәлләрендә табылган игенчелек кораллары турында белешмә һәм аларның таралыш ареалларын күрсәтүче карталар урнаштырылган.

«Пермь Урал алды төбәгенең урта гасырлар чоры халкында игенчелек системалары» («Системы земледелия средневекового населения Пермского Предуралья») дип аталган икенче бүлек, минем карашка, монографиянең соңгы, йомгаклау өлешендә урын алырга тиеш иде, чөнки мантыйк шулай куша: игенчелек системаларының, чәчү әйләнешенең үзенчәлекләрен, төп сыйфатларын бары тик археологик казылмаларда табылган җир эшкәртү коралларын, культуралы үсемлекләрнең һәм аларның иярченнәре – чүп үләннәренең составын өйрәнгәннән соң гына ачыкларга мөмкин. А.Н. Сарапулов игенчелек системасын башлыча этнография материалларын таянып аныкларга омтыла. Әмма этнография материаллары бит XVIII–XIX гасырларда гына туплана башлый, ә безне VII–VIII гасырлардан башланып XIV–XV гасырларга кадәр сузылган урта гасырлар дәвере кызыксындыра. Этнографиягә мөрәҗәгать итү археологиядә киң таралган, чөнки матди культура материалларында борынгырак дәверләр тарихы да сакланып калган. Инде VII гасыр башында ук, дип яза автор, Урал алды төбәкләрендә чәчүлек өчен урманнан арчылган ышна җирләре киң кулланылган («подсечно-огневая система»), әмма «археология материаллары бу система турында бернинди дә мәгълүмат бирми» (б. 33). Җирне әле китмәннәр белән генә эшкәрткәннәр дип фаразлыйлар («китмәнле игенчелек»). Шул ук вакытта «ломоватово халкына калдау, ягъни, кысыр җирләр системасы да (перелог) билгеле булган», дип саный А.Н. Сарапулов, әмма, әлеге дә баягы: «археология материалларында әлеге система чагылыш тапмый» (б. 36). Кыскасы, болайрак: тоташтан диярлек урманнар арасында яшәгән коми-пермякларның борынгы бабалары, игенчеләр, чәчү өчен җир кишәрлекләрен урманнарны кисеп-яндырып, агачлардан арчып әзерләгәннәр. Берничә ел үтүгә туфрак ярлылана, чүп үләннәре басып китә, шуңа күрә, ул җирләргә ял биргәннәр, берничә елга кысыр калдырганнар, һәм янәшәдәге урманны арчып, яңа чәчүлек җирләре булдырганнар.

М.В. Талицкийның этнографик күзәтүләргә нигезләнгән «бик тә ышанычлы» фикеренә кушылып, А.Н. Сарпапулов игенчелекнең I–II меңьеллыклар чигендә барлыкка килгән һәм җирле халык телендә «шутёма», «шутьма» дип аталган тагын бер «яңа» системасын тәкъдим итә. Бу бик тә үзенчәлекле калдау – төньяк яткыны («северный перелог»): агачлары кисеп-чабып чистартылган делянкаларда, агач төпләре арасына, биш ел буена арыш чәчкәннәр, аннан соң ул җирләрне калдырып киткәннәр. Игенчелекнең менә бу системасы коми-пермякларда XIX, хәтта XX гасыр башларына кадәр сакланып килгән (б. 37).

Хәзерге коми-пермяк җирләренә руслар күченеп утыра башлаганнан соң, ягъни XII–XV гасырларда, А.Н. Сарапулов фикеренә күрә, «игенчелектә тагын да нәтиҗәлерәк пар системасы киң тарала», әмма бу факт та археологик яктан расланмыйча калган (б. 37).

Әлеге бүлекнең моннан соңгы параграфында сүз коми-пермяклар игә торган бөртекле культураларның составы турында бара. Биредә археологик казу эшләре вакытында табылган һәм палеоботаниклар тарафыннан җентекләп анализланган ифрат та кызык материалларны китапның игенчелек системаларын өйрәнүгә багышланган өлешендә кулланырга иде. Игътибар итегез: бөртекле культуралар арасында бодай, арпа, солы, борай, борчак, тары, ә техник культуралар арасында җитен һәм киндер орлыклары очрый. Әлеге исемлектә уҗым культуралары һәм аларның «юлдашлары» саналган чүп үләннәре күренми. Бу факт исә игенчелектә, чәчү әйләнешендә пар системасы кулланылган дигән фаразга карашы килә. Әмма болай дип кырт кистереп әйтү дә урынсыз кебек тоела. А.Н. Сарапулов, бөртеклеләрнең кайбер төрләре коми халкына Идел болгарларыннан, кайберләре руслардан килеп кергән, дип фаразлый (б. 45) һәм ул, минемчә, дөреслеккә якын тора кебек.

Монографиянең әлеге бүлегендә Е.Ю. Лебедеваның культура катламыннан алынган туфракны флотация ысулы кулланып туплаган археоботаник анализ нәтиҗәләре киң урын алган (б. 41–45). Урта гасыр чоры җирле халыкларының игенчелек системаларын өйрәнүдә яшь галимебез палеоботаниклар белән хезмәттәшлеген тагын да ныгытсын иде дигән теләктә калабыз.

Рецензияләнә торган монографиянең өченче бүлеге «Пермь алды Урал буенда яшәгән урта гасырлар чоры халкының игенчелек формалары» («Формы земледелия средневекового населения Пермского Предуралья») дип атала. Исеме ничектер этнография хезмәтләрендәгечә яңгыраса да, ул башлыча археологик материалларга нигезләнеп язылган, Эчтәлегенә караганда әлеге бүлекне «Җир эшкәртү коралларының классификациясе. Игенчелек формалары мәсьәләсенә карата» («Классификация почвообрабатывающих орудий. К вопросу о формах земледелия») дип атау дөресрәк булыр иде.

Җирне кул хезмәте белән эшкәртү формаларына багышланган параграфта А.Н. Сарапулов, әле бронза гасырында ук, безнең эрага кадәр II меңьеллык урталарында барлыкка килгән китмәнле игенчелек VII–XV гасырларда да, «үзенең әһәмиятен югалтмаган, китмән туфрак эшкәртүнең төп коралы булып кала биргән», дип раслый» (б. 49). Әмма әлеге раслау аның X–XI гасырлардан башлап, сөрүле игенчелек (пашенное земледелие) чәчүлек җире эшкәртүнең төп формасына әйләнә, китмән исә урман туфрагын эшкәртүдә ярдәмчел эш коралы рәвешендә генә сакланып кала, дигән тезисына каршы килә (б. 50).

Өченче бүлекнең икенче параграфында А.Н. Сарапулов Пермь краенда сөрүле игенчелекнең кайчан һәм нинди юллар белән барлыкка килү мәсьәләсен чишәргә омтылыш ясый.

Үзе тупланган артефактларга түгел, ә шул проблема белән шөгыльләнгән элгәреләренең фикерләренә таянып, А.Н. Сарапулов сөрүле игенчелекгең төп билгесе итеп өйрәнелә торган районнарда табылган җир сөрү коралларының очлыкларын саный (б. 52). Мондый табылдыклар, дип күрсәтә ул, X – XI гасыр башы объектларында ук очрый, әмма XI гасырның икенче яртысы – XII гасыр истәлекләрендә генә киң таралыш ала. Китапның 54нче битендә автор чәчүлек өчен туфракны китмән белән түгел, сөрү юлы белән эшкәртүнең барлыкка килү вакытын төгәлрәк билгели – XI гасыр ахыры –XII гасыр, ягъни, Роданово археологик культурасының рождествено этабы. Нәкъ менә шушы чорда, дип ышандырырга тырыша укучыны А.Н. Сарапулов, сөрүле игенчелек җирле халык хуҗалыгының төп тармагына әверелә.

Әлеге бүлекнең өченче параграфында укучы игътибарына җир сөрү коралларының – сука төрәннәренең классификациясе тәкъдим ителә. Тупланган материаллар бай – 99 данә һәм алар җентекләп тикшерелгән. Игенчелек системасын өйрәнергә алынган галим өчен, әгәр дә алардан «суырып» алынган бай информацияне төрле фантазияләргә бирелмичә аңлап куллансаң, менә дигән археологик чыганак! Сөрү коралларының шул чыганакларны һәм дә Ю.А. Краснов хезмәтләрен, өстәмә рәвештә этнография материалларын нигез итеп алып тәкъдим ителгән автор реконструкциясе дә игътибарга лаек (б. 65–68).

Дүртенче бүлекнең атамасы, минем карашка, шулай ук уңышлы түгел – «Игенчелек кораллары. Ашлыкны эшкәртү һәм саклау». Игенчелек коралларына бит алдагы бүлектә тикшерелгән туфрак эшкәртү кораллары да керә, ә монда сүз бары тик өлгергән уңышны җыеп алу (урак, чалгы), эшкәртү (кул тегермәне ташлары, ашлык төйгечләр) җайланмалары һәм ашлык саклау корылмалары турында гына бара.

Өлгергән уңышны җыеп алу кораллары, ягъни, ураклар (7 данә) һәм чалгылар (17 данә) башлыча сынык хәлдә табыла, бөтен килеш сакланганнары сирәк. Шулай да автор,

уңышлы аналогияләр китереп, азсанлы чыганаклардан ярыйсы гына бай тарихи-этнографик информация алуга ирешкән.

Басулардан җыеп алынган ашлыкны эшкәртү коралы – кул тегермәне ташлары да фрагментлар рәвешендә генә сакланган (табл. 1, № 259–282).

Ротацион, ягъни, кул белән әйләндереп эшли торган «тегермәннәр», билгеле булганча, Урта Идел һәм Кама буе төбәкләрендә II меңьеллык урталарында килеп чыга. Бу яңалыкны монография авторы А.Н. Сарапулов IV–VII гасырларга караган Имәнкискә кабиләләре белән бәйли (б. 92). Каманың югары агымнары төбәкләренә, коми-пермяк җирләренә әлеге яңалык, ягъни, ротацион тегермәннәр, турыдан-туры түгел, ә имән кискәлеләрнең якын һәм ерак күршеләре Азелино, Мазунино, Неволино кабиләләре аша үтеп кергән дип расларга омтыла (б. 92). Миңа калса, коми-пермяк бабаларының игенчелек коралларына аналогияләр эзләгәндә монография авторына, беренче чиратта, Идел Болгары материалларына ныграк игътибар итәргә кирәк иде. Болгарлар бит ул төбәкләр белән сәүдә мөнәсәбәтләре генә урнаштырып калмаганнар, этномәдәни бәйләнешләр дә көчле булган.

Ашлык саклау урыннары турындагы әлегә кадәр тиешенчә өйрәнелмәгән мәсьәләләрне тикшергәндә дә А.Н. Сарапулов бай археологик материаллар җәлеп иткән.

Профессиональ күзлектән караганда, авторның урта гасырлар чорына караган Югары Кама-Урал алды авылларында археологлар ачкан ашлык-саклау базларын җентекләп тасвирлап бирүе тел-теш тидерерлек түгел. Әмма аның төп фикере, анализ нәтиҗәсе белән һич килешә алмыйм. Ул болай яза: «ломоватово чорында ашлыкны, кагыйдә буларак, чокырларга урнаштырылган балчык савытларда саклаганнар»; соңрак, басуларның уңышлылыгы күтәрелү сәбәпле, махсус чокырлар казып, саклау корылмалары ясаганнар, шунда ук ашлык киптерә торган учаклары да булган, имеш (б. 94, 97). Алай ук примитивлаштырырга кирәк түгел инде. Минемчә, ломоватово чорында да, соңрак та ашлыкны диаметры 20–30 сантиметрдан артмаган, кулдан әвәләп ясалган кечкенә балчык савытларда саклау мөмкин булмаган. Авторның үзе җыйган материалларыннан ук күренеп тора ич: агач (такта) ларларда саклаганнар; аларның хәтта вак бүрәнәләрдән корылган амбарлары да булган (рәс. 44–46).

Историографик характерда язылган соңгы, йогаклау бүлегендә коми-пермяклар яши торган Пермь якларына сөрүле игенчелекнең кайчан килеп чыкканлыгы турындагы мәсьәлә киңрәк планда тикшерелә (әлеге проблема китапның өченче бүлегендә кузгатылган иде). Биредә А.Н. Сарапулов, үзе туплаган чыганаклар комплексына таянып, коми-пермякларның урта гасырлар дәверендә яшәгән борынгы бабаларына җир эшкәртүнең прогрессив формалары кайсы яклардан үтеп керә һәм үзләштерелә, дигән сорауга да җавап табарга тырыша.

Бу хакта фәнни әдәбиятта ике төрле караш яшәп килә: сөрүле игенчелекнең чишмә башын йә Төньяк Русь җирләреннән, йә Идел Болгарыннан эзлиләр. Кайсысы дөреслеккә туры килә? Төньяк Русьтан түгелме? Шикле, чөнки А.Н. Сарапулов үзе үк бит рецензияләнә торган әлеге китабында, коми-пермяклар яшәгән төбәкләргә сөрүле игенчелектә кулланыла торган җир эшкәртү кораллары X гасыр ахырларында – XI гасыр башларында ук үтеп керә, дип тәкрарлады (б. 52), ә русларның бу якларга эпизодик рәвештә килеп төпләнә башлаулары исә бары тик XII гасырга гына карый, XIV гасырда бераз активлаша. Бәлки, турыдан-туры Идел Болгарыннандыр? Әмма А.Н. Сарапуловка әлеге фараз нишләптер ошамый. Куелган сорауга җавапны ул Көньяк Русьтан эзли. Нәкъ менә көньяктагы рус кенәзлекләрендә коми-пермякларда таралган сука төрәннәренең тулы аналогларын, тиңдәшләрен очратырга мөмкин, ди ул. Хәзерге Пермь якларына алар ничек килеп эләккәннәр соң? «Коми-пермякларның көньяк рус кенәзлекләре белән турыдан-туры бәйләнешләрен, хәтта алар эпизодик характерда булган очракта да, күз алдына да китереп булмый», – дип акыллы гына искәртеп үтә Алексей Николаевич (б. 119). Бердән-бер юл – Идел болгарлары аша. Алар бит сәүдәгә хирыс халык! «Башка товарлар белән бергә болгарлар аша коми-пермякларга сука төрәннәренең көньяк рус формалары да үтеп кергән», – дип йомгаклый яшь галимебез. Без, әлбәттә, мондый нәтиҗә белән һич тә килешә алмыйбыз. Чагыштырып карагыз болгарларның сука төрәннәрен Пермь якларында табылганнары белән – алар охшаш кына түгел, бер яклары белән дә бер-берсеннән аерылып тормыйлар. Мин хәтта болай уйлыйм: коми-пермяклар яшәгән төбәкләрдә болгарлар да яшәгән ич – археология материаллары шуны күрсәтә (Белавин, 2016, с. 72 и сл.) – шул болгарлардан калган табылдыкларга охшаган ул сука төрәннәре. А.Н. Сарапулов үзе үк, комилар – урман халкы, XX йөз башларына кадәр үз җирләрен кадимидән калган ысул белән эшкәртүләрен дәвам, дип язган иде ич (б. 37). Әлбәттә, алар арасына әкренләп болгарлардагы җир эшкәртү ысуллары да үтеп керә башлый. Монография авторы күрсәтеп үткәнчә, коми-пермяклар телендә лингвистлар өч дистәгә якын төрки (болгар-татар) сүзләре табалар, аларның бер өлеше нәкъ менә игенчелек лексикасына карый (б. 116).

Ничек кенә булмасын, А.Н. Сарапуловның монографиясен мин мөстәкыйль рәвештә башкарылган оригиналь хезмәт буларак югары бәялим. Автор укучыны уйларга һәм бәхәсләшергә мәҗбүр итә. Аның кыйммәте дә шунда. Дөреслеккә киләсе тикшеренүләр нәтиҗәсендә ирешербез.

## Файдаланылган әдәбият

*Белавин А.М.* Западное Приуралье в составе Булгарского государства // История татар Западного Приуралья Т. 1. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарските средневековые государства. Коллективная монография / науч. рук. Р.С. Хакимов. Казань: Ин-т истории АН РТ, 2016.

*Лебедева Е.Ю.* Культурные растения Ростиславля: археоботанические материалы из дьяковского городища и древнерусского города // Археология и естественнонаучные методы. Сб. ст. М.: Языки славянской культуры, 2005.

*Лебедева Е.Ю., Кубанкин Д.А.* Уникальные находки редких растений в золотоордынском городе Укек // КСИА. 2014. Вып. 236.

*Кирьянов А.В.* К вопросу о раннеболгарском земледелии // МИА. 1958. № 61.

*Краснов Ю.А.* Древнейшие упряжные пахотные орудия. М.: Наука, 1975.

*Краснов Ю.А.* Опыт построения классификации железных наконечников пахотных орудий (по археологическим материалам Восточной Европы) // СА. 1978. № 4.

*Краснов Ю.А*. Средневековые плуги Восточной Европы // СА. 1979. № 4.

*Краснов Ю.А.* Древние и средневековые рала Восточной Европы // СА. 1982. № № 3.

*Левашова В.П.* Сельское хозяйство // Очерки по истории русской деревни. Тр. ГИМ. М., 1956. Вып. 32.

*Туганаев В.В.* Материалы по истории культурных и сорных растений Среднего Поволжья // Ботанический журнал. 1972. № 5.

*Туганаев В.В.* К истории распространения паровой системы земледелия в Среднем Поволжье // Агрофитоцинологическое исследование паров как предшественников озимой ржи. Казань, 1975.

*Туганаев В.В.* Состав и характеристика культурных и сорных растений билярских полей // Исследования Великого города / Отв. ред. В.В. Седов. М.: Наука, 1976.

*Туганаев В.В., Туганаев А.В.* Природа Волжской Булгарии по материалам письменных и археологических источников // Историко-археологические исследования Поволжья и Урала. Материалы III Халиковских чтений / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: РИЦ «Школа», 2006.

*Ж. «Поволжская археология».*
*2015. № 3. С. 249–255.*
*(Кайбер өстәмәләр белән ирекле тәрҗемә).*




## «ШАЙТАН КАЛАСЫ» – АК МӘЧЕТ УЛ!

(Язучы Мөсәгыйт Хәбибуллинның яңа романы турында)

Нәкъ шулай: урыслар тарафыннан Явыз Иван заманнарыннан бирле «Шайтан каласы» дип йөртелә торган таш бина хәрабәләрен мөселман кардәшләребез бүгенгә кадәр Ак мәчет дип йөртәләр. Алай гына да түгел, шул мәчеттән сакланып калган манарага килеп намаз укыйлар, борынгы бабаларыбыз, изгеләребез рухына багышлап дога кылалар, күңелләрен сафландырып китәләр.

Артык зур булмаган Болгар шәһәрчеге бүгенге Алабуганың көньяк-көнбатыш читендә, Тойма елгасының Камага кушылган җирендә, 52–60 метр биеклектәге тау башында урнашкан. Табигать тарафыннан әйбәт кенә ныгытылган булуга карамастан, ясалма ныгытмалары да бар: балчыктан өеп ясалган өч рәт үрләр һәм тирән чокырлар белән уратып алынган. Шәһәрлекнең гомуми мәйданы өч гектар чамасы. Кызганыч ки, борынгы калабыз начар сакланган: 1950–1960 елларда биредә таш чыгара торган карьер булган. Ныгытмаларның беренче һәм икенче рәтләре, культура катламының күп өлеше бөтенләй диярлек җимерелгән.

Болгар чорыннан калган атаклы таш манара – урыслар бары тик шул манараны гына «Шайтан каласы» дип атаганнар – шәһәрлекнең көнчыгыш өлешендә, Каманың текә ярында урнашкан. Нәкъ яр читендә ул, убылып төшеп китү куркынычы бар.

Манара беренче мәртәбә билгесез (Аноним) урыс язучысы тарафыннан 1564–1565 елларда иҗат ителгән «Казан тарихы» әсәрендә искә алына. Урыс риваятьләрендә телгә алынганча, ул заманнарда бушап калган борынгы калачыкта шайтаннар, җеннәр яшәгән, имеш. Әле болгар чорында ук биредә мәҗүсиләрнең (мөселманнар дип аңларга кирәк, чөнки урыслар нәсара/христиан динен тотмаган халыкны мәҗүсиләр

дип атаганнар) табыну урыны һәм мәчете булган, ди «Казан тарихы» авторы. Бирегә бик күп кешеләр килеп йөргән: җирле халык та, чирмешләр дә, хәтта христиан динендәгеләр дә. Алар «җен-шайтанга» корбан китергәннәр, гыйбадәт кылганнар. «Җен» мондый кешеләрне чирләреннән терелткән, ә аны күрмәмешкә салышып, корбан бирмичә генә үтеп китүчеләргә зыян салган, елгада батырып үтергән, имеш.

«Шайтан каласы»н һәм аның тирә юнендәге таш бина хәрабәләрен беренчеләрдән булып 1769 елда атаклы галим Н.П. Рычков тикшерә. Ул вакытта әле бу бинаның өч манарасы сакланып калган була. Бу хәрабәләрне Рычков болгарлар чорыннан ук калган мәчетнеке булырга тиеш дип бәяли.

1825 елда һәм бераз соңрак шәһәрлектә Казан университеты профессоры Ф.И. Эрдман һәм Н.Ф. Кафтанников булып китәләр. Бу вакытта инде ныгытмалар эчендәге таш корылманың (мәчетнең) бер генә манарасы калкып торган, калган икесе җимерелеп беткән була. Ике катлы бу манараның рәсемен һәм борынгы шәһәрлекнең планын Ф.И. Эрдман үзенең мәкаләсендә бастырып чыгара.

1855 елда киләчәктә дөньякүләм танылачак яшь рәссам Иван Шишкин, җирле тарихчы К.И. Невоструев үтенече буенча, шәһәрлекнең планын һәм анда әле күрергә мөмкин булган таш корылмаларның хәрабәләрен рәсемгә төшерә.

Бу борынгы корылмалар рәссамның әтисен – Алабуга тарихында тирән эз калдырган шәһәр башлыгы И.В. Шишкинны – күптән кызыксындырып килгән. 1867 елда аның тырышлыгы белән борынгы таш бинаның җимерелгән ике катлы манарасы, төзекләндерелеп, яңадан элеккеге хәленә китерелә. Шул рәвешендә әлеге манара – монгол яуларына чаклы яшәгән болгар бабаларыбызның бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган бердәнбер архитектура һәйкәле, дип әйтергә хаккыбыз бар. Шул ук вакытта ул бүгенге Алабуга шәһәренең үзенчәлекле символы булып, еракლардан ук күренеп тора.

И.В. Шишкин 1871 елда Алабуга тарихына багышланган кечкенә генә китап бастырып чыгара. Элеккеге авторлар тарафыннан әйтелгән фикерләрне тәнкыйтьсез генә кабул итеп, автор тулы ышаныч белән, бик борынгы чорларда хәзерге Алабуга җирлегендә скифлар шәһәре Гелон, ә болгарлар чорында Ибраһим (Бряхимов) каласы урнашкан була, дип яза.

Тарихчы К.И. Невоструев та үзенең хезмәтендә урыс елъязмалары буенча мәгълүм Бряхимов шәһәрен «Шайтан каласы» белән тәңгәлләштерә: «Алабуга шәһәре элек Идел Болгарстаны карамагында булып, соңрак Казан ханлыгына кергән, ә аның барлыкка килүе тагын да борынгырак чорларга карый. Бернинда шикләнүләрсез әйтергә мөмкин, биредә элек Андрей Боголюбский гаскәрләре тарафыннан таланган һәм җимертелгән Бряхимов шәһәре торган».

Алабуга-Бряхимов тәңгәллеге соңгырак чорда эшләгән тарихчыларның тәнкыйть утына дучар ителә.

Профессорлар С.М. Шпилевский һәм В.Ф. Смолин хезмәтләрендә XI йөздән башлап монгол яуларына кадәр Идел буена урнашкан Болгар шәһәренең Бряхимов исемен йөрткән булуы турында ышынычлы дәлилләр китерелә. Бу фикер тарихчы-галимнәр арасында бүген дә киң таралган.

1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр Алабуга шәһәрлегендә археологик казу эшләре бер генә тапкыр була. 1888 елда биредә күренекле рус археологы А.А. Спицын кызыклы тикшеренүләр үткәрә, бер генә манарасы сакланып калган таш корылма хәрабәләрен, ягъни «Шайтан каласын» нигезенә кадәр казып чыгара. Борынгы бинаның нигезе квадрат формасында булып, почмакларына түгәрәк манаралар (башнялар) утыртып куелган була. А.А. Спицын раславынча, әлеге бина, XIII гасырдан элегрәк төзелгән һәм ул йә кәрван-сарайның бер өлеше, йә берәр атаклы мөселман изгесенең төрбәсе булган. Хәтта ул, XIV йөз ахырында шушы төрбәне карарга мәшһүр Аксак Тимер килмәдеме икән, дип фаразлый. Бу мәсьәләдә ул Хисаметдин Мөслиминең чынбарлыктан ерак торган мәгълүматларыана таяна.

Узган гасыр урталарында Алабуга шәһәрлеге болгар фәненә (булгароведение) нигез салучы атаклы археолог, Мәскәү университеты профессоры Алексей Петрович Смирновның игътибарын җәлеп итә. 1951 елда дөнья кргән «Идел болгарлары» исемле фундаменталь хезмәтендә ул: «Шайтан каласы» әле болгарларга кадәр үк барлыкка килгән һәм бик озак гомер яшәгән», – дип яза. Икенче бер хезмәтендә исә А.П. Смирнов: «Әлеге кала, борынгы ыруглык җәмгыяте чорында ук, моннан якынча 2600–2700 еллар элек хәрби ныгытма, ягъни крепость буларак төзелгән» – дигән фикер әйтә. Галимнең раславынча, X–XI гасырларда калага болгарлар киләләр һәм ак таштан биек манаралы яңа корылма – цитадель торгызып куялар. Болгар иленең төньяк чигендәге иң мөһим терәк пункты була ул. Алабуга каласыннан болгарлар күрше удмурт (ар) кабиләләренә яу чабып торганнар, аларны феодаль бәйлелектә тотканнар, салым түләткәннәр.

1981 елда Алабуга каласында СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты археологы Мурат Кавиев уңышлы гына казу эшләре үткәрә. Казылмалардан чыккан табылдыкларга нигезләнеп ул: «Калада болгарлар даими яшәмәгәннәр, сугыш куркынычы килеп туганда гына качу-саклану урыны итеп файдаланганнар», – дигән мөһим нәтиҗәгә килә.

«Шайтан каласы» территориясендә киң казу эшләре 1990 нчы елларда профессор Альфред Хәсән улы Халиков тарафыннан үткәрелә. Заманында И.В. Шишкин торгызган манара тирәсендә казып, ул борынгы таш бина хәрабәләрен яңадан ача. Аның нигезе яхшы гына сакланган була: һәр як стенасының озынлыгы 21 метр, почмакларда диаметры 6 метрга җитә торган түгәрәк манаралар урнашкан. Бүгенге көнгә кадәр сакланган манараның гына диаметры тагын

да зуррак – 10 метр чамасы. Күрәсең, ул башкаларга караганда биегрәк тә булгандыр. Бинаның тагын бер кызыклы һәм әлегә кадәр аңлашлып җитмәгән үзенчәлеге бар: өч якның диварлары уртасында язымтүгәрәк, ә көньяк-көнбатыш якта өчпочмаклы манаралар күтәртелгән. Манаралар арасы өч-дүрт метрдан артмый. Нигә кирәк булган алар? Игътибарны тагын бер нәрсә җәлеп итә: өчпочмаклы манара урнашкан ягы белән бина көньяк-көнбатышка – нәкъ кыйблага карап торган. Шуңа күрә А.Х. Халиков аны мәчет дип атаган да инде. Бу фикергә архитекторлар да кушыла. Бер үк вакытта элеге мәчет кечкенә крепость ролен дә үтәгән булырга тиеш, дип уйлыйлар. Төзелү вакыты XII гасырның икенче яртысы дип фаразлана, әмма борынгырак та булырга мөмкин.

Калатауда өстәмә казу эшләре Алабуга дәүләт педагогика институты доценты Альберт Нигамаев тарафыннан үткәрелде. Кала ныгытмаларыннан 130 метр чамасы көньяк-көнчыгышка китеп, культура катламының җимерелгән участокларын чистартканда археологлар хатын-кыз каберлегенә юлыгалар. Кызганычка каршы ул таланган була инде, күрәсең, бай кабер булгандыр. Сакланып калган әйберләр арасында көмештән эшләнгән чигә алкасы, бакырдан эшләнгән шалтыравык асма бизәк чылбырлары, тимер сөнге очы бар иде. Болар – X–XI гасырларга хас табылдыклар. Бу каберлектә X гасыр ахырында ерак Урал яклары ннан Кама елгасы буйлап күчеп килгән угыр (угор) телле халыкның бер вәкиле күмелгән. Сүз уңаеннан әйтергә кирәктер: Алабуга шәһәрлегендә тупланган табылдыкларның яртысыннан артыгырагы венгр-мадьяр-маҗарларның борынгы бабаларына карый.

Борынгы венгрлар башка урынга күчеп киткәч, бирегә болгарлар килә. Бу вакытта Болгар дәүләте күзгә күренеп ныгый, үсә, чикләрен төньякка һәм дә көнчыгышка таба киңәйтә, яңа җирләр үзләштерә, күрше халыклар белән икътисади-сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга сала. Болгарлар Алабуга каласында төпләнеп калалар. Бар яктан да уңайлы урын була ул: табигать тарафыннан яхшы ныгытылган, сәүдә итү өчен янәшәдә генә су юлы, бай көтүлекләр, урманнар...

Кайда яшәгән соң борынгы Алабуга халкы? Бу сорауга да җавап табылды: хәзерге шәһәрнең иске үзәк өлешендә. Ни генә булмасын, «Шайтан каласы», һичшиксез, безнең болгар бабаларыбыз мирасы. Беренче чиратта ул, күп манаралы таш бина, хәрби максатларда төзелеп, махсус күзәтү пункты вазифасын үтәгән. Шул ук вакытта Кама кичүе янында ялга, хәл җыярга тукталган сәүдәгәрләр өчен мәчет булып та хезмәт иткән.

... Еллар, гасырлар уза. Болгар-татар җирләре Явыз Иван тарафыннан яулап алына. Ни гаҗәп, хәрабәгә әверелеп баручы мәчетне бабаларыбыз барыбер ялгыз калдырмый. Ел саен килеп-китеп йөриләр, хәтта ерак җирләрдән дә. Дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичеп, тәүге диненә, Тәңресенә

табынып яшәп ятучы сәеррәк изге зат та булгандыр, бәлки, ярымҗимерек бу мәчеттә. Әкренләп ул тирә-юньгә шом таратып утыручы серле бер бинага әверелеп китә. «Шайтан каласы» дип юкка гына атамаганнардыр инде аны. Баксаң, кайчандыр Ак мәчет булган икән ул!

Серле бина корылмалары хәрабә хәлендә булса да, халык өчен ул әле дә исән, татарын, удмуртын, урысын үзенә тартып тора, чөнки борынгылык һәр халык өчен дә мирас ул, мәңгелек хатирә. Ак мәчетне баскынчы урыслар үз тарихларына «Шайтан каласы» дип кертеп җибәрсәләр дә, анда шайтаннар яшәмәгән әлбәттә, ә менә ерак бабаларыбызның рухы әле булса яши, әле булса саклана. Тарихи әсәрләр язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин «Шайтан каласы романында болгар чорының күпсанлы сәхифәләреннән кайберләрен генә тасвирлаган. Әйтергә кирәк, шәп тасвирлаган, ышанычлы итеп! Бу роман, һичшиксез, үзенең яңа укучыларын табар.

*Мөсәгыйт Хәбибуллин. Шайтан каласы. Тарихи роман.*
*Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2006. Б. 283–286.*




## ВАХИТ ИМАМОВ ИҖАТЫНДА ТАТАР ТАРИХЫ

Элегрәк чыккан бер мәкаләмдә мин: «Тарихи романнарны бик яратып һәм кызыксынып укыйм», – дип язганмын икән. Алай ук түгел. Әйе, барысын да диярлек укып барам, әмма... юк, яратып укыйм дип әйтү дөрес үк булмас. Моның сәбәпләре төрле. Теге яки бу язучы тарихи вакыйгаларны, шәхесләрне фәнни яктан ни дәрәҗәдә дөрес итеп тасвирлаган һәм, иң мөһиме, әсәр сәнгатьчә эшләнеше ягыннан ни дәрәҗәдә камил вә мөкәммәл? – тарихчы-галим һәм гади укучы буларак, иң әүвәл мин шул нәрсәләргә игътибар итәм. Менә шул «нәрсәләр» төрле язучыда төрлечә, һәм ул, табигый ки, шулай булырга тиеш тә. Тарихны мин үземчә күзаллыйм, ә язучылар исә әнә шул без күнеккән стереотип карашларны җиңел генә җимерәләр дә куялар. Кайвакыт күңелдә ризасызлык туа. Югары сәнгатьчәнлек күзлегеннән караганда, миңа калса, «тарихи» дип аталмаган жанрларда иҗат итүче язучыларның әсәрләре күпкә отышлырак. Ә мин андый әсәрләрне дә барыбер тарихчы-галим күзлегеннән карап укыйм һәм ихлас ләззәтләнү хисләре кичерәм. Тарих дәреслекләрен укып кына, әби-бабаларыбыз сөйләгәнннәрдән чыгып кына халкыбыз тарихын бөтен тулылыгы, нечкәлекләре белән аңлап булмый. Халкыбыз тарихы ул – Галимҗан Ибраһимов, Мәхмүт Галәү, Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин, Айдар Хәлим һәм башка бик күп әдипләребез иҗатында! Талантлы шагыйрьләребезнең шигырь-поэмаларында гына түгел, хәтта лирикада да тарих чагыла! Мөхәммәт Мирзаның: «Безнең буын кешеләре өчен әдәбият хак тарихыбызның бердәнбер дөрес чыганагы буларак кабул ителә,» – дигән сүзләрендә

(«Мәйдан», 2011, № 1, 40 б.) тирән мәгънә ята.

Тарихи романнар, әйе, языла тора. Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Җәмит Рәхимов, Флүс Латыйфи, Рабит Батулла, Солтан Шәмси, Фәүзия Бәйрәмова, Факил Сафин, Ркаил Зәйдулла, Равил Вәлинең төрле елларда дөнья күргән әсәрләрен укучылар яратып укый. Мин моңа бик шатланам, чөнки без, язучылар һәм тарихчы-галимнәр, бер үк эш – изге эш! – эшлибез. Аның асылы – хәзерге заман татар укучысында, беренче чиратта, яшь буында, халкыбызның шанлы үткәне һәм бүгенге уңышлары мисалында горурлык хисләре тәрбияләү. Татар угылы татармын! Менә шул горурлык хисе булмаса бездә, бөтен галәмгә һәм гавәмгә глобальләшеп бетү куркынычы янаган бер заманда татарның милләт булып сакланып калу мөмкинчелеге югалачак. Яшь буынга милли тәрбия бирү өлкәсендә безгә әле, бигрәк тә әдәбият һәм сәнгать әһелләренә, бик күп тырышырга, максатчан һәм җиң сызганып эшләргә кирәк. Кызганыч, бу эштән, милли мәгарифне үстерү турында күп сөйләсәләр дә, мәктәпне һәм югары уку йортларын аңлы рәвештә һаман читләштерә баралар.

Шушындый озын керештән соң 1980 нче еллар башында кыю рәвештә әдәбият дөньясына килеп кергән талантлы язучыбыз Вахит Имамов иҗатына күчик әле. Кызганыч, мин аның үзе, гаиләсе турында бик аз беләм. Чыгышы белән Актаныш районының Иске Байсар авылыннан ул. 1954 елның 18 мартында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң ике ел чамасы Казан моторлар төзү заводында эшләп ала һәм 1973 елда университетның журналистика бүлегенә укырга керә. Тагын ике елдан укуын читтән торып, бер үк вакытта Балык Бистәсе районы газетасында эшләп дәвам итәргә карар кыла. Армиядә хезмәт итеп кайта. 1982 елдан Вахит Имамов Чаллы шәһәрендә. Башта ул урта мәктәптә тарих фәне укыта, аннан соң КамАЗның пресс-рам заводында мастер, участок башлыгы, өлкән диспетчер булып эшли. 1990 елда «КамАЗ» типографиясе нигезендә газета-китап нәшрияты оештырып, шунда баш мөхәррир вазыйфасын башкара. 1997 елдан бирле Вахит Имамов Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеген җитәкли, 2005 елдан – «Мәйдан» журналының баш мөхәррире. Менә шушы кыска гына рәсми белешмә язучы иҗатын характерлый торган «киң колачлы» дигән билгеләмәнең серен ача да сала, минемчә. Тормыш юлы урта мәктәп тәмамлап, университетта белем алу һәм газета-журнал редакцияләрендә эшләү чорларын гына «кочып алган» язучыдан бүгенге заман тормышын чагылдырган күләмле эпик әсәрләр таләп итү урынсыз. Вахит Имамов исә тормышны тирәнтен белә, яшәү дәверендә, гади эшче һәм мәктәп укытучысы рәвешендә дә, журналист һәм язучы буларак та, төрле социаль катлау кешеләре арасында кайнаган, татар дөньясын бөтен катлаулылыгы, каршылыклары белән аңлый һәм боларның барсын да, сәнгатьчә эшкәртеп, үзенең иҗатында чагылдырырга тырыша.

Алып карагыз аның Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Ир канаты» (1988), «Нәзер» (1991) исемле китапларында туплап бирелгән элгәреге повесть-хикәяләрен, «Аргамак» журналының беренче номерын ачып җибәргән «Кәнәфи» повестын. Таныш вакыйгалар, таныш геройлар – барысы да тормышның үзеннән алынган, берсе дә язучы фантазиясе түгел. Шуңадыр күрәсең, укучы аларны яратып кабул итте, кулдан кулга йөртеп укыды. Язучының әхлак проблемаларын күтәргән «Нәзер» повесте һәм «Өмет» хикәясе исә Татарстан телестудиясе төшергән һәм күп тапкырлар телевизор экраннарыннан күрсәтелгән кыска метражлы нәфис фильмнарның сценарийлары өчен нигез булып хезмәт иттеләр.

2001 елда Чаллыда дөнья күргән «Могикан» исемле китап язучының популярлыгын тагын да ныгытты, ул моңа кадәр беркем дә кул тидерергә җөрьәт итмәгән кискен мәсьәләләрне күтәрергә сәләтле кыю автор буларак танылды. Китапка исем биргән «Могикан» повесте күңелдә бигрәк тә нык уелып калган. Күрәсең, эчтәлеге үземнең туган якларга бәйле (безнең авыл Чаллыдан 20 чакрымда гына), бер генә кешене дә тыныч калдыра алмый торган вакыйгалар турында булгангадыр. Әсәрнең үзәгенә узган гасырның җитмешенче елларында гигант «КамАЗ» корпусларын торгызганда түрәләрнең гафу ителмәслек саксызлыгы, гади халыкны санга сукмаулары аркасында искиткеч гүзәл табигатьнең, дистәләгән татар авылларның юкка чыга баруы, шул вәхшилеккә каршы тигезсез көрәш проблемасы куелган иде. Кызганыч, бу проблема безнең көннәрдә дә актуальлеген югалтмый.

Вахит Имамовның әлеге китабына урнаштырылган тагын бер әсәр укучының игътибарын җәлеп итә. Ул – «Исемең ничек, татар авылы?» дип аталган тарихи-топонимик очерк. Автор үзенең «Татар энциклопедик сүзлеген» укыгач туган фикерләре белән уртаклаша. Исемнәре бозылып, урыслашып беткән татар авыллары, елга-күл атамалары турында күңелсез статистика китерә. Әйе, утырып уйлар уйларлык, ди автор, урыска ничек ярарга белмәгән татар түрәләре үз авылларының тарихи исемнәрен кайсы якка гына боргалап бетермәгән дә, ничек кенә итеп үзгәртмәгән. Исемнәр дә татарлыгын югалта, урыслаша бара икән бит.

Вахит Имамовның заман таләпләренә сизгер, халык язмышына битараф булмаган, үткәннәрдән сабак алырга өндәүче тынгысыз автор булуын аның 1991 елда рус һәм татар телләрендә басылып чыккан «Әфган «кызалаклары» (Афганские «тюльпаны») дигән очерклар җыентыгы да ачык раслый. Биредә сүз Чаллы төбәгеннән китеп, Әфганстан җирендә ятып калган фаҗигале сугыш корбаннары турында бара. Интернациональ бурычыбызны үтибез дип башланган «гадел» сугышның киләчәктә сабак алырлык аяныч нәтиҗәләре турында. Заманы өчен бик тә кирәк, укыла торган китап булып чыкты ул. Язучы туплап чыгарган материаллар республикабызның күп кенә мәктә-

пләрендә, мәдәният йортларында, китапханәләрдә, төбәк музейларында Әфган корбаннарына һәм сугышчыларына багышланган экспозицияләр ачарга этәргеч бирделәр. Шундый экспозицияләрнең берсен мин С. Рәфыйков исемендәге Зәй үзәк китапханәсе фойесында күрдем. Китапханә хезмәткәрләре сөйләвенчә, аның идеясе Вахит Имамов җыентыгын укыганнан соң туган.

Татар авылын күмәкләштерү тарихы белән бәйле вакыйгаларны рәсми фәндә кабул ителгәнчә түгел, бөтенләй яңача, халкыбыз язмышында олы фаҗига буларак шәрехләгән «Тозлы яра» (Казан, 2004), егерменче йөз башларында туган якларын калдырып, чарасызлыктан Япониягә килеп төпләнгән татарлар тормышын реаль картиналарда ышанырлык итеп күрсәткән «Япун татары» (Чаллы, 2004) романнары да язучының уңышлы әсәрләреннән саналырга хаклы.

Табигый ки, югарыда санап үтелгән әсәрләр тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтә калмады. Алар бит гадәттә әдәбият дөньясында инде күптән үз юлын тапкан танылган язучыларның, яисә яшь авторларның талантлы әсәрләре турында язарга яраталар. Йомшаграк дип табылган әсәрләрне күрмәмешкәрәк салышалар. Әдәбият бусагасына яңарак кына аяк баскан Вахит Имамов иҗаты турында беренчеләрдән булып Гариф Ахуновның сүз башлавы үзе үк күп нәрсәләр турында сөйли. «Әдәбиятыбызга саллы прозаик килә!», – дип язды ул, куанып, үзенең бер мәкаләсендә («Мәйдан», 2002, № 6, 168 б.). Аннан соң матбугатта берберартлы Мөдәррис Вәлиев, Барлас Камалов, Марсель Галиев, Мөсәгыйт Хәбибуллин кебек олпат язучыларыбызның, әдәбият белгечләренең бәяләмәләре басылып чыкты. Вахит Имамовның күпкырлы, үзенчәлекле талант икәнлегенә басым ясап, аның тарихи әсәрләр язарга да сәләтле автор икәнлеген искәртеп үттеләр. Һәм ялгышмадылар.

Халкыбызның борынгы һәм урта гасырлар тарихы белән шөгыльләнүче галим буларак, аңлашыла ки, мине беренче нәүбәттә Вахит Имамовның тарихи романнары, тарихи-документаль әсәрләре, публицистикасы кызыксындыра. Миңа аның бигрәк тә үзе җитәкләгән «Мәйдан» журналында – һәр санында диярлек! – басылып килә торган тарихи-публицистик язмалары ошый. Чөнки Вахит әфәндендең теге яки бу төбәк тарихына, шул төбәкнең тарихи шәхесләренә багышланган язмалары өр-яңа, әле фәндә билгеле дә булмаган кызыклы мәгълүматлар белән тулган була. Ул чын тарихчы һәм күбрәк нәкъ менә тарихи әсәрләре белән әдәбиятта үз урынын яулады да инде.

Язучының иҗатын мин даими рәвештә 1993 елдан бирле күзәтеп барам. Шул елны аның атаклы тарихчыбыз Равил Әмирхан белән бергә язылган «Татарларның Ватан сугышы: XVI–XVIII гасырларда милли-азатлык яулары турында тарихи очерклар» китабы басылып чыкты. Йөз җитмеш меңлек тираж белән! 80 битлек китапчык, билләһи дип әйтәм, чын сенсация булды без-

нең өчен. Беренчедән, күпләрне аның «сәер» исеме шаккаттырды, моңарчы әле бер генә тарихчы да татарларның урыс хакимиятенә каршы алып барган милли көрәшен, восстаниеләрен «Ватан сугышы» дип атарга, ягъни, дөресен язарга батырчылык итмәгән иде; икенчедән, халкыбыз тарих битләреннән төшеп кала язган каһарман бабаларыбызның кылган гамәлләре, язмышлары белән танышырга мөмкинлек алды. Баксаң, алар гасырлар буена үзләренең борынгы дәүләтчелеген торгызу өчен армый-талмый көрәшкәннәр, кан түккәннәр икән. Тиешле органнар тарафыннан ничәмә-ничә еллар буена махсус яшерелеп яткан әлеге фактлар, ниһаять, халыкка барып иреште. Китап кулдан-кулга йөреп, тиз арада таралып та бетте. Республикабыз суверенитетын яклап күтәрелгән милли-азатлык хәрәкәтенең тагын да җанланып китүендә, миңа калса, әлеге китапның роле зур булды.

Бер елдан соң Вахит Имамовның «Яшерелгән тарих» исемле тагын бер документаль әсәре дөнья күрде. Рус телендә һәм җәмгысе 400 мең тираж белән! Дөрес тарихка сусаган халык, бигрәк тә татар милли хәрәкәтендә катнашучы яшьләр, язучыга бик рәхмәтле иде. Тиз арада бу әсәрне мәктәп укытучылары тарих дәресләрендә өстәмә материал рәвешендә куллана башладылар. Безгә аз таныш булган фактлар «Татарстан тарихыннан хикәяләр» дип аталган һәм ул елларда бик популяр мәктәп дәреслегенә дә кертеп җибәрелде.

Вахит Имамовны коеп куйган язучы сыйфатында гына түгел, тарихчы буларак та таный башладылар. Аны якыннанрак белүче каләмдәшләре һич тә гаҗәпләнмәде моңа. Эшли торган заман килде, совет чорындагы кебек яңа фикерләргә киртә куючылар юк хәзер. Татар тарихында таплар күп – билгеле факт. Галимнәребез ул тапларны бетерергә ашкынып тормыйлар. Нишлисең, үзеңә тырышып карарга туры киләчәк. Һәм Вахит әнә шул «яшерелгән» тарихны – татарларның үз дәүләтчелеген торгызуга юнәлдерелгән милли-азатлык көрәшенә караган тарихны! – архивлардан эзли башлый. Мәскәү, Казан, Уфа, Оренбург, Уральск һәм башка шәһәрләрнең архивларында казынып, моңа кадәр галимнәр кулы тимәгән йөзләгән, меңләгән документлар таба. Шул чорга караган фәнни әдәбиятны җентекләп өйрәнә. Җитмәсә әле халык арасында таралган легенда-риваятьләрне җыеп бара, тел гыйлеменең ономастика (топонимика) һәм этимология дигән тармаклары белән тирән кызыксына. Әйе, Вахит Имамов беренчел чыганаклар белән эш итәргә ярата.

Күп еллык хезмәтнең нәтиҗәсе язучының Пугачев явы һәм анда катнашкан батыр бабаларыбыз язмышына багышланган «Сәет батыр» (Чаллы: «КамАЗ», 1994. 512 б.) һәм «Татар яугирләре» (Казан: Мәгариф, 2003. 355 б.) исемле күләмле әсәрләрендә бәян ителде. Беренчесенең тиражы 90 мең данә! Ул китапны

кулга алып уку башлагач туган тәэсирләремне, шатлану катыш шаккатуларымны әле һаман да хәтерлим. Мин генә шулай һушым китеп кабул итмәгәнмендер дип уйлыйм «Сәет батыр»ны. Никадәр яңалык алып килде ул укучыга?! Аксакал тарихчыбыз Сәлам Алишев китабын[1] да шулай сөенеп каршы алган идек заманында. «Каһарман бабайлар» (1976) китабында ул безгә Бәхтияр Канкаев, Мәсәгут Гомәрев, Каранай Моратов кебек герой-шәхесләребезне ачты. Әмма барыбер соңгы елларга кадәр Пугачев яуларын без элеккечә, изелгән урыс крестьяннарының алпавытларга каршы сугышы рәвешендә генә күз алдына китерә идек. Алишевтан соң бу тема белән кызыксынучы булмады, XVIII йөз һәм аннан элгәрерәк чор тарихын өйрәнүчеләр аз, чөнки күбесенең тешләре үтми. Ә менә Вахит Имамов булдырды, югыйсә, фәнни дәрәҗәсе дә юк. Пугачев отрядларында сугышучыларның яртысыннан артыграгы татарлар булган! Башкортларның Салават Юлае дәрәҗәсендәге татар каһарманнары, полковниклар, бригадирлар да берәү генә түгел, дистәләгән. Вахит моны документлар белән раслады.

Мин беләм, урта мәктәпнең тарих укытучылары бу китапларны дәреслеккә өстәмә уку ярдәмлеге рәвешендә дә, сыйныфтан тыш чаралар үткәргәндә дә бик теләп кулланалар. Матур һәм аңлаешлы тел белән язылганнар алар. Вахит Имамов әсәрләрен югары уку йорты студентлары – булачак тарихчылар да өйрәнәләр. Елмаеп-көлеп дигәндәй, үземнең мөгаллимлек тормышымнан бер кызыклы фактны искә төшереп үтим әле: өч-дүрт ел элек чыгарылыш курс студентының (дөрес, ул читтән торып белем алучы укытучы ханым иде) миңа рецензияләргә биргән диплом эшендә ярылып яткан плагиатлык галәмәтләре күреп, «дөрес» билге куя алмыйча авыр хәлдә калган идем. Бер бүлеген «Сәет батыр» китабындагы «Татарлар Пугачев явында» исемле очерктан күчереп алынган мәгълүматлар белән тутырган да, авторын күрсәтмичә генә, фикерләрен үзенеке итеп тәкъдим иткән. Болай ярамаганлыгын аңлаттым, әлбәттә, әмма язучы өчен, ни генә димә, күңелле факт – файдаланалар ич хезмәтләреннән!

Ярый, хуш, хәзер инде Вахит Имамовның минем карашка иң уңышлы әсәрләреннән саналган «Казан дастаны» (2005) һәм «Утлы дала» (2001, беренче китап; 2012, беренче һәм икенче китаплар) тарихи романнарына күз салыйк. Алар язучының элгәреге әсәрләреннән нык аерылып торалар. Сурәтләнгән вакыйгалар 10–13 йөзләргә, борынгы бабаларыбызның монгол яуларына кадәрге чорларына карый. «Утлы дала»ның элегрәк чыккан беренче китабына тотынырга куркып тордым. Әлбәттә инде, әсәрне тәнкыйтьче сыйфатында анализларга да атлыгым тормадым. Эш шунда ки, миңа, археолог булarак, гомерем буе халкыбызның урта

[1] Аның 1973 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Татары Среднего Поволжья в пугаческом восстании» исемле китабын күз алдында тотам.

гасырларга караган бик тә катлаулы чорларын өйрәнергә туры килде. Болгар фәне дөньясында бүгенге көндә билгеле булган барлык язма чыганакларны беләм. Алай гына түгел, Вахит Имамов романнарында сурәтләнгән төп вакыйгаларның урыннарын – Биләр, Сувар, Җүкәтау, Алабуга, Казан, Кирмән ише калаларның барсын да җентекләп, казып-чокып өйрәндем. Кыскасы, без икебез дә бер үк чорны тасвирлыйбыз-өйрәнәбез, белгәннәребезне укучыга җиткерергә ашкынабыз: мин, галим буларак, – фәнни хезмәтләремдә, Вахит дус, язучы буларак, – «Казан дастаны»нда һәм «Утлы дала»да. Шул чор турында минем инде калыплашып өлгергән үз карашым бар, язучының – үзенеке. Менә шул карашлар, фән теле белән әйткәндә, концепцияләр, бер-берсенә тәңгәл килерме, Вахит Имамов дигән язучының ошбу әсәре миндә канәгатьсезләнү хисләре тудырмасмы, күңелемне кайтармасмы дигән сораулар мине гел борчып торды.

Әлеге әсәрләргә шикләнебрәк тотынуымның тагын бер сәбәбе бар иде. Ул – Нурихан Фәттах феномены. Яратам мин ул язучыны. Аның «Итил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» романнары, «Кол Гали» трагедиясе – классик әсәрләр. Тарихи чынбарлык (без белгән күләмдә) ул әсәрләрдә дөрес чагылдырылган, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан телтеш тидергесез. Нурихан Фәттахтан соң килгән татар язучыларының тарихи жанрда иҗат ителгән әсәрләренә бәяне, ихтыярсыздан, мин әнә шул эталонны күз алдында тотып бирәм.

Вахит Имамов әсәрләре шул эталонга ни дәрәҗәдә туры килә? Хәзер инде курыкмыйча әйтә алам: тарихи вакыйгаларны, шул вакыйгаларда катнашучы персонажларны фәнни дөреслеккә туры китереп сәнгатьчә сурәтләү дәрәҗәсе ягыннан Вахит Имамов әсәрләре иң югары бәһагә лаек!

«Утлы дала» романы турында мин язып чыккан идем инде (Мәйдан. 2002, № 6. 193–199 бб.; 2012, № 8, 59–64 бб.). Макталды да, тәнкыйть сүзләре дә әйтелде. Кабатлап тормыйм. Бәям шундый иде: «Титаник эш эшләнгән! Киң панорамалы, тарихи роман жанрының иң югары таләпләренә туры килерлек, укучыбыз күптән көткән һәм аңа бик кирәкле әсәр язылган».

«Казан дастаны» турында да бер-ике сүз әйтәсем килә. Вахит Имамов әсәрен язарга утырганчы эшне һәрвакыттагыча чыганаклардан башлый. Тарихи роман авторларының барысы да шулай эшли торгандыр дип беләм. Әнә, Нурихан Фәттах, романында тасвирланасы вакыйгаларны документлардан өйрәнә-өйрәнә, чын галим булып китә язды заманында, Вахит та шул чамада дип беләм (кандидатлык диссертациясе булса да якла инде ичмасам дип үгетләүчеләр күп булган, ишетүемчә). Һәрхәлдә урыс елъязмаларын яттан белә кебек ул. Хәтта безнең археология материаллары белән дә таныш. Нәтиҗәдә, язган әсәре без белгән чынбарлык кысаларыннан чыкмый. Чыганаклардан таныш тарихи вакыйгаларны, чамасын белеп кенә, уйлап чыгарыл-

ган маҗаралы сюжетлар белән баета: бер укый башласаң, аерылып булмый китабыннан. «Казан дастаны»нда, миңа калса, автор әнә шул маҗаралы сюжетлар белән артык мавыга кебек. Китапны мин гадәттә кулга карандаш алып укыйм. Үземә кирәк урыннарны тамгалар белән билгеләп барам, кырга кыска гына итеп үз фикеремне дә язып та куйгалыйм кайчакта. «Казан дастаны» битләрендә минем «ышандырмый» дигән репликам, сорау билгеләре «Утлы дала»га караганда күбрәк. Мондый гына нәрсәләргә укучы игътибар итми гадәттә. Шулай кирәктер дә, бәлки. Әмма кайбер принципиаль характердагы вакыйгалар турында сүз барганда, автор фантазиясенә артык бирелмичә, тарихи дөреслектән ерак китмәскә тырышырга кирәк. Мәсәлән, Елантауда Казанга нигез салу күренеше. Язучы аны 985 елда Болгар иленә яу чапкан Киев кенәзе Владимир белән Ибраһим хан арасында солых килешүе төзелү вакыйгасы белән бәйләгән. Ибраһим хан булачак каланың беренче казыгын кага:

– Меңьяшәр кала булырга язсын инде берүк!

– Уртак кала булсын! – дип, чакчак кына ишетелерлек итеп пышылдады бер як читтә турсаеп торган кенәз.

Бу эпизодны тарихи дөреслеккә туры килә дип булмый инде. Казанны без Елантауда (Казансу елгасы тамагында) түгел, хәзерге Кремль калкулыгында нигезләнгән дип расладык ич. Һәм 985 нче елда түгел, унберенче йөз башында. Ә инде бу мөһим вакыйгага болгарларны таларга килгән урыс кенәзен китереп кушуны аңлый да, аңлата да алмыйм.

Әйтергә теләгән тагын бер фикерем бар. Вахит Имамовның тарихи романнарын укып, болгар бабаларыбызның өч гасырдан артык вакытка сыйган чын тарихын өйрәнергә була. Дәреслекләр, фәнни хезмәтләр укыгандагы кебек үз-үзеңне мәҗбүр итеп түгел, ә язучының матур тел белән язылган, югары сәнгать кануннарына туры килә торган талантлы әсәрләрен укудан ләззәт алып. Кызганыч, мәктәп балаларын ул китапларны укудан тыярга мәҗбүрләр. Сәбәбен китап битләренә карандашым белән төртеп куйган сүзләрдән аңларга була: «Эротика!», «+16». Бу нәрсәләр белән артык мавыгуны заман шаукымы дип аңларгадыр инде. Кирәк микән?

Вахит Имамов – беркемгә дә ошамаган һәм ошарга да тырышмаган, күп санлы китаплары, иң әүвәл тарихи романнары белән бөтен татар дөньясына танылган олпат язучыбыз. Үзенең 60 еллык юбилеен ул иҗатының иң югары ноктасына җитә язып каршылый. Шулай дип язам, чөнки әле без аннан тагын да саллырак әсәрләр өмет итеп калабыз (иң әйбәт әсәрләрем әле язылмаган, дип әйтергә яраталар ич язучылар). Потенциаль мөмкинлекләре чиксез аның. Исәнлек-саулык һәм яңа иҗат уңышлары теләп калабыз Сиңа, Вахит дус!

*Казан утлары. 2014. № 3. Б. 173–178.*



## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҢ УҢЫШЛЫ ӘСӘРЕ
### («Утлы дала» тарихчы күзлегеннән)

Элегрәк чыккан бер мәкаләмдә мин: «Тарихи романнарны бик яратып һәм кызыксынып укыйм», – дип язганмын икән. Алай ук түгел. Әйе, барысын да диярлек укып барам, әмма... юк, яратып укыйм дип әйтү дөрес үк булмас. Моның сәбәпләре төрле. Теге яки бу язучы тарихи вакыйгаларны, шәхесләрне фәнни яктан ни дәрәҗәдә дөрес итеп тасвирлаган һәм, иң мөһиме, әсәр сәнгатьчә эшләнеше ягыннан ни дәрәҗәдә камил вә мөкәммәл? – тарихчы-галим һәм гади укучы буларак, иң әүвәл мин шул нәрсәләргә игътибар итәм. Менә шул «нәрсәләр» төрле язучыда төрлечә, һәм ул, табигый ки, шулай булырга тиеш тә. Югары сәнгатьчәнлек күзлегеннән караганда, миңа калса, «тарихи» дип аталмаган жанрларда иҗат итүче язучыларның әсәрләре күпкә отышлырак. Ә мин андый әсәрләрне дә барыбер тарихчы-галим күзлегеннән карап укыйм һәм ихлас ләззәтләнү хисләре кичерәм. Тарих дәреслекләрен укып кына, әби-бабаларыбыз сөйләгәнннәрдән чыгып кына халкыбыз тарихын бөтен тулылыгы, нечкәлекләре белән аңлап булмый. Халкыбыз тарихы ул – Галимҗан Ибраһимов, М. Галәү, Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин, Айдар Хәлим һәм башка бик күп язучыларыбыз иҗатында! Талантлы шагыйрьләребезнең шигырь-поэмаларында гына түгел, хәтта лирикада да тарих чагыла! Шуңа күрә мин, бары тик тарихи романнарны гына яратып укыйм дип һич әйтә алмыйм.

Тарихи романнар, әйе, языла тора. Нурихан Фәттах, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Җәмит Рәхимов, Флүс Латыйфи, Солтан Шәмси, Фәүзия Бәйрәмова, Факил Сафин, Ркаил Зәй-

дулла, Равил Вәлинең төрле елларда дөнья күргән әсәрләрен укучылар яратып укый. Мин моңа бик шатланам, чөнки без, язучылар һәм тарихчы-галимнәр, бер үк эш – изге эш! – эшлибез. Аның асылы – хәзерге заман татар укучысында, беренче чиратта, яшь буында, халкыбызның шанлы үткәне һәм бүгенге уңышлары мисалында горурлык хисләре тәрбияләү. Татар угылы татармын! Менә шул горурлык хисе булмаса бездә, бөтен галәмгә һәм гавәмгә глобальләшеп бетү куркынычы янаган бер заманда татарның милләт булып сакланып калу мөмкинчелеге югалачак. Яшь буынга милли тәрбия бирү өлкәсендә безгә әле, бигрәк тә әдәбият һәм сәнгать әһелләренә, бик күп тырышырга, максатчан һәм җиң сызганып эшләргә кирәк. Кызганыч, бу эштән, милли мәгарифне үстерү турында күп сөйләсәләр дә, мәктәпне һәм югары уку йортларын һаман читләштерә баралар.

Шушындый озын керештән соң 1980 нчы еллар башында кыю рәвештә әдәбият дөньясына килеп кергән талантлы язучы Вахит Имамов иҗатына күчик әле. Киң колачлы, күпкырлы, бик тә үзенчәлекле һәм искитәрлек дәрәҗәдә актив каләм иясе ул. Аның әсәрләрен укып барырга тырышам. Миңа аның бигрәк тә үзе җитәкләгән «Мәйдан» журналында – һәр санында диярлек! – басылып килә торган тарихи-публицистик язмалары ошый. Чөнки Вахит әфәндедең теге яки бу төбәк тарихына, шул төбәкнең тарихи шәхесләренә багышланган язмалары өр-яңа, әле фәндә билгеле дә булмаган кызыклы мәгълүматлар белән тулган була. Гаҗәп түгел – архивларда күп эшли ул, халык арасында таралган легенда-риваятьләрне җыеп бара, тел гыйлеменең ономастика (топонимика) һәм этимология дигән тармаклары белән тирән кызыксына, кыскасы, беренчел чыганаклар белән эш итәргә ярата. «Сәет батыр» (1994) һәм «Татар яугирләре» (2003) дигән күләмле әсәрләрен генә алып карагыз. Күренекле тарихчыбыз Сәлам Алишевтан соң Пугачев яуларына игътибар итүче дә юк иде, XVIII йөз тарихын өйрәнүчеләр бигрәк тә аз, чөнки күбесенең тешләре үтми. Ә менә Вахит Имамов булдыра, югыйсә, фәнни дәрәҗәсе дә юк. Мин беләм, урта мәктәпнең тарих укытучылары аның китапларын, публицистик мәкаләләрен дәреслеккә өстәмә уку ярдәмлеге рәвешендә кулланалар. Вахит Имамовны югары уку йорты студентлары да беләләр. Елмаеп-көлеп дигәндәй, үземнең мөгаллимлек тормышымнан бер кызыклы фактны искә төшереп үтим әле: өч-дүрт ел элек чыгарылыш курс студентының (дөрес, ул читтән торып белем алучы укытучы ханым иде) миңа рецензияләргә биргән диплом эшендә ярылып яткан плагиатлык галәмәтләре күреп шаккаткан идем. Бер бүлеген «Сәет батыр»дан күчереп алынган мәгълүматлар белән тутырган да, авторын күрәтмичә генә, фикерләрен үзенеке итеп тәкъдим иткән. Болай ярамаганлыгын аңлаттым, әлбәттә, әмма язучы өчен, ни генә булмасын, күңелле факт!

Ярый, хуш, хәзер инде Вахит Имамовның минем карашка иң уңышлы әсәрләреннән саналган «Утлы дала» романына күз салыйк. Әсәрне анализларга атлыгым тормавымны укучы, шәт, сизгәндер инде. Аның ике төрле сәбәбе бар. Эш шундадыр ки, мин – тарихчы. Гомер буе халкыбызның урта гасырларга караган бик тә катлаулы чорын өйрәнергә туры килде. Болгар фәне дөньясында бүгенге көндә билгеле булган барлык язма чыганакларны беләм. Алай гына түгел, Вахит Имамов романында сурәтләнгән төп вакыйгаларның урыннарын – Биләр, Сувар, Җүкәтау, Алабуга, Казан, Кирмән ише калаларның барсын да – археолог буларак җентекләп, казып-чокып өйрәндем. Кыскасы, без бер үк чорны тасвирлыйбыз: мин, галим буларак, – фәнни хезмәтләремдә, Вахит дус, язучы буларак, – ике китаптан торган менә шушы тарихи романында. Шул чор турында минем инде калыплашып өлгергән үз карашым бар, язучының – үзенеке. Менә шул карашлар, фән теле белән әйткәндә, концепцияләр, бер-берсенә тәңгәл килерме, Вахит Имамов дигән язучының ошбу әсәре миндә канәгатьсезләнү хисләре тудырмасмы, күңелемне кайтармасмы дигән сораулар мине гел борчып торды.

Икенче сәбәп – Нурихан Фәттах феномены. Аның «Итил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» романнары, «Кол Гали» трагедиясе – классик әсәрләр. Тарихи чынбарлык (без белгән күләмдә) ул әсәрләрдә дөрес чагылдырылган, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан тел-теш тидергесез. Нурихан Фәттахтан соң килгән татар язучыларының тарихи жанрда иҗат ителгән әсәрләренә бәяне, ихтыярсыздан, мин әнә шул эталонны күз алдында тотып бирәм. Бу эталонга, минем субъектив фикеремчә, мәрхүм Флүс Латыйфиның «Хыянәт» романы якын иде. Ә «Утлы дала»?

Вахит Имамовның «Утлы дала»сы – эпик әсәр. Күләме ягыннан гына түгел. Романда сурәтләнгән дөньякүләм әһәмиятле тарихи вакыйгалар географиясе гаять киң – Монголия далаларыннан башлап, Харәзем дәүләтен, Болгар илен һәм рус кенәзлекләрен дә кертеп, Карпат тауларына кадәр. Шул киңлектә барган геополитик вәзгыятьтә катнашучы, кешелек тарихында үзләренең йә вәхшилеге, йә зирәк акыллары белән җуелмас эз калдырган атаклы шәхесләрнең, автор фантазиясе белән тудырылган образларның, укучыларга мәгълүм вә нәмәгълүм эреле-ваклы кабиләләрнең, халыкларның саны йөзләгән. Кирәк булдымы шулкадәр катлауландырыга әсәрне? Әйе, кирәк! Утлы дала кайный: әле кичә генә сәүдә итешеп, килен-кәләш, кан алмашып тыныч тормышта яшәгән кабиләләр бүген инде кан коеша, бер-берсенә яу чаба; җиңелгәннәр, туган җирләрен калдырып, башка якларга күчеп китәргә мәҗбүр була, җиңгәннәр исә, бераз хәл җыеп алганнан соң, икенче күршеләрен талый башлый. Сугыш солых белән тәмамлана, тормыш яңадан үз эзенә төшә. Һәм аннан соң... Вакыйгалар

гаять зур тизлек белән алмашынып торалар. Бу – урта гасырлар җәмгыятенең яшәү рәвеше. Автор шуны күрсәтергә теләгән. Монда инде биш-алты төп персонаж белән генә чикләнә алмыйсың, дистәләгән эпизодик образлар кертү кирәк була. Хуш, аларның барысын да хәтердә саклау мәҗбүри дә түгел. Алыгыз әсәрнең урыс кенәзлекләренә багышланган бүлекләрен. Бүген Киев тәхетендә Изяслав кенәз утыра, иртәгесен аны Мстислав алмаштыра, ә тегесе Черниговка чыгып кача, Чернигов кенәзе Святослав Тверьга китәргә мәҗбүр була. Тверьга килеп егылгач, Суздаль кенәзе Юрийга мөрәҗәгать итеп, үзенә яңа кала дәгъва итә башлый. Тегесе аны аңлый һәм икенче көнне чыгып китәләр болар яу белән Рязаньны таларга. Урысларның XII гасырда башланган феодал таркаулык чорындагы сәяси тормышын укучыга дөрес итеп җиткерергә телисең икән, шул заман кенәзләренең исемнәрен атап үтмичә булмый шул. Борынгы елъязмаларын укып карагыз – урыс башын урыс ашый анда (без бу гыйбәрәне татарларга карата гына кулланабыз гадәттә). Ахыр чиктә бит автор шундый ысул белән урыс күршеләребезнең менталитетын ачып бирә, укучыга аларны болгарлар белән чагыштырып карарга юл ача.

Болгарлар дигәннән. Урыс кенәзлекләренең һәм монголларның китапта бәян ителә торган чорга караган тарихларын без ярыйсы гына әйбәт беләбез, чөнки беренчел чыганаклар сакланып калган, шуларны тикшереп әллә никадәр фәнни хезмәтләр язылган. Болгарларга нисбәтле мондый чыганаклар юк дәрәҗәсендә, булса да санаулы гына: уникенче гасыр урталарында Болгарга Андалусия (Испания) сәүдәгәре әл-Гарнати килеп китә һәм үзенең сәяхәте турында кызыклы гына язмалар калдыра (әмма ул язмаларда илнең сәяси тормышы чагылыш тапмаган); урыс елъязмаларында ике күрше ил арасында алып барылган сугышлар һәм 1236 елгы монгол яулары турында турында кыска гына хәбәрләр теркәлеп калган; Болгар иленә 1235 елда Венгриядән Юлиан исемле монах килә һәм безнең көннәргә кадәр сакланып калган көндәлегендә аз булса да мәҗүси мажарлар һәм монголлар турында мәгълүмат калдыра. Әлеге чыганакларда бары тик бер тарихи шәхеснең – казый һәм «Болгар тарихы»ның авторы Якуб ибн Ногманның исеме телгә алына. Шуның белән шул. Бу хәл язучы алдына беренче карашка үтеп чыга алмаслык авыр киртәләр куя. Нишләргә? Әлбәттә, автор үзенең бетмәс-төкәнмәс фантазиясен эшкә җигәргә мәҗбүр.

Ә мин үз чиратымда әле безнең карамакта азсанлы язма чыганаклардан башка археологик материаллар да булуын искә төшереп үтәргә тиешмен. Менә шул археологик материаллар нигезендә галимнәр XII гасырдагы Болгар илен икътисади яктан көчле, сәяси яктан бердәм, үзәкләштерелгән дәүләт рәвешендә күз алдына китерәләр. Бу – болгарларда шәһәр икътисадының нигезен тәшкил иткән һөнәрчелекнең һәм сәүдәнең чәчәк

ату чоры. Яңа кала-крепостьлар торгызыла, искеләре төзәтелә, ә монгол яулары алдыннан иң эре шәһәрләрдә өстәмә саклану ныгытмалары корыла. Игенчеләр шәһәр-калаларны берөзлексез икмәк белән тәэмин итеп торганнар – Биләр амбарларында археологлар әле бүген дә капчык-капчык бодай, борчак, арпа, тары бөртекләре җыеп алалар.

Болгар иленең менә шушы халәтен Вахит Имамов беренче китапның икенче бәйләмендә (Андрей Боголюбскийның Кашанга һәм Болгарга сәяхәте) бик матур итеп тасвирлый. Рәхәтләнеп укыйсың, болгар бабаларыбыз белән ихластан горурланып, уңышларына сөенеп. Автор бераз чама хисен югалта, әлбәттә, чүт кенә идеаллаштыра да кебек болгар җәмгыятен, әмма бу куркыныч түгел, безне болай да гел мәсхәрәләү дәрәҗәсенә төшереп кимсетеп тора «өлкән туганнарыбыз».

Ә менә Андрей делегациясе киткәннән соң Болгар илендә хәл бөтенләй үзгәрә, күз тидергәннәр диярсең, билләһи. Бер яктан илгә урыс юлбасарлары, икенче яктан карлуклар (?) һәм кыпчалар басып керә. Кыпчаклар белән орышта Шәмгун хан үтерелә. Китә тәхет өчен көрәш, китә суеш, югыйсә, әле кайчан гына бит хан угылы һәм Кашан бәге Хисам бәк (Әмир Колын) Андрей кенәзгә, Болгар илендә кабул ителгән кануннарны аңлатып, тәхет варисын ничек билгеләп куюлары турында ашкынып сөйләгән иде. Фани дөнья күпкә катлаулырак икән шул. Тәхеткә дәгъва кылучылар башлап җибәргән бәхәс-талаш, коточкыч мәшхәр, беркавымга тынычланып калганнан соң тагын көчлерәк кабынып китеп, әмма өзлексез диярлек, монгол яуларына кадәр дәвам итә. Амбарларда ашлык запасы бетә, илдә ачлык башлана. Һөнәрчеләрнең остаханәләре тынып кала, сәүдә туктый. Ирләрен сугышта югалткан гаиләләр, туган якларын калдырып, чит җирләргә, ят кавемнәр арасына китеп югалырга мәҗбүр булалар. Болар турында укыганда, билләһи, болгар бабаларыбызны кызганып утырасың инде һәм... оялып.

Шулай булырга мөмкинме безнең Болгарда? Ә нигә булмасын ди, бик мөмкин. Тәхет өчен көрәшнең бер илдә дә, беркайчан да тынып торганы юк аның. Күреп торабыз бит – бүген дә көрәшәләр һәм ничек кенә әле! Шуңа күрә, син безнең бабаларыбызның кылган гамәлләрен каралтып күрсәткәнсең дип, язучыны гаепләргә нигез юк.

Шулаен ул шулай да... Барыбер, миңа калса, автор кайбер моментларда чама хисен югалткан кебек тоела. Алыйк Болгар иленең баш сәете Давыд белән бәйле сюжетны. Ул – атаклы баш казый һәм «Болгар тарихы» китабының авторы Якуб ибне Ногманның оныгы, нәсел җебе Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташа торган иң абруйлы дин башлыгы. Бәрәҗ хан тәхетне яулап алгач, аның башбаштаклыгына каршы, кара халыкның бөтенләй бөлгенлеккә төшүенә түзеп тора алмыйча көрәшкә күтәрелгән фетнәчеләр, дөресрәге, «Ил-дан» яшерен фиркасе башлыгы Идрис хәзрәтнең коточкыч

җәзага тарылуы, шул фетнәчеләргә хәер-фатиха биргән Давыт сәетнең дә кылычтан үткәрелүе, ничектер, сәеррәк тоела. Сәет кадәр сәеткә кул күтәрү, аны түбәнсетү һәм мәсхәрәләү, ахыр чиктә, үтерү – акыл белән аңлатып булмый торган гайре табигый хәл. Кашан бәге Әмир Колынның угылы канечкеч Хәмбәлнең чирмешләр ягында, туй кичендә күрсәткән кыйланмышлары да һич башка сыярлык түгел.

Тагын бер нәрсә. Китапны укып чыкканнан соң, Болгар ханнары күрше чирмеш, ар, мукшы халыкларын гел изеп-кыйнап торганнар икән, дигән фикер туа. Алай түгел! Һәрхәлдә, безнең кулда булган археологик материаллар киресен сөйли. Элеккеге мукшы, хәзерге Мордовия җирләрендә казып тикшерелгән борынгы авылларның бер өлешен җирле халык нигезләгән (табылдыкларның 90 процент чамасы мордваларныкы), аннан соң бирегә болгарлар килгәннәр һәм шул мукшылар белән бергәләп тыныч гомер кичергәннәр (соңгырак катламдагы табылдыкларның 50–60 проценты мукшыларныкы, калганы болгарларныкы). Болгарлар тарафыннан нигезләнгән авыллар да бар (80 процент чамасы болгар әйберләре), соңрак ул авылларга да мукшылар килеп төпләнгән (табылдыкларның 30–40 проценты аларныкы). Болар – безнең мордва коллегаларыбыз тарафыннан ачылган бик кызыклы фактлар! Элек ул язалар иде, фин-угыр халыкларын башта болгарлар, аннан соң Казан ханнары талап торган дип. Хәзер күрәләтә алдауга бармыйлар – кулларында дәлилләр юк. Гади халык кайда да бер инде ул – иген игәргә, мал-туар асрарга, гаилә корып имин тормышта балалар үстерегә хыялланып яши ул. Өстән өстереп торучылар булмаса, беркайчан да үзләре теләп, күршеләрне талап кайтыйм әле дип, яуга кубарылмый. Ханнарны да алай ук беркатлыга санамасыннар – аңа буйсынган халык никадәр бай булса, казнасына аның шулкадәр байлык керә. Нәрсә дим инде? Ни генә әйтмә, тормыш без уйлаганнан күпкә катлаулырак шул. Вахит Имамов, язучы буларак, болгар дөньясын үзенчә күрергә хаклы.

«Утлы даланың» болгарларга багышланган бүлекләрендә минем күңелемә якын һәм гаҗәп дәрәҗәдә оста башкарылган сюжет линиясе Кол Гали образы белән бәйле. Аның турында без бик аз беләбез, белгәннәребез исә «Кыйсса-и Йосыф»та китерелгән кыска гына бер-ике белешмәдән (бу поэмада авторның исеме һәм әсәрнең язылу вакыты гына күрсәтелгән) һәм халык телендә сакланып калган кайбер риваятьләрдән гыйбәрәт. Соңгылары Таҗетдин Ялчыголның 1806 елда язылган «Тәварихы Болгария» дигән китабында китерелгән. Риваятьтә сөйләнгәнчә, Кол Гали Болгар иленең асыл шаһзадәләреннән саналган Мирхаҗи бәкнең угылы була. Утыз ел чамасы Кашан шәһәрендә гомер кичереп, Мирхаҗи Зәй якларына күчеп килә. Кол Гали шул төбәктә туа, зирәк, акыллы егет булып үсә, аннан соң, белем эстәп Харәзем якларына чыгып китә. Биредә укый, мөдәрри-

слек итә, соңыннан, монгол яулары Харәзем җирләрен басып алгач, туган ягына әйләнеп кайта, Аксак Тимернең (дөресрәге, Батыйның) Биләргә һөҗүме вакытында шәһит була.

Менә шушы ярымлегендар характердагы кыска гына мәгълүматларга таянып, Вахит Имамов Кол Галинең гаҗәеп тормышчан, тулы бер образын тудырган. Бу – аның зур уңышы! Безнең күз алдына бөек шагыйребезнең туганнан алып каһарманнарча үлеменә кадәрге бөтен тормышы күз алдына килеп баса. Беләбез, фантазиягә бай инде ул, безнең авторыбыз, маҗаралы сюжетлар остасы, әмма ни хәл итәсең – Кол Гали образы ышандыра. Хәтта шагыйрьнең башта Бохарада Чынгызхан белән, соңыннан, Болгар җирендә, Батый хан белән очрашу вакыйгасын да, уйламыйча-нитмичә генә, реаль факт буларак кабул итәсең. Шунысына игътибар итми мөмкин түгел – нәкъ шушы трагик (!) образ аша автор әсәрнең оптимистик рухта тәмамлануына ирешә алган.

Әсәрнең монголлар тормышын, яшь Тимучинның гайрәтле Чынгызханга әверелү һәм аның дистәләгән дәүләтләрне басып алу тарихына караган бүлекләр, автор фантазиясе белән баетылган маҗаралы вакыйгаларның күп булуына карамастан, асылда борынгы документларда чагылыш тапкан тарихи чынбарлыктан ерак китмиләр. Чынгызханның фәнни биографиясен язу мөмкин түгел – ул яртылаш легендалардан тора. Аларның бер өлеше әле бөек җиһангир үзе исән вакытта ук тудырылган, бер өлеше – аның үлеменнән соң биографлары тарафыннан. Бу традицияне лаеклы рәвештә хәзерге заман галимнәре дәвам итә. Вахит Имамов боларны белә, шулай да үзенең романын язганда фәндә кабул ителгән кануннар кысасыннан тайпылмаска тырыша.

Минем максатым – әсәргә тарихчы күзлегеннән карап бәя бирү. Шуны истә тотып, игътибарымны кайбер төгәлсезлекләргә, аңлашылып бетмәгән урыннарга юнәлтим әле. Беренче китап Тимучинның олуг хан – Чынгызхан итеп сайлау корылтае белән тәмамланган иде (бу вакыйганың ничәнче елда булганлыгы күрсәтелмәгән). Икенче китапта аны янә бер мәртәбә ак киезгә күтәрәләр һәм Чынгызхан дип игълан итәләр. Бусы 1206 нчы елда була. Беренче китаптагы магуллар мәңгелләргә әверелгән. Аңламадым, укучы да аңламас дип уйлыйм. Аннан соң Чынгызханның титулын «кахан» дип, Монгол дәүләтен «каханат» дип атау дөрес булырмы икән? Бөек (олуг) ханны монголларда «каан» дип йөрткәннәр ич (дөрес анысы, «кахан»нан барлыкка килгән термин ул). Монгол феодалларына карата «солтан» терминын куллану да урынсыз кебек.

Урыс-болгар чикләренә якынлашыйк. Миңа мәгълүм булганча, урыслар «монгол» дигән халыкны бөтенләй белмәгәннәр, аларны «татарлар» дип йөрткәннәр, һәрхәлдә, елъязмаларында шулай. Ә татарлар – монголларга буйсынган халык, дәрәҗәләре түбәнрәк, шуңа күрә аларны гадәттә һөҗүм итүче гаскәр-

нең алдына чыгарып куя торган булганнар. Ә соңыннан монголларга буйсынган халыкларны «татарлар» дип йөртә башлаганнар. Вахит Имамов боларны гына белә инде, әлбәттә. Ни өчен «татар» сүзеннән курыкканын гына аңламыйм. Монголлар басып алган Саксин каласын Җигулат (Жигули) таулары итәгенә урнаштыру да дөрес түгел, Түбән Иделдә, хәзерге Әстерхан шәһәре тирәсендә булган ул. Пургасны чирмешләр кенәзе сыйфатында бирү дә чынбарлыкка хилафлык китерә, елъязмаларда ул мукшылар (мордва) кенәзе буларак телгә алына. Чирмешләр дип гәдәттә мариларны һәм чувашларны атаганнар.

Бер башлагач, әйтим инде, әмма артык тәнкыйтьли дип уйламагыз. Урта гасыр тарихчылары теге яки бу сәрдәрнең (армия башлыгы дигән сүз була инде бу) гаскәрендәге сугышчылар санын гадәттә күпкә арттырып күрсәтәләр. Гомумән, борынгы чыганаклардагы саннар белән бик сак эш итәргә кирәк. Академик Валерий Алексеев, бөтен Монгол империясендә халык саны 500 меңнән артмаган, сугышчылар саны исә 50 мең чамасы яки бераз күбрәк булгандыр дип язган иде. Реаль саннар, әйтергә кирәк. Бу җәһәттән Вахит Имамов шаккаттыргыч саннар белән артык мавыкмый, әмма болгар калаларының халык санын, минемчә, күпкә арттырып күрсәтә. Мәсәлән, беренче китапта ул, шәһри Болгарның (ул аны «иске пайтәхет» дип бирә) «очы-кырые күренми, ул тирән ерымнар артына һәм киң үзәнлек эченә сузылып югала», дип яза. Чынбарлыкта исә аның мәйданы монгол яулары алдыннан 40–45 гектар чамасы гына булган. Бу – археологларның 70 елдан артыграк казып тикшерү нәтиҗәсендә билгеле булган факт. Күпме кеше яшәгән анда? Якынча гына исәпләп карыйк: бер хуҗалык якынча 10 сотый җирдә урнашкан дип алсак (йорты, амбары-келәтләре белән, бәлки әле җиләк-җимеш бакчасы да булгандыр), 1 гектар җиргә (100 х 100 м) 10 хуҗалык туры килә. Бер хуҗалык – бер гаилә инде ул. Урта гасырлар өчен гадәттә гаиләдә 5–6 кеше булган дип исәплиләр. Бер гектар җирдә 60 кеше яши дигән сүз бу. Димәк, 45 гектар җиргә 450 хуҗалык һәм 2700 кеше туры килә. Ләкин бит шәһәрнең барлык мәйданы да йортлар белән шыгырдатып тутырылмаган – булган аның урамнары, мәчетләре һәм аның тирәсендәге мәйданнары, һөнәрчеләрнең остаханәләре урнашкан җирләр. Шуларны да күчереп исәпләсәң, якынча 35 гектар җире кала Болгарның – 2000 меңләп чамасы кеше. Вахит Имамов Биләрдә (ул аны «яңа пайтәхет» дип атый) 70 меңләп кеше яшәгән ди. Минем остазым, профессор Альфред Халиков бу санны 130–150 меңгә җиткерә иде. Мин исә, югарыда кулланылган ысул белән санап, Биләр халкын бик теләсәм дә 30 меңнән арттыра алмыйм. Күрәсез, язучыбыз артык хаталанмаган.

Әдәби тәнкыйтьче булмагач, үземнең зәвегымә генә ышанып, әсәрнең теле турында фикеремне әйтергә читенсенәм. Кыскасы, авыррак

аңлаешлы гарәп-фарсы алынмалары күбрәк булуга карамастан, миңа калса, бик шома, авторның үзенә генә хас үзенчәлекле тел белән язылган. Бераз кырысрак, кискенрәк стиле әсәрнең характерына, эчтәлегенә туры килеп тора.

Язылачак әсәр геройларына лаек исем табу гаять авыр нәрсә дип ишеткәнем бар язучылардан. Бер карасаң, «Утлы дала» геройлары белән, формаль яктан караганда, бар да тәрптиптә кебек. Әмма... Алтынбәк, Алтынчәч, Даир (Казан каласының атаклы ташчы-мигъмары), Хәсән (Казан әмире) исемнәрен, әле алар янәшәсенә Ташаяк, Бишбалта кебек топонимик атамаларны да китереп куйсаң, укучылар аңы, һичшиксез, Ултын Урда һәм Казан ханлыгы чорының мәгълүм тарихи шәхесләре һәм легендар геройлары белән тәңгәлләштерәчәк. Алар – символик исемнәр: Болгар ханы Габдулланың Аксак Тимер кулыннан исән калган сабые Алтынбәк (энесе Галимбәк белән), исеме елъязмаларда саклан-ган һәм каберташка уеп язылган әмир Хәсән, хан Казанының атаклы Таһир мунчасы («Даирова баня»), «Алтынчәч» операсыннан Җик Мәргәннең сөйгәне. Ханлык чорына багышлап тагын бер роман язарга уйласаң, ул исемнәргә яңадан әйләнеп кайтмыйча мөмкин түгел.

Менә әсәрне тагын бер мәртәбә тулаем күз алдыннан үткәрәм. Титаник эш эшләнгән! Киң панорамалы, тарихи роман жанрының иң югары таләпләренә туры килерлек, укучыбыз күптән көткән һәм аңа бик кирәкле әсәр язылган. Авторны бу олы уңышы белән котларга һәм аңа яңадан-яңа иҗат уңышлары гына телисе кала.

*Вахит Имамов. Утлы дала. Тарихи роман.*
*Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 752–758.*




## ХАК ТАРИХНЫ КАЙТАРУ ЮЛЫНДА
«ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»

*«Казан утлары» журналының быелгы 5–6нчы саннарында Вахит Имамовның «Карабәк» исемле тарихи романы басылып чыгуга, ул тарихчы галимнәр арасында гына түгел, ә киң катлау укучылар арасында да зур кызыксыну уятты,бәхәсләр тудырды. Журналыбыз редакциясенә юллаган сораулар, телефоннан шалтыратулар да күп җыйналды. Шуларны истә тотып, редакциябездә бер төркем галимнәр «түгәрәк өстәл»гә җыйналды. Фикер алышуларда тарихчылар һәм әдәбият галимнәре, фән докторлары ... катнашты. «Түгәрәк өстәл»дә фикер алышуларны журналның баш мөхәррире* ***Илфак Ибраһимов*** *алып барды.*

**Илфак Ибраһимов**:

Татар халкының дәүләтчелегенә багышланган фәнни хезмәтләр белән янәшә әдәби романнар, бәяннар, очерклар, поэмалар язылып тора. Шуңа да карамастан, бу тема һаман да колач җитмәслек булып кала. Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты әнә 7 томлык тарихыбызны бастырып чыгарды. Хак тарихыбызны әлегәчә өйрәнеп бетә алмыйбыз.

Тарих фән өчен кирәк булса, тарихи әдәби әсәрләр күпсанлы укучыларыбыз өчен кирәк. «Карабәк» романын тарихчыларыбыз ничек кабул итте икән?

Әсәрне без кызыксынып кабул иттек, әмма ажиотаж булмады, ыгы-зыгы, шау-шу күтәрелмәде. Игътибардан читтә калдырмавыбызның сәбәбе шул: Вахит Имамов – татарларның башлыча урта гасырлар чорына караган тарихи романнары белән һәм халкыбызның киләчәк яз-

мышын билгеләүдә әһәмиятле роль уйнаган тарихи вакыйгаларга үзенең шәхси, фәндә кабул ителгән рәсми концепцияләргә туры килеп бетми торган бәяләмәләре белән киң катлам укучылар арасында танылу алган язучы. Кызганыч, тарихчылар арасында «Казан утлары»н даими укып, бүгенге татар әдәбияты белән танышып баручылар сирәк. Шуңа күрә галимнәребезнең күбесе әлеге романны әлегә укымады да, тизрәк китап булып басылып чыгуын көтәләр.

Без Болгар дәүләте белән Алтын Урданы бербөтен итеп күзаллауга өйрәнеп киләбез. Болгар Алтын Урдага кадәр дә, Алтын Урда составында да гел алгарышта булган дибез... Шул ук Вахит Имамов «Утлы дала» романында Болгарга татар-монгол яулары басып керүләрне сурәтләде. «Карабәк» романында Болгарның соңгы әмире Карабәк – Габдулла ханның Алтын Урда дәүләтен саклап калу өчен җан атып йөрүе, көрәшүе сурәтләнә. Туктамыш баскын Аксак Тимергә каршы ике тапкыр 200 меңлек гаскәр туплый. Һәр ике яу алдыннан Болгар әмирлегеннән өчәрдүртәр төмән җайдак җыеп, Карабәк тә аның әләме астына баса. Шундый көчне Алтын Урда составындагы тагын кайсы олыс бирә алган соң? Әллә монда «әдәби якын килү» күбрәкме?

Әйе, Болгар Алтын Урдага кадәр дә, Алтын Урда составында да бай, икътисады, димәк, хәрби көче һәм мәдәнияты ягыннан да алга киткән өлкә булган. Әмма Алтын Урданы һәм аңа кадәр чәчәк атып яшәгән Идел Болгарын (Болгарстанын) бербөтен итеп күзалларга тырышу тарихи дәреслектән ерак тора. Идел Болгары, исеменнән үк күренеп торганча, – хәзерге Идел-Урал татарларының бабалары булган болгарлар дәүләте, Алтын Урда исә, монгол-татар яуларыннан соң әнә шул Болгар дәүләтен юкка чыгарып, аның биләмәләрен, халкын һәм, әлбәттә, башка җирләрне дә кушып барлыкка килгән баскын монголлар дәүләте. Ул дәүләтнең буйсындырылган халкын, шул исәптән болгарларны да, татарлар дип йөртә башлаганнар. Болгарлар, кайбер тарихчылар әйтүенчә, XIV гасыр урталарында килеп чыккан үләт (чума) эпидимиясе вакытында үлеп бетмәгәннәр (күрше мордвалар, марийлар һ.б. халыклар исән калганнар ич), Алтын Урда составында яшәүләрен дәвам иткәннәр.

«Карабәк» романында башлыча XIV гасырның икенче яртысында булып үткән вакыйгалар сурәтләнә. Бик болгавыр заманнар бу, 20 ел эчендә тәхеттә 25 хан алышынган, барыбызга мәктәп елларыннан ук таныш Мамай һәм Туктамыш, Идегәй һәм Аксак Тимер, алар белән янәшә Болгар ханы Габдулла (Карабәк) яшәгән һәм көрәшкән чор. Аларның барысы да илнең таркала баруына борчыла, дәүләтнең бөтенлеге өчен көрәшә, бары тик шул максаттан чыгып кына тәхеткә омтыла кебек. Әмма тәхет бирәү генә, дәгъвачылар күп. Алтын Урданың бердәмлеген саклап калу өчен ихластан көрәшүчеләр арасында Туктамышның «уң кулы» Карабәк тә бар.

Романда сурәтләнгән вакыйгалар шулкадәр ышандыра ки, күп вакыт тарихи дөреслеккә туры киләме алар, килмиме дип уйлап та тормыйсың. Кайта-кайта укыганда гына кайбер төгәлсезлекләргә тап буласың. Шуларның берничәсе турында әйтеп үтмәкче булам. Кызганыч, автор болгарларны бөтенләй юкка чыгарган. Болгар шәһәреннән чыккан кешеләр бар («болгарлылыр»), ә болгарлар, күрәсең, теге чума вакытында кырылып беткәннәрдер – аларны автор бер тапкыр да телгә алмый. Аның каравы, Туктамыш әмере белән Болгар олысын яңадан күтәрү өчен «бушап калган» элеккеге болгар җирләренә кырым татарларын, кыпчак-бәҗәнәкләрне, кыргызларны, тагы әллә кемнәрне күчереп утырта. Берьюлы 14 төмән, ягъни 140 мең яугир (күбесе үзләренең гаиләләре белән!) килеп төпләнә безнең якларга. Соңыннан гаскәриләр саны 200 меңгә җитә. Аларга тагын шул кадәрле үк гаскәр килеп кушылачак әле. Габдулла хан үзе дә кырымлы Гәрәйләр нәселеннән дип күрсәтелә (ә без аны һәм аның Алтынбәк белән Галимбәк атлы улларын болгарлардан дип йөри идек). Без, бүгенге татарлар, шуларның токымнары булабыз инде. Уйланырлык нәрсәләр бар монда. Саннар кеше ышанмаслык дәрәҗәдә артык күпертелгән, минемчә.

Тагын бер төгәлсезлек. Туктамыш хан Болгарга, Карабәк янына килә: «елга буйлап, кораб илә менә», Чулман тамагындагы Айгыр тавын да үтә, «ике тәүлектән соң Ага-Базарга килеп җитүе бар». Соң, елга (Идел) буйлап күтәрелеп, Кама тамагына килеп җиткәч, Болгарны узып киткән була ич инде ул. Каманың Иделгә кушылган җиреннән Болгарга кадәр 30 гына чакрым, аны үтү өчен ике тәүлек кирәк түгел. Шуңа охшаш төгәлсезлек Туктамышка урыс кенәзлекләреннән килгән сугышчыларга бәйле сөйләшүләр барышында киткән: Муром каласыннан Иделгә килеп җиткәнче, ди Рязань кенәзе Алексей, Мукшы урманнары аша узасы бар». Һич алай түгел, мукшылар бит алар Болгардан көньяктарак яшәгәннәр. Туктамышның Болгарда булу-булмавы да – бәхәсле мәсьәлә.

Аннан соң Җидесу ул, искәрмәдә күрсәтелгәнчә, Амударья белән Сырдәрья арасы түгел (бусы аның Мәверәннәхр дип йөртелә) ), ә Балхаш күле белән хәзерге Алматы шәһәре арасындагы артык зур булмаган бер өлкә.

«Карабәк» романы моңарчы тарихи шәхесләр булып торган ике каһарманны яңача тасвирлый, яңача бәяли. Без өйрәнгән тарих дәреслекләрендә Куликово кырында хурлыклы рәвештә җиңелгән Мамай мирза романда чын-чынлап милли каһарман буларак сурәтләнә, ә дастаннарда да җырланган Идегәй мирза хыянәтче итеп күрсәтелә. Гәрчә Р. Фәхретдин дә Идегәйне мөртәт дип атый. Вахит Имамов бу яңа бәяләмәсе белән тарихи әдәбиятка, чыннан да, яңалык алып килә бит. Тарихчылар әлеге яңалыкны кабул итәме?

Мин үзем бу очракта күбрәк «Карабәк» авторы яклы. Соңгы елларда Идегәйне бик нык күтәрдек. Алтын

Урданың таркалуында аның да саллы гына өлеше бар, һәм моны безгә таныргa кирәк. Чынлап торып карасаң, патшаларның бөтенесе бер иш инде – тәхеткә утырып, үз мәнфәгатьләрен кайгыртучылар. Әлбәттә, тәхеткә утыргач, илең турында да уйларга мәҗбүрсең. Патшаларны идеаллаштыру ягында түгел мин. Әкиятләрдә генә була андый патшалар.

«Карабаәк» романында үзебезнең Идел-Чулман төбәгендә яшәүчеләрнең тормышы шактый тыгыз яктыртылган. Биредәге таулар, елгалар, кала-салаларның атамалары да, каһарманнарның шәҗәрәләренә кадәр «ачып бирү» дә бар. Болар, әлбәттә, әдипнең җитди эзләнүләре нәтиҗәсе бит. Монда чамалау, фаразлау гына була алмыйдыр.

Вахит Имамов – үзе яза торган чорның тарихын тирәннән өйрәнгән әдип. Мин моны, аның әсәрләрен даими укып баручы кеше буларак, ышанып әйтәм. Әдәби әсәр язу фәнни хезмәт язу түгел, әлбәттә. Әмма барыбер тарихи романдагы вакыйгалар һәм аларны тудыручы шәхесләр күпсанлы һәм төрле характердагы чыганакларда, шул исәптән, архив документларында сакланып калган фактларга нигезләнеп тасвирланган бит. Кызганыч, барлык фактлар да елъязмаларга теркәлеп калмаган, бу очракта инде аларны аңлатканда фаразлау ысулын да кулланмыйча булмый. Аңлашыла ки, язучылар бу ысулны тарихчы-галимнәргә караганда күбрәк файдалана.

Әйдәгез, романның әдәбилегенә дә тукталыйк әле. Миңа калса, Вахит Имамов фольклорчы буларак та ачыла кебек. Халыкчан тел, мәкаль-әйтемнәр, риваятьләр күп кулланыла. Романдагы вакыйгалар тыгызлыгы берничә романга җитәрлек түгелме?

Сез хаклы. Романның сәнгатьчә эшләнеше дә тел-теш тидерерлек түгел дип саныйм мин. Әйе, халык мәкальләре, әйтемнәр, риваять-легендалар күп һәм бик урынлы кулланылган биредә. Әмма «мәгарәдәй сузылган тынлык», «келәм кебек йомшак, нәфис су һәм аның хәтфә суыклыгы», «чыбыркысын шартлатып малларын кузгаткан көтүченеке төсле яңа фәрман», «түшенә салган чәч толымнарының кар астыннан типкән чишмәләрдәй уянып сулкылдавы» кебек чагыштыруларны уңышлы дип әйтмәс идем. Тагын бер нәрсә. Вахит Имамов, яшь кызлар турында сүз кузгатуга аларның бөтен матурлыгын, нәфислеген укучыда эротик хисләр уятырлык дәрәҗәдә җентекләп тасвирларга ярата. Кайчакта хәтта, артык мавыгып, әйтеләсе төп фикерен дә онытып җибәрә. Начар димим, әлбәттә, ә менә кайсы яшьтән башлап укырга рөхсәт итәрләр икән бу романны? Болай да тар укучылар даирәсен тагын да тарайтмасмы әлеге эротик күренешләр, дип кенә шикләнүем.

*«Алтын Урда» дәүләте... Бу темага күпләр алынып карады: Александр Сегеньның «Тамерлан»ы, Анатолий Егинның «Үзбәк хан» романнары. Евразия киңлекләрендәге дәүләттә безнең борынгы бабаларыбыз көн иткән. Хәзерге Европа киңлегендә, Рәсәй дәүләтендә дә безнең кардәшләребез*

*яши. Бу халыкларның язмышын ни көтә? Халыкларны берләштерү зарурмы бүген?*

Алтын Урда күпмилләтле дәүләт булган, яшәү гомеренең озынлыгы 200 елдан артык. Шул вакыт эчендә яңа халыклар формалашкан (мәсәлән, нугайлар, кырым татарлары), булганнары исә юкка чыкмаган, исемнәрен алыштырып булса да яшәүләрен дәвам иткәннәр (кыпчаклар, болгар-татарлар). Алтын Урда цивилизациясе – борынгы тарихыбызның олы бер чоры. Ул тарихны әле тагын да тирәнрәк итеп өйрәнәсе бар. Әмма шул чор белән артык мавыкмыйча гына. Халкыбызның тарихы күптамырлы – шуны онытмаска кирәк. Милләтебезнең киләчәген билгеләүдә тарихи хәтер зур урын алып тора. Вахит Имамов, үзенең элгәреге һәм бүгенге каләмдәшләре кебек, шул хәтерне саклауга зур өлеш кертә.

*Казан утлары. 2017. № 10. Б. 120–133.*




## ИДЕЛ БОЛГАРЛАРЫ ТАРИХЫ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАП: Георги Владимиров. Великата България на Волга през средните векове. София: Просвета, 2019. 170 с.

Казан археологлары инде узган гасырның җитмешенче елларыннан башлап ук үзләренең коллегалары – Болгария галимнәре белән тыгыз элемтәдә торып эшлиләр. Әлеге хезмәттәшлеккә безнең яктан күренекле галимебез профессор Альфред Хәсән улы Халиков, болгарлар ягыннан профессор Димитр Димитров белән аның шәкерте Рашо Рашев нигез салдылар. Европаның урта гасырлар чоры тарихында күренекле урын тоткан борынгы болгарлар – уртак бабаларыбыз тарихын өйрәнүдә Болгария һәм Татарстан галимнәренең бергәләп эшләргә омтылуы табигый күренеш иде. Д. Димитровның элгәреге болгарлар археологиясенә багышланган китабында аның 1976 елда Татарстанга килеп өйрәнеп киткән Олы Тархан каберлеге материаллары да киң кулланылган иде (Димитров, 1987; Халиков, 1988). Соңрак әлеге теманы Р. Рашев тагын да тирәнрәк һәм киңрәк планда тикшерде (Хузин, 2011, с. 283–286) һәм, әйтергә кирәк, А.Х. Халиковның да теләген-үтенечен истә тотып, Болгариянең беренче башкаласы атаклы Плиска территориясендә казу эшләрен башлап җибәрде, шул ук вакытта Биләр, Болгар истәлекләрен өйрәнүче Казан археологлары белән элемтәләрен беркайчан да өзмәде (Рашев, 1998; 2001; 2004; 2006; 2007 һ.б.).

А.Х. Халиков – гомеренең күп өлешен фин-угыр археологиясенә багышлаган галим. Әмма ул болгар археологиясе өлкәсендә дә уңышлы эшләп килде, Олы Тархан, Танкеевка каберлекләрен, Биләр, борынгы

Казан, Алабуга калаларын өйрәнеп, Идел болгарлары тарихын дөньякүләм танытуга зур өлеш кертте. Табигый ки, Татарстан галимнәренең болгар археологиясендәге яңа ачышлары Болгариядәге коллегаларыбызның игътибарыннан читтә калмады. А.Х. Халиковның Болгариядә чыга торган фәнни басмаларда дөнья күргән мәкаләләре (Халиков,1981; 1981а; 1982; 1983; 1988; 1988а; 1989) шул кызыксынуның бер чагылышы иде.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: нәкъ менә Альфред Хәсән улының Мәскәү галимнәре тарафыннан хупланган башлангычы белән Болгария һәм элеккеге Советлар Берлеге галимнәре катнашында болгар археологиясенә багышланган халыкара симпозиумнар, конференцияләр үткәрү традициягә кереп китте. 1976 елда Болгария Фәннәр академиясенең Шумен шәһәрендә үткән конференциядә Казаннан гына да А.Х. Халиков, Т.А. Хлебникова, Е.П. Казаков, Е.А. Халикова, П.Н. Старостин кебек олуг галимнәр катнашкан иде. Шундый конференцияләрнең тагын берсе, миңа калса, иң истәлеклесе – «Болгар цивилизациясенең чишмә башы, тарихи үсеше һәм мәдәни мирас» дип аталган IV Халыкара форум – 2012 елның октябрендә Болгариянең Варна шәһәрендә уздырылды. Әлеге форум «Bulgarica. Время и пространство Болгарской цивилизации» дигән фундаменталь хезмәтнең киң фәнни җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителүе һәм бу чараларда Татарстанның Дәүләт киңәшчесе М.Ш. Шәймиев һәм Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә.М. Мазһаровның да катнашуы белән фән дөньясында мөһим вакыйга буларак кабул ителде (Владимиров, Ситдиков, Хузин, 2013).

Әлеге чаралар урта гасырлар тарихының һәм археологиясенең Дунай һәм Идел болгарлары арасындагы бәйләнеш проблемаларын өйрәнүне тагын да җанландырып җибәрде. Болгариядә чыга торган фәнни журналларда, җыентыкларда В. Йотов, П. Георгиев, Б. Борисов, Г. Владимиров, Л. Дончева-Петкова кебек галимнәрнең мәкаләләре ешрак күренә башлады. Санап үтелгән галимнәр арасыннан мин Георги Владимиров хезмәтләренә аерым тукталып үтәргә телим.

Г. Владимиров Болгария мәдәният министрлыгында фән секторын җитәкли. Без исә аны күбрәк Идел һәм Дунай болгарларының урта гасырлар тарихын чагыштырма планда өйрәнүче талантлы галим буларак беләбез. Аның күпсанлы мәкаләләрен һәм «Дунавска България през VII–XI век» (София, 2005), «Казанското ханство» (София, 2005), «Волжка България и Казанското ханство: строително изкуство и архитектура» (София, 2006) исемле китапларын республикабызның фәнни җәмәгатьчелеге, беренче чиратта, әлбәттә, археологлар, Казанның 1000 еллык юбилеена багышланган олы бүләк рәвешендә кабул итте. Г. Владимировның Идел Болгары һәм Казан ханлыгы тарихына багышланган башка китаплары да бар (Владимиров, 2007; 2011). Шушы китаплар сериясеннән мин аның «Волжка и

Дунавска България. Формиране и промяна на културните модели. VII–XI век» дигән монографиясен аерым атап үтәр идем, чөнки ул Болгария һәм Татарстан галимнәре арасында урнашкан хезмәттәшлекнең яңа этабын башлап җибәрүгә этәргеч бирде (Владимиров, 2005б; Хузин, 2007).

Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты 2018 елда Г. Владимиовның «Серьги в виде знака вопроса из средневековой Болгарии (XIII–XIV вв.)» исемле монографиясен бастырып чыгарды. 2019 елда Софиянең «Просвета» нәшриятында аның тагын бер китабы дөнья күрде. Ул «Великата България на Волга през средните векове» дип атала. Миңа калса, бик үзенчәлекле китап бу. Минем игътибарымны шул үзенчәлекләр җәлеп иттеләр дә инде.

Беренчедән, китап тарих белән кызыксынучы киң катлам укучыларга, иң әүвәл югары сыйныфларда укучы мәктәп балаларына һәм аларның укытучыларына, шул ук вакытта тарихчы галимнәргә, музей хезмәткәрләренә дә тәгаенләнгән. Теле – матур, шома, җөмләләре – кыска, фикерләр – тирән. Бәхәсле мәсьәләләр читләтеп үтелми, авторның үз фикере язма һәм археологик чыганаклар белән ныгытылып китерелә. Күрәсез, автор тарафыннан кыю адым ясалган – бүгенге болгарлар, бигрәк тә яшь буын, Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң, Аспарух төркеменнән аерылып, Урта Иделгә килеп төпләнгән ерак кардәшләренең тарихын да белергә тиеш. Безнең галимнәр өчен дә үрнәк адым бу, минемчә.

Икенчедән, китап матур итеп төсле рәсемнәр, фотолар белән бизәлгән; ул рәсемнәрнең шактый өлеше нәшрият заказы белән китап өчен махсус эшләнгән, икенче өлеше исә рәссамнәрнең инде безгә мәгълүм әсәрләреннән җентекләп сайлап алынган. Бу нәрсәгә басым ясап әйтүемнең сәбәбе шул: бездә татар тарихыннан фәнни-популяр китаплар чыгарганда автор заказы буенча текстка, ягъни эчтәлеккә туры килерлек иллюстрацияләр ясап мәшәкатьләнмиләр, булганыннан файдаланырга туры килә. Шунлыктан Рушан Шәмсетдинов, Фиринат Халиков, Равил Заһидуллиннарның күбесенчә бер үк темага язылган рәсемнәре китаптан китапка күчеп йөри.

Өченчедән, китапның кушымталар бүлегендә (117–154 бб.) гади укучылар өчен кызыклы һәм алдагы бүлекләрдә бирелгән факт-вакыйгаларны тагын да төплерәк итеп үзләштерергә исәпләнгән язма чыганаклар, татар риваятьләре һәм легендалары, Идел – Дунай болгарлары тарихындагы вакыйгаларны чагыштырып карарга уңайлы хронологик таблица урнаштырылган.

Хәзер китапның эчтәлегенә күз төшерик.

Ул болгар тарихын чагылдырган язма чыганакларга, археология, нумизматика материалларына һәм Болгария галимнәренең Идел Болгары тарихын яктырткан, дөресрәге, аз гына булса да искә алып киткән

хезмәтләренә күзәтү белән башланып китә (11–21 бб.).

Болгарларның дәүләтчелек тарихын Г. Владимиров хаклы рәвештә Кубрат хан оештырган Бөек Болгариядән («Старата Велика България») башлап җибәрә. Барлыгы 30–40 ел чамасы гына яшәп калган бу дәүләтнең тарихы, табигый ки, һаман да әле җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, чөнки язма чыганаклар аз сакланган, археология материаллары башлыча Азов-Кара диңгез буе далаларына сибелеп урнашкан аерым каберлекләрдән генә гыйбәрәт. Шулай да укучы болгарларның беренче дәүләте турында ярыйсы гына мәгълүмат ала һәм Кубрат ханны соңрак Дунайда һәм Идел буенда калкып чыккан дәүләтләрнең идарәче династияләрен нигезләүче шәхес сыйфатында кабул итә (22–27 бб).

Бүген Урта Идел бассейнында яшәүче халыкларның ерак тарихы таш, бронза, элгәреге тимер гасырларын – якынча 70 меңь еллык дәверне үз эченә ала. Төбәкнең этник картасындагы кискен үзгәрешләр «Халыкларның бөек күчеше» дип аталган чор белән бәйләнгән. Г. Владимиров бу чорны хаклы рәвештә һуннардан башлап җибәрә, шул чорда барлыкка килеп, Төрк каһанлыгы чорында үсеш алган Имәнкискә һәм Кушнаренко кабиләләренең этник йөзе турында үз фикерләре белән уртаклаша. Кушнаренко кабиләләрен галимнәр угыр телле булган дип язалар, ягъни алар – борынгы венгрлар (протовенгрлар), Имәнкискә кабиләләренең этник йөзе әлегә кадәр ачыкланмаган (төркләр? славяннар? балтлар? сарматлар? готлар?). «Хәер, бу безнең өчен артык мөһим дә түгел, – дип яза Г. Владимиров, – бу очракта безгә Урта Идел халкының әле болгарлар килгәнче үк күп милләтле булуын күрсәтеп үтәргә кирәк» (32 б.).

Элгәреге болгарларның Урта Иделгә күчеп утыруларын Г. Влади-миров 660-нчы елларда Кубрат хан дәүләтенең таркалуы белән бәйли. Элегрәк һәм кайберәүләр әле хәзер дә бу күчешне 737 елгы Гарәп-Хәзәр сугышлары нәтиҗәсе итеп кабул итәләр иде. Галим узган гасырның сиксәненче елларында хәзерге Самара һәм Ульян өлкәләрендә ачылган Новиньково тибындагы каберлекләрне төрки телле халыклар калдырган һәм алар арасында, һичшиксез, болгарлар да булган, дигән фикерне дәлилли (33 б.).

Китапның алдагы бүлекләре тулысы белән диярлек Идед Болгары тарихына багышланган. Биредә укучы Болгар дәүләтенең биләмәләре, халкы һәм аның ислам динен кабул итүе (37–44 бб.), Болгар-Русь хәрби-сәяси мөнәсәбәтләре турында нигездә язма чыганакларга таянып бәян ителгән реаль фактлар белән таныша ала (45–53 бб.). Болгар – Русь хәрби-сәяси мөнәсәбәтләрен тикшергәндә Г. Владимиров болгарлар үткәрә торган сәясәтнең үз-үзләрен саклау – оборона юнәлешендә булуына игътибар итә (50 б.). Бу уңайдан беренче рус тарихчысы В.Н. Татищев сүзләре искә төшә: «... болгаре хотя некогда с русскими воевались, однако ж видно, что немного о том прилежали и не

искали чужаго преобрести, но свое паче засчисчать старались» (Татищев, 1962, с. 269).

Болгар шәһәрләре һәм шәһәр архитектурасы – галимнең яратып тикшеро торган темасы. Бу теманы яктыртканда Г. Владимиров еш кына Дунай Болгариясе шәһәрләренә дә күз ташлый һәм соңгыларының архитектурасына Византия империясенең йогынтысын ассызыклап күрсәтә. «Болгар калалары исә нигездә буш урында барлыкка килгәннәр һәм аларның топографик структурасында күчмәннәр традициясе, ә архитектурасында Шәрык архитектурасы йогынтысы сизелә», – дип билгеләп үтә автор (55 б.; шулай ук карагыз: Владимиров, 2002, 19–21 бб.). Үз чиратыбызда, Р. Рашев тикшеренүләренә таянып (Рашев, Дочева, 1989), Дунай болгарларының беренче башкаласы Плиска архитектурасында да күчмәннәрдән килгән традицияләрнең бик ачык чагылышын искәртеп үтәргә тиешбез.

Китапның соңгы бүлекләрендә (63–91 бб.) сүз Идел болгарларының икътисадына (сүз күбрәк авыл хуҗалыгы – игенчелек һәм терлекчелек, шулай ук шәһәр һөнәрчелеге һәм сәүдә турында бара), көндәлек тормышка һәм мәдәният үсешенә караган материаллар бирелгән. Г. Владимиров Идел Болгарын икътисад һәм мәдәният үсеше ягыннан караганда күрше Киев Русе һәм рус кенәзлекләре белән бер дәрәҗәдә торган дәүләт буларак ассызыклый. Биләр каласында туып үскән һәм шунда ук монгол-татарлар явы вакытында соңгы сулышын алган Кол Гали иҗатын, төгәлрәк әйткәндә, аның «Кыйсса-и Йосыф» поэмасын урта гасырлар дөнья мәдәниятенең иң күренекле әсәрләре рәтенә куеп бәяли.

Г. Владимиров фикеренчә, болгарларның монгол-татар яуларына кадәр үк шактый югары үскән икътисады һәм мәдәнияте Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында да төшенкелек кичерми, алгарышлы үсешен дәвам итә. Болгар халкы XIII–XIV гасырларда булып узган глобаль характердагы сәяси үзгәрешләр чорында да үз йөзен, традицион яшәү рәвешен югатмый, ата-бабалар мирасын саклап, татарлар исеме белән бүгенге көннәргә кадәр килеп җитә, дип йомгаклый автор үзенең укучыларына җиткерәсе фикерен.

Әлеге китапта әлләни ачышлар да юк кебек, ул фәндә күптән билгеле тарихи чыганаклар, Россия һәм Татарстан галимнәренең совет чорында һәм соңгы елларда чыккан күпсанлы фәнни хезмәтләре нигезендә язылган. Әмма бу очракта Георги Владимировның максаты ачыш ясау түгел, бәлки киң болгар җәмәгатьчелеген, беренче нәүбәттә мәктәп укучыларын, укытучыларны алар өчен әлегә ятрак, серлерәк, әмма бер тамырдан чыккан Идел болгарларының, ягъни безнең, татарларның, борынгы бабалары тарихы белән таныштыру. Һәм автор, һичшиксез, үз максатына ирешкән дип әйтә алабыз.

**Файдаланылган әдәбият**

*Владимиров Г.* Столичен град в културата на Волжка България // Български векове. 2002. № 4. С. 13–21.

*Владимиров Г.* Дунавска България през VII–XI век. София, 2005.

*Владимиров Г.* Казанското ханство: история, икономика, култура. София, 2005а. 112 с.

*Владимиров Г.* Волжка и Дунавска България. Формиране и промяна на културните модели. VII–XI век. София, 2005б. 158 с.

*Владимиров Г.* Волжка България и Казанското ханство: строително изкуство и архитектура. София: ТАНГРА ТанНакРаИК, 2006. 89 с.

*Владимиров Г.* Волжка България и Казанското ханство в географическите карти на Средневековиете и Новато време. София, 2007. 86 с.

*Владимиров Г.* Волжка България и Казанското ханство: предания и легенди на народите на Средна Волга. Пловдив, 2011. 78 с.

*Владимиров Г.* Серьги в виде знака вопроса из средневековой Болгарии (XIII–XIV вв.): о материальных следах куманов и Золотой Орды в культуре Второго Болгарского царства. Казань: Ин-т археологии им. А.Х. Халикова АН РТ, 2018. 139 с.

*Владимиров Г., Ситдиков А.Г., Хузин Ф.Ш.* IV Международный Болгарский форум «Истоки, историческое развитие и культурное наследие Болгарской цивилизации». (Варна, Болгария, 22–25 октября 2012 г.) // Поволжская археология. 2013. № 1 (3). С. 232–237.

*Димитров Д.* Прабългарите по Северното и Западното Черноморие. (Към въпроса за тяхното присъствие и история в днешните руски земи и ролята им при образуването на Българската държава. Варна: Изд-во «Георги Бакалов», 1987. 304 с.

*Рашев Р.* О возможности выделения самых ранних археологических памятников в степях Восточной Европы // Татарская археология. 1998. № 2. С. 65–72.

*Рашев Р.* Водные пути Дунайской Болгарии в эпоху средневековья и проблемы связей с Волжской Булгарией // Великий Волжский путь. Материалы Круглого стола и Международ. семинара / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: Мастер Лайн, 2001. С. 224–234.

*Рашев Р.* Прабългарите през V–VII век. Изд. 2-е, доп. София, 2004. 348 с.

*Рашев Р.* Великая Болгария. Первое Болгарское царство на Дунае // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. 2. Волжская Булгария и Великая степь / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: РухИЛ, 2006. С. 36–59.

*Рашев Р.* Праболгары на юго-западной окраине евразийской степи // Средневековая археология евразийских степей. Материалы Учредит. съезда Международ. конгресса. Т. 1 / Отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2007. С. 104–117.

*Рашев Р., Дочева В.* Юртообразен постройка в Плиска // Проблеми на прабългарската история и култура. Вып. 2. София, 1989. С. 291–313.

*Татищев В.Н.* История Российская. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1962. Т. 1. 500 с.

*Халиков А.* Към въпроса за археологическите извори на културата на прабългарите // Проблеми на културата. Кн. 4 / Отгов. ред. Р. Рашев. София, 1981. С. 9–15.

*Халиков А.* Изучение археологической культуры ранних болгар на Волге // Плиска – Преслав. Кн. 2. Прабългарската култура. Материали от българо-съветската среща, Шумен, 1976 / Отгов. ред. Дм. Ангелов. София: Изд-во. БАН, 1981а. С. 36–42.

*Халиков А.* Культурно-исторические связи между Дунайской и Волжской Булгариями // Международ. конгресс праболгаристики. София, 1982. С. 381–387.

*Халиков А.Х.* Семеновский клад железных изделий // Плиска – Преслав. Кн. 3 / Отгов. ред. Р. Рашев. Шумен, 1983. С. 254–261.

*Халиков А.* Рец.: Дм. Димитров. Прабългарите по Северното и Западното Черноморие. (Към въпроса за тяхното присъствие и история в днешните руски земи и ролята им при образуването на Българската държава. Варна: Изд-во «Георги Бакалов», 1987 // Исторически преглед. 1988. Кн. 5. С. 85–88.

*Халиков А.Х.* Булгарская руника в Среднем Поволжье // Археология (София). 1988а. № 2. С. 36–48.

*Халиков А.Х.* Протоболгары и протовенгры в Среднем Поволжье и Нижнем Прикамье // Проблеми на прабългарската история и култура / Отгов. ред. Р. Рашев. София, 1989. С. 55–65.

*Хузин Ф.* Ново за двете Българии: Волжска и Дунавска (рец. на: Г. Владимиров. Волжска и Дунавска България. Формиране и промяна на културните модели (VII–XI в.). София: Изд-во «Орбел», 2005) // Исторически преглед. 2007. № 1–2. С. 232–235.

*Хузин Ф.Ш.* Выдающийся исследователь археологии и истории дунайских болгар: профессор Рашо Рашев // Хузин Ф.Ш. Исследования по булгаро-татарской археологии. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2011. С. 283–286.

*Фәнни Татарстан. 2020. № 4 (28). Б. 167–172.*




## КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ МӘШҺҮР ХАТЫННАРЫ ТУРЫНДА РОМАН-ТРИЛОГИЯ

(Ольга Иванова. Повелительницы Казани. Нурсолтан. Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. 495 с.; Повелительницы Казани. Гаухаршад. Казань: Татар. кн. изд-во, 2019. 382 с.; Повелительницы Казани. Сююмбика. Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. 471 с.)

Рус телендә язып иҗат итүче Ольга Иванова исеме бүгенге татар әдәбияты дөньясында соңгы елларда гына яңгырый башлады. Аның «Повелительницы Казани» сериясеннән «Нурсолтан» исемле беренче китабы Казанның «Эксклюзив» нәшриятында 2002 елда ук басылып чыккан иде. Язучының үз акчасына нәшир ителгән ул китабы, шактый гына (3 мең данә) тиражы булуга карамастан, кибетләрдә сатылмады, укучылар кулына таныш-белешләре аша гына килеп керде, шуңа күрә, авторның исеме дә күпләр өчен билгесез булып кала бирде. «Нурсолтан»ның кайбер бүлекләре «Казанский альманах» җыентыгында һәм, татарчага тәрҗемә ителеп, «Безнең мирас» журналында басылдылар. 2017 елда Татарстан китап нәшрияты әлеге китапның икенче басмасын, 2019 һәм 2020 елларда исә шул ук сериядән «Гәүһәршад» һәм «Сөембикә» исемле яңа китапларын дөньяга чыгарды.

Мәгълүм булганча, узган гасырның туксанынчы елларына кадәр, ягъни илдә совет идеологиясе хөкем сөргән чорда, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы тарихы белән иркенләп шөгыльләнергә мөмкинлек булмады. Хәзер исә андый мөмкинлекләр бар, әмма татар тарихын урта мәктәпләрдә укытуга чик куелды. Гло-

бальләшү шартларында милләтебезне юкка чыгудан саклап калуда, ана телен белмәүче татарларның милли үзаңын үстерүдә тарих фәненең роле арта бара. Соңгы елларда Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, А.Х. Халиков исемендәге Археология институты, Татар энциклопедиясе һәм төбәкләр тарихы институты һәм Казан федераль университеты галимнәре татар тарихының төрле чорларына караган күпсанлы хезмәтләр бастырып чыгардылар. Татарлар – укымышлы халык, фәнни әдәбиятны да үз итәләр, укып баралар, әмма аларның күбесе барыбер авыр тел белән язылган, коры фактлардан гына торган монографияләрне түгел, бәлки фәнни-популяр китапларны, бигрәк тә профессиональ язучыларның тарихи романнарын якынрак күрә.

Шөкер, язучыларыбыз ялган тарихтан туйган, дөреслеккә сусаган татар укучыларының ихтыяҗларын тиз аңлап алдылар. Әдәбиятыбызнын тарихи романнар жанрына караган өлкәсе чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә татарларның борынгы төркиләр һәм болгарлар чорыннан башланып киткән тарихын чагылдырган әсәрләр белән баетылды. Казан ханлыгында булып үткән катлаулы вакыйгаларга, дәүләтнең күренекле шәхесләренә багышланган әсәрләр – Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», Рабит Батулланың «Сөембикә», Флүс Латыйфиның «Хыянәт», Марат Әмирхановның «Олуг Мөхәммәд», «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг», Вахит Имамовның «Сөләйман солтан», Нурулла Гарифның «Мәмеш Бирде» исемле романнары һәм тарихи кыйссалары укучылар арасында аеруча популярлык казанды.

Ольга Иванованың «Повелительницы Казани» трилогиясенә кергән өч романы турында сүз башлаганчы, кыскача гына аның үзе белән таныштырып үтим. Ул чыгышы белән Себердән – Кемерово өлкәсенең Новокузнецк шәһәрендә туган. Әнисе – татар, этисе – украинлы. Тиздән аларның гаиләсе Сочига, күп тә үтми, 1982 елда, Казанга күчеп килә. Биредә Ольга урта мәктәпне тәмамлый, югары белем ала, бухгалтерлык эшенә өйрәнә, экономист профессиясен үзләштерә. Белеме һәм кызыксыну даирәсе буенча гуманитар фәннәрдән, филологиядән ерак торган кыз татар тарихы белән очраклы рәвештә кызыксына башлый – кулына килеп кергән бер газетада Казан ханбикәләре турында мәкалә басылган була. Үзендә дә татар каны ага ич – ерак бабалары белән ныклап кызыксына башлый. Унбиш ел чамасы, берөзлексез диярлек, аз гына вакыты булдымы, Милли китапханәгә чаба, дәфтәренә Казан ханлыгын караган факт-вакыйгаларны теркәп бара. Әкренләп аның күңелендә китап язу теләге уяна. Җыелган материалларны яңадан бер тапкыр күңеленнән үткәрә, җентекләп анализлый, чагыштыра һәм тәвәккәлләп кулына каләм ала. Ярты елдан да кимрәк вакыт эчендә Нур-

солтанга багышланган беренче китап әзер була.

Ул китапларны мин бик кызыксынып, әйтергә кирәк, ниндидер бер ләззәт белән, башта гади бер укучы, икенче тапкырында профессиональ тарихчы күзлегеннән карап укып чыктым. Беренче тапкыр укыганда мине иң шаккаттырганы – әсәрнең югары дәрәҗәдә сәнгатьчә эшләнеше иде. Авторның үз стиле: җөмләләре төзек, музыкаль яңгырашлы; сюжет сызыклары катлаулы, әмма укыганда «адашырлык» түгел, әсәрнең эчтәлегенә туры килеп тора, бер максатка буйсындырылган. Еш кулланудан таушалып беткән эпитетлар, чагыштырулар, метафоралар юк – Ольга Иванова каләменә генә хас сурәтләү чаралары. Образларның характеры, хәтта эпизодик күренешләрдә чагылып китүчеләрнеке дә, киемнәре, хәрәкәтләре, сөйләшү манералары аша тулысынча ачылган дияргә мөмкин. Автор – менә дигән психолог һәм аның шул сыйфаты образларның эчке халәтен аңларга, кылган гамәлләренең асылына төшенергә ярдәм итә. Әйтергә кирәк, психологик тирәнлек һәм сәнгатьчә камиллек трилогиянең өч китабы өчен дә хас. Әсәрне укудан тукталуы кыен, ул уйландыра, нәфрәтләндерә, берүк вакытта ерак бабаларыбыз тарихы белән горурлану хисләре дә уята.

Хәзер трилогиягә кергән әсәрләргә тарихчы күзлегеннән карыйк. Бу җәһәттән мине тагын бер нәрсә шаккаттырды – язучы ханымның Евразиянең Казан ханлыгы чоры белән бәйләнгән урта гасырлар тарихын тирән үзләштергән булуы. Беренче чиратта мин аның шул чорлардан сакланып калган язма чыганакларны, архив материалларын яхшы белүенә басым ясап үтәр идем. Ул чыганаклар арасында рус елъязмалары, билгесез авторның «Казан тарихы» («Казанский летописец»), хан ярлыклары, дәүләт идарәчеләре арасында йөргән хатлар, чит ил дипломатлары калдырган истәлекләр (мәсәлән, Австрия илчесе С. Герберштейн язмалары), сәяхәтнамәләр һәм башка төрле документлар бар. Халык авыз иҗаты әсәрләреннән риваять-легендалар, мәкаль-әйтемнәр һәм дә мәшһүр Шәрык шагыйрләре Фирдәүси, Җами, Гомәр Хәйям, Низами, Нәваи, болгар-татар шагыйрьләре Кол Гали һәм Мөхәммәдьяр поэмаларыннан өзекләр бик урынлы кулланылган.

Ольга Иванова шул заман халыкларының этнографиясеннән дә киң мәгълүмат туплаган. Әсәрдә югары катлау вәкилләренең һәм гади халыкның, картларның һәм яшьләрнең, сугышчыларның һәм сәүдәгәрләрнең киемнәре, аш-су төрләре, көнкүреш әйберләре, эш һәм сугыш кораллары, гади йортларның һәм хан сарайларының эчке һәм тышкы күренешләре – барысы да дөрес тасвирланган һәм бу, беренче карашка «вак-төяк» детальләр, укучыны шул чор атмосферасына җиңел генә кереп китәргә, әсәр геройлары белән бергә яшәргә, хәрәкәт итәргә ярдәм итә.

Табигый ки, Ольга Иванова Казан ханлыгын гына түгел, Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән

башка дәүләтләр тарихын да җентекләп өйрәнгән. Миңа калса, аның язучылык эшенә керешүенең төп сәбәбе дә фәнни әдәбият белән танышканнан соң туган фикерләр, уй-кичерешләр, ә кайчакта теге яисә бу авторның фикерләре белә килешмәүдән килеп туган канәгатьсезлек хисләре булгандыр. Чыннан да, алып карагыз атаклы рус тарихчылары В.Н. Татищев, С.М. Соловьев, В.О. Ключевский, үзебезнең М.Г. Худяков, М.Г. Сәфәргалиев, Н.Ф. Калинин, А.Х. Халиков, С.Х. Алишев һәм, ниһаять, бүгене көн тарихчыларының хезмәтләрен. Күпме көч куйган әлеге галимнәр Казан ханлыгының бер гасырдан аз гына артыграк гомере эчендә тупланган серләрен ачуга?! Бер-берсенә каршы килә торган күпме фикер-фаразлар әйтелгән?! Ә сораулар кала бирә, серләр һаман да җиңел генә ачылырга җыенмый – аларның күбесе ханлык архивының тулысынча юкка чыгуы сәбәпле барлыкка килгән. Тарихыбызның Сөембикә, Нурсолтан һәм Гәүһәршад белән бәйле сәхифәләрен исегезгә төшерегез! Алар бит, документлардан күренгәнчә, ханнар алып бара торган сәясәтне читтән генә күзәтеп торучы назлы ханымнар түгел, шул сәясәттә актив катнашучылар да! Нишләп алар турында бик аз беләбез? Әйе, чыганаклар аз, әмма моның белән акланырга ярамый. Булганын тәфсилләп өйрәнергә кирәк! Менә шул теләк-омтылыш, минемчә, язучы Ольга Ивановны Казан ханбикәләренең дәүләт идарәсендә тоткан урынын калкурак итеп, әмма чынбарлыкка булдыра алганча хилафлык китермичә күрсәтергә этәргәндер.

Әлеге максатка ирешүнең төрле юллары бар. Өч ханбикәне бер китапка да «сыйдырып» бетерергә мөмкин иде, югыйсә. Автор башка юлны, минемчә, иң дөрес юлны сайлаган. Һәм бу аңлашыла да. Казан ханбикәләренең бөтен тормышы, гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам иткән сәяси эшчәнлеге Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән Казан, Касыйм, Кырым, Әстерхан, Себер ханлыклары һәм Нугай Урдасы белән бәйләнгән. Әлеге дәүләтләр исә үз чиратында Мәскәү Русе, Бөек Литва кенәзлеге, Төркия (Госманлы империясе) һәм Византия белән тыгыз мөнәсәбәттә торганнар. Ольга Иванова шул дәүләтләрнең тарихын да яхшылап өйрәнгән, аларның идарәчеләре алып барган тышкы сәясәтне җиңел генә һәм бик оста итеп безнең ханбикәләр белән бәйле тарихи вакыйгаларга тоташтырып куйган, фактларны бер җепкә тезеп, бер төенгә бәйләп күрсәтә алган. Боларның барысы да трилогия авторын укучылар алдына киң эрудицияле галимә буларак күз алдына китереп бастыралар.

Кыскача гына трилогиянең беренче китабын тәшкил иткән «Нурсолтан»га тукталып үтик. Нурсолтан – Ногай далаларында туып-үскән кыз. Унҗиде яшьләр тирәсендә аны Казан ханы Хәлилгә кияүгә бирәләр. Хәлил ханлык белән озак идарә итә алмый, 1467 елда яшьли гүр иясе була. Тол калган Нурсолтанны, борынгыдан килгән йола буенча, Хәлилнең энесе

Ибраһим хан үзенә икенче хатынлыкка ала (беренче хатыны Фатыйма-солтан шулай ук ногай кызы була). Бу никахтан аларның Мөхәммәдәмин, Габделлатыйф исемле уллары һәм Гәүһәршад исемле кызлары дөньяга килә. 1479 елда Ибраһим хан, яшь кенә балаларын – ятим, хатынын тол калдырып, якты дөнья белән хушлаша. Мәрхүмнең өлкән хатыны Фатыйма-солтан Казанда кала, чөнки улы Илһамны әтисе урынына хан тәхетенә утыртып куялар. Нурсолтанны Кырым ханы Миңлегәрәй үзенә хатынлыкка сорый – ул бу чибәр һәм акыллы хатынны кыз чагыннан ук белгән була инде. Нурсолтан ризалыгын бирә һәм яңа гына ун яшен тутырган Мөхәммәдәминне Мәскәүгә, Иван III хозурына озатып, үзе төпчек улы Габделлатыйф һәм сабые Гәүһәршад белән Кырымга китеп бара.

Миңлегәрәйнең Нурсолтанга кадәр дә хатыннары булган, әлбәттә, әмма нәкъ менә Нурсолтан тиз арада Кырым ханының иң дәрәҗәле һәм сөекле хатынына әверелеп китә. Миңлегәрәй күзлегеннән чыгып караганда, Нурсолтан Казан ханлыгын һәм Ногай Урдасын Кырым белән туганлаштырган илче-дипломат та әле ул. Мәскәү кенәзе белән дә дустанә мөнәсәбәттә. Шунлыктан яшь хатынның әкренләп хан киңәшчесенә әверелеп китүен аңлау бер дә авыр түгел. Вакыйгалар агышы да нәкъ менә Нурсолтан фаразлаганча: елдан-ел көчәеп барган Мәскәү кенәзе Иван III 1487 елда Казанны яулап алып, Илһамны тәхеттән бәреп төшерә һәм аның урынына Мөхәммәдәминне утырта. Төпчек малай турында да уйларга вакыт – Габделлатыйфны Мәскәүгә, шул ук Иван III тәрбиясенә җибәрергә карар кылалар. Нурсолтан Мәккә-Мәдинәгә хаҗ сәфәре кылып йөргән арада Мәскәү – Казан хәлләре бераз катлаулана: 1496 елда Мөхәммәтәминне тәхеттән куып, Себер угланы Мамыкны хан итеп куялар. Әмма озакка түгел, берничә айдан Казан тәхете Иван III ризалыгы белән Габделлатыйфка тапшырыла. Хакимлек итүенең беренче елларында ул Мәскәү кенәзенә тугрылыклы булып калачагы турындагы антын онытмый, әмма озак еллар Кырым шартларында тәрбияләнгән хан мөстәкыйль сәясәт үткәрә башлый һәм башында олугбәк Коләхмәт торган хөкүмәт каршылыгына очрый. Көрәш 1502 елда Габделлатыйфның тәхеттән куылуы белән тәмамлана. Аны тоткын итеп, Мәскәүгә алып китәләр һәм Белоозерога сөргенгә озаталар. Казан тәхетенә яңадан Мөхәммәтәмин менеп утыра.

Мөхәммәтәминнең Казанга кайтуы Нурсолтанны сөендерсә, Габделлатыйф язмышы кайгыга сала. Бакчасарайдан Мәскәүгә хатлар агыла башлый. Мөхәммәтәмин дә Мәскәү кенәзеннән энесен әсирлектән азат итеп, Кырымга кайтаруын сорый. Моңа Боярлар думасы каршы килә. Нурсолтан үзе Мәскәүгә омтыла. 1510 нче елда ул Мәскәүдә улы Габделлатыйф белән күрешә, аннан соң Казанга юл тота, Мөхәммәтәмин янында ярты ел чамасы кунак була, 1511 елда яңадан Мәскәүдә, әмма ни-

кадәр тырышса да улын әсирлектән азат итүгә ирешә алмый.

Нурсолтан Кырымга кайтып егыла. Монда үзенең проблемалары – Миңлегәрәй авыру, урын өстендә; уллары әтисенең Мәскәүгә кагылышлы тышкы сәясәтен хупламыйлар, солых урынына сугышны өстен күрәләр.

1515 елда Миңлегәрәй хан гүр иясе була. Шул арада Мөхәммәтәминнең озакка сузылган авыруы башлана. Ул тәхетне Габделлатыйфка калдырырга теләве турында белдерә. Казан илчеләре бу турыда Василий III кә хәбәр җиткерәләр. 1517 елның ноябрендә Габделлатыйф кинәт үлеп китә. Көтелмәгән үлемнең сәбәбен ачыклый алмыйлар, әмма ул күпләр өчен сер булмый. 1518 елда Мөхәммәтәмин дә якты дөнья белән хушлаша. Өч иренең һәм сөекле улларының үлемен күреп тирән хәсрәтләр кичергән, җитмештән артык яшәп олы дөнья мәшәкатьләрен татыган Нурсолтан бу хәлләрдән соң озак яши алмый...

Күргәнегезчә, әсәрнең «скелеты» тарихи документлар белән расланган факт-вакыйгалардан гыйбәрәт. Төп персонажларның исемнәре дөрес бирелгән, вакыйгалар хронологиясе – фәнни әдәбиятта, дәреслекләрдә күрсәтелгәнчә. Кыскасы, әсәрнең таяну ноктасы, нигезе – ныклы. Шушы «скелетка» кундырылган "ит", әлбәттә, автор фантазиясе. Әйе, махсус уйлап чыгарылган вакыйгалар һәм аерым сюжет сызыклары да күп без тикшерә торган әсәрдә. Әмма ни хикмәт, автор фантазиясе, хәтта маҗарага якын күренешләр дә, күп очракта тарихи факт, реаль тормышта булган вакыйгалар рәвешендә кабул ителә. Чөнки алар нәкъ менә шул реаль тормышта булган вакыйгаларны тулыландыру өчен уйлап чыгарылганнар да, шуңа күрә ышандыру көче күп аларда. Моны, әлбәттә, талантлы авторның зур уңышы дип бәяләргә кирәк.

Трилогиянең икенче китабы Ибраһим хан белән Нурсолтанның төпчекләре Гәүһәршад ханәкә турында. Атаклы Олуг Мөхәммәд династиясенең соңгы вәкиле Гәүһәршад исеме тарихи документларда сирәгрәк очрый. Булган чыганакларга таянып, аның 1478–1479 еллар тирәсендә туганлыгын һәм, әнисе Кырым ханы Миңлегәрәйгә кияүгә чыкканнан соң, Бакчасарайда тәрбияләнеп үскәнлеген фаразларга мөмкин. Казан ханлыгындагы иҗтимагый-сәяси вакыйгаларда Гәүһәршад 1530 нчы еллар башыннан актив катнаша. Аның олуг максаты – Казан ханбикәсе булу. 1532 елда Сафа Гәрәй тәхеттән куылганнан соң оешкан яңа хөкүмәттә (диванда) җитәкчелек эшен олугбәк Булат Ширин белән Гүһәршад ханәкәгә тапшыралар. Хөкүмәт Казан дәүләте алып барган тышкы сәясәткә Кырым ханнары йогынтысы көчәюенә каршы көрәшә. Гүһәршад һәм аның Мәскәү яклы тарафдарлары тәкъдиме белән хан тәхетенә Касыймнан 15 яшьлек Җангали ханзадә чакырыла. Сәхиб һәм Сафа-Гәрәйләр заманында мөстәкыйльлеккә ирешкән Казан яңадан Мәскәү кулына эләгә. Шәһәрдә йөзләгән рус сугышчылары пәйда була, Мәскәүдән килгән

«киңәшчеләр» күбәя. Җанггали балигълык яшенә җиткәч, Гәүһәршад тәкъдиме һәм бөек кенәз Василий III рөхсәте белән аны ногай морзасы Йосыф морза кызына өйләндерәләр. Казан дәүләте белән чынбарлыкта Җангали түгел, Мәскәү яклы, әмма шул ук вакытта мөстәкыйльлекне дә инкяр итүдән ерак торган Гәүһәршад белән Булат Ширин идарә итә.

Василий III вафатыннан соң Мәскәү тәхетенә өч яшьлек Иван IV утыра. Боярлар арасында тәхет өчен көрәш туктамый. Шул ыгы-зыгыдан файдаланып, Казан илен үзенең төньяк биләмәсе дип санаган Кырым ханы Сәхиб-Гәрәй туганнан туган энесе Сафа-Гәрәйне яңадан тәхеткә кайтарырга хыяллана. Һәм аның ул хыялы тиздән тормышка да аша: 1535 елның көзендә Эчке/Иске Казан тирәсендә Җангали ханның үле гәүдәсен табып алалар. Сафа-Гәрәй Казанга кайта һәм җиңел генә хан тәхетен яулап ала. «Гәүһәршад ханәкә белән Булат бәк һәм барлык Казан җире кенәз Иван Васильевичка хыянәт итте», – дип теркәп куя көндәлегенә рус елъязмачысы, әле вакыйгаларга бәя биреп. Сафа-Гәрәйнең икенче мәртәбә ун ел чамасы хакимлек итү чорында Казан хөкүмәтендә Гәүһәршадка урын табылмый, әмма ул әле сәяси активлыгын югалтмаска тырыша.

1546 елда Казан аксөякләренең Мәскәүгә йөз тотучы төркеме Сафа-Гәрәйне яңадан тәхеттән куа, ләкин ул тугандаш нугайлар ярдәме белән тәхетне тиз арада янәдән үзенә кайтара. Гәүһәршад һәм аның тарафдарлары каты эзәрлекләүгә дучар ителә. Кызганыч, әлеге чорга караган тарихи документлар юк дәрәҗәсендә. Гәүһәршадның 1546 ел вакыйгаларыннан соңгы язмышы билгеле түгел. Һәм бу хәл язучы фантазиясенә киң юл ача.

Укучы Гәүһәршадны Ольга Иванова тасвирлаганча кабул итә: чибәрлеге ягыннан әнисенә охшамаган, шуңа күрә үзен Аллаһ тарафыннан кимсетелгән дип саный; яшьтән үк якын туганнарыннан үзсүзле булуы һәм ирек сөючән, буйсынмаучан характеры белән аерылып тора; астыртын, хәйләкәр һәм мәкерле, интригалар остасы, шул ук вакытта зирәк акыллы, кыю һәм максатчан – морадына ирешмичә тынычланмас. Әйе, ялгыш адымнар да ясый ул, әмма максатына ирешү юлында уңышлары да күп, Ничек кенә булмасын, укучы әлеге персонажны, кайчакта бераз кызгану хисе аша булса да, яратып кабул итә, сәясәт өлкәсендә кылган гамәлләрен хуплый, бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндәге зирәк акылына, катлаулы хәлләрдән җиңел чыга белү осталыгына соклана. Ахыр чиктә бит Гәүһәршад үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртмый, дәүләт иминлеген дә күз алдында тотып эш йөртә, үзенчә тырыша. Һәм бу тарихи шәхес безгә нәкъ шуның өчен кадерле дә!

Ниһаять, трилогиянең өченче китабы – «Сөембикә». Халкыбыз хәтерендә Сөембикә образы бүген дә каһарманлык, ватанпәрвәрлек, иманга тугрылык символы буларак кабул ителә. Аның язмышы тарихыбызның бәхетле мизгелләрен дә, кайгы-хә-

срәтләрен дә, киләчәккә юнәлдерелгән өмет-хыялларын да – барысын да сыйдырган. Шуңа күрә халык күңелендә саклана да ул. Ләкин соңгы елларда һәвәскәр, хәтта фәнни дәрәҗәләргә ия булган тарихчылар арасында да Сөембикәгә башкачарак, дөресен әйтик, тискәре караш ташлаучылар да күренә башлады. Имеш, ул әхлаки яктан бозык хатын: башта Җангали ханга кияүгә чыга, ул үлгәч, Сафа-Гәрәйгә «кала», гомеренең соңгы көннәрен Касыйм шәһәрендә, Шаһгали хәрәмендә үткәрә. Кырым килмешәге Кошчак белән дә гыйшык-мыйшык уйнамыйча калмагандыр, мөгаен... Казанның Явыз Иван тарафыннан яулап алынуында да Сөембикәне гаепли башладылар хәттә! Шуңа күрәдер инде, Ольга Иванованың бу әсәрен саклык белән генә, бераз шикләнебрәк тә укый башладым – үзебезнең татарлар шулай кыланганны, безнең милләттән булмаган язучы каләменнән нәрсә чыкмас?!

Шөкер, Ольга Иванова Сөембикә образын иҗат иткәндә дә, башка тарихи персонажлары кебек, фәндә булган барлык тарихи чыганакларны нигез итеп алган. Ә ул чыганаклар Сөембикәне яман хатын итеп сурәтләргә һич тә мөмкинлек бирмиләр. Аның Казандагы тормышы (сабые Үтәмеш-Гәрәй урынына дәүләт башлыгы булып торган ике ел чамасы гомерен дә кертеп) тоташ борчулардан, кайгы-хәсрәтләрдән, кагу-сугулардан торган кебек. Җангали белән никахы уңышлы булып чыкмый. Бу ханны автор, без күз алдына китерергә гадәтләнгәнчә, йомшак характерлы, сүлпән хәрәкәтле, хатын-кызга сүз дә әйтергә базмый торган пешмәгән ир заты итеп түгел, бәлки дуамал, Сөембикә кебек чибәр һәм яшь хатынына да кул күтәрергә тайчынмый торган тупас һәм усал бер адәм итеп сурәтләгән. Сафа-Гәрәй белән яшәгәндә бәхетле мизгелләре дә булгандыр, әлбәттә. Әмма ханның көнче хатыннары, алар янындагы сарай әһелләре оештырган ызгыш-талашлар, чыш-пышлар, төрле интригалар Сөембикәгә каршы юнәлдерелгән була. Сөембикә тешен кысып түзә, Сафа-Гәрәй вафатыннан соң башланып киткән катлаулы вакыйгаларда да югалып калмый, идарәне үз кулына ала. Язучы Ольга Иванова сурәтләвендә акыллы, кыю һәм тәвәккәл хатын буларак килеп баса ул безнең күз алдыбызга. Сөембикә ханбикәнең башка идарәчеләрдә булмаган тагын бер өстенлеген күрсәтеп үтә язучы – чибәрлеге белән түгел, гамәлләре белән абруй казанып өлгергән була ул гади халык арасында, эчке һәм тышкы дошманнарга каршы көрәштә халык белән аралашудан ала ул көч-куәтне.

Казан фаҗигасе – Сөембикәнең шәхси фаҗигасе дә ул. Ләкин аның сәбәбе Сөембикәдә генә түгел, ул бик тирәндә ята һәм тамырлары белән Алтын Урда чорына ук барып тоташа. Китапны игътибар белән укысаң, уйлансаң, туп-туры шундый фикергә киләсең.

Сөембикәнең Касыймдагы тормышы турында китапта бер сүз дә әйтелмәгән. Бәлки шулай кирәктер

дә. Ханбикәнең язмышын тагын да фаҗигалерәк итеп күрсәтергә теләмәгәндер язучы. Болай да аңлашыла ич.

Бәяләмәм гел мактаудан гына тора кебек. Җитешмәгән яклары да бардыр инде дип уйлаучыларга шуны әйтәсе килә: әлбәттә бар, ләкин алар вактөяк детальләргә генә карый, минемчә. Мәсәлән, урта гасырлар Казанын, хан сараен, мәчетләрне, мунчаларны мин, археолог буларак, үземчә күз алдына китерә идем. Бераз гадирәк иттереп. Безнең башкалабызны язучы бераз матурлабрак бирә кебек: таш сарайлар, фонтаннар, биек манаралы мәчетләр, җәннәт бакчалары. Хан һәм ханбикәләрнең, бәкләрнең, бай сәүдәгәрләрнең киемнәре, бизәнү әйберләре, көн саен кулланыла торган савы-сабалар – артык бай, кыйммәт, күбесе чит илләрдән кайтарылган. Ярый, шулай булсын, гафу итмәслек кимчелек түгел.

Данияр, Илнур, Айнур кебек кеше исемнәре артык заманча яңгырый, минемчә. Булды микән шундый исемнәр ханнар заманында? Борынгы язмаларда очрамый кебек.

Бер-берсенә каршы сугышучы гаскәрләрдәге сугышчылар саны да бераз күпертелгән. Дөрес, язучы гаебе түгел бу, елъязмачылар үзләре ярата шундый зур саннарны. Күпсанлы дошман гаскәрен җиңүчеләрнең дәрәҗәсе югарырак була бит инде.

«Сөембикә» романындагы Сафа-Гәрәй ханның үлеме белән бәйле эпизодта бераз күңелне тырный торган тагын бер нәрсә бар. Билгесез рус авторының 1560 нчы елларда язылган «Казан тарихы»ндагы хәбәрләренә таянып (бирედә, галимнәрнең бердәм фикеренчә, уйлап чыгарылган әйберләр күп), хөрмәтле язучыбыз Сафа-Гәрәйне исерек килеш мәҗлестән кайтып юынган вакытында башы белән җиз комганга бәрелеп үлгән дигән версияне китерә. Хан тикле хан сакчыларсыз йөрми, әлбәттә. Исерек булган очракта (мөселман кешесенең шул дәрәҗәгә җитеп исерүенә дә ышанмыйм мин) аны йокы бүлмәсенә кадә озатып куярлар иде. Сафа-Гәрәйне дошманнары үтергән – бу фараз чынбарлыкка күбрәк туры килә, минемчә.

Ярый, нәтиҗә ясыйк. Ольга Иванованың без югарыда тикшергән роман-трилогиясен язучыларыбызның соңгы елларда чыккан иң яхшы тарихи әсәрләре рәтенә куярга була. Мин аны мәктәп укучыларына да, югары уку йортлары студентларына да (бигрәк тә булачак тарихчыларга), гомумән, татар тарихы белән кызыксынган һәркемгә укырга тәкъдим итәр идем. Бу китапларны укып чыккан кеше Казан ханлыгы һәм аның белән тыгыз мөнәсәбәттә торган башка дәүләтләр тарихыннан бик күп һәм дөрес мәгълүмат алачак. Тиздән аның татарчага тәрҗемәсен дә күрербез, дип ышанып калам.

*Фәнни Татарстан. 2021. № 1. Б 172–180.*







## БОРЫНГЫ БАБАЛАРЫБЫЗ НИНДИ ТЕЛДӘ СӨЙЛӘШКӘН?

Профессор Марсель Бакировның «Тайны происхождения наших предков (историко-лингвистическое исследование)» дигән китабын укып чыккач туган фикерләр

Геродот (б.э.к. V гасыр) грек тарихының, Фабий Пиктор (б.э.к. III гасыр) Рим тарихының атасы санала. Россия тарихы фәненең чишмә башы елъязмачы Несторга (XII гасыр), Болгар тарихыныкы Йакуб ибн Ногманга (XI–XII гасырлар) барып тоташа. Бу тарихчыларның барысын да бер нәрсә берләштерә – аларның һәрберсе үз тарихларын «безнең борынгы бабаларыбыз кемнәр?» дигән сорауга җавап эзләүдән башлап җибәрәләр. Шуны да ассызыклап әйтергә кирәктер: әле тарих фәне һәм профессиональ тарихчылар килеп чыкканга кадәр һәр ыруг-кабиләнең, һәр халыкның үзләренең борынгы бабалары турында белгәннәре безнең көннәргә кадәр килеп җиткән легенда-риваятьләрдә, дастаннарда, халык иҗатының башка жанрларында чагылыш тапкан. Әмма халык хәтере барлык очракта да объектив чынбарлыкка туры килеп бетми. Бүгенге фәндә «этногенез» (халыкларның килеп чыгышы) төшенчәсе белән атап йөртелә торган бик катлаулы һәм дәвамлы процесс халык иҗаты әсәрләрендә, бигрәк тә генеологик легендаларда бик җиңел аңлатыла: «без – бүреләр (торналар, еланнар, аккошлар...) токымы», «бабаларыбыз – Нугай нәселеннән», «без – болгарлар» һ.б. Шәҗәрәләрдә исә генеологик җеп кайвакыт Адәм белән Һәвага кадәр сузыла. Әмма шундый самими-наив карашлар да күп очракта гыйльми тикшеренүләргә дөрес юнәлеш бирә алалар.

Россия халыкларның этногенезы белән бәйле проблемалар тарих фәнендә XVIII гасырдан башлап өйрәнелә башлады – хөкүмәт әһелләренә,

чиновникларга чикләре меңләгән чакрымнарга сузылган империя халыклары белән «дөрес» идарә итү өчен аларның тарихы, яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, телләре турында да азмы-күпме мәгълүмат кирәк иде. Теге яки бу халыкның килеп чыгышы турында беренчел чыганаклар шул чорда тупланды. Бу чыганаклар башлыча тарих, тел һәм этнография материалларыннан гыйбәрәт иде. Соңрак, XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, бу эшкә археологлар да җәлеп ителде. Әмма Иван Крылов мәсәлендәге Аккош, Чуртан һәм Кысла кебек, һәркем үз юнәлеше буенча эшләде, тупланган материалларны анализлап, чагыштырып карап, аңлашып, бердәм фикергә килү булмады.

Хәл узган гасыр урталарында гына үзгәрә башлады, галимнәр төрле характердагы чыганакларны комплексы рәвештә өйрәнү кирәклеген күтәреп чыктылар. Халыкларның килеп чыгышы мәсьәләләренә багышланган фәнни конференцияләргә тарихчылардан, этнографлардан, телчеләрдән һәм археологлардан башка антропологларны, фольклорчыларны, соңгы елларда хәтта табигать фәннәре, гамәли сәнгать һәм этномузыка белгечләрен дә чакыра башладылар. Һәр белгеч үз концепциясен алга сөрде, фикерләр туры килмәгән очракта көч аның сәбәпләрен эзләүгә, яңа материаллар туплауга юнәлделәр. Төрле фән белгечләре үз юнәлешләре буенча актив эшләде, тикшеренүләрнең яңа ысулларын тәкъдим итте.

Этногенез проблемаларын өйрәнгәндә галимнәр лингвистика – тел чыганакларыннан элегрәк тә актив рәвештә файдаланып килде. Бу аңлашыла да, чөнки халыкның күпгасырлык тарихы телдә (лексикада гына түгел, фонетика һәм морфологияда да) чагылыш тапмый калмаган. Узган гасырның икенче яртысында бу өлкәдә тикшеренүләр тагын да ныграк җанланып китте. Мисал өчен күренекле галимнәребез М.З. Зәкиев (Закиев, 2008), Д.Г. Тумашева (Тумашева, 1977), Л.Т. Мәхмүтова (Махмутова, 1982; 1985), Д.Б. Рамазанова (Рамазанова, 1996), Х.Р. Курбатов (Kurbatov, 1994), Р.Г. Әхмәтҗанов (Ахметьянов, 1981; 1988), Ф.С. Хәкимҗанов (Хакимзянов, 1987) һ.б. телчеләрнең билгеле хезмәтләрен искә төшереп үтәргә була. Чуваш галимнәре исә, Н.И. Ашмариннан башлап Н.И. Егоровка кадәр, этногенетик тикшеренүләрдә тел чыганакларын беренче планга куеп киләләр (Ашмарин, 1902; Егоров В., 1953; Федотов, 1986; 1990, с. 32–59; Егоров Н., 2017). Хронологик яктан караганда, татар телчеләре башлыча болгар чоры белән чикләнделәр. Бары тик М.З. Зәкиев кенә тагын да борынгырак чорларга үтеп керә алды һәм төрки телләр тарихын, кайбер чит ил һәм Россия галимнәренең тикшеренүләренә таянып, хәзерге Ирак җирлегендә б.э.к. III меңъеллыкта яшәгән шумер-аккадлардан башлап өйрәнү кирәклегенә басым ясады.

2019 елда Татарстан китап нәшриятында олуг галимебез, әдәбият һәм тел белгече, фольклорчы Марсель

Хәернас улы Бакировның «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура» (Казань, 2019. 463 б.) дигән фундаменталь хезмәте дөнья күргән иде. Биредә ул үзен, күп көч куеп үзе тупланан лексик-семантик һәм өлешчә этимологик чагыштырма сүзлек материалларына таянып, иң борынгы төркләр һәм аларның телләре, фәндә ныклап урнашкан концепция авторлары карашынча, Алтайда түгел, бәлки Якын Көнчыгышта, ягъни Азия кыйтгасының көньяк-көнбатыш өлешендә формалаша башлаган дигән теория тарафдары буларак танытты. Галимнең раславынча, безнең борынгы бабаларыбыз саналган һуннар иң элгәреге төркләр түгел, алар Якын һәм Алгы Көнчыгыштан Туран җирләренә күчеп утырган борынгы төркләр (бабалары сак, массагетлар) составыннан аерылып чыкканнар һәм Үзәк Азиядә, ягъни хәзерге Монголия, Байкал аръягы җирләрендә өлешчә монгол телле кабиләләр белән кушылганнар. Бу фикерне М.Х. Бакиров ышандырырлык итеп, абруйлы белгечләр фикеренә таянып, тел, археология һәм антропология өлкәсенә караган яңа фәнни фактлар белән исбатлады. Һәм, басым ясап әйтергә кирәк, әлеге хезмәтендә тюрколог галимебез төркләрнең этногенез һәм борынгы этник тарихы ике зур этаптан торганлыгын ышандырырлык итеп раслады, шул исәптән Якын һәм Алгы Көнчыгышта узган башлангыч этабында төрк баба телнең һәм иң элгәреге төркләрнең нинди үле яки борынгы этник төркемнәр катнашлыгында ялган-лыгын ачыклауга үзеннән зур өлеш кертте (Дәүләтшин, 2019, б. 166–174; Азертюрк, 2021, с. 282–285) .

Узган ел Татарстан китап нәшриятында профессор Марсель Бакировның борынгы бабаларыбызның килеп чыгышына багышланган тагын бер саллы китабы басылып чыкты: «Тайны происхождения наших предков. Историко-лингвистическое исследование» (Казань, 2002. 391 с.). Аның бу китабын мин, Идел болгарлары археологиясе белән шөгыльләнүче галим буларак, бигрәк тә кызыксынып укып чыктым, чөнки автор биредә күбрәк болгар, хазар, барсил, савир/сувар телләре турында сүз алып бара, бик тә бәхәсле болгар һәм чуваш телләренең үзара мөнәсәбәте, чувашларда болгар мирасы мәсьәләләренә дә киң туктала. Автор күтәргән проблемалар, ул проблемаларны чишүгә юнәлдерелгән яңа фактлар, шул фактларны анализлау нәтиҗәсендә туган гөман-фаразлар, моңарчы аз билгеле булган чыганаклар белән расланган төпле фикерләр телче һәм тарихчы галимнәрнең генә түгел, милли тарихыбызга битараф булмаган киң катлам укучыларыбызның да игътибарын җәлеп итәр дип уйлыйм.

Китапның беренче өлешендә гомумболгар этник берләшмәсен тәшкил иткән аерым компонентларның (болгар, сувар, барсил һ.б.) телләре тикшерелә. Билгеле булганча, лингвистикада төрки телләрне ике төп төркемгә бүлеп өйрәнү кабул ителгән: 1) *р*-телле угыр-болгар төрке-

ме (боларга борынгы болгар, сувар, хазар, бәҗәнәк һәм хәзерге чуваш телләре керә); 2) *з*-телле угыз, икенче төрлерәк әйтсәк, гомумтөрки төркем (кыпчаклар, төрек, азәрбайҗан, төрекмән, татар, башкорт, уйгыр, казах, кыргыз һ.б. телләр). Россия һәм чит ил тюркологиясендә, чувашлар – болгар төркеменең бүгенгә кадәр сакланып калган бердәнбер халкы дигән фикер өстенлек итә, ә бу исә аларга, ягъни безнең чуваш күршеләребезгә, Идел болгарлары мирасын тулысынча үзләренеке итеп күрсәтергә җирлек бирә. Татарларның болгар мирасына катнашы юк, имеш, алар – килмешәк монгол-татарлар токымыннан. Чуваш тарихчылары бүген дә шул «теория» тарафдарлары (кара: Болгары и чуваши, 1984; Димитриев, 2004).

Билгеле булганча, чувашларда һәм, XIV гасыр кабер ташларындагы язмаларга караганда, болгарларда да башка төрки халыклар телендә кулланыла торган [з] авазы урынына [р] авазы (ротацизм күренеше), [ш] авазы урынына [л] авазы (ламдаизм), [к] авазы урынына [х] авазы кулланыла. Мәсәлән, татар телендәге *кыз* сүзен чувашлар *хӗр* диләр (болгар ташларында – *хир*); ишек (тат.) – э**л**ик (болг.) – алӑк (чув.) – эшик (гомумтөрк.). Әмма шул ук эпитафия язмаларында гомумтөрки телгә хас з-авазлы сүзләр дә урын алган. Кабер ташларында кулланылган, моңарчы ике төрле эпитафик стиль итеп саналган бу тел аерымлыкларын М. Бакиров функциональ яктан киңәйтеп һәм җирле сөйләм белән бәйләп, болгар теленә хас булган ике төрле сөйләш (наречие) чагылышы итеп карый. Әлеге кабер ташларын, бәхәссез, мөселман динендәге болгарлар куйган, димәк, ике сөйләш төркемендәге кешеләр, ягъни мөселманнар, бер-берсен яхшы аңлаганнар, чөнки *р*-телле болгарлар да, *з*-теллеләре дә бер үк дәүләттә яшәгәннәр (сөйләшләрнең бер-берсенә тәэсире: *тат*. кы**з**-кы**р**кын, яткы**р**у-яткы**з**у, җитке**р**-җиттке**з**, кү**з**-кү**р** һ.б.).

Моңарчы игътибар үзәгеннән төшеп калган аерым фәнни хезмәтләргә һәм яңа дәлилләргә таянып, М.Х. Бакиров раславынча, бүген чувашлар сөйләшә торган *р*-тел элгәреге төрки телләр арасында иң борынгысы түгел, ул җирле фин-угыр телләре катнашында соңрак формалашкан дип әйтә алабыз. Ә менә төрки дөньяда элек тә, хәзер дә күпчелекне тәшкил итүче угыз-кыпчак тибындагы *з*-телләрнең барлыкка килүе исә, чыннан да, борынгырак чорларга карый. Соңгы елларда аларның беренчел ватанын кыю һәм яңача фикерләүче галимнәр Якын Көнчыгышта, хәзерге Ирак-Иран җирләрендә дип күрсәтә (Закиев, 2003; Азертюрк, 2018).

*Р*-телле угыр-болгар катламы кайда формалашкан соң һәм *з*-телле гомумтөрки катламыннан аерыла торган тел тармагы буларак кайчан һәм ничек барлыкка килгән? Бу сорауларга М. Бакиров, тарихи һәм лингвистик чыганакларга нигезләнеп, төпле җавап бирә: *р*-телдә сөйләшә торган халыкның анаватаны – Туран, ягъни Амударья һәм Сырдарья елга-

ларының Арал диңгезенә коя торган түбән агымнары тирәсендәге җирләр, хәзерге Казакъстанның көньяк-көнбатыш өлкәләре. Б.э.к. IV–III меңъеллыкларда әлеге Туран җирендә Якын Көнчыгыштан, төгәлрәге, хәзерге Иран-Ирак территориясеннән күчеп килгән һәм үзләреннән соң Кельтеминар археологик культурасын калдырган халыклар – борынгы дравидлар яшәгән. Алар биредә Көньяк Себер якларыннан килеп чыккан угырлар белән кушылганнар. Дравид кабиләләренең төрки халыкларга хас агглютинатив диалектларда сөйләшкәнлегенә һәм дә телләрендә архаик төрки сүзләрнең шактый күп сакланып калуына нигезләнеп, галим үзенең элегрәк чыккан китабында алар (борынгы дравидлар) көнбатышта формалашкан иң элгәреге төрки дөньяның бер катламы – этник компоненты булган дигән нәтиҗәгә килгән иде. Фонетик күренеш буларак ротацизм һәм ламдаизмның иң борынгы үрнәкләрен М. Бакиров нәкъ менә шул дравидлар телендә таба. Аның фикеренчә, ротацизм күренеше беренче башлап туранга үтеп кергән дравидларның, угырлар – хәзерге ханты, манси, венгр халыкларының элгәреләре белән үзара аралашкан катнаш нигездә барлыкка килгән. Туран җирлегендә дравидларның һәм Якын Көнчыгыштан күчеп килгән башка элгәреге төркләрнең борынгы угырлар белән очрашуы-керешүе, шул очрашулар җирлегендә туган катнаш тел ротацизм формалары өчен кулай нигез булган. Археология материаллары күрсәтүенчә, соңыннан алар акрынлап Үзәк Азия, Көньяк Себер далаларына күчеп китәләр. Бу якларда элек-электән яшәгән төрки һәм монгол телләрендә дравидлар белән уртак ротацизм үрнәкләре очравын, кайберләренең хәтта болгар теленә үтеп керүен галим шул күченү-аралашуларга бәйләп карый.

Алай гына да түгел, М. Бакиров яклаган гомуми караш буенча, Төньяк Кавказда, ә аннары Дунай һәм Урта Идел буенда үз дәүләтләрен корып яшәгән болгарларда *р*-телле сөйләшнең булуы да угыр телләренең йогынты ясау нәтиҗәсе. Ачыклап әйткәндә, бу йогынты Кавказга Тураннан һәм Себердән угыр һәм төрки телләр катнашлыгыннан торган оногур/унугыр һәм сабир/сувар кабиләләренең күчеп килүе белән бәйләнгән. Болгар телендә ике арадагы бәйләнеш, ягъни угыр тәэсире, нигездә, фонетика өлкәсендә – аерым сүзләрнең әйтелешендә, авазлар чиратлашуында чагылыш табуы белән чикләнгән һәм шуңа күрә болгар халкының *з*-телдә сөйләшкән катламына да аңлаешлы булган. Ә менә автохтон яки җирле фин-угырлар (башлыча марилар) белән кушылып формалашкан чувашларда исә үзара йогынты бик көчле булган һәм чувашларның болгарлардан аерымланып яшәвенә, телләренең башка төрки халыкларга аңлашылмавына китергән. М. Бакиров үзенең тикшеренүләрендә болгар теленең үзенчәлекләре һәм варислары, ни өчен *з*-телле угыз-кыпчак катламының җиңеп чыгуы турында сөйләгәндә менә шуларга басым ясый.

Югарыда әйтелгән фикерләрнең һәм нәтиҗәләрнең археология, антропология һәм генетика материаллары белән дә ярашуын ассызыклап үтү мөһим. Көньяк Себер һәм Казакъстан далаларында бронза чорына караган Карасук, Андрон археологик культураларын калдырган кабиләләрнең, исемнәре тарихи язмаларда теркәлеп калган саклар, массагетлар, скифлар һәм сарматларның күпчелек өлеше чыгышлары ягыннан Якын Көнчыгышта һәм Алгы Азиядә формалашкан борынгы төрки дөнья белән бәйләнгән. Бу үзенчәлекле карашны куәтләү-исбатлауга да Марсель Хәернас улы үзеннән шактый зур өлеш керткән. Моның өчен аның төрки дөньяга хас булган этник тотрыклы «милли»-этник үзенчәлекләрне аерып чыгаруы һәм аларны тел фактларына өстәп этносны билгеләүче асыл сыйфат яки күрсәткеч буларак файдалануы (Көнчыгышны изгеләштерү, бүрене һәм бер башлы канатлы мифик елан-сазаганны олылау яки тотемлаштыру, кавемгә нигез салган тотем затның яки бабаның тау куышында яралуы, өс киеменең изүен сул якка эләктерү һ.б) аерым хуплауга лаек. Монографияда ышандырырлык дәлилләргә нигезләнеп, бик дөрес күрсәтелгән: шул Туран халыклары арасыннан бит инде һуннар, Алтай төбәгендәге Ашина түркләре, соңыннанрак болгар, хазар, бәҗәнәк берләшмәләренә кергән кабиләләр, хәтта уйгырлар һәм башка төркиләр (угызлар) аерылып чыккан.

Марсель Бакиров туплаган чыганаклар күрсәткәнчә, «чиста түркләр» телендә, ягъни угызлар, кыпчаклар, усуннар һәм борынгы кыргызларда, шулай ук VI–VIII гасырларга караган орхон-енисей язмаларында *р*-телгә хас элементлар табылмаган, чөнки алар фин-угырлар белән тыгыз бәйләнештә тормаганнар һәм үзара кушылмаганнар. Димәк, төркиләрнең аерым этник төркемнәрендә *р*-теленең формалашуы, чыннан да, аларның күршеләре булган фин-угырларга (башлыча соңгыларына) нисбәтле булып чыга. Яңа тикшеренүләр төрки этногенезын Алтай-Саян төбәгенә бәйләп карый торган традицион теориягә каршы килә, алтай төркеменә кертеп йөртелә торган телләрнең, атап әйткәндә, төрки, монгол, манчжур тел группаларының, үзара кардәш итеп каралуын да расламый. Чөнки алтай телләрен үзара якынайта торган тел һәм мәдәният өлкәсендәге уртаклыклар яки охшашлыклар этник кардәшлек аркасында түгел, бәлки үзара элемтәләр, аралашулар нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр.

Профессор М. Бакировның ачышлары төрки халыклар анаватанын, алда әйтелгәнчә, Алтай-Саян җирләре белән бәйләүче, шулай ук чуваш теленә хас *р*-сөйләше, имеш, иң борынгы төрки телләрдә үк барлыкка килгән, *з*-сөйләше исә баштарак чорларда гомумән булмаган дип инанучы тюркологларның фаразга корылган карашларын нык какшата һәм кискен кире кага. Әлеге монографиядә төрки этногенезының Якын Көнчыгышка мөнәсәбәтле башлангыч чорын з-телле прототөркиләр белән, ә *р*-тел сөйләше барлыкkка килгән

урынны Каспий-Арал (Туран) төбәге белән бәйләп аңлатуны һәм дә моны үзе туплаган лексик-семантик чагыштырма сүзлек материаллары һәм тотрыклы этник-мәдәният дәлилләре белән исбатлауны мин олуг галимебезнең иң зур ачышы-казанышы дип саныйм.

Галимнең меңгә якын иң борынгы лексик берәмлекләрне эченә алган чагыштырмалы сүзлеге генә түгел, ә аерым сүзләрнең, шул исәптән ономастик тәңгәллекләрнең килеп чыгышына, генетик яки элемтә-контактка нигезләнгән охшашлык-уртаклыкларга мөнәсәбәтле тикшеренүләре дә җитди игътибарга лаек. Менә көтелмәгән шундый архаик бәйләнешләрне ача торган (һәм шәхсән үзем өчен бик тә кызык тоелган) берничә лексик оя (тезмә): 1) *массагетлар* – баш (олуг, бөек) саклар: mah (шум.) – олуг / maha (драв.) – зур, бөек / mas (иран) – зур // (м ↔ б / с ↔ ш) → мас < баш (борынгы төрки. – баш, башлык + саг/сак (этнос атамасы) + -ет / -ат (күплек кушымчасы)[1]; 2) Алгы Азиядән чыккан *каспи, кассит* кабиләләре: кас – этноним + -пи, -ит – күплек кушымчалары, *Каспи, Кавказ* – топонимнар. Кавказ тауының элгәреге җирле аталышы – Кап / Каф + каз > кас (с ↔ з). *Казак / казак*: а) кас / каз → кез (бор. төрки) – күченеп йөрү(че) + ак / к[2] – күплек кушымчасы; ә) Ка / кап (бор. төрки) – якынлык, кардәшлек + зак >к сак (субстрат этноним); 3 амазонкалар – сугышчан яки яугир хатын-кызлар: ам / ама – хатын-кыз + зон (чон, сөн, һун) – халык, кабилә мәгънәсен белдерүче сүзләр + к – күплек кушымчасы. Димәк, М. Бакиров тарафыннан тәкъдим ителгән версия *казакъ* этнонимының, шулай ук Кече Азиядә һәм Азов (Азак) диңгезе буенда яшәгән амазонкалар атамасының төрки телдәге мәгнәләре казакъларның генетик тамырларын һәм казакъта сакланган амазонкалык традициясен Туран саклары белән бәйли торган карашлар файдасына хезмәт итә.

М. Бакировның турыдан-туры үзебезнең җирлеккә, болгар-чуваш-татар мөнәсәбәтләренә караган тикшеренүләрендә дә кызыклы күзәтүләр һәм ачышлар шактый. Шундыйлардан мин чуваш һәм татар телләренең ничек формалашуларын, бер-берсенә якын да килмәгән үзенчәлекләрен ачыклауга мөнәсәбәтле табышларын аерып күрсәтер идем. Ә инде галимнең «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының Урта Азиядә түгел, ә үзебезнең болгар-татар җирлегендә иҗат ителгәнлеген исбатлауга багышланган фәнни эзләнүләре, күзәтүләре – укучы игътибарын нык җәлеп итә торган үзе бер дөнья! Автор анда моңарчы кул тимәгән яңа материалларны кулланышка кертеп, шул исәптән «Кыйсса-и Йосыф»ны әлегә кадәр

[1] Күплекне белдерүче архаик -ет / -ат кушымчасының борынгы төрки телдә сакланган эзләре: ир-ат (ирләр), тюрк-ут / түрк-үт (төркләр), алпаг-ут – хәрби яраннар (алп / алпагу – батыр, каһарман).

[2] Чагыштырыгыз: турк / түрк > Тур / Түр (ыруг-кавемгә нигез салучы легендар каһарман) + к (күплек кушымчасы) – төркләр; Туран > Тур + ан (сүз ясагыч кушымча) – тураннар (төркләр) иле.

аз билгеле «Ана вә угыл» дигән болгар чорына нисбәтле поэма (дастан) белән чагыштырып, болгар-татар әдәби теленең ничек формалашуын һәм аның үзенчәлекләрен ача торган ышанычлы нәтиҗәләр ясый.

Марсель ага Бакировның әлеге ачышлары, минемчә, тюркологларны нык уйланырга, элеккеге традицион концепцияләрен яңадан карап чыгарга мәҗбүр итәчәк. Фәндә Идел болгарлары телен бары тик чуваш теле белән генә тәңгәлләштерү өстенлек итә, дидек. Алайса, *р*-сөйләше, ягъни ротацизм элементлары катнашуга карамастан, нигә болгар кабер ташларының теле татарга аңлашылып тора, ә чуваш теле безгә бөтенләй аңлашылмый?! Мондый җитди аермалар асылда чувашларның элек марилар яшәгән, әмма Идел-Кама буе болгарларыннан аерымланып торган төбәктә формалашулары (Серебренников, 1956; 1957) һәм антропологик яктан аларның җирле фин-угыр халкының турыдан-туры төрдәше булуы (Алексеев, 1971) М. Бакиров үзәккә алып күрсәткән фактлар җирлегендә генә аңлатыла ала.

Янә килеп, әгәр чувашлар Болгар дәүләтендә яшәгән төп халыкның дәвамчылары икән, кая киткән соң ул вакытта аларда болгарлардан калган дәүләтчелек, шәһәрләр һәм мөселман архитектурасы, язмачылыкка нигезләнгән ислам мәдәнияте? Нишләп юкка чыккан Кол Галидән, «Ана вә угыл» дастаны авторыннан һәм Сөләйман ибн Дауд ас-Саксини-Суваридан башланып киткән матур әдәбият? Чувашлар – болгарларның исламнан баш тарткан мәҗүси өлеше дибез икән, күрсәтегез Болгар территориясендә шул мәҗүси чувашларның X–XV гасырларга караган берәр зиратын. Юк бит алар. Авыл-шәһәр урыннары да табылмаган. Нәкъ менә болгарлардан читтә яшәгәнгә күрә дә чуашлар яши торган төбәкләрдә болгарлардан калган кабер ташлары юк һәм, монография авторы искәрткәнчә, аларның кыпчаклашмыйча үз телләрен саклап калуының сере дә элек-электән болгарлардан аерылып яшәве белән бәйле. «Сувар-чувашларның» X гасыр Сувары да – мөселман шәһәре, «аның үзәк мәйданында биек манаралы мәчет урнашкан», – дип язган замандашлары (Хвольсон, 1869, с. 82). Әмирләре дә – мөселманнар, суккан дирһәмнәрендә – гарәпчә текст.

Чувашларның мәдәни мирасы, менталитеты белән кискен каршылыкка керә торган менә шундый хәлиткеч аермалар һәм дә М. Бакиров тарафыннан тәфсилләп тикшерелгән ышаычлы яңа фактлар фәндә, ниһаять, чуваш кавемен болгарларның турыдан-туры дәвамчылары итеп карый, хәтта ике арада тигезлек билгесе куя торган ясалма карашлардан баш тартуга китерер дип ышанасы килә. Иң мөһиме, аерым тюркологларның һәм чуваш галимнәренең татарларны икенче планда калдырып, болгарларның законлы һәм төп мирасчысы булуын танымауларына чик куелырга вакыт җиткәндер кебек. Соңгы елларда чуваш археологлары белән Олы Таяба шәһәрлегендә алып барыла торган казу эшләре

нәтиҗәләре дә шушы ук хәерхаһ концепциягә хезмәт итәчәге, минемчә, шиксез.

Тюркология фәнендә абруй казанган олуг галимебез Марсель Хәернас улы Бакировның яңа китабын укып чыкканнан соң туган фикерләр бу.

## Файдаланылган әдәбият


*Азертюрк Т.* Генезис тюрка и тюркского языка (на основе клинописи). СПб.: Супер, 2018. Т. 1, 2. 1294 с.

*Азертюрк Т.* О вкладе татарского тюрколога в ориенталистику (рецензия на монографию проф. М.Х. Бакирова «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура». Казань, 2019) // Филология и культура. Philology and culture. 2021. № 4 (66). С. 282–285.

*Алексеев В.П.* Очерк происхождения тюркских народов Восточной Европы в свете данных краниологии // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / Отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1971. С. 232–271.

*Ахметьянов Р.Г.* О соответствиях звуков *Р* и *Л* (*Р'* и *Л'*) в зоне татарско-чувашско-русских контактов // Источниковедение и история тюркских языков / отв. ред. Э.Р. Тенишев. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1978. С. 69–76.

*Ахметьянов Р.Г.* Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М.: Наука, 1981. 260 с.

*Ахметьянов Р.Г.* Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. М.: Наука, 1988. 220 с.

*Ашмарин Н.И.* Болгары и чуваши / Изв. Общ-ва археологии, истории и этнографии при Импер. Казан. ун-те. 1902. Т. XVIII, вып. 1–3. С. 1–132.

Болгары и чуваши / Отв. ред. В.Д. Димитриев. Чебоксары: ЧувНИИ, 1984. 158 с.

*Дәүләтшин Г.* Прототөрки бабаларыбызга юл яручы китап // Казан утлары. 2019. № 7. Б. 166–174.

*Димитриев В.Д.* Вопросы этногенеза, этнографии и истории культуры чувашского народа. Чебоксары: Изд-во Чуваш. гос. ун-та, 2004. 392 с.

*Егоров В.Г.* К вопросу о происхождении чуваш и их языка // Уч. зап. Чув. НИИ. 1953. Вып. VII. С. 64–91.

*Егоров Н.И.* Избранные труды по этнолингвогенезу и этнической истории чувашского народа. В двух книгах. Чебоксары: Новое время, 2017. Кн. 1, 428 с.; кн. 2. 440 с.

*Закиев М.З.* Происхождение тюрков и татар. М.: Инсан, 2003. 446 с.

*Закиев М.З.* История татарского народа. (Этнические корни, формирование и развитие). М.: Инсан, 2008. 560 с.

*Махмутова Л.Т.* Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики (краткий анализ и приложение) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. (Материалы и исследования. Вып. 2). Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1982. С. 68–153.

*Махмутова Л.Т.* О некоторых татарско-куманских параллелях (по материалам фонетики и грамматики) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. (Материалы и исследования. Вып. 3). Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1985. С. 117–142.

*Рамазанова Д.Б.* К истории формирования говора пермских татар. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1996. 240 с.

*Серебренников Б.А.* Проблема субстрата // Доклады и сообщения Института языкознания АН СССР. М., 1956. № 9. С. 33–57.

*Серебренников Б.А.* Происхождение чувашского народа по данным языка // О происхождении чувашского народа. Чебоксары, 1957. С. 40–45.

*Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 294 с.

*Федотов М.Р.* Народность и язык волжских болгар // Проблемы средневековой археологии Урала и Поволжья / отв. ред. Р.Г. Кузеев. Уфа: Изд-во ИИЯЛ БФАН СССР, 1986. С. 43–48.

*Федотов М.Р.* Чувашско-марийские языковые взаимосвязи. Саранск: Изд-во Саранск. филиала Саратов. гос. ун-та, 1990. 336 с.

*Хакимзянов Ф.С.* Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и и их язык. М.: Наука, 1987. 192 с.

*Хвольсон Д.А.* Известия о хозарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда бен Омар Ибн-Даста. СПб., 1869. 199 с.

*Kurbatov H.* Idil-Çulman (Volga-Kama) boylarında eke geçen runik kitabeler // Türk Dünyası Arastırmaları. 1994, Şubat, N 88. S. 104–113.

*Фәнни Татарстан. 2023. № 1 (37). Б. 164–173.*

## ЙОМГАКЛАУ УРЫНЫНА

2006 елның 20–21 октябрендә, ягъни моннан нәкъ егерме ел элек, Казанда Татар дәүләт гуманитар-педагогик университеты башлангычы белән Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия интеллектуаль тарих җәмгыятенең Татарстан бүлеге оештырган фәнни-практик конференция булып узган иде. Әлеге конференция Казан шәһәренең югары уку йортларында Россия, Татарстан һәм татар халкы тарихын укытуның актуаль проблемаларына багышланды. Хәзерге күзлектән чыгып караганда, ышанмаслык хәл – югары уку йортларының һәрберсендә профессиональ белем алучы студентлар Россия һәм төбәк тарихын өйрәнәләр. Дөрес, бу хәл озак дәвам итмәде, Дәүләт Думасының 2007 елгы карары нигезендә Россия гомумбелем бирү мәктәпләрендә укытыла торган фәннәрнең дәүләт стандартыннан милли-региональ компонентны алып ташладылар. Милләте белән рус булмаган укучы үз халкының тарихын Россия тарихында тапмагач, яки ул тарих тупас рәвештә бозып күрсәтелгәч, ничек итеп аңа карата ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләргә мөмкин? Мин моны аңламыйм. Соңгы елларда массакүләм информация чаралары шовинизм һәм милләтчелек турында күп шаулый. Милли нигездә барлыкка килгән куркыныч киеренкелек барыбызны да борчый. Федераль дәреслек авторлары бу хакта төптән уйлансыннар иде. Түбәндә урнаштырылган мәкалә – ул югарыда әйтеп үтелгән фәнни конференциядә укылган доклад нигезендә язылган иде – укучыларыбызны да уйланырга мәҗбүр итәр дип ышанам. Мин аны татарчага тәрҗемә итмичә генә бирәм – укучылар аудиториясе киңрәк булсын дип.

# СРЕДНЕВЕКОВЫЕ ПРЕДКИ ТАТАРСКОГО НАРОДА НА СТРАНИЦАХ ВУЗОВСКИХ УЧЕБНИКОВ

В конце 1980-х – начале 1990-х годов, когда в России начали устанавливаться демократические порядки, в период, когда в Татарстане активизировалось национальное движение, направленное на восстановление своей государственнсти, перед нашими учёными была поставлена очень ответственная и сложная задача: заново пересмотреть созданную за годы советской власти ложную историю татар и написать, основанную на объективных источниках историю Татарстана и татарского народа. Наверное, помните: какую только газету или журнал не возьмёшь, на их страницах можно было найти поразительные по смелости постановки вопросов и насыщенные до сих пор неизвестными фактами статьи по истории татар или других нерусских народов, начиная с древнейших времён и до современности. Наши глаза, привыкшие смотреть на прошлое через призму марксизма-ленинизма и советского интернационализма, наконец, открылись, начал устанавливаться новый взгляд на историю народов России.

В эти же годы я совместно со своими коллегами Г.М. Давлетшиным и И.Л. Измайловым приступил к написанию «Рассказов по истории Татарстана» – первого нового учебника для 5–6 классов средней школы[1]. Пришлось, естественно, просмотреть и старые учебники, причём не только изданные у нас, но и в соседних республиках и областях. Поразительные открытия сделал для себя: оказывается, с одной стороны, много говорили об интернационализме и дружбе народов, с другой – делали с точностью наоборот. Сказанное хочу проиллюстрировать краткими цитатами из учебника Н.А. Кузминского «Наш край родной» для VII–VIII классов[2].

Раздел о Волжской Булгарии: «Местные племена встретили пришельцев-булгар с оружием в руках»[3]; «Стремление покорённых народов к освобождению подавлялось с необыкновенной жестокостью»[4]; «Их разбойничьи набеги на древнерусские города и сёла требовали сильной охраны границ и огромных расходов на их защиту»[5]; «Булгарские князья

[1] См.: Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш., Измайлов И.Л. Рассказы по истории Татарстана. Учебник для 5–6 классов средней школы / Под ред. С.Х. Алишева. Казань: Магариф, 1994. 272 с.

[2] Кузминский Н.А. Наш край родной. Учебное пособие для учащихся VII–VIII классов Ульяновской области. Ульяновск, 1975.

[3] Там же, с. 11.

[4] Там же, с. 12.

[5] Там же.

принялись разорять и грабить… русские земли, захватывать многие тысячи русских пленников»[6] и т.д.

В разделе «Монголо-татарское иго», конечно, не найдём ни одного положительного слова о наших предках. Не стану даже приводить цитаты.

Раздел «Казанское ханство»: «Кроме феодального гнёта они (марийцы и мордва. – *Ф.Х.)* подвергались насильному отатариванию; их заставляли переходить в мусульманскую веру, отказываться от национальных обычаев и родного языка…»[7]; «Самым же доходным делом считалась торговля живым товаром – русскими пленниками, которых только в одной Казани насчитывалось до 100 тысяч…»[8]; «Опасный сосед вёл себя агрессивно… Недаром в те времена писали, что Казань допекала Руси хуже Батыева разорения, Батый только один раз протёк русскую землю, словно горящая головня, а казанцы бесперстанно нападали на русские земли, жгли, убивали и таскали людей в плен. Во время набегов татары отрубали пленным руки и ноги, выкалывали глаза, обрезали уши и носы, вешали за рёбра на железных крючьях. Для забавы стреляли в детей из луков, рубили саблями. Всё это не имело никакого оправдания. Жестокость совершалась ради жестокости»[9] и т.д.

Вот вам пример интернационального воспитания по-советски! Теперь попробуйте понять положение татарских детей, сидящих со своими русскими сверстниками за одной партой. Откуда раздобыл автор данного учебника эти «факты»? Их нет ни в одном историческом источнике.

Нет сомнения, что образцом для автора послужили вузовские учебники, в которых, мягко говоря, тенденциозно освещались эти же вопросы, как раньше, так и последние годы.

В начале 2000-х годов мне пришлось участвовать в написании ещё одного учебника – «История Татарстана» под редакцией Б.Ф. Султанбекова[10]. В 2004 г. вышла «История Татарстана с древнейших времён до середины XVI века[11]. Вновь просмотрел учебники, новые, изданные у наших соседей, и в них уже не обнаружил такого пасквиля против татар. Объясняется это просто. Во-первых, мы, татары, даже в наши сложные времена сумели показать себя перед российской и мировой общественностью только с положительной сторо-

[6] Там же, с. 16.

[7] Там же, с. 25–26.

[8] Там же, с. 27.

[9] Там же, с. 27–28.

[10] См.: История Татарстана. Учебное пособие для основной школы. Изд-е 2-е, стереотипное / Руководитель проекта и науч. ред. Б.Ф. Султанбеков. Казань: Изд-во «ТаРИХ, 2005. 544 с.

[11] См.: Хузин Ф.Ш., Пискарёв В.И. История Татарстана с древнейших времён до середины XVI века. Учебное пособие для 6 класса общеобразовательной школы / Рук проекта Б.Ф. Султанбеков. Казань: Изд-во «Хэтер» (ТаРИХ), 2004. 95 с.

ны. Татарстан во многих отношениях – пример для многих. Политика межнациональных и межконфессиональных отношений, провозглашённая Президентом РТ М.Ш. Шаймиевым, показала и показывает свою жизнеспособность. Есть почва для мирного существования, но нет причин для раздоров. Во-вторых, показали свою активность и историки, в частности, сделали глубокий анализ содержания учебников для средних школ[12], неутешительные результаты направили в Министерство образования и науки РФ, в издательства. Надо сказать, что в будущем в разного уровня учебниках истории не будет места показу предков татар как кровожадных зверей и неспособных к цивилизации варваров.

Проблемы остаются, конечно. Недостатки в освещении вопросов истории татарского народа и Татарстана в федеральных учебниках по истории России для основной и полной средней школы вызвали справедливую критику в печати[13]. Здесь я хочу вкратце остановиться на истории тюркоязычных народов эпохи древности и средневековья – далёких предков татар, нашедшей отражение в некоторых вузовских учебниках для студентов-историков.

На мой взгляд, самым существенным недостатком всех учебников является отсутствие последовательно изложенной истории тюрко-татарских государств: Хуннской державы, Тюркского каганата, Великой Болгарии Кубрата, Хазарского каганата, Волжской Булгарии, Золотой Орды (Улуса Джучи), постзолотоордынских ханств (Казанского, Астраханского, Крымского, Сибирского) и Ногайской Орды.

Кроме русских, татары в составе Российской Федерации являются практически единственным народом, имеющим свою государственность с многовековыми корнями. Причём ранние из перечисленных государств – Хуннская держава, Тюркские каганаты, Великая Болгария и Хазария – возникли на современной территории России задолго до появления на исторической арене славян и Древней Руси. Конечно, вполне понятно игнорирование авторами учебников столь важной, с точки зрения представителей национальной историографии, но щепетильной темы – тогда станут прозрачными причины и мотивы многовековой борьбы татарского народа за восстановление своей государственности. Но студенты, наши будущие специалисты с высшим образованием, в первую очередь, те, которые получили среднее образование за пределами нашей республики, лишаются возможности получать объективные знания по истории народов России. Такая недальновидная политика, проводимая через наши учебники, может иметь серьёзные последствия. В российской истории мы не находим своей истории, следо-

[12] История татарского народа и Татарстана в федеральных учебниках // Магариф. 2001. № 12. С. 54–56; 2002. № 1. С. 63–65.

[13] См. там же.

вательно, сама Россия – не наша. Как ни прискорбно признаться в этом, но у читателей нерусских национальностей остаётся почва для подобных рассуждений.

Остановимся на сюжетах по истории средневековых предков-тюрко-татар, рассыпанных по разным разделам и главам вузовских учебников.

В учебнике под редакцией А.Н. Сахарова «с сильными и жестокими пришельцами из глубины Азии» – киммерийцами встречаемся впервые в главе… «Происхождение славян. Их соседи и враги». Странновато, конечно. Как уверяет автор, в начале I тыс. до н. э., «под натиском опасных соседей славяне покидали плодородные солнечные земли и уходили в северные леса»[14]. Заметим, что по новейшим данным археологических и исторических источников, становление праславянского этноса (культура подклёшевых погребений) прослеживается не ранее середины I тыс. до н.э. в бассейне Вислы и Одера, т.е. в областях, далёких от «плодородных и солнечных земель» юга[15].

Далее А.Н. Сахаров продолжает: «Периодически, век за веком, из глубин Азии… выходили в Восточную Европу кочевые орды, и первыми на их пути вставали восточные славяне. Борьба с кочевниками с тех пор стала частью их постоянной жизни. Это нескончаемое противоборство уносило тысячи жизней, отвлекало людей от мирного труда, заставляло в трудные дни бежать на север, приводило к разорению поселений. Всё это, конечно, замедляло общее развитие Восточной Европы, которая вставала на пути кочевников и защищала тем самым Запад»[16]. Вот так происходит первая «встреча» студента-историка с кочевниками степей.

В описании «нашествия скифов», а также более поздних сармат, не менее «опасных соседей славян», вынужденных после их походов заново «осваивать земли и строить свои посёлки», тоже ничего положительного не найдём[17].

С появлением гуннов А.Н. Сахаров связывает начало господства «тюркомонгольских племён на степных просторах Евразии». Вид гуннов был ужасен, говорит автор, и описывает их дикие нравы и зверства, по-своему интерпретируя сведения античных (римских) историков. «Они прошли огнём и мечом по южнославянским поселениям, – пишет он. – В очередной раз, спасаясь от гибели, славянское население бежало под укрытие лесов, бросало свои плодородные южные чернозёмы»[18]. Но дело в том, что храбрых и мужественных, красивых и рослых славян, любящих

[14] История России. Т. 1. С древнейших времён до конца XVIII века / Под ред. А.Н. Сахарова. М., 2003. С. 24.

[15] Седов В.В. Славяне: историко-археологическое исследование. М., 2002. С. 74.

[16] История России. Т. 1. История России с древнейших времён до конца XVIII века. С. 24.

[17] Там же, с. 25, 27.

[18] Там же, с. 30, 31.

свободу и ласковых к чужеземцам, по описанию А.Н. Сахарова, всё ещё не было в южных степях. Возможно, обитали они, окончательно ещё не оформившиеся в самостоятельный этнос («значительный процент населения» в составе черняховской культуры го́тов, по В.В. Седову), северо-западнее, в Верхнеднестровском и Подольско-Днепровском регионах[19]. К сожалению, ни слова о том, что гунны – первый достоверно известный по письменным источникам тюркоязычный народ на территории России, достигший в своём социально-политическом развитии уровня государственности; о том, что кроме кочевого скотоводства, они занимались и земледелием, рыли оросительные каналы, строили города, где археологами открыты бревенчатые дома с централизованной системой отопления; знали гончарный круг, стенобитную технику и многое другое[20], которые следовало бы, на мой взгляд, хотя бы упомянуть в учебнике для студентов-историков высших учебных заведений.

В середине VI в., когда, наконец, фиксируются первые достоверные археологические следы славян на территории будущей Руси (пражско-пеньковская культура антов, и пражско-корчакская культура склавен/славян, по В.В. Седову[21]), удару новых врагов – аваров подверглись южные области восточных славян. «С горечью писал позднее летописец о том, что авары «примучивали» славян, издевались над славянскими женщинами, запрягая их телеги вместо волов и лошадей»[22].

С уходом авар на запад «опасными соседями восточных славян», по А.Н. Сахарову, на долгие столетия становятся хазары, натиск которых сумели выдержать, потому что славяне стремились освободить свои «исконные земли» в районе Среднего Поднепровья[23].

В.В. Григорьев, один из выдающихся востоковедов XIX столетия, писал в своё время, правда, не без элементов идеализации, что Хазарский каганат, *«окружённый племенами дикими и кочующими, имел все преимущества стран образованных: устроенное правление, обширную, цветущую торговлю, и постоянное войско. Когда величайшее безначалие, фанатизм и глубокое невежество оспаривали друг у друга владычество над Западной Европой, держава Хазарская славилась правосудием и веротерпимостью… Как светлый метеор, ярко блистала она на мрачном горизонте Европы…»*[24] Казалось бы, что такая, в целом объективная характеристика первого раннефеодального государства на территории

[19] Седов В.В. Указ соч., с 187–188.

[20] Кызласов Л.Р. Городская цивилизация Срединной и Северной Азии.: исторические и археологические исследования. М.: Вост. лит-ра, 2006. С. 149 и сл.

[21] Седов В.В. Указ соч., с. 203 и сл.

[22] История России с древнейших времён. Т. 1., с. 35.

[23] Там же, с. 36.

[24] Григорьев В.В. Обзор политической истории хазаров // Россия и Азия. М., 1876. С. 66.

Восточной Европы обязывает более подробно изложить его историю. Однако на страницах учебника мы этого не обнаруживаем, автор ограничился лишь указанием на вассалов хазар в лице буртасов, мордвы, марийцев и нескольких славянских племён, упоминанием их столицы на Итиле, где торговали и славянские купцы, а также принятии ими монотеистической религии в виде ислама и иудаизма.

Заметим, что о Тюркском каганате, возникшем ещё до Хазарского государства и сыгравшем исключительно важную роль в истории тюркоязычных народов Евразии, в учебнике А.Н. Сахарова нет ни слова.

Меньше половины страницы текста занимает полуторатысячелетняя история гуннов, аваров, Тюркского и Хазарского каганатов, Болгарского царства, которые названы в учебнике А.С. Орлова и его соавторов «непрочными конгломератами степняков, промышлявших военной добычей»[25]. Таким образом, будущий историк с высшим образованием не будет знать практически ничего о тюркской цивилизации с высоким уровнем градостроительства, кирпично-каменной архитектуры, письменнсти, общественно-политического устройства, которые преемственно будут развиваться позднее у хазар, волжских булгар, населения Улуса Джучи и постзолотоордынских государств. Зато надолго запомнится старый стереотип, вновь озвученный А.Г. Кузьминым: «Степняки других специальностей, кроме воинской, не знали – они войной кормились»[26].

Ради справедливости следует заметить, что имеется учебное пособие для системы педагогических вузов России, изданное в 2001 г. под редакцией А.Н. Сахарова и выдащегося хазароведа А.П. Новосельцева, где параграфы о гуннском нашествии и его последствиях, Хазарском государстве, степных кочевниках и народах Поволжья IX – начала XIII вв. написаны, притом достаточно подробно и весьма квалифицированно, именно А.П. Новосельцевым[27]. Однако автор основное внимание в освещении их истории обращает на военно-политические события, этнический состав населения, не затрагивая вопросов, связанных с их материальной и духовной культурой, хозяйственной жизнью, определеним вклада тюркоязычных народов в мировую средневековую цивилиацию.

История Волжской Булгарии домонгольского периода – «небольшого государства» (располагавшегося – добавим от себя, – на нынешних территориях Татарстана, Чувашии, Мордовии, в Ульяновской, Самар-

[25] Орлов А.С., Георгиев В.А., Георгиева Н.Г., Сивохина Т.А. История России. Изд-е 2-е, перераб. и доп. М., 2004. С. 14–15.

[26] Кузьмин А.Г. История России с древнейших времён до 1618 г. В 2-х кн. Кн. 2. / Под ред. А.Ф. Киселёва. М., 2004. С. 81.

[27] История России с древнейших времён до конца XVII века / Отв. ред. А.Н. Сахаров, А.П. Новосельцев. М., 2001. С. 27–38, 85–91.

ской, Пензенской областях, а также в Пермском крае), стоявшей примерно на одной ступени развития с Древней Русью и русскими княжествами, странами Запада и Востока; обладавшей примерно одинаковым экономическим и духовным потенциалом, во всех учебниках для вузов освещается отдельными сюжетами, преимущественно в связи с необходимостью показа их роли в торговых и военно-политических взаимоотношениях со своими русскими соседями. Вот, к примеру, одно из имеющихся двух предложений по «истории» Волжской Булгарии в учебнике А.Ю. Дворниченко, Ю.В. Тота и М.В. Хомякова, написанном, как уверяют авторы, с учётом последних достижений исторической науки и в соответствии с государственным образовательным стандартом высшего профессионального образования РФ: «Это государство долгое время представляло реальную угрозу для восточных славян»[28].

История монголо-татарских завоеваний (в учебниках нередко: «татарское нашествие»), монгольского ига («татарское иго») и борьбы русских земель за независимость в наших учебниках освещается достаточно подробно. И это понятно, ибо последствия монголо-татарского владычества имели исключительное значение в последующих судьбах русского и других народов Восточной Европы.

В освещении некоторых аспектов данной проблемы авторы учебников не учитывают ряд важных моментов. Читатель, в данном случае студент-историк, впервые встречается на страницах учебника с монголами и татарами, которые не дифференцируются и зачастую представляются как синонимы одного и того же народа-завоевателя. Более того, остаётся почва для отождествления этих татар (монголов) с современными татарами, одним из основных предков которых были волжские булгары. Студенты хорошо знают, что русские – это потомки восточных славян, но мало кто знает, особенно за пределами нашей республики, что современные татары – потомки волжских булгар и половцев-кыпчаков, местных народов края, покорённых монголами и включённых в состав созданного им государства Золотая Орда. Монголы не имеют практически никакого отношения к этногенезу современных татар. Справедливости ради следует заметить, что в аторском учебнике А.Г. Кузьмина об этом имеется необходимое разъяснение: «И исторически, и антропологически современные казанские татары – потомки волжских булгар, испытавших такое же разорение, как и Русь… Монголоидной примеси у казанских татар не больше, чем у русских»[29].

Второй момент, который, как правило, обходят молчанием авторы учебников, связан с феноменом золотоордынской цивилизации. Она, эта цивилизация, несомненно, существовала объективно, в реальности, вне

[28] Дворниченко А.Ю., Тот Ю.В., Хомяков М.В. История России. Учебник. М., 2005. С. 9.
[29] Кузьмин А.Г. Указ соч., кн. 2. С. 325.

зависимости от пристрастий учёных, что доказано всем комплексом исторических источников, в том числе и археологических. Эту цивилизацию характеризуют чрезвычайно высокий уровень развития градостроительства и городского хозяйства, ремесла и международной торговли с непривычно низкими таможенными пошлинами, а также упорядоченная система административно-государственного устройства и делопроизводства, религиозная терпимость, достижения в области науки и культуры, в частности, поэзии[30]. На наш взгляд, включение в учебники для вузов сюжета о золотоордынской цивилизации способствовало бы более глубокому пониманию процессов, происходивших в области ордынско-русских взаимоотношений.

Еще один аспект рассматриваемой проблемы связан с последствиями, причём исключительно негативными (с точки зрения авторов учебников), так называемого «монголо-татарского ига». На эту тему написано много как в научной, так и научно-популярной литературе. Не обходится она и авторами учебников. Наиболее концентрированно, на наш взгляд, мысль о масштабах и последствиях монгольских завоеваний выражена в учебнике А.Г. Кузьмина: «от ужасов татарского погрома мог бы проследиться антихрсит». По его подсчётам, население Руси в канун нашествия монголо-татар насчитывало 12 млн. человек. «Эта численность не будет достигнута даже в конце XVII в. … Археологи насчитывают в домонгольской Руси до полутора тысяч укреплённых поселений, примерно треть которых являлась городами. После монголо-татарского разорения не сохранились даже и названия многих городов, а скажем, плотность населения в Среднем Поднепровье в канун вторжения полчищ Батыя была затем достигнута лишь в XIX в."[31] В результате монголо-татарского ига Русь была отброшена в своём развитии на два века назад, утверждают практически все учебники.

Между тем в современной российской историографии всё чаще появляются научные труды, авторы которых на фактических материалах показывают надуманность такого рода утверждений[32]. Оказывается, в течение более двух столетий пресловутого «татарского ига» не была разрушена ни одна прославная церковь, наоборот, их количество увеличилось ровно в два раза. В два раза увеличилось и количество населения[33] и, самое главное, прекратились кровавые распри между князьями, готовыми разнести «свою Русь на бессвязные, вечно враждующие

[30] См.: Кульпин Э.С. Золотая Орда: проблемы генезиса Российского государства. М., 1988. С. 29–86.

[31] Кузьмин А.Г. Указ. соч. Кн. 1. М., 2003. С. 341.

[32] См.: Кульпин Э.С. Указ соч.; Русь в XIII веке: континуитет или разрыв традиций? Тез. док. нач. конф. М., 2000; Русь в XIII веке: древности тёмного времени / Под ред. Н.А. Макарова, А.В. Чернецова. М., 2003.

[33] Кузьмин А.Г. Указ. соч. Кн. 1. М., 2003. С. 66.

между собой удельные лоскутья»[34], была заложена прочная основа для формирования единого Русского государства[35]. Явление толерантности, о которой много говорим в последние годы, было естественным в повседневной жизни Улуса Джучи.

В 2000 г. учёные Института археологии РАН проводили конференцию «Русь в XIII веке: разрыв традиций или преемственность», на опубликованные материалы которой мы успели уже ссылаться выше. В своём выступлении на этой конференции член-корреспондент (ныне академик, вице-президент РАН), директор Института археологии Российской Академии наук Н.А. Макаров говорил: «Представление о катастрофе и последовавшем за ней разрыве культурных традиций базируется на ярких и достоверных свидетельствах письменных источников и обширном археологическом материале, казалось бы, идеально согласующихся между собой. Тезис о прямой связи между военным разгромом русских княжеств в 1237–1240 гг. и значительными изменениями русской культуры, утратившей в этот период многие яркие элементы, кристаллизовавшиеся в X–XII вв., постепенно стал общим местом в трудах по средневековой истории и археологии Восточной Европы. Между тем новые раскопки археологических памятников XII–XIV вв. в различных регионах Древней Руси открывают более противоречивую картину развития, … археология накапливает всё больше количество данных о том, что культурные изменения середины XIII в. не могут быть объяснены одним лишь внешним воздействием»[36].

Тезис о том, что монголо-татарами было разрушено более 23 древнерусских городов и 1/3 из них не были затем восстановлены, подвергнут сомнению А.В. Чернецовым: «Археологическая дата гибели большинства… городищ слишком широка для того, чтобы с достаточным основанием связывать каждое такое событие с монголо-татарским нашествием»[37]. По его данным, даже Киев и Рязань не были полностью уничтожены и вскоре после событий 1237 и 1240 гг. восстановлены, ибо в глазах ордынцев они представляли собой важные в военно-политическом отношении пункты[38].

Вот мнение известного исследователя археологии Киева Г.Ю. Ивакина: «Братские могилы, разрушенные каменные сооружения, клады, следы пожаров – всё это относилось исключительно к 1240 г., а вещи оттуда датировались соответственно. Считалось, что прекратилось производство стекла, пряслиц (шиферных. – *Ф.Х.*), ювелирных изделий и т.д. Отрицался сам факт наличия культурных слоёв в

[34] Ключевский В.О. Сочинения в девяти томах. Т. II / Под ред. В.Л. Янина. М., 1988. С. 41.
[35] Седов В.В. Указ. соч. С. 205 и сл.
[36] Русь в XIII веке: континуитет или разрыв традиций? С. 5.
[37] Там же, с. 11.
[38] Там же, с. 12, 87.

Верхнем Киеве до XVII в. Но не учитывались разгромы и осады города (русскими же. – *Ф.Х.*) в 1203, 1300, 1399, 1482 гг., возможные пожары, стихийные бедствия этого времени. Каменные соборы Киева (если не считать Десятинной церкви) не были разрушены монголами в 1240 г. Археология таких случаев не фиксирует... Продолжалось развитие материальной культуры XI–XII вв., обусловленное, прежде всего, внутренними факторами, которые были осложнены внешними ударами. Последнее касалось лишь отдельных аспектов и сторон культурной ситуации, а не её глубинной основы. Разрыва традиций не было»[39].

Ведущие московские археологи Л.А. Беляев и Т.Д. Панова подчёркивают, что «на развитии Москвы, как, вероятно, и для многих других территорий Руси, это столетие отнюдь не было катастрофическим»[40], наоборот, «в истории города это был период бурного развития и роста», который в новых, благоприятных для Москвы условиях вскоре положил начало стремительному политическому взлёту[41].

Таких примеров можно было привести множество[42]. К сожалению, они игнорируются авторами наших учебников. Только в одном учебнике я нашёл объективную оценку последствий монгольского «ига»: «История Золотой Орды представляет важную страницу нашей российской истории, но, может быть, ещё более важно то, что этому бесспорно восточному по своему типу государству предстояло сыграть огромную роль в дальнейшей истории Руси. По его подобию сформировались многие институты власти, явления будущей Московии, возникла соответствующая социальная психология»[43].

В истории Казанского ханства – «паразитарного образования, подвергавшего эксплуатации и прямому ограблению поволжские народы»[44], «сильного и агрессивного государства, совершавшего постоянные набеги на территории России»[45], учебники с той или иной степенью подробности освещают лишь ход и итоги «Казанского взятия» 1552 г., когда Иваном Грозным было освобождено якобы 100 тысяч угнанных в рабство русских, вынужденных влачить жалкое существование среди 10–12 тысячного мусульманского населения Казани.

Если верить авторам учебников, «летописные известия за 50-е годы XVI в., заполнены постоянными прошениями населения о принятии в российское подданство». Добро-

[39] Там же, с. 48–49.
[40] Там же, с. 17.
[41] Там же, с. 79.
[42] См.: Орлов А.С., Георгиев В.А., Георгиева Н.Г., Сивохина Т.А. История России. Изд-е 2-е, перераб. и доп. М., 2004.
[43] Дворниченко А.Ю., Тот Ю.В., Ходяков М.В. Указ соч., с. 64.
[44] Кузьмин А.Г. Указ. соч. Кн. 2. С. 246–247.
[45] Дворниченко А.Ю., Тот Ю.В., Ходяков М.В. Указ соч., с. 104.

вольно сдалась Астрахань, к Москве потянулся едва ли не весь Кавказ, из далёкой Сибири едут служилые татары. «Власть Москвы для всех них была большим облегчением»[46]. Как говорится, комментарии излишни.

* * *

Национальный вопрос – один из тех, что определяет судьбу сегодняшней России. И он всегда будет стоять на повестке отечественной истории, потому что наша страна может существовать только как полиэтничное и поликонфессиональное государство. Каждая эпоха – в зависимости от своего масштаба и стиля – ставит его в самых разных формах. От того, как ставятся и решаются на страницах школьных и вузовских учебников вопросы межэтнических отношений прошлого, зависит воспитание подрастающего поколения в духе толерантности, подлинного уважения к истории и культуре всех народов страны. Начавшиеся конфликты на национальной почве в современной России – симптомы очень тревожные. Очень не хотелось бы, чтобы в числе причин таких конфликтов фигурировало предвзятое и унизительно-ложное освещение в наших учебниках истории так называемых неславянских народов, «инородцев.

*Историческое образование в вузах Казани.*
*Материалы научно-практической конференции.*
*Казань, 2006. С. 45–56.*

*От ответственного редактора:* В 2024 году Институт Российской истории РАН начал издавать «Историю России в двадцати томах». Во втором томе этого издания помещена специальная глава, посвященная истории Волжской Булгарии и финно-угорских народов Поволжья (Хузин Ф.Ш., Ситдиков А.Г., В.Ю. Коваль. Волжская Булгария и народы Волго-Уральского региона // История России: в 20 т. Т.2. Государства и народы на территории России в VI – середине XIII века / отв. ред. А.А. Горский. М.: Наука, 2024. С. 785–804). Издание примечательно тем, что в нем в качестве авторов участвуют и ведущие специалисты из регионов, которые, судя по содержанию указанного труда, представили объективные материалы по средневековой истории своих регионов, не оставляющие места разным толкованиям. Надеемся, что и по более поздним периодам, связанным с историей Золотой Орды и Казанского ханства, эта тенденция сохранится. А авторы будущих учебников для вузов должны будут ориентироваться на основополагающие идеи нового издания «Истории России».

[46] Кузьмин А.Г. Указ. соч. Кн. 2. С. 247.

## Кыскартмалар исемлеге

АН РТ – Академия наук Республики Татарстан. Казань

БАН – Болгарская академия наук. София

ГАИМК – Государственная академия истории материальной культуры. М.

ГИМ – Государственный исторический музей. М.

ГЭ – Государственный Эрмитаж. Л.; СПб.

ИА – Институт археологии

ИИЯЛ БФАН СССР – Институт истории, языка и литературы Башкирского филиала Академии наук СССР. Уфа

КСИА – Краткие сообщения Института археологии АН СССР (РАН). М.

Удм. ИИЯЛ УрО РАН – Удмуртский институт истории, языка и литературы Уральского отделения Российской Академии наук. Ижевск

ИЯЛИ КФАН СССР – Институт языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова Казанского филиала АН СССР. Казань

КГУ – Казанский государственный университет им. В.И. Ульянова-Ленина

КНЦ РАН – Казанский научный центр Российской Академии наук

КФАН СССР – Казанский филиал Академии наук СССР

КФУ – Казанский Федеральный университет

МарАЭ – Марийская археолоическая экспедиция. Йошкар-Ола

МИА – Материалы и исследования по археологии СССР. М.; Л.

НЦАИ – Национальный центр археологических исследований им. А.Х. Халикова

ПСРЛ – Полное собрание русских летописей

РА – ж. «Российская археология». М.

РАН – Российская Академия наук

РИЦ – Редакционно-издательский центр

СА – ж. «Советская археология». М.

САИ – Свод археологических источников. М.

СГУ – Самарский государственный унивнерситет

СПбГУ – Санкт-Петербургский государственный унивнерситет

ТГГПУ – Татарский государственный гуманитарно-педагогический университет. Казань

ЧГИГН – Чувашский государственный институт гуманитарных наук. Чебоксары

ЧувНИИ – Чувашский Научно-исследовательский институт языка, литературы, истории и экономики при Совете министров Чувашской АССР. Чебоксары.

*Научное издание*

**Фаяз Шарип улы Хуҗин**
**Болгар-татар тарихыннан сайланма хезмәтләр**

**Фаяз Шарипович Хузин**
**Избранные труды по болгаро-татарской истории**

Под редакцией академика АН РТ
А.Г. Ситдикова

Оригинал-макет
*Асылгараева Г.Ш.*

Подписано в печать 28.07.2026 г.
Формат 70x100 1/16. Усл. печ. л. 26,65.
Общий тираж 500 экз. Первый завод 300 экз.
Заказ № 28.7/1

Оригинал-макет подготовлен
в Институте ахеологии им. А.Х. Халикова АН РТ
420111 г. Казань, ул. Баумана, 20

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111 г. Казань, ул. Баумана, 20

Отпечатано с готового оригинал-макета
ИП Казанцев Д.В.
420034, г. Казань, ул. Энергетиков, д. 5

16+